УФИМСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ

приоритет2030^
лидерами становятся

# АКТУАЛЬНЫЕ ПРОБЛЕМЫ СОВРЕМЕННОЙ ТАТАРСКОЙ ФИЛОЛОГИИ

**Сборник статей XII Международной очно-заочной научно-практической конференции, посвященной юбилеям ветеранов кафедры:**
**100-летию со дня рождения Народного писателя Республики Башкортостан, доктора филологических наук, профессора С.Ш. Поварисова,**
**90-летию со дня рождения доктора филологических наук, профессора Р.Г. Сибагатова,**
**85-летию со дня рождения кандидата филологических наук, доцента Р.М. Мухаметзянова**
**(г.Уфа, 22 ноября 2024 г.)**

**МИНИСТЕРСТВО НАУКИ И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ РФ**
**УФИМСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ НАУКИ И ТЕХНОЛОГИЙ**

# АКТУАЛЬНЫЕ ПРОБЛЕМЫ СОВРЕМЕННОЙ ТАТАРСКОЙ ФИЛОЛОГИИ

***Сборник статей***
***XII Международной очно-заочной научно-практической конференции, посвященной юбилеям ветеранов кафедры:***
***100-летию со дня рождения***
***Народного писателя Республики Башкортостан,***
***доктора филологических наук,***
***профессора С.Ш. Поварисова,***
***90-летию со дня рождения доктора филологических наук,***
***профессора Р.Г. Сибагатова,***
***85-летию со дня рождения кандидата филологических наук,***
***доцента Р.М. Мухаметзянова***
***(г. Уфа, 22 ноября 2024 г.)***

Научное электронное издание сетевого доступа

**Уфа**
**РИЦ УУНиТ**
**2024**

УДК 811.512.145+80
ББК 81.2Тат+80
А43

*Печатается по решению кафедры татарской филологии
и культуры УУНиТ.
Протокол № 3 от 17.11.2024 г.*

***Редакционная коллегия:***
канд. филол. наук, доцент **И.Ф. Зарипова** *(отв. редактор)*;
канд. филол. наук, доцент **И.К. Фазлутдинов** *(отв. редактор)*;
канд. филол. наук, доцент **Г.У. Гайнуллина**

А43 Актуальные проблемы современной татарской филологии: сборник статей XII Международной очно-заочной научно-практической конференции, посвященной юбилеям ветеранов кафедры: 100-летию со дня рождения Народного писателя Республики Башкортостан, доктора филологических наук, профессора С.Ш. Поварисова, 90-летию со дня рождения доктора филологических наук, профессора Р.Г. Сибагатова, 85-летию со дня рождения кандидата филологических наук, доцента Р.М. Мухаметзянова (г. Уфа, 22 ноября 2024 г.) / отв. ред. И.Ф. Зарипова; И.К. Фазлутдинов. [Электронный ресурс] / Уфимск. ун-т науки и технологий. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2024. – 376 с. – URL: https://uust.ru/digital-publications/2024/254.pdf – Загл. с титула экрана.
ISBN 978-5-7477-6017-2

Сборник статей включает исследования, посвященные актуальным проблемам татарской лингвистической науки, тюркологии, сравнительно-исторического и сопоставительного языкознания, лингвокультурологии и когнитивной лингвистики, литературоведения, фольклора и методики преподавания родных языков и литератур в условиях новых образовательных стандартов.

Сборник предназначен для научных сотрудников, преподавателей вузов, ссузов, учителей образовательных учреждений, аспирантов, магистрантов и студентов.

УДК 811.512.145+80
ББК 81.2Тат+80

ISBN 978-5-7477-6017-2 © УУНиТ, 2024

УДК 811.512.145

**Гайнуллина Г.У.,**
*Уфа ш., Россия*

# ГАЛИ УЛЫ – ГАЛИ ЗАТ (ПРОФЕССОР Р.Г. СИБӘГАТОВ ТУРЫНДА)

***Аннотация:*** *мәкаләдә филология фәннәре докторы, профессор Радик Гали улы Сибәгатовның фәнни хезмәтләренең төп юнәлешләре карала.*

***Терәк сүзләр:*** *галим, укытучы, татар теленең синтаксисы, предикативлык теориясе, этнолингвистика, татар теленең статусы.*

Дөньяда фәнни эшләре язылуга күп еллар үтсә дә, актуальлеген югалтмаган галимнәр бар. Аларның фәнни хезмәтләре фундаменталь һәм алга таба тикшеренүләр өчен нигез булып тора. Мондый галимнәргә, һичшиксез, филология фәннәре докторы, профессор Радик Гали улы Сибәгатовны кертергә була.

Радик Гали улы Сибәгатов 1958 елда Бөре дәүләт педагогика институтын «татар мәктәпләре өчен рус теле һәм әдәбияты» белгечлеге буенча, 1966 елда Ленинград югары педагогика мәктәбенең матбугат хезмәткәрләре бүлеген тәмамлый. Филология факультетында укыганда алган рус теле буенча белемнәре Р.Г. Сибәгатовка алга таба рус һәм татар телләрен чагыштырма аспектта өйрәнергә мөмкинлек бирә.

Профессор Р.Г. Сибәгатовның фәнни тикшеренүләрен өч төп юнәлешкә бүлеп карарга була:

1) тәрҗемә теориясенең лингвистик мәсьәләләре;
2) Хәзерге татар теленең синтаксисы (коммуникатив аспект);
3) БР татарларының лингвоэтнотарихы, социолингвистика.

Р.Г. Сибәгатов – рус теленнән татар теленә тәрҗемә мәсьәләләре буенча беренче китапларның авторы. (Тәрҗемә методикасы нигезләре, Уфа, БашДУ, 1979). 1970 елда ул «Рус теленнән татар теленә тәрҗемәнең кайбер синтаксик мәсьәләләре» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Һәм бүген дә «Тәрҗемә методикасы нигезләре» белгечләр өчен өстәл китабы булып тора.

1987 елда докторлык диссертациясе сыйфатында аның «Предикативлык теориясе (татар теле материалында)» дигән монографиясе яклана. Яклау Алма-Атада, Казах ССР Фән Академиясенең тел белеме институтында уза. Диссертациянең төп материалы «Советская тюркология» һәм «Вопросы языкознания» журналларында басылып чыга. Галим «Предикативлык теориясе» дигән монографиясендә тюркологиядә

беренче булып җөмләнең төп билгесе булган предикативлык категориясен тикшерә. Бу китапта предикация күренешен лингвистик билгеләү, предикатив мөнәсәбәтне белдерү ысуллары һәм чаралары, ярымпредикативлык, предикатив конструкциянең модаль конституенты кебек мәсьәләләр карала.

«Җөмләнең хәзерге теориясе предикация күренешенең лингвистик табигатен билгеләмичә яисә аны лингвистик интерпретацияләмичә мөмкин түгел. Предикативлык теориясен эшләгәндә лингвистлар еш кына мантыйкта эшләнә торган фикер теориясенә мөрәҗәгать итәләр. Һәм бу тулысынча закончалыклы: предикация күренеше җөмлә (тел категориясе) нигезендә генә түгел, ә фикер (фикерләү категориясе) нигезендә дә ята. Бу шундый чынбарлык, ул җөмлә һәм фикерне аермый, ә берләштерә — лингвистика һәм мантыйкның тикшеренү объектлары» [3; 4]. Синтаксист буларак, Р.Г. Сибәгатовның барлык фәнни әсәрләрендә дә фикерләүнең төгәллеге, логикалылыгы өстенлек итә. Профессор һәрвакыт үзенең бөтен эшләрен ахырына кадәр җиткерә, җаваплылык, принципиальлек, дисциплиналылык, зыялылык аның характерының төп билгеләре булып тора иде.

Галимнең моннан 30-40 ел элек басылып чыккан фәнни хезмәтләре төрки телләр синтаксисы буенча иң еш кулланыла торган һәм цитаталана торган теоретик тикшеренүләр рәтендә хәзер дә кала килә.

Радик Гали улы 200 дән артык фәнни хезмәт бастырган. Алар арасында 9 монография һәм синтаксис, лингвоэтнотарих, социолингвистика теоретик мәсьәләләре буенча уку әсбаплары бар. Ул күп кенә укыту-методик басмалар авторы. Профессор Р.Г. Сибәгатовның фәнни эшләре Башкорт дәүләт университеты, М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университеты, Казан федераль университеты Гыйльми Советлары тарафыннан расланган «Хәзерге татар әдәби теле» курсы буенча программаның төп әдәбият исемлегенә кертелде. Профессор Р.Г. Сибәгатов соңгы елларында Башкортстан Республикасында татар теленең хокукый статусы проблемасына багышланган хезмәтләр бастырып чыгарды Әлеге проблеманы ул социолингвистика, халыкара хокук һәм дөнья практикасы мәгълүматларын исәпкә алып анализлый. Теоретик тикшеренүләр белән бер үк вакытта профессор Р.Г. Сибәгатов Башкортстанда татар теленең статусы проблемасын практик чишү буенча зур иҗтимагый эш алып бара. Аның җитәкчелегендә галимнәрнең вузара комиссиясе тарафыннан «Башкортстан Республикасы халыклары телләре турында» законның альтернатив проекты эшләнә, ул 1998 елда Дәүләт җыелышына карауга кертелә. 2004 елның июнендә Башкортстан татарлары иҗтимагый оешмалары берлеге Р.Г. Сибәгатов докладе буенча Башкортстан

Республикасында татар теленең статусы проблемасы буенча референдум үткәрү кирәклеге турында Карар кабул итә.

Профессор Р.Г. Сибәгатов күп еллар дәвамында «Россия Федерациясе халыклары телләре» буенча докторлык диссертацияләре, «Гомуми, чагыштырма-тарихи тел белеме» буенча кандидатлык диссертацияләрен яклау советы әгъзасы булды.

Фән һәм югары белем өлкәсендәге казанышлары өчен профессор Р.Г. Сибәгатовка «Башкортстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» (1993), «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» (2005) дигән мактаулы исемнәр бирелде, ул СССР һәм РФ Югары уку йортлары Министрлыгының «Хезмәттәге зур уңышлары өчен» (1985) һәм «Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирүнең Мактаулы хезмәткәре» (2002) кебек билгеләр белән бүләкләнде.

Радик Галиевичның студенты һәм аспиранты буларак, шуны әйтә алам: ул танылган галим генә түгел, искиткеч остаз да иде, шәкертләре белән эшләүдә аның девизы булып А.С. Экзюперинең «Мы в ответе за тех, кого приручили» дигән сүзләре тора алыр иде. Ул безне һәрвакыт курчалап, яклап, саклап торды. Диссертация язганда, ул минем өчен иң төп мотиватор булды. «Бик шәп эш килеп чыга, син булдырасың», – дип мине һәрвакыт канатландырып торды. Мин, һичшиксез, Сибәгатовның шәкерте булу белән горурланам һәм бик бәхетлемен.

**Әдәбият исемлеге**


1. Сибагатов Р.Г. Основы методики перевода. – Уфа: РИЦ БашГУ, 1979. – 72 с. (на тат. яз).
2. Сибагатов Р.Г. Основные признаки предложения. Уфа, РИЦ БашГУ, 1980. – 84 с. (на рус. яз.).
3. Сибагатов Р.Г. Теория предикативности (на материале татарского языка), Саратов: Изд. СГУ, 1984. – 208 с. (на рус. яз.).
4. Сибагатов Р.Г. Строение предложения. Уфа, изд.БашГУ, 1991. – 76 с. (на тат. яз).
5. Сибагатов Р.Г. Полемика о татарах Башкортостана и их языке. – Уфа: ТиД, 1997. – 54 с. (на тат. яз).
6. Сибагатов Р.Г. О правовом статусе языков в Башкортостане. – Уфа: Изд. РОО «Азатлык», 1997. – 54 с. (на тат. яз).
7. Сибагатов Р.Г. Татары Башкортостана. Проблемы языка, истории, культуры. – Казань: Изд. «Магариф», 2002. – 170 с. (на тат. яз.).
8. Сибагатов Р.Г. Проблемы статуса татарского языка в Башкортостане. – Уфа: Изд. БГПУ, 2004. – 120 с. (на тат. и рус. яз., в соавторстве).

9. Сибагатов Р.Г. Съезд татар Башкортостана. – Уфа: Изд. БГПИ, 2004. – 175 с. (на тат. и рус. яз.).

© Гайнуллина Г.У., 2024

УДК 811.512.145

**Зарипова И.Ф.,**
*Уфа ш., Россия*

## ГАЛИ ГАЛИМ, ЗЫЯЛЫ ЗАТ

***Аннотация:*** *мәкаләдә филология фәннәре докторы, профессор Радик Гали улы Сибәгатовның фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешләре анализлана. Аның синтаксис, тәрҗемә белеме һәм социолингвистика өлкәләрендәге фәнни хезмәтләренең әһәмияте ассызыклана.*

***Терәк сүзләр:*** *галим, татар теле, лингвистика, синтаксис, тәрҗемә белеме, социолингвистика.*

Татар теле һәм әдәбияты буенча үткәрелгән Республика олимпиадасында комиссия рәисен барыбыз да күреп белсәк тә, профессор Радик Гали улы Сибәгатовның үзе белән шәхсән соңрак, ямьле җәй көннәренең берсендә, танышырга туры килде.

Олимпиада нәтиҗәләре буенча Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе бүлегенә сынауларсыз укырга керү бәхетенә ия булып, документларымны тапшырып кайтып, бик бәхетле халәттә йөргәндә генә әлеге уку йортыннан имтиханнардан азат итүче мактау кәгаземне кабул итү комиссиясенә калдырмаганлыгым турында шалтыраттылар. Өстәвенә, иртәгә китермәсәгез, исемлеккә сезне кертмәячәкләр дип искәртеп тә куйдылар.

Икенче көнне үк Уфага юлланырга туры килде, әмма эш бик ансат кына барып чыкмады: махсус кәгазьдән башка һич кенә дә бу мәһабәт бинага үтә алмавым ачыклангач, әлеге уку йорты белән бернинди генә дә элемтәсе булмаган гади авыл кызының төшенкелеге бераз күз алдына киләдер, мөгаен. Җитмәсә, мәсьәлә уңай хәл ителмәсә, бу уку йорты белән һич кимендә берәр елга хушлашып торырга туры киләчәк, дигән күңелсез уйлар да куера башлады.

Шулай да берникадәр вакыттан соң татар филологиясе кафедрасының телефонына шалтыратып, хәлне бераз аңлаткач, ниндидер могҗиза көткәндәй, безгә ярдәм итүче, бу ябык ишекләрне ачтыручы берәр кешенең чыгарына өметләнеп, күзләрне ишеккә төбәдек.

Шул вакыт, әкият сараеннан безнең тарафларда пәйда булган тылсымлы зат кебек диимме, күкләрдән иңгән илаһи фәрештәдәй дияргәме, алдыбызга зыялылыгы белән ниндидер бер нур булып үзенә тартып торучы мөхтәрәм мөгаллим – профессор Радик Гали улы үзе безнең янга салмак кына атлап чыгып килә иде. Мөлаем елмаеп исәнләште дә, хәлләрне сорашкач, миңа сакта торган әкияттәге «сарай сакчыларын» хәтерләткән абыйларга итәгатьле итеп нидер эндәшеп, миңа ымлап үзеннән алда керергә юл бирде... Шулай Радик Гали улы миңа бу белем иленең ишекләрен ачучы гына түгел, тормышымны шушы уку йорты белән бәйләргә юллама тапшыручы Олуг Остазым булып китте. Соңыннан Радик Галиевич җитәкчелегендә кандидатлык диссертациясен яклау һәм укытучымнан кафедрада эшкә калырга чакыру алу бәхете тиде. Аның укучысы булуым белән мин бик горурланам.

Филология фәннәре докторы, профессор Радик Гали улы Сибәгатов 1934 елның 29 маенда Башкортстанның Балтач районы Иске-Балтач авылында туа. 1958 елда Бөре дәүләт педагогия институтының филология факультетының татар мәктәпләре өчен рус теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, 1966 елда ул Ленинград шәһәрендәге югары партия мәктәбенең матбугат эшчеләре бүлегендә белемен камилләштерә.

Профессор Р.Г. Сибәгатовның фәнни тикшеренүләр өлкәсе күпкырлы. Ул тәрҗемә теориясенең лингвистик мәсьәләләре, хәзерге татар теле синтаксисы (коммуникатив аспект), Башкортстан Республикасы татарларының лингвоэтнотарихы, социолингвистика юнәлешләрендә тирән эзләнүләр алып бара.

Һөнәри эшчәнлеген 1957 елда Республиканың «Кызыл таң» гәзите редакциясендә башлаган яшь белгеч тәрҗемәче, тәрҗемәчеләр төркеменең җитәкчесе, махсус корреспондент, совет төзелеше бүлеге мөдире, хатлар бүлеге мөдире, мәгълүмат бүлеге мөдире, авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире вазыйфаларын башкара. Редколлегия әгъзасы була. «Кызыл таң»да тәрҗемәче булып эшләгән тәҗрибәсе, күзәтүләре, тикшеренүләре бу өлкәдә бүгенге көндә дә файдалы һәм әһәмиятле булган хезмәтләрен язарга этәргеч бирә. Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү мәсьәләләләренә багышланган 1979 елда беренчеләрдән булып нәшер ителгән «Тәрҗемә методикасының нигезләре» дип исемләнгән китапның авторы – Р.Г.Сибәгатов. Аның кандидатлык диссертациясе дә тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган, темасы «Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итүнең кайбер синтаксик мәсьәләләре» дип атала.

Радик Гали улы Сибәгатов гомеренең 35 елын Башкорт дәүләт университетында татар филологлары әзерләүгә багышлый. Бу вакыт аралыгында ул ассистенттан башлап кафедраның профессоры дәрәҗәсенә

кадәр ирешә. 17 ел дәвамында Радик Гали улы җитәкләгән татар филологиясе кафедрасы юлламасы алган шәкертләр – бүген Башкортстанның гына түгел, илебезнең башка өлкәләренең мәктәпләрендә, югары уку йортларында белем бирүче меңәрләгән укытучылар, шулай ук төрле-төрле матбагаларда, телевидениеләрдә эшләүче бихисап журналистлар. Фән һәм югары белем бирү өлкәсендәге казанышлары өчен Р.Г. Сибәгатов 1993 елда «Башкортстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе», 2004 елда «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәргә лаек була. 1985 елда «Хезмәттәге югары уңышлар өчен» һәм «Русия Федерациясенең югары һөнәри белем бирүнең мактаулы хезмәткәре» дигән билгеләргә ия.

Университетта профессор Р.Г. Сибәгатов «Хәзерге татар әдәби теле», «Башкортстан Республикасы татарларының лингвоэтнотарих проблемалары» курслары буенча лекцияләр укый, махсус курслар алып бара иде. Аның лекцияләрен сәбәпсез калдыручы студентларны бер дә хәтерләмим. Дәресләренә зур кызыксыну белән йөри идек, чөнки биредә синтаксисның теоретик мәсьәләләре, лингвоэтнотарих, социолингвистика буенча бик күп фәнни хезмәтләр авторы, мәртәбәле галим фән серләре белән таныштыра, аның нечкәлекләрен аңлата. Бүгенге көндә дә аның укыту-методик кулланма чыганаклары – безнең үзебезнең генә түгел, укучыларыбызның да өстәл әсбабы. Р.Г. Сибәгатовның хезмәтләре Башкортстан, Татарстанның гына түгел, башка төбәкләрнең югары уку йортларындагы укыту программаларының әдәбият исемлекләрендә урын алган.

1984 елда үз чорының фән мәркәзе булган Саратов шәһәрендә монография бастырып чыгаруы галимнең тикшеренүләренең гомуми тел белемендә әһәмиятле фундаменталь хезмәтләрнең берсе булып торуын дәлилли. «Предикативлык теориясе» дип исемләнгән бу монографиясен галим 1987 елда Казахстанның Алма-Ата шәһәренең фәннәр академиясенең тел белеме институтында докторлык диссертациясе дәрәҗәсендә уңышлы яклап чыга. Диссертациянең мөһим өлешләре үзәк матбугатта – «Совет тюркологиясе» һәм «Тел гыйлеме мәсьәләләре» журналларында күләме белән 9 басма табак булып 10 мәкаләдә дөнья күрә. Бу хезмәт – кырык ел элек басылып чыгуына карамастан, төрки телләр синтаксисы буенча актуальлеген бүгенге көндә дә югалтмаган, киң файдаланылуда булган теоретик хезмәтләрнең берсе.

Р.Г.Сибәгатов татар милләте, халкы, теле өчен җан атып яшәгән толерантлы милләтпәрвәр шәхес иде. Үзенең Башкортстан татарларының этник тарихы, тел статусы һәм милли-мәдәни үсеше проблемаларына багышланган «Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният

мәсьәләләре» дип исемләнгән гыйльми-публицистик хезмәтендә Радик Гали улы Республиканың көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш районнарында яшәүче халыкларның милли мөнәсәбәтен һәм туган телен билгеләүне югары квалификацияле филолог буларак кына түгел, яхшы хәзерлекле политолог буларак та анализлый. Татарстан Республикасының Фәннәр Академиясе гуманитар институтларының гомумтеоретик концепцияләре юнәлешендәге катлаулы мәсьәләләрне чишүгә яраклы, кабул итәрдәй алымнар тәкъдим итә.

Галимнең аерым хезмәтләре Башкортстан Республикасында татар теленең хокукый статус мәсьәләләренә багышлана. Әлеге проблеманы ул социолингвистика, халыкара хокук һәм дөнья сәясәте буенча белешмәләр нигезендә тасвирлый. Теоретик тикшеренүләр белән беррәттән, Р.Г. Сибәгатов Башкортстан Республикасындагы татар теле статусы мәсьәләләренең практик чишелеше буенча күләмле иҗтимагый эш алып бара. Аның җитәкчелегендә галимнәрнең вузара комиссиясе тарафыннан «Башкортстан Республикасы халыкларының телләре турындагы Законның» альтернатив проекты әзерләнә. Ул 1998 елда Дәүләт җыелышына тәкъдим ителә. 2004 елның июнь аенда Башкортстан татарларының иҗтимагый оешмалары берләшмәсе профессор Р.Г. Сибәгатов докладлы буенча Башкортстан Республикасында татар теле статусы мәсьәләләре буенча референдум үткәрүнең әһәмиятлелеге турында карар кабул итә. «Тарихыбызга һәм бүгенге реаль хәлебезгә объектив бәя булганда, Башкортстанда милләтара мөнәсәбәтләр концепциясе яңабаштан каралырга тиеш була. Шундый зур бер хакыйкать өскә чыга бара: Башкортстанда татар мәсьәләсен башкорттан, башкорт мәсьәләсен татардан аерым хәл итү мөмкин түгел. Бу бәйләнеш Башкортстан Республикасының нигезендә ята», – дип яза галим. Бу катлаулы мәсьәләләрнең халкы өчен уңай чишелешенә ирештерү теләге белән гомеренең соңгы көненә кадәр янып яшәде ул.

Олуг остазыбымның рухы, аның үрнәге, минемчә, һәрчак ярдәмгә ашкынып, эшләрне уңышлы башкарып чыгарга этәргеч көч бирәдер кебек тоела.

Без, кафедра әгъзалары, бүген дә олуг профессорыбызны, аның тугры хезмәтен олы хөрмәт, җылы сагыну сүзләре белән искә алабыз, әйткән киңәш-сүзләрен рухи мирас итеп саклыйбыз. Килеп туган четерекле хәлләрдә «Эх, Радик Галиевич булса...» диюләребез дә һәркайсыбызның остазыбызны юксынуы һәм аңа карата тирән ихтирамы турында сөйли.

© Зарипова И.Ф., 2024

УДК 811.512.145

**Насибуллина Н.Ш.,**
*Казан ш., Россия*
**Эшчанова Г.О.,**
*Ургенч ш., Үзбәкстан*

# СУФИЯН ПОВАРИСОВ ИҖАТЫНА, ФӘННИ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ КҮЗӘТҮ

***Аннотация:*** *мәкаләдә татар язучысы, филолог һәм педагог, күренекле әдәби тәнкыйтьче һәм пубицист С. Поварисовның (1924-2016) татар әдәбияты тарихын үстерүгә керткән өлешләренең берсе буларак әдәби иҗаты карала.*

***Терәк сүзләр:*** *С. Поварисов, Г. Ибраһимов, татар әдәбияты, трилогия.*

Күпмилләтле Ватаныбыз халыкларының культурасы тарихында үзенең үлемсез әсәрләре белән халкына, аның сәнгатенә шөһрәт китергән шәхесләр аз түгел. Шундый шәхесләрнең берсе – Башкортстанның халык язучы, күренекле галим, Башкорт дәүләт университеты профессоры, филология фәннәре докторы, Башкортстан һәм Татарстан республикаларының атказанган фән эшлеклесе, РФ югары белем бирү учреждениеләренең шәрәфле хезмәткәре, Г. Ибраһимов исемендәге премия лауреаты Суфиян Шәмсетдин улы Поварисов. Ул берьюлы берничә юнәлештә – әдәби иҗатта да, тел гыйлеме өлкәсендә дә уңышлы эшләп килә. Иҗатын шагыйрь булып башлап җибәргән әдип әдәбиятның драматургия, публицистика, әдәби тәнкыйть, аеруча проза тармагындагы роман-повестьлары, хикәяләре белән китап сөючеләрне сөендерде, аның тугыз романы басылды. Аларда татар халкының бай рухи дөньясы, авторның кешеләр язмышына педагогларча каравы, кешелеклелек мәсьәләсе, халык язмышы беренче планга куела.

С. Поварисов илһамының бер канаты төрле характердагы, төрле жанрдагы әдәби иҗаты булса, икенче канаты – олы гыйльми эшчәнлеге. Ул Г. Ибраһимов әсәрләренең тел үзенчәлекләрен тикшерү өстендә иң күп эшләгән галимнәрнең берсе. «Татар әдәби телен үстерүдә Г. Ибраһимовның эшчәнлеге» дигән темага докторлык диссертациясен уңышлы яклый. Галимнең фәнни хезмәтләре язучылык эшчәнлегеннән аерылгысыз.

С. Поварисов – ике трилогия авторы. Тәүге трилогиясе Бөек Ватан сугышы темасына багышланган «Язмыш корбаннары», «Ут эчендәге мәхәббәт», «Канлы бәхет» романнарын берләштерә.

Икенче трилогия-эпопея бөек язучы, Хезмәт батыры, тиңдәшсез сүз сәнгате остасы, репрессия корбаны, яңа татар совет әдәбиятына нигез салучы әдипләрнең берсе, талантлы тәнкыйтьче, әдәбият теоретигы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовка багышланган.

«Пәйгамбәр таңы» романында XIX һәм гарасатлы XX гасырлар кисешкән чорда Башкортстанның хәзерге Авыргазы районы Солтанморат авылында туып, тарихка канлы вакыйгалары, сыйнфый бәрелешләре белән кереп калган фаҗигале елларда шәхес буларак формалашкан Г. Ибраһимовның балачак һәм яшүсмер еллары сурәтләнә.

Әсәр баланың дөньяга килүе, аңа исем кушу вакыйгалары белән башланып китә. Исеме җисеменә туры килсен, йөрәк тибешен, эчке дөньясын, күңел хәзинәсен, эчке холык-фигылен аңлатып торсын, дәвер пәйгамбәре исемен йөретерлек укымышлы, акыллы, галим кеше булсын иде, дип, Гыйрфан мулла улына Галимҗан исемен куша. Аның фамилиясе дә Ибраһим Галәйһиссәламнең исеменнән алынган, чөнки нәсел тамыры Ибраһим хәзрәттән килә.

Романда кешелеклелек, кечелеклелек, кеше бәхете өчен яшәү алгы планга куела. Әсәрнең кыйммәте дә әнә шунда. Гыйрфан мулла белән Хәсәнә абыстай шуларның бөек үрнәген күрсәтеп яшиләр, балалары күңеленә дә шундый орлыкларны салалар. Язучы кешеләрне Галимҗан тарафыннан 4 төркемгә бүлдерә: «Югарыга әтисен дә куеп карады ул. Ләкин башлык түгел. Шуңа күрә ил, халык мәнфәгате белән яшәү ягыннан караганда, аны өстән аска табан икенче баскычка бастырырга мөмкиндер. Яхшы, иҗтиһадлы башлыкка ул җанын фида кылырга да әзер тора. Өченче төркемгә Мөбахис мәзин кебек хәйләкәрләр керә. Дүртенчесенә – староста Тәхлис ишеләр. Аларга арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит. Ә менә Хөрмәтулла абзый сыманнарны кая куярга? Андыйлар, үзләре кыерсытылган булсалар да, башкаларга яманлык теләми. Димәк ки, олы йөрәкле, киң күңелле, кешелекле булып чыгалар. Алар икенче төркемнең бер күзәнәге... » [1; 263].

Галимҗан турында әтисе горурлык белән: «Әнә нинди ул үстерәбез... – кайбер утын авыз кебек Хәрти дими бит. Матур итеп, олыларны кадер-хөрмәт итү йөзеннән, эчке бер җылылык, илаһилык белән «Хөрмәтулла абзый» дип әйтә. Димәк ки, һәр адәми затны кешегә саный. Ул гына да түгел, аның язмышы өчен ут йотып, үрсәләнеп йөри. Югалган сарыкны көне буе эзләп иза чиккәннәр. Дөрес әйтә бит, шайтан алгыры: «Ырынбур качмас әле» – ди. Әйе, Оренбург качмый да, югалмый да, җир дә упмый аны. Ә кеше югалса? Тап син аны яңадан. Менә бит ничек зур уйлый бу «таш маңгай» Пәйгамбәрләр башы бар анда. Пәйгамбәрләр башы!» [1; 110].

Ходай Тәгаләнең пәйгамбәрләре кешелек дөньясын вәхшилектән, кыргыйлыктан йолып калып, халыкны тәрбияләгән, Ходай Тәгалә кушкан якты юлга чыгарган. Аларның бу миссиясе язучыларга тапшырылган, алар пәйгамбәрләр кебек үк, кешелек дөньясын матурлыкка өндәгән, кешеләрдә үзара дус булу, тыныч тормышта яшәү, бер-береңне хөрмәт итү кебек асыл сыйфатлар тәрбияләгән.

Солтанморат, Зәңгәр Чишмә буйларының искиткеч гүзәл табигате кешеләрнең якты күңеле белән бергә үрелеп тасвирлана. «Солтанморат бит ул! Ходай Тәгалә аңа оҗмах бакчасының бер як читен кисеп биргән», – ди язучы. Табигать матурлыгы белән хозурлану кешене олы йөрәкле итә. Әтисенең: «Табигать йөрәге матур кешеләргә генә ачыла» дигән сүзләрен булачак язучы күңел сандыгына мәңгелеккә салып куя.

Роман 1906 елда Галимҗанның туган авылыннан Уфага «Галия» мәдрәсәсенә укырга китүе белән тәмамлана.

Әсәр «Казан утлары»нда басылып чыккач авторга төрле тарафлардан бик күп хатлар килә. Язучы Тәүфикъ Әйди: «...көчегезне «Пәйгамбәр таңы» романының дәвамын язуга багышласагыз, минемчә, отышлырак булыр иде. Ибраһимовның катлаулы тормыш, иҗат дәверен сурәтләү үтә җаваплы һәм кыен эш, аңа теләсә кем тотына алмый. Бездә әнә шундый батырлык таләп иткән иҗатка бирелүдән өркү, тарту-сузу аркасында даһиларыбызның балачагы гына кәгазьгә төшергә өлгерә. Сезнең башлангыч андый язмышка очрамасын иде», – ди [4; 79].

Язучы героеның образын тулырак ачу максатыннан тагын ике роман иҗат итте. «Күкнең җиденче катында» (1999) дигән икенче өлеше Г. Ибраһимовның 1906-1917 еллардагы гомерен үз эченә ала.

Әсәрнең герое уйлап чыгарылган персонаж түгел – киң билгеле конкрет кеше, калебе-холкы ифрат катлаулы. Г. Ибраһимов – атаклы язучы, тарихчы, әдәбият галиме, публицист, методист, педагог, тел галиме, тәнкыйтьче, революционер. Шул сыйфатлар чытырманлыгында адашып тукталып калмыйча гүзәл әдәби образ коеп, С. Поварисов үзендә пәйгамбәрләр зирәклеге, Галимҗанныкыдай сәләт һәм осталык барлыгын дәлилләде.

Бу романнарның дәвамы «Оҗмахка бер адым» дип атала. Трилогиянең өченче кисәгендә репрессия корбаны Г. Ибраһимовның шәхес буларак формалашкан һәм «халык дошманы» дигән кара ягылганнан алып, төрмәдә һәлак булуына кадәрге тормыш юлы яктыртыла. Романның беренче җөмләсеннән үк без Г. Ибраһимовның «халык дошманы» булуын беләбез. Алга таба мондый хәлгә дучар булуның сәбәпләре, Г. Ибраһимовның үткәне – Ленин һәм Сталин белән бергә эшләве, ул еллардагы авырлыкларны җиңүе, гражданнар сугышы вакытында Колчак тылында разведчик булып йөрүе, кайнар мәхәббәте,

якыннарын югалту кайгысын кичерү, Ялтада дәваланып яткан җиреннән кулга алынуы, Казанга кайтарып төрмәгә ябылуы, андагы кичерешләре сурәтләнә.

1937 елның 29 сентябрендә Г. Ибраһимов кулга алына. Ул бу вакытта Ялтада дәваланган була. Кичкә табан Г. Ибраһимов бүлмәсенә ике НКВД кешесе килеп керә. Бүлмәнең астын өскә китереп, бөтен кәгазьләрне актарырга керешәләр. Тентү үткәрүчеләр арасында Г. Ибраһимовның «шәкерте» Мөбарәк тә була. Бу кеше белән без Г. Ибраһимовтан соңгы сынау алганда да очрашабыз. Димәк, остазының үлеменә шаһит булган бу кеше йөзендә автор каһәр төшкән репрессия елларында заманның яман агышына җайланып алган, үз тиресен саклаган, үзеннән мең өлеш өстен торган кешеләр язмышына төкереп караган кешеләрне сурәтли.

Г. Ибраһимовны кулга алалар, ә аның тормыш иптәше Хәдичә ханым, ире артыннан ияреп, Казанга китә. Ләкин аны да «халык дошманының хатыны» дип төрмәгә утыртып куялар, бер ай буена җәзалыйлар, ә чыгаргач ул «анасыннан аерылып калган бәбкәдәй, ялгыз башын кая куярга белми, шәһәр урамнарында аптырап йөри».

Төрмәдә Г. Ибраһимов үзенең үткәннәрен исенә төшерә. Сталин аңа Үзәк мөселман комиссариаты оештыруны тапшыра, шулай итеп, ул Сталин кул астында эшли башлый. 1918 елны аклар һәм чехларның кара дулкыны Казан, Самара һ.б күп кенә калаларга ябырылгач, Г. Ибраһимовның җаны түзә алмый, һәм үзенең якташы Көнчыгыш фронты өчен батальоннар оештыру башлыгы Мәхмүт Шаһиәхмәтов янына килә, үзен берәр батальонга кушуын сорый. Аны аклар ягына разведчик итеп җибәрергә булалар. Өстенә ямаулы бишмәт кидереп, башына тишек – тошык эшләпә элеп, иягенә биленә кадәр сакал ябыштырып, арбага җигелгән атка утыртып, кырык тартмачы карт кыяфәтендә Г. Ибраһимовны яшерен юллар белән фронт сызыгына үткәрәләр.

1923 елда Г. Ибраһимов Казан универститетына лекция укырга чакырыла. Аның керүен студентлар түземсезлек белән көтәләр, чөнки бу лекторның язмышы, татар дөньясында үзенчәлекле шәхес, милләт йолдызы булып балкуы, Ленин, Сталин янында эшләве, Колчак тылында кылган каһарманлыклары – барысы да кызыксындыра. Лекциядән соң ул медицина факультетында укучы Гөлсем исемле кыз белән таныша. Гөлсем башка белгечлек буенча укыса да, әдәбият белән бик кызыксына, Галимҗанның лекцияләрен тыңларга килә. Тора-бара бу дустанә мөнәсәбәтләр мәхәббәткә әверелә. Уллары Рөстәм дөньяга килә. Ләкин эти кешегә улын рәхәтләнеп сөяргә насыйп булмый. Г. Ибраһимов туберкулез белән авырый, улын үзенең янына якын җибәрергә курка.

Дүрт яшь ярымлык вакытында Рөстәмне йөрәк параличы якты дөньядан алып китә. Бала югалту кайгысын икесе дә бик авыр кичерә. Берникадәр вакыт үткәч, Гөлсем ханым Г. Ибраһимовны ташлап чыгып китә. Әсәрдә Галимҗанның кичерешләре табигать күренеше белән параллель куела. Кинәт көчле гарасат куба, җир тетри башлый, җирнең асты өскә килә.

Төрмәдә сорау алу вакытында Г. Ибраһимовны күп тапкыр «халык дошманы» булуын танып, кул куюын таләп итәләр, ләкин ул кул куймый. Соңгы сорау вакытында ерткыч бүредәй бер тентүче каләм белән аның күзләрен төртеп тишә, моннан соң бик каты кыйныйлар. Бу көнне, 1938 елның 20 гыйнварында Г. Ибраһимов мәңгелеккә күчә.

С. Поварисов каһәр төшкән репрессия елларында илнең алтын баганасына торырлык ватан каһарманнарының корбан булуы хакында ачынып яза. Совет властен оештыру һәм ныгыту өчен көчен һәм сәламәтлеген кызганмаган, коммунистлар партиясенең һәр карарын тормышка ашыру өчен хәтта фанатикларча хезмәт иткән көрәшче – революционерның шундый хәлгә дучар булуын сурәтли. Аның герое җирдә явызлыкның бетерелүен, гаделлекнең тантана итүен күрергә тели һәм шуңа бөтен җаны-тәне белән омтыла.

Моңа кадәр Г. Ибраһимовның тормыш юлын тулысынча чагылдырган әсәрләр юк дәрәҗәдә иде. 1987 елда Гөлсем Мөхәммәтованың «Яшьлек көннәре» һәм «Эзләнүләр» исемле документаль повестьларында Г. Ибраһимовның 1909 елдан алып февраль революциясенә кадәрге тормыш юлы бәян ителә. Шулай ук Афзал Шамовның «Г. Ибраһимов турында истәлекләр» дигән китабында да әдипнең тормыш юлы өлешчә генә яктыртыла.

С. Поварисов «Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым» романнарында бөек әдипнең тормыш һәм иҗат эволюциясен бар нечкәлекләре белән ачып бирүгә ирешә. Таһир Таһиров «Таң-хәйран калдыра» исемле мәкаләсендә: «Поварисовның ялкынлы революционер, әдәбият классигы, академик Галимҗан Ибраһимовны әдәби образга, романнар героена әверелдерергә җөръәт итүе үзе бер кыюлык булса, шул авыр эшне искиткеч уңышлы башкарып чыгуы – чын-чыннан иҗади батырлык, әдәби каһарманлык. Трилогия – татар-башкорт әдәбиятының гына түгел, бөтен төрки халыклар мәдәниятенең зур казанышы, авторның таң-хәйран калырлык уңышы», – дип бәя бирә [5; 2].

Гомумән, С. Поварисовның тарихи темада эшләвенең янә бер уңышлы нәтиҗәсе булды, халкыбызның бөек улы, күренекле дәүләт эшлеклесе һәм төрки дөньяга танылган галим, Г. Ибраһимовның исемен художестволы алымда мәңгеләштерүдә бәһаләп бетергесез иҗади каһарманлык үрнәге дә ул. С. Поварисовның таланты киң колачлы һәм

күпкырлы булуы, тормыш күренешләренә һәм кеше күңеленә үтеп керү көче, үткенлеге белән аерылып тора. Аның тирән эзләнүле трилогиясе әдипнең тагын да югарырак баскычка күтәрелүен генә түгел, талантының күпкырлы булуын да, иҗат даирәсенең киңлеген дә раслады.

### Әдәбият исемлеге

1. Поварисов С.Ш. Пәйгамбәр таңы: Роман / Суфиян Поварисов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 285 б.

2. Поварисов С.Ш. Күкнең җиденче катында: Роман / Суфиян Поварисов. – Казан: Матбугат йорты, 1999. – 279 б.

3. Поварисов С.Ш. Оҗмахка бер адым: Романнар / Суфиян Поварисов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 464 б.

4. Поварисов С.Ш. Прометей яки Галимҗан Ибраһимов хәяте / Поварисов С.Ш. // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2007. – 332 б.

5. Таһиров Т. Таң – хәйран калдыра / Таһир Таһиров // Кызыл таң. – 2001. – февраль.

© Насибуллина Н.Ш., Эшчанова Г.О., 2024

УДК 811.512.145 + 821.512.145

**Сулейманова Д.Д.,**
*Уфа ш., Россия*

## С.Ш. ПОВАРИСОВ ПРОЗАСЫНДА ЛИНГВОПОЭТИК ЧАРА БУЛАРАК ПАРЛЫ СҮЗЛӘР

***Аннотация:*** *мәкаләдә күренекле татар язучысы Г.Ибраһимов турындагы «Пәйгамбәр таңы» трилогиясеннән мисаллар аша С.Ш. Поварисов прозасында парлы сүзләрнең лингвопоэтикасы ачыла. Автор хикәяләү структурасында портретны, геройларның характерын, топосны сурәтләүдә уңышлы сәнгати алымнары ролендә чыгыш ясаучы парлы сүзләрнең лингвопоэтик функцияләрен карый. Трилогиянең беренче өлешендә әдипнең арадаш мәгънәле, синоним компонентлы парлы сүзләрне киң куллануы әсәрнең идея-эстетик юнәлешен билгеләүче романтик тонын саклап калу өчен хезмәт итә.*

***Терәк сүзләр:*** *лингвопоэтика, Суфиян Поварисов, Башкортстанның татар телле прозасы, парлы сүзләр, редупликатлар.*

Парлы сүзләр Урал-Алтай гипотетик тел гаиләсенә, шул исәптән төрки телләргә хас җете лексик үзенчәлекләрнең берсе булып тора. Татар телендәге парлы сүзләргә кагылышлы фәнни әдәбиятка кыскача күзәтү «Татар грамматикасы»ның 1нче томында [6; 268–269] Ф.А. Ганиев тарафыннан ясалган. Парлы сүзләрне галим компонентлары тезүле мөнәсәбәт белән бәйләнгән кушма сүзләрнең аерым очрагы буларак карый һәм аларны «куш сүзләр» дип атый; тигез хокуклы бәйсез элементлардан ясалган конструкцияләр буларак билгели; аларның борынгылыгын билгеләп үтә һәм хәзерге телдә дә ясалуларын әйтә [Шунда ук; 193].

Татар телендә парлы сүзләрне махсус тикшерү Р.М. Миргалиевның «Татар телендә парлы сүзләр: лексик-семантик һәм стилистик аспектлар» кандидатлык диссертациясендә [3] һәм «Татар телендә парлы сүзләр» дигән укыту ярдәмлегендә бәян ителгән [4]. Парлы сүзләрнең лексик-семантик характеристикаларын өйрәнүдән тыш, галим аларның стилистик үзенчәлекләрен, эмоциональ-экспрессив функцияләрен тикшерә, шуның белән аларны лингвопоэтик өйрәнүгә нигез сала. Парлы сүзләрнең семантикасы тулысынча бары тик контекстта гына ачыла алуын күрсәтә [Шунда ук; 54–55], аларны өйрәнгәндә комплекслы әдәби һәм лингвистик алымнар куллану кирәклеген раслый.

Лингвопоэтик анализда Ф.А. Ганиев тәкъдим иткән классификациягә таянып [6; 302–315], парлы сүзләрне компонетлары арасындагы семантик мөнәсәбәтләрне исәпкә алучы структур-семантик классификациягә берләштерү кулай. Мондый ысул парлы сүзләрнең әдәби тексттагы лингвопоэтик мөмкинлекләрен ачарга ярдәм итә ала.

Билгеле булуынча, линвгопоэтик анализның берничә төре бар. Өчбаскычлы анализ, мәсәлән, аерым әдәби әсәрнең лингвопоэтик үзенчәлекләрен тикшерүне күздә тота: тәүдә текстта кулланылган тел чараларының семантикасы билгеләнә, аннары аларның хисси-экспрессив-бәһаләү роле белән бәйле метиосемиотик мәгънәсе өйрәнелә, ә инде лингвопоэтик баскычта стилистик тел чаралары гомум контекстта тикшерелә [1; 488]. Аерым сәнгатьчә чараның лингвопоэтикасы исә бу берәмлекнең тексттагы йөкләнешен ачыклауга, аның әсәрнең идея-эстетик эчтәлеген ничек ачарга булышуына юнәлтелә [2]. Ягъни парлы сүзләрне лингвопоэтик чара буларак тикшерү аерым әһәмияткә ия.

Атаклы татар язучысы Галимҗан Ибраһимовка багышланган «Пәйгамбәр таңы» трилогиясен Башкортстанның халык язучысы Суфиян Поварисовның (1924–2016) иҗат таҗы дип санарга мөмкин. Әдәби телнең чын остасы буларак, С. Поварисов парлы сүзләрнең бай мәгънәви

төсмерләрен уңышлы файдалана. Мисалга, парлы сүзләрнең лингвопоэтик мөмкинлекләре түбәндәге җөмләдә ачык чагыла:

«*Ул, **уйнаклап-муйнаклап**, чегән кызларыныкына хас өзелеп төшәргә торган нечкә билен мең төрле боргалап, шомырттай ялтырап торган **кап-кара** күз алмаларын **әйләндереп-тулгандырып**, үзе белән **дала-болыннар** матурлыгын алып килүен хәтерләтеп, **керер-керешкә** тәтелдәргә тотынды*» [5; 19].

Әлеге җөмләдә 5 парлы сүз файдаланылган, алар, бүтән әдәби троплар (эпитет, чагыштыру, метафора, градация) белән беррәттән, сәнгатьчә тәэсирлелекнең отышлы алымнары ролендә чыгыш ясыйлар, геройның балалык елларына багышланган трилогиянең беренче өлешенә хас талгын, иркен, шул ук вакытта экспрессив, романтик рухын тудыруда катнашалар.

Мәсәлән, *уйнаклап-муйнаклап* редупликатлы парлы сүз, *әйләндереп-тулгандырып* синоним компонентлы парлы фигыльләр геройның ихласлыгын, уенчаклыгын, шаян җитезлеген белдереп, күтәренке кәефен, хәрәкәт үзенчәлекләрен тасвирлаучы ритмик-интонацион чара буларак кулланылалар. Гадәттә сөйләм теленә хас дип саналучы редупликатлы парлы сүз авторның геройга карата рәсми булмаган дустәнә мөнәсәбәтен дә чагылдыра. Фигыль формаларын янәшә кую ысулы белән ясалган *керер-керешкә* парлы сүзе, герой хәрәкәтенең өзлексезлеген белдерү өчен файдаланылудан тыш, алдагы парлы сүзләр булдырган ритмны тотрыклы итә. Көчәйткеч кисәкчәле *кап-кара* парлы конструкциясе укучы игътибарын кызның күзенең төсенә юнәлтә. Шул рәвешчә, парлы сүзләр ярдәмендә автор героеның портрет детальләрен (күз төсе), темпераментын (хәрәкәтнең җитезлеге), яшьләргә хас дәртлелеген (уенчаклык), үзенең кызыксынулы-яратулы мөнәсәбәтен бер җөмләдә әйтеп бирүгә ирешә.

Компонентлары чиктәш мәгънәле *дала-болыннар* парлы сүзе кызның дала да, болыннар да булган төбәктән булуын искәртә (дала коры климат һәм киңлекләргә хас булса, болыннар елга буйларында очрый). Моннан тыш, бу парлы сүз әсәрнең прототибы (Г. Ибраһимов) балачакта яшәгән җирләрнең дә (тигез киң яланнар һәм яшел үзәннәр Башкортстан республикасының Авыргазы районындагы Солтанморат авылында янәшә очрый) үзенчәлекле сыйфатларына ишарә итеп, әсәрнең топосына уңышлы бер деталь буларак өстәлә.

Янә бер мисал:

«*Алар, һәрвакыттагыча, **сөйләшә-сөйләшә, гөрләшә-гөрләшә, тирле-тирле** чәй эчтеләр*» [5; 20].

Әлеге җөмлә татар халкы көнкүрешендә мөһим моментларның берсе булган чәй эчү процессын характерлаучы өч парлы фигыльне

рәттән кулланылуы белән кызыклы. Кабатлау ысулы белән ясалган парлы фигыльләр (*сөйләшә-сөйләшә, гөрләшә-гөрләшә, тирли-тирли*) татар әдәбиятында яратып кулланылган әдәби троп – градация элементлары буларак кулланыла. Лексемаларның шулай кабатлануы интонацияне көчәйтә, парлы конструкцияләрнең һәркайсына мәгънәви басым ясала, һәм, тулаем алганда, җөмләнең ритмик нигезен тәшкил итә. Бу җөмләне русчага тәрҗемә иткәндә, лингвопоэтик төсмерләрне тулысынча тапшыру өчен синономик фигыльләрне (неспешно, но оживленно и беспрестанно разговаривая, любезно и подолгу беседуя; одновременно шумя, воркуя и обливаясь потом; в целом, как обычно принято у татар) кулланырга кирәк булыр иде.

*«Шуны уйлап, кулыннан килгәнчә, Галимҗанны* ***мәгълүмат-мәгариф*** *диңгезендә* ***өч-дүрт*** *яшьтә үк йөздерә башлады ул»* [5; 27].

Бу мисалда Парлы саннар (*өч-дүрт*) геройның яшенең төгәл генә билгеле булмавын ассызыклый. Гомумән, парлы саннар татар әдәбиятында тулыканлы лингвопоэтик чара буларак чыгыш ясый, дип санарга мөмкин. Саннар, кагыйдә буларак, гадәттә, конкрет семантикага ия, әмма парлы конструкцияләрдә алар әдәби контекстка бәйле рәвештә өстәмә мәгънәви төсмерләр ала. Галимҗанга өч яшь тулуы да мөмкин, бәлки, дүрт яшь тә булгандыр, ләкин авторга анысы кызык түгел, иң мөһиме – ул өч-дүрт яшь арасында, ягъни сабый чагыннан ук белем диңгезенә чума. Әдәбиятта ассызыклануынча, парлы сүзләрнең төп мәгънәләренең берсе билгесезлек семантикасы белән бәйле [4; 32–35]. Билгелелек-билгесезлек грамматик оппозициясе исә, Җ Киекбаев хезмәтләрендә теоретик яктан нигезләнгәнчә – урал-алтай гаиләсе телләре нигезендә яткан иң мөһим категорияләренең берсе. Парлы сүзләр билгелелек-билгесезлек мәгънәсен тартым кушымчасыннан тыш та белдерә ала. Мәгънәләре чиктәш яисә охшаш сүзләрнең парлы конструкциядә янәшә кулланылуы аларның мәгънә чикләрен, беренчедән, җуя төшә, икенчедән, алар белдергән гомум мәгънәне киңәйтә һәм контекстка бәйле рәвештә, яңа мәгънәви-экспрессив төсмерләр өсти. Лингвопоэтик функцияләренә килгәндә, мондый парлы сүзләр хикәяләүгә әдәби стиль төсмере бирә. Әгәр язучы «*Шуны уйлап, кулыннан килгәнчә, Галимҗанны мәгълүмат диңгезендә өч яшьтә үк йөздерә башлады ул*», дип язса, бу текст әдәби стильдән бигрәк, публицистикага карамыймы, дигән шик тууы бик мөмкин булыр иде.

Гомумән, парлы сүзләрнең структурасы үзе үк билгелелек яки билгесезлек идеясен җиткерә. Мәсәлән, көчәйткеч кисәкчәләр, тулы кабатлаулар билгелелек мәгънәсен бирсә, компонентларын синономимнар һәм чиктәш мәгънәдәге парлы исемнәр, редупликатлар тәшкил итүче парлы сүзләр – күплек санны, җыелмалылыкны аңлата, ә

фигыльләрнең грамматик формалары янәшә килү, парлы саннар вакыт пространствосының, күренешләрнең, хәрәкәтнең киңлеген, чикләренең төгәл билгесезлеген, дәвамлылыгын чагылдыра.

Нәни Галимҗан чумган диңгез – *мәгълүмат-мәгариф диңгезе,* русча бу сүзтезмә «море информации и образования» дип тәрҗемә ителә. Шиксез ки, үзе дә тел галиме, профессоры булган язучы гарәп теленнән алынган, югары стильгә караган *мәгълүмат, мәгариф* сүзләрен парлап һәм изафет аша белдерелгән метафора составында очраклы кулланмаган. Фразеологик әйләнмәгә әверелеп барган *белем диңгезе* метафорасы урынына катлаулырак мәгънәле парлы сүзләрне куллану нәни Галимҗанның әйләнә-тирәсендә җитди һәм киң мохит булуына ишарәли. Чыннан да, Г. Ибраһимов заманы өчен алдынгы карашлы Гыйрфан мулла гаиләсендә туа, өстәвенә, әнисе Хәсәнә дә гыйлемле ханым була, аның образы романда аеруча җылылык белән сурәтләнә.

Әгәр беренче мисалда редупликатлы, синоним компонентлы парлы фигыльләрне, көчәйтелгән кисәкчәле сыйфатларны куллану авторга кызның портретын булдырырга мөмкинлек бирсә, икенче мисалда фигыльләрнең тулы кабатлануы чәй эчү процессы этапларын экспрессив тасвирлау өчен хезмәт итә. Соңгы җөмләдә исә парлы сүзләрнең лингвопоэтик функциясе аларның семантик һәм стилистик мәгънәләренә, әдәби контекстка тыгыз бәйле.

Компонентлары чиктәш мәгънәдәге сүзләр, синономнар булган парлы конструкцияләр трилогиянең аеруча беренче өлешендә күп кулланыла. Алар авторга гомум романтик тонны тотрыклы сакларга ярдәм итә: автор үзенең әдәби каһарманына чын күңелдән соклана һәм Г. Ибраһимовның сабыйлык, яшьлек елларының илаһи матурлыкка ия сәхифәләрен тергезергә ирешә.

Гомумән, парлы сүзләр С.Ш. Поварисов тарафыннан персонажларга һәм әйләнә-тирә дөньяга үз мөнәсәбәтен белдерү, герой портретын, аның характерын, топосны һәм мәгънәләрнең бик нечкә төсмерләрен сурәтләүнең отышлы чарасы буларак кулланыла. Аларның игътибарны көчәйтү, юнәлтү функциясендә файдаланылуын да күзәтәбез. Шулай рәвешчә, парлы конструкцияләр, дәвамлылык, интенсивлык, күренешләрнең һәм хәрәкәтләрнең билгеле булу-булмавын белдерү белән бергә текстка экспрессив, стилистик йөкләнеш биреп, тирәнлек һәм күләм өстәп, семантик, метасемиотик һәм лингвопоэтик бербөтен буларак чыгыш ясарга сәләтле.

**Әдәбият**

1. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. – М.: КомКнига, 2007. – 576 с.

2. Липгарт А.А. Основы лингвопоэтики. Изд. 5-е. – М.: ЛИБРОКОМ, 2013. – 164 с.

3. Миргалиев Р.М. Парные слова в татарском языке: лексико-семантический и стилистический аспекты: дис. ... канд. филол. наук: 10.02.02. – Уфа, 2002. – 159 с.

4. Миргалиев Р.М. Татар телендә парлы сүзләр: уку ярдәмлеге. – Уфа: РИО БашГУ, 2004. – 126 б.

5. Поварисов С.Ш. Пәйгамбәр таңы. Романнан өзек // Хәлиуллина А.Г., Сөләйманова Д.Д. Туган як әдипләре. Башкортстанда хәзерге татар прозасы: шәхес, иҗат, тәнкыйть. Уку-укыту басмасы. – Уфа: Китап, 2013. – Б. 18–30.

6. ТГ 2015 – Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Ф.М. Хисамова. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т. I. – 512 б.

© Сулейманова Д.Д., 2024

УДК 398

**Фазлутдинов И.К.,**
*Уфа ш., Россия*

# РИФ МӨХӘММӘТҖАНОВ – БАШКОРТСТАНДА ТАТАР ФОЛЬКЛОРИСТИКАСЫНА НИГЕЗ САЛУЧЫ

***Аннотация:*** *мәкалә үзенең бөтен гомерен Башкортстан Республикасы территориясендә яшәүче татар халкының фольклор мирасын тикшерүгә багышлаган күренекле татар фольклорчысы Р.М. Мөхәммәтҗановның (1939-1996) тууына 85 ел тулуга багышлана.*

*Автор Р.М. Мөхәммәтҗановның шәхесен өч яссылыктан анализлый: галим, милли фольклорны җыючы һәм тикшерүче; 40 елдан артык Башкорт дәүләт университетының (Уфа шәһәре) татар филологиясе кафедрасында хезмәт куйган педагог; XX гасырның 80 нче елларында Башкортстан территориясендә татар милли хәрәкәтен булдыруда зур роль уйнаган җәмәгать эшлеклесе.*

*Мәкаләдә тикшеренүченең төп фәнни хезмәтләре, аның публицистик һәм әдәбият белеме эшчәнлеге комплекслы анализга дучар ителде.*

***Терәк сүзләр:*** *галим, йола фольклоры, Башкортстан татарлары, туй йолалары, календарь поэзиясе, әдәбият, татар халык иҗаты.*

Фән тарихында артык зур дәрәҗә-титулларга ирешмәсәләр дә, исемнәрен алтын хәрефләр белән халык күңеленә язып калдырган галимнәр дә, гомер эчендә дәүләт бүләкләренең һәммәсен алып бетереп, әрсезлеге, танышлыгы аркасында зур рәсми танылу яулаган, ләкин дөньядан китүе белән хезмәтләренең дә гыйльми-гамәли әһәмияте юкка чыккан фән эшлеклеләре дә еш очрый. Гомумән, галимнең гомер озынлыгы аның хезмәтләренең актив гыйльми кулланылышта йөрү дәвере белән билгеләнә дип әйтер идем мин. Нәкъ язучы-шагыйрьләрнеке кебек үк. Аларның да гомере әсәрләренең халык күңелендә яшәү дәвере белән билгеләнә бит. Тукай, Такташ, Туфаннарны шуңа үлемсез дип атыйбыз.

Күренекле фольклорчы-галим, җәмәгать эшлеклесе Риф ага Мөхәммәтҗановның исеме дә татар фольклористикасы тарихына, халкыбыз күңеленә алтын хәрефләр белән язылган. Аның хезмәтләре бүген дә меңнәрчә студентлар, халык авыз иҗаты белән кызыксынучылар тарафыннан җентекләп өйрәнелә, ә димәк, галим дә яши...

Риф Мирхәбибулла улының исеме, гыйльми язмалары, китаплары Башкортстанда яшәүче татарлар өчен аеруча газиз һәм якын, чөнки галим бар гомерен туган як халкының рухи мирасын барлау һәм тикшерүгә, аны саклап калуга, тирә-якта популярлаштыруга багышлады. Ул туган җиреннән, туган халкыннан беркайчан да аерылмады, аны кайгы-шатлыклары белән яшәде: татар еласа – елады, көлсә – көлде.

Риф Мирхәбибулла улы Мөхәммәтҗанов 1939 елның 2 июлендә Башкортстанның Ярмәкәй районының ямьле Ык елгасы куенына яшеренеп утырган Аксак авылында дөньяга килә. (Бу авыл 1960 еллардагы кечкенә авылларны берләштерү кампаниясе вакытында юкка чыгарыла. – И.Ф.) Яшьтән үк моңлы, җыр-шигырьгә мөкиббән малай булып үсә. Үзе дә каләм тибрәтә башлый. Туган авылында сигезьеллык белем алгач, 1957 елда Ярмәкәй районының Иске Турай урта мәктәбен көмеш медаль белән тәмамлый. Әдәбиятка, туган телгә булган мәхәббәте аны Башкорт дәүләт университетына алып килә [14; 117]. Шунысы кызык: Риф Мөхәммәтҗанов бер ел буена филология факультетының башкорт-рус бүлегендә укырга мәҗбүр була. Моның сәбәбен аның бертуган энесе, күренекле татар драматургы Ризван Хәмид түбәндәгечә тасвирлый.

«... Имтихан алучылар «собеседование» уздырганда – медале булгач, экзамен тотасы юк абыйның – абруйлы фольклорчы-галим Кирәй Мәргән килеп керә һәм Рифнең кулында ниндидер калын «амбар кенәгәсе» күреп, кызыксынып актара башлый. «Нәмәкәй был? » – дип сорый башкорт галиме. «Әти агроном минем, ул гомер буе табигать күренешләрен көндәлеккә теркәп барды, хәтеренә төшкән йолаларны,

төрле җыруларны да җыя ул, мин үзем дә кайберләрен өстәп куйгалыйм», – дип җаваплый Риф абый, ояла-ояла гына. «Нимәгә ҡыҙараһың быңа, егетем, изге нәмәдән оялмайҙар. Мин һине үҙ бүлегемә алам, ҡустым», – димәсенме атаклы фольклорчы [13; 23]!

Шунысын да өстик: киләчәктә филология фәннәре докторы, Башкортстанның халык шагыйре, Язучылар берлеге рәисе дәрәҗәләренә ирешәчәк Равил Бикбаев нәкъ шул елда Башкорт дәүләт университеты филология факультетының татар-рус бүлегенә укырга кергән була. Ягъни, кызыклы парадокс килеп чыга: башкорт егете – татар бүлегендә, татар егете башкорт бүлегендә белем ала. Беренче курс тәмамлангач, 1958 елда, бу «хата» төзәтелә – алар уку урыннары белән «алмашалар» һәм Риф ага 1962 елда БДУның татар-рус бүлеген тәмамлый. Шулай булса да, ул 1962-1966 еллар дәвамында башкорт телендә нәшер ителүче «Совет Башҡортостаны» республика гәзитендә әдәби хезмәткәр вазыйфасын башкара, күпсанлы очерклар, мәкаләләр яза [14; 117].

1966 елда сәләтле белгеч БДУның татар филологиясе кафедрасына эшкә чакырыла. Аңа «Татар халык иҗаты», «Татар әдәбияты тарихы» фәннәре, махсус курслар буенча лекцияләр уку, студентларның гыйльми эшләренә җитәкчелек итү бурычы йөкләтелә. Риф ага яңа эшкә күңел биреп тотына һәм тиз арада хезмәттәшләре арасында зур абруй казана.

Риф Мөхәммәтҗановның фән өлкәсендәге иң зур казанышы – БДУның татар филологиясе кафедрасы каршында фольклор фонды оештыруыдыр, мөгаен. Ул – Башкортстан татарларының халык авыз иҗатын системалы рәвештә җыю һәм өйрәнү эшен башлап җибәргән беренче галим. Алтмышынчы еллар уртасыннан алып ул республиканың татарлар күпләп яшәгән районнарына утызга якын фольклор экспедициясе оештыра, 150дән артык авылны урап чыга. Билгеле, әлеге сәяхәтләрдә катнашкан студентлар өчен бу, беренче чиратта, һичнәрсә белән алыштыргысыз аралашу мәктәбе була. Чөнки чын фольклорчы үз фәнен яхшы белү өстенә, оста психолог та булырга тиеш. Авылларда кемнәрнең генә йортларына керергә туры килми! Гаилә низагларына да, эчкечеләргә дә, сугыш чукмарларына да, Сталин дәвереннән калган курку белән яшәүче, авызларыннан сүз тартып чыгара алмаслык «партизан»нарга да еш очрарга туры килә экспедиция әгъзаларына. Аларның күңеленә юл табу, хәтер чоңгылларыннан бәяләп бетергесез әһәмияткә ия рухи ядкарьләрне өскә тартып чыгару өчен зур тырышлык салырга туры килә аларга. Әйткәндәй, бүгенге көндә Риф Мирхәбибулла улы җитәкчелегендәге фольклор экспедицияләре вакытында җыеп алынып, БДУның татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы фондларында саклanучы ул материаллар безнең тарафтан электрон

форматка күчерелде. Халыкның энҗе-мәрҗәннәре юкка чыкмасын, җилгә очмасын өчен кирәк бу гамәл.

Әлеге экспедицияләрдә җылган фольклор материаллары тиз арада фәнни әйләнешкә кереп китә. Мәсәлән, 1977-1993нче елларда Казанда дөнья күргән «Татар халык иҗаты» унөчтомлыгының һәр китабында да Риф ага тарафыннан тупланган халык авыз иҗаты үрнәкләре урын ала. Ә инде «Йола һәм уен җырлары» томының нигезен, гомумән, ул җыйган материаллар тәшкил итә. Уйлап карасаң, гаҗәп бит: Казанда тулы бер институт шөгыльләнгән эшне, Риф ага тик үзенә һәм студентларына таянып кына да башкарып чыга алган! Әле бу лекция, практик дәресләр, йөз төрле җәмәгать вазыйфаларын исәпкә кертмичә генә! Югыйсә, ул 20 елдан артык кафедра профоргы, «Акчарлаклар» әдәби-иҗат түгәрәге җитәкчесе була, авылларга барып, гади халык алдында төрле темаларга лекцияләр белән чыгыш ясый. Нинди тырышлык, эшеңә бирелгәнлек кирәк моңа!

Риф ага Мөхәммәтҗановның фидакарь эшчәнлеге нәтиҗәсендә җыелган фольклор материаллары гомуми җыентыкларда урнаштырылып кына калмый, яшь тикшеренүченең аларга карата фәнни күзәтүләре, тикшеренүләре монографик хезмәт булып формалаша. 1973 елда ул БДУдагы беренче «танышы», филология фәннәре докторы, профессор Әхнәф Кирәев (әдәби тәхәллүсе – Кирәй Мәргән. – И.Ф.) җитәкчелегендә «Башкортстан Ык буе татарларының йола поэзиясе» темасына кандидатлык диссертациясен яклый. Анда кулланылган материалның күплеген, эзләнүләрнең күп тармаклы булуын хезмәтнең күләме үк күрсәтеп тора. Кандидатлык диссертацияләренең уртача күләме 150-170 биттән артмаска тиеш дигән күрсәтмә булса да, аның хезмәте 228 бит тәшкил итә [9]! Тикшеренүнең янә бер бик әһәмиятле ягын да истә тотарга кирәк: ул Татарстаннан читтә яшәүче татар халкының, аерым алганда, Башкортстанда яшәүче татарларның, милли фольклорын, аның төбәк үзенчәлекләрен, биредә яшәүче башка халыкларның авыз-тел тел иҗаты белән бәйләнешен чагыштырма планда, комплекслы һәм системалы рәвештә тикшергән беренче гыйльми хезмәт булып тора. Шуны да өстик, Башкортстанда яшәүче татарларның милли фольклорын фәнни тикшерү юнәлешендәге икенче кандидатлык диссертациясе безнең тарафтан язылды һәм легенда, риваять жанрларын тикшерүгә багышланды [12].

Риф Мирхәбибулла улының әлеге хезмәтләре киләчәктә студентлар өчен дәреслекләр, уку кулланмалары булып формалашты. Аның 1979, 1982 елларда дөнья күргән «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: туй поэзиясе» һәм «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: календарь поэзия» дип аталган хезмәтләре бүген дә студентлар,

халык авыз иҗаты белән кызыксынучылар өчен әһәмиятле чыганаклар булып кала кала [6] [5]. Үз хезмәтләрендә галим Башкортстанда яшәүче татар халкының йола поэзиясен ике төргә бүлеп тикшереп, календарь һәм туй поэзиясенең жанрлар буенча ул чор өчен өр-яңа бүленешен тәкъдим итә, аларны Казан ягы татарлары фольклоры белән тарихи-чагыштырма аспектта анализлап, уртак һәм аермалы якларын билгели, шул ук вакытта, Башкортстанда яшәүче татарларның һәм тел, һәм мәдәният, һәм фольклоры ягыннан гомумтатар халкының аерылгысыз өлешен тәшкил итүен ассызыклый. Бер үк вакытта ул уртак географик һәм рухи җирлектә гомер кичерүче башкорт, урыс, мордва, мари, чуваш һ.б. халыклар фольклоры белән параллельләр үткәрә, төрле халыкларның авыз-тел иҗатында үзара бәйләнешләрнең чагылышын тикшерә.

Риф ага татар халкының милли йолаларына бирелгән зат иде. Аларны җыеп, өйрәнеп, ул онытылып барган күпсанлы йолаларга яңа сулыш өрде, фольклор коллективлары, халык ансамбльләре өчен кулланма әсбаплар төзеде. Башкортстан радиосының «Әллүки» тапшыруында Ык буе татарларының йола иҗатын шәрехләгән тапшырулар циклын тудырды. Кызганычка каршы, кыска хәтерле халык шул без. Риф ага тасвирлаган таңкучатлы, шәмчыраклы, самаклы татар туйлары инде тарихта гына калды, карга боткалары, тула өмәләре дә онытылу алдында тора. Хәтта үзебезнең төп милли бәйрәмебез – сабантуйларның да асыл мәгънәсен югалтып, аны югарыдан килгән күрсәтмәләр буенча гына, «отчет» өчен генә үткәрә башладык шул без. Югыйсә, заманында ул чәчүгә төшәр алдыннан уздырылып, язгы кыр эшләренең «генераль репетициясе» вазыйфасын үтәгән, төрле символик йолаларга, сынамышларга бай булган бит.

Риф Мирхәбибулла улының халык йолаларына гашыйклыгы турында шул да сөйли: ул лекцияләрендә нинди генә темага алынмасын, ахырда барыбер йола иҗатына кереп китә иде. Моның серен мин, еллар үтеп, университетта үзем «Татар халык иҗаты»н укыта башлагач кына аңладым. Баксаң, барлык фольклор жанрлары да тамырлары белән борынгы йолачылыкка, ыру-кабиләнең тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә килеп тоташа икән. Бу йолалар үзләре күптән югалсалар да, аларның калдыклары әкиятләр, легендалар, риваятьләр аша символлар рәвешендә безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Риф ага моны үзе тирән аңлаганлыктан, студентларына да төшендерергә тырышкан. Ә без, наданнар, көлә идек: «Русиядә нәрсә генә төзесәләр дә, Калашников автоматы килеп чыккан кебек, Риф Мөхәммәтҗанов, нинди генә темага лекция укымасын, барыбер йола турында сөйли», – дип... Хәзер бик тыңлар идек тә соң аның лекцияләрен – соң... Терсәкне тешләп булмый.

Башкортстан татарларының йола поэзиясен тикшерү аның гыйльми эшчәнлегенең бер тармагы булса, икенчесен әдәбиятта фольклор традицияләренең күчемлелеген анализлау тәшкил итте. Әллә үзе дә шигырьләр язганга, ул поэзияне аеруча якын күрде. Классик әдипләребез Һади Такташ, Фатих Кәрим, Башкортстандагы татар шигъриятен әйдәп баручы Салават Рәхмәтулла иҗатына аның тарафыннан фольклорчы күзлегеннән җентекле анализ ясалды [8]. Фольклордан килгән меңьеллык традицияләрнең күчемлелеген тикшерү аша, галим халкыбызның яшәү менталитетын, рухиятен ачуга ирешә.

Галимнең рус телендә нәшер ителгән «Специфика татарских фольклорных жанров» дип аталган китабын аның кырык елга якын сузылган гыйльми эзләнүләренең логик нәтиҗәсе итеп карарга кирәк [10]. Биредә Риф Мирхәбибулла улы үзенең гомерлек гыйльми тикшеренү предметы булган йола поэзиясе белән генә чикләнеп калмыйча, милли фольклорыбызга колачлы караш ташлый.

Китап ике бүлектән тора. «Йола поэзиясе һәм лирика» дип аталган беренче бүлектә туй һәм календарь йолаларының генезисы, аларның халык авыз иҗатының лирик төренә караган жанрлары белән бәйләнеше тикшерелә; рекрут һәм солдат җырлары (назлар) җентекле анализлана; туй поэзиясендәге үгет-нәсыйхәт җырларын бата, арбау, тулгау, картлар сүзе, вәгазь һ.б жанрларга классификацияләү принциплары тәкъдим ителә [10; 6-44].

«Фольклор һәм әдәбият» дип исемләнгән икенче бүлектә исә галим, фән тарихында беренчеләрдән булып, ярымфольклор характердагы сөйләк жанрын Башкортстанның көнбатышында яшәүче татарларның тарихи хәтерендә әлегә кадәр сакланып килгән легендар комдив Чапаев турындагы халык хикәяләре мисалында анализлый, шулардан чыгып, сөйләк жанрына гыйльми билгеләмә бирү омтылышын ясый. Бәетләрнең, тарихи җырларның, балалар фольклоры әсәрләренең язма әдәбиятка йогынтысын, традицияләр күчемлелеген тикшерү әлеге бүлекнең асылын билгели [10; 45-74]. Бу хезмәт әлегә кадәр «Татар халык иҗаты» курсын уку-укыту процессында әһәмиятле чыганак булып кала.

Гомумән алганда, Риф Мөхәммәтҗанов үзенең кыска гына тормышында дүрт монографик хезмәт һәм уку кулланмасы, 100дән артык фәнни мәкалә язып һәм бастырып калдыра [14; 117]. Ә экспедицияләр вакытында аның тарафыннан җыеп тупланган фольклор материаллары безнең тарафтан төзелеп, 2021 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында нәшер ителгән «Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенең өч китабы төсен алды [1] [2] [3]. Галимнең теоретик хезмәтләре, матбугатта басылган гыйльми язмалары шулай ук безнең тарафтан бергә тупланып,

2021 елда «Башкортстан татарларының йола иҗаты» исемле монография рәвешендә дөнья күрде [4].

...Шәкерте буларак, хәтеремә шунысы уелып калган: Риф Мирхәбибулла улы имтиханнарны гаять таләпчән ала иде. Аның предметыннан «бишле» эләктерү – сирәкләр өлешенә тигән бәхет. Ләкин тышкы кырыслык битлеге астына, аның юмор-сатирага гаять бай күңеле яшерелгән иде. Ул, хәтта, үзенә кушамат тагылуга да үзе сәбәпче булган. Югары курс студентлары безгә түбәндәге тарихны сөйли иделәр.

Җәйге сессия вакыты...

Риф Мөхәммәтҗановка имтихан тапшырырга читтән торып укучы ниндидер бер студент кыз килгән. Укытучыга авырлык төшмәсендер дипме инде, ни сәбәптәндер, зачет кенәгәсен үзе тутырырга булган бу. Предмет атамасын, имтихан датасын да язып куйган. Билге төшерәсе һәм имза куясы гына калган. Тик укытучының фамилиясен тар гына графага сыйдыра алмаган: «Мухаметзя» өлеше сыйган, «нов»ы төшеп калган.

Ярар, имтиханны «яхшы»га тапшырган бу. Билгесен куйдырырга дип, зачеткасын остазына сузган. Риф ага аның язганнарын җентекләп укыган да:

– И кызым, ни дип, интегеп, «Мухаметзя» дип язып тордың? «Муха»сы да җитәр иде, – дип көлеп җибәргән.

Шуннан соң галимгә студентлар арасында «Муха» кушаматы гомерлеккә тагылды. Яраткан «Муха»быз иде ул... Үзебезнең «Муха» иде... [11; 31].

«Кеше күңеле – мең катлы», – диләр. Яраткан остазыбызның шигъри күңелле зат икәнлеген белсәк тә, аның оста каләмле шагыйрь дә булганлыгын үзе исән чакта белмәгәнбез шул. Юкса аның йөздән артык шигыре узган гасырның 60-70нче елларында республика вакытлы матбугатында дөнья күргән булган. Болары – басылганнары, ә беркайда да нәшер ителмәгәннәре, «күңел өчен» генә язылганнары күпме? Кайда, кем кулларында саклана? Бу сораулар җавапсыз кала... Югыйсә, аның поэтик осталыгын «Ярмәкәй чишмәләре» иҗат берләшмәсенең юбилеена багышланган кечкенә генә җыентыкта дөнья күргән берничә шигыреннән дә күрергә мөмкин.

Күренекле галим, педагог Риф Мирхәбибулла улы Мөхәммәтҗановның җәмәгатьчелек эшчәнлеге турында да сөйләп үтмәсәм, язмам тулы булмас иде. 1980нче еллар азагында илдә милли үзаң күтәрелеше башлангач, ул республика татар милли хәрәкәтендә әйдәп баручыларның берсе булды. Башкортстан Татар иҗтимагый үзәгенең Гали мәҗлес әгъзасы итеп сайланды, «Алтын ай» милли агарту фондын җитәкләде. Аның «Телем, җирем, халкым» (соңыннан «Рәйхан») телевизион тапшыруындагы чыгышлары татар теле, милли фольклор

мәсьәләләренә багышланды, Башкортстан радиосында да ул әлеге проблемалар буенча «Әллүки» дип аталган радиотапшырулар циклын оештырып, үзе дә шунда еш чыгыш ясады. Бүгенге көндә Башкортстанда татар телендә дүрт республика басмасы дөнья күреп, өч югары уку йортында татар бүлекләре эшләп килә икән – монда Риф аганың да өлеше бар.

«Ходай яраткан кешеләрен тизрәк үз катына алырга тырыша», – дигән ышану яши халыкта. Риф аганың да гомере бик кыска булды. 1996 елда, нибары 57 яшендә, хәерсез замананың аяусыз чире аны арабыздан алып китте. Ләкин ул салган иҗади очкын меңнәрчә шәкертләренең күңелендә әле дә яши, вакыт сынавын узган гыйльми хезмәтләре аның рухына мәңгелек һәйкәл булып тора. Юксынабыз без Сезне, Риф ага... Юксынабыз... Урыннарыгыз җәннәттә булсын!

### Әдәбият

1. Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. – Казан: ТӘҺСИ, 2021. – 312 б.

2. Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. – Казан: ТӘҺСИ, 2021. – 296 б.

3. Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. – Казан: ТӘҺСИ, 2021. – 304 б.

4. Мөхәммәтҗанов Р.М. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты / төзүчеләр: И.И. Ямалтдинов, И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. – Казан: ТӘhСИ, 2021. – 228 б.

5. Мөхәммәтҗанов Р.М. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: календарь поэзия / фәнни редакторы Т.Н. Галиуллин. – Уфа: БДУ нәшрияты, 1982. – 72 б.

6. Мөхәммәтҗанов Р.М. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: туй поэзиясе. – Уфа: БДУ нәшрияты, 1977. – 72 б.

7. Мөхәммәтҗанов Р.М. Йола поэзиясе // Татар теле, әдәбияты һәм аларны укыту методикасы мәсьәләләре. – Уфа: БДУ нәшрияты, 1971. – Б. 30-42.

8. Мөхәммәтҗанов Р.М. Хәзерге поэзиядә традицион фольклор образларының үсеше: Һ. Такташ иҗаты материалында // Татар

филологиясе мәсьәләләре (әдәби әсәрдә поэтика): вузара җыентык. – Уфа: БДУ басмасы, 1990. – Б. 57-67.

9. Мухаметзянов Р.М. Обрядовая поэзия приикских татар Башкирии: дисс. ... канд. филол. наук: 10.01.09. – Уфа, 1973. – 228 с. https://search.rsl.ru/ru/record/01009856164

10. Мухаметзянов Р.М. Специфика татарских фольклорных жанров: учебное пособие. – Уфа: Издательство БашГУ, 1989. – 84 с.

11. Фазлетдинов Илдус. Юксыну // Тулпар. – 2009. – № 4. – С. 30-31.

12. Фазлутдинов И.К. Топонимические предания и легенды татар Башкортостана: исторические основы и идейно-эстетические функции : дисс. ... канд. филол. наук : 10.01.09. – Уфа, 2005. – 263 с.

13. Хәмид Р. Яшьти абый // Тулпар. – 2014. – № 3. – Б. 22-27.

14. Энциклопедия. Ермекеевский район. Республика Башкортостан: А-Я / Т.И. Аминев (рук.) и др.; редкол.: Т.И. Аминев (отв. ред.) и др.. – Уфа: Уфимский полиграфический комбинат, 2010. – 199 с.

© Фазлутдинов И.К., 2024

УДК 811.512.145

**Халиуллина А.Г.,**
*Уфа ш., Россия*

## СУФИЯН ПОВАРИСОВ: ЖУРНАЛИСТ, МӨГАЛЛИМ, ГАЛИМ

***Аннотация:*** *мәкалә филолог-галим, язучы-фронтовик Суфиян Поварисовның фәнни-педагогик, журналистлык эшчәнлегенә багышлана. Аның татар теле стилистикасы үсеше тарихына, әдәби текстларга филологик анализ ясауга керткән өлеше карала. Кызыклы биографик фактлар җәлеп итү юлы белән язучы шәхесе формалашуының эволюциясе күзәтелә.*

***Терәк сүзләр:*** *Суфиян Поварисов, журналист, галим-филолог, язучы-фронтовик.*

Филология фәннәре докторы (1991), профессор (1993), язучы, драматург, публицист, тәнкыйтьче, тел белгече, Башкортстан (1992) һәм Татарстан (2004) республикаларының атказанган фән эшлеклесе, Русия Федерациясе югары белем бирү өлкәсенең атказанган хезмәткәре (1997), Башкортстанның халык язучысы (2011), Галимҗан Ибраһимов исемендәге әдәби премия (1998) лауреаты Суфиян Шәмсетдин улы

Поварисов 1924 елның 29 августында БАССРның Илеш районы Тыпый авылында туган.

Шәмсетдин мулла һәм Әсмабикә абыстай гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килгән Суфиян авыр балачак елларын, ятимлек ачысын, гаделсезлекне үз башыннан кичерә. Тормыш сынаулары бер яшьлек чагыннан ук башлана: хезмәт сөючән, тырыш, күтәренке күңелле, авылда ике катлы йорт салып, җиләк-җимеш бакчасы үстергән этисе Шәмсетдинне 1925 елда көтелмәгән фаҗига якты дөньядан алып китә. Авылдан шактый ерак урнашкан мәктәпкә барып уку мөмкинлеге булмау сәбәпле, дүртьеллык мәктәпне тәмамлагач, туганнарын ачлыктан, ялангачлыктан саклап калыр өчен үсмер Суфиян чабата үрергә алына. Әмма белемгә ихтыяҗ, тырышлык аны янәдән мәктәпкә алып килә. Бер елдан үз авылларында ачылган җидееллык мәктәптә укуын дәвам итә, әмма чабата үрү шөгылен ташламый. Тирә-якта «Суфиян чабатасы» дигән даны таралып өлгергән, җиде юкәдән үрелгән чабаталар ныклыгы, матурлыгы һәм нәфислеге белән аерыла. Талантының чишмә башы шушы юкә чабатада булуы турында үзе дә шаяртырга ярата. Авыр тормыш шартларында, буыннары да ныгып бетмәгән яшүсмер, җиң сызганып колхоз эшенә тотына. Җиденче сыйныфтан соң бәхет эзләп, читкә чыгып китә, казах, үзбәк балаларына үз туган телләрен укыта. Уналты яше тулгач, паспорт алып, Себер якларына юллана, чатлама суыкларда да тимер юлга шпал салу эше аны куркытмый.

1941 елда башланган Бөек Ватан сугышы ул чордагы бер гаиләне дә читләтеп үтми. Унсигез яше тулып килгән егет, Алкиндагы минометчылар әзерләү курсын үтеп, 1942 елның августында Кызыл Армия сафларына чакырыла. Иглин районында оешкан 469 нчы аерым миномет полкы составында Украинаны, Белоруссияне азат итүдә катнаша, Көнбатыш Европа илләре (Польша, Румыния, Венгрия, Чехословакия, Германия) җирләрен исә минометчылар расчеты командиры буларак уза. Данлыклы «Башкорт полкы» дип йөртелгән полкның беренче расчеты төзәүчесе (наводчик) була, эре калибрлы коралдан төз ату осталыгын күрсәтә, шуның өчен дә аны «миномётчы-снайпер» дип йөртә башлыйлар. «Поварисов минаны немецның үзенә генә түгел, черкинең күзенә дә төшерә», – диләр аның хакында. Суфиян Поварисов 22 яшендә беренче расчет командиры булып билгеләнә, еш кына миномет расчеты артына үзенә басарга туры килә. Курск дугасыннан башланган хәрби хезмәтен Эльба елгасы ярындагы Дрезден шәһәрендә тәгәлли, озак көтелгән Җиңү көнен шунда каршы ала. Сугышчан казанышлары өчен II нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы һәм III нче дәрәҗә Дан орденнары, күпсанлы медальләр белән бүләкләнә. Дошманның ут позицияләрен тар-мар иткәндә күрсәткән батырлыклары

өчен аңа Югары Башкомандующий тарафыннан ике дистә тапкырдан артык рәхмәт игълан ителгән. Днепр елгасын кичкәндә күрсәткән каһарманлыгы Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, тик документлар янгында калып, тиешле урынга барып җитмәү сәбәпле, бу награда бирелми кала. Сугыштан соң Венгриядә хезмәтен дәвам итеп, 1947 елда гына демобилизацияләнә. Сугыш яланында ике тапкыр каты яралана, контузия ала.

Тыныч тормышка кайткач, Кыргызстан һәм Үзбәкстан мәктәпләрендә хәрби җитәкче булып эшли. Шул ук вакытта үзе дә Наманган өлкәсендәге Уйча мәктәбендә урта белем ала, унынчы сыйныфны тик бишлегә генә тәмамлап, 1951 елда Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетына укырга керә һәм 1955 елда әлеге уку йортын кызыл дипломга тәмамлый. Уку елларында әдәбият буенча шагыйрь Габдрахман Әпсәләмов, Сибгать Хәким, тел белеме өлкәсендә – Латыйф Җәләй, Вәли Хангильдин һ.б. ярдәм-киңәшен тоеп үз белемен камилләштерә. Ул булачак язучы-шагыйрьләр Барлас Камалов, Илдар Юзеев, Хисам Камалов, Марс Шабаев, Роберт Әхмәтҗановлар белән бер чорда белем ала. Өченче курста укыганда якташы, адашы Суфиян Сафуановтан «иҗат түгәрәге дибегәсен» үз кулына ала. Биш ел буена группа старостасы булып тора.

Педагогик хезмәт юлын Суфиян Поварисов Татарстан АССРының Актаныш районы Бурсык мәктәбендә директор вазифасында башлый (1955–1958), татар теле һәм әдәбиятыннан укыта. Яшь җитәкче, элеккеге фронтовик мәктәп тормышына гына түгел, ә авыл көнитмешенә дә яңа сулыш өрә: мәктәп янында 1 гектар җирне уратып алып, зур җимеш бакчасы утыртуга алына, төрле һөнәр кешеләрен танго, вальс, фокстрот биергә өйрәтә, иҗат түгәрәкләре оештыра, актуаль темага әсәрләр таба алмаганда, сәхнәләштерү өчен ике дистәгә якын пьеса иҗат итә. Кызганыч, әдипнең өйрәнчек пьесалары сакланмаган. Шул ук вакытта үзе дә режиссер, артист буларак чыгыш ясый.

Иҗатка тартылу, иҗади шәхесләр белән аралашу ихтыяҗы аны 1958 елда Уфага, «Кызыл таң» республика гәзитенә алып килә. Яшь журналист Суфиян Поварисов нефть-химия бүлегенә билгеләнә, республика заводлары, нефть-химия оешмалары, комбинатлары буйлап туктаусыз командировакаларга йөри, дистәләгән язмышлар белән очраша. Билгеле, дөньяны колачлап йөзәргә әзер, дәрт-дарманы ташып торган талантлы журналист бер тема чикләрендә генә калмый: төрле һөнәр кешеләре язмышы белән кызыксына, данлыклы якташлары турында материал җыя, күпсанлы мәкаләләр, очерклар язып бастыра. Илеш игенчеләре хакындагы язмаларын туплап, рус һәм башкорт телләрендә «Бәхет турында легенда» дигән китабын нәшер итә. Авыл

хуҗалыгындагы проблемаларны күтәреп, аларны ун дәфтәргә бүлеп, уртак идея-эстетик концепциягә буйсындыра – авыл эшчәннәренең фикадарь хезмәтенә дан җырлый. Якташларына булган игътибары, аларны алдынгылар рәтендә күрү теләге язучы Әмир Гәрәев белән берлектә төзелгән «Баймак – Илеш» китабында ачык чагыла.

Авыл тормышын якыннан белгән, аның киләчәге өчен борчылган ялкынлы журналист «Авыл язмышы кем кулында?» исемле язмаларын да ахырда китап итеп бастыра. Авторга хас булганча, биредә дә документальлек белән публицистик аң-фикер үрелеп бара. Заман сулышын тоеп язылган «Нәрсә ул бәхет?», «Әдәплелек», «Акыл кайчан утыра?» кебек мәкаләләре гәзит укучыларны бәхәскә чакыра, матбугат тормышын җанландырып җибәрә.

Суфиян Поварисовның язганнары коры публицистик язма булып калмый, образлы, халыкчан тел белән, хис-тойгы кушылып, характерлы детальләр белән баетылып иҗат ителә, документальлек һәм художестволылыкның органик берләшүеннән туган әсәр дәрәҗәсенә күтәрелә. Мәсәлән, «Алтын Йолдызлы Ләйлә» документаль повесте нефтьче кыз, 33 яшендә Социалистик Хезмәт Герое исеме алган Ләйлә Мәрданшина хакындагы мәкалә, очерклардан үсеп чыккан. Кайбер башка проза һәм драма әсәрләренә дә очеркларына материал булган вакыйгалар алынган, алар иҗатчының документальлекне художество дәрәҗәсенә күтәрү осталыгын раслый.

1960 елдан Суфиян Поварисов Башкорт дәүләт университетында укыта башлый, педагогик һәм фәнни эшчәнлеккә ныклап тотына. Гади ассистенттан башлап профессор дәрәҗәсенә кадәр юлны бер урында – татар филологиясе кафедрасында үтә. Яшь буын тел-әдәбият белгечләрен укытуга ярты гасыр гомерен багышлый, соңгы көннәренә кадәр бу югары уку йорты белән бәйләнешне өзми – шәрәфле профессор, консультант була. Югары мәктәп укытучысының көндәлек мәшәкатьләреннән тыш, ул төрле конференцияләрдә, диссертацияләр яклау Советында, иҗтимагый оешмалар эшчәнлегендә катнашырга да вакыт таба. Башкорт дәүләт педагогия институтында 1995 елда ачылган татар бүлеге студентларына да дистә елга якын лекцияләр укый, «үз профессорына» әверелә.

С.Ш. Поварисов – 300 дән артык фәнни хезмәт авторы. Аның фәнни-тикшеренү эшчәнлеге татар теленең стилистикасын һәм грамматикасын, татар әдәби теленең тарихын, әсәрләрнең телен, язучылар стилен өйрәнүгә багышлана. М.З. Зәкиев, Г.Ф. Саттаров, М.В. Зәйнуллин, Ф.А. Ганиев, Р.Г. Сибәгатов, С.Г. Сафуанов кебек академик-профессорлар аның фикердәше, фән юлында аркадашы булды, анны «абруйлы белгеч» [2; 23] буларак таныды.

Максатчан һәм тырыш хезмәт нәтиҗәсендә галим җиде саллы монография бастыра. «Тел – күңел көзгесе» (Казан,1982), «Сүз һәм сәнгатьле сөйләм» (Уфа, 1997), «Тел рухияте» (Уфа, 2008) һ. б. монографияләрендә сәнгати сүзнең – тел җәүһәрләренең эчке мөмкинлекләрен, образ тудырудагы көчен ачып сала, эстетик кыйммәтен ачыклый [1; 7]. Галим бар гомерен тел җәүһәрләрен җыюга багышлый, аларның матурлыгына гаҗәпләнә, шул сокклануын укучылар белән уртаклаша. Кыргыз, үзбәк, уйгур, төрек, мадьяр телләрен өйрәнгән телче туган телнең матурлыгын, байлыгын, эчке серләрен тагын да нечкәрәк тоемлый. «Энҗеләр кайда ята?» дигән хезмәтендә дә ул 11 телне чагыштыра, бу телләрнең сүзлек хәзинәсенә игътибарын юнәлтә.

Суфиян Поварисовның фән белән кызыксынуы Казан дәүләт педагогия институтында уку елларында ук башлана [2; 21]. Студентларның фәнни конференциясендә укыган «Муса Җәлил иҗатында чагыштырулар һәм аларның әдәби әсәрнең идея-эчтәлеген ачудагы роле» дигән доклады «Совет мәктәбе» (1956, №1) журналында басылып чыгу бу юлда беренче уңыш була. Кандидатлык диссертациясен М.З. Зәкиев җитәкчелегендә «Татар телендәге чагыштырулар» (1966) темасына яклый. Фәнни-тикшеренүләрен тагын да киңәйтеп, тирәнәйтеп, «Система образных средств в художественной прозе Г. Ибрагимова» (1990) исемле докторлык диссертациясен яклый.

Күрүебезчә, галимнең Г. Ибраһимов шәхесе һәм иҗаты белән кызыксынуы, әсәрләрен төрле аспектлардан чыгып өйрәнергә алынуы нәтиҗәле һәм бәрәкәтле булды. Бу уңайдан С.Ш. Поварисов «Г. Ибраһимов стиленең үзенчәлеге һәм аларны мәктәптә өйрәнү» (1974), «Г. Ибраһимов прозасының теле һәм стиле» (1978), «Г. Ибраһимов прозасында образлар системасы» (1980), «Роль Г. Ибрагимова в развитии татарского литературного языка» (2003), «Г. Ибраһимов поэтикасында фразеология» (2004), «Галимджан Ибрагимов и татарский литературный язык» (2009) һ.б. методик кулланмалар, монографияләр бастырып чыгарды. Галим Г. Ибраһимовны сурәтләү остасы буларак җентекле тикшерде, тел мөмкинлекләрен файдалану осталыгын ачыклады, тел һәм әдәбият галиме буларак эшчәнлегенә анализ бирде, әсәрләренең идея-эстетик кыйммәтен барлады. Фәндәге кызыксынулары киләчәктә язылачак трилогиягә дә оеткы булып ятты. Бу елларда Галимҗан Ибраһимов шәхесе белән рухлану, билгеле ки, Суфиян Поварисовның әдәби-эстетик карашларын да киңәйтә, иҗатына яңа сулыш өсти.

Әдәби иҗатны, язучының иҗат лабораториясен тирәнтен тоемлап, аңлап язылган әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, рецензия-бәяләмәләре аны тел, әдәбият күренешләрен бүгенге филология фәне казанышларыннан чыгып бәяләүче галим буларак күрсәтте [3; 131]. Язучыларның

индивидуаль стилен ачыклап язылган дистәләрчә мәкаләләрендә татар, башкорт әдипләренең ни дәрәҗәдә телне куллана белү осталыгы анализланды, тел үсешендәге кызыклы күренешләр барланды, үзенчәлекләре билгеләнде. Алар арасында шагыйрьләрдән – Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Г. Кандалый, М. Гафури, Г. Тукай, Дәрдмәнд, М. Җәлил, Һ. Такташ, С. Хәким, М. Кәрим, С. Кудаш, Р. Гарипов, Ә. Атнабаев, М. Нәзиров, М. Вафин, прозаиклардан – Г. Ибраһимов, Г. Бәширов, Г. Хөсәенов, Ә. Әминев, Җ. Киекбаев, И. Гыйззәтуллин, Д. Булатова, драматурглардан – Н. Исәнбәт, К. Тинчурин, Н. Асанбаев, С. Мифтахов, Н. Гаетбаев һ. б. ларның иҗатлары игътибар үзәгенә алынды. Драматург тәҗрибәсе аңа театр тәнкыйтьчесе буларак чыгыш ясарга да мөмкинлек бирде.

Шулай ук, тел-стильне өйрәнүнең фәнни-методик нигезләренә багышланган мәкаләләр, уку кулланмалары авторы буларак та абруй казанды.

Галимнең хезмәтләре үз чорындагы фәнни карашларга нигезләнеп, милли әдәбият материалларын әйләнешкә кертеп язылган. Соңгы елларда коры фәнни стильдән бигрәк, хисси фәнни-публицистик юнәлешне өстен күрде, танылып торган үз стилен барлыкка китерде. Ул язган хезмәтләр тел-әдәбият белгечләрендә генә түгел, киң катлам укучыларда да кызыксыну уятты.

С.Ш. Поварисовның телче-галим буларак фәнни-методик эшчәнлеге, тюркология фәне үсешенә керткән өлеше хакында М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, М.В. Зәйнуллин, Ф.Б. Саньяров, А.Г. Шәйхулов, К.М. Миңнуллин, И.С. Насипов язган мәкаләләр игътибарга лаек.

Профессор С. Поварисов яшь галимнәр әзерләүгә дә зур өлеш кертте. Аның җитәкчелегендә Р.Р. Гәрәева (2001), Р.М. Миргалеев (2002), А.Ф. Камалова (2005), З.С. Кәримова (2008), К.А. Габбасова (2009) кандидатлык диссертацияләре якладылар. Студентларның, яшь галимнәрнең фәнни-тикшеренү мәкаләләрен туплап, «Сүз сәнгате» дигән җиде басма әзерләде, аларның күбесен үз исәбенә бастырып таратты, фәнгә мәхәббәт тәрбияләү юлында тынгысыз хезмәт итте.

## Әдәбият исемлеге


1. Зайнуллин М.В., Саньяров Ф.Б. Татар әдәби теленә һәйкәл койды // Актуальные проблемы современной татарской филологии. Сборник статей Всероссийской научно-практической конференции. – Уфа, 2014. С. 6–11.

2. Зәкиев М.З. Нәфис сүз сәнгате остасы // Поварисов С.Ш. Сүз – сәнгать илаһияте. Уфа: РНҮ БашДУ, 2011. – Б. 21–24.

3. Шайхулов А.Г., Миннуллин К.М., Насипов И.С. Суфиян Шамсутдинович Поварисов // Российская тюркология. – 2018. № 1–2(18–19). – С. 131.

© Халиуллина А.Г., 2024

УДК 821.512.145

**Шарипов М.С.,**
*Уфа ш., Россия*

# Р.Г. СИБӘГАТОВНЫҢ ЭТНОЛИНГВИСТИКА ҺӘМ ПОЛИТОЛОГИЯ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Аннотация:*** *мәкаләдә күренекле галим, филология фәннәре докторы, профессор, Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Р.Г. Сибәгатовның социолингвистика, этнолингвистика һәм политология өлкәсендәге фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеге ачыла, аның фәнгә керткән өлеше анализлана.*

***Терәк сүзләр:*** *Р.Г. Сибәгатов, татар теле, социолингвистика, этнолингвистика һәм политология.*

XX йөз азагы – XXI йөз башы арасы татарлар тупланып яшәгән төбәкләрдә милли үзаңның тиз арада уяну һәм милли азатлык хәрәкәте активлашу чоры. Бу хәрәкәт башында кыю рухлы милләт уллары һәм кызлары – зыялылар торды. Милли хәрәкәт сафында галимнәр дә актив катнашты. Алар тарафыннан матбугатта тел, аның тарихы, тел статусы, кавем тамырлары, чишелергә тиешле проблемалар калкытып куелды. Андый шәхесләр милләт каһарманнарына әйләнделәр, аларның татар халкында милли үзаңны үстерүгә, милли тойгыларны уятуга керткән хезмәтен яңа буын кешеләре югары бәяли.

2010 елның октябрь башынды Башкорт дәүләт университетында беренче тапкыр «Сибәгатов укулары» дип аталган гыйльми-гамәли чара оештырылды. Уфа шәһәренең «Рамазан» төрки милли-агрту үзәге, Башкорт дәүләт университеты, М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университеты оештырган бу проектта Башкортстан галимнәре, аспирантлар, студентлар, катнашты. Җыелыш тантанасын ачканда, М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университеты ректоры Р.М. Әсәдуллин профессор Р.Г. Сибәгатовны тарихи шәхес дип атады, аның хезмәтләре халык күңелендә озак сакланачагын белдерде. Мәҗлестә Бөтендөнья татар конгрессының оештыручыларга, катнашучыларга тәбрикләү хаты укылды, анда Р.Г. Сибәгатовның татар лингвистикасына,

милли хәрәкәткә, XX гасыр ахыры – XX гасыр башында милли күтәрелеш кичергән Башкортстан татарларының рухи үсешенә зур өлеш керткәнлеге югары бәяләнде, галимнең хезмәтләре якташлары өчен таяныч булуы билгеләнде. Башкортстандагы танылган шәхеснең якты истәлегенә багышланган бу проект алдагы елларда да дәвам итте. Бүгенге көндә «Сибәгатов укулары» студентлар, аспирантлар өчен оештырыла. Әйтергә кирәк, БДУның татар филологиясе кафедрадасында эшләп киткән бер укытучыга да даими рәвештә гыйльми мәҗлесләр оештырылмый. Кайсы уңышлары, кайсы ягы белән Р.Г. Сибәгатов, аның күптармаклы эшчәнлеге замандашлары, шәкертләре тарафыннан тирән хөрмәт итеlә? Р.Г. Сибәгатов – танылган телче-галим, югары уку йорты мөгаллиме, остаз, этнолог, политолог, җәмәгать эшлеклесе, журналист... Иң мөһиме, ул – арсландай кыю, олы йөрәкле, тирән фикерле, универсаль эшчәнлек алып барган милләтпәрвәр шәхес иде.

Билгеле ки, узган гасырның 90 нчы елларында Совет Социалистик Республикалар Берлегенең таркалуы җәмгыятьтә милли мәсьәләнең актуальләшүенә китерде. Элекке империя харитасында аерым җөмһүриятләр барлыкка килде, аларда милли азатлык, бәйсезлек өчен көрәш башланды.

Төрле урыннарда тупланып яшәгән татарлар, милли оешмалар да тарихтагы үз урыны, теле, мәдәнияте, киләчәге турында җитди уйлана башладылар. Милли хәрәкәтнең активлашуы яңа кешеләрне, әйдәманнарны көрәш мәйданына алып менде.

Башкортстанда яшәүче татарларның милли лидерлары арасында Радик Гали улы Сибәгатов та бар иде. Ул митинглар, җыелышлар кебек урам чараларында катнашмады, әмма аның тел мәсьәләсенә багышланган чыгышлары, милли тигезлек, гаделлек хакындагы язмалары чор өчен зур әһәмияткә ия иде.

Хәлбуки телче-галимнең сәясәткә килүе очраклы булмады. Аның биографиясенә игътибар итсәк, шәхесне заман тудыруы хакында кызыклы гына күзәтүләр ясарга мөмкинбез. Булачак галимнең үсмер чоры Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. 1934 елның 29 маенда Башкортстанның Балтач районые Иске Балтач авылында дөньяга килгән Р.Г.Сибәгатов бала чагыннан ук тоталитарзм шаукымының тере шаһиты була, ә инде «Хрущёв җепшеклеге» дәверендә егет кеше тормыш эчендә актив кайный башлый. Зыялылар гаиләсендә тәрбияләнеп, авыл мәктәбен уңышлы тәмамлагач, ул Бөре дәүләт педагогик институтына документларын тапшыра, татар мәктәпләре өчен рус теле һәм әдәбияты белгечләре әзерли торган татар-рус бүлегендә укый.

Әмма егет алга таба педагогик юлны сайламый, аны журналистика кызыксындыра. Каләм тибрәтү белән бәйле хезмәт юлын Р.Г. Сибәгатов

1957 нче елда Уфада даими чыгып торган «Кызыл таң» республика газетасының редакциясендә башлый. Башта ул редакциядәге тәрҗемәчеләр төркемен җитәкли, алга таба махсус хәбәрче булып эшли. Үз һөнәренә җаваплы караган белгечне баш мөхәррир редакциянең дәүләт төзелеше бүлеген, хатлар бүлеген, мәгълүмат бүлеген, авыл хуҗалыгы бүлеген җитәкләргә җәлеп итә. Кыскасы, республика буйлап төрле командировкаларда йөрү вакытында, редакция тормышы эчендә кайнау дәверендә Р.Г. Сибәгатов чынбарлыкны бөтен тулылыгында өйрәнә, анда барган үзгәреш-борылышларны якыннан күзәтә. 1966 елда аны, белемле, тырыш журналистны, Ленинград шәһәрендәге Югары партия мәктәбенең матбугат хезмәте бүлегенә укырга җибәрәләр. Баксаң, Р.Г. Сибәгатов киләчәктә матбугат җитәкчелеге һәм партия төзелеше юлы буенча китәргә, бу юлда карьера ясарга тиеш иде кебек. Әмма сәләтле белгечне иҗат, фән өлкәсе кызыксындыра. Җае да килеп чыга: аны Уфадагы югары уку йортына эшкә чакыралар. 1970 елның ноябреннән Р.Г. Сибәгатов Башкорт дәүләт университетының татар-рус бүлегендә тел курсларын укыта башлый, тиз арада ассистент вазифасыннан профессор дәрәҗәсенә кадәр үсә, кандидатлык, докторлык диссертацияләрен уңышлы яклый. Р.Г. Сибәгатов гомеренең 35 елын Башкорт дәүләт университетында татар филологларын, мәктәпләр өчен татар теле һәм әдәбияты укытучыларын, татар журналистларын әзерләүгә багышлый. 1988 елда чираттагы гыйльми утырышта коллегалары Р.Г. Сибәгатовны кафедра мөдире итеп сайлый. 17 ел дәвамында ул татар филологиясе кафедрасын уңышлы җитәкли. Бу дәвер кафедраның чәчәк аткан еллары иде. Беренчедән, укыту эшенә ул сәләтле яшьләрне җәлеп итте, икенчедән, колллективның бердәмлеген булдырды. Кафедра һәм аның янында эшләгән татар-рус бүлеге тиз арада Башкортстан татарларының мәгариф, милли-мәдәни үзәгенә әйләнде.

Университетта укыткан вакытның беренче яртысында профессор Р.Г. Сибәгатов ике юнәлешне тикшерү объекты итеп ала: татар синтаксисы һәм тәрҗемә теориясе. Бу өлкәләрдә галим ике йөздән артык фәнни хезмәт, шул исәптән җиде дәреслек яза. Аның «Предикативлык теориясе» (Саратов, 1984); «Рус теленан татар теленә тәрҗемә итү методикасының нигезләре» (Уфа, 1979) хезмәтләре гыйлем ияләре арасында зур хуплау тапты. Алга таба галимне тел темасы гына түгел, ә тарих, татар телен үстерү, социолингвистика һәм этнолингвистика проблемалары да кызыксындыра башлый. Илдә барган сәяси, иҗтимагый үзгәрешләр моңа этәргеч ясый иде.

Узган гасырның 90 нчы еллары ахырында Р.Г. Сибәгатов тормышында яңа чор башлана. Башкортстан Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, Башкорт дәүләт педагогия институты ректоры,

профессор Э.Ш. Хәмитов аны җәмгыять оешмасы эшенә җәлеп итә. Абруйлы шәхеснең шәхсән чакыруын Р.Г. Сибәгатов кире какмый. Э.Ш. Хәмитовның Башкорт дәүләт педагогия институтындагы филология факультеты эчендә татар бүлеген ачуы, татар теле һәм әдәбияты кафедрасын оештыруы җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алынды. Нәтиҗәдә, Р.Г. Сибәгатов Башкортстан Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары булып озак еллар эшли. Конгресс эшенә ул кайбер коллегаларын да җәлеп итә. Әйтик, Башкортстан Татар конгрессы башкарма комитетының мәдәният һәм сәнгать комиссиясе җитәкчесе булып эшләргә Р.Г. Сибәгатов БДУның татар филологиясе кафедрасы укытучысы М.С. Шәриповны чакыра.

Башкортстан Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары вазифасын башкару Р.Г. Сибәгатовка яшәү һәм иҗади тормыш өчен уңайсызлыклар тудырганын билгеләргә кирәк. Әйтик, Башкорт дәүләт университеты җитәкчелеге аның бу әвәсенә канәгатьсезлек белдергән очраклар да булды, гыйльми утырыш вакытында аңа урынсыз кисәтүләр дә яңгырый. Әмма мондый вакытта галим салкын канлы булды, үзен кыю йөрәкле милләтпәрвәр икәнен ачык күрсәтте. Әйтик, ул үзенең чыгышларында Башкортстанда татар теленә дәүләт теле статусы биру өчен нигезле дәлилләр китерә иде. Аның гыйльми батырлыгын чагыдыручы хезмәт 2002 елда Казанда дөнья күрә [1].

Киң катлам укучылар өчен гыйльми-публицистик стильдә язылган бу китап Башкортстан татарларының тарихына, теленә, мәдәниятенә комплекслы анализ ясый. Китап үзара тыгыз бәйләнгән өч бүлектән тора. «Башкортстан татарларының үзенчәлекле этник берләшмә булып оешуы» дип аталган беренче бүлектә автор татарларның этногенезын, милләтнең диалект үзенчәлекләрен, мишәрләр, типтәрләр, керәшеннәрнең Урал, Ирәндек тауларына күчеп утыру юларын ачып сала. Р.Г. Сибәгатов халык телендәге онытылган кайбер үзатамаларны искә төшерә: «Башкортстан мишәрләре үзләрен «төмән», «алатыр» (элек яшәгән урыннары – Темников, Алатыр) исемнәре белән атаганнар. Бу исемнәр матбугат басмаларына да кереп калган. Галимҗан Ибраһимов үзенең бер мәкаләсендә Уфа алатырларын телгә ала. Әмирхан Еники үзенең истәлекләрендә Каргалы төмәннәре турында яза. Мондый үзатамалар акрынлап телдән югала барган. Мишәрләр үзләренең бөтен этнографик төркемнәре белән мөселман, татар исемнәренә күчкән» [1; 30].

Башкортстандагы христиан динендә булган татарларны галим керәшеннәр дип атау ягында: «Бакалы керәшеннәре – Казан татарларына якын төркем. Ләкин дин аермасы аларның рухи һәм матди мәдәниятендә,

телендә үзенчәлекләр китереп чыгарган. Ул үзенчәлекләр, бер яктан, христианнар йогынтысы нәтиҗәсе булса, икенче яктан, татарның борынгы традицияләре сакланып калуы (консевацияләнүе) белән характерлы». Галим бүгенге көндә дә бәхәсләр уяткан типтәрләрнең килеп чыгышы мәсьәләсен объектив анализлаган.

Хезмәтнең икенче бүлеге Идел белән Урал арасында иҗтимагый фикер үсеше, җирле сөйләшләрнең татар һәм башкорт телләренә мөнәсәбәте, борынгы һәм хәзерге тел арасындагы аермалар мәсьәләләрен яктырта. «Башкортстан татарларына мөнәсәбәт, аларның телен һәм милләтен билгеләү мәсьәләсе» дип аталган бу бүлек үзенең кыюлыгы белән аерылып тора.

Китапның «Башкортстанда татар теленең хокукый статусы турында"исемле өченче бүлегендә автор фикере Башкортстандагы дәүләт теле статусы тирәсендә хәрәкәт итә. Үзенең карашларын раслаганда, галим архив кәгазьләренә, дәүләт документларына таяна. Китаптан күренгәнчә, Р.Г. Сибәгатов Башкортстанда татар теленең дәүләт теле статусына карата анык позициядә тора. Ул бер миллионлы татарларның туган теле дәүләт теле хокукына ия булырга тиешлеген, мәгариф, мәдәният мәсьәләләренддә милли үзбилгеләнүне, телнең сафлыгын, яклый, татар әдәби теленең башка төрки халыклар эчендә йөзсез калуга кискен каршы чыга.

Китапның мөһим өлеше – кушымта. Р.Г. Сибәгатов монда матбугатта басылган кызыклы мәкаләләрне, хатлар, гаризалар, белдерүләр күчермәләрен, кануннардан, милли оешмалар тарихына караган документлардан өземтәләр китерә.

Р.Г. Сибәгатов хезмәт ахырында фәлсәфи нәтиҗә ясый: «Тел – гомер-гомердән конфликтлы өлкә. Максат – аларны кайсын да булса сайлап, аерып карау түгел, ә теге яки бу дәрәҗәдә үсеш алуының сәбәпләрен ачыкларга тырышу. Фән һәрвакыт ситуациягә объектив анализ нигезендә, байтак катлаулы мәсьәләләрнең күпчелек кабул итәрлек чишелешен таба» [1; 100].

«Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре» хезмәте белән филология фәннәре докторы, профессор Р.Г. Сибәгатов Башкортстан татарларының тарихы, теле, киләчәге турындагы белемнәрне, карашларны фәнни нигездә формалаштыруга, Урал тавы җирләрендә барган этносәяси күренешләрне аңлатуга һәм фаразлауга зур өлеш кертте. Китапта белдерелгән фикерләр, күзәтүләр бүген дә актуаль булып кала.

Әйтергә кирәк, үзенең дөньяга мөнәсәбәтендә Р.Г. Сибәгатов киң карашлы галим, интернационалист кеше иде. Ул бар халыкларга, шул исәптән татарларга да, башкортларга да хөрмәт белән карады. Аның

фикеренчә, татар һәм башкорт халыкларының киләчәге хокукый гаделеккә, тигезлеккә һәм бердәмлеккә нигезләнгән, демократик принципларга таянган шартларда үтәргә тиеш.

**Кулланылган әдәбият**

1. Сибәгатов Р.Г. Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре. – Казан: Мәгариф, 2011. – 191 б.

Шарипов М.С., 2024

УДК 81 – 119

**Абдиева А.Ф.,**
*г. Уфа, Россия*
*Научный руководитель – к.ф.н., доцент* ***И.Ф. Зарипова***

# ЛЕКСИКО-СЕМАНТИЧЕСКИЙ АНАЛИЗ ФРАЗЕОЛОГИЗМОВ С КОЛОРИСТИЧЕСКИМ КОМПОНЕНТОМ «ЧЕРНЫЙ» (НА МАТЕРИАЛЕ РУССКОГО, АНГЛИЙСКОГО И ТАТАРСКОГО ЯЗЫКОВ)

***Аннотация:*** *статья посвящена исследованию лексико-семантического анализа фразеологизмов с колористическим компонентом «чёрный» в русском, английском и татарском языках. Целью работы является выявление общих черт и различий в использовании этого компонента в данных языковых системах, а также определение культурно-исторических аспектов его применения. В ходе исследования использованы методы компонентного анализа, сопоставления, контекстуального анализа.*

***Ключевые слова:*** *фразеология, лингвистика, лингвокультурология, колористика, концепт, символ.*

Фразеология является одной из наиболее интересных областей лингвистики, поскольку она отражает культурные особенности языка, его историю и менталитет носителей. Лексические единицы с устойчивыми значениями, такие как фразеологизмы, обладают высокой степенью идиоматичности и часто содержат в себе элементы символизма, которые могут различаться от одного языка к другому. Одним из таких элементов является использование цвета в составе фразеологических единиц. В данной статье мы рассмотрим фразеологические выражения с колористическим компонентом «чёрный» в трёх языках: русском, английском и татарском. Мы проанализируем их семантику, структуру и

культурную специфичность, а также проведём сравнительный анализ для выявления общих черт и различий между этими языками [2].

Колористика – это область науки, изучающая восприятие и использование цветов в различных областях жизни, включая язык. Цветовые компоненты играют важную роль в формировании смысла фразеологических единиц, так как они несут в себе определённые ассоциации и символы. Например, в русской культуре чёрный цвет ассоциируется с чем-то негативным, трагичным или таинственным, тогда как белый – с чистотой и добром [1; 3].

В русском языке существует множество фразеологических выражений с компонентом «черный», приведем некоторые из них. *Чёрный день* – трудное время в жизни кого-либо, время нужды, безденежья, несчастий. *Мы не знали другой власти, кроме родной советской. И значит: мы не знали безработицы, бесправия, черного дня* (Б. Горбатов). Черный день — это мифологическое противоречие, ибо день должен быть светлым, белым. Черный же – такой, который аналогичен ночи и потому открывает дьяволу широкие, поистине ночные возможности. Черный день тем самым смыкается и с недобрым часом, и с лихой годиной. Данный фразеологизм встречается и в татарском языке: *кара көн. Про (на) чёрный день* – иметь, хранить, беречь, сберегать (сберечь), откладывать (отложить), прятать (запрятать) и т.п. На случай острой нужды (хранить, беречь и т.п.). *Сколько я помню, больше семи или десяти рублей из «запасу» на черный день бабушка никогда Левонтьихе не давала, потому как весь этот «запас» состоял, кажется, из десятки* (В. Астафьев). *Держать в черном теле* – сурово строго обращаться с кем-либо; притеснять кого-либо. *Мартынова **держали в черном теле,** выпуская почти исключительно в водевилях* (Б. Горин-Горяйнов). *Черная кость – кара сөяк* – человек незнатного происхождения или принадлежащий к непривилегированному сословию в дореволюционной России. *Теперь – вы сами знаете – Чем дерево дворянское Древней, тем именитее, Почетней дворянин. Не так ли, благодетели? Так! – отвечали странники. – Кость белая, **кость черная** – И поглядеть, так разные. Им разный и почет* (Н. Некрасов). *Чернильная (бумажная) душа* – бюрократ, чиновник, формалист. *Что Бастрюков **бумажная…душа**, Ефимов понял довольно быстро, как только началась война* (К. Симонов). *Черная кошка пробежала (проскочила)* – произошла ссора, размолвка между кем-либо; кто-либо с кем-либо поссорился. *Между нами **пробежала черная кошка*** (В. Немирович-Данченко). Этот фразеологизм связан с поверьем, существовавшим у славянских народов: чёрная кошка, перебежавшая дорогу, приносит несчастье, неудачу. Также в Древнем Египте кошка почиталась как священное животное, после смерти её тело

бальзамировали, как и тело человека. Из Египта кошка попала в Грецию, где долгое время считалась экзотическим, «роскошным» животным. Для ловли мышей в домах в то время использовали ласку или хорька. Древние германцы также обожествляли кошку. В Средние века, из-за ночного образа жизни, кошка стала предметом суеверного страха, особенно не повезло в этом смысле чёрным котам и кошкам. Очень плохой приметой считалось, если чёрная кошка переходила дорогу. Эквивалент данной фразеологической единицы в татарском языке – *арага кара мәче керү = арадан кара мәче чыкты (үтте*), *кара песи булу, арага кара песи җибәрү*.

Во всех приведенных примерах чёрный цвет ассоциируется с чем-то негативным, неприятным или опасным. Эти ассоциации уходят корнями в русскую культуру и традиции, где черный цвет традиционно воспринимается как символ смерти, горя и зла.

Английские фразеологизмы с компонентом «black» также имеют широкий спектр значений: *black sheep* – человек, который отличается от остальных членов группы, обычно в негативном смысле. Этот термин используется для описания члена семьи или коллектива, который ведет себя иначе, чем остальные, и часто вызывает неодобрение. *He is the **black sheep** in our family because he always gets into trouble*. В русском языке есть эквивалент данного фразеологизма, только с компонентом «белый» – *белая ворона* – человек, резко выделяющийся среди других людей. *To look through a black glass* – видеть мир пессимистично. Этот оборот описывает состояние ума, когда человек видит все в мрачных красках. *She tends **to look through a black glass** when things don't go her way*. *A black mark* – пятно на репутации, нечто негативное, что портит имидж. Как и в предыдущих примерах, черный цвет ассоциируется со злом или неприятностями. *His past mistakes left **a black mark** on his reputation*. В английском языке черный цвет также несет в себе как негативные, так и положительные коннотации, в зависимости от контекста. Например, *In the black* – иметь прибыль, находиться в финансовом плюсе. Здесь черный цвет приобретает положительное значение, связанное с финансовой стабильностью и успехом. *The company finally got back **in the black** after years of losses.*

Татарский язык имеет свои уникальные фразеологические единицы с компонентом «кара»: *кара кымыз* – опьяняющий кумыс. Ранее ферментировался особым способом. *Кара яну* – 1) от сильных ударов синяки на теле; 2) от сильного беспокойства чернеет лицо. *Карасалар, **кара янмаган** җире юк. Бөтен тәненә кан сауган* (М. Дибаева). *Кара көю* – сосотояние гнева. *Ул ачуыннан **кара көеп** почмакка барып баскан иде* (Г. Әпсәләмов). *Кара язмыш* – несчастная судьба, жизнь. *Кара карга* –

глупый, необразованный человек. *Кара төлке* – редкая вещь, редко встречающийся человек. – ***Кара төлке*** *булдың син, ә? Кара эч(ле)* – о двуличном, завистливом, циничном человеке. ***Кара эчле*** *явызлар шунда безгә карап тик үртәнеп үлсеннәр әйдә* (М. Җәлил). *Карага батып йөрү* – мрачное, злое лицо. *Юк, авырмый. Күрмисеңмени, миңа үпкәләгән, шуңа* ***карасына батып йөри*** (Г. Гомәр). *Йөзне кара итү* – унизительный позор. Следующие фразеологизмы с цветовым компонентом «черный» – «кара» имеют положительную окраску: *кара тун* – монах, *кара алтын* – нефть. *Газеталарда без нефтьне* ***кара алтын*** *дип язабыз. Димәк, хәзинә* (Г. Ахунов), *кара бай* – богатый хлебопашец, в значении очень богатый. *Авылыбызда череп беткән* ***кара бай*** *бар иде* (Г. Ибраһимов).

Для полного понимания природы фразеологических выражений необходимо рассмотреть исторические и культурные факторы, влияющие на формирование ассоциативных смыслов, связанных с цветом.

Исторически в русской культуре черный цвет ассоциировался с трауром, смертью и несчастьем. В православной традиции черный цвет был символом скорби и печали. Также в народной мифологии и сказках черные предметы часто имели магическое значение и использовались в ритуалах. Эти ассоциации нашли отражение в многочисленных фразеологизмах, где черный цвет выступает как символ угрозы или негатива.

В англоязычной культуре черный цвет также имеет долгую историю негативных ассоциаций. Он ассоциировался с ночью, тьмой и неизвестностью, что вызывало страх и тревогу. Однако, как было отмечено ранее, в некоторых контекстах черный цвет приобрел положительные коннотации, особенно в сфере бизнеса и финансов, где он стал символом успеха и стабильности.

Татарская культура, будучи частью тюркской цивилизации, имеет свою уникальную систему символов и образов. Черный цвет в татарской культуре часто ассоциируется с тайнами, мистикой и скрытыми угрозами, а также означает богатство, принадлежность к чему-либо.

Исследование фразеологизмов с компонентом «черный» («black», «кара») в русском, английском и татарском языках позволило выявить как общие черты, так и уникальные особенности употребления этого компонента в каждой культурной среде. Общие черты включают преобладание негативных ассоциаций, связанных с несчастьем, опасностью и злом. Однако существуют и исключения, где черный цвет приобретает положительные или нейтральные значения.

## Список литературы

1. Абдиева А.Ф., Зарипова И.Ф. Татар һәм рус телләрендә колористик фразеологизмнар тәңгәллеге // Актуальные проблемы современной татарской филологии: сборник статей XI Международной научно-практической конференции (г. Уфа, 24 ноября 2023 г.) / отв. ред. И.Ф. Зарипова; Г.У. Гайнуллина. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2023. – 306 с.
2. Виноградов В.В. Основные понятия русской фразеологии // Вопросы языкознания. – М., 1986. – № 1. – С. 15–28.
3. Кунин А.В. Курс фразеологии современного английского языка. – М.: Высшая школа, 1990. – 320 с.
4. Шарафиев Р.З. Татарская фразеология: история и современность. – Казань: Изд-во Казанского университета, 2008. – 256 с.
5. Longman Dictionary of English Idioms. – Harlow: Pearson Education Limited, 2017. – ISBN 978-1-4082-4209-5.


© Абдиева А.Ф., 2024

УДК 821.512.141

**Алдырханова-Кәримова А.Р.,**
*Сибай к., Рәсәй Федерацияһы*

## БАШЛАНҒЫС КЛАСТАРҘА ФОЛЬКЛОР ЖАНРҘАРЫН ӨЙРӘНЕҮ

***Аннотация***: *мәкәлә башланғыс кластарҙа фольклор жанрҙарын өйрәнеүгә арналған. Фольклор балаларҙы әхлаҡи тәрбиәләүҙең мәрхәмәтле һәм бер нәмә менән дә алмаштырғыһыҙ сығанағы булып тора, сөнки унда яуызлыҡ һәм изгелек, бәхет һәм ҡайғы менән бөтә реаль тормош сағылдырыла. Ул балаға йәмғиәт һәм тәбиғәт тормошон, кеше тойғолары һәм үҙ-ара мөнәсәбәттәр донъяһын аса һәм аңлата.*

***Асҡыс һүҙҙәр:*** *фольклор, жанр, әхлаҡи тәрбиәләү, башланғыс кластар.*

Халыҡ ижады сығанаҡтарына мөрәжәғәт итмәйенсә, милли мәҙәниәт ҡиммәттәрен аңламайынса һәм ҡабул итмәйенсә мөмкин түгел. Мәктәп практикаһында фольклор менән танышыу ғәҙәттә эпизодик рәүештә бара һәм башлыса йырҙарҙы өйрәнеү аша башҡарыла. Фольклорҙың ижади фекерләүҙе әүҙемләштереү сараһы булараҡ әһәмиәтен асыу төп бурысы булып тора. Уның нигеҙендә уҡыусыларҙа ысын матурлыҡты аңлау үҫешә, халыҡ музыкаһы ҡиммәттәренә, тыуған

яҡ тарихына, үҙ халҡының йолаларына һәм ғөрөф-ғәҙәттәренә, ата-бабаларҙың йыр мираҫына ҡушылыу ихтыяжы барлыҡҡа килә.

Фольклор һүҙе, йыш ҡына ауыҙ-тел ижады төшөнсәһен аңлата, ике инглиз һүҙенең ҡушылыуынан килеп сыҡҡан: folk халыҡ һәм lore аҡыл. Фольклор тарихы бик боронғо замандарға барып тоташа. Уның башы кешеләрҙең тирә-яҡ тәбиғәт донъяһын һәм унда үҙ урынын аңлау ихтыяжы менән бәйле. Был аңлау һүҙҙә, бейеүҙә һәм музыкала, шулай уҡ һынлы сәнғәт әҫәрҙәрендә, тәү сиратта ҡулланма сәнғәттә, биҙәүестәрҙә, дини культ предметтарында сағыла.

М.Х. Иҙелбаев фекеренсә, фольклор ярҙамында бала тирә-яҡ донъяға еңел инә, тыуған тәбиғәттең матурлығын тулыраҡ тоя, халыҡтың матурлыҡ, әхлаҡ тураһындағы күҙаллауҙарын үҙләштерә, йолалар менән таныша. Фольклорҙа халыҡтың ҡараштары, идеалдары һәм ынтылыштары, уның шиғри фантазияһы, уй-тойғолар, кисерештәрҙең бай донъяһы, ғәҙеллек һәм бәхет тураһында хыялдар кәүҙәләндерелә [3; 7].

Фольклор жанрҙарына күләме буйынса ҙур булмаған әҫәрҙәр ҡарай: Оҙон көйҙәр, йырҙар, таҡмаҡтар, бәйеттәр, мөнәжәттәр, ҡобайырҙар, эпостар, легенда-риүәйәттәр, хикәйәттәр, мәҡәл-әйтемдәр, әкиәттәр һ.б. жанрҙар инә.

Үзаллы эш дигəн сүзнең төшенчəсен һəр автор үзенчə ача. Бер төркем галимнəр үзаллы эшне үзаллы шөгыльне оештыру чарасы итеп карыйлар [1; 93]. Икенче төркем галимнəр үзаллы эшне оештыруның формасы итеп карый [2; 67].

Югарыда əйтелгəн галимнəрнең фəнни хезмəтлəрен гомумилəштереп: үзаллы эш – укучыларның укытучы җитəкчелегендə белемнəрне үзлəштерүдə биремнəр үтəү чарасы, дип билгелибез. Үзаллы эшне классификациялəүдə төрле карашларны анализлау аларның гаять күп булуын ачыклый, һəм алар үзаллы эшкə генə түгел, ə шəхеснең үзаллы иҗади үсүенə юнəлтелгəнлеген күрсəтə. Үзаллы эшне оештыру бик катлаулы һəм укытучыдан əзерлек талəп итүче процесс. Бу процессның катлаулылыгы һəм аңа əзерлек шуннан гыйбарəт: укытучы үзаллы эшне барлык этапларында да: планлаштыру, оештыру, контрольдə тоту – тəэмин итəргə тиеш. Бу эшчəнлек нəтиҗəсендə укучылар үзаллы белем алырга һəм практикада үзаллы кулланырга өйрəнергə тиешлəр.

Шəхси эш тəҗрибəсеннəн чыгып, шуны билгелəп үтəргə кирəк.Татар мəктəплəрнең кимүе уку программаларыннан төрки телле балалар өчен махсус басылган «Рус теле» дəреслеклəренең төшеп калуына китерде. Бу, үз чиратында, əти-əнилəрне үзлəренең балаларының телен рус телендə ачарга мəҗбүр итте, чөнки рустелле мəктəплəр өчен басылган «Рус теле» дəреслеклəре фəкать татар телен генə аңлаган балаларның укуын күпкə авырлаштыра.

Мəктəплəрдə балалар башлангыч əзерлексез туган теллəрен (татар телен) сайлыйлар. Əти-əнилəр мəктəплəрнең балаларны туган телдə сөйлəшергə өйрəтүенə өметлəнə. Кызганычка каршы, рустелле балаларны татар теленə өйрəтү методикасы – яшь методика дияргə була. Шулай ук, укучыларның башлангыч белем дəрəҗəлəре төрле булуы, туган тел дəреслəренə сəгатьлəрнең əз бүленүе, еш кына укучыларның, укытучыларның төрле җитди сəбəплəр белəн дəрес калдыруы, кайбер

мәктәпләрдә татар теле дәресләренең бөтенләй дә булмавы кебек проблемалар татар телен өйрәнүдә кытыршылыклар китереп тудыра.

Югарыда күрсәтелгән кимчелекләрне хәл итүгә зур көч салган шәхесләр дә байтак. Федераль дәүләт стандартларына җавап булган, рустелле балаларга интенсив рәвештә үзаллы татар теленә өйрәнергә мөмкин булырлык методиканы булдыру өстендә күп кенә эшләр эшләнә. Татар теле укытучылары тафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы сайтында байтак кына булган укыту методик кулланмаларны даими күзәтеп бару, укучыларның һәм эти-әниләрнең игътибарларын шундый яңалыкларга дәресләр, төрле җыелышлар, мәктәп сайтлары аша юнәлтеп тору укучыда үзаллылыкны тәрбияләүдә бер мөһим эш булып тора.

«Рустелле балаларны татар теленә өйрәтү өчен Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты хезмәткәрләренең фәнни-методик җитәкчелеге астында чит һәм туган тел укытучылары тарафыннан «Сәлам!» укыту методик комплекты (УМК) төзелде. УМК «Сәлам!» ике телле мохит шартларында уңышлы аралашу өчен укучыларда кирәкле база булдырырга ярдәм итә. УМКның төп үзенчәлеге – интенсив сөйләм (уку, тыңлау, сөйләү, язу) һәм укучыларның интеллектуаль үсешенә, тел тойгысын үстерүгә юнәлеш бирү» [4] Башлангыч сыйныфларда рустелле балаларны татар теленә өйрәтү өчен «Сәлам!» УМКсында жырларга аерым урын бирелгән. 1-4 класслар өчен җыр тексты һәм аңа караоке куелган.

«Сәлам!» УМКсына кергән жыр текстларын татар телен яхшы аңламаган балаларның ни дәрәҗәдә үзләштерә алуын анализлау укытучы өчен катлаулы гына мәсьәлә. Атнасына 0,5 сәгать бүленүен искә алганда, ел дәвамында 17 дәрес кысаларында бу кадәр жырларны өйрәтү мөмкин түгел, чөнки укучы бер дәрескә 5-7 яңа сүз генә истә калдыра ала, ә аларны хәтердә ныгыту өчен 6-7 дәрес таләп ителә. Шуңа күрә грамматик формалары катлаулы булмаган сүзләрне үз эченә алган текстлардан башлау, аларны календарь-тематик планда күрсәтелгән темалар белән жайлап кына бәйләү мотлак.

Гомумән, бу жырлар аша 1нче класста шундыйрак грамматик формадагы сүзләрне үзләштерергә мөмкиннәр: исем (сан, килеш категорияләре); сан (микъдар саннары); сыйфат (гади һәм артыклык дәрәжәсе); алмашлык (зат алмашлыклары); фигыль (хикәя, хәл, боерык фигыльләр); рәвеш (урын, вакыт, күләм). 2-3 нче класста ымлыклар, хикәя фигыль (билгеле үткән заман) формаларында килгән сүзләр өстәлә. 4 нче класста билгесез үткән заман формаларында килгән сүзләр белән баетылган текстлар өстәлә.

Чит телләрне жыр аша өйрәнү темасына үзебезнең һәм чит ил галимнәре күп хезмәт салган: Н.Д.Гальскова, И.Н.Балунец, В.Ф.Аитов, Г.Н.Доля, Д.И.Евладова, Е.П. Карпиченкова, Н.Д. Куметова, И.В.Лабутова, Е.В.Любавина, Кэролин Грэхем, Альмурзаева П.Х., Д.Бирн Дж.Уэлман һ.б. Аларның фәнни эшләрен анализлау нигезендә һәм практик укытучы тәҗрибәсенә таянып, жырлар аша дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда тел өйрәнү өчен берничә киңәш тәкъдим итәргә була:

1. Җырлар белән эшләүне берүк сүзләр һәм сүзтезмәләр кабатланган әкрен җырлардан башлап җибәрергә кирәк.

2. Текста булган сүзләрне башта телдән кабатларга, аларның сурәтләрен күрсәтергә (электрон дәреслектә шулай ук тыңлар өчен жыр, караоке, бу сүзләрне истә калдыру өчен сурәтләр, уен төрләре бирелгән).

3. Жырның сүзләрен принтер аша чыгарып укучыларга тарату бик мөһим. Чөнки Интерактив тактаны куллануның вакыты чикле, еш кына Интернет белән элемтәләр өзелү очраклары дәрестә көтелмәгән паузалар барлыкка китерергә мөмкин һәм укучыларда дәрескә карата кире эмоцияләр тууына китерергә мөмкин. Уку елы башында ук класс житәкчеләре, укучыларның әти-әниләре белән бу эшләрне басарга күпме кәгазь кирәклеген, принтерларга буяулар өчен булган чыгымнарның күләмен аңлатып, дәрестә кулланасы технологиянең мөһимлеген дәлилләп, материал чыгымнарны каплау турында киңәшеп, протоколга теркәү зарур, яисә спонсорлар табу бурычы кала. Сыйфатлы укытуның нәтижәсе күп очракта укытучының осталыгы белән беррәттән материал чыгымнарга да бәйле булып кала.

«Музыка терапиясенең уңай нәтиҗәләренә берничә фактор ярдәм итә дип раслана:

1. Игътибарны модуляцияләү. Музыка безнең игътибарыбызны җәлеп итә һәм тискәре эмоцияләр (мәсәлән, борчылу, авырту хисләре) тудырырга сәләтле башка ярсыткычлардан читкә юнәлтә.

2. Хисләрне модуляцияләү. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, музыка баш миенең инициацияләүдә, генерацияләүдә, ярдәм итүдә, туктатуда һәм хис-кичерешләрне модуляцияләүдә катнаша торган өлкәләренең активлыгын җайга сала ала.

3. Танып белү модуляциясе. Музыка хәтер процесслары белән бәйле (музыкаль мәгълүматны һәм музыкаль тәҗрибәгә бәйле вакыйгаларны кодлау, саклау һәм декодлау).

4. Үз-үзеңне тотыш модуляциясе. Музыка терапиясе шулай ук үз-үзеңне тотышны үзгәртү аша эшли. Музыка йөрү, сөйләм һәм эләктереп алу белән бәйле хәрәкәтчән тотышны барлыкка китерә.

5. Аралашуны модуляцияләү. Музыка шулай ук аралашуга йогынты ясый, дөресрәге, ул аралашу чарасы да булып тора. Ул музыкаль импровизация вакытында вербаль булмаган тел булып хезмәт итә» [3].

«Монан тыш, галимнәр музыка тыңлау рәхәтлек хисе өчен җавап бирә торган дофамин гормонын эшләп чыгаруга ярдәм итүен ачыклаган.

Баш миенең музыка үзәге сул ижади ярымшарда урнашкан һәм шуңа күрә уң ярымшардагы сөйләм үзәгенә караганда тизрәк истә калдыра. Шулай итеп, ике ярымшарның эшен берләштереп, жырлар шигырьгә караганда яхшырак истә кала. Тагын бер факт: Альцгеймер, Паркинсон белән авыручылар, геморрагик инсульт кичерүчеләр тикшерү барышында үзләренең исемен хәтерли алмасалар да, күп еллар элек тыңлаган жырларын тулаем искә төшерә алганнар. Бу искиткеч истә калдыру көче.

Истә калдыруның төп компоненты – ритм. Ритм чынбарлык тойгысын югалтканнарның да игътибарын беразга тупларга ярдәм итә.

Кабатлау нәтижәле истә калдыру өчен таләп ителә, ә музыка күп тапкырлар кабатларга ярдәм итә» [5].

Тырышып эшләүнең мотивы булып нәрсә тора соң? Ахыргы максатны аңлау, көтелгән нәтижәләргә ирешү. Шуңа күрә аудиоматериалны тыңлау алдыннан бу эштән нинди нәтижәләр көтүне ачыклау: яңа сүзләрне өйрәнү; сөйләмне ишетеп кабул итәргә өйрәнү; сүзәйтелешен камлләштерү; жирле халыкның көн-күреше, мәдәнияте үзенчәлекләре белән танышу.

Башлангыч сыйныфта балалар җырларны яраталар. Аларны күңел ачуларда яки дәресләрдә җырлап кына калмыйча, эчтәлеген дә уйныйлар. Бу балаларга үзләрен иркен тотарга, хис-кичерешләрен һәм артистлык сәләтләрен үстерергә ярдәм итә. Кече яшьтәге балалар дәрестә күңел биреп эшләгән эшләрне, әлбәттә, башка вакытларда да, караокега кушылып, үзаллы кабатлыйлар.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, башлангыч сыйныф укучыларын татар теленә өйрәткәндә жыр – жирле халыкның көн-күрешен, мәдәниятен чагылдырган сөйләмнең өлгесе, укучының рух һәм акылын бербөтен итеп берләштерүче чара.

Рустелле балаларга телгә өйрәтүнең төп максатларның берсе коммуникатив компетенция формалаштыру булганга күрә, музыка терапиясе элементлары (җырлар, биюләр, музыкаль уеннар) бу максатка ирешүдә гаять зур ярдәм булып тора. Балаларның әхлакый, эстетик, интеллектуаль һәм физик үсешенә йогынты ясап, музыка башлангыч классларда телне үзаллы өйрәнүгә зур мотив булып тора.

## Кулланылган әдәбият


1. Гальскова Н.Д. Современная методика обучения иностранным языкам: пособие для учителя / Н.Д. Гальскова, Е.Г. Тарева. – М.: АРКТИ, 2000. – 165 с.

2. Нильсон О.А. Теория и практика самостоятельной работы учащихся / О.А. Нильсон. – Таллин, 1976. – 165 с.

3. Первакова Е.О. Музыка как метод психотерапевтического воздействия // Актуальные исследования. – 2022. – № 47. – С. 126.

4. selam.tatar

5. https://www.teacherjournal.ru/categories/13/articles/5201


© Белянина Р.А., Сагидуллина Л.Р., 2024

УДК 821.512.145

**Белянина Р.А., Сагидуллина Л.Р.,**
*Уфа ш., Россия*

# ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮДӘ ИЛЬЯ ФРАНКНЫҢ УКУ МЕТОДЫ

***Аннотация:*** *мәкаләдә рус телле балаларны татар теленә өйрәтүдә Илья Франкны уку методының әһәмиятле яклары ачыклана.*

***Тәрәк сүзләр:*** *чит тел буларак татар теленә өйрәтү, Илья Франкның уку методы, татар теленә җайлаштырылган китаплар.*

Федераль белем бирү программаларына ярашлы рәвештә, 2024-2025 уку елы башында күп кенә мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты дәресләренә бүленгән вакыт 0,5 шәр сәгать кенә калды. Хәер, үткән уку елларында да артык күп булмады, берешәр генә иде. Ә кайбер мәктәпләрдә татар телен бөтенләй өйрәнмәгәннәрен искә алсак, туган телне саклап калуның башка юлларын эзләргә кирәклеге аңлашыла, чөнки Андрей Вороновның трилогиясе буенча төшерелгән нәфис фильмнан алынган: «Янәшәдә кече халык һәлак булганда зур халыкның бәясе бер тиен» [3], – дигән сүзләрдә хаклык бар. Чыннан да, халык үзенең теле өчен көрәшми, хөрмәт итми, аның үзаңы юк икән, башка халык өчен дә файдасы артык зур түгел.

Бүгенге көндә хөкүмәт тарафыннан яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү максаты тора. Гади сүзләр белән әйтсәк, патриотик рух – үз Ватанына, теленә, гореф-гадәтләренә һәм мәдәниятенә мәхәббәт ул. Үз илебезне ярату һәм яхшы традицияләрне хөрмәт итү – безнең һәрберебезнең бурычы. Татар халкы үзенең традицияләренә тугры калырга омтыла. Беренче сыйныфта үз телендә бер сүз дә аңламаган

егермеләгән балаланың туган телен өйрәнергә теләп парта артына килеп утыруы да шул омтылышның чагылышы.

Бу омтылыш укытучыга бар көчен салып укучыда телгә кызыксындыру уяту, аларны үзаллы белем алырга өйрәтү бурычын куя. Кызганычка каршы, туган телгә чит телгә өйрәтү методикасыннан башка мөмкин түгел. Ярый әле Интернет мәйданының киң булуы телне үзаллы өйрәнүгә, телне өйрәтүдә яңа технологияләр үзләштерергә зур мөмкинлекләр ача.

Эзләнүләр барышында Илья Франкның уку методы игътибарны җәлеп итте. Аның бер мәкаләсеннән өзек кенә дә тел өйрәнүчеләрдә оптимистик хисләр уята: «Сез русча сөйләшәсезме? Димәк, тел өчен җавап бирә торган баш мие үзәкләре белән сездә барысы да тәртиптә. Яшь шулай ук роль уйнамый. Әйткәнебезчә, эш хәтердә, материалны истә калдыруда түгел, ә телгә ияләшүдә. Күпчелек кеше телне олы яшьтә өйрәнә. Һәм монда бернинди яшь чикләүләре юк. Иң мөһиме – суга сикерүдән курыкмау» [4]. Автор йөзәргә өйрәнү кагыйдәләрен генә белеп, суга кермичә йөзәргә өйрәнеп булмаган кебек, телне дә, грамматикасын гына өйрәнеп, үзләштерү мөмкин түгеллеген әйтергә тели.

«Илья Франк методы – чит телне өйрәнү ысулы, ул текстның оригиналын укудан һәм тәрҗемә итүдән гыйбарәт. Бу методны кулланып басылган китапларда текст зур булмаган өзекләргә бүленгән. Башта җайлаштырылган өзек килә. Анда һәр синтагманың җәяләр эчендә тәржемәсе һәм зур булмаган лексик-грамматик шәрехләр белән текст бара. Аннан соң текстның оригиналы бирелә» [4].

Үзенең шәхси уку методының инициаторы Илья Франк телне бары жанлы аралашу мохитендә, яисә шул телдә укуга бирелгән очракта гына өйрәнеп булуын, шуңа күрә уку һәм тыңлау өчен тәкъдим ителгән текстлар иң элек үзеннән үзе кызыклы булырга тиешлеген ассызыклый.

Россия филологы, полиглот, тәрҗемәче, чит телләрне өйрәнү, культурология буенча гомуми тиражы 1 млн. данәдән артык булган китаплар сериясе һәм мәкаләләр авторы, «Илья Франкның уку методы» һәм «Скайп буенча өйрәнегез. Илья Франкның чит телләр мәктәбе» дигән сайтларга ия булган Илья Михайлович Франкның методы дөнья күләмендә киң танылу яулаган.

Интернет битләрендә бу метод буенча Лилия Вәлиуллинаның, Рөстәм Шайдуллинның яраклаштырылган татар китаплары табылды: Г.Кутуй «Неотосланные письма», Г.Кутуй «Татарский с любовью», «Поэтические сказки Г.Тукая», «Татарский язык с Тукаем». Бу китаплар татар телен үзаллы өйрәнүчеләр, татар мәдәнияте белән кызыксынучылар өчен тәгаенләнгән. Мәсәлән, Г.Тукайның «Шүрәле» әкиятеннән өзек: *«Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – «Кырлай» диләр, /*

*Җырлаганда көй өчен, «тавыклары җырлай», диләр»* [2; 1]. И. Франк методы нигезендә адаптацияләнгән вариантта ул шулай тәкъдим ителә: «Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл *(прямо за Казанью есть одна деревня; арт – зад, задняя часть)* – «Кырлай» диләр *(Кырлай / её / называют); Җырлаганда көй өчен (когда поют, для рифмы; җырлау – петь; көй – мелодия, порядок),* «тавыклары җырлай», диләр *(«/ её / курицы поют, / так / говорят; тавык – курица)»* [2; 1].

Методның асылы шунда ки, укучы махсус җайлаштырылган китапны укый һәм әкренләп телнең логикасын, аның төзелешен аңлый, сүзләрнең төрле формаларын истә калдыра.

«http://franklang.ru сайтында Илья Франк методына яраклаштырылган төрле телдә китаплар бар. Сайтка 64 телдә 466 китап куелган. Илья Франк методы нинди дә булса чит телне үзләштерүчеләргә, тел системасына тиз ияләшеп һәм лексик запас туплап (мәсәлән, көненә 2 сәгать укыганда – аена ким дигәндә 1000 сүз үзләштерелә), сүзлексез китап укырга мөмкинлек бирә. Мондый ысул белән көндәлек укыганда ел дәвамында иркен укырга өйрәнергә мөмкин. Сүзләрне һәм сөйләм әйләнешләрен истә калдыру бу вакытта ятлау хисабына түгел, ә текстагы сүзләрнең даими кабатлануы хисабына бара. Сез бары тик китап укыйсыз һәм шул ук вакытта телне өйрәнәсез» [4].

Илья Франкның уку методы буенча телне өйрәнү билгеле бер әзерлек таләп итә: татар теленең авазларын дөрес әйтергә өйрәнү, морфемаларның мәгънәләрен аңлау – төп бурыч. Бу уңайдан методка үзгәрешләр кертү үзен аклар иде. Мәсәлән, татар телендәге текстларда сүзләрнең кайбер морфемалары билгеләнсә яхшы булыр иде, чөнки полиглотлар арасында төркителле текстларны аңлау читенлеген белдерүчеләр дә бар. Монда төрле вариатив график алымнар, төсләр тәкъдим итәргә мөмкин, әлбәттә: *«Нәкъ Казан артынДА барДЫР бер авыл – «Кырлай» диЛӘР, / Җырла<u>ГАНД</u>А көй өчен, «тавыкЛАР<u>Ы</u> җырлай», диЛӘР».* Шулай итеп, татар телендә Илья Франкның уку методын кулланып, укуны җиңеләйтү исәбеннән, яңа бер алым да өстәргә була. Практик укытучы буларак бу алымны кулланам, укучылар да бу алымны ошата.

Илья Франкның уку методын күзәтеп, мәктәп программаларындагы татар теленә бүленгән сәгатьләрнең аз булуын искә алып, шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: Илья Франк методы нигезендә төзелгән дидактик материаллар (текстлар) вакытка экономия ягыннан уңышлы; тиз вакыт эчендә икенче телдәге текстның эчтәлеге белән танышырга мөмкинлек бирә; грамматик формаларны теориядән тыш, текст аша практик юл белән үзләштерүне киңәйтә һ.б. Бу метод нигезендә

эшләнгән әдәби текстлар татар телен икенче тел буларак укытуда нәтиҗәле чара булыр иде дип уйлыйбыз.

**Кулланылган әдәбият**

1. Биктагирова Р.Ф.В каждой книге живет волшебство (Метод чтения Ильи Франка, как альтернативный способ обучения чтению) / KAZANOBR.RU. – 2018. – № 22. – http://smi.kazanobr.ru/22/35.html

2.Татарский с Габдуллой Тукаем. Поэтические сказки – Габдулла Тукай. Әкиятләр / пособие подгот. Л. Валиуллина. – Москва: ВКН, 2016. – 77 с.

3. Рай под тенью сабель. – https://vk.com/video35256471_456239113

4. Метод чтения Ильи Франка http://franklang.ru (официальный сайт)

5. Лучшие книги Ильи Михайловича Франка. https://www.livelib.ru/author/229427-ilya-frank (официальный сайт)

6. Илья Франк https://www.native-english.ru/articles/frank?ysclid=m3lqz95lyk655467193

© Белянина Р.А., Сагидуллина Л.Р., 2024

УДК 821.512.145

**Валиефф София,**
*Аделаида ш., Австралия Берлеге*

## АВСТРАЛИЯДӘГЕ ТАТАР МИЛЛИ-МӘДӘНИ ОЕШМАЛАРЫ: КИЧӘ, БҮГЕН ҺӘМ ИРТӘГӘ

***Аннотация:*** *мәкаләдә Австралия Берлегенең полилингваль киңлегендә татар теленең урыны күрсәтелә. Автор Аделаида шәһәренең татар-башкорт җәмгыяте оештырган милли-мәдәни чаралар, Россия Федерациясенең Башкортстан һәм Татарстан республикалары белән мәдәни һәм мәгариф багланышлары, милли оешмалар турында сөйли.*

***Терәк сүзләр:*** *татар-башкорт җәмгыяте, татар этник мәктәбе, мәгариф, мәдәният, Татарстан, Башкортстан, китап, сабантуй, халык бәйрәме.*

1991 елда Аделаида каласында «Татар-башкорт җәмгыяте» төзелеп, Австралия хөкүмәте аңа рәсми таныклык сертификаты бирде.

Татар-башкорт җәмгыяте рәисе Зыя Маски 15 еллык тырыш хезмәт дәверендә яшьләрне тәрбияләп, җәмгыять эшләрен алып барырга өйрәтте, шул рәвешле, үзенә алмаш әзерләде. Оешма эшен яшьләр алып барса да,

өлкәннәребез, комитет әгъзалары, аларга һәрчак акыл биреп, юл күрсәтеп, җәмгыятебезнең тәрәкыяте өчен күп көч куйдылар.

Без оештырган якшәмбе мәктәбе Аделаида каласындагы этник уку йортлары төркемендә «Татар этник мәктәбе» исеме астында теркәлү үтте. Хөкүмәтнең тиешле ярдәмен алу белән бергә, ул төрле рәсми чараларда катнашып, милләтебезнең данын бөтен Австралиягә таратты. Беренче чыгарылыш укучылары үсеп җитеп, инде аларның балалары мәктәбебездә укый башлады.

Татар мәктәбенең мөдире Мөшәррәф Вәлиева – 25 ел, укытучы Гайшә Маски 19 ел бушлай укытып, үзләренең кыйммәтле вакытларын татар мәктәбенә сарыф иттеләр. Мәктәп төзелгәннән соң узган 34 ел эчендә әнием, туганнарым Сөенгөл Чанышева, Сания, Диләрә, Гөлфия, Гүзәл Вәлиевалар балаларны бушлай укытып, милли мәгарифкә үз өлешләрен керттеләр.

Татар-башкорт җәмгыяте Австралия татарлары өчен күпсанлы изге гамәлләр кылып, илебездә һәм бар дөньяда танылу яулады. Милли мирасны алдагы буыннарга тапшыру өчен, тагын да дәртләнебрәк хезмәт итә башладык. Өлкән яшьтәге милләттәшләребезгә ярдәм күрсәтү эшен дә оештырып җибәрдек.

* * *

Татар-башкорт җәмгыяте 1997 елда Австралия кыйтгасында тәүге тапкыр татар халкының иң зур милли бәйрәме Сабан туен уздырды. Ул Аделаида каласының ботаник бакчасында үтте. Түргә сәхнә ясалган иде. Аның янына корылган ак чатырлар тирәсендә милли киемнәр кигән балалар һәм яшьләр, ефәк шәл, ак яулык бәйләгән әбиләр, түбәтәйле бабайлар җыелган. Чатыр эчендә ак ашъяулык ябылган өстәлләр куелып, алар тәмле татар ашлары – чәк-чәк, өчпочмак, пәрәмәч, кош теле, ит бәлеше, калачлар белән тулган иде. Күңелләрне күтәреп, татар җырлары яңгырый. Кыскасы, үзебезне Татарстандагы кебек сизә идек.

Сабан туена Татарстаннан хөрмәтле кунак Фәрит Ишмәков та килеп җитте. Бәйрәмебездә аның да катнашуы монда яшәүче татарларның рухын, Австралия хөкүмәте алдындагы абруен, хөрмәтен күтәреп җибәрде.

Фәрит Ишмәков Татарстан хөкүмәтенең котлау хатын укып, күңелләребезгә дәрт өстәде. Яшьләр һәм балалар әзерләгән концерт номерлары яңгырап, төрле милли уеннар уйналып, Сабан туе мәйданы шатлыкка тулды.

Милли ризыкларыбыз булган пылау, мантыйдан авыз иткән яшьләр Сабан туе мәйданын кыздырып җибәрде. Ат ярышы белән көрәштән башка барлык уеннарда да катнашкан егет-кызларның һәркайсы үзләренә тиешле бүләкләрен алып куандылар.

Сабан туена килүчеләр, таралышырга теләмичә, гармун уйнап, биеп-җырлап, караңгы төшкәнгә кадәр бакчада бәйрәмне дәвам итте.

Хөкүмәт вәкилләре дә бик шатланып, мондый матур чараны күптән күргән юк иде, дип, киләсе елда янә чакыруыбызга өмет итеп, сөенеп кайтып киттеләр. Бу – без оештырган тәүге Сабан туе булды.

Сабан туен җәмгыять җитәкчелеге һәм әгъзаларының, әнинең һәм кардәшләремнең тырышлыгы белән, бик матур, күңелле, истә калырлык итеп уздырдык.

Бәйрәмебез татарларның гына түгел, монда яшәүче барча төрки милләт вәкилләренең, яратып катнаша торган шатлыклы бер фәгалиятенә әверелде. Шуннан бирле Сабан туен һәр елны уздырып киләбез.

Татарстан, Башкортстан, Кытай, Америка һәм Төркиядән, Австралиянең Сидней, Брисбун, Мельбурн калаларыннан кунаклар чакырып, Австралия хөкүмәте вәкилләренең катнашлыгы белән зур итеп оештырылган Сабан туйлары 1999, 2004, 2006, 2009, 2011–2014 елларда үтте.

Татар-башкорт балаларының милли биюләре, кунакларның җырлап-биеп, спорт уеннарын уйнап күңел ачулары, тәмле татар ашлары белән Сабан туена килүчеләрне сыйлап җибәрү безнең өчен күркәм гадәткә әверелде.

Татарстан хөкүмәте Сабан туебызга Башкортстанның һәм Татарстанның халык артисты Фән Вәлиәхмәтов белән танылган җырчы, композитор Фәнир Галимовны, күренекле сәнгать әһелләре Венера Ганиева, Хәмдүнә Тимергалиеваларны, яшь җырчылар Алсу Әбелханова, Айгөл Бариева, Лилия Муллагалиеваларны, Татарстанның Чулпан Закирова җитәкчелегендәге «Казан» бию ансамблен, «Казан егетләре» төркемен җибәрде. Алар бәйрәмгә дәрт, күңеллелек өстәделәр.

Сабан туйларыбызга килеп, Австралиядәге милләттәшләрне сөендергән артистларыбыз өчен, Татарстан хөкүмәтенә чиксез рәхмәтләребезне белдерәбез.

* * *

Җәмгыятебез кечкенә булса да, күзгә күренерлек эшләр башкарды.

1995 елда Татарстанның Премьер-министры Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге Татарстан делегациясен Аделаида каласында каршы алдык. 1997 елда Россиянең Австралиядәге илчесе Рәшит Хәмидуллин һәм аның хатыны Мәһирә ханымны каршылап, очрашу оештырдык.

1998 елның 1 августында Аделаида каласында урнашкан Көньяк Австралия иммигрантлары музеенда, ватаннарыннан аерылып, дөньяның төрле почмакларына сибелгән татар-башкортлар рухына багышланган истәлек ташы куелды. Тантанада хөкүмәт әһелләре дә, төрле төрки

милләт вәкилләре дә катнашты. Мәҗлесне иммигрантлар музее рәисе В. Закарис ачты. Залда татар-башкорт этник мәктәбе укучылары Татарстан, Башкортстан һәм Австралия байракларын күтәреп басып тордылар.

Иркеннән, Ватаныннан аерылып, Себергә сөргенгә җибәрелгән, башка чит җирләрдә вафат булган татар-башкортларның рухына багышлап, дога кылдык. Көньяк Австралия премьер-министры Лон Олсынның рәсми вәкиле булып килгән парламент әгъзасы Джон Довкинска хатирә ташын тантаналы ачу хокукы бирелде.

Бездән кайткач, Джон Довкинс әфәнде җәмгыятебез уздырган чаралар турында парламентта озак чыгыш торткан. Бу исә татарларның Австралия хөкүмәте белән үзара хезмәттәшлеген тагын да ныграк көчәйтеп җибәрде.

1997 елда әнием, Гайшә Маски, Зыя Маски, Сөенгөл Чанышевалар белән берлектә, унбер кешедән торган яшьләр төркемен Татарстанга алып барып кайтты.

2003 елда хөрмәтле Минтимер Шәймиев әфәнде әнием белән яшьләр төркемен үзендә кабул итеп, егет-кызларыбызның туган телне, динне, гореф-гадәтләрне саклап калуларына сокланып, моның өчен зур рәхмәтләрен җиткерде. Алар шулай ук Кукмара районының Арпаяз һәм Апас районының Урта Балтай авылларына барып, корбан чалып, сәдака таратып, кардәшләренең каберләрен ядь итеп, авыл һәм район җитәкчеләре белән бәйләнешләрен ныгытып кайттылар.

1997 елда Роза Туфитуллова Гайшә Маскины «Ак калфак» җәмгыятенең Австралиядәге вәкиле итеп билгеләп, «Сөембикә» журналының 70 еллыгына багышлап махсус бәйләнгән зәңгәр шәл бүләк итте.

Шушы ук чорда, Татарстаннан җиде диңгезче, дөньяны 615 көн эчендә әйләнеп чыгу максаты белән, «Норд Стар» көймәсендә юл алган иде. 1998 елда Казан шәһәре башлыгы Камил Исхаков әфәнде бездән аларны Австралиянең Аделаида каласында каршы алып, ярдәм итүебезне сорады. Җәмгыять әгъзалары сәяхәтчеләрне шат күңел белән каршылап, тугыз көн кунак итеп озатып куйды.

1998 елда Татар-башкорт җәмгыятенең рәисе Зыя Маски Башкортстан хөкүмәтенең мәдәният һәм сәүдә бәйләнешләрен ныгыту өчен Австралиягә җибәрелгән рәсми вәкиллеген кабул итте.

1999 елның 26 декабрендә, татарларның Австралиягә аяк басуына 50 ел тулу уңаеннан, Татар-башкорт җәмгыяте Көньяк Австралия иммигрантлар музеенда милләтләребезнең тарихы, мәдәнияте, сәнгате белән таныштырган бай күргәзмә ачты. Музейга татар халкының осталыгын гәүдәләндереп, энҗе белән чигелгән байрак бүләк ителде. Ул байрак әлегә кадәр шунда саклана.

2000 елның 15 мартында Татарстанның «Дүрт кешелек скрипка» ансамбле музыкантлары Марат Зарипов, Камил Монасыйпов, Шамил Монасыйпов һәм Альберт Әсәдуллин әфәнделәрне кунакка чакырдык. Алар иммигрантлар музеенда ачылган күргәзмәбездә чыгыш ясады.

Шул ук елның октябрендә Казан шәһәре башлыгы Камил Исхаков Австралиянең Каернис каласында ачылган 24нче «Дөньякүләм мәдәни мирас» фестиваленә килде. Монда Казан Кремле дөньякүләм әһәмияткә ия мәдәни һәйкәлләр исемлегенә теркәлде. Сәфәр барышында Камил әфәнде Аделаидага да килеп, Татар-башкорт җәмгыяте вәкилләре белән берлектә Көньяк Австралия иммигрантлар музеена экскурсия ясады.

2005 елның 25 февралендә Казан шәһәренең 18нче мәктәп директоры урынбасары Миләүшә Гомәрова җитәкчелегендәге биш укучы үзара тәҗрибә уртаклашу һәм мәдәни бәйләнешләр булдыру максаты белән безгә килде. Җәмгыять әгъзалары укучыларны үз гаиләләренә кабул итеп, Австралия буенча сәяхәткә алып барды. Кунак балалар үзләренең яшьтәшләре белән аралашып, тәҗрибә уртаклашты.

2008 елда Зыя һәм Гайшә Маски, Рамил һәм Фирдәвес Садрилар, ун кешелек яшьләр төркемен алып, Казанга икенче мәртәбә барды. Монда алар Минтимер Шәймиев белән янә күрештеләр. Ул татар телен саклаган яшьләребезгә сокланып, тагын бер тапкыр афәрин әйтте.

1992 елдан Татарстан хөкүмәте безгә аерым игътибар бүлеп, вәкилләребезне Бөтендөнья Татар конгрессына, Халыкара универсиадага, Бөтендөнья хатын-кызлар форумына, «Сәләт» лагерена, яшьләрнең спорт ярышларына чакыра башлады. Күп кенә егет-кызларыбызга бу чараларда катнашу бәхете тиде.

Бу вакыйгадан соң яшьләребез Казан уку йортларына еш бара башлады. Бабаларыбызның туган авылларын күреп, туганнар, яңа дуслар табу өчен сәяхәтләргә чыгып, Аделаида-Казан арасын якынайттылар.

Шулай итеп, Идел-Урал яклары белән бәйләнешләр көчәйде. Татар-башкорт җәмгыяте көн саен зураеп, эшчәнлеге дә киңәя барды.

2010 елда татарларның Австралиягә күченә башлавының чираттагы юбилеен билгеләп, Көньяк Австралия хөкүмәте милли делегациябезне парламент сараена кунакка чакырды. Анда яшь укучыларыбыз Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырен татар, инглиз телләрендә яттан сөйләп, милли биюләр башкарып, депутатларның алкышына иреште. Парламент әгъзасы, милли мәдәният министры Макел Аткинсин әфәндегә түбәтәй бүләк иттек.

2013 елның гыйнварында Татарстанның «Сәләт» лагере җитәкчелеге үзара тәҗрибә алмаштыру нияте белән балаларны Аделаидага җибәрде. Без 25 яшүсмерне каршы алып, урнаштырып, төрле чаралар уздырып, яшьләргә үзара аралашу мөмкинлеге тудырдык. Унбиш

көн бергә вакыт уздырган яшьләр кочаклашып, күз яшьләре белән аерылыштылар.

Җәмгыятебез кечкенә булса да, әгъзаларыбыз арасында сәләтле кешеләр күп иде. Яшьләребез арасында биюче, җырчы, музыкантларыбыз да шактый булып, Сабан туйларында, төрле чараларда үзебезнең иҗади көчләребезне күрсәттек. Җәмгыятебездә «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмасы бүлекчәсе һәм җырчылар төркеме, «Шатлык» бию ансамбле эшләп килә, аларның чыгышлары тамашачыларның алкышларына күмелә.

Вәлиевләр гаиләсеннән чыккан өч язучыбыз бар. Сөенгөл Салих кызы Чанышева язган «Күз яшендә өелгән туфрак» исемле китап инглиз, төрек, уйгыр, татар, рус телләрендә Англиядә, Төркиядә һәм Казахстанда басылып чыкты. Тиздән япон телендә нәшер ителәчәк. «Атмаган таң» исемле икенче китабы төрек һәм уйгыр телләрендә Төркиядә дөнья күрде. Сөенгөл Чанышева – Бөтендөнья язучылар союзы әгъзасы. Ул язучыларның ПЕН-үзәге эшендә даими катнашып, оешманың Төркиядә, Швейцариядә, Монголиядә, Кырымда, Кореядә, Кыргызстанда узган конгрессларына делегат итеп сайланды.

Гайшә Салих кызы Маски язган «Сабантуй» исемле китап инглиз һәм иске гарәп графикасындагы татар телендә басылып, Австралия хөкүмәтеннән югары бәя алды. Җыентык төрле китапханә, мәктәп, балалар бакчаларына таратылды. Аның күпсанлы шигырьләре Татарстанның төрле газит-журналларында дөнья күрде. «Иркенлеккә сәфәр» исемле китабы Татарстан һәм Австралия хөкүмәтенең матди ярдәме белән 2012 елда татар һәм инглиз телләрендә дөнья күреп, җәмәгатьчелек тарафыннан яратып кабул ителде.

Сафия Салих кызы Вәлиеваның «Йөрәк хисләрем» исемле шигырьләр җыентыгы Башкортстанның Туймазы шәһәрендә басылды. Аның күпләгән шигырьләренә көйләр язылган. Безнең тарафтан язылган «Әни» исемле китап Вәлиевлар гаиләсенең чын тарихы булып, реаль вакыйгаларга нигезләнгән [1].

Җәмгыятебездә спортка мөкиббән киткән яшьләр бар. Искәндәр Маски Франциядә чыккан «Петанки» спорт уены белән 2006 елдан бирле шөгыльләнеп, 2008-2012 елларда чемпионлыкка ирешә. Оста футболчы Нәҗип Вәлиев та 2005 елда чемпионлык бүләген ала.

Австралиядә туып үскән бер буын яшьләребез, төрле югары уку йортларында белем алып, хөкүмәт вазыйфаларында эшли.

2011 елның 27 сентябрендә Татарстан җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов әфәнде Австралиянең Аделаида каласында гомер итүче татарлар белән очрашты. Ул «Татар-башкорт җәмгыяте» әгъзалары Зыя Маски, Шөһрәт Вәлиев, Мөшәррәф Вәлиеваны, милләтебез файдасына

кылган хезмәтләре өчен, Рәхмәт хаты белән бүләкләде. 2011 елның 11 декабрендә Гайшә Маски, Рамил Садри, Сания һәм Диләрә Вәлиевалар милли мәдәниятне саклауда зур көч куйганнары өчен, Татарстан Мәдәният министрлыгының Мактау хатына лаек булды. 2000 елда Сафия Вәлиеваның хезмәтен югары бәяләп, Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты аны ихтирамнамә тапшырды.

Җәмгыятебез Мәүлет, Корбан, Рамазан бәйрәмнәрен үткәрү белән бергә, дини кыйммәтләребезне киләчәк буыннарга тапшыру өчен дә хезмәт итә. Гает көннәрендә бергәләп мәчеттә намаз уку, аннары зиратка барып, әти-әни, туганнарның каберләрен тәрбияләп, Коръән укып кайту, барча кардәшләрне бәйрәм белән котлап, аларның хәлен белешү – безгә бабалардан калган изге әманәт. Гает көнне әти-әнигә, олыларга һәм балаларга бүләкләр биреп, айлар буена чәй мәҗлесләре үткәрәбез.

Рамазан аенда олысы-кечесе ураза тотып, һәр көнне төрле гаиләләрдә ифтар ашлары уздырабыз. Мәүлет кичәләрен төрле мөнәҗәт һәм салаватлар әйтеп, күп кеше катнашлыгында күңелле итеп үткәрү гадәткә кергән.

Милли бәйрәмнәр дә югары дәрәҗәдә үтә. Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышланган шигърият кичәләрендә җәмгыять әгъзалары, балалар, яшьләр теләп катнашып, төрле уеннар, комедияләр куялар, Тукай шигырьләрен һәм үз иҗатларын яттан укып, әдибебезне искә алалар. Нәүрүз бәйрәмнәре дә күңелле уза.

Зур гаиләбездә гомер бәйрәме булып исәпләнгән туган көннәр һәр атна саен үтеп тора. Бәйрәмдә Аллаһы тарафыннан бирелгән гомергә шөкер кылып, барыбызга да саулык-сәламәтлек, тигезлек-тынычлык, эшләребездә уңышлар теләп, матур теләкләр һәм хәер-догалар белән рәхәтләнеп күңел ачабыз.

Австралиядә борынгы татар йолалары буенча милли туйлар үткәрү дә гадәткә керде. Аларда исерткеч бөтенләй кулланылмый.

Соңгы елларда җәмгыятебез Татарстан һәм Башкортстан белән якын элемтәдә тора. 2013 елда Башкортстанның Туймазы районы Төмәнәк авылында Фәнир Галимов әфәнде авылның 320 еллык юбилеен үткәрде. Шәҗәрә бәйрәменә чакыру алып, мин дә катнаштым. Татар телен, Ислам кыйммәтләрен, гореф-гадәтләрне саклаган Төмәнәк халкының изге эшләрен, тирән тарихын өйрәнеп кайтып, аны якташларыма үрнәк итеп сөйләдем. Бәйрәмдә төшерелгән видеоязмаларны, фоторәсемнәрне күрү читтә яшәүче татарларга да зур илһам бирде. Аларның тырышлыгы, кунакчыллыгы, татар мәктәпләрен саклап калып, балаларда милли рух тәрбияләүгә салган хезмәтләре безне сокландырды.

Фәнир Галимов җитәкчелегендә беренче мәртәбә оештырылган «Сәләт-Кандракүл» лагеренда да булып, аннан бик тәэсирләнеп кайттым. «Сәләт»нең бүлекчәсен Австралиядә дә төзеп, яшьләрнең үзара тәҗрибә алмашу мөмкинлеге барлыгын аңладым.

Балаларыбызга, яшьләребезгә ата-бабалардан калган, әти-әнидән алган тәртип-тәрбия кануннарын, гореф-гадәтләрне җиткерү өчен, бөтен көчебезне салдык. Инде яшь буыннарның да башлаган эшебезне шундый ук активлык белән дәвам итүенә өмет тотабыз.

**Әдәбият исемлеге**

1. Вәлиефф С. (Вәлиева С.). Әнием: документаль повесть. – Казан: «Мәгариф–Вакыт», 2015. – 239 б.

© Валиефф С., 2024

УДК 821.512.145

**Гайнуллина Г.У.,**
*Уфа ш., Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КЕШЕНЕҢ ЭЧКЕ ДӨНЬЯСЫН ХАРАКТЕРЛАУЧЫ ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕ СЕМАНТИК ЯКТАН ТӨРКЕМЛӘҮ

***Аннотация:*** *мәкалә татар телендә кешенең эчке дөньясын тасвирлаучы фразеологизмнарны өйрәнүгә багышланган, әлеге берәмлекләрнең семантик классификациясе бирелгән, шулай ук дөнья тел картинасында фразеологизмнарның роле карала.*

***Терәк сүзләр:*** *фразеологизм, кешенең эчке дөньясы, дөнья тел картинасы.*

Татар теленең фразеология фонды – татар мәдәниятенең, тарихының аерым байлыгы. Телнең мәдәни-милли үзенчәлеге фразеологияләрдә бигрәк тә ачык күренә. Фразеологик берәмлекләр мәдәниятне, традицияләрне, көнкүрешне, милли аңны, образлы фикерләүне ачык чагылдыра.

Без диплом эшебездә кеше сыйфатларын чагылдыручы фразеологик берәмлекләрне тикшерүне максат итеп алдык. Фразеологик сүзлекләргә күзәтү ясау шуны күрсәтә: фразеологик берәмлекләр кешенең уңай һәм кире сыйфатын белдерер өчен кулланыла. Әмма кешенең уңай сыйфатын күрсәтүче фразеологик берәмлекләр кешенең кире сыйфатын белдерүче берәмлекләргә караганда азрак икәнлеге билгеле булды.

Кешене кире характерлаучы фразеологияләр акылсызлыкны, явызлыкны, әрсезлекне, әдәпсезлекне, саранлыкны, ялкаулыкны, мактануны, ялагайлыкны, тәрбиясезлекне, ярсулыкны һ.б. шундый кире сыйфатларны белдерәләр. Ә шәхеснең уңай сыйфатларын белдерүче фразеологик әйтелмәләр уңганлыкны, җитезлекне, юмартлыкны, йомшак, татлы теллелекне, турылыкны, тугрылыкны, изгелекне, әдәплелекне, ярдәмчелекне белдереп киләләр.

Фразеологияне өйрәнү практикасыда семантик кырны аерып чыгу методы турында сүз алып барганда, шуны әйтергә кирәк: төрле авторлар бу эшкә төрле ысуллар белән киләләр. Әйтик, Ю.А. Гвоздарев, семантик анализда өч төрле дәрәҗә күрсәтә. Шуларның беренчесе – тупланган бөтен материалны анализлау һәм уртак класслар буенча аларны бүлү. Автор шундый классларны бишкә бүлә: предметлык, сыйфатлык, процесслык, хәл, чагыштырмалылык. Икенче этапта һәрбер класс чигендә семантик группалар барлыкка килә [3; 12-20].

Шулай ук А.М. Эмирова фразеологизмнарны семантик кыр буенча бүлүдә үз методын тәкъдим итә. Аныңча, беренче этапта фразеологик берәмлек составыннан экстралингвистик характерда булган уртак бер семантик сыйфат алына, ә соңыннан инде үзенең семантикасында уртак компоненты булган фразеологик әйтелмәләр бер кырга берләшәләр [5; 55].

Татар телендә кешенең эчке сыйфатларын характерлаучы бик күп фразеологик берәмлекләрне тикшереп, анализлап үткәннән соң, без аларга классификация эшләдек. Семантик кыр төзү берничә этаптан торды. Беренче этапта тел аспекты зур урын алып торды. Монда киң планда бер үк мәгънә белдерүче фразеологик берәмлекләр буенча фразеосемантик кыр төзедек. Аларны икенче төрле макрокыр дип атарга мөмкин. Шуннан соң шушы макрокырлар эчендә семантик кырлар саналып үтелде.

Фразеологик берәмлекләр дүрт класс буенча төркемләнделәр һәм шулар арасында иң күбе булып кешенең интеллект эшмәкәрлеген билгеләүче класс саналды. Аңардан тыш тагы берничә класс төзелде: бу кешенең әхлак-этик сыйфатлары, шәхеснең аффект-психик һәм ихтыяр сыйфатлары. Һәрбер класс үз эченә билгеле бер санда группа ала. Ул группалар, үз чиратында, теге яки бу классны җентекләп характерлыйлар. Димәк, безнең тарафтан дүрт макрокыр составына кергән семантик кырлар төзелде. Менә алар:

**1. Кешенең интеллектуаль эшчәнлеген атаучы фразеологик берәмлекләр:**

– акыллы: *Акылга беткән. Акыл иясе. Акыл капчыгы. Акыллы баш. (Аның) күле тирән. Башлы кеше. Бизмәне авыр тарта. Бөтен кеше.*

*Гыйлем иясе. Иллә дә баш үзендә. Фикер иясе. Авызыңнан чыкканчы эләктереп ала. Күктән йолдыз каптыру*;

– надан, аңгыра, тиле: *Агач башмак. Агач арасыннан урман күрмәгән. Адәм имгәге. Акылга бертөрле. Акылга зәгыйфь. Акылга таман. Акылдан буш (коры) калган. Акыл чәчләре башын ташлаган. Акылына хыләл килгән. Акылын кәҗә ашаган. Акыл (үзенә) кереп тә чыкмаган. Алла сарыгы. Аягына алып селексәң бер хәреф (әлиф) төшмәс. Акылга туймый калган. Акылга тулы түгел. Башсыз кеше. Башына чүбек (кибәк) тутырган. Бер тактасы ким (җитми). Бер әлиф тә танымый. Берәү тулмый. Бизмәне тартмый (тулмый). Борын төбеннән ары күрми. Ботыннан тотып селексәң авызыннан бер әлиф төшмәс (өч хәреф төшмәс). Буш баш. Бүкән баш. Бүрек калыбы. Бүрекле карга. Дебет колак. Гөмбә белән шалканны да аера алмый. Гөмбә – шалкан, ком – талкан. Ике аяклы ишәк. Исәр баш. Ишәк колагы. Кабак баш. Кайнар баш. Кара карга. Карга мие эчкән. Кибәк баш. Кибәктән арпаны аера белми. Миңгерәү сарык. Мыскалы тулмый. Озын буй, буш кафа. Савыты тулмаган. Саламга гына ускән. Сукыр бәрәңге. Сукыр тавык. Тавык баш. Тавык мие эчкән. Тишек борын. Туң баш. Туң боз. Уймакка салырлык та (акылы юк). Унга тугыз тулмаган. Уңны-сулны аермый. Чи надан. Чыпчык баш. Чәберчек йомыркасы чүмергән. Чәүкә мие эчкән нәрсә. Чүпрәк баш. Шыр надан. Эчен ярсаң бер әлеф чыкмас. Юка баш, сыек ми. Әйтсәң белмәс, дәшсәң килмәс. Әлифне (әлепне) таяк дип (тә) белми. Сукыр чикләвек. Чикмән калыбы. Шалтыравык кеше. Кайнар баш. Чапмаган да,юнмаган да. Йөзгә бер тулмаган. Ярты баш.*

Иң күп санны кешенең акыл сыйфатларыннан мәхрүм булганны күрсәтүче фразеологик берәмлекләр тәшкил итте. Интеллектуаль үзенчәлекләр пар төзиләр. Бу фразеологик системада фразеологик берәмлекләрнең турыдан-туры каршы характер сыйфатларын атыйлар дигәнне аңлата.

**2. Шәхеснең ихтыяр сыйфатларын атаучы фразеологик берәмлекләр.** Фразеологик әйтелмәләр тупланган материалны тикшерүне анализлаганда, В. Калинин тарафыннан башкарылган ихтыяр-ынтылыш сыйфатларының классификациясенә таянып, без макрокыр составында шундый семантик кырлар билгеләдек:

– үзен кулда тота белә: *Астан уртын чәйни;*

– ярсу: *Балта сабы кыска. Дуамал баш. Кау кебек кабынырга гына тора. Кызу канлы. Кыска тәртәле. Әчедер теле, дуамалдыр үзе. Яшен ташы (кебек). Ачуыннан тиз кайта. Утка баскан. Холкы бармакка урарлык та юк;*

– үзсүзле: *Ассалар да, сүзеннән кайтмас. Ватылмый торган чикләвек. Аның белән борчак пешми. Аңа әйттең ни, стенадагы бүрәнәгә*

*әйттең ни. Йөрешкәнгә юл бирмәс. Кире беткән. Кирегә каешып үскән. Кире киткән (сүткән). Кире чабата. На дисәң бармый, ту дисәң туктамый. Олтан колак. Сүзен бирми. Тире тунын тискәре кигән. Тискәре (беткән) нәрсә. Чукынган нәрсә. Шайтан алыштырган. Башы каты, арты сасы;*

– йомшак: *Йомшак күңелле. Бәлеш төбе. Миһербан иясе. Балавыз кебек эреп аккан;*

– уңган: *Баскан җиреннән (эзеннән) ут чыгара. Билне буып туган. Иренмәс җан. Ут егет. Җилдән өлгер, эштә сизгер. Чәчрәп тору;*

– ялкау: *Аю табан. Авыр гәүдәле. Авыр санлы. Адымын санап атлый. Авызына чәйнәп салганны (каптырганны) көтә. Ак кул. Артын салып утырган. Аш янында ат кебек, эш янында эт кебек. Аягын санап атлый. Баскан да каткан. Башыннан арты (саны) авыр. Бер аягын алганчы (атлаганчы) икенчесен эт ашый. Бер туктый да бер атлый. Бетле йөрәк. Бохар ишәге. Бәйрәмбай кеше. Бүреген башына кигәнче ел уза. Йокы капчыгы. Ике кулы кесәсендә. Итәгенә ут капса да кузгалмас. Үзе ятып йоклаган, сәке башы кортлаган. Уңмаган утын тукмагы. Төче камырдан әвәләнгән затлы кенәри;*

– тәҗрибәле: *Балта мае ялаган. Дөньяның ачысын-төчесен тату (татыган кеше). Карт төлке. Җиде морҗадан үткән;*

– тәҗрибәсез: *Ана куеныннан чыкмаган (чыгып җитмәгән). Авыз суы кипмәгән. Авызыннан ана сөте (дә) кипмәгән. Авызы пешмәгән. Аягына бозау (сыер) басмаган. Дөнья күрмәгән. Йомырка сарысы кипмәгән. Йомырка эчендәге чебеш. Иренендә ана сөте кипмәгән. Урман әүлиясе. Чи күчән. Яшел авыз. Яңа гына йомырка кабыгыннан чыккан;*

– аумакай: *Авызыңа бал да май булып керә. Ике койрыклы (булу). Юма тел. Юмакай тел;*

– җитез: *Җилдәй җитез. Җиңел сөякле* һ.б.

**3. Хис-тойгы мәгънәсен белдерүче фразеологик берәмлекләрне** икегә бүлеп карап була: а) шәхеснең хис-тойгыларын атаучы фразеологик әйтелмәләр; б) кешеләр арасындагы хис-тойгыларны атаучы фразеологизмнар. Аларның составында түбәндәге семантик кырлар билгеләнә:

а) шәхеснең хис-тойгыларын атаучы фразеологик әйтелмәләр:

– хиссез: *Йөрәгеп май (мүк) баскан. Йөрәк мүкләнгән (булу). Йөрәге бетләнгән. Мүк йөрәк. Мүкләч йөрәк. Итеннән ит кисеп алсаң да сизмәс. Таш чәчкә. Туң күз. Туң йөрәк;*

– батыр: *Куш йөрәкле. Егет дисәң дә егет. Күзен ботактан сакламый;*

– куркак: *Ишек шыгырдаганны ишетеп, төсе китә. Йон йөрәк. Куян җанлы. Чыпчык йөрәк. Чыпчык пыр иткәнгә йөрәге шыр итә;*

– сер тотмаучы, күп сөйләүче: *Авызына саескан төкергән. Авызына теле сыймаган. Авызында сүз тормый. Авызында эт балалаган. Авызын (иләктәй) җәеп. Авызының тоткасы юк. Авызын яба белми. Авызы тишек. Алты авыз. Бакылдык бака. Буш барабан. Ерык авыз. Ияк асты тишек. Озын телле. Сер тотмас үрдәк. Сирәк иләк биш юкә. Сүз тегермәне.Сүз капчыгы. Теше аралы. Бер тиен биреп сөйләтеп булмас, ике тиен биреп туктатып булмас.Җәлпәк авыз. Үзе борчактай, теле кисаптай. Иннегә тыгылмаган. Китек теш. Тел бистәсе. Урам авыз. Төпсез чиләк. Тишек авыз. Ярык барабан, ярык быргы;*

– тәкәббер: *Зур бавырлы;*

– астыртын: *Тавышсыз мылтык. Йөзен яшерү*.

б) кешеләр арасында хис-тойгыларны атаучы фразеологик берәмлекләр:

– үз-үзенә бикләнгән, аралашмаучан: *Авызына йөзен яшергән. Дәшмәки кеше. Каптырмалы кеше;*

– яхшылык теләүче, ярдәмчел: *Шәфкать иясе. Ай белән көндәй һәркемгә кирәкле. Зур йөрәкле. Изге җан;*

– усал: *(Аның белән) каберең якын булмасын. (Аның) талканы коры. Еланга агу бирер. Елан йоткан. Йоны коелган яман эт. Йөзе кара (лар). Йөзендә иман (нуры) әсәре юк. Зәһәр елан. Зәһәр йоткан. Иблис төкереге. Кабык ирен, без танау. Кара йөрәк. Кара йөз. Кара эч(ле). Каты куллы. Колагыңны кисеп, кулыңа тоттырыр. Тешле-телле кеше. Хөсетле кеше. Каты холыклы. Чүл бүресе. Шайтанның арт аягы (арт боты). Ыжгырыйм ата. Эт теше. Адәм аждаһасы. Аю беләк, таш йөрәк. Кабил токымы. Каты бавырлы. Адәм тилчәсе. Кан дошман. Кара елан. Талканы коры, талканын коры тота. Таш бавыр. Таш бәгырь. Таш бөерәк. Таш йөрәк. Таш күңел. Таштан (битәр) каты. Таш та – таш, ул да – таш. Эчендәге җаны юктыр моның!*

– якын кешеңне ярату: *Ачык йөз(ле). Ачык кеше. Ачык күңелле. Йөзе якты, бите ачык. Чырае белән туйдыра. Хуш күңелле. Җылы канлы. Керсез йөрәк. Олы йөрәкле (җанлы).*

**4. Кешенең әхлак-этик сыйфатларын белдерүче фразеологик берәмлекләр:**

– изгелекле: *Изге зат. Илаһи кеше. Ак күңел. Ак күңелле. Ак эчле;*

– тәрбиясез: *Иблис өшкергән нәрсә. Нәфесе башына менеп утырган. Нәфес колы. Юнмаган кисап. Юнмаган таяк. Алладан курыкмый, бәндәдән оялмый. Аннан файда күргәндә алладан каза күрерсең. Илаһи кыз. Кече морҗа тыгынчылыгы;*

– хәйләкәр: *Башы йомры. Йомры баш. Койрыгына бастыра торган кеше түгел. Койрыксыз төлке. Теле (белән) төлке тота. Шома көпшә. Юлы җир астыннан йөри. Юха нәрсә. Ата төлке. Иске бер тиен.*

*Түбәдән атсаң да мәче кебек дүрт аягына төшәр. Агач башындагы карга авызыннан калҗа тартып ала (торган кеше). Җиңелнең астыннан, авырның өстеннән. Иблис токымы;*

– беркатлы: *Юка баш. Эчендәге тышында. Юләр нәрсә;*

– юмарт: *Актык ыштанын салып биргән. Икмәкле-тозлы (кеше). Киң куллы. Су сорасаң бал бирә. Ыштансыз кеше. Ачык куллы. Киң күңелле. Иркен (киң) күңелле;*

– саран: *Анасының имчәген имгәндә, икенчесен кулы белән җибәрми тотып торган. Аннан әйбер алганчы, тавыктан сөт савырсың. Башыннан бөркәнеп ашый. Бер тиенгә бетәшкән. Бер тиене онытылып калса, йөз чакрым кире кайтыр. Бер тиен өчен черәеп каткан. Бетен сыгып (чәйнәп) канын эчкән. Бет чәйнәгән. Бетәшкән нәрсә. Бик "кырып алыйм" кеше. Бир дисәң дәшмәс, мә дисәң кул сузар. Калтырар карун. Кар бирмәс карун бай. Каты кеше. Кискәндә кан чыкмас саран. Кыш көне кар бирмәс. Таш борчак. Тимер борчак. Төкереге белән камыр баскан. Төнлегеннән җил какмый (өрми), ишегеннән кеше бакмый (керми). Уртын суырган. Учыннан акканны ялаучы. Уң күзен сул күзеннән кызгана. Эт эченнән өйрә эчкән. Айны учлап тотар иде, буе җитми. Акча өчен анасын сатар. Карт бүре. Кырып алыйм кеше. Акча корты. Акча колы. Акча капчыгы. Акчасын тавык та чүпләп бетермәс. Акча өчен иманын саткан. Дөньяга бирелгән (кеше);*

– икейөзле: *Акылга дивана. Арты былчырак. Изге монафикъ. Ике битле ком икмәк. Ике йөзле. Ике сүзле. Ике телле. Ишеккә карап елап, түргә карап көлеп. Кереп ашым ашый, чыгып башым ашый. Кешегә барса ал да гөл. Күз алдында мактый, күз артында сүгә. Сары май булып керә, кара елан булып чыга. Эче елый, тышы көлә. Ала йөрәк. Ала күңел. Ала эч. Алдан аяк ялый, арттан үкчә тешли. Алдыңда ашыңны, артыңда башыңны ашый. Өйгә кереп ашың ашый, урамга чыгып башың ашый;*

– тугры, намуслы: *Вөҗданы пакъ, йөзе ак;*

– алдакчы: *Дөя шикелле бер төз җире юк. Кара ялганчы. (Ул кеше белән) аең-көнең уртак булмасын. Чанасының төбе тишек. Шыр чыккан. Алдакчы капчыгы. (Аның) сарыгы да бүре тота;*

– бәйләнчек: *Авызына алды инде, өзмәс тә куймас. Ак яктан куса, кара яктан керә. Арбаның бишенче көпчәге. Ашап туйгач – тозы юк. Аягына таш тисә,миннән күрер. Йөрәк бозгыч. Замаска булды. Каймалы бизгәк. Кан корткыч. Кирәкле кишер яфрагы. Күзге чебен. Салкын бизгәк. Чыршы сагызы. Ябышкак сагыз. Бүз көясе;*

– мактанчык: *Авызын ачса үпкәсе күренә, борынына юкә җитми. Зур күтәреп бәләкәй суккан. Коры кукыр. Тел тегермәне. Шапылдык кеше. Шәп кеше. Яргыч тегермән. Ярма ташы. Ярма яргыч. Әтәч Фәхри (пәхри). Калай әтәч. Таш сыбызгы. Йон батыр;*

– оятсыз: *(Аның) бите юмаган. Битенең керенә биш эт туярлык. Битенә дүңгыз тиресе каплаган. Битенә күн теккән. Битенә алтан салган. Битенә төкерсәң, яңгыр тама дип торыр. Битенә ыштыр япкан (каплаган). Бите юмаган. Бите җәһәннәмгә керсә дә кызармас. Битсез кеше. Йөзен дә чытмый. Йөзенә ыштыр каплаган. Ояты да юк, хәясы дә юк. Тәлинкәсен башына каплаган. Утка керсә, йөзе кызармас. Ыштыр бит. Эттән әрсез, алабайдан гарьсез (кадерсез). Җир бит.*

Кешенең эчке доньясын характерлаучы 78 семантик кыр билгеләнде. Бер үк фразеологик әйтелмә теге яки бу макрокырга карарга мөмкин. Мәсәлән, *ассалар да сүзеннән кайтмас* фразеологизмы беткәнче бер сүзле, бер принциплы, үз сүзе өстендә үлә торган кешене белдерә һәм бер генә семантик кырга карый – үзсүзле. *Үзсүзле* шәхеснең ихтыяр сыйфатларын атаучы макрокырга керә. Ә башка төрле фразеологик әйтелмәләр берничә семантик кырга карарга мөмкиннәр. Мәсәлән, *ачык кеше* фразеологизмы «киң күңелле» дигән семантик кырга караса да, аны бер үк вакытта «саф күңелле», «беркатлы» кебек семантик кырларга да кертеп була. Күрүебезчә, безнең алда семантик кырларга кертү планында күп мәгънәле фразеологик берәмлекләр тора.

Менталь характеристика бирүче кайсыбер фразеологик берәмлекләр турында сөйләгәндә, шуны әйтергә кирәк: кире бәяләмә бирүче фразеологизмнар (мәсәлән, *карга маен эчкән*) яисә уңай бәяләмә бирүче (*алтын куллы*) фразеологик берәмлек бар. Ләкин бар шундый фразеологик әйтелмәләр, алар кешегә уңай бәяләмә дә, киресен дә бирергә мөмкиннәр (мисал өчен, *ата төлке*).

Барлык эчке характеристика кешенең эш-хәрәкәтендә күренә. Шул ук вакытта эш-хәрәкәтнең характеристикасын ике төрле аңлатылырга мөмкин: 1) билгеле тышкы характеристиканың күрсәткече; 2) кешенең ментальлеген раслаучы, яисә эчке характеристиканың күрсәткече буларак; 3) бер үк вакытта беренчесе дә һәм икенчесе дә. Мәсәлән, *бүреген башына кигәнче ел уза* дигән фразеологизм, контекстан аңлашылганча, кешенең үзгәрми торган характер сыйфаты булырга мөмкин, ә шул ук вакытта аерым алынган эш-хәрәкәте дә була ала.

Китерелгән классификация фразеологик әйтелмәләрнең мәгънәләре формалашуын анализларга ярдәм итә. Шулай ук бу классификация фразеологик мәгънәнең лексема мәгънәсеннән ераклашу дәрәҗәсен күрсәтә. Бу, үз чиратында, фразеологик берәмлекләрнең нигезендә ятучы үзенчәлекле образлар һәм символларны ачыкларга һәм сурәтләргә, шулай ук сүзтезмәләрнең фразеологик берәмлекләргә әйләнү этабының эчке процессларын ачыкларга ярдәм итә. Лингвокультур гомумилек (общность) үзенең дөньяны кабул итү үзенчәлекләрен чагылдыра. Халык дөньяның «фотосурәтен» генә ясап калмый, ә тел

символлары аша дөньяны аңлата, шуның белән дөньяның менталь рәсемен дә бирә. Фразеологик әйтелмәләр белән тудырылган тел образлары халык рухын, милли хис-тойгы, дөньяны кабул итү һәм аңлауны чагылдыра.

**Әдәбият**


1. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.
2. Татар теленең фразеологизмнар сүзлеге: тотрыклы сүзтезмәләр һәм тәгъбирләр: Өч томда. – Казан, 2022.
3. Хайруллина Р.Х. Фразеологическая картина мира: от мироведения к миропониманию – Уфа: БГПУ, 2000. – 283 с.
4. Эмирова А.М. К теоретическим основам фразеологической идеографии (Некоторые проблемы фразеологической ономасиологии) // Вопросы фразеологии. – Самарканд, 1979, вып.14. – С. 50-61.


© Гайнуллина Г.У., 2024

УДК 811.512.141

**Гамбарова А.Х.,**
*Өфө к., Рәсәй Федерацияһы*
*Ғилми етәксеһе: ф.ф.к., доцент* ***Р.Я.Хөснөтдинова***

## КОМПАРАТИВ КОНСТРУКЦИЯЛАРҘЫҢ МОРФОЛОГИК ЮЛ МЕНӘН ЯҺАЛЫШЫ

***Аннотация***: *мәҡәләлә компаратив конструкцияларҙың структур үҙенсәлектәре ҡарала. Сағыштырыуҙарҙың морфологик ысулына айырым урын бирелә.*

***Төп һүҙҙәр:*** *башҡорт теле, компаративлыҡ, сағыштырыуҙар.*

Компаратив конструкцияларҙың морфематик барлыҡҡа килеү юлдары телдең фонетик, шулай уҡ синтаксик аспекттарына ҡағылған ҡатмарлы һәм күп кимәлле процесс булып тора. Беренсе сиратта, сағыштырыу формаларын барлыҡҡа килтереүҙең киң таралған ысулы – ялғауҙар ҡулланыу, был, үҙ сиратында, сағыштырыуҙы булдырырға мөмкинлек бирә. Мәҫәлән, «аҡыллы» һүҙбәйләнешен «аҡыллыраҡ» тип үҙгәртеү сифаттың юғарыраҡ кимәлен күрһәтә; «*Йыраҡтараҡ* трактор менән ер һөрәләр, тағы ла *алыҫтараҡ* иген һуғыусылар күренде (Б. Бикбай). Бынан тыш, аналитик конструкциялар бар, уларҙа компаратив

мөнәсәбәттәр һылтауҙар аша сағылыш таба. Был алым телмәрҙең һығылмалығын һәм баҙыҡлығын арттыра.

Шуның менән бер рәттән ҡайһы бер телдәрҙә компаратив конструкциялар образлы ассоциациялар нигеҙендә формалашҡан метафорик көсәү күренеше күҙәтелә. Тимәк, сағыштырыу тура характеристикаларға ла нигеҙләнә ала, шул рәүешле интерпретацияла тәрәнлек һәм күп мәғәнәлелекбарлыҡҡакилә. Шулайитеп, компаратив конструкцияларҙың морфематик барлыҡҡа килеү юлдары тел ресурстарының байлығын һәм төрлөлөгөнсағылдыра, был телдә идеяларҙы һәм эмоцияларҙы асыуға булышлыҡ итә.

Һүҙьяһалыш тел ғилеменең морфология бүлеге менән тығыҙ бәйләнештә, сөнки һүҙьяһалыш процесы күп осраҡта тамыр һәм аффиксаль морфемаларҙың мөнәсәбәттәшлеге, йәғни һүҙ яһаусы нигеҙҙәрҙең бер-береһе менән ҡушылыуҙары, ишләшеүҙәре, ҡабатланыуҙары йәки һүҙ яһаусы аффикстар менән ҡушылыуҙары һөҙөмтәһе булып тора; юҡҡа ғына һүҙьяһалыштың иң продуктив һәм киң таралған күп тармаҡлы төрҙәренең береһе морфематик юл тип аталмай.

Һүҙҙәрҙең морфематик төҙөлөшө һәм уларҙың грамматик формаларының яһалыу үҙенсәлектәре буйынса башҡорт теле, башҡа төрки телдәр кеүек үк, агглютинатив телдәрҙең аффиксаль төркөмөнә ҡарай. Был – башҡорт телендә һүҙҙәрҙең морфематик төҙөлөшө агглютинатив юл менән, йәғни күптән ҡалыплашҡан һәм билдәле бер функция атҡарған аффикстарҙың механик рәүештә тамыр (нигеҙ) аҙағына эҙмә-эҙлекле ҡушылыуы һөҙөмтәһендә, башҡарылыуына бәйләнгән: баҡ-са-сы-лыҡ-ты үҫтерәйек», – тип яҙа К.Ғ. Ишбаев [2; 45].

Шуны билдәләп үтәйек: морфема – грекса «morphe» (форма) һүҙенән яһалған. Ул иһә һүҙҙең артабан бүленә алмай торған иң бәләкәй мәғәнәүи өлөшөн аңлата. Башҡорт телендә морфемалар, башҡа төрки телдәрҙәге кеүек, мәғәнәләре, урындары һәм функцияларына ҡарап ике төргә: тамыр морфемаларға йәки тамырҙарға һәм аффиксаль морфемаларға йәки аффикстарға бүлеп ҡарала. Шулай итеп, һүҙ морфематик төҙөлөшө буйынса, нигеҙҙә, ике төрлө морфеманан: тамыр менән аффикстан тора. Мәҫәлән:

һал (тамыр) – ма (аффикс),

ҡой (тамыр) – маҡ (аффикс).

Белеүебеҙсә, морфематик юлдың аффикслашыу һәм нигеҙҙәр ҡушылыу ысулдары, шулай уҡ һүҙҙәрҙе ҡыҫҡартыу юлы менән яңы һүҙҙәр яһалған саҡта, йыш ҡына һүҙ яһаусы нигеҙҙәр составындағы айырым фонемалар йәки фонемалар рәте төшөрөп ҡалдырылалар, әйтелмәҫ булалар; был күренеш яһаусы нигеҙҙәрҙең ҡыҫҡарыуы рәүешендә ҡабул ителә, уның төп сәбәптәре булып телдәге

морфемаларҙың һүҙьяһалыш процесы барышында үҙ-ара ҡушылыусанлыҡ үҙенсәлектәре һәм төрлө фонетик процестарҙың сағылышы иҫәпләнә.

Тимәк, башҡорт телендә компаратив конструкцияларҙың морфематик барлыҡҡа килеү юлдары – тел структураһы һәм семантикаһы үҙенсәлектәрен сағылдырған ҡатмарлы һәм күп кимәлле процесс. Башҡа төрки телдәрҙәге кеүек үк, башҡорт телендә лә объекттарҙы сағыштырыуға төрлө морфологик алымдар, шул иҫәптән хатта айырым һүҙҙәр ҡулланыу ярҙамында өлгәшелә. Сағыштырыу конструкцияларын барлыҡҡа килтереүҙең киң таралған ысулдары ҡушымталар нигеҙенә -ыраҡ/-ерәк ялғауҙарын ҡушыуҙы үҙ эсенә ала. Мәҫәлән, «матур» – «матурыраҡ» (иң матуры).

Шулай уҡ телдә мәғәнә һәм контекстың өҫтәмә ҡатламдарын өҫтәгән «ҡарағанда» йәки «ҡарап» кеүек сағыштырма һүҙбәйләнештәр махсуслаштырылған конструкциялар ҙа осрай.

Компаратив конструкцияларҙың -дай/-дәй, -са/-сә аффикстары бар. Мәҫәлән: «**Алмалай** ҡыҙым Гөлйөҙөмдө юҡ итте, **арыҫландай** кейәүемде харап итте (Һ. Дәүләтшина). Шулай уҡ бәйләүестәр: уҡ **кеүек** атылыу; башына таш төшкән **һымаҡ**; умарта **һымаҡ** гөж килеү; юрға ат **шикелле** йөрөү.

Тел үҙләштереүҙең һәм башҡа телдәрҙең йоғонтоһо күҙәтелә, был компаратив формаларҙың структураһын киңәйтә. Диалект төрлөлөгө мөһим аспект булып тора, унда төрлө райондарҙың тел үҙенсәлектәре барлыҡҡа килә.

Бынан тыш, компаратив конструкцияларҙың стилистик контексҡа ҡарап үҙгәреүе мөмкин. Әҙәби телдә йышыраҡ формаль формалар ҡулланыла, ә һөйләшеү телмәрендә ябайлаштырылған конструкциялар ҡулланыла. Ул, мәҫәлән, ябайлаштырылған сағыштырыу формаларын һәм метафораларын ҡулланыуҙа сағыла, был иһә тағы ла йәнлерәк һәм хислерәк телмәр тыуҙырырға мөмкинлек бирә.

Компаратив конструкциялар өлкәһендәге тикшеренеүҙәр шулай уҡ прагматика аспекттарын үҙ эсенә алыуы, шул иҫәптән билдәле риторик эффекттарға ирешеү өсөн сағыштырмаларҙы файҙаланыуы ла мөмкин. Күп кенә осраҡтарҙа сағыштырыу конструкцияларын ҡулланыу, сағыштырыуҙың мәғәнәләргә баҫым яһап, социаль йәки мәҙәни айырмалыҡтарҙы асыҡлау өсөн хеҙмәт итергә мөмкин. Шулай итеп, башҡорт телендә компаратив конструкцияларҙың морфологик ысул менән барлыҡҡа килеү юлдары артабан өйрәнеү һәм анализлау өсөн ҡыҙыҡлы һәм күп яҡлы өлкәләрҙән ғибәрәт, был ошо телдең байлығын һәм ҡатмарлылығын раҫлай.

**Әҙәбиәт исемлеге**

1. Ғәниев В.В. Ж.Ғ. Кейекбаев әҫәрҙәренең тел һәм стиль үҙенсәлектәре. – Өфө: БДУ, 2002. – 133 б.

2. Ишбаев, К.Ғ., Ишкилдина, З.К. Башҡорт теленең ҡыҫҡаса һүҙьяһалыш һүҙлеге / К.Ғ.Ишбаев, З.К. Ишкилдина. – Өфө: Китап, 2014. – 552 б.

3. Сәйетбатталов Ғ.Ғ. Башҡорт теле. 5 том. Стилистика. – Өфө: Китап, 2009. – 352 б.

4. Хакимова В.Ш. Функционально-семантическая категориялы компаративности в современном башкирском языке. – Уфа: Издание Башгосуниверситета, 2002. – 131 с.

5. Талипова Т.Р., Хөснөтдинова Р.Я. Мостай Кәримдең әҫәрҙәрендәге сағыштырыуҙарҙы тәржемә итеү юлдары. В сборнике: Мостай Кәрим феномены һәм глобаль XX быуат: донъя контексында милли-рухи мәҙәниәт (Башҡортостандың халыҡ шағиры Мостай Кәримдең тыуыуына 100 йыл тулыу айҡанлы). Сборник материалов Международной научно-практической конференции, к 100-летию со дня рождения народного поэта Башкортостана Мустая Карима. Ответственный редактор Кунафин Г.С. – Уфа: БГУ, 2019. – С. 230-235.

6. Усманова А.Ф. Рәми Ғариповтың поэзияһында сағыштырыуҙарҙың ҡулланылышы // Сборник материалов международной научно-практической конференции студентов, магистрантов, аспирантов и молодых ученых «Актуальные проблемы современной филологии, востоковедения и журналистики». 23 апреля 2024 г. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2024. С. 341-343.

© Гамбарова А.Х., 2024

УДК 811.512.145

**Гареева Р.Р., Зарипова И.Ф.,**
*Уфа ш., Россия*

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЛИНГВИСТИКА ӨЛКӘСЕНӘ КАРАГАН ФРАЗЕОЛОГИК ТЕРМИННАР

***Аннотация:*** *мәкаләдә фразеологик берәмлекләр белән белдерелгән лингвистик терминнар тасвирлана.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, лексикология, фразеологизм, термин, фразеологик терминнар.*

Фәнни-техник белемнәр үсеше белән бәйле рәвештә, хәзерге телләрдә барлыкка килгән күп санлы яңа сүзләр махсус лексика, ягъни

терминологик берәмлекләр тәшкил итә. Төрле табигый, төгәл, гуманитар фәннәр терминнары санының үсеше телнең гомуми кулланыштагы сүзләре санының үсешен узып китә. Хәзерге вакытта аерым фәннәр (химия, биология) терминнары саны телнең махсус булмаган сүзләре саныннан артыграк булырга мөмкин. Шул ук вакытта күп кенә терминнар гомуми кулланыштагы телгә үтеп керә, ә терминологик проблемалар гомумән телгә күбрәк йогынты ясый, шуңа күрә махсус өйрәнү телнең лексик системасын үстерү өчен мөһимрәк була бара.

Фәндә «термин» төшенчәсе нигездә XX гасыр башында формалаша. Терминология тикшеренүләренең тарихы зур. Терминологик өлкәсендәге заманча хезмәтләр автоматлаштыру һәм инженер-лингвистик модельләштерү принципларын кулланып, аның тасвирламасында (Р.Г.Пиотровский, Л.Н. Беляева, А.С. Герд, Б.Ю. Городецкий, Ю.Н. Караулов, П.Н. Денисов һ.б.) рус һәм совет терминологиясе классиклары (А.А.Реформатский, В.В. Виноградов, Д.С. Лотте, Л.В. Щерба һ.б.), шулай ук терминнар проблемаларына игътибар иткән һәммахсус терминология белән шөгыльләнгән чит ил тел белгечләре (Ф. де Соссюр, Э. Бенвенист һ. б.) тарафыннан салынган фундаментка нигезләнә.

Терминның асылы турындагы сорау һәрвакыт терминологиядә мөһим булган. Ул Д.С. Лотте һәм Э.К. Дрезен хезмәтләрендә тикшерелә. А.А. Реформатский билгеләп үткәнчә, «терминология» – ул фән, техника, сәясәт, ягъни интеллектуаль оешкан социаль чынбарлык өлкәләренең үзлеге. Терминология, беренче чиратта, әлеге фән төшенчәсе системасы белән бәйле».

Терминның системалылыгы турында сөйләгәндә, Б.Ю. Городецкий һәм В.В. Раскин аерым алынган терминның фикция булуын билгелиләр. Ул бары тик билгеле бер мөнәсәбәтләр белән бәйле булган терминнар системасында гына бар. Һәм, чыннан да, термин, беренче чиратта, лексик берәмлекләрнең бөтен классына карый, һәм аның махсус лексикага каравы икенчел, специфик үзенчәлек булып тора, ә бу специфика гомуми кулланыштагы лексикага карата нисбәт һәм, аерым алганда, оппозиция белән бәйле.

Г. Гийом билгеләгәнчә, лингвистиканың бурычларының берсе «бик якын арадан һәм тирән уйланулар ярдәмендә формалашкан һәм безнең өчен гадәти булган телләрдә сүз формасын алган тел асылларының ничек барлыкка килүен тикшерүдән гыйбарәт».

Төрле термин системаларны һәм терминологияләрне тикшерүчеләрнең күбесе терминнарның асылын аларның барлыкка килүе һәм оешмасы ягыннан гына түгел, ә терминологик һәм гомуми кулланыштагы лексика арасындагы аермалар турында да сорау куялар. Бу аерма телнең табигатендә ята. Терминнар профессиональ телгә карый,

алар профессиональ төшенчәне белдерүче һәм формалаштыручы махсус мәгънәгә ия. Терминнар фәнни һәм һөнәри-техник объектларны һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләрне танып белү һәм үзләштерү процессында кулланыла.

Татар тел белемендә фразеология буенча хезмәтләрнең күп булуына карамастан, фразеологик терминнар буенча булган белемнәрне туплап, системага салган, аларны төрле аспекттан чыгып анализлаган һәм төгәл, конкрет нәтиҗәләр ясаган, хезмәтләрнең әлегә булмавы сайланган теманың актуальлеген билгели.

Татар телендә лингвистика өлкәсенә караган фразеологик терминнарны, үз чиратында, берничә төркемгә бүлергә мөмкин. Мәсәлән:

а) фонетика тармагына караган фразеологик терминнар:

*Ачык иҗек* – сузык авазга тәмамланучы иҗек.

*Интердентал‌ь тартык* – телне аскы һәм өске тешләр арасына куеп әйтелә торган аваз.

*Ирен авазлары* – иреннәр катнашы белән әйтелә торган авазлар (*б, п, в, ф, о, ө, у, ү*).

*Латераль тартыклар* – телнең кырыйлары (яны) буйлап чыккан һава агымы ярдәмендә ясалган тартык авазлар.

*Логик басым* – җөмләдәге берәр сүзнең мәгънәсенә басым ясау өчен аны башкаларыннан көчлерәк тавыш белән аерып әйтү (мәс., татар телендә хәбәр алдында торган сүзне, рус телендә җөмләдә соңгы торган сүзне көчлерәк тавыш белән әйтү).

*Оешма тартыклар* – составында ике элемент булган кушык тартык авазлар; аффрикатлар (мәс., [ч] = [т] + [ш], [ц] = [т] + [с]).

*Сонор тартыклар* – әйткәндә тон өстенлек итә торган авазлар (мәс., [р], [м], [н], [й], [ң], [w], [л]).

*Төшерелмә дифтонг* – иҗек ясаучы сузык һәм й яки у (ү) ярым сузыгыннан торган дифтонг. Мәсәлән, *көй, тау, туй.*

*Яңгырау тартыклар* – артикуляция вакытында тавыш ярылары бер-берсенә якынаеп, һава агымы үткәндә калтырап тавыш барлыкка китереп, тавыш өстәп әйтелә торган авазлар; Мәсәлән, *б, в, г, д, ж, з* һ.б.

ә) лексикология тармагына караган фразеологик терминнар:

*Күп мәгънәле* – сүзнең төп мәгънәсеннән соңрак барлыкка килгән икенчел мәгънәсе. Метафора, метонимия, синекдоха, вазифа (функция) буенча күчеш төрләре бар.

*Тагылма сүз* – кабатлаулы парлы сүз ясый торган, беренче компонентка кушыла торган сүз. Соңгы вакытта тагылма сүзләр элекке сүзнең башындагы авазын [м] авазына үзгәртеп кабатлау белән ясала, мәсәлән, *ит-мит, әз-мәз.*

б) морфология тармагына караган фразеологик терминнар:

*Артыклык дәрәҗәсе* – сыйфат төркемчәсе. Бер әйбердәге билгенең башка әйбердәге билгеләргә караганда артык булуын белдерә. Мәсәлән, *кап-кара, иң зур, җете кызыл; высочайший, самый сильный, красивее всех* һ.б.

*Бүлем саны* – төрдәш әйберләрнең тигез өлешләргә бүленүен белдерүче сан, микъдар санына *-ар/-әр, -шар/-шәр, -ышар/-ешәр* кушымчалары ялгап ясала: *унар, бишәр, алтышар, туксанышар, сиксәнешәр* һ.б.

*Иялек килеше* – исемне исемгә яки исемләшкән сүзләргә ияртүче һәм иялек нисбәтен билгелелек төсмере белән белдерүче килеш. Кемнең? нәрсәнең? сорауларына җавап бирә, сүзләргә *-ның/-нең* кушымчалары ялганып ясала. Иялек килешендәге сүз җөмләдә күбесенчә аергыч я тәмамлык була.

*Кайтым юнәлеше* – эшнең үтәүчегә кайтуын белдерә торган фигыль формасы, субъект үз эшенең объекты да була, *-ын/-ен/-н* кушымчалары ярдәмендә ясала: *буя-н-а, ю-ын-а, ки-ен-ә* һ.б. Рус телендә *-ся, -сь* постфикслары ярдәмендә ясала: *одевает-ся, моет-ся* һ.б.

*Киләчәк заман* – хикәя һәм сыйфат фигыльләрнең бер төре. Эшнең сөйләү моментыннан соң булачагын белдерә.

*Ялгызлык исем* – бер төрдән булган әйберләрнең берсенә генә бирелә торган исем (кеше исемнәре, фамилияләр, географик атамалар, газета, журнал, китап исемнәре, хайван кушаматлары һ.б.).

*Ярдәмлек сүзләр* – 1. Атау функциясе башкармыйча, бары мөстәкыйль сүзләргә өстәмә мәгънәләр бирү, аларны бер-берсенә бәйләү яки модаль мәгънәләр белдерү өчен генә хезмәт итә торган сүзләр (теркәгеч, бәйлек, кисәкчә, модаль сүзләр). Бәйләгеч сүзләр һәм модаль сүзләргә бүленәләр. 2. Грамматик мәгънә белдерә торган чараларның бер төре – предлоглар, послелоглар, артикльләр, кисәкчәләр һ.б.

*Ярдәмче фигыль* – төп фигыльгә ияреп аңа үзгә мәгънә төсмере өсти торган фигыль; аналитик фигыль составында грамматик функция үти торган фигыль.

в) синтаксис тармагына караган фразеологик терминнар:

*Тиңдәш кисәкләр* – җөмләнең бер үк синтаксик функция башкара, бер үк җөмлә кисәгенә карый, үзара тезүле бәйләнештә була торган кисәкләре. Җөмләнең барлык кисәкләре дә тиңдәшләнеп килә ала (тиңдәш ияләр, тиңдәш хәбәрләр, тиңдәш аергычлар һ.б.).

*Туры тәмамлык* – күчемле фигыльгә ияреп, процесс турыдан-туры үзенә төшә торган әйберне, төшенчәне белдерә торган тәмамлык.

*Кире хәл* – җөмләдә ияртүче кисәктән аңлашылганның киресен белдергән (иярчен кисәк тур.).

*Ике составлы* – составында иясе дә, хәбәре дә булган җөмлә.

*Иярчен кисәк* – җөмләнең ия яки хәбәренә буйсынып, алар белдергән эчтәлекне ачыклап, тулыландырып килгән кисәк; төгәлләүле һәм аныклаулы мәнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесе.

*Иярченле кушма җөмлә* – баш җөмләгә ияру юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмлә.

*Ким җөмлә* – контексттан яки ситуациядән билгеле булганга күрә, бер яки берничә кисәге төшереп калдырылган җөмлә.

*Максат хәле* – эшнең үтәлү-үтәлмәү, билгенең булу-булмау максатын белдерүче җөмлә кисәге. Татар телендә юнәлеш килешендәге исемнәр, инфинитив; өчен бәйлеге яки дип сүзе белән килгән исемнәр һәм фигыльләр ярдәмендә белдерелә.

*Өстәмә сүз* – берәр сүзне ачыклап, аның белән бер үк килештә килгән исем белән белдерелгән аергыч.

г) пунктуация тармагына караган фразеологик терминнар:

*Ике нокта* – тиңдәш кисәкләр алдындагы гомумиләштерүче сүздән соң, бәйләүче чарасы интонация булган кушма җөмләләрдә баш җөмләдән соң, автор сүзләреннән соң килгән туры сөйләм алдында һ.б. очракларда куела торган тыныш билгесе (:).

*Күп нокталар* – сүзнең тәмамланмавын белдерү өчен, бер өлеше төшеп калган текст башында яисә бер фикердән икенчесенә кинәт күчкәндә барлыкка килә торган зур паузаларны белдерү максатыннан куела торган тыныш билгесе (...).

д) телләрне төркемләү өлкәсенә караган фразеологик терминнар:

*Тунгус-маньчжур телләре* – Алтай телләре семьялыгының эвенк, эвен, маньчжур, нанай, негидаль, удэгэ, орок, солон, ульч телләре кергән төркеме.

*Һинд-европа телләре* – иң зур тел гаиләсе. Үзенең төркемнәре бар: һинд т. (бенгаль, пенджаб, урду, һинди һ.б. телләр), иран т. (афган, фарсы, көрд, таҗик, осетин һ.б.), славян т., балтыйк т. (литва, латыш, прус һ.б.), герман т., роман т., грек т. һ.б.

Шулай итеп, телдә, сүзләр белән бер рәттән, мәгънәләре һәм синтаксик функцияләре буенча сүзләргә якын торган, ә структур яктан сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне хәтерләткән күчерелмә мәгънәле үзенчәлекле төзелмәләр яши. Фразеологик әйтелмәләрнең, шул исәптән фразеологик терминнарның, чиген билгеләү, аларны сүзләрдән һәм ирекле сүзтезмәләрдән һәм бигрәк тә башка төр тотрыклы тезмәләрдән аеру гаять катлаулы, һәм тел белемендә бу мәсьәләләргә карата фикерләр төрлелеге күзәтелә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, I том (А-Й). – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1977. – 476 б.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, II том (К-Р). – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1979. – 726 б.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, III том (С-Һ). – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1981. – 832 б.
4. Реформатский А.А. Мысли о терминологии / А.А.Реформатский // Современные проблемы русской терминологии. – Москва: «Наука», 1986. – С. 83-85.

© Гареева Р.Р., Зарипова И.Ф., 2024

УДК 811.512.145

**Гарипова-Хасаншина В.М.,**
*Казан ш., Россия*

## НУРИХАН ФӘТТАХНЫҢ «СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР» РОМАНЫНДА АНТРОПОНИМИК СИСТЕМА

***Аннотация:*** *мәкалә язучы Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романында чагылыш тапкан антропонимик картинаны гомуми күзәтүгә багышлана. Тарихи әсәр жанрының онимнар сайланышына карата үз таләбе бар. Бу сайланышка герой-персонажлар хәрәкәт иткән тирәлек тә, чор мохите дә, әсәрнең идея-проблемасы да йогынты ясый. Әлеге антропонимик системаның состав өлешләрен номинатив һәм тарихи-мәдәни вазифа үтәгән тарихи шәхес исемнәре һәм ярдәмче образ-персонажларның әһәмияте ягыннан тарихи антропонимнардан һич тә калышмаган исем-атлары тәшкил итә. Әдәби әсәр тукымасында урын алган антропонимнар, атау функциясеннән тыш, эмоциональ-экспрессив катлам тудыруда да зур роль уйныйлар, стилистик чара буларак та актив кулланылалар.*

***Ключевые слова:*** *ономастика, антропонимика, оним, тарихи роман, исем, проза, тарихи шәхес исемнәре.*

Әдәби әсәр лексикасының аерым бер төркемен тәшкил иткән антропонимнарның әсәрнең жанрына, идея-проблемасына нисбәтле үз вазифасы бар. Гадәттә, аларны поэтик антропонимия кысаларында өйрәнәләр. Поэтик антропонимия үз эченә әдәбият һәм тел чигендә торучы эзләнү-тикшеренүләрне ала. Монда автор идеясен дә, әсәр язылган чор мохитен дә, шул исәптән жанр үзенчәлекләрен дә исәпкә

алырга кирәк. Болар барысы да поэтик антропонимиконга турыдан-туры тәэсир ясаучы факторлар. Әдәби әсәр эченә килеп кергән антропонимнар очраклы күренеш кенә булып кала алмый. Алар кайвакыт хәтта автор уйламаган, планлаштырмаган мәгънә төсмерләре белән байый, поэтик функциясен киңәйтә.

Антропонимик системаның табигате, аны тәшкил иткән берәмлекләрнең үзенчәлеге нисбәтеннән тарихи әсәрләр, аеруча тарихи роман жанры аерылып тора. «Татар милләтенең яңарышына этәргеч бирү өчен аны, иң әүвәл, үз тарихы белән, үзенең милли чыганаклары белән таныштыру, аның тарихи аңын кузгату кирәклеген» [3; 2] беренчеләрдән булып аңлаган Нурихан Фәттах күләмле һәм яңгырашлы «Сызгыра торган уклар» әсәрен иҗат итә. Автор, гомумән, татар әдәбиятында тарихи роман жанры үсешенә зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе [1], [6], [8].

«Киң планлы дәвамлы хәрәкәтне, күптөрле иҗтимагый-шәхси бәйләнешләрне, масштаблы характерларны чәчмә рәвештә хикәяләүче, катлаулы композицияле, күп бизәкле» [7; 199] «Сызгыра торган уклар» романы б.э.к. III гасырларда Монголия һәм Төньяк Кытай территорияләрендә яшәгән сөннәр тормышын яктырта. Сурәтләнгән вакыйгаларның ерак тарихка барып тоташуы, сөннәрнең гореф-гадәтләрен, яшәешен, башка халыклар белән катлаулы иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләрен яктырту автордан, билгеле, шактый зур эзләнүләр таләп итә. Н. Фәттах үзе ассызыклаганча, ул борынгы кытай язмаларына да, фәнни хезмәтләргә дә таянып эш итә [5; 428].

«Сызгыра торган уклар» романының лексик катламын формалаштыруда, тарихи чор мохитен тудыруда апеллятив лексика гына түгел, ә антропонимнар да гаять зур роль уйныйлар. Бу, үз чиратында, онимнар сайлауга бик саклык белән якын килүне сорый. Әлеге таләп төп геройларга да, ярдәмче образ-персонажларга да кагыла.

Әсәрдә тарихи шәхес исемнәре – роман антропонимиконының үзәген тәшкил иткән төп, терәк онимнар. Башка кеше исемнәре исә шулар тирәсендә урнаша. Шуңа да тарихи шәхес исемнәренә автор аерым аңлатма биреп китүне кирәк дип таба. Әсәрнең төп герой исемнәре хакында Н. Фәттах: «Кеше исемнәренә килгәндә, кытай язмаларында *Тоумань* дип аталган исем романда *Туман* дип, *Маодунь – Албуга*», – дип яза [5; 428]. Албуганың прототибы тарихта *Модун, Мете-хан, Модэ* исемнәре белән дә билгеле. Ләкин автор, әдәби әсәр кануннарына туры китереп, аларга төрки яңгыраш биргән. Әлеге яңгыраш калган тарихи шәхес исемнәренә да кагыла. Цинь империясенең беренче императоры *Цинь Шихуандиның* исеме дә романда *Шихуанди* формасын алган. Шулай ук автор тарихи чынбарлыкны сакларга тырышып, аның тәхеткә

утырганга кадәрге исемен дә файдаланып, героен *Ин Чжэн (Ин Чжэн)* дип атый һәм күпчелек очракта аны кушып яза: «*Инчжэннең* тәхете, бөек каган, сөңге очына гына эләгеп тора» [4; 69]. Аның беренче киңәшчесе *Ли Сы* исеме дә романда *Лисы* буларак яңгырый. Н. Фәттах, әсәр ахырында үзе үк боларның тарихи шәхес исемнәре булуына басым ясап, аңлатмалар бирә: «*Ментәйн* – тарихи шәхес. Чин империясенең атаклы гаскәр башлыгы» [5; 430], «*Пәйгун* – тарихи шәхес. Хань династиясенең беренче императоры. *Гаоди, Гаоцзу, Любан* дигән исемнәре дә билгеле. Б.э.к. III гасырда яшәгән» [5; 431] һ.б. Романда *Пәйгун* антропонимы белән янәшә *Гаоди* исеме дә кулланыла. Ягъни реаль шәхес исемнәре романның антропонимик системасына, мөмкин кадәр тарихи фактларны истә тотып, сөннәрнең шул дәвердәге тел үзенчәлекләрен фаразлап, аларның сигнификатив мәгънәләрен яхшы күзаллап кертелгән.

Романдагы герой-персонажлар – төрле кавем, кабилә, дәүләт вәкилләре. Аларның исемнәре романның төп антропонимик массасын тәшкил итә. Бу, билгеле, үз чиратында антропонимнар сайланышында да чагылыш тапмый калмый: сөн кавеменнән *Бүзбала, Котлуг бәк, Сылу-кыз, Албуга,* кыпчак иленнән китерелгән *Табылдык*, Дунху бәге *Начин нойон*, Цинь империясеннән килгән *Чәнси, Йу, Йуй,* кытай якларыннан булган *Сүйши, Лүшән, Лиму* һ.б.

Әсәр вакыйгаларында төп рольләрнең берсен үтәгән Исәнтәйнең катлаулы һәм каршылыклы образын тудыруда автор парлы исемне бик уңышлы файдалана: «*Исәнтәй-Банхуаның* атасы Чжао ягында туган, Чжао ягында үскән ярым сөн, ярым түбет кешесе иде. ...Ул чакларда *Исәнтәй-Банхуаның* әтисе *Банлу* Чжао гаскәрендә меңбашы булып хезмәт итә иде һәм иң турылыклы сугышчылардан санала иде» [4; 33]. Әлеге парлы исем персонажның ике урталыкта калган, мәсләген югалткан, үзенең кавеме, тамырлары белән бәйләнеше тәмам өзелгән, шул ук вакытта сөннәрне дә җаны-тәне белән күралмаган, эчке каршылыклар белән яшәгән, исән калу, дәрәҗә өчен авыр шартларда бертуктаусыз көрәш алып барырга мәҗбүр булган кеше буларак характерлый.

Сөн герой-персонажларына бирелгән исем-атамалар нигезендә халыкның мифологик ышанулары ята, алар арасында зооморф характерындагы антропонимнар шактый: *Куянкай, Кәлтә, Көчек, Бавыр, Аю-Мамак, Тычкан-Мамак, Кондыз, Ябалак, Тишек-Таш, Кече-Тай* һ.б.

Н. Фәттах чор мохитен тудыру максатында роман җирлегенә исемнәрне «титул, дәрәҗә, һөнәр + антропоним» формасында кертеп җибәрә: *йөзбашы Күчәр, чин ваны Инчжэн, Өлкән бичә Күрекле бикә, сул кул карачы Тук-Сыртлан, уң кул карачы Бүзбала, Туман каган, Туңгак алып, Йөзбашы күчәр, баш бага Корта, Салчак алып, Елдырым бәк, Кара-Тире би, йөзбашы Этимчәк, унбашы Җидекул* һ.б.

Мондый төзелмәләр романда тарихи чынбарлыкны тудыруга, герой-персонажларны характерлауга, сурәтләүгә хезмәт итәләр.

Романда урын алган антропонимнарның денотаты бер – кеше. Ләкин һәр исемне укучы үзенчә кабул итә, ул аңарда билгеле бер тәэсирләр калдыра. Шул сәбәпле прагматик компонентны да күз уңыннан читкә җибәрә алмыйбыз. Әсәр эченә кереп киткән антропонимның коннотациясе, вакыйгалар куерган, сюжет йомгагы сүтелгән саен, мәгънәви төсмерләргә байый бара, һәм исем, нәтиҗәдә, үзенең героен характерлаучы билге-сүзгә әверелә. Мисал өчен башта романга *Исәнтәй, йөзбашы Күчәр* буларак килеп кергән антропонимнар, әсәр барышында *юлбасар Исәнтәй, хәйләкәр Исәнтәй, хәйләкәр йөзбашы Күчәр* рәвешендә эпитетлар белән кулланыла башлыйлар.

«Антропоним+карт, бикә» конструкциясенә нигезләнгән формалар да романда шактый актив: *Баргынтай баба, Кортка-бикә, Өлкән бичә, Сырга бикә, Күник карт, Кондыз карт* һ.б. Кайбер очракларда мондый төзелмәләрдә мәгънәләре ягыннан шактый якын торган апеллятив лексиканы параллель куллануда билгеле бер стилистик үзенчәлекләр күренә. Мисал өчен Н. Фәттах бер үк персонажга карата *Ябалак баба* һәм *Ябалак карт* дигән формалар куллана. *Ябалак карт* дигәндә, яшен яшәгән, өлкән яшьтәге гади кеше образы килеп баса: «Күлгә аяк басар алдыннан *Ябалак карт* кычкырып дога укыды, күл иясенә йолыкка дип алып килгән бер чүлмәк кымызны боз өстенә түкте дә, күңеле белән котылу, җиңеләю тоеп, сөңгесенә тотынган көе, шома боз өстеннән атлап китте» [4; 218]. *Ябалак баба* дигәндә исә, укучы хыялында хөрмәтле, тәҗрибәле аксакал гәүдәләнә. Албуганың анасы Күрекле бикә аңа хөрмәт белән бары тик шул формада гына мөрәҗәгать итә: ««Бары да истә, Ябалак баба», – диде бикә моңсу гына» [4; 217].

Роман антропонимиконында *Адай, Төпсә, Баскак Мичән, Саттай, Юкәл, Йәрти, Чура* кебек бик актив булмаган исемнәр дә әсәрнең хәрәкәт мәйданын оештыруда, төп геройларның эш-гамәлләрен тасвирлауда, аларның башка герой-персонажлар белән мөнәсәбәте аша холыкларын ачуда, психологик портретларын тудыруда үзләреннән өлеш кертәләр.

Шул рәвешчә, «Сызгыра торган уклар» тарихи романының антропонимик системасы үзенең сигнификациясе, коннотациясе ягыннан җитди уйланылганлыгы белән аерылып тора. Бу системада һәр берәмлек үз урынында, аларның һәркайсының идея-эчтәлеккә бәйле үз конкрет вазифасы бар.

Һәрбер әдәби әсәрдә өч вакыт – вакыйгалар, язучы һәм укучы вакыты [2; 17] бар. Н. Фәттах, вакыйгалар булган чорга үз дәвере күзлегеннән бәя биреп, аларны алдагы буыннарга да сабак булырлык итеп тасвирларга тырыша. Бу иҗат процессында антропонимнар, хаклы

рәвештә, тарихи чор һәм тирәлекне тасвирлауда, тарихи герой һәм образ-персонажлар тудыруда ярдәм итүче төп чараларның берсе булып торалар.

**Әдәбият**

1. Галимуллин Ф. Тарихтагы эзләребез буйлап / Ф. Галимуллин // Шәһри Казан. – 1994. – 20 апр.
2. Рогозина В.И. Антропонимическая номинация в русском историческом романе: (10.02.01): Автореф. дис. на соиск. учен. степ. канд. филол. наук / Одес. гос. ун-т им. И.И. Мечникова. – Одесса, 1991. – 18 с.
3. Фәттах Н. Сайланма әсәрләр. – 5 томда. 3 том / Нурихан Фәттах. – Казан: татар. кит. нәшр., 2002. – 464 б.
4. Фәттах Н. Сызгыра торган уклар. Тарихи роман. Беренче китап / Нурихан Фәттах. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. – 344 б.
5. Фәттах Н. Сызгыра торган уклар. Тарихи роман. Икенче китап / Нурихан Фәттах. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. – 432 б.
6. Хатипов Ф. Тарихи жанрны үстерүче / Ф. Хатипов // Мирас. – 2004. – № 1. – 98-106 б.
7. Хатипов Ф. Әдәбият теориясе / Ф. Хатипов // Мәгариф. – 2000. – 351 б.
8. Шириязданов Р. Аның дәрте, дәрманы белән / Р. Шириязданов // Казан утлары. – 1978. – №10. – 162-170 б.

© Гарипова-Хасаншина В.М., 2024

УДК 070 + 17.022.1

**Гарифуллин В.З.,**
*Казан ш., Россия*

# ТАТАР БАЛАЛАР МАТБУГАТЫНЫҢ ТРАДИЦИОН КЫЙММӘТЛӘРНЕ САКЛАУДАГЫ РОЛЕ

***Аннотация:*** *татар телендәге балалар һәм балалар-яшүсмерләр өчен вакытлы матбугат басмалары гасыр дәвамында үсеп килүче буында туган якка, туган телгә, үз халкының мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләүгә зур өлеш керттеләр һәм бүген дә бу эшләрен дәвам итәләр. Алар булачак әдәбиятчыларның һәм журналистларның иҗади потенциалын ачуның төп мәйданына әверелде. Мәкаләдә татар телендәге вакытлы матбугатның барлыкка килү чыганаклары анализлана, аның үсешенең төп этаплары ачыла, балалар аудиториясе өчен медиа ресурсларның бүгенге торышы һәм алга таба үсеш перспективалары тасвирлана.*

***Терәк сүзләр:*** *газета, журнал, басма, медиа балалар, тел, әдәбият, тәрбия*

Быел татар телендә балалар өчен чыгып килүче ике басма үзләренең 100 еллык юбилейларын билгеләп үтте. «Ялкын» журналының беренче саны 1924 елның мартында Мәскәүдә «Кечкенәң иптәшләр» исеме белән дөнья күрә. Журналга нигез салучыларның берсе һәм баш мөхәррире күренекле шагыйрь Муса Җәлил була. «Сабантуй» балалар басмасы беренче тапкыр 1924 елның 10 октябрендә «Яшь ленинчы» газетасы буларак чыга һәм 2014 елда гына, аудитория ихтыяҗларын искә алып, журналга әверелә. «Яшь ленинчы» Советлар Союзының беренче балалар газетасы була. Хәтта «Пионерская правда» да аннан соң ярты ел узгач – 1925 елның мартында гына чыга башлый. Бу басмаларны булдыруның төп максаты коммунистик идеалларга бирелгән яңа, совет кешесен формалаштыру иде.

Шунысын да әйтергә кирәк, балалар өчен татар телендә беренче басмалар 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр, Россиянең аз санлы халыкларына билгеле бер хокуклар һәм ирекләр гарантияли торган 1905 елгы патша манифесты игълан ителү нәтиҗәсендә дөнья күрә. XX гасыр башында чыккан татар балалар басмаларының биш исеме (ике газета һәм өч журнал) булуы билгеле. «Галәме сабыян» (Балалар дөньясы) һәм «Мәктәбе сабыян» (Балалар мәктәбе) газеталары мәшһүр мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспринский тарафыннан Бакчасарайда «Тәрҗәман» газетасына кушымта рәвешендә нәшер ителә. Бу басмаларның беренче битләрендә гадәттә иллюстрацияле, тәрбияви эчтәлекле кечкенә хикәяләр, бүгенге балалар нинди булырга тиешлеге турында гыйбрәтле мәкаләләр, икенче һәм өченче битләрендә – укучылардан хатлар, кыска хәбәрләр, шаяртулар, шулай ук дүртенче биттә реклама урнаштырылган була. Кызганычка, бу газеталарның нибары биш саны гына сакланып калган [1; 5].

Моннан тыш, балалар өчен чын-чынлап мөстәкыйль өч басма чыга. Аларның беренчесе «Тәрбиятел-этфаль» (Балалар тәрбиясе) 1907 елның гыйнварында Мәскәүдә Заһид Шамил редакторлыгында басыла башлый. Ул үзе татар телен камил белмәгән, шуңа күрә редакция эшен күренекле язучы һәм журналист Фатих Әмирханга тапшыра. Журнал балаларга багышланса да, өлкәннәргә дә файдалы булыр өчен зур тырышлык куя. Бу фикер беренче санның баш мәкаләсендә дә чагылыш таба. Анда заманча белем алу, шулай ук илдәге һәм дөньядагы вакыйгалар турында мәгълүмат җиткерү зарурлыгы ассызыклана. Журнал тормышның барлык өлкәләрен дә яктыртырга тырыша. Җәмгыять тормышы, мәдәният һәм сәнгать, дин, фән, техника, күңел ачу һ.б. Журналда хикәяләр һәм

шигырьләр, дөнья һәм табигать турында мәгълүмат, укытучылар һәм укучылар өчен киңәшләр басыла. Һәр санда дөньяның төрле өлкәләреннән 10-15 ләп рәсем, «Белешмә бүлеге», «Көлке рубрикасы» һ.б. сәхифәләр урнаштырыла [2; 115-116].

Балалар өчен икенче журнал – «Ак юл» Аның нәшире һәм мөхәррире-Фәхрислам Агиев. Журнал 1913 елның 15 апреленнән 1916 елның 22 гыйнварына кадәр ике атнага бер тапкыр «Өмид» типографиясендә нәшер ителә. Барлыгы 67 саны бар. Басмада «Соңгы көннәрдә», «Актуаль тәрҗемәләр», «Хикәя», «Бабаларыбыз хикәяләре», «Хайваннар дөньясы», «Сәламәтлек» рубрикалары бар. Биредә шулай ук «бүлмәләр» дип атала торган рубрикалар да эшли – «башваткычлар бүлмәсе», «уен бүлмәсе» һ.б. Матур әдәбият әсәрләре – әкиятләр, кыска хикәяләр, тәрҗемәләр, повестьлар актив басыла. Фәнни хикәяләр дә күп урын алып тора, алар астрономия, физика, табигать белеме, геометрия буенча аерым цикллар булып та, мөстәкыйль материаллар буларак та чыга. Тарихи хикәяләр, риваятьләр, репортажлар, мәкаләләр, шигырьләр, әкиятләр дә очрый. Төрле кроссвордлар, чайнвордлар, башваткычлар басыла. Барлык материаллар да матур итеп иллюстрацияләнгән [2; 117].

Өченче журнал «Балалар дөньясы» исеме астында 1917 елның 1 мартыннан 1918 елның 22 гыйнварына кадәр Казанда Якуб Хәлили нәшриятында басыла. Басманың ешлыгы – аена бер тапкыр, ә кайчакта ике-өч тапкыр, барлыгы 8 номер чыга. Журналда рубрикалар юк диярлек. Бүлекләре генә бар – әдәби әсәрләр, шигырьләр, фәнни хикәяләр. Бары бер бүлектә генә «Күңел ачу» рубрикасы бар. Аерым рубрикалар булмауга карамастан, басманың программасында күрсәтелгән темаларга материаллар чагыштырмача төгәл урнаштырылган [Шунда ук].

Татар халкының рух һәм мәдәни тормышында балалар журналларының роле бәхәссез. Алар, бер яктан, мәдәният тарихын (кешелек тарихын, матди һәм рухи кыйммәтләрне) пропагандалаганнар, үз чорының мәдәни тормышын (музыка, театр, рәсем сәнгате, рәсем сәнгате, архитектура) яктыртканнар, икенче яктан – үзләре төрле чаралар оештырганнар («Шәрыкъ клубы», балалар кичәләре һ.б.). Балалар журналлары китап нәшрияты эшчәнлеге белән актив шөгыльләнгән. Югарыда аталган өч журнал редакциясе көче белән барлыгы 80 китап-кушымта басылып чыга.

XX гасыр башы балалар матбугаты энциклопедик характеры белән аерылып тора. Анда табигать белеме, биология, анатомия, география, астрономия, физика, химия, гуманитар фәннәр, әдәбият, этнография кебек фәннәрнең киң даирәсе чагылыш таба. Моннан тыш нәширләр нәни укучының дөньяга карашын киңәйтү өчен төрле башваткычлар, фокуслар, математик мәсьәләләр, фән һәм техника яңалыклары бастыра. Алар фәнне

популярлаштырып кына калмыйча, укучыны күренекле фән эшлеклеләре, дәүләт башлыклары, язучылар турындагы тәрҗемәләр белән дә таныштыралар.

Шулай итеп, беренче балалар журналлары аерым тормыш өлкәсе белән генә чикләнми, төрле өлкәләрне колачлый, үз укучыларының дөньяга карашын формалаштыра, аларны киләчәк олы тормышка әзерли. Алар татар журналистикасы тарихында лаеклы урын алып торалар.

Татар телендәге балалар матбугаты, беренче адымнарын ясап, әле аякка гына баскан бер вакытта, 1917 елгы Октябрь революциясе чорында һәм аннан соң, большевиклар тарафыннан патша Россиясе басмаларын бетерү, типографияләрне ябу һәм кәгазь запасларын алу буенча радикаль чаралар күрелә. 1917 елның 27 октябрендә Совет хөкүмәтенең беренче утырышында матбугат турында Декрет кабул ителә. Икенче көнне хакимият махсус карар белән большевистик булмаган басмаларны ябу буенча чараларны законлаштыра. Шулай итеп, 1917 елның октябреннән 1918 елның сентябренә кадәр Россиядә большевикларныкы булмаган вакытлы матбугат, шул исәптән балалар өчен басмалар да тулысынча юкка чыгарыла. Аларга алмашка коммунистик идеалларга тугрылыклы яңа кеше тәрбияләүгә юнәлдерелгән идеологик басмалар килә. Шулай итеп, 2024 елда татар телендә берьюлы ике балалар басмасы – «Ялкын» журналы һәм «Яшь ленинчы» газетасы пәйда булды.

Шунысы мөһим, балаларга адресланган яңа басмалар революциягә кадәрге вакытлы матбугат традицияләрен уңышлы дәвам итә. Моның сәбәбе – яңа заман балалар журналистикасында татар алдынгы интеллигенциясенең иң алдынгы идеяләрен һәм традицияләрен үзләштергән педагоглар, язучылар, журналистлар эшләвен дәвам итә. Алар – революциягә кадәрге мәдрәсәләрдә тәрбияләнгән һәм белем алган буын вәкилләре. Әйтик, хәзерге «Сабантуй» журналының иң беренче саны 1924 елның 10 октябрендә «Яшь ленинчы» исеме астында, газета форматында ул вакыттагы яшь язучы Афзал Шамовның кечкенә генә фатирында формалаша. Беренче мөхәррире комсомол активисты Шәһит Шаммазов була. Газетаның беренче саннарын чыгаруда язучылар Шамил Усманов, Госман Закир, Ибраһим Гази, Абдулла Алиш, Галимҗан Мөхәммәтшин, Ләбиб Гыйльми, Ибраһим Сәләхов, Шамил Гәрәй актив катнаша. Алга таба да татар әдәбиятының һәм журналистикасының күп кенә күренекле иҗат эшлеклеләре үз көчләрен беренче мәртәбә нәкъ менә балалар басмалары битләрендә сынап карый. Киләсе дистә еллар дәвамында алар үсеп килүче буында туган якка мәхәббәт, үз халкының мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә, туган телебезгә ихтирам һәм игътибар тәрбияләүдә үзләреннән зур өлеш кертеп килделәр.

«Яшь ленинчы» Бөек Ватан сугышы елларында «Кызыл Татарстан» газетасына кушымта буларак чыгарыла. Газета белән сугыш алдыннан хезмәттәшлек иткән күп кенә авторлар, шул исәптән Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим сугышта һәлак була. Басма 1961 елда баш мөхәррир Венера Ихсанова җитәкчелегендә яңадан чыга башлый. 1970 елларда газета 100 меңнән артык тираж белән басыла, бөтен Советлар Союзына тарала.

Пионер газетасы белән беррәттән «Ялкын» журналы да балалар арасында зур популярлык казанды. Аның беренче саны 1924 елның 20 мартында Мәскәүдә «Кечкенә иптәшләр» исеме астында дөнья күргән. Үзенең яшәве дәверендә басма берничә тапкыр исемен алыштыра. Мәскәүдә журнал 1924-1928 елларда «Кечкенә иптәшләр», 1928-1932 елларда «Октябрь баласы» исеме белән нәшер ителә. 1933 елдан башлап журнал Казанда басыла башлый (1933-1941 елларда – «Пионер каләме», 1951 елдан – «Пионер», 1957 елдан – «Ялкын»).

Бу урында татар телендә чыгучы ике балалар басмасының якын дуслыгы турында әйтеп узу да урынлы булыр. Алар үзара аралашуның һәм бер-берсен баетуның кызыклы формаларын табалар. 30 нчы еллар башында чыккан бер санда «Яшь ленинчы» мондый белдерү бастыра: «Мәскәүдә чыга торган «Октябрь баласы» журналына карата суд процессын башлыйбыз. Аның кимчелекләре, укучыга вакытында киләме һәм бала йөрәкләренә барып җитәме икәнлеге турында фикер алышачакбыз? Журналны яхшырту буенча сезнең теләкләрегезне җыярбыз». Шулай итеп, газета, беренчедән, укучыларның игътибарын Мәскәү журналына юнәлтә, икенчедән, журналны эчтәлекле, кызыклырак итү өчен «хаталар өстендә» зур эш башкара. «Суд процессы» биш ай дәвам итә, барлыгы 14 утырыш уза һәм журналның баш мөхәррире Муса Җәлил исеменнән зур җавап белән тәмамлана. Анда Җәлил Казан газетасы укучыларына Мәскәү журналына карата игътибарлары өчен рәхмәтен белдерә. Газета ярдәмендә журналның Татарстанда да популярлыгы арта, кызыклы яңа рубрикалар ачыла, аның тиражы арта, укучылар һәм хәбәрчеләр саны ишәя.

1991 елда «Яшь ленинчы» газетасының исеме «Сабантуй» дип үзгәртелә. 2014 елдан башлап «Сабантуй» журнал форматында чыга.

Шул рәвешле, бүген ике басма да, үзен укый торган аудиториянең мәнфәгатьләрен күздә тотып, журнал форматында чыга. Әгәр «Сабантуй» кече һәм урта яшьтәге балалар аудиториясенә йөз тотса, «Ялкын» нигездә өлкән яшьтәге балаларга һәм яшүсмерләргә юнәлдерелгән. Ике басмада да балаларның татар телендәге иң яхшы иҗади хезмәтләре: хикәяләр, шигырьләр, кроссвордлар, табышмаклар, ребуслар һ.б. басыла. Кайбер рубрикаларны балалар үзләре алып бара. Алар үзләренең мавыгулары һәм

хоббилары, бүгенге яшүсмерләр тормышынданиләр барганы турында сөйлиләр.

Совет балалар журналистикасының бай традицияләрен дәвам итеп, «Ялкын» һәм «Сабантуй» бүген үсеп килүче буынның иҗади потенциалын ачуның төп мәйданчыгы булып кала. Басма редакцияләре тарафыннан балалар бәйрәмнәре һәм иҗтимагый файдалы акцияләр, төрле иҗади конкурслар, танылган журналистлар һәм язучыларның мастер-класслары үткәрелә, балалар редколлегияләре актив эшли.

Үз аудиторияләрен киңәйтү өчен «Ялкын» һәм «Сабантуй» заманча технологияләрне һәм форматларны уңышлы үзләштерә, социаль челтәрләрдә тиз тарала. 2020 ел ахырында Татарстан Республикасында иң эре төбәк медиакомпаниясе булган «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте балалар басмалары белән берлектә «Татмедиа Junior» проектын башлап җибәрде [3]. Әлеге проект кысаларында төрле интернет-мәйданчыклар һәм социаль челтәрләр кулланучылары өчен дистәләрчә мультимедиа әсәрләре эшләнде. Контентны булдыруда балалар үзләре дә актив катнаша һәм шул рәвешле журналистика нигезләрен актив үзләштерә, милли медиа киңлекне иҗтимагый әһәмиятле һәм балалар аудиториясе өчен файдалы мәгълүмат белән тутыра.

Мәгълүмат өлкәсендәге тирән үзгәрешләр, медиаиндустриянең яңа моделен формалаштыру шартларында Татарстан Республикасында балалар массакүләм мәгълүмат чараларының бербөтен системасы уңышлы эшли, яшь аудитория өчен медиаресурсларның барлык төрләре дә эшкә җигелә. Мәгълүмат чаралары барлык булган платформалар һәм социаль челтәрләр аша балалар аудиториясен максималь дәрәҗәдә колачларга омтыла.

**Әдәбият исемлеге**

1. Галиәхмәтова А.Ф. ХХ гасыр башы татар балалар матбугаты. – Казан: Казан университеты, 2015. – 114 б.

2. Гарифуллин В.З. История татарской журналистики начала ХХ века. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2023. – 168 с.

3. Шамиль Садыков: «Татмедиа» лидирует по подписчикам в Telegram и развивает TikТок. [Электронный ресурс]. – Доступно на: URL: https://www.tatar-inform.ru/news/shamil-sadykov-tatmedia-lidiruet-po-podpischikam-v-telegram-i-razvivaet-tiktok (режим доступа – свободный).

© Гарифуллин В.З., 2024

УДК.398

**Гафарова Г.Ф.,**
*Краснокама районы,*
*Башкортстан Республикасы, Россия*

# КРАСНОКАМА РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ФОЛЬКЛОР ҮРНӘКЛӘРЕ

***Аннотация:*** *Краснокама районында лирик жанрлар: җырлар, такмаклар, мөнәҗәтләр,бәетләр киң таралыш алган. Алар бай һәм чагу. Халык иҗатында җирле халыкның мәдәнияте, идеаллары, сөйләме, сүз сәнгате ачык чагылыш тапкан.*

***Терәк сүзләр:*** *халык авыз иҗаты, фольклор, жанр.*

Халык иҗаты ул – халык вәкилләре тарафыннан телдән иҗат ителеп, күп еллар буе халык хәтерендә сакланып килгән чәчмә һәм шигъри әсәрләр җыелмасы. Халыкара практикада халык иҗатын билгеләү өчен фольклор атамасы да кулланыла. Фольклор сүзе 1846 елда галим Вильям Томас тарафыннан фәнгә кертелгән халыкара термин. Ул ике өлештән тора: folk – халык, lore – акыл, хикмәт дигәнне аңлата. Димәк, фольклор сүзен шартлы рәвештә халык акылы, халык хикмәте дип тәрҗемә итәргә мөмкин. [1; 5 ]

Бик борынгы заманнардан алып, бүгенге көнгәчә татарларда төрле фольклор жанрлары формалашкан, әмма һәр төбәктә алар үзгә һәм кабатланмас.

Күренекле фольклор һәм әдәбият галиме Марсель Бакиров татар халык иҗатының һәм традицион классик жанрларының төрләргә мөнәсәбәттә түбәндәгечә төркемләүне тәкъдим итә:

1) эпик жанрлар: әкиятләр, риваятьләр, легендалар, героик эпос-дастаннар, мәзәкләр.

2) лирик жанрлар: йола җырлары, лирик җырлар, уен-бию җырлары, такмаклар, мөнәҗәтләр.

3) лиро-эпик жанрлар: бәетләр, тарихи җырлар, мәхәбәт яки көнкүреш дастаннары.

4) драма башлангычы белән үрелгән иҗат төрләре: йола поэзиясе, халык уеннары һәм уен-бию җырлары, балалар фольклоры. [2; 5]

Краснокама районында икенче һәм өченче төркемгә караган жанрлар киң таралган. «Халык акылы», «халык хикмәте» канатлы гыйбарәләрдә дә шулай ук киң чагылыш тапкан. Күп гасырлар элек фольклор әсәрләрен иҗат итүдә, аларны халыкка таратуда кабилә башлыклары, чичәннәр зур тырышлык салса, безнең дәвердә җор телле апа, абыйларның роле зур. Туган якның тарихын, мәдәниятен өйрәнү –

шунда яшәгән халыкның авыз иҗатын өйрәнүдән башлана. Җирле тел осталары «хикмәте»ндә җирле халыкның яшәеше, көнкүреше, үткәне, киләчәге ачык чагыла.

**Лирик жанрлар.**

**Яшьлегем (өзек)**

**(Информант:** Габидуллина Хөмәйрә Госман кызы 1915 нче елгы, Яңа Бөртек авылы)

Мин әткәйгә бер генә,
Әнкәемә гөл генә,
Бергенә, гөл генә,
Иркәләнәм гел генә.
Ишегалды зур чирәм,
Шунды уйныйм, йөгерәм,
Куанам, йөгерәм,
Бер керәм дә, бер чыгам.
Абзарымда таем бар,
Кырда урман, тавым бар,
Кояшым бар көнемдә,
Йолдызым бар төнемдә,
Уйныйм бәхет көнемдә.

Шигырь балачакның иң күңелле, бер кайгысыз вакытлары турында. Әти-әниле булганда гына бала үзен «гөл» итеп тоя, рәхәтләнеп уйный һәм бәхетле була.

**Такмаклар**

**(Информант:** Борханова Хөмәйрә Гыйльметдин кызы 1939 нчы елгы, Яңа Хаҗи авылы)

**Мәхәббәт темасына**

Алсу алмалар төядем
Тартыр микән атларым?
Үзем кебек ачык итеп,
Сөйләр микән хатларым?
Ир бала-зәңгәр чәчәк,
Кыз бала-кызыл чәчәк,
Кызыл чәчәк, зәңгәр чәчәк
Берләргә бәйләнәчәк.

***Фәлсәфи такмаклар***

Агыйделләрне буйладым,
Уйладым тугайдыр дип,
Күп уйладым инде уйламыйм
Язмышым шулайдыр дип.

Су буйларыннан эзләдем
Сандугачның эзләрен,
Күрсәгез дә танымассыз,
Саргайды инде йөзләрем.

***Шаян такмаклар***
Машиналар хут барганда,
Асларыннан пар чыга,
Сандугач тотам дип йөреп,
Тотып калма карчыга.
Сөям сине, сөям сине
Сөям ышанасыңмы,
Ачлык еллар туры килеп,
Тотып ашамассыңмы?
Сөям сине, сөям сине
Үземә булсаң гына,
Ипи фәлән сорамыйча,
Бәрәңге ашасаң гына.

Такмакларның тематикасы төрле, үзәгендә – кеше һәм аңа бәйле ил язмышы. Халыкның җанлы теле «җырлый» аларда.

**Мөнәҗәт. Үлемнең каты хәле. (өзек)**
**(Информант:** Габидуллина Хөмәйрә Госман кызы)
Аналарны кыйла хәйран,
Тормышларны кыйла вәйран,
Әҗәл һәммәне аерган,
Иманымнан аерма, Аллам.
Сөйлим, балаларым, сезгә сүзләремне,
Сүзләремне түгел, моңнарымны,
Мин үлгәчтин, балаларым, укытың Коръән,
Тәрәзәләрдән килеп-килеп тыңлармын.
Зинһар әйтәм, балаларым, укытың Коръән,
Васыятем сезгә шул булыр.
Сез,балаларым, Коръән укытсагыз,
Кабер эчләремә нур булыр.

**Бәетләр** (Өзекләр)
**(Информант:** Бәдретдинова Хәлүдә
Хатыйп кызы 1954 елгы, Куян авылы)
Сине сагынып еласак та,
Язар идек, бармас хат та.

Беребез дә мәңге түгел,
Бу дөньяда без кунакта.
(«*Мөнир бәете*»)

Алтын көздә генә булган икән
Гомеремнең соңгы мизгеле.
Кичерегез мине, туганнарым,
Түземлекнең җебе өзелде.
(«*Миргасый абый бәете*»)

Жыйдың безне бүген яннарыңа,
Үзең бер дә безгә дәшмисең.
Әллә тыныч кына йоклыйсың син,
Ходай шулай кушкач, нишлисең.
(«*Зилия кодагый бәете*»)

Гадәттә, бәетләр «Тарих мең дә фәлән йөздә» яки «Бисмиллаһи вә билләһи» кебек сүзләр белән башлана. Хәлүдә Хатыйп кызы да вакыйганың кайчан булганын бәетнең башлам өлешендә күрсәтә:

Карсыз кышның унөченче декабре,
Карлы кышлары да түзелде.
(«*Зилия кодагый бәете*»)

Төзелешләре ягыннан бәетләр төгәл һәм төзек. Аларда, гадәттә, сүзләрне иске әйтелештә куллану хәзерге заман әсәрләрендә дә саклана, ә Хәлүдә апада бу күренеш күзәтелми...

**Яңа Бөртек халкы лексиконындагы сүзләр**

**(Информант:** Габидуллина Хөмәйрә Госман кызы)

Кордамал-юкка, тиккә, файдасызга; былагай-бәйләнчек, күп сөйләнергә яраткан кеше; зобани-явыз, алама; зурат-олы, биек. Рус диалектында «зарод» – озынча эскерт, киртәләп алынган кибәннәр төркеме [3; 2]; ирәвәнләп – җебеп, мескенләнеп тору. Ирү – «привал, диал. медленно, неторопясь» – борынгы төркиләрдә «Эриг» – тукталыш, эр-тукталу, ял итү сүзеннән [4; 2].

**Сурәтләү чаралары.** Куян каны кебек. Чәй куян каны кебек чыккан (куе, каты булып); йомырка тәгәрәтерлек тигез урын. **Фразеологизмнар.** Ип-сап булу – тәртипкә китерү, тәртипкә килү. Кылбырдыктан китерү-ашыктыру, кабаландыру. Ач теңкәне корыту-ялкыту. **Мәкаль-әйтемнәр.** Минәҗетдин элек туган, Гыйләҗетдин белеп туган. Көлмә кешедән, авызың өшегән, без үзебез көләбез синең кебек кешедән. Этле кунак өйгә сыймас. Алган чакта карчыга, биргән чакта җан чыга. Этнең койрыгын кем киссә, шуны җизнәм дип әйтер. Урыс мыегын

кисмәс, беркөйдән артык үсмәс. Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялый. **Теләкләр. (Информант:** Хәбибуллина БибисараМинигали кызы, 1931 елгы.) Күчеп китсәң дә, чәчеп кит. Күчеп киткән җирендә юлың уң булмаса да, кайтуыңа чәчкән икмәгең әзер була. **(Информант:** Габидуллина Хөмәйрә Госман кызы 1915 нче елгы, Яңа Бөртек авылы) Үзе калыксын, суы сарыксын. Баланы юганда әйтәләр.

**Җырлар**

**Такталачык**

**(Информант:** Гөлчирә Гыйльмегаянова,
Такталачык авылы)

Бакча артында ялгыз каен
Яфрак яра яз саен,
Шул каенга карап елыйм
Сезне сагынган саен.
Бакча артында ялгыз каен,
Текә яр итәгендә,
Сагынам да кире кайтам
Читләргә китәмен дә.
Шул каенның төпләрендә
Уйнадым яланаяк,
Сабый чагымны искә алам
Шул каеныма карап.
Юлга чыксам, борылып карыйм
Авылым якларына
Шушы җырларны җырлыймын
Сагынган чакларымда.
Суга барсам, сирпеп алам
Бидрәләрем тулганчы
Ялгызлык белән картлыкның
Ай.икесе булмаса.

Алда китерелгән кыска гына үрнәкләрдә дә Краснокама районы татарларының авыз иҗаты гаҗәеп бай һәм чагу икәне күренә. Аларда җирле халыкның мәдәнияте, идеаллары, сөйләме, сүз сәнгате ачык чагылыш тапкан.

**Кулланылган әдәбият**

1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы. – Татарстан китап нәшрияты,1995.

2. Әхмәтьянова Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимлогик сүзлеге. – Татарстан китап нәшрияты, 2001.

3. Ганиев Ф.Ә. Татарча-русча сүзлек. – Татарстан китап нәшрияты, 1998.

4. Гыйниятова З.М., Фәйзрахманов Х.Г., Шакирова Т.Р., Кадыйрова И.И., Татар халык иҗаты. Сүз эчендә хикмәт бар. – Казан: Мәгариф нәшрияты, 1999.

5. Сәйфуллина Ф.С., Җамалиева Л.Ф. Р.М. Мөхәммәтҗанов җитәкләгән фольклор практикасында тупланган шәхси кулъязмалар: Учебное методическое пособие. – URL: https://kpfu.ru/staff_files/F196794226/F.S._Zamalieva.Uch..Metod..posob..pdf

© Гафарова Г.Ф., 2024

УДК 811.512.141

**Ғөбәйҙуллина Р.В.,**
*Өфө к., Рәсәй Федерацияһы*
*Ғилми етәксеһе: ф.ф.к., доцент* ***Р.Я. Хөснөтдинова***

# ХӘҘЕРГЕ БАШҠОРТ ТЕЛЕНДӘ ПАРЦЕЛЛЯЦИЯНЫҢ ӨЙРӘНЕЛЕШЕ

***Аннотация*****:** *мәҡәләлә башҡорт телендә парцелляция күренеше һәм уның әйтемдең йөкмәткеһен интонацион-мәғәнәле телмәр берәмлектәренә (һөйләмдәргә) бүлеү сараһы булараҡ роле ҡарала. Башҡорт тел ғилемендә был конструкцияның өйрәнелеү дәрәжәһенә айырым урын бирелә.*

***Төп һүҙҙәр:*** *башҡорт теле, айырымланыу, парцелляция.*

Парцелляция термины башҡорт тел ғилеменә француз теленән (өлөшсә, киҫәксә) килеп инә. Рус телендә уны А.Ф. Прияткина, Л.Г. Хатиашвили, Л.Н. Константинов һ.б. күп ғалимдар өйрәнә, әммә беренселәрҙән булып профессор А.Ф. Ефремов ҡарай. Хәҙерге башҡорт телендә был күренеш өйрәнелә, ул синтаксик бәйләнештең үҙенсәлекле бер төрөн барлыҡҡа килтерә. Парцелляттар төп һөйләмдән һуң килеп, тамамланыу, йәғни үҙ аллы һөйләм интонацияһы менән әйтеләләр, төп һөйләмдән айырымланған булһалар ҙа, мәғәнәһе яғынан алдағы һөйләмгә бәйләнәләр һәм уның составына ҡарайҙар.

Был синтаксик алымды үҙ хеҙмәттәрендә проф. Ғ.Ғ.Сәйетбатталов, проф. Д.С.Тикеев һәм Ғ.Ғ.Ҡаһарманов ҡарай.

Башҡорт тел ғилемендә парцелляция күренешен ентекләп проф. Ғ.Ғ. Сәйетбатталов өйрәнә [2; 5]. Ғалим парцелляцияға шундай билдәләмә бирә: «Телмәрҙең тәбиғи ағышында, текста һөйләмдең баш

киҫәген йәки эйәрсән киҫәктәрен, йә булмаһа хәл әйтемен, эйәрсән һөйләмдәрҙе үҙ аллы һөйләм итеп биреү парцелляция тип атала» [2, 257]. Былдай синтаксик алым теге йәки был һөйләм киҫәктәрен йәки эйәрсән һөйләмдәрҙе актуалләштереү өсөн хеҙмәт итә, уҡыусының берәмектәренә йүнәлдерелә. Ғалим башҡорт телендә парцелляция күренешенең егерме ике төрөн күрһәтә. Мәҫәлән:

1. Һөйләмдең эйәһе үҙ аллы һөйләм сифатында бирелеп, актуалләшеп килә. Миҫал: Күмелгәновтың машинаһы ғына ул сафлыҡты бысрата алмай. *Һәм үҙе лә.* (И. Абдуллин «Ант итмәҫкә ант итәм».

2. Синтаксик конструкцияның хәбәре йәки хәбәрҙәре айырым һөйләм рәүешендә ҡулланыла, фраза баҫымына эйә була. Миҫал: Фекерҙәр һәм тойғолар бер-береһенә тап булып, ҡуш килгәндә, шатлыҡлы минуттарҙы беҙ бергә кисерҙек. *Кисерә киләбеҙ.* (М. Кәрим «Сәнғәтебеҙҙең йәме».)

3. Һөйләмдең аныҡлаусыһы үҙ аллы һөйләм итеп бирелә, ул үҙенсәлекле интонация менән уҡыла. Мәҫәлән: Бер егет булырға тейеш ҡыҙҙар араһында. *Көслө, намыҫлы.* (И. Абдуллин).

4. Синтаксик конструкцияның тултырыусыһы актуалләшеп килә. Һәҙиә Дәүләтшина апайға мин табыныу дәрәжәһендә һоҡлана торғайным. *Матурлығына, талантына, баҫалҡылығына.* (З.Биишева).

5. Артабан ғалим хәлдәрҙең һәр төрөнөң парцелляция күренешен барлыҡҡа килтергән осраҡтарына туҡтала

Ғ.Ғ. Ҡаһарманов парцелляцияны барлыҡҡа килтергән конструкцияларҙы *парцелляттар* тип атай. Уны айырымланыу менән сағыштырырға мөмкин, ти. Айырымланған киҫәк ни тиклем үҙаллылыҡҡа ынтылмаһын, ул барыбер һөйләм сиктәрендә хәрәкәт итә. Парцелляшкән киҫәктәр (парцеляттар) иһә һөйләмдең тышына сығарыла, йәғни бында һөйләм тышына сығарыу тенденцияһы сағылыш таба. Төҙөлөшө менән һөйләм ни тиклем ҡатмарлы берәмек булһа ла, бөтәһен дә һыйҙырып бөтмәй, хатта бөтә лә алмай. Бер үк контекста әйтелеп бөтмәгән, әммә актуалләшкән һәм экспрессивлыҡ хас булған берәмектәрҙе парцелляттар юлы менән биреү юлы бар [1; 85]. Автор шундай миҫалдар килтерә:

Парцеллят эйәләр: Кеше рухын әҙәбиәт, сәнғәт кенә түгел, фәндәр ҙә өйрәнә. *Дин дә, педагогия менән психология ла.* (Ватандаш).

Парцелләшкән хәбәрҙәр: Ауылым, ауылдаштарым тураһында яҙыу – ғүмерлек хыялым. *Хыялым да, бурысым да.* (Р. Солтангәрәев).

Тура һәм ситләтелгән тултырыусыларҙың парцелләшеүе.

Хәҙерге заман техникаһы әллә ниндәй ҡатмарлы документтарҙы бынамын тигән итеп күсереп бирә ала. *Хатта аксаны ла* (Заман-Башҡортостан).

Парцеллят хәлдәр: Сәғәтенә ҡарағайны – туҡтаған. Армияла командиры бүләк иткәйне. *Оҫта ҡулдары өсөн.* (Шоңҡар).

Аныҡлаусының парцелләшеүе: Ҡарайылға буйынан үткәндә шәшке күрҙе Заһит. *Елле. Аҡ билбаулы* (Шоңҡар).

Проф. Д. С. Тикеев был күренеште өҫтәлмә конструкциялар тип атай һәм тәбндәгесә аңлатма бирә: «Өҫтәлмә конструкциялар – һөйләм киҫәктәре һәм һөйләм араһындағы урта позицияла тороусы күренеш, улар, интонацион үҙ аллылыҡҡа эйә булыу сәбәпле, төп һөйләмдән ситкә сығарыла алһалар ҙа, мәғәнәүи күҙлектән алдағы һөйләм составына ҡарарҙар һәм төп уй-фекерҙе белдереүсе һөйләм менән бер синтаксик бөтөнлөктө тәшкил итәләр. Бәйләнеү саралары буйынса өҫтәмә конструкциялар теркәүесheҙ һәм теркәүесле, бәйләүесheҙ һәм бәйләүле булалар. Теркәүесheҙ бәйләнгән өҫтәлмә конструкицялар төп һөйләм менән тығыҙыраҡ бәйләнештә торалар, сөнки төп уй-фекерҙе белдереүсе һөйләмдән башҡа улар аңлашылмайҙар һәм граматик йәһәттән үҙ аллы булмайҙар [3; 158]. Мәҫәлән: Һыуҙың тәмен һәм составын боҙалар. *Бигерәк нефть эшкәртеү, химия заводтары*. (И.Абдуллин). Теркәүесле өҫтәмә конструкцияларҙы барлыҡҡа килтереүҙә теҙеү һәм эйәртеү теркәүестәре – йышыраҡ, ә бәйләүестәр һирәгерәк ҡулланыла, һәм уларҙың мәғәнәләре бәйләүсе мәғәнәүи биҙәктәренә бәйле үҙгәрелә: Ҡыҙрастың бөтөнләй кәйефе боҙолдо. *Хатта ул ҡош булып та һайрамай башланы.* (З.Биишева).

Үрҙәге тикшеренеүҙәрҙә килтерелгән миҫалдар нигеҙендә шуны әйтергә мөмкин: парцелляция матур әҙәбиәттә, йәнле һөйләү телендә йыш ҡулланылған синтаксик-стилистик сараны тәшкил итә. Үҙенсәлекле стилистик саралар булараҡ, улар публицистик әҫәрҙәрҙә лә урын ала. Парцелляттар булып һөйләмдең барлыҡ киҫәктәре лә, һөйләм төрҙәре лә ҡулланыла. Был берәмектәрҙең һөйләмдең мәғәнәһенә баҫым яһауҙы арттырып, өҫтәмә мәғәнә белдереүҙәрен көсәйтеп ебәргән саралар бик ентекләп өйрәнелмәгән әле.

**Әҙәбиәт исемлеге**

1. Ҡаһарманов Ғ.Ғ. Башҡорт теленең ябай һөйләм синтаксисы. – Стәрлетамаҡ, 2003.

2. Сәйетбатталов Ғ.Ғ. Башҡорт теле. 1-се том. Ябай һөйләм синтаксисы. – Өфө, 1999. – 351 бит.

3. Тикеев Д.С. Хәҙерге башҡорт теле. Ябай һөйләм синтаксисы. – Өфө: Ғилем, 2002. – 178 бит.

4. Тикеев Д.С., Тикеев Ф.С. Хәҙерге башҡорт теле. Синтаксис. – Өфө: Ғилем, 2008 . – 376 бит.

5. Иҫәнғолова Г.А., Хөснөтдинова Р.Я. Ғәли Ғәли улы Сәйетбатталов – ғалим һәм педагог (тыуыуына 95 йыл тулыуға ҡарата). В сборнике: Хәҙерге төрки филологияһының көнүҙәк мәсьәләләре. Күренекле башҡорт ғалимдары Ғ.Ғ. Сәйетбатталов һәм Н.Х. Ишбулатовтың тыуыуына 95 йыл тулыуға арналған II халыҡ-ара фәнни ғәмәли конференцияның материалдар йыйынтығы. Уфа, 2023. – С. 6-11.
© Губайдуллина Р.В., 2024

УДК 811.512.145

**Еникеева Д.Д., Зарипова И.Ф.,**
*Уфа ш., Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГЕНДЕР КОМПОНЕНТЛЫ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация:*** *мәкалә татар телендә гендер компонентлы фразеологизмнарны тасвирлауга багышланган. Хезмәттә тотрыклы берәмлекләрнең гендер компонентларының лексик-семантик классификациясе тәкъдим ителә.*
***Терәк сүзләр:*** *татар теле, лексикология, фразеология, фразеологизм, гендер компонент.*

Телнең лексикасы һәм фразеологик катламы халыкның тарихын, географиясен, иҗтимагый-сәяси төзелешен, яшәү шартларын, көнкүрешен барлык билгеләре, үзенчәлекле яклары белән чагылдыру сәләтенә ия. Тел үзе тәэмин иткән халыкның мәдәни-тарихи хәзинәләрен саклый, шулай ук хәзерге заман белән бәйле фактларны да ачып сала. Шул сәбәпле фәндә телнең мәдәни трансляторы ролен үти торган фразеологик әйтелмәләрне өйрәнү ихтыяҗы һәрвакыт булган һәм хәзер дә кимеми.

Фразеология фәненең үсешенә француз лингвисты Ш. Балли (1865–1947) идеяләре йогынты ясый (Балли, 1955). Фразеология, мөстәкыйль тел тармагы буларак, ватан тел белемендә XX гасырның 40 нчы елларында формалашып җитә. Рус фразеологиясе турында беренче теоретик мәгълүматлар А.А. Потеобня (1894, 1976, 1999), И.И. Срезневский (1873), Ф.Ф. Фортунатов (1898) хезмәтләрендә бирелә. 50 нче елларда В.В. Виноградов хезмәтләрендә фразеологиягә кагылышлы төп төшенчәләр ачыклана, өйрәнү бурычлары билгеләнә, юнәлешләр күрсәтелә (1947, 1954, 1959, 1972). Алга таба фразеологизмнар, телнең

структур берәмлекләре буларак, А.И. Смирницкий (1952, 1954, 1956), О.С. Ахманова (1957) хезмәтләрендә яктыртыла, шулай ук фразеологизмнарны төркемләү, аларның составы, ясалыш-структур үзенчәлекләре, семантикасы, лексикографик тасвирлау, лингвокультурологик аспектта тикшерү, башка телләр белән чагыштырып өйрәнү белән бәйле мәсьәләләр В.Л. Архангельский (1960, 1964, 1968, 1969, 1978), Н.Н. Амосова (1951), В.П. Жуков (1978, 1986), А.В. Кунин (1970), Н.М. Шанский (1957, 1969), В.М. Мокиенко (1986, 1989, 1990), В.Н. Телия (1986, 1996) һ.б.ның хезмәтләрендә чагылыш таба. Төрки телләрдә фразеологизмнарны өйрәнү дөнья һәм рус филологларының фәнни эзләнүләре белән параллель алып барыла [1].

Татар телендә дә фразеологик берәмлекләрнең төрләрен һәм үзенчәлекләрен өйрәнүгә, аларны системага салуга багышланган хезмәтләр мәгълүм. Мәсәлән, Ш.А. Рамазанов (1954), Г.Х. Әхәтов (1954, 1975), Л.Җәләй, Н.Б. Борһанова, Л.Г. Мәхмүтова (1957), Г.Х. Ахунҗанов (1972), Р.А. Йосыпов (1980, 2000, 2007), С.Ш. Поварисов (1982), В.Х. Хаков (1999), Ф.С. Сафиуллина (1979, 1999, 2001), Х.Ш. Мәхмүтов (1999, 2008) кебек галимнәрнең хезмәтләрендә татар фразеологиясе төрле яклап тикшерелә: «фразеологизм» һәм «фразеология» төшенчәләренә билгеләмә бирелә, фразеологизмнарның сүзләрдән һәм гади сүз тезмәләреннән аермасы аңлатыла; бу төр әйтелмәләрнең барлыкка килү, туплау, аларны төркемләү мәсьәләсе кузгатыла; фразеологик әйтелмәләрнең стилистик кулланылышы яктыртыла, аларның семантик, грамматик һәм лексикографик үзенчәлекләре тасвирлана, башка телләргә тәрҗемә итү проблемалары турында сөйләнелә, этимологияләре ачыклана һ.б. [1]

Тел белемендә фразеологизмнарга багышланган хезмәтләрнең күп булуына карамастан, «фразеологизм категориясе» төшенчәсе конкрет билгеләнмәгән, төр һәм күләм-состав мәсьәләсе хәл ителеп бетмәгән. Телдәге кыска әйтелешле, составлары буенча бөтен булган, телдә әзер килеш саклана һәм кулланыла торган һәр төрле әйтем-тәгъбирләрне (мәсәлән, канатлы сүзләрне, мәкаль һәм әйтемнәрне, атама-терминнарны, афоризмнарны һ.б.) фразеологизмнар составында карауны хуп күрүчеләр аз түгел. Татар фразеологизмнарының компонентларын тикшерүгә багышланган хезмәтләр дә таләп ителә. Мәсәлән, гендер компонентлы фразеологизмнарга багышланган махсус хезмәтләрнең бүгенге көндә бик аз булуы безнең тарафтан сайланган теманың актуальлеген билгели. Мондый фразеологизмнарны компонентларының лексик-семантик үзенчәлекләре буенча түбәндәге төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин:

**1. Фразеологизмнарда гомуми мәгънәгә ия булган гендер компонентлар**:

- *Ашыкма,* ***кызым,*** *абынып егылырсың* – ашыккан кешегә төрттереп әйтем;
- ***Ир-ат*** *арасы* – элек татар хатын-кызларына ирләр арасында буталып йөрү гаеп саналганда һәм, гаиләдән тыш, ирләр үзенә, хатын-кызлар үзенә бүленебрәк яшәгәндә ирләр төркеме "ир-ат арасы" дип йөртелгән;
- ***Малай*** *актыгы* – малайның соңгысы, соңгы калдыгы, чиктән арткана, әле булса малайлыгын ташлый алмаганы мәгънәсендәрәк шелтәләп әйтем;
- ***Егет*** *дисәң дә* ***егет*** – һәр яктан егет сыйфатлы, чын егет табигатьле буйдак ир.

**2. Фразеологизмнарда иҗтимагый-сәяси төшенчәләрне белдерүче гендер компонентлар**:

- ***Әби патша*** *заманында* – бик күптән, әллә кайчан;
- *Андый гына* ***патша кызында*** *да була* – кечерәк гаепне кичереп үткәрергә тиешлек хакында;
- ***Хан кызының*** *кулы кубыз тотып кабарган* – астыртын көлеп әйтем;
- ***Хан*** *юлы* – киң, такыр юл. Хәзер юл ачык, семафор ачык дигән мәгънәдә әйтелә;
- *Чикмән тула* ***бай улы*** – элек җан исәбе алганда татар крестьяннары хөкемәткә эләкмәс өчен үз фамилияларен юри төрлечә борып әйтүләреннән берсе.

**3. Фразеологизмнарда һөнәр атамаларын белдерүче гендер компонентлар**:

- ***Кендек әбисе*** – элек акушеркалар булганчы бәбине тудырышкан, кендеген кисеп, юып бәйләгән әби;
- *Суык* ***дипломат*** – базар дипломаты. Агай-эне арасында закон сатып, ашап-эчеп йөрүче, ходатай;
- *Салкын* ***тимерче*** – тимер чиләк-савытлар төзәтүче, төпләүче;
- *Сукыр* ***аучы*** *кыек атып туры тидергән шикелле* – сәләтсез кеше дә көтелмәгәндә әллә нидә бер ялгыш атып туры тидерүенә, уңышлы ирешеп куюына мисалдан әйтем.

**4. Фразеологизмнарда кешене характерлаучы гендер компонентлар**:

- ***Ил кызы*** – һөнәре, сәнгате белән яки илгә күрсәткән каһарманлыгы белән дан тоткан хатын-кыз;

• ***Итәксез хатыннар*** – үз идеалына, үз максатына ирешү юлыннан, көрәштән баш тарткан, качкан ирләргә, дезертирларга карата мыскыллы әйтем;

• ***Фәсле малай*** – элекке патша Россиясендә эшләнгән рус аракысы. Шешә башы кызыл сургуч белән пичәтләнгән булуы белән кызыл фәс кигән төреккә охшатып әйтелгән. Малай диелү-шуның ярты шешәсе;

• ***Шома егет. Тәти егет*** – тыштан көяз, франт, булдыклы күренгән, арты ничек булып чыгуы шиклерәк егет;

• ***Сәхрә малай*** – мәдрәсәгә яңа килгән кала күрмәгән авыл малаен башта байтак вакыт шулай дип йөргәннәр.

**5. Фразеологизмнарда кеше исемнәрен белдерүче гендер компонентлар**:

• *Эшең бетте, **Зөбәйдә*** – шушының белән эш тәмам димәктән. Эш төшкәндә генә кирәк булып, эш беткәч кирәге калмаган кеше хакында;

• *Бер сәгатьлек **Хәлифә*** – очраклы рәвештә, кыска гына вакытка башлык урынына куелган кеше турында;

• ***Фатыйманың** кашы кара дип... **Фатыйманың** кара кашы өчен* – якын кешеләрне танышлык юлы белән эшкә урнаштыру хакында;

• *Аны **Мәнди** анасы да белә* – аңгыралык мисалына әйләнгән. Мәнди нәселе тиле булып, анасы да шундый булган, ул Гөләп җиңги исеме белән китерелә;

• *Бер җирдә ике **Сөләймән**, берсенә әйтсәң берсе сөмәйгән* – берсенә бер сүз әйтсәң, икенчесенең хәтере кала торган ике кеше турында;

• ***Әмәк** белән **Шәмәк*** – бер-беренә тагылып йөрүче, аерылмас дуслар турында.

**6. Фразеологизмнарда тарихи шәхесләрнең исемнәрен белдерүче гендер компонентлар**:

• *Тугры **Тукай*** – шагыйрь Габдулла Тукай кешенең кем булуына карамыйча турысын әйтеп сөйләшкән каһарман йөрәкле кеше булган һәм шулай ук күңелендәге хисен дә турыдан әйтеп язган;

• ***Гиппократ** оныклары* – врачлар;

• ***Сталыпин** галстугы* – муенга кидереп дарга асып үтерә торган бау. 1905 нче елдан соңгы реакция елларында Столыпин эчке эшләр министры булган чорда әйтелгән әйтем;

• ***Сәетбаттал** китабы чаклы* – сүзең озын булды дигәннән.

**7. Фразеологизмнарда яшь үзенчәлекләрен белдерә торган гендер компонентлар**:

• ***Ак бабай*** – бабай кешене исеме белән исемләмичә, кадерләп, олылап эндәшү сүзе;

• ***Ак карт атай*** – әнинең бабасының бабасы;

• ***Ак сакаллы карт*** *булган булыр идем* – тәҗрибә җитмәүдән бер хата эш эшләгәнгә үкенеч белдергәндә китереп әйтелә;

• ***Әбисен*** *таныту* – кыйнау, тукмау;

• *Әпчи* ***карчык*** – күп сөйләүчән, һәр нәрсәне төпчеп сораша торган, тикшереп, акыл өйрәтеп торырга яратучан хатын-кызга карата әйтелә.

**8. Фразеологизмнарда туганлык атамаларын белдерә торган гендер компонентлар**:

• *Төп* ***кодалар*** – кияү яки киленнең ата-анасы, туганнары;

• *Эшең бетте,* ***кодагый*** – шушының белән эш тәмам димәктән;

• *Назлы* ***кияү*** – аш-су, кунак-сый иркәсе;

• *Үзебез тапкан мал түгел,* ***атай*** *тапкан җәл түгел* – ата-анадан мираска калган малны кадерсезләп, туздырып бетерү турында

• *Җиде* ***бабадан*** *килгән* – бик күптәнге, борынгы; борынгыдан мирас булып калган;

• ***Биатайныкы*** *ярылды* – кинәт булган эш яки кинәт ишетелгән тавыш турында.

**9. Фразеологизмнарда милләт үзенчәлекләрен белдерүче гендер компонентлар**:

• ***Мукшының*** *уңган килене аяк өсте ашый* – ашыгыч һәм утырыр өчен урын җитмәүдән табын янында тәлинкәсен күтәреп аяк өсте ашарга туры килүгә мисалдан әйтәләр;

• *Ат ите ашаганга кызыккан* ***урыс малае*** *кебек* – кешенең үзенә ярамаган берәр нәрсәгә ымсынуына карата әйтелә;

• *Сакаллы* ***марҗа*** – гайбәтче ир, ялачы, доносчы, сатлык, шпик;

• *Базар* ***марҗасы*** *кебек* – үзен тупас, кадерсез тотып кешеләр белән әдәпсез кычкырынып мөгамәлә итүче, вак сатулашучыга карата әйтелә;

• *Хәерче* ***марҗа*** *төенчеге* – җыен вак-төяк әйбер җыентыгы.

**10. Фразеологизмнарда дини тематикага караган гендер компонентлар**:

• *Андый гына* ***мулла кызында*** *да була* – кечерәк гаепне кичереп үткәрергә тиешлек хакында;

• ***Хур кызы*** – оҗмах кызы, гомерлек яшь, гүзәл кыз;

• *Кәткән* ***мулла*** *зур елый* – киселгән чыбык шахмакларыннан чиертке уйнаганда кисәтү урынындда әйтелә;

• ***Мәчет карты*** – олыгайгач мәчеткә намазга йөрүче диндар карт.

**11. Фразеологизмнарда хәрби өлкәгә караган гендер компонентлар**:

• *Ак* ***офицер*** – ак армия офицеры;

• *Атлы* ***казак*** *булма* – гел үрә басып әтәчләнергә, гайрәт орып кешегә команда бирергә, җикеренергә яратучыга кисәтү урынында әйтелә;

• *Атлы* ***казак*** – Россия патшалыгында Дон далаларында атманнар җитәкчелегендәге махсус атлы гаскәри халык.

**12. Фразеологизмнарда әкият геройларын белдерүче гендер компонентлар**:

• ***Камыр батыр*** – татар әкиятендә камырдан әвәләнеп дөньяга килгән батыр;

• ***Алпамыш батыр*** *йокысы* – көн-төн сузылган тирән йокы;

• ***Су анасы*** *кебек гүзәл* – ямьсезлеккә мисалдан;

• ***Сихерче карчык*** – әкиятләрдә сурәтләнгән явыз рухлар белән эш итүче, им-томчы карчык;

• ***Җен карчыгы*** – мәхәббәтсез, тискәре.

**13. Фразеологизмнарда фауна өлкәсенә караган гендер компонентлар**:

• ***Ана бәпкә*** – түбә кыегындагы ике атламаның ырмаулысы, киртлесе;

• ***Кортның анасы*** *эләкте* – төп җитәкче, башчы кулга төште, иярченнәре үзеннән-үзе безнең кулда димәктән;

• *Тол* ***ата каз*** – үзеннән нәсел калдырмаган тол ата каз корыга буйсынын катырып, бушка муенын сузып, каранып йөргән кебек, балачагасыз кешенең дә корыга җан саклап, җыен чүп-чар эш эшләп көн күрүенә ишарә;

• ***Ата казыгыз*** *күкәй саламы* – сүзе булмаган килеш бер дә урынсыз, ахмак сүз сөйләп куйган кешегә: – ата казыгыз йомырка саламы дигән кебек булды бу, – дип ишарә белән әйтелә;

• ***Бүре малае*** – кешеләр белән аралашмыйча, кешегә буйсынмыйча үз иркендә яшәүче турында.

Кайбер фразеологизмнар составында **ике гендер компонент бергә килү очраклары** да күзәтелә. Мәсәлән:

• *Безнең* ***кыз*** *да бер* ***кияү*** *күрсен дигән кебек* – кешедән калышмаска, ким күренмәскә тырышуга мисалдан;

• ***Атасы-анасы*** *юк* – рәте-чираты юк, төпсез, рәтсез эш, рәтсез сүз;

• *Кыланышының* ***атасы-анасы*** *юк* – тәрбиясез, байлык яки дәрәҗәсен күтәрә алмыйча әллә кем булып сөйләшүче, үзен дәрәҗәсенә күрә тота белмәүче турында;

• ***Кодалар*** *килде капкага,* ***кыз*** *утырды кабага* – эш тәмам актык чиккә килеп терәлгәч кенә кузгалып хәрәкәт итүчеләргә карата.

Шулай итеп, фразеологизмнар — сөйләмне бизәп, образлы итеп тасвирлый торган чаралар. Аларның составында төрле сүзләр катнаша, һәрберсендә үзенчәлекле мәгънә ята. Фразеологизмнар арасында гендер компонентлы фразеологизмнарның да булуы даими күзәтелә. Алар татар фразеологик фондында аерым урын алып тора. Гендер компонентлы фразеологизмнарны системалы рәвештә туплап, гендер компонентына нигезләнеп төркемнәргә бүлү аларның үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итә.

### Әдәбият

1. Зәкиев М.З., Галиуллина Г.Р. Татар лексикологиясе. Өч томда. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т.I. – 352 б.

2. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. I Том – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989.

3. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. II Том – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989.

© Еникеева Д.Д., Зарипова И.Ф., 2024

УДК 398.91

**Закирова И.Г.,**
*Казан ш., Россия*

## АЙ ҺӘМ ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ БЕЛӘН БӘЙЛЕ АТАМАЛАР (МӘКАЛЬ-ӘЙТЕМНӘР МИСАЛЫНДА)

***Аннотация:*** *бу мәкаләдә календарьларның килеп чыгышы һәм таралышы, ай исемнәренең татар телендә фольклор фәне контекстында барлыкка килүе һәм яшәеше турында мәгълүматлар бирелгән. Ай исемнәрендә татар халкының бәйрәмнәре, аның хуҗалык эшчәнлегенең төп төре – игенчелек һәм терлекчелек белән бәйле терминнар сурәтләнгән. Көнкүрештә берничә календарь булган, аерым алганда, кояш календаре буенча ел язгы көн белән төн тигезләшү чорыннан башланган. Айларның исемнәре, мәсәлән, Нәүрүз, Әмәл, Сөмбел исемнәре календарь бәйрәмнәр исемнәрендә сакланып калган. Хезмәттә һәр төргә кыскача характеристика бирелә, үткән еллардагы тикшеренүләр тасвирлана, ай исемнәренең этномәдәни маркировкаланганлыгы, аларның халык ышанулары белән үзара бәйләнеше ачыклана.*

***Тeрәк сүзләр:*** *татар фольклоры, календарь, ай исемнәре, мәкальләр.*

Бу мәкаләдә төрле чыганакларда сакланып калган ай исемнәрен, ай исемнәре белән бәйле мәгълүматны барлап, укучыларның да исенә төшерергә телибез.

Ерак бабаларыбыз кулланган календарь исәбе, ел һәм ай исемнәре төрле чыганакларда, халык иҗатында сакланып калган. Мәсәлән, телдә аерым йолаларга бәйле рәвештә әмәл, сөнбелә дигән ай исемнәрен ишеткәнебез бар. Әби-бабаларыбыз әйтә торган «*Хәмәлдә әмәлеңне корытырмын, дигән» яки «Хут керде, хатыннар артына ут керде*» кебек мәкальләрне хәтерләгәннәр әле дә бардыр. Болар – татар халкында XX йөз башларына кадәр гамәлдә булган ай исемнәре. Чилләгә капма-каршы мәгънәне биргән гыйнвар суыкларын белгерткән *акман-тукман* дигән сүзләр дә ишетүчеләр бардыр. Алары тагын да борынгырак, әмма безнең ата-бабаларыбыз да кулланган төрки календарьдагы ай исемнәре.

Татар телендә хәзерге вакытта борынгы римлыларның рус теле аша кергән ай исемнәре гамәлдә. Нәкый Исәнбәт бу календарь турында: «Россиядә Петр Беренче тарафыннан кертелгән календарь системасы бездә XIX гасырның икенче яртысында гына ныклап җирләшә» дип яза [1; 435]. Хәзерге вакытта гамәлдә булган григориан календаренда ай исемнәре татарларга да кулланыла, алар озак вакытлар фонетик яктан халык теленә яраклаштырып кулланылган. Мәсәлән, Нәкый Исәнбәт, аларның халык телендәге үзенчәлекләрен саклап, түбәндәгечә тәкъдим итә: гыйнвар, фибрал, март, април, май, июн, июл, аугыс, үктәбер, нүябер, дикәбер. Мәкаль-әйтемнәрдә дә ай исемнәре шул рәвешле кергән. Бу яңгыраш өлкән буын телендә әле дә саклана. Әдәби телгә бары гыйнвар атамасы гына кергән, хәзерге вакытта алар рус телендәге атамалар белән тәнгәл яңгырый. Григориан календаре буенча айларда көннәр саны 30 һәм 31 булып, бары февраль ае гына 28 яки 29 көннән тора. Халык кайсы айда ничә көн булуын онытканда кул бармакларын йомарлап санап карый.

Мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗани «<u>Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар</u>” дигән хезмәтендә татар халкының ай атамалары турында тулы мәгълүмат бирә: «Әмма мөселманнар һәр очракта һиҗри тарихны кулланып, айларны: «Мөхәррәм, сәфәр, шәһре рәбигыль-әүвәл, шәһре рәбигыль-ахир, җөмадиел-әүвәл, җөмадиел-ахир, рәҗәб, шәгъбан, шәһре рамазан, шәүвәл, зөлкагдә, зөлхиҗҗә», – дип саныйлар. Фәкать игенчелек эшләре өчен, кояш хисабы белән яз башыннан башлап, «хәмәл, сәвер, җәүза, саратан, әсәд, сөнбөлә, мизан, гакърәб, кавыс, җәди, дәлү, хут» дип, гарәби исемнәр кулланалар. Ә кайчакта, мөселман гарәпләрдә йөртелгән сөрьяни исемнәр белән, «азәр, нисан, айяр, хәзиран, тәммүз, аб, эйлүл, тиш-рин әүвәл, тишрин сани, кянун әүвәл, кянун сани, шобат» дип саныйлар» [2; 379]. Галим бу өзектә татар халкында өч төрле ай исемнәренең параллель куллануын күзәтә: беренчесе мөселманнарның ай

календаре, икенчесе хәмәл белән башланган Кояш календаре, өченчесе Борынгы Сирия халкыннан таралган гарәп ай исемнәре.

Татар халкында бөтен мөселман дөньясы өчен уртак ай каленьдаре да кулланылышта. Ислам белән бәйле бәйрәмнәрне, йолаларны һәм намаз вакытын шушы ай календарена карап беләбез. Мөселман ай календаре милади белән 622 елның 16 июленнән, Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә күченү вакытыннан башлана. Һиҗрәт гарәп теленнән күчүне белдереп, календарьның исеме дә шуннан алынган. Бу календарьның һиҗри календарь дигән исеме дә шуның белән бәйле. Ай календаренда ел мөхәррәм ае белән башлана. Һәр ай яңа ай туу белән башлана. Шуңа күрә милиди белән һиҗри еллар арасында 10 яки 11 көн аерма бар. Ай календаренда көннәр айга бәйле рәвештә күчеп йөри, алар аерым вакытка да, ел фасылларына да бәйле түгел.

Ш. Мәрҗани хезмәтендә Олуг Кавал имамы мелла Сәлимҗан бине Дустмөхәммәд исемле кешенең китабына да таянып календарь системалары турында мәгълүмат бирә: «И аңлы кеше, бел, кояш елының өч төрле хисабы бар: берсен – «фарсилар хисабы» диерләр. Аның белән Болгар кешеләре файдаланганнар. Берсенә – «Румия хисабы» диерләр. Аның белән христианнар файдаланганнар. Берсе белән барлык шәһәрләрдәге мөселманнар файдаланганнар. Димәк, хәмәл хисабын барлык мөселманнар белергә тиеш, чөнки намаз вакытлары аның белән беленә, кояш баю аның белән беленә» [2; 379].

Татар халкында ай исемнәренең тагын берсе, зодиак билгеләре исемнәренә нигезләнгәне булган. Алар да бүгенге көндә тулысынча онытылып, хәзерге вакытта мәкаль-әйтемнәрдә, әдәби әсәрләр текстларында, фәнни хезмәтләрдә сакланып калган. Ш. Мәрҗани хәмәл белән башланган ай исемнәрен татар халкы игенчелеккә бәйле рәвештә кулланылуын күрсәтә. Күк йөзе кояш уза торган линия буенча 12 өлешкә бүленеп, ай исемнәре кояшның кайсы йолдызлыкта булган вакытыннан чыгып санала: *Хәмәл – сарык бәрәне, март ае; Сәвер – үгез, апрель ае; Җәүза – игезәкләр, май ае; Сарәтан – кысла, июнь ае; Әсәд – арыслан, июль ае; Сөнбөлә – ашлык башагы, август ае; Мизан – үлчәү, бизмән, сентябрь ае; Гакърәб – чаян, октябрь ае; Кавыс – җәя, ноябрь ае; Җади – кәҗә бәтие, декабрь ае; Дәлу – су чиләге, гыйнвар ае; Хут – кит балыгы, февраль ае.*

Бу календарь мөселман ай календареннан аермалы буларак, билгеле бер көндә – язгы көн белән төн тигезләшкән март аенда башланып, һәр айның тотрыклы вакыты һәм көннәр саны бар:

Хәмәл – 31 көн, 21 март – 20 апрель. Кучкар йолдызлыгы; Сәвер – 31 көн, 21 апрель – 21 май. Үгезбозау; Җәүза – 31 көн, 22 май – 21 июнь. Игезәкләр; Саратан – 31 көн, 22 июнь – 22 июль. Кысла; Әсәт – 31 көн, 23

июль – 22 август. Арыслан; Сөмбелә – 31 көн, 23 август – 22 сентябрь. Кыз; Мизан – 30 көн, 23 сентябрь – 22 октябрь. Үлчәү; Гакрәп – 30 көн, 23 октябрь – 21 ноябрь. Чаян; Кавәс – 30 көн, 22 ноябрь – 21 декабрь. Укчы; Җәди – 30 көн, 22 декабрь – 20 гыйнвар. Кәҗәмөгез; Дәлү – 30 көн, 21 гыйнвар – 19 февраль. Сукояр.

*Татар халкында бу календарьның актив кулланышта булуын мәкаль-әйтемнәргә керүе раслап тора.*

*Сәвердәге явым – савып торган савын* [1; 435].

*Сәвер килми яз булмый* [1; 435].

*Гакрәп башында кар яуса, Кырык көн ятар* [1, 435].

Нәкый Исәнбәт бу сынамыш янында «Гакрәп – 10 нчы ай» дип аңлатып китә. Бу мәкаль хәзергә кадәр *Октябрьнең башында кар күрсәтсә, Кырык көн ятар,* дигән вариантта саклана.

*Сөнбелә туса, су суыр* [1; 435].

*Хут керде, хатыннар артына ут керде* [1; 435].

Нәкый Исәнбәт әлеге ай исемнәре кергән мәкальләрдә, бу айларның вакыты, һәм мәкальдә нәрсә турында сүз барганын да аңлатып бара. Мәсәлән: «Хут – февраль, искечә 7 нче мартта чыга. Бу айда хатыннар киндер станына утырырга тиеш булганнар» [1; 436].

*Хәмәлдә әмәлеңне корытырмын, дигән.* (Хәмәл – март, искечә 7 нче марттан башлап исәпләнеп, ул көн ел башы (Нәүрүз) саналган һәм өй саен йөреп нәүрүз бәетләре әйткәннәр. Шунлыктан хәмәл урынына нәүрүз ае дип тә йөртелгән. Бу мәкаль хәмәлдәге язгы өзектә запас бетү авырлыгыннан алып әйтелгән.

*Хут чыга, Хәмәл керә* [3; 41].

*Җәүза көнне сандугачлар сайрый башлый.*

*Җәүза керми, җәй булмый, Кавәс керми кыш булмый* [1; 437].

Хәмәл март аена туры килә һәм 21 марттан башлана. Бу – Нәүрүз, ягъни Яңа елны каршы алу көне. Идел буе, Казан татарлары бу бәйрәмне Нәүрүз дип атасалар. Ул Әстерхан һәм себер татарларында Әмәл бәйрәме буларак хәзер дә билгеләп үтелә.

Нәкый Исәнбәт төзегән «Татар халык мәкальләре» җыентыгында татар халкында тагын да борынгырак календарьдан калган ай исеме кергән берничә мәкаль дә кергән. Аларда кантар дигән ай исеме телгә алына:

*Кантарда калпак кимә, язның көне бүрек кимә.*

*Кантарда карга адымыдай көн озаер, акманда ат адымыдай көн озаер.*

*Кантар килми яз булмас, кырпак төшми көз булмас* [1; 435].

Кантар дигән ай исеме казахларда сакланган һәм ул гыйнвар аена туры килә. Алда китерелгән беренче ике мәкальдә кантар аеның

гыйнварга туры килүен күрәбез. Гыйнвар аенда көн акрынлап озыная башлый. Һава торышының салкын вакыты, җылы киенеп йөрү тиеш. Өченче мәкальдә кантар аеның вакытын аеру кыен. Мәкальнең эчтәлегеннән чыгып, ул мартка туры килә. Әмма кыш булмый, яз килми, дип аңлап була. Ай исеме гамәлдән чыкканнан соң, аның вакыты, кайсы ел фасылына туры килүе дә буталырга мөмкин.

Шунда ук ел вакытын белдергән акман һәм акман-тукман дигән сүз кергән берничә мәкаль дә урын алган.

*Акман-тукман алты көн, алты айдан да каты көн.*

*Акман-тукман алты көн, ай-һай синең катуың,*

*Үлчәп салган итеңә, кунак килсә, каты көн* [1; 434].

«Акман-тукман алты көн» дигәннән үк бу сүзнең айны түгел, бәлки ниндидер аерым көннәрне аңлатылуын күрәбез. Акман-тукман, кыш бетүгә барып, көннәр йомшарып киткәннән соң, яңадан салкыннар әйләнеп кайткан яки көчле буранлы көннәр. Ул көннәр март аена туры килә. Бу буранлы көннәрне хәзерге вакытта «Карга бураны» дип атыйлар. Нәкый Исәнбәт бу мәкальләргә аңлатма биреп «Акман-тукман яки әпмән-төпмән, әкмән-төкмән һ.б. – кышның азык запасы беткән иң соңгы, суык көннәре» дип яза [1; 434].

Казах календаренда акпан февраль аеның исеме. Татар халкында да акпан сүзе февраль аен белдерергә мөмкин. Соңрак ул февраль яки март аеның салкын көннәрен һәм бураннарын белдерә башларга мөмкин.

*Печән өстендәге, урак вакытындагы* түзә алмаслык кызуны аңлаткан *Чиллә* дигән сүзне әлегә кадәр кулланабыз. Чиллә дә борынгы календарьда ай исемен аңлатканын аның башка халыкларда саклануы раслый. Мәсәлән, ул казах телендә шилдә буларак кулланыла һәм июль аен белдерә.

Татарлар елның төрле вакытын шул вакыттагы кыр эшләренә яки һава торышына бәйле рәвештә дә атаулары таралган. Алда телгә алынган *урак өсте һәм печән вакыты*ның билгеле бер вакыты бар. Шуңа охшаш *чана юлы төшкән вакыт, кырпак кар яуган вакыт, шомырт чәчәк аткан вакыт* кебек ел вакытын белгертә торган гыйбарәләр бар. Шуларның *урак өсте* яки *урак* ай исемен, августны аңлатуы да мөмкин.

Н.П. Остроумов 1876 елда Казан губернасында яшәгән керәшен татарларында кулланышта булган түбәндәге ай исемнәрен сүзлегенә кертә: *агам кырлач ае* – декабрь; *энем кырлач ае* – гыйнвар; *буш ай* – февраль; *нәүрүз* – март; *яз ае* – апрель; *сабан ае* – май; *җәй ае* – июнь; *чиллә айлары* – июль, август; *ашлык сугу ае* – сентябрь; *келәү ае* – октябрь: *кыш ае* – ноябрь [4]. Бу ай атамалары арасында Нәүрүз атамасы башка календарьдан керүен күрәбез. Ул фарсы сүзе.

Татар халкындагы иң борынгы ай атамалары әлегә кадәр ачыкланып бетмәгән. Орхон-Енисей эпитафик истәлекләрнедә айларны тәртип саннары белән, *беренче ай, икенче ай* дип билгеләүләре мәгълүм. Төрле чыганакларда, бигрәк тә интернет челтәрендә татар халкының борынгы ай исемнәре дип бирелгән мәгълүматлар бик каршылыклы булу сәбәпле, алар яңадан өйрәнүне һәм барлауны таләп итә.

**Әдәбият исемлеге**


1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – Т.1. – 959 б.
2. Мәрҗани Ш. Сайланма әсәрләр. – Казан: ТәһСИ, 2018. – 450 б.
3. Мәхмүтов Х.Ш. Ел тәүлеге – 12 ай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 128 б.
4. Остроумов Н.П. Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии. – Казань: тип. Ун-та, 1876. – 145 с.


© Закирова И.Г., 2024

УДК 398.221

**Закирова И.Г.,**
*Казан ш., Россия*

## «ТҮЛӘК» ДАСТАНЫНЫҢ ТАМЫРЛАРЫ КАЯ ТОТАША?

***Аннотация:*** *«Түләк» дастаны – уникаль мифологик әсәр. Дастанның эчтәлеген япон һәм Кытай территориясендә яшәүче дунган халыклары фольклоры белән чагыштырып өйрәнү аларның бер үк сюжетлы булуын һәм уртак мотивлардан торуын күрсәтә. Бу охшашлык сюжетның бик борынгы заманда барлыкка килүен һәм татар дастанының тамырлары Кытай территориясендә яшәгән борынгы халыкларның фольклорына барып тоташуын фаразларга мөмкинлек бирә.*

***Терәк сүзләр:*** *татар фольклоры, «Түләк» дастаны, мифология, дунганнар, «Урасима Таро».*

«Түләк» дастаны халык дастаннары арасында иң үзенчәлекле әсәрләрнең берсе [4; 123-135]. Бу дастан нигездә бары ике халыкта, татар һәм башкорт халкында гына очрый. Дастанның татар вариантлары нигездә кульъязмаларда сакланып, Татарстан территориясендә аның берничә тулы варианты табылган. «Түләк» дастанына багышланган фәнни хезмәтләр дә аз түгел. Археограф галим М.Г. Госманов «Түләк»

дастанына аерым игътибар бирә. Галимнең «Каурый каләм эзеннән» дигән монографиясендә «Түләк» дастанының өйрәнү тарихына зур урын бирелә, кулъязма вариантларга анализ ясала [1; 225-262]. Әсәрнең барлык вариантларын өйрәнеп, Ф.И. Урманчеев «Түләк турында риваять» дигән хезмәтен яза. Ул әсәрнең архаиклыгын күрсәткән мотивларга тукталып, текстка чор һәм чорга бәйле вакыйгалар керткән үзгәрешләрне күрсәтә. Эпосны башка халыклар фольклоры белән чагыштыра [5; 72-89]. Д. М. Исхаковның дастанны тарихи аспектта тикшергән хезмәте әсәрнең төп сюжетын һәм Түләкнең кемлек мәсьәләсен, геройның социаль статусын ачыкларга багышланган [10; 10-168].

Бу мәкаләдә дастанны тулысынча тикшерү максаты куймыйча, сюжетның башка халыклар, бигрәк тә Кытай һәм Япония халыкларының фольклор әсәрләре белән уртаклыгын барлыйбыз.

Су кызы образы белән бәйле фольклор әсәрләре күп халыклар иҗатында бар. Су асты дөньясын күргән, диңгез патшасы кызына өйләнгән җир кешесе турындагы язмача теркәлгән иң борынгы әсәр VIII гасырга карый. Шул дәвердә төзелгән «Манъёсю» дигән япон җыентыгында «Урасима Таро» исемле баллада урын алган. Инде VIII гасырда ук бу әсәр архаик булып саналган [7; 5].

Әсәрнең эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт: Урасима Таро исемле балыкчы су буенда балаларның бер ташбаканы җәберләүләрен күреп аны сатып ала һәм иреккә җибәрә. Икенче көнне ташбака аны су асты патшалыгына кунакка чакыра. Патша сараенда балыкчыны драконның гүзәл кызы Ото-Химэ каршы ала. Иң зур могҗиза – сарай бакчасы була. Аның беренче ягында чия-алмагачлар чәчәк ата, сандугач сайрый – яз була, икенче ягында җәй хөкем сөрә – җиләк-җимеш пешә, өченче ягында алтын көз җиткән – купшы хризантемалар чәчәк ата, өрәңге яфраклары кыштырдый, дүртенче ягында – ап-ак карга күмелгән кыш була. Су кызына гашыйк булган Урасимо Таро күпме вакыт үткәнен дә тоймый. Шулай да бер көн эти-әнисе, йорты исенә төшә һәм ул җиргә кайтырга теләк белдерә. Саубуллашканда су кызы Ото-химэ аңа яшма ташыннан ясалган тартма бүләк итә, әмма аны беркайчан да ачмаска куша. Туган ярына чыгып баскан Урасима бернәрсәне дә танымый, өендә дә танышларын-туганнарын тапмый. Кешеләр аңа «Монда 300 (вариантлары 100, 700) ел элек Урасима дигән балыкчы яшәгән», дип риваять сөйлиләр. Урасима диңгез ярына барып тартманы ача да, мизгел эчендә картаеп үлә.

«Урасима Таро» белән «Түләк» дастаны арасында охшашлыклар, уртак мотивларның күп булуы, аларның уртак чыганагы турындагы фикергә этәрә. Ике әсәрнең дә геройлары су астына, диңгез патшасының сараена эләгәләр. Икесе дә су кызына гашыйк була һәм шушы стихиядә кала. Мәхәббәттән башлары әйләнгән геройлар җир өсте дөньясын, анда

калган тормышларын озак вакыт үткәч кенә искә төшерәләр. Икесе дә җирне сагынып, җиргә чыга. «Урасима Таро»да сарай бакчасы дүрт якта дүрт ел фасылын күрсәтә. «Түләк» дастанында сарайның бер ягында сөт дәрьясы, икенче ягында бал дәрьясы, дүрт ягында дүрт олуг су дәрьясы агып тора.

Диңгез патшасының музыка яратуы һәм геройның музыка коралларында уйнавы, су кызына өйләнүе Кытай территориясендә яшәгән халыклар фольклорында да еш очрый торган сюжет. Бу сюжетка корылган әсәрләр Кытайда яшәүче дунган халкы фольклорында аеруча күп. Алар, нигездә бер үк сюжетка корылган булса да, һәрберсенең аерым, кабатланмас мотивлары бар. Мәсәлән, «Лосань» дигән әкияттә карт белән карчыкның өч улы була. Үсеп җиткәч алар өчесе өч якка һөнәр өйрәнергә чыгып китәләр. Ике елдан соң һөнәр урынына щяньцзы дигән музыка коралында уйнарга өйрәнеп кайткан төпчек улын әтисе куып чыгара. Диңгез ярында кайгыдан щяньцзыда уйнап утырган Лосаньның уенын диңгез патшасы ишетә һәм үз сараена чакыра. Үзенең кызын аңа кияүгә бирә. Алар озак һәм бәхетле яшиләр [2; 46-49].

Су иясенең музыка яратуы «Чжон Юй» дигән әкияттә дә тасвирлана. Диңгез патшасының төпчек кызы атасы рөхсәтеннән башка җиргә чыга һәм цитра дигән уен коралы тавышын ишетеп, җир егетенә гашыйк була. Күп каршылыкларны җиңеп, геройлар кавышалар [2; 49-56]. Түләкнең дә гөлстан, думбра, кыл кубыз дигән музыка уен коралары, дигән уенчык ясавы һәм уйнавы турында дастанда берничә тапкыр искә алына. Геройның музыка уен коралары ясавы әсәрнең борынгылыгына ишарә итә. Үртәкә дигән уенчыкны дастан түбәндәгечә сурәтли: «Ул үртәкәнең мөгезен алтындин, аякларын көмешдин, ике күзен данәдин ясады. Ул үртәкәне бу җиһан бизәге берлән бизәде» [4; 131].

«Чжон Юй» әкиятендә «Түләк» дастаны белән охшаш тагын бер эпизод бар. Диңгез патшасы кызы егеткә көмеш казан, тимер кашык һәм алтын тәңкә бирә. Егет казанга тәңкәне салып, кашык белән диңгездән су сала. Казандагы су кайный башлагач, диңгез дә кайный башлый. Бөтен диңгез халкы ни эшләргә белми, диңгез патшасы драконга барып ялына. Диңгез патшасы үзенең патшалыгын коткару өчен кызын җир егетенә кияүгә бирергә мәҗбүр була [2; 50].Түләк үзенең максатына ирешер өчен, Алладан диңгез төбенә эсселек җибәрүен сорый, шуннан соң «өч көн-төн һава эсселеке кайнар булды, ул сарайның янындин аккан бал дәрьясы, сөт дәрьясы, дүрт тарафыдай аккан су дәрьясы тәмам корыдылар, һичбер эчем су калмады, такатьсез булдылар – барчасы ятып үлгүтик булды» [4; 128].

Без чагыштыра торган әсәрләрнең ландшафты да үзенчәлекле. Дунган фольклорында таулар һәм диңгез тасвирлана, әмма урман, елга-күлләр, болын һәм кырлар очрамый. «Түләк» дастанында да вакыйгалар барган урыннар – *олуг дәрья* һәм герой кат-кат искә алган *Балкан тавы*.

Кытай территориясендә яшәгән халыкларның фольклорында Кытай диңгезе – Дунхэй – еш телгә алына. Анда Кытай һәм дунган әкиятләренең төп герое – диңгез патшасы Дракон яши. Татар халык әкиятләрендә исә диңгез төбендә Аждаһа яши. «Түләк» дастанында диңгез патшасы – Чачдар ханның исеме дә яңгырашы белән Аждаһага да якын. Аждаһаның төрки халыкларда Аждарһа дип аталуы да мәгълүм. Чачдар хан белән Аждарһаның охшаш яңгырашын истә тотып, бу ике геройны берләштереп булмыймы икән дип, фараз итәбез. Бу гипотезаның дөреслеген дастан сюжетын кытай, япон халыклары фольклоры белән чагыштыру да раслый. Кытай халыклары фольклорында дракон су асты патшасы. Кытайдан еракkарак киткән саен драконга Кытай императорларының исемен бирү күренеше ешая.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин, татар һәм башкорт фольклорында сакланган «Түләк» дастаны бик борынгы әсәр булып, аның башка төрки халыкларда очрамаган сюжеты әсәрнең килеп чыгуы һәм формалашуы ягыннан да уникаль булуын раслый. Кагыйдә буларак, төрки халыклар дастаннары уртак сюжетка корылган милли версияләрне тәшкил итәләр.

Дастанның сюжетын Япон һәм Кытай территориясендә яшәгән дунган халыклары фольклоры белән чагыштырып өйрәнү аларның бер үк сюжетка корылуын, уртак мотивлардан торуын күрсәтә. Бу охшашлык әлеге сюжетның бик борынгы заманнарда иҗат ителүен һәм татар дастанының тамырлары Кытай территориясендә яшәгән борынгы халыклар фольклорына ук барып тоташуын фаразларга мөмкинлек бирә.

Киләчәктә, «Түләк» дастанының төрле вариантларын сюжеты уртаклыгы ягыннан тикшерү кызыклы нәтиҗәләргә китерер дип уйлыйбыз.

**Әдәбият исемлеге**

1. Госманов М.Г. Каурый каләм эзеннән / М.Г. Госманов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1994. – Б. 225-262.

2. Дунганские народные сказки и предания. – М., Главная редакция восточной литературы издательства «Наука», 1977. – 573 с.

3. Исхаков Д.М. Халкыбызның эпик әсәрләрендә милли тарих. («Түләк һәм Сусылу», «Ак Күбәк», «Идегәй», «Чура батыр» дастаннарына һәм тарихи риваятьләргә анализ) // Туган җир. – 2022. – № 2. Махсус сан. – Б. 10-168.

4. Татар халык иҗаты: Дастаннар / Томны төзүче, кереш мәкалә

һәм искәрмәләрне язучы Ф.В. Әхмәтова. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. – Б. 123-135.

5. Урманчеев Ф.И. Героический эпос татарского народа. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1984. – С. 72-89.

6. Японские народные сказки. – М.: Эксмо, 2019. – 576 с.

7. Японские сказки. – М.: Гослитиздат, 1958. – 112 с.

© Закирова И.Г., 2023

УДК 821.161.1

**Зарафутдинова Э.Т.,**
*г. Нефтекамск, Россия*

# ТЮРКИЗМЫ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ С.Т. АКСАКОВА

***Аннотация:*** *в статье рассматривается очерк С.Т. Аксакова «Буран» – первое реалистическое произведение писателя. Представлена история его создания и публикации, выделены ведущие принципы аксаковского творчества, проявившиеся в очерке и функционирование тюркизмов в произведениях писателя. Тюркизмы имеют значимое место в русском языке, и их использование способствует обогащению и разнообразию лексического состава языка, а также отражает культурные и исторические связи между различными народами.*

***Ключевые слова:*** *С.Т. Аксаков, лексика, художественная литература, тюркизмы, заимствованные слова, национальный колорит, взаимовлияние языков.*

Новизна работы состоит в том, что ранее в литературе не рассматривались тюркизмы как следствие дружеского взаимодействия двух культур, что значительно оказывает влияние на развитие верного мировоззрения у школьников, показывая правдивые взаимоотношения славянских и тюркских народов.

Лексика русского языка, как и любого другого функционирующего языка, состоит из исконных и заимствованных слов. Изучение лексики любого языка, в том числе русского, имеет не только лингвистический, он и исторический, этнографический интерес, так как именно в языке отражаются многие процессы, происходящие в обществе.

«Соприкосновение языков является исторической необходимостью, и соприкосновение это неизбежно влечет за собой их взаимопроникновение», справедливо заметил французский лингвист Ж. Вандриес [Вандриес: 2004].

Фиксация тюркизма в языке художественных произведений позволяет проследить (хотя и приблизительно) характер заимствования в пространстве, во времени, установить причины в данный исторический период. В связи с этим интересным представляется вопрос об использовании тюркизмов писателями в целях создания местного колорита, изучение особенностей функционирования тюркизмов в языке художественных произведений.

К пониманию огромной роли и значения тюркизмов в русском языке писатели и ученые приходили постепенно. Русско-тюркские языковые связи уходят корнями в глубь истории. Возможно, это взаимодействие началось ещё в эпоху ностратической языковой общности. Контакты русского и тюркских народов длятся уже более 14 столетий, и столько же времени продолжается взаимовлияние языков, которое, прежде всего, проявляется в их словарном составе. Проблема изучения тюркско-русских языковых контактов, а именно тюркских элементов в русском словарном составе, имеет давнюю традицию. Эти исследования проводились на различном материале (памятники письменности, художественная литература, диалекты, регионы, фольклор, язык СМИ и др.), в различных аспектах (этимологический, хронологический, фонетический, орфографический, семантический, грамматический, функциональный, сравнительно-сопоставительный и др.). Объектами научных исследований становились тюркские заимствования определенных тематических групп (названия растений, животных, одежды, построек и строительного дела, предметов домашнего обихода, наименования лиц, во-енная лексика, лексика пищи и др.).

Вместе с тем, вопросы применения тюркизмов, – как в повседневной речи, так и в художественных текстах остаются весьма актуальными. В нашем регионе, где существует реальное многоязычие, изучение взаимовлияний тюркских и русского языков является приоритетным.

Традиционно исследователи выделяют несколько слоёв тюркских заимствований: из праславянского языка; древнерусские; из тюркских языков периода Золотой Орды; заимствования после ордынского периода – а) XVI –XVII вв., б) XVIII-XX вв.

Важность тюркской лексемы не в первичности, а в том, что только тюркский этнос находился со славянским этносом в длительном непрерывном культурно-историческим взаимодействии, благодаря чему был возможен синергизм языков, в котором, естественно, проявлялась доминанта более древнего тюркского языка. Такое положение дел было обусловлено коммуникационной необходимостью в процессе совместной жизнедеятельности.

Тюркизм – это «слово или оборот речи в каком-нибудь языке, заимствованные из какого-нибудь тюркского языка или созданные по образцу тюркского слова или выражения. Широкое проникновение тюркизмов в русский язык происходило в XIII–XV вв. – в золотоордынский период, а также в XVI–XVII вв. – период не только военных столкновений, но и активных политических, торговых и культурных контактов русского и тюркоязычных народов. Потребность в обозначении новых реалий и понятий активизировала такой способ лексической номинации, как заимствование» [Бурибаева М.А: 2014, 323].

В целях более точного, соответствующего истинному происхождению слов определения границ термина «тюркизм» все тюркизмы подразделяют на исконные и исторические:

1) исконные тюркизмы – употребляющиеся в русском языке тюркские слова, которые принадлежат к собственному, относительно первоначальному словарному составу тюркских языков;

2) исторические тюркизмы – проникшие в русский язык из тюркских языков слова первоначально нетюркского происхождения, усвоенные тюркскими языками из какого-либо другого языка (иранских, арабского, монгольских и др.).

В «Толковом словаре русского языка» С.И. Ожегова и Н.Ю. Шведовой тюркизм определяется как «слово или оборот речи в каком-нибудь языке, заимствованные из какого-нибудь тюркского языка или созданные по образцу тюркского слова или выражения» [Ожегов, Шведова: 1999, с. 819].

Научное изучение тюркизмов, функционирующих в русском литературном языке, началось ещё в XVIII веке.

В Республике Башкортостан данная проблема рассматривалась такими учёными-лингвистами, как Л.Л. Аюпова, Т.М. Гарипов, З.П. Здобнова, Р.Х. Хайруллина, Ф.Г. Фаткуллина и др.

Можно ставить вопрос о влиянии башкирского и татарского языков на все уровни и подсистемы русской разговорной речи и русского языка в целом.

Некоторые из тюркизмов, представляют собой экзотизмы, т.е. разновидность заимствований, использующихся для передачи местного колорита. Главной причиной появления экзотизмов является необходимость обозначить предмет, явление или понятие, свойственные только культуре или быту данного народа и отсутствующие в другом языке. Таким образом, основной функцией экзотизмов можно назвать обогащение словарного запаса. Экзотизмы могут быть широкоупотребительными (коран, курай, кумыс, мечеть и мн. др.) и малоупотребительными (сэсэн, шежере, тамга, буза и др.).

Слова тюркского происхождения разнообразны по тематике и проникли во все семантические группы лексики [6: 875]. Так, тюркизмы обозначают: явления природы и географические понятия (буран, бархан, буерак, арык и т.п.), растения (камыш, жасмин, арбуз, банан и т.п.), домашнюю утварь (казан, арба, аркан и т.п.), одежду (халат, зипун, кафтан, бешмет и т.п.), животных, птиц (альбатрос, бурундук, ишак, беркут и т.п.), кушанья, напитки (каймак, кумыс, айран, кофе) и т.п. Тюркизмы пополнили административно-социально-экономическую терминологию: хан, есаул, эмир, казна, аймак, вилайет, визирь и т.п.

Часть тюркизмов – слова, связанные с религией: ислам, дервиш, бедуин, гяур и т.п. В русском языке много заимствований, и чуть ли не половина приходится на заимствования из тюркских языков. Первым и до сих пор самым полным словарем считается «Словарь тюркизмов в русском языке», составленный Е.Н. Шиповой в 1976 г. [Шипова: 1976]. Ценность его состоит прежде всего в том, что автор, будучи ученым-лексикографом, поставил перед собой задачу не только включить все зарегистрированные в словарных источниках и в работах отдельных авторов тюркизмы, но и, по мере возможности, раскрыть их этимологию.

Таким образом, изучение тюркизмов в русском языке представляет значительный интерес для понимания лексических и культурно-исторических законов функционирования русского языка в тюркских регионах России, и, прежде всего в Татарстане. Осознание того, что русский язык несет в себе смыслы многих тюркских заимствований, должно стать основой создания новых эффективных методик преподавания языков на основе исторически сложившегося билингвизма, открыть новый конструктивный этап тюрко-славянского диалога в XXI веке.

В произведениях С.Т. Аксакова значительное место занимают заимствованные тюркские слова и словосочетания, которые проникли в русский язык из разных языков и диалектов в период новых интенсивных контактов, обусловленных присоединением к России народов Казахского, Астраханского, Сибирского, Крымского ханств, Средней Азии и Кавказа (16–19 вв.). По своей тематике тюркские заимствования относятся к самым различным лексическим пластам русского языка:

а) природный мир, явления природы, растения, животный мир и т.д. (буран, камыш, инжир, изюм; балык, мерин и др.;

б) религия: муфтий, оран, байрам и др.;

в) административно-социально-экономическая терминология: тюба, башр, ямщик и др.;

г) дом и домашняя утварь: конура, очаг, таган, кочерга др.;

д) пища, напитки: щербет, кумыс и др.

Одним из первых – задолго до А.С. Пушкина и В.И. Даля – С.Т. Аксаков употребил тюркское слово «буран», которое обозначает степную вьюгу, метелицу при сильном северном ветре. Аксаков и Пушкин целенаправленно использовали данный тюркизм для передачи особого колорита в описании Оренбургской степи, где вместе с русскими жили башкиры, татары, казахи. Есть в очерке С.Т. Аксакова и другие тюркские слова: «малахай», «сырт», «умет», «кошма», лингвокультурологический комментарий которых также дается в интермедиальном формате.

В очерке «Буран» Аксакова тоже есть несколько слов тюркского происхождения. Среди них есть уже обрусевшие слова: буран, шиш, лошадь, базар и т.д., а также такие слова как зипун, малахай, сырт, кошма. Такая лексика обычно указывает на место, где происходят события. Например, Оренбургская степь, по которой кочевали башкиры. Присутствуют тюркизмы: «буран», «умет», «малахай», «сырт», «кошма», «Яик». Использование тюркизмов даёт возможность писателю как можно точнее отразить изображаемую действительность.

В художественном произведении тюркизмы передают национальный колорит. Значительную роль в создании национального колорита играют тюркские имена собственные. Авторские пояснения выносятся за пределы текста – сноски «…в роскошной долине в живописном беспорядке теснилась эта деревушка на подошве горы Байрам-тау, защищавшей ее от севера; на запад возвышалась другая гора Зеин-тау…». В сноске: «Тау, значит гора, байрам- праздник. Это имя, как говорит предание, дано горе потому, что на ней будто бы башкирцы совершали торжественное молебствие после уразы, то есть поста. Зеин-тау – значит гора собрание; зеином называется собрание народа для борьбы, бегания и конской скачки».

Тюркская лексика выделяется курсивом и объясняется писателем: «Тау значит гора, Байрам - праздник. Это имя, как говорит предание, дано горе потому, что на ней будто бы башкирцы совершали торжественное молебствие после уразы, то есть поста. Зе-ин-тау – значит гора собрания; зеином называется пир или собрание народа для борьбы, беганья и конской скачки. Гора эта получила название Зеина со времен приобретения от башкирцев земли, лежащей по речке Узе. Г-н Алкин, после заключения условия с башкирцами, дал для них на этой горе пир с разными увеселениями. Тамак значит устье...» [Аксаков: 1955; 261].

С.Т. Аксаков включал в тексты своих произведений большое количество гидронимов (названия различных водных объектов): реки Конлыелга, Ик, Узы, Кармалка, Большой Суюш, озеро Киишки с последующим пояснением происхождения этих названий. Например, вот

как он поясняет название озера Киишки: «В одно прекрасное летнее утро, на большом озере, называемом по-татарски Киишки, таскал я плотву и подлещиков» В сноске: «Киишки – по-русски значит длинный. Это озеро находится в тридцати верстах от губернского города Уфы и полуверсте от реки Белой, с которой сливается весною; разумеется, русские называют его и сидящую на нем деревню Киишки».

При изображении инонациональных явлений Аксаков использует характерные этнографические реалии, которые способствуют созданию этнического пласта бытия. Писатель обращает внимание на башкирский музыкальный инструмент – чебыз-гу, давая его описание: «Чебызга – дудка, которую башкирец берет в рот, как кларнет, и, перебирая пальцами, играет на ней». В мире духовых инструментов чебызга, по определению автора, является «чудным явлением», так как издает «двойные тона». Поэтому создается впечатление, что в одно и то же время играют два разных инструмента. Описание чебызгы и связанного с ней уникального горлового пения башкир появляется в произведениях русских писателей XIX века – В.И. Даля, А.К. Толстого, А.М. Авдеева.

Таким образом, произведения С.Т. Аксакова наполнены национальным колоритом, традициями, природными особенностями, которые автор выразил в виде тюркизмов, передающих этнокультурную и этнические особенности его произведений.

## Список литературы

1. Аксаков С.Т. Семейная хроника // Собрание сочинений в 5 т. – Т.1. – М.: Правда (библиотека «Огонек»). 1955. – С. 55-260.

2. Аксаков С.Т. Семейная хроника. Детские года Багрова-внука. Собрание сочинений: В 4 т. – М.: ГИХЛ, 1955. – Т.1. – 639 с.

1. Исянгулова Г.А. Особенности употребления сравнений в произведениях Т. Кильмухаметова // Филологическая наука в современном образовательном пространстве: традиции и инновации. Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 70-летию известного ученого-литературоведа, доктора филологических наук, профессора Балтабая Әбдіғазіұлы. – Алматы, 2022. – С. 140-144.
2. Исянгулова Г.А. Особенности употребления сравнений в произведениях Г. Якуповой (на примере трилогии «Женщины») // Научный альманах. – 2022. – № 2-2 (88). – С. 124-126.
3. Сәйетбатталов Ғ.Ғ. Сабир Шәрипов теленең ҡайһы бер үҙенсәлектәре // Башҡорт теле. 5 т. Стилистика. – Өфө: Китап, 2009. – 300-318-се биттәр.
4. Шәрипов С. Аҡ ҡулсатыр: повестар, хикәйәләр, хикмәттәр һәм мәҙәктәр. – Өфө: Китап, 1998. – 488 бит.
5. Шәрипов С. Зәңгәр катер: роман, хикәйәләр, хикмәттәр. – Өфө: Китап, 2008. – 544 бит.
6. Шәрипов С. Ҡолонташ: повестар, хикәйәләр, драмалар, юлъяҙмалар. – Өфө: Китап, 2013. – 542 бит.
7. Хөсәйенов Ғ. Б. Әҙәбиәт теорияһы. – Өфө: Китап, 2010. – 384 бит.
8. Әхмәтйәнов К. Ә. Әҙәбиәт теорияһы. Үҙгәрешле 3-сө баҫма. – Өфө: Китап, 2003. – 392 бит.


© Иҫәнғолова Г.А., 2024

УДК 821.512.145

**Исмагилова А.В., Сагидуллина Л.Р.,**
*Уфа ш., Россия*

# «СҮЗ» КОНЦЕПТЫНЫҢ ӘДӘБИ ТЕКСТТА ЧАГЫЛЫШЫ

***Аннотация:*** *мәкаләдә «сүз» концептының шигъри тексттагы репрезентациясе анализлана (Лилия Фәттахова «Әллә елар, әллә көлер...»).*

***Терәк сүзләр:*** «*сүз*» *концепты, концептуаль анализ, текст, лирик герой.*

Концепт лингвистика һәм әдәбият белемендә, лингвокультурологиядә иң мөһим төшенчәләрнең берсе булып тора. Концептлар семантик эчтәлеккә ия һәм текстка билгеле бер мәгънә төсмере биргән лексик берәмлекләр аша белдерелә. Текст үз эченә алган концептларны тикшерү автор дөньясының тел картинасы үзенчәлекләрен, аның чынбарлыкка индивидуаль карашын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Концептның әдәби әсәрләрдә чагылышы – ул концептның эстетик яктан формалашкан, авторның дөнья картинасы үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирә торган күренеш. Текст авторның фикерен объективлаштыру, аның иҗади ниятен тормышка ашыру, кеше һәм дөнья турында белем һәм күзаллауларны тапшыру, бу күзаллауларны автор аңыннан читкә алып чыгып, аларны башка кешеләр белән кабул итү өчен төзелә.

Сәнгатьле текст чынбарлыкның шәхси интерпретациясен чагылдыра. Язучы чынбарлыкның үзенә таныш өлешләрен тасвирлый; үзенә якын һәм аңлашылган фикер-карашларны үстерә, куәтли; тел берәмлекләрен һәм үзе өчен мөһим шәхси мәгънә белән тулыландырылган метафоралар куллана. Сәнгатьле текстта чагылган дөнья картинасы, автор тарафыннан структуралаштырылган һәм вербальләштерелгән шәхси дөнья картинасы буларак аңлана һәм кабул ителә (Белянин, 1988, б. 6) [2; 5].

Әдәби иҗатта кулланылган концептларны анализлау әсәрнең тирән мәгънәләрен ачу һәм авторның мотивларын аңлау мөмкинлеге бирә. Тексттагы концептларны ачыклау авторның укучыга ничек мөрәҗәгать итүен, нинди лингвистик чаралар белән теләгән эффектка ирешүен аңларга ярдәм итә.

Әдәби тексттагы концепт катлаулы күп үлчәмле структурага ия. Тел ияләре өчен иң актуаль ассоциацияләр үзәк концепт белән билгеләнә, калганнары периферияне тәшкил итә.

Әдәби текстка концептуаль анализ ясау, иң беренче чиратта, түбәндәгеләрне күз уңында тота: беренчедән, текстның терәк-ачкыч сүзләр җыелмасын ачыклау; икенчедән, шул сүзләр арасыннан төп концептны билгеләү; өченчедән, алар ярдәмендә билгеләнгән концептуаль киңлекне (пространство) тасвирлау.

Әдәби текстка концептуаль анализ ясау алгоритмнары күп төрле. Без Л. Г.Бабенко тәкъдим иткән вариантка тукталабыз:

1. Текстның концептуаль киңлеге формалашу өчен әһәмиятле тексттагы пресуппозицияләрне аеру: текстның язылу вакыты, автор исеме; әгәр булса – эпиграфның роле.

2. Текст исемен һәм аның тексттагы семантик радиусын анализлау.

3. Текстның терәк-ачкыч сүзләрне ачыклау максатында психолингвистик эксперимент үткәрү.

4. Тексттагы терәк-ачкыч сүзләр белән парадигматик һәм синтагматик бәйләнешләргә кергән, кабатланган сүзләрне ачыклау. Тексттагы төп сүзне – текст концептының лексик репрезентантын билгеләү.

5. Бер тематик өлкәгә караган, әмма экспрессив дәрәҗәсе төрле булган сүзләрне ачыклау максатында текстның лексик составын анализлау.

6. Текстның концептосферасын тасвирлау.

7. Концептосфераның структурасын модельләштерүгә, ягъни аның үзәген ( төп когнитив-пропозицион структурасын), үзәк янын (төп лексик репрезентатларны), якын периферияне (образлы ассоциацияләрне) һәм ерак перифирияне (субъектлы-модальле мәгънәләрне) аеру [2].

Татар халкының дөнья картинасын билгеләүче концептларны тикшерү эшләре сан ягыннан артып тора. Әмма алар арасында «сүз» концептын тикшерүчеләр күзәтелми.

Татар телендә «сүз» төшенчәсе хәрефләр тышчасында яшәүче берәмлекне генә түгел, ә үз эчендә бик күп коннотацияләр булган мәгънә җыелмасын һәм, гомумән, сөйләмне дә аңлата. Бу татар мәдәниятендә сөйләмнең аерым әһәмияте булуга һәм аралашуның иң мөһим чараларының берсе булып саналуга бәйле.

Без «сүз» концептын тикшерүне тел материалы белән чикләмичә (сүзлек аңлатмасы. Фразеологик берәмлекләр, паремияләр һ.б.), аны әдәби текст эчендә күзәтү максатын да куйдык. Мондый тикшеренүне Н. Измайлованың «Сүз» шигыреннән башласак, алдагы анализ өчен Лилия Фәттахованың «Әллә елар, әллә көлер... » шигыре сайланды.

Лилия Фәттахова – Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, журналист, шагыйрә. Фәйрүзә Мөслимова (шагыйрә, Татарстан Язучылар берлегенең Шигърият остаханәсе җитәкчесе) аның хакында түбәндәге фикерләре

белән бүлешә: «Бик күп үзешчән авторлар арасында ул үзенчәлекле энҗе кебек ялтырап тора иде. Дөньяга яшьләрчә романтик карашы, хыялый омтылышлары белән генә түгел, яшәешнең мәгънәсе турында тирәннән уйлана белүе, фәлсәфи фикерләре белән дә. <…> ул дөньяны матурларга, җәмгыятьтә әдәп-әхлак сыйфатларын тәрбияләргә омтыла, үзе төзәтә алмастай кимчелекләрне күреп уфтана, борчыла. Шагыйрәне милләт язмышы, аның киләчәге уйландыра. Бу уйлар – гадәти акыл сату түгел, алар – тормыш мисалларына таянып, киләчәккә карау. Лилиянең лирик шигырьләрендә исә кайнар хисләре чайпалып, түгелеп тора» [3; 4]. Шагыйрьгә биргән характеристика «Әллә елар, әллә көлер... » шигыренең лейтмотивы рәвешендә яңгырый.

Сайланган шигырьнең үзәге булып – авторның үзен «сүз» белән тәңгәлләштерүе тора. Бу шигырьдә «*сүз мин*» юлының рефрен рәвешендә кабатлануы очраклы түгел. Авторның сүзгә мөнәсәбәте аша чагылган уй-кичерешләре тасвирлана. Шагыйрә бүгенге җәмгыятьтә «сүз» кичергән үзгәрешләр, югалтулар турында сорау куя. «Сүз гомере»н үз гомере белән паралелльләштерә. Бу очракта әдәбияттагы параллелизм күренеше күзәтелә. Шигырьнең концептуаль үзәген «сүз» һәм «лирик мин» мөнәсәбәте алып тора.

Лилия Фәттахова шигырьгә исеме куймаган. Автор, бәлки, шигырьне тагын да конкретлаштыру, аңа исем кую – контекстны ачуда яки аны кабул итүдә авырлык тудырырга мөмкин дип уйлаган. Әммә «сүз» шигырьнең эчтәлеге һәм идеясе белән аерылгысыз бәйләнештә. Үзәктә ике концептның булуын искә алсак, шигырьне «Сүз һәм мин» дип атап булыр иде.

Төп концептны ачыклау максатыннан без психолингвистик эксперимент үткәрдек. Анда 10 кеше катнашты. Эксперимент нәтиҗәсендә концептуаль үзәкнең «сүз» булуы ачыкланды. 10 респондентның да беренче һәм төп атамалары «сүз» булды.

Шулай ук, «сүз»нең шигырьдә үзәк булуы һәр строфа эчтәлеге аша дәлилләнә. Кабатлау ешлыгыннан карасак, «сүз» – 4, лирик «мин» – 13 тапкыр кабатлана. Сүз – бөтен башлангычның башы, дигән фикер үткәрелә.

Шигырьне анализлаганда, төп герой («сүз»нең) гомере алдан артка сурәтләнүе билгеләнә. Бу кире композиция күренеше. Әлеге метод гадәттән тыш сәнгать осталыгын таләп итә, димәк, авторның аеруча талантлы булуын белдерә. /*Әллә елар, әллә көлер*/ *Сәбәп эзлим.*/ *Ач күз белән нидер күзлим.*/ *Нидер күзлим...*/

Шигырьнең беренче юлларында без авторның дөньяда югалып калганын, уйларының төрлечә таралганын күзәтә алабыз. Һәм шул ук вакытта, шагыйрәнең көчле сыйфаты – бирешмәүчәнлеге ачыктан ачык

күренә: күңелендә бушлык булса да, күзләрен һаман да «ач» – аларда киләчәккә омтылыш бар, алар хәрәкәттә – эзлиләр һәм күзлиләр. Бу күзләр дөньябызда югалып барган хак *Сүзне* эзли, күзли, аны табарга тели.

Алдагы юлларда – *Богауланып, /Тынып калган/ Сүз мин/* – тәүге тапкыр шигырьнең конептуаль үзәге – «сүз» очрый. Бу юллар ирексезлекне сыйфатлый, лирик геройның мондый хәлләрдә үз теләге белән булмавына ишарәли (*богауланган...).* Бу строфада гомер юлының бер чоры сурәтләнә. Әлбәттә, ул гомер тәмамланганны аңлатмый, ә киресенчә, монда яңа күтәрелеш алдыннан, үткәннәрне артта калдырып, тиешле йомгаклар ясап, бар көчне җыеп алга бару дигәнне аңлап була.

Икенче строфада – «*Тамам, тамам диеп/ Тора яшем./ Һәр тамчыда/ Дөнья гаме яши*»/ – «сүз»не табуга гаҗизләнүдән туган хисләр сурәтләнә. «*Тамам, тамам*» дигән юллар авторның көчле рухлы икәнен кабат ачыклап китә. Кыен вакытларга карамастан, ул һаман үзен кулда тота. Тыеп торган күз яшьләренең сәбәбе дөня өчен кайгыру, «*дөнья гаме*» булса да, ул каты елау-сыкрануга бирелеп, төшенкелеген дөньяга таратмый.

Алдагы юлларда*: Саклап кара тәкәллефле йөзең – /Меңәр еллык сыкрау тулы /Сүз мин/* шагыйрә җәмгыятьтә сүз кодрәтен саклап калуда һәрберебезнең әһәмиятен ассызыклый. Без барыбыз да *сүзгә*, шул исәптән туган телгә дә, тугры кала ала, әмма бу җиңел түгел*, сүз* аклыгын саклау авыр. Гасырлар буе аклыкка-сафлыкка, гаделлеккә каршы, димәк, Хак Сүзгә каршы көрәш барган һәм бара. Лирик герой үзенә һәм безгә сорау бирә: «Ә бу көрәштә Хак Сүзне (*тәкәллефле йөзең)* сакларга, акларга безнең рухыбыз җитәрме?.. »

Алдагы строфада *Сөмсез җилләр/ Яңак чабып уйный./ Басып торам чатта/ Түзәр-түзми. /Кахкаһәле еллар давылында /Егылмыйча /Исән калган Сүз мин/* заман җилләре «*сөмсез*» дип атала. Алар «лирик мин»не сыный: «*яңак чабып уйный*». Сүз, димәк, лирик «мин» бу коточкыч давылда егылмыйча, аңа бирешмичә исән калырга тиеш.

Дүртенче строфада: *Җиде чатта җиде уйны сүтәм / Уң юл табарыма / Өмет өзми. /Мәңгелекнең фани бишегендә / Дөнья яралганда / Туган Сүз мин/.* Дөрес юлны сайлау, хак сүзне табу, саклау, тапшыру мөмкинлеге проблемасы булуы ачыклана *(Җиде чатта җиде уйны сүтәм).* Автор андый мөмкинлекне күрә, «*өмет өзми*»*,* чөнки ул үзен «*дөнья яралганда туган сүз*» итеп күрә. Бу строфада Сүзнең Илаһи башлангыч булуына туры ишарә бар.

Соңгы строфада автор үткән юлын исенә төшереп, нәтиҗә ясый: киләчәктә уң юл табарына өмет өзми, чөнки бүгенге өметсез заманда – *Хәзер генә менә /Ач күз белән /Нидер эзлим Җирдә. /Нидер эзлим.../.*

Димәк, ул Илаһи башлангычтан туган зат, хәзер (шушы вакытта һәм шушы урында) Сүзне эзли, Сүзгә тугры үзен эзли...

Без шигырьгә ясалган концептуаль анализның бер өлешен түбәндәге модель рәвешендә кузаллыйбыз.




Шулай итеп, Лилия Фәттахованың «Әллә елар, әллә көләр...» шигырендә «сүз» концептын реальләштерү үзенчәлеген күзәтү безгә концептның коннотацион тирәлеге киңәюен күзәтергә, авторның эстетик, этик, гражданлык  принипларын ачыкларга да мөмкинлек бирде. Димәк, Лилия Фәттахова – «үз йөзе-сүзе, үз төсе-исе белән аерылып торган «яңа дөньялар» тудыручы иҗатчылардан» [2; 2].

## Кулланылган әдәбият

1. Бабенко Л.Г., Казарин Ю.В. Филологический анализ текста. (практикум). – М.: «Академический проект. Екатеринбург.: «Деловая книга». – 2004. – 400 с.

2. Сагидуллина Л.Р. Текст. Язык. Литература = Текст. Тел. Әдәбият: учебное пособие / Л.Р. Сагидуллина; Уфимский университет науки и технологий. – Уфа: РИЦ УУНИТ, 2023.

3. Фәттахова Л.Р. Карурман миләүшәсе. Хикәяләр / Лилия Фәттахова. – Казан: Рухият, 201. – 239 б.

© Исмагилова А.А., Сагидуллина Л.Р., 2024

УДК 398.91

**Калкаманова Г.Ф.,**
*Башкортстан Республикасы, Россия*

# ӘЙТЕМ – СҮЗНЕҢ БИЗӘГЕ, Ә МӘКАЛЬ – СҮЗНЕҢ ҖИЛӘГЕ

***Аннотация:*** *мәкаләдә халык авыз иҗаты үрнәкләрен дәрестә куллану укучыларның сөйләм күнекмәләрен үстерүе, баетуы, фикерләү сәләтен арттыруы турында тасвирлана.*

***Терәк сүзләр:*** *мәкаль, әйтем, сөйләм үстерү, фикерләү сәләте, дәрес, халык авыз иҗаты.*

Бүгенге көндә төп бурычларыбызның берсе – һәрьяктан камил булган зыялы шәхес тәрбияләү. Ә ул, үз чиратында, туган телебезне яратучы, үз халкының мәдәниятын, гореф-гадәтләрен, иң күркәм йолаларын, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш.

Яңа буын дәүләт стандартларынада белем һәм тәрбия бирүне, милли традицияләргә таянып, халык педагогикасы нигезендә алып бару тәү чираттагы максатлар дип танылды.

Татар халык авыз иҗаты элек-электән халык тарафыннан киң кулланылган һәм яшь буынны тәрбияләүгә юнәлтелгән. Шуна күрә мин үземнең дәресләремдә халык авыз ижаты урнәкләре булган мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, әкиятләр, тизәйткечләр кулланам. Шул уңайдан үземнең хезмәтемдә «Халык авыз иҗаты аша укучыларга әхлакый тәрбия бирүдә мәкальләрнең роле» дигән темага тукталырга булдым һәм минем максатым: әхлак тәрбиясе бирүдә, тел һәм әдәбият дәресләренә кызыксыну уятуда мәкальләр куллануның мөһим һәм нәтиҗәле эш төрләренең берсе булуын исбатлау, методик папкалар әзерләү.

Иҗади эзләнү барышында түбәндәге бурычларны куйдым:

1.Мәкальләрнең тематик яктан бүленешен өйрәнү;

2.Укыту эшчәнлеге нәтиҗәләренә куелган таләпләргә туры килгән төрле эш алымнарын билгеләү;

3.Мәкальләрнең зур тәрбия чыганагы икәнлеген мисаллар ярдәмендә күрсәтү;

4.Укучыларда мәкальләр туплау эшчәнлегенә кызыксыну уяту.

Яңа буын дәүләт стандартлары укыту эшчәнлеге нәтиҗәләренә түбәндәге таләпләрне куйды. Алар шәхси, эшчәнлекнең гомумиләштерелгән ысуллары (метапредмет) һәм фәнне өйрәнү нәтиҗәләрен үз эченә ала.

**Шәхси эшчәнлек** баланың тормыш кыйммәтләрен, әхлакый һәм мораль нормаларны аңлавына һәм кабул итүенә, аның әйләнә-тирәсендәге барлык нәрсәгә шәхси карашы формалашуны аңлауга юнәлтелгән.

Әхлак тәрбиясе бирүдә мөһим һәм нәтиҗәле эш төрләренең берсе итеп тел һәм әдәбият дәресләрендә мәкальләр куллануны күрәм. *Мәкаль ул* халыкның зур тормыш тәҗрибәсен чагылдырган дидактик эчтәлекле, кыска һәм образлы сөйләм берәмлеге. Халык үзе болай, ди «Әйтем – сүзнең бизәге, ә мәкаль – сүзнең җиләге». Аның төбендә кешелеклелек, гаделлек, мәрхәмәтлелек, тыйнаклык кебек матур сыйфатлар ята.

Татар теле һәм әдәбият дәресләрендә аларны тематик яктан берничә төргә бүлеп өйрәнәбез. Ватанга, туган телгә, халыкка мәхәббәт белән сугарылган мәкальләрне дөрес файдалану яшь буында патриотик тойгылар формалаштыруга ярдәм итә.

Белем, акыл, һөнәрлелек темасына караган мәкальләр тырыш хезмәткә,укуга уңай караш тәрбияли.

Яхшылык һәм яманлык, туганнар арасындагы мөнәсәбәтләргә багышланган мәкальләр дә укучыларга әхлакый тәрбия бирүдә мөһим урын алып тора.

Урынлы кулланылган мәкальләр укучыларның белемен тирәнәйтеп кенә калмыйлар, тел дәресләренең тәрбияви әһәмиятен, шәхси эшчәнлекнең нәтиҗәләрен арттырырга ярдәм итәләр.

**Метапредмет нәтиҗәләренә** логик фикерләү,нәтиҗә ясый белү, диалогик, монологик, язма сөйләм төзи белү, үз фикереңне ачык, дөрес итеп аңлату, парларда, төркемнәрдә эшли белү кирә. Бу нәтиҗәләргә түбәндәге эш төрләре аша ирешәм.

Башлангыч сыйныфларда дәреснең башын ярыш формасында башлыйм. Бер дәрестә «Кем күбрәк белә?» дип мәкаль әйтеп җиңүчене белсәк, икенче дәрестә «Дәвамын беләсеңме?» дигән ярышта укучы мәкальне дәвам итәргә тиеш. Һәр дәрескә аерым тәрбия темасын алырга тырышам.

Төркемнәрдә эшләгән вакытта мәкальләрнең бер өлешен генә бирәм, ә икенче өлешен укучылар үзләре уйлап, фикер йөртеп, киңәшләшеп эзләп табалар.

Хикәя укыйбызмы, экиятме, шигырьләр өйрәнәбезме – аларның асылы барыбер әдәпкә кайтып кала. Укылган әсәргә анализ ясала һәм авторның әйтергә теләгән фикере ачыла. Әлеге фикерне укучылар үзләре мәкальләр ярдәмендә тулыландыралар һәм нәтиҗә ясыйлар. Мәсәлән, Ә. Еникинең «Ипекәй» хикәясен укыгач, балалар «Икмәксез алтын тавы башында да үлүең бар», «Ипекәйне кадерсезләмә, үзең кадерсезлеккә төшәрсең» дигән мәкальләрне тәкъдим итәләр.

Уку дәресләрендә, мәкальләрнең тәрбияви функциясеннән киңрәк файдалануны күздә тотып, мәкальләр белән исемләнгән язма эшләр уздырам. Мәсәлән, «Эш беткәч, уйнарга ярый», «Дуслык ашаганда беленми, эшләгәндә беленә», «Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс». Укучы үзенең тәртибен, холык-фигылен тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәяләргә өйрәнә.

Сөйләм үстерү дәреслерендә дә темага эпиграф итеп мәкальләр алырга була. Мәсәлән «Иле барның-теле бар». «Китап-белем чишмәсе».

Рус, башкорт телләре белән чагыштырулар, мәкаль һәм әйтемнәрне тәрҗемә итү дә мәкальләрне тирәнрәк аңларга, аларны истә калдырырга ярдәм итә.

**Фәнне өйрәнү нәтиҗәләренә** фонетик, лексик, морфологик һәм грамматик материалларны, орфографик кагыйдәләрне өйрәнү, ситуация тудыру, уку мәсьәләсен кую, чишү, сөйләм телен баету керә.

Бу нәтиҗәләргә ирешү өчен тел дәресләрендә үтелгән теманы ныгыту, кабатлаулар вакытында мәкальләр белән дә эш оештырам.

Башлангыч сыйныфларда матур язу күнегүе итеп мәкаль дә алына. 2 нче сыйныфта төшеп калган хәрефләр урынына тиешлеләрен куеп язу яисә мәкальләрдән исемнәрне табу кебек эшләр булса, 3-4 нче сыйныфларда мәкальдәге исемнәрнең килешләре билгеләтелә.5-6нчы сыйныфларда сыйфат темасын өйрәнгәндә сыйфат һәм сыйфатланмышларны табу, дәрәҗәләрен билгеләү, сыйфатларны синоним яки антоним белән алыштыру кебек эшләр оештырам.7-8 нче сыйныфларда боерык фигыльләрне, аның төрләрен табабыз, киләчәк заман хикәя фигыльләрнең кушымчаларын күрсәтәбез. Ә инде югары сыйныфларда тест куллануны кулай курәм. Эш тәмамлангач, укучылар бик теләп мәкальләрнең эчтәлеген аңлатырга омтылалар.

Татар теле атналыгыныгының бер көне халык авыз иҗаты буенча иҗади эшләргә багышлана. Укучылар әкиятләр уйлап чыгаралар, табышмаклар, мәкальләр кулланып, ребуслар, кроссвордлар төзиләр. 6 нчы сыйныф укучысы Галимова Лиана мәкальләр кулланып көндәлек режим төзеде. Аны сезгә дә күрәтәсем килде.

Без 5-6 сыйныф укучылары белән берлектә төрле темалар буенча мәкальләр тупланган җыентык булдырдык. Быел «Гаилә елы» булганлыктан, шушы темага караган мәкальләр туплый башладык. Укучылар бу эшкә бик теләп катнашалар. Киләчәктә дә дәвам итәрбез дип уйлыйм.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, халык авыз иҗаты үрнәкләрен дәрестә куллану укучыларның сөйләм күнекмәләрен үстерә, матурайта, баета, фикерләү сәләтен арттыра һәм шәхес тәрбияләү буенча заман куйган таләпләргә җавап бирә дип уйлыйм.

**Әдәбият**

1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Казан, 1959. – Т.1. – 959 б.
2. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Казан, 1963. – Т.2. – 800 б.
3. Исәнбәт Н. Мәкальләребез турында // Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – Т. 1. – Б.5-22.
4. Мәҗитов З.М. Мәкальләрһәмәйтемнәр // Фольклор жанрларын система итеп тикшерү. – Казан: КДУ нәшр., 1987. – Б. 43-49.
5. Урманче Ф.И. Татар халыкиҗаты. – Казан: Мәгариф, 2005. – 383 б.
6. Яхин А.Г., Мәһдиев М.С. Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе. – Казан: КДУ нәшр., 1987. –154 б.


© Калкаманова Г.Ф., 2024

УДК 821.512.145

**Камаева И.И.,**
*Уфа ш., Россия*
*Фәнни җитәкче – ф.ф.к., доцент* ***М.С.Шәрипов***

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА «КЕЧКЕНӘ КЕШЕ» ТЕМАСЫНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

***Аннотация:*** *мәкаләдә автор XX гасыр башы татар әдәбиятында «кечкенә кеше» образының барлыкка килүенең иҗтимагый-тарихи һәм әдәби-эстетик факторларын ача.*

***Терәк сүзләр:*** *әдәбият, реализм, проза, осталык, поэзия, «кечкенә кеше».*

XX гасыр башы татар җәмгыяте сәяси, социаль һәм мәдәни үзгәрешләр белән бәйле сизелерлек үзгәрешләр кичерә. Бу чор милли үзаңның көчәюе, татар мәдәнияте һәм теле белән кызыксынуның үсүе, шулай ук рус мәдәнияте белән актив хезмәттәшлек итү белән характерлана. Татар зыялылары Россия империясенең үсә барган йогынтысы шартларында үз тәңгәллеген саклау һәм үстерүнең мөһимлеген аңлый башладылар. Бу чорда иҗтимагый тормышта, шул исәптән мәгарифтә, әдәбиятта һәм сәнгатьтә сизелерлек үзгәрешләр була.

«Кечкенә кеше» образы XX гасыр башы татар әдәбиятында шул чорның социаль һәм мәдәни чынбарлыгын чагылдырып, әһәмиятле урын алып тора. Бу образ индивидуаль язмышны гына түгел, бәлки халыкның коллектив борчылуларын, аның газапларын һәм өметләрен дә гәүдәләндерә. Татар әдәбиятында «кечкенә кеше» еш кына рәхимсез

тормыш шартлары, социаль гаделсезлек һәм мәдәни маргинализация белән очрашкан гади халык вәкиле буларак күрсәтелә.

«Кечкенә кеше» образының үзенчәлекле сыйфатларыннан берсе – аның каршылыклар белән тулы эчке дөньясы. Бер яктан, ул кимсетүләр һәм газаплар кичерүче, икенче яктан – тирән зирәклек һәм тормыш тәҗрибәсе йөртүче кеше.

Габдулла Тукай һәм аның чордашлары гади һәм тирәнлекне берләштергән образлар тудырганнар, хәтта иң авыр шартларда да кешелек дәрәҗәсен һәм киләчәккә өметне саклап калырга мөмкин икәнен күрсәткәннәр.

Тукай, мәсәлән, үзенең әсәрләрендә еш кына гади кеше образына мөрәҗәгать итә, ул, барлык сынауларга карамастан, үзенең кешелеклелеген һәм адәм балаларына карата кызгану сәләтен саклый. Аның шигырьләре халык зирәклеге һәм тормыш турында фәлсәфи уйланулар белән тулы, бу исә «кечкенә кеше» образын универсаль һәм актуаль итә. Тукай язган әсәрләре белән шуны күрсәтә: җәбер-золым һәм фәкыйрьлек шартларында да кеше әхлакый һәм рухи яктан бай булып кала ала.

Вакыйгалар үсә торган социаль контекст та мөһим аспект булып тора. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәбияты милли яңарыш рухы, үзаңга һәм мәдәни үзенчәлеккә омтылыш белән сугарылган. «Кечкенә кеше» образы халыкның гаделлеккә һәм тигезлеккә омтылышын чагылдырып, хокук һәм ирек өчен көрәш символына әверелде. Бу образ индивидуаль кичерешләрне белдерү чарасы гына түгел, ә яхшы киләчәккә коллектив өметләр дә булып хезмәт итә.

Әйтергә кирәк, XX гасыр башы татар әдәбиятында «кечкенә кеше» образы халыкның шәхси язмышын гына түгел, коллектив кичерешләрен дә чагылдырган күпкырлы һәм катлаулы символ булып тора. Бу образ ул вакыттагы татар җәмгыятендә барган мәдәни һәм социаль процессларны аңлау өчен мөһим корал булып хезмәт итә. Бу образны өйрәнү татар әдәбиятын гына түгел, аның рус әдәбиятына тәэсирен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, алга таба тикшеренүләр һәм чагыштырма анализлар өчен яңа офыклар ача.

XX гасыр башы рус әдәбиятында «кечкенә кеше» образы шул чорның катлаулы социаль һәм мәдәни чынбарлыгын чагылдырып, күпкырлы һәм күп мәгънәле булып тора. Бу образ еш кына җәмгыять күзендә әһәмиятсез булуларына карамастан, эчке көчкә, абруйга һәм кеше зирәклегенә ия булган гади, гади кешеләр белән ассоциацияләнә. Федор Достоевский, Антон Чехов һәм Максим Горький кебек рус язучылары «кечкенә кеше»нең якты һәм истә калырлык образларын тудырганнар,

алар социаль тигезсезлек һәм изелү шартларында яшәү өчен көрәш һәм яшәү мәгънәсен эзләү символына әверелгәннәр.

Федор Достоевский үзенең «Преступление и наказание» һәм «Идиот» кебек әсәрләрендә «кечкенә кеше»не өметсезлек чигендәге хәлләр корбаны итеп сурәтли. Аның геройлары, Родион Раскольников һәм князь Мышкин кебек, аларның кешелеклелеген һәм зәгыйфьлеген ассызыклаган эчке конфликтлар һәм әхлакый дилеммалар белән очраша. Достоевский хәтта иң авыр шартларда да «кечкенә кеше» бөек гамәлләргә һәм тормыш, мәхәббәт һәм гаделлек турында тирән уйлануларга сәләтле булуын күрсәтә.

Антон Чехов, үз чиратында, көндәлек тормыш призмасы аша «кечкенә кеше» образына мөрәҗәгать итә. Аның «Акчарлак» һәм «Чияле бакча» кебек хикәяләрендә һәм пьесаларында персонажлар еш кына социаль һәм икътисади басым шартларында яшәүче гади кешеләр булып күренәләр. Чехов аларның эчке кичерешләрен, хыялларын һәм өмет өзелүләрен оста итеп укучыга җиткерә, шуның белән кеше язмышының тирән һәм күңелне нечкәртә торган суләтен тудыра. Аның геройлары, гади булуларына карамастан, тормыш энергиясе һәм бәхеткә омтылыш белән тулы, бу аларны укучыга якын һәм аңлаешлы итә.

Максим Горький «кечкенә кеше» образын үзенең «Тормыш төбендә» һәм «Ана» кебек әсәрләрендә тәкъдим итеп, игътибарны социаль тигезсезлеккә һәм сыйнфый көрәшкә юнәлтә. Аның җәмгыять төбендәге персонажлары яхшырак тормышка омтыла һәм үз хокуклары өчен көрәшә. Горький хәтта иң авыр шартларда да «кечкенә кеше» каршылык күрсәтергә һәм гаделлек өчен көрәшергә сәләтле булуын күрсәтә. Аның әсәрләре социаль тәнкыйть һәм үзгәрешләргә өндәү белән тулы, бу аларны заманча контекстта да актуаль итә.

Билгеле ки, XX гасыр башы рус язучылары тарафыннан «кечкенә кеше» образын интерпретацияләү кеше тормышының һәм социаль гаделлекнең күп аспектларын ача. Бу образ зәгыйфьлек һәм газаплану символы гына түгел, ә көч, батырлык һәм өмет чыганагы да булып хезмәт итә. «Кечкенә кеше» призмасы аша язучылар әхлак, кеше мөнәсәбәтләре һәм социаль гаделлекнең катлаулы мәсьәләләрен тикшерәләр, бу аларның әсәрләрен төрле буын укучылары өчен актуаль һәм әһәмиятле итә. Татар һәм рус әдәбияты арасындагы үзара бәйләнеш бу контекстта мәдәни һәм әдәби традицияләрне аңлау өчен яңа офыклар ача, халыклар арасында үзара йогынты ясауның һәм идеяләр алмашуның мөһимлеген ассызыклый.

«Кечкенә кеше» образы XX гасыр башы татар әдәбиятында бу чорда татар халкы тормышының социаль, мәдәни һәм психологик аспектларын чагылдырган күпкырлы һәм тирән күренеш булып тора. Бу

образның төп сыйфатларын ул очрый торган төрле әсәрләр призмасы аша, шулай ук аның әһәмиятен һәм иҗтимагый аңга йогынтысын анализлау аша аерып карарга мөмкин.

Г, Ибраһимов «Карт ялчы», «Көтүчеләр» хикәяләрендә татар халкы вәкилләре булган тормыш төбендә интегүче «кечкенә кеше» образларын иҗат итте. Ф.Әмирхан «Сәмигулла абзый», «Габделбасый гыйшкы» хикәяләрендә, тәмамланмаган «Урталыкта» романында ниндидер конкрет эшләргә сәләтсез булганг «кечкенә кеше» тибын тудыра һәм ул тип Н. В. Гогольнең «Шинель» повестендә сурәтләнгән Акакий Акакиевич образы хәтерләтә. Татар әдипләре Г.Исхакый, Ш.Камал да бу юнәлештә иҗат итәләр һәм уңышларга ирешәләр. Шәриф Камал үзенең «Сәмруг кош» исемле хикәясендә, ярты сәгать эчендә кояшка менеп җитәргә һәм кояшның тап уртасына мескен бүреген элеп, европалыларны шаккатырырга җыенгана Гайнетдин Гайнелисламов образын тудыра һәм аңардан үтергеч көлә, күз яше аша көлә.

Татар әдәбиятында «кечкенә кеше» образының мәйданга чыгу ни сәбәпләргә бәлән бәйле иде? Беренчедән, «кечкенә кеше» социаль гаделсезлек һәм икътисади хәерчелек шартларында яшәүче гади кешене символлаштыра. Бу образ еш кына крестьяннар, эшчеләр һәм җәмгыятьнең түбән катлам вәкилләре белән образлары ассоциацияләнә, аларның язмышлары һәм кичерешләре әсәрләренең үзәк темасына әверелә». Мондый текстларда авторлар бу кешеләрнең эчке дөньясын, аларның хыялларын, өметләрен һәм газапларын күрсәтергә омтыла, бу исә укучыга аларның тормыш чынбарлыгын тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә.

Икенчедән, «кечкенә кеше» ныклык һәм батырлыкны гәүдәләндерә. Авыр тормыш шартларына карамастан, бу образны гәүдәләндерүче персонажлар еш кына гаҗәеп рух көчен һәм каршылык күрсәтү сәләтен күрсәтәләр. Бу аларның гаделлеккә омтылуларында, яхшырак тормыш эзләүләрендә һәм үз язмышларын үзгәртү теләгендә чагыла. Мондый сыйфатлар «кечкенә кеше»не теләктәшлек объекты гына түгел, ә хокук һәм ирек өчен көрәш символы да итә.

Образның өченче төп үзенчәлеге – аның мәдәни тәңгәллек белән бәйләнеше. «Кечкенә кеше» татар әдәбиятында еш кына традицион кыйммәтләрне, гореф-гадәтләрне һәм телне йөртүче булып тора. Бу чор әсәрләрендә авторларның гади кешеләр образлары аша татар мәдәниятенең байлыгын, аның фольклор элементларын һәм әхлакый дәресләрен ничек тапшыруларын күрергә була. Бу геройның шәхси язмышы һәм халыкның мәдәни мирасы арасында тирән бәйләнеш тудыра.

Дүртенче сыйфат – образның универсальлеге. «Кечкенә кеше» нең татар контекстына хас үзенчәлекләре булса да, аның кичерешләре һәм

омтылышлары башка мәдәниятләр һәм чор кешеләренә аңлаешлы һәм якын булырга мөмкин. Бу образны заманча әдәби дискурста да актуаль итә, аңа исән һәм әһәмиятле булып калырга мөмкинлек бирә. «Хәзерге татар әдәбият белеме XX гасыр башындагы милли әдәбиятны өйрәнүнең теоретик һәм тарихи-мәдәни мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Галимнәр язучыларның иҗатын өйрәнү принципларын үзгәртергә, бүгенге көн позициясеннән әсәрләрне аңлатырга, сәнгать текстларын заманча һәм традицион анализ ысуллары белән тикшерергә, XX гасыр башындагы иҗтимагый-фәлсәфи фикер нәтиҗәсе булган әсәрләрне ачыкларга омтылалар» [2; 328].

Хәлбуки XX гасыр башы татар әдәбиятында «кечкенә кеше» образы күп катламлы һәм әһәмиятле булып тора. Ул үз чорының социаль чынбарлыгын гына түгел, ә тирән мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләрен дә чагылдыра. Бу образны анализлаганда, әдәбиятның халыкның өметләрен һәм газапларын чагылдыру чарасына, шулай ук гаделлек һәм кеше хокуклары өчен көрәш коралына әверелүен күрергә мөмкин. «Кечкенәдән кеше» катлаулы дөньяда гади кешенең әһәмиятен ассызыклап, язучыларны һәм укучыларны рухландыруны дәвам итүче мөһим символ булып кала.

Ахырда, XX гасыр башы татар әдәбиятында «кечкенә кеше» образын тикшерү аның күпкырлылыгын һәм әһәмиятен ассызыклый. Бу образ сәнгать чарасы гына түгел, ә вакыт рухын һәм кешенең эчке кичерешләрен чагылдырган мөһим мәдәни символ да булып тора. «Кечкенә кеше» булган әсәрләргә анализ ясау татар әдәбиятын гына түгел, мәдәниятне, аның кыйммәтләрен һәм традицияләрен тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә.

Г.Ибраһимовлар, Ф. Әмирханнар иҗат иткән «кечкенә кеше» тибы тоталитаризм чорында, иҗтимагый һәм әдәби образ буларак, мәйданнан югала, аның урынына идеологик көрәшне чагылдыручы яңа әдәби геройлар килә башлый. Татар прозасына сыйнфый конфликтлар, инкыйлабый пафос үтеп керә. Әмма, ничек кенә булмасын, әдәби хәрәкәт бара, тормышның үзендә мондый типлар яшәүләрен дәвам итә. XX гасырның икенче яртысында күренекле проза остасы Рафаил Төхфәтуллин, мәсәлән, кабатланмас Фазылҗан абзый белән аның карчыгы Хөббениса карчык кебек «кече кеше» образларын гәүдәләндергән «Җәйге челләдә» хикәясе белән югары фикерне раслады.

Шулай итеп, «кечкенә кеше» образы татар халкының әдәби мирасының гына түгел, ә аның мәдәни үзенчәлегенең дә мөһим элементы булып тора дип әйтергә була. Ул кешеләрнең йөрәкләрендә яшәвен дәвам итә, аларны иҗатка һәм тормыш, аның мәгънәсе һәм кыйммәтләре турында уйлануларга рухландыра. Бу образны өйрәнүнең дәвам итүе, яңа

офыклар ачуы һәм татар әдәбияты һәм тулаем мәдәнияте турында аңлауны тирәнәйтүе мөһим.

**Кулланылган әдәбият**

1. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

2. Шарипов М.С. Дәрдемәнд иҗатын өйрәнүдә герменевтика методы // Актуальные проблемы современной татарской филологии: сборник статей X Всероссийской научно-практической конференции (9 декабря 2022 г.) / отв. ред. И.Ф. Зарипова; И.К. Фазлутдинов. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2022. – С.328-332.

© Камаева И.И., 2024

УДК 821.512.145

**Камалова А.Р.,**
*Уфа ш., Россия*
*Фәнни җитәкче – ф.ф.к., доцент* ***И.Ф.Зарипова***

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ МОДАЛЬ СҮЗЛӘР БЕЛӘН БЕЛДЕРЕЛГӘН СҮЗ ҖӨМЛӘЛӘР

***Аннотация:*** *мәкаләдә модаль сүзләр белән белдерелгән сүз-җөмләләргә күзәтү ясала. Нигездә, мондый синтаксик конструкцияләр раслау я инкарь итүне белдерә.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, синтаксис, җөмлә, модаль сүзләр, сүз-җөмлә.*

Элек-электән галимнәр телне өч компонентка: фонетика, грамматика һәм лексикага бүлгәннәр. Грамматиканың бер төре булып синтаксис тора. Ул җөмлә һәм сүзтезмәләрдә сүзләрнең бәйләнеш закончалыкларын, җөмлә төзелешен, җөмләләрнең синтаксик бөтенгә һәм текстка оешу принципларын өйрәнә.

Татар синтаксис фәненең тарихы 1814 елда башлана: Александр Троянский тарафыннан язылган «Краткая татарская грамматика» дигән хезмәт дөнья күрә. Тиздән татар теле синтаксисын өйрәнү буенча күбрәк хезмәтләр чыга. Мартиньян Ивановның «Татарская грамматика» (1842), Александр Казимбәкнең «Общая грамматика турецко-татарского языка» (1846), Мөхәммәтгали Мәхмүдевнең «Практическое руководство к изучению татарского языка» (1857), Каюм Насыйринең «Краткая

татарская грамматика, изложенная в примерах» (1860), «Әнмүзәҗ» (1895) һәм А. Архангельскийның «Грамматика народно-татарского языка» (1894) дигән хезмәтләре татар синтаксисына нигез салалар. XX гасырда бу фән Ш.Х. Иманаев, Г.Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г.Х. Алпаров, М.З. Зәкиев, В.Н. Хангильдин, Ф.С. Сафиуллина, Р.Г. Сибәгатов һ.б. күренекле галимнәр тарафыннан үстерелә [1; 137]

М.З. Зәкиев синтаксисның өйрәнү объекты буларак сөйләмне, ә аның хәбәрлеккә һәм модальлеккә ия булган иң кыска берәмлеге буларак җөмләне билгели [6; 14].

Татар телендә структур-семантик үзенчәлекләре буенча җөмләләрне төркемләүнең берничә принцибы бар. Мәсәлән:

1. Әйтү максаты буенча хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләр;

2. Көчле хис-тойгы белән әйтү-әйтмәүгә карап, тойгылы яки тойгысыз җөмләләр;

3. Хәбәрлекнең реаль булу-булмавыннан чыгып, раслау яки инкяр җөмләләр;

4. Әйтелергә мөмкин булган кисәкнең әйтелү-әйтелмәвенә карап, тулы һәм ким җөмләләр;

5. Хәбәрлекле үзәкнең санынннын чыгып, гади һәм кушма җөмләләр;

6. Оештыра торган үзәкнең санына карап, бер составлы һәм ике составлы гади җөмләләр;

7. Җөмләнең грамматик нигезен формалаштыручы баш кисәкләргә карап, таркала һәм таркалмый торган җөмләләр.

«Бер сүз яки тотрыклы сүзтезмә белән белдерелгән, үз составында аерым җөмлә кисәкләренә таркалмый торган, күбесенчә коммуникатив функцияне диалогик сөйләмдә башкаручы җөмләләр грамматик яктан таркалмый торган җөмләләр дип атала. Аларны башкача сүз җөмләләр дип атыйлар» [5; 337].

Бүгенге көндә сүз җөмләләрнең синтаксик парадигмасындагы урынына өч караш барлыкка килде: сүз җөмләләр бер составлы җөмләнең төркеменә керә (М.З. Зәкиев, Ф.С. Сафиуллина); сүз җөмләләр таркалмый торган җөмләләргә генә керә (В.В. Бабайцева, Н.С. Валгина, Г.И. Кустова, П.А. Лекант, Л.Ю. Максимов); сүз җөмләләр җөмләнең системасыннан тыш каралырга тиеш (В.А. Белошапкова, В.В. Виноградов, Е.М. Галкина-Федорук, А.М. Пешковский, Н.Ю. Шведова) [2; 93].

Сүз җөмләләр «модаль квалификацияләрнең, эмоциональ бәяләү, ихтыярый һәм менталь реакцияләрнең, шулай ук аралашу вакытында кулланыла торган төрле дәрәҗәдәге субъектив-бәяләү репликаларының киң диапазонын белдерү өчен хезмәт итә торган сүзләрдән оеша» [3; 492].

Шуңа күрә татар телендәге сүз җөмләләрне, белдерелешләренә карап, берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин: ымлыклар белән белдерелгән сүз җөмләләр, модаль сүзләр белән белдерелгән һәм аваз ияртемнәре белән белдерелгән җөмләләр.

Ымлыклар белән белдерелгән сүз җөмләләр дә, мәгънәләренә карап, семантик яктан эмоциональ (***Вай**! Тагын соңга кала бу бала.* (Ф.Әмирхан)) һәм императив (*Алда – мәңгелек кыш. **Хуш**...* (Л. Сәгыйдуллина)) сүз җөмләләргә бүленәләр. Ә алар, үз чиратында, тагын да ваграк төркемнәрне берләштерә.

Татар теле синтаксисында аваз ияртемнәре белән белдерелгән сүз җөмләләр аерым төр булып торалар. Һәм аваз ияртемнәренең мәгънәсенә карап, сүз җөмләләр шулай ук тавыш тасвирларын (*Эләктеңме иблис токымы! **Хе-хе-хе**...* (Г. Ибраһимов)) һәм образ тасвирларын (***Ялт**! итте яз кылычы кыеп күкне* (Дәрдемәнд)) белдерүче җөмләләргә бүленәләр.

Модаль сүзләр белән бирелгән сүз җөмләләр, гадәттә, раслауны я инкярне белдерүче модаль сүзләрдән торалар.

А.С. Крайнова «Согласие и несогласие в русском речевом общении: лингвистический и коммуникативный аспекты» дип аталган мәкаләсендә бу бүленешне тагын да конкретлаштыра. Аның фикеренчә, раслау җөмләләр составында түбәндәге төркемнәр карала ала:

1. Чын раслауны белдергән сүз җөмләләр.

Мәсәлән:

*– Хат алдың, ахры? – дидем мин.*

– ***Әйе.*** (И. Гази).

2. Кемнеңдер фикере белән ризалашуны белдерүче сүз җөмләләр:

*Аның белән көлеп сүз башладым,*
*Көлеп җавап бирде.*
*Уйнап кына: «Чыгасыңмы?» – дидем.*
*Уйнап: «**Ярар!**» – диде* (Р. Гаташ).

3. Сөйләүченең үз фикере белән ризалашуны белдерүче сүз җөмләләр (монологик сөйләмдә) [4; 82]. Мәсәлән:

*Тормыш – хата...*
***Ярый**... Әле яшимен ич каралама.*
*Икенчегә яшәрмен дип актан акка.* (Л. Сәгыйдуллина).

Инкарьне белдерүче сүз җөмләләр дә, раслауны белдерүче таркалмый торган җөмләләр шикелле, эчтәлекнең характерына карап, шулай ук берничә типка бүленә:

1. Чын инкарьне белдергән сүз җөмләләр.

Мәсәлән:

– *Рух. Шундый исемне ишеткәнең бар идеме?* – ***Юк.*** (Г.Гыйльманов).

2. Кемнеңдер фикере белән ризалашмауны белдерүче сүз җөмләләр:

*Ә Совнаркомдагы Ленинның бүлмәсе*
*Бик озак көтте хуҗасын, —*
*Килмәде...*
*Таш дивар,*
*Ятим диваннар белмәде...*
***Юк!***
*Ул үлмәде!* (Һ. Такташ).

3. Сөйләүченең үз фикере белән ризалашмауны белдерүче сүз җөмләләр (монологик сөйләмдә) [4; 84]. Мәсәлән:

***Юк!*** *Тоттырмыйм! Йөгерәм! Өлгерәм?!. Әбәк!..* (Л. Сәгыйдуллина);

*Уйлыйсыздыр: адәмнәргә шагыйрьнең үзе кирәк?*
***Юк!*** *Шагыйрьнең, үзе үлгәч, даны һәм сүзе кирәк...* (И. Юзеев).

Кайвакыт мәгънәне көчәйтү өчен «юк» сүзе редупликацияләнергә, ымлык я кисәкчә белән янәшә килергә мөмкин:

***Ах! Юк!*** *Сөйләмәгез, мин сорыйм* (Һ. Такташ);
*Яшәешнең зар-кайгысын гына,*
*Таный белгән йөрәк йөртәмме?*
***Юк ла! Юк ла!*** *Чәчләремне тарап,*
*Җил җилдереп үтә иртәнге* (А. Суфиянов);

*Алар... Алар мине үтерде!*
***Юк, юк!*** *Мин үлмәдем! Әле мин үлмәдем!* (Һ. Такташ).

Димәк, сүз җөмләләрнең функцияләре алдагы әйтелгән фикергә экспрессив-модаль бәя бирүгә, гади раслауга я инкарь итүгә, яисә ризалашу я ризалашмауны белдерүгә кайтып кала.

Раслау һәм инкарь итүче сүз җөмләләр, гадәттә, раслауны я инкярне белдерүче модаль сүзләрдән торалар. Күбесенчә, мондый җөмләләрдә «әйе», «ярый», «ярар», «юк» сүзләре кулланыла. Һәм, моннан тыш, модаль сүзләр белән бирелгән сүз җөмләләр, аларның эчтәлегенә карап, төрле төркемнәргә бүленергә мөмкин.

**Әдәбият исемлеге**

1. Зарипова И.Ф. Способы выражения нечленимых предложений в татарском языке // Теоретические и практические проблемы развития современной гуманитарной науки. – Уфа: УУНиТ, 2023. – С. 135-140.

2. Камалова А.Р., Зарипова И.Ф. Аваз ияртемнәре белән белдерелүче таркалмый торган җөмләләр // Актуальные проблемы современной татарской филологии. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2023. – С. 92-96.

3. Караулов Ю.Н. Русский язык. Энциклопедия. – Москва: Дрофа, 1997. – 722 б.

4. Крайнова А.С. Согласие и несогласие в русском речевом общении: лингвистический и коммуникативный аспекты // Теория и практика сервиса: экономика, социальная сфера, технологии. – Санкт-Петербург: СПбГУСЭ, 2012. – С. 81-86. – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/soglasie-i-nesoglasie-v-russkom-rechevom-obschenii-lingvisticheskiy-i-kommunikativnyy-aspekty/viewer (мөрәҗәгать итү датасы: 13.11.2024).

5. Розенталь Д.Э., Голуб И.Б., Теленкова М.А. Современный русский язык – 11-е изд. – М.: Айрис-пресс, 2010. – 448 с.

6. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – Т. III. – 536 б.

© Камалова А.Р., 2024

УДК 811.512.145

**Камалова А.А., Халиуллина Н.У.,**
*Уфа ш., Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «БӘХЕТ» КОНЦЕПТЫ

***Аннотация:*** *хезмәттә дөнья тел картинасында «бәхет» концептының эчтәлеге чагыштырма аспектта анализлана. Әлеге концепт лингвокультурологик берәмлек буларак карала.*

***Терәк сүзләр:*** *концептосфера, лингвокультурология, семантика.*

«Бәхет» төшенчәсе төрле халыклар мифологиясендә һәм төрле дини фәлсәфәдә төрлечә аңлатыла. Әйтик, әлеге төшенчәне антик заманнардан башлап, бүгенге көнгә кадәр философик һәм психологик дәрәҗәдә төрле галимнәр өйрәнгәннәр. Тарихи үсештә «бәхет» төшенчәсе гел трансформацияләнеп торган; иң элек ул объектив нигездә булып, кешегә хас игелек дип кабул ителгән. Мәсәлән, Борынгы Грециядә еш кына бәхет эвденомия дип йөртелгән, ягъни бәхет, «уңышлы тәкъдир» дигән мәгънәдә. Греклар бәхет чыганагы кешедән тыш дип инанганнар.

Акрынлап «бәхет» төшенчәсе субъектив характер кабул итә – ул кешенең тормышта булган вакыйгаларга мөнәсәбәте, аның үзендә булган сыйфатларын бәяләү кебек аңлатыла башлый. Борынгы грекларда мондый бәхет эвтюмия дип аталган, ягъни «җан тынычлыгы, күтәренке кәеф». Бүгенге көндә бәхет ул – субъектив сиземләү һәм тормыштагы вакыйгаларның объективлыгы комбинациясе.

Лингвистик концепт буларак, бәхет бик күп галимнәрнең (С.Г. Воркачев, И.С. Гаврилова, И.Б. Русакова һ.б.) өйрәнү объекты булып торган. Алар бәхетне катгый структурасы булмаган, ләкин аңлатып була торган, мәгънәгә ия һәм образлы катламнардан торган лингвокультур концепт итеп аңлыйлар.

Борынгы мифологиядә «бәхет» төшенчәсен «җил очыртып бара торган озын толымлы хатын-кыз» рәвешендә сурәтләгәннәр [1]. Ул янына очып килеп ятканда, толымыннан эләктереп кенә аласы! Ләкин йоклап торсаң, бәхетең тиз генә очып китеп тә бара, тоту мөмкинлегең бетте дигән сүз.

Рус лингвокультурасында бәхетне белдерә торган «счастье» сүзе кешенең нindидер үзе сайлаган уңай өлешкә ия булуын күрсәтсә, «доля» сүзе бәхетнең бүлеп бирелгән начар өлешен аңлата. «Делаю у+дачи» дип шул гамәл кыла торган җир янына эләгүне теләүне аңлатканнар. Савыт-саба ватылса, «бәхеткә» дип әйтәләр, монда тагын шул өлешкә ия булу мөмкинлеге турында сүз бара.

Гарәп телендә исә «бәхет» дигән сүз «очраклы хәл» дигәнне аңлатып килә. Бу аңлатманың татар теле фәлсәфәсенә туры килмәвен «бәхетеннән щашкан» дигән әйтем дә белдерә. Мәсәлән, төрки-татар язмышы буенча нindидер нәтиҗәгә ирешә икән, аның өчен шул нәтиҗә очраклы хәл түгел. Шуңа күрә «бәхет» көтелмәгән әйбер булып кешене акылдан яздыра.

Борынгы төрки телендә «шатлык» сүзе, «бәхет» төшенчәсе белән бергә «кот», «җан» мәгънәләрен белдерә. Ягъни, *кот* – бәхет, шатлык, байлык белән тиңләштерелгән. Бәхет-шатлык, байлык теләү белән бәйле рәвештә борынгы төрки телендә һәм иске татар телендә Кутлуг, Котби, Котлыбәк, Котлыкай, Котчы һәм башка исемнәр барлыкка килгән. Шуннан Кутчин, Котлин, Кутлин, Кутуков, Кутыев, Котаев, Кутаев фамилияләре ясалган.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бәхет сүзенә түбәндәге бәя бирелгән: «*Бәхет*» – иң көчле һәм тулы канәгатьлек хисе (халәте); уңыш, уңышка очрау, уңай язмыш; көчле, уңай хисләр барлыкка килә [2].

«Бәхет ул нindидер вакыйгалар яки гамәлләр нәтиҗәсендә барлыкка килүче эчке гармония һәм канәгатьлек хисе», – дип белдерә психологлар. Ул озакка да сузылырга, кыска гына да булырга мөмкин,

ләкин бу хис һәрвакыт кешегә канәгатьлелек китерә. Ә канәгатьлек чынбарлыктагы вакыйга, хыялдагы сурәт белән тәңгәл килгәндә була торган рухи халәт. Бөтен хикмәт тә шунда инде: бәхет ачкычы һәркемнең үз эчендә. Тик бәхетне кем беләндер бергәләп гамәл кылганда гына татырга мөмкин. Игътибарың һәм энергияң нәрсәгә дә булса, мәсәлән, тормышка, кешеләргә таба юнәлгән булса, бәхетне күрергә һәм тоярга мөмкин. Ләкин дикъкатеңне юнәлтеп, аны эзли башласаң, ул шунда ук кача. В.Франклин сүзләре бу очракта бик тә туры килә: «Бәхет күбәләк кебек. Тотам дип куган саен тоттырмый. Ләкин әгәр игътибарыгызны башка әйбергә күчерсәгез, ул әкрен генә килә дә, иңбашына куна» [1].

Бәхет төшенчәсен тикшерү белән, нигездә, дин, философия һәм психология фәннәре шөгыльләнә. Бәхеткә карата яһүд динендә бик үзенчәлекле караш яшәп килә. Кеше тулы бәхеткә ирешер өчен 613 вәгазьне үтәргә тиеш, аның башка мөмкинлекләре юк. 613 гамәл ике төп категориягә бүленә. Беренче категориягә 248 үтәлергә тиешле гамәл керсә, икенче категориягә 365 эшләнергә ярамаган гамәл керә. Эшләргә ярамаган гамәлләр саны төгәл 365, бу яһүдләрнең Талмудында язылганча, бер елдагы 365 көн белән тәңгәл килә, 248 үтәлергә тиешле гамәлләр – кеше тәнендәге әгъза һәм сөякләр саны белән аңлатыла. Икенче яктан, яһүд диненең классик юнәлеше белгечләре әйтүенчә, кешегә бәхетле булыр өчен, деструктив уйлардан арынып, уңай булган, конструктив уйларга күчәргә киңәш итәләр, христиан динендә килгәндә инде, бәхеткә якын килү өчен син үзеңнен Ходай алдында, камил, төгәл булмавынны аңлауда ята.

Христиан динендә әйтелгәнчә, бәхетле булыр өчен билгеле бер әйберләр булырга тиеш. Мәсәлән, христианга бәхетле булыр өчен Ходайның мәхәббәте, рәхмәте кирәк. Моның өчен йөрәгеңә Иисус Христосны кабул итәргә, йолаларын үтәргә, чиркәүгә йөрергә, кагыйдәләрне үтәргә, димәк, даими рәвештә, кайбер гамәлләрне үтәргә тиеш буласың. Христиан динендә бәхет төшенчәсе вакытлыча дип күрсәтелә, чөнки кеше тормышында бәхет һәрвакыт кәнәгатьсезлек һәм кайгы белән алмашынып тора. Шулай ук христиан динендә бәхет төшенчәсен *ләззәт* төшенчәсе белән тәңгәл куялар. Бу халәт үз эченә барлык кәнәгатьләнү шартларын да ала.

Ислам динендә бәхет төшенчәсенә бөтенләй икенче караш; матди уңайлык бәхет китерми дип санаала. Коръән күзлегеннән караганда, абсолют бәхеткә кеше үз өстендә һәрдаим эшләп кенә ирешә ала. Бәхет турындагы мөселман доктринасы, яһүд динендәге кебек, Сөннә күрсәтмәләрен үтәүгә кайтып кала. Бәхеткә юл исламның биш кагыйдәсен үтәүдән башлана: Аллага гына табыну һәм Мөхәммәт пәйгамбәр миссиясен үтәүне тану, Көненә биш тапкыр намаз уку, Рамазан аенда

ашау-эчүдән тыелып тору, Мохтаҗ кешеләргә хәер бирү, Мәккә шәһәренә Хаҗ кылу. Сөнни исламда, Мөхәммәт пәйгамбәрнең, хәдисләр аша җиткерелгән гадәтләрен кабатлау, кылган эшләрен эшләү, үгет-нәсихәтләрен үтәп яшәү – ул үзе бәхет диелә. Ислам дине билгеле бер яшәү рәвешен таләп итә. Кешеләргә якты йөз күрсәтеп, булганыңа куанып яшәргә чакыра.

Будда диненә килсәк, бәхет төшенчәсе астында кешенең үз теләкләрен кәнәгатьләндерү тора. Шул ук вакытта, теләк – негатив һәм тискәре йогынтыгыга ия. Теләк булу – ул патология. Кеше бер теләген кәнәгатьләндерү белән генә чикләнми, аның теләкләре көннән-көн күбәя. Бу, үз чиратында, ябык боҗра хасил итә. Шуңа күрә Буддизмда бәхет – ул ләззәт, кәнәгатьләнү, уңыш, казаныш, ә бу әйберләр мәгънәсез булып санала.

Төрле кешеләр бәхет төшенчәсен төрлечә ассоциацияли, әмма тагын да көчлерәк бу аерма, халыклар арасында күренә. Тарихи вакыйгалар, культура,тирә-яктагы шартлар һәм башка факторлар йогынтысында символлар барлыкка килә. Алар тормышның төрле якларын күренешләрен аңлатып киләләр. Күп кенә халыкларда бәхет символлары охшаш. Мәсәлән, Феникс – мифологик ут кошы, ул үзенең көленнән барлыкка килгән дип карала. Ул, бик күп халыкларда, бәхет, мәңгелек, үлемсезлек, дан-шөһрәт символы булып тора. Аның тарихы безнең эрага кадәр, V нче гасырда Геродот хезмәтләрендә искә алына. Аннары инде бәхет кошы турындагы ышанулар христиан дөньясына, соңыннан инде яһүд культурасына һәм Борынгы Россия территориясенә дә үтеп керә. Шулай итеп, Финиста һәм Бәхет кошы турында мифлар барлыкка килә. Халык арасындагы оста куллы кешеләр, бәхеткә дип, агачтан аларның сурәтләрен кисеп эшли башлыйлар. Соңыннан, Феникс белән беррәттән башка, бик күп кошларны да символ итеп саный башлыйлар. Мәсәлән: кыргавыл, тәвис кошы, император үрдәге һ.б. Кытайда бәхет символы булып әтәч тора. Тәвис кошының койрыгы, Мин династиясе идарә иткән чорда бәхет символы булган. Киң таралган бәхет символы булып, торна кошы санала. Ул рухи омтылыш, мәңгелек мәхәббәт һәм шатлыкны символлаштырып килә. Алдагы бәхет символы булып, свастика тора. Бүгенге көндә свастика, бик сирәк кенә яхшы нәрсә белән ассоциацияләнә, әмма башта ул бәхет символы дип саналган. Очлары бөгелгән тәре, Азия, Африка, Европа һәм Американың борынгы культураларында очрый. Буддизмда – Будданың йөрәге, японнарда- озын, бәхетле тормыш, кытайлыларда – уңай энергия туплау. Күп кенә халыкларда яшәү символы, яктылык, иминлек, бәхет символы булып санала.Борынгы Грециядә бәхет символы булып күбәләк саналган. Эросның хатыны Психея күбәләк образына керә. Борынгы мисырлылар

анын сынын фрескаларда һәм пирамидаларда төшергәннәр. Бүгенге көндә дә, бу матур бөҗәк, күп кенә халыкларда бәхет һәм шатлык символы булып тора. Һинд буддистларының ышанулары буенча, Будданың флейтасына 8 күбәләк кунган дип карала. Кытайда кияү булган кеше, булачак хатынына тере яки нефриттан ясалган күбәләк бүләк итә. Бу аның бәхет һәм озын гомер теләвен аңлата.

Ат дагасын уңыш символы дип саныйлар, ләкин күбесенчә ул бәхет символы дип карала. Даганың үзенчәлекле булуына христиан халыклары, төркиләр, яһүдләр һәм бик күп башка башка халыклар ышана. Борынгы заманнардан ук аның кара көчләрдән саклый торган үзенчәлеге бар дип уйлаганнар. Ышанулар буенча, даганы ойнең ишек башына элсәң, өй хуҗалары бәхетле булачак дип саналган.

Бүгенге көндә дә бәхет проблемасы актуаль проблемаларның берсе булып кала бирә. Кеше яшәгән чор, буын алышынган саен бәхет төшенчәсенең дә кыйммәтләре үзгәрә бара.

**Әдәбият**


1. Новый энциклопедический словарь. – М.: Большая Российская энциклопедия, 2000. – 1040 с.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казань. Татар. китап нәшрияты, 1979. – 476 б.


© Камалова А.А., Халиуллина Н.У., 2024

УДК 811.512.145

**Камалова З.Х.,**
*Дүртөйле ш., Россия*

# ПОЛИЛИНГВАЛЬ ШАРТЛАРДА ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕН ЧАГЫШТЫРЫП УКЫТУ

***Аннотация:*** *мәкаләдә полилингваль белем бирү мохитендә эшләүче укытучы тәҗрибәсе чагыла. Рус телле балаларга татар телен өйрәтү алымнары үзара бәйләнештәге телләрнең типологик үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләнгән.*

***Терәк сүзләр:*** *полилингвизм, икенче тел буларак татар теле, аңлы-чагыштырма метод, рус телле балаларны татар теленә өйрәтү алымнары.*

Рус мәктәбендә укучы балаларга туган (татар) телне укыту – бик катлаулы, җитди эш. Яшерен-батырын түгел, күп балалар русча фикерли, өйдә әти-әниләре белән дә туган телдә аралашмый диярлек яки ике телне

катыштырып сөйләшә. Ата-аналар баласын татар төркеменә биреп, аның сөйләмендә рус теле тәэсирендә булган акцентын бетерүне, татарча сөйләмне аңлавын, туган телдә матур итеп сөйләшергә өйрәнүен тели.

Соңгы елларда рус мәктәпләрендә эшләүче укытучылар телгә өйрәтүдә дөрес методика сайларга, грамматикага өйрәтүдән китеп, аны коммуникатив максатка ярашлы өйрәтүгә күчеп баралар.

Кешеләр чит телне өйрәнә башлаган вакыттан бирле телләрне чагыштырып өйрәнү яшәп килә. Татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасын төзүне башлап җибәрүче дип энциклопедист-галим һәм мәгърифәтче К.Насыйрины атый алабыз.

Ике телне чагыштырып өйрәткәндә фонетика, орфоэпия үзәктә торырга тиеш. Төп күнекмәләр башлангыч классларда булдырыла, алга таба алар камилләштерелә. Дөрес әйтелеш күнекмәләрен булдыру өчен, мисаллар бала хәтерендә калырдай булырга тиеш. Аерым игътибарны “охшаш” авазларга юнәлтергә кирәк. Мәсәлән, как – пастила, как – ничек; хата – ошибка, хата – жилье; бар – иди, бар – место для общественного питания.

[а] авазының ике телдә дә дөрес әйтелешен аңлаткач, тренажерларга күчү отышлы:

БА ВА ГА ДА КА ЛА МА НА ПА РА СА ТА ФА ХА ЧА ША иҗекләрен башта русча, аннары татарча укытып карыйбыз. Аннары сүзләргә күчәбез: МАЛАЙ АЛМА ТАТАР КАЗАН БАТЫР БАЛА АЛГА САБЫР АЛКА АВИАЦИЯ АРТИСТ АФИША ГАЗЕТА АДРЕС ПАНДА НАБАТ АЛМАЗ

«Рус кешесе татар сүзләрен ничек укыр иде?» – дип, балалардан укытып карыйбыз.

Рус теленнән кергән алынма сүзләрдә [о], [ы], [э] авазлары сузыбрак әйтелә. Хәреф бер, ике төрле аваз. Балалар өчен монысы да язганда, сөйләгәндә кыенлык тудыра. Мондый авазлар белән эшләгәндә дә чагыштыру алымын кулланабыз. Мәсәлән: ОН БОР ТОТ КОЛ кебек сүзләрне башта русча укыйбыз, татарчага тәрҗемә итәбез. Икенче вариантта шул ук сүзләрне татарча укыйбыз, русчага тәрҗемә итәбез.

Монда да тренажерлар ярдәмгә килә. ОРДЕН ПОСЫЛКА НОТА ТОРТ МОДА БОКС ОПЕРА ФУТБОЛ ТОЗ БОРЧАК СОРАУ ОРЛЫК ХОЛЫК КОРТ КОҢГЫЗ СОҢ сүзләрен татар кешесе булып та, рус кешесе булып та укып карыйбыз.

1-5 классларда тренажерлар белән һәр дәрестә эшләү (һәр дәрес башында) мөһим. Бу эш өзлексез, системалы алып барылырга тиеш, шул чагында ул үз нәтиҗәсен бирә. Балалар авазларны дөрес әйтергә өйрәнә.

Татар һәм рус телләрендә тартыкларның калын яки нечкә әйтелүенең нәрсәгә бәйле булуын төшенү исә балаларга дөрес язу

күнекмәләрен үстерергә булыша: угол –уголь, мел-мель; кул,  бул, тал; күл, гөл, кил. Әгәр бала татар телендә тартыкларның нечкәлеге сузыклар белән бәйле икәнен аңласа, киләчәктә язганда ул хаталар җибәрмәячәк. Аңламаса, дәфтәр тышларына татрча язганда  Ильнур, Ильгиз дип язулар дәвам итәчәк. Мин үз практикамда русча язганда нечкәлек билгесе язылган, ә татарча язганда язылмаган кеше исемнәрен  кайсы төркем күбрәк яза ала дип  ярыш оештырам.

Җөмләдә сүз тәртибен өйрәнгәндә дә ике телдә җөмләләрне чагыштырып, аермалы һәм охшаш якларны күрсәтү кирәк. Ике тел җөмләләрен чагыштырып өйрәнү, алардагы бертөрле, охшаш һәм аермалы якларны күрсәтү – сөйләм практикасы өчен бик мөһим. Җөмлә кисәкләренең  ике телдә урнашу тәртибенә игътибарны юнәлтү, телдән бик күп мисаллар төзетеп карау мөһим. Р.Р.Нигъмәтуллина  төзегән методик кулланмалар монда  миңа зур ярдәм булып тора. Ул тәкъдим иткән күнегүләр укчыларга да ошый, аларның кызыксынуын арттыра. Гомумән, туган тел дәресләрендә телдән эшләүгә зур игътибар бүлү кирәк. Мин дәрес вакытының 60–70% сөйләшүгә алам. Ә сөйләшүнең төп берәмлеге – сүз. Сүзне төрле калыпларда күреп, танып, ишетеп, кулланырга өйрәтү кирәк.

Татар теле – аглютинатив, ә рус теле флектив телләр гаиләсенә керүен дә югарырак классларда аңлатам. Моның өчен аларга гади генә мисал бирәм. Балакайларыбызныкы дигән сүзне русчага тәрҗемә итәргә (то, что принадлежит нашим детишкам). Татар һәм рус телләрендәге аффиксларның урнашу тәртибе, аларның уртак һәм аермалы якларын чагыштырып өйрәнү балаларга кызыклы.

9 нчы класс укучылары быел 3 нче ел татар теленнән төп дәүләт имтиханын (ОГЭ) яңа  формада тапшыралар.  Телләрне чагыштырып өйрәнү  монда да безгә ярдәмгә килә. Безнең мәктәптә 9нчы класста татар теле атнага 0,5 сәгать исәбеннән үткәрелә. Бу аз. Имтиханның 1,2 нче өлешләрен уңышлы эшләү өчен теоретик белем кирәк. Укучыларга “Татар теле грамматикасы” рус теле грамматикасы  нигезендә язылган. Без ничә еллар дәвамында ике телне чагыштырып өйрәндек. «Татар теленнән алган белемнәрегез рус телендә, ә рус теленнән алган белемнәрегез татар теленнән имтиханда ярдәм итәрлек булсын!» – дип өйрәтәм. Балалар телне ятлап түгел, ә уйлап-фикерләп, аңлап  өйрәнергә тиеш.

Соңгы елларда укучылар, үзләре кызыксынып, татар һәм рус телләрендә кечкенә тематик сүзлекләр төзиләр. Мәсәлән, «Татар һәм рус телләрендә иң еш кулланылган 200 фигыль», «Кешене бәяләүче сыйфатлар» һ.б. Аларны да дәресләрдә балаларның тел байлыгын үстерү өчен файдаланам.

Минемчә татар һәм рус телләрен чагыштырып укыту ике телне дә үзләштерергә ярдәм итә, баланы уйларга, фикер йөртергә өйрәтә. Ятлап түгел, ә фикер йөртеп алган белем генә ныклы булуын онытмыйк.

© Камалова З.Х., 2024

УДК 811.512.145

**Каримова З.С.,**
*Уфа ш., Россия*

# ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА ТУГАНЛЫК АТАМАЛАРЫНЫҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ҺӘМ СТИЛИСТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация:*** *мәкаләдә татар халык җырларында кулланылган туганлык терминнарының лексик-семантик һәм стилистик үзенчәлекләре карала.*

***Терәк сүзләр:*** *туганлык терминнары, лексик мәгънә, стилистика, музыкаль-поэтик жанр, лексема, строфа, синонимик вариант.*

Татар әдәби телендә туганлык атамаларын белдерүче сүзләр байтак. Алар күбесенчә сөйләм телендә, безнең көндәлек тормышыбызда актив кулланылалар, ләкин шулай үк аларны матур әдәбият әсәрендә, мәкаль-әйтемнәрдә һәм татар халык җырларында да күпләп очратабыз. Кардәшлек терминнары – төгәлрәк әйткәндә, кешеләрне яше, җенесе һәм гаилә-никах мөнәсәбәтләре системасында урыннары буенча классификацияләү төшенчәләре – халыкның гаиләсе тарихы эзләрен бик әйбәт саклыйлар. Туганлыкны белдерүче сүзләр бик борынгыдан килү сәбәпле, алар арасында алынмалар азрак очрый, туганлык мөнәсәбәтен белдерүче сүзләр аша без халкыбызның тормышын, яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен күрәбез.

Бу мәкаләдә без татар халкының тарихи һәм лирик озын җырларында туганлык атамаларының лексик-семантик, стилистик үзенчәлекләрен тикшерәбез.

Татар халкының җыр хәзинәсе үзенә күрә бер тарих ул. Без анда ерак гасырлар тавышын да, бүгенге көннәр аһәңен дә ишетәбез. Татар халык җырлары сәнгатьчә самимилек һәм нечкәлек белән кеше күңеленең иң тирән якларын яктырта [1; 6].

Татар халкының җыр мирасы күп төсле бизәкләрдән тукылган моңлы, шигъри бер дөнья булып күз алдына килә. Җырның хискә, мәгънәгә бай нәфис сүзләре һәм гамьгә, дәрткә бай тылсымлы музыкасы халыкның рухи бөтенлеген һәм тиңдәшсез талант иясе булуын раслый.

Гомүмән, халык җыры – катлаулы, синтетик музыкаль-поэтик жанр дип санала. Тарихи җырлар төркеменә халыкның үткән тарихындагы аерым социаль-тарихи вакыйгаларга, күренекле шәхесләргә һәм билгесез геройларга багышланган әсәрләрне кертәләр.

*Мисалга «Ханәкә-солтан» җырын алыйк. Ханәкә-солтан* – исеменнән һәм җырның эчтәлегеннән күренгәнчә – югары катлау вәкиле. Ул, күрәсең, үз заманындагы феодаль сугышларның берсендә яу кулына төшеп, әсирлектә җәфа чигүче, аерылу хәсрәтеннән ачыргаланучы зат. Кайчандыр иркен, бай тормышта яшәгән назлы кыз михнәтле язмышыннан зарлана, җыр аның сагышлы хатирәсе булып яңгырый:

*Госман бер хафиз кызы идем,*
*Ханәкә-солтан атлы идем,*
*Сахтиян кимәс наз идем,*
*Чабата тапмай барамын.*

Җырның аерым строфаларында Ханәкә-солтан гади авыл кызы итеп сурәтләнә. Бер җирдә ул үз җирләрендә урак урмый китүенә үкенә, икенче җирдә Ханәкә исеме «солтан» титулыннан башка гына телгә алынып, аларның кырга арты белән утырган йортлары турында сүз бара. Ханәкә-солтан турындагы җыр борынгы тарихның бер мизгелен сурәтле итеп күз алдына китерүче әсәр.

Лирик җырлар асылында һәркем күңеленә дә хуш килгән, һәр кешегә дә якын булган эчке кичерешләр, уйланулар, хис-тойгылар ята. Ир-атлар арсында гына яшәүче җырлар да бар, аларда никах туганлыгы атамасы булган «ир» лексемасы еш күзәтелә, еш кына ул ир-егет, ир-ат лексемалары белән кулланыла. Ир, хатын лесемалары никахлашкан, гаилә берлеген төзегән затлар алар. Ир сүзе – бик борынгы сүзләрнең берсе. Ул ностратик чорда ук кулланылган һәм ностратик сүзлектә Нега формасында булган. Ир лексемасының семантик мөмкинлекләре киң: «сугышчы», «гаскәри», «кыю», «тәвәккәл», «гайрәтле» [2; 44].

*Йөгереп лә йөгереп җыяр идем,*
*Юлның буйларында җуым юк;*
*Эзләп тә тапмаган бәхетләрне*
*Сатып ала торган җола юк.*
*Сандугачлар оча тал эзләп,*
*Ир егетләр боега мал эзләп.*

Хатын-кызлар мохитенә генә хас булган туганлык атамаларыннан әнкәй, хатын, кыз, кодача лексемалары еш очрый. Халык җырларында бигрәк тә «әнкәй» лесемасы күп кулланыла. Ул туры линиясе буенча булган кантуганлык атамасы. Тарихи яктан караганда, беренче булып кан туганлыгы атамалары формалаша башлаган, чөнки бу атамалар бер гаилә эчендәге мөнәсәбәтләрне турыдан-туры чагылдыру, конкретлаштыру

өчен кирәк. Татар теленең төрле ареалларында ана сүзенең алгы рәт сузыклары белән формалашкан төрле вариантлары яшәп килә: әни, әнкәй, әннә, инә, инәй, инәкәй һ.б.

*Әнкәемнең аклы күлмәге*
*Чите каюлы, биле сапмалы;*
*Җаным бармады, күңелем тартмады,*
*Үз дигәннәрем мине тапмады.*
*Кызлар бәйлиләр мамык шәл генә,*
*Сабый балага буй кыз җәл генә.*

Яшь хатынны барыннан да бигрәк ире белән мөнәсәбәте газаплый. Элек, әтисе, агасы яисә җизнәсе кызны, малга, акчага, байлыкка кызыгып, бөтенләй яратмаган кешегә көчләп биргәннәр.

Кыз сүзе төп мәгънәсен даими саклый, кыз сүзе катнашлыгында бик күп йола атамаларын белдерүче тәгьбирләр дә бар.

Кантуганлык атамасы булган «ата», «әткәй» лексемасы да җырларда байтак. Ата сүзе дә бик борынгы чорлардан ук билгеле.

*Сары камышлардан баулар үреп,*
*Әтием, кемгә йортлар бурадың?*
*Яшьли сөйгән ярым була торып,*
*Әтием, нигә картка юрадың!*
*Бирмәделәр сөйгән ярыма,*
*Кызыктылар дөнья малына.* (Мәдинә матур)

Шаян җырларда, мәсәлән, матур кызлар сайлап картая башлаган егет хәле сурәтләнә:

*Узып бара машина, дөньяда,*
*Калай япкан башына, вай, дөнья;*
*Матур кызлар сайлый-сайлый, дөньяда,*
*Җиттем утыз яшемә, вай, дөнья.* («Вай, дөнья»)

Шулай ук, халык җырларында никах туганлыгы еш кулланыла: килен, кияү, каенана, кода, кодагый, кодача һ.б.

*Кодачамның шәлләре,*
*Буй-буй төшкән аллары;*
*Шул кодачам миңа булса,*
*Кирәкми дөнья маллары.* («Кодачам»)

Татар халык җырларында туганлык атамалары синонимик вариантта да бирелә. Борынгыдан килгән җырлар булганлыктан, мәсәлән, «әнкәй», «әткәй» атамалары җырның һәр куплетында төрлечә бирелә.

*Сызрань юлларының, ай, өстендә*
*Хәзер тора Шәрук олавы;*
*Җиде чакрымнан ишетелә*
*Әни дә кәбәмнең елавы.*

*Саматта Шәрук мин генә,*
*Кадерлем бит, энкәй, син генә.* (Шәрук беглый)

Татар халык җырларында «абый» төшенчәсен белдергән кантуганлык атамасы булган абзый, ага(й) сүзләре төрле вариантта кулланыла. Мәсәлән, без тикшергән җырларда аның «абзеки» варианты да бар. Биредә «абзый» атамасы татар сөйләшләрендә доминант булып тора, ул төрле фонетик үзгәрешләргә дучар булучан.

*Сафәрләргә чыксам,иияте м бар*
*Шәһре Болгарларны үтәргә;*
*Әллүки, бәллүки,*
*Сезне сагынып йырлыйм, абзеки.*

Без бер мәкалә кысаларында халык җырларында чагылыш тапкан барлык туганлык атамаларын да тикшерә алмыйбыз. Җырларда никах туганлыгы һәм кантуганлык атамалары шактый киң чагылыш таба. Туганлык атамалары – бик борынгы гомумтөрки лексик катламнарның берсе һәм алар ясалыш үзенчәлекләре буенча да төрле. Без тикшергән җырларда кулланылган туганлык атамалары гади яки тамыр икәнлегенә игьтибар иттек. Халык җырларындагы туганлык атамаларын тикшерү безгә тормышыбызда онытыла барган атамаларның үзенчәлекләрен тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

**Әдәбият**


1. Надиров Д.Н. Татар халык җырлары. – Казан: Тат.кит.нәшр.,1965. – 454 б.
2. Рамазанова Д.Б. Атамаларда туганлык һәм гаилә мөнәсәбәтләре. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2014. – 284 б.


© Каримова З.С., 2024

УДК 811.512.145

**Касимова Р.А., Каримова З.С.,**
*Уфа ш., Россия*

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕЛМӘЛӘРНЕ ӨЙРӘТҮЧЕ ЧАРАЛАР

***Аннотация:*** *мәкалә татар теле дәресләрендә фразеологик берәмлекләрне укыту методикасын өйрәнүгә багышланган.*

***Терәк сүзләр:*** *фразеологик берәмлекләр, сөйләм культуралары диалогы, контекст, синоним, антоним, омоним, лексик-семантик күнегүләр, стилистика.*

Фразеологизм – мәгънә үзенең составындагы сүзләр мәгънәсенә туры килми торган тотрыклы тәгъбирләр, сүзтезмәләр, әйтемнәр [2; 627].

Татар теле дәресләрендә лексикология бүлеген өйрәнгәндә фразеологик әйтелмәләргә дә игътибар бирелә. Татар теле дәресләрендә фразеологик әйтелмәләрне өйрәнгәндукучыны җәлеп итәрлек, кызыктырырлык нинди чараларны кулланырга мөмкин соң?

Укучыларның сөйләм культурасын үстерү өчен диалоглар төзү дә бик зур әһәмияткә ия. Телебезнең бай хәзинәсеннән файдаланып, матур итеп, дөрес итеп сөйләшә белү укучының гомумкультура дәрәҗәсен күрсәтә. Шушы максатны күздә тотып, диалог төзү матур нәтиҗәләр бирә:

1. Фразеологик берәмлекләрне диалогларга, укучының бәяләү сүзләре арасына, да кертеп җибәрергә мөмкин. Мәсәлән,

а) *– Син кичәгә киләсеңме?*

*– Киләм, әлбәттә.*

*– Дөресен әйт, бәлки, вакытың юктыр?*

*– Киләм, **таш яуса да (кызыл кар яуса да)** киләм инде.*

ә) *– Кичә апаларда кыстыбый ашадым.*

*– Тәмлеме?*

*– Бигрәк тәмле! **Телеңне йотарсың.***

б) *– Кичә репетициядә озак биедегезме?*

*– Әйе. Аяктан утлар чыкканчы.*

в) *– Очрашуда укучылар күп идеме?*

*– Әйе. Аяк басарлык та урын юк иде.*

2. Фразеологизмнарның мәгънәләрен аңлату төрле юллар белән башкарылырга мөмкин:

1) Туган телгә (рус теленә) тәрҗемә итү, мәгънәне төгәл итеп белдерү чарасын эзләү;

2) Контекст ярдәмендә мәгънәне аңлату (баланы кырык кат киендерергә ярамый, ул тирләп, салкын тидерергә мөмкин);

3) Синонимнар яисә синонимнар рәте *белән (күз ачып йомганчы – тиз-тиз генә, бик тиз; кызыл кар яугач – беркайчанда; коеп куйган – нәкъ үзе, үзенә охшаган , бер кашык су белән йотарлык – чибәр, бик матур һ.б.)*;

4) Тасвирлау юлы белән *(кеше кубызына бию – үз фикерең булмау, кеше әйткәнгә риза булып тору)*;

5) Фразеологик әйтелмәләрнең синонимик вариантларын төзү *(телен йоту- телен тешләү, күкрәгенә өмет җылысы йөгерде – эченә өмет җылысы йөгерде, бәгырьне кимерү – бәгырьне суыру, серен ачмады – серен чишмәде, сүз йөртмәү – гайбәт ташымау, ачу кубу = җене котыру)*;

6) Антоним фразеологик әйтелмәләр төзү: *(ис киту – ис китмәү, күзгә йокы эленде – күздән йокы качты, башы дөрес эшли – башы эшләми, авызын ачты – авызын йомды, эш кайный – кулдан эш төште)*;

7) Омоним фразеологик әйтелмәләр төзү *(кул кую – ризалашу, кул кую – документка имза куючытә какмау – уяулык; керфек тә какмау – йокламау мәгънәсендә)* [1; 204 ].

1. Фразеологизмның эчтәлегенә (мәгънәсенә) аңлатма бирү аеруча истә кала.

Укытучы, фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен укучыларга аңлатыр алдыннан, һәр катлаулы очракта, иң башта ул мәгънәне үзе үзләштерергә тиеш.

Фразеологизмнарны өйрәнгәндә, лексик-семантик күнегүләрдән дә файдаланырга була:

1) Фразеологизмнарның төрле ситуацияләрдә кулланылышын күрсәтеп була;

2) Ирекле һәм фразеологик сүзтезмәләрне аеруны максат итеп куеп була.

Мәсәлән, *идән астында бәрәңге саклыйбыз – идән асты хәрәкәтләре Бераз тынычланды*;

3) Фразеологик берәмлекләрнең лексикасын өстен кую (мәсәлән: *...тибәргә, ...акылга, ...яшен тизлеге, ....телле* һ.б.);

4) Фразеологизмнарның мәгънәсен өстен кую (мәсәлән, якын мәгънәле яки капма-каршы мәгънәләргә пар эзләп табу: *алып бару – алып кайту, бурычка чуму – муеннан бурычка чуму, хан заманында – биш былтыр* һ.б.).

2. Фразеология буенча биремнәрнең икенче төре, аларны балаларның сөйләм телен активлаштыру стимулы буларак файдалануны күз уңында тота. Мәсәлән:

1) Кеше турында: «Ул татар телен су кебек эчә», – дип әйтәләр. Бу очракта төп сыйфат атала;

2) Аерым кешеләр турында болай әйтәләр: «Алар эт белән мәче кебек яшиләр» яисә «Абый эленке-салынкы эшли». Бу кешеләрне характерлауга кирә;

3) «Исе дә китми», «йолдызлары туры килде», сул аягы белән торган», – дип тә кайчак әйтәләр.

5. Биремнәрнең өченче өлеше фразеологизмнарны танып-белү өчен әһәмиятле һәм телне-халыкны өйрәнү белән бәйле. Этимологик белешмә турында укытучы сөйләгәннәрне файдаланырга мөкин. Мәсәлән:

1) Бу фразеологизмнарда «*кара*» сүзе нинди мәгънәләрдә кулланылган: *кара бай, кара болыт кебек, кара гайбәт, кара елан, кара кайгы;*

2) Хайван атамаларын фразеологизмнарда куллану ниниди мәгънәләр хасил итә: *кара песи булу, кара төлке, карт төлке, карчыга булып ташлану, аю урынына умыра, аю аяк.*

6. Тотрыклы сүзтезмәләр мәкальләр, табышмакларда, әдәби әсәрләр һәм кушма сөйләмдә, бигрәк тә олы кешеләрнең сөйләмендә, еш очрый.

Укучыларның сөйләмен шундый сүзтезмәләр белән баету максатында, аларга төрле биремнәр бирергә, һәм үзләренең сөйләмендә аларны урынлы файдалана белү күнекмәләрен булдырырга кирәк. Моның өчен:

1) Укучылар яши торган урындагы тотрыклы сүзтезмәләрне язып алу һәм шуларга аңлатмалар бирү кебек эшләр кушарга;

2) Тотрыклы сүзтезмәләр кергән табышмак һәм мәкальләр җыйдырырга;

3) Тематикасы буенча фразеологик мәкальләр сайлап язарга: *дуслык, хезмәт* һ.б;

4) Өйрәтә торган сүз төркемнәренә караган тотрыклы сүзтезмәләр сайлап язарга: исемнәргә, сыйфатларга яки фигыльләргә караган сүзтезмәләр;

5) Тотрыклы сүзтезмәләр кертеп, билгеле бер тема буенча, хикәя, изложение яки инша яисә аерым җөмләләр генә яздырырга; шулай ук, мәсәлән, иншаның темасы итеп бирәр мәкаль яки тотрыклы сүзтезмә тәкъдим итәргә;

6) Билгеле бер язучының әсәреннән өзекләр биреп, аларда тотрыклы сүзтезмәләрнең куллану дәрәҗәсен билгеләргә (текстларга анализ ясатырга) һ.б.;

7) Аерым язучыларның әсәрләреннән (хикәя яки шигырьдә) тотрыклы сүзтезмәләрнең куллану дәрәҗәсен билгеләргә һәм шул тотрыклы сүзтезмәләрне сайлап яздырырга, аларның мәгьнәләрен тикшерергә.

8) Фразеологияне кулланудагы хаталар. Билгеле ки, һәр телнең фразеологиясе, үз системасы барлыкка килү сәбәпле, аларны чит тел вәкиле тарафыннан куллануда хаталар да булырга мөмкин. Уку-укыту барышында хаталарның сәбәпләрен ачыклау да әһәмиятле:

- Фразеологизмнарның мәгънәсе турында ачык күзаллау барлыкка килми;

- Аның стилистик бизәкләре исәпкә алынмый;

- Фразеологизмнарның констатив билгеләре турында белеп булмый;

- Кулланылыштагы үзданә нормалар бозыла;

- Теге яки бу фразеологизм белдерә торган ситуациянең характеры аңлап җиткерелми;

- Туган тел фразеологиясе тәэсир итә, ә ике телдәге фразеологик берәмлекләр мәгънә ягыннан да, стилистик яктан да тулысынча туры килмәскә мөмкиннәр һ.б.

Фразеогизмнарны үзләштерү – озак процесс. Алар укучының сүз байлыгында әкрен-әкрен генә урын алып килергә тиеш. Сөйләм эшчәнлегенең һәрбер төрендә аларны урынлы рәвештә кулланырга кирәк. Моннан кала, сүз һәм сүзтезмәләр өйрәнүне телне халык тарихы белән бәйләп өйрәнүдән аермаска кирәк, чөнки соңгысы беренчеләрен өйрәнү өчен кирәк. Бу процесс яңа мөмкинчелекләр ача, укучыларның аралашу компетенциясен үстерә.

Тотрыклы сүзтезмәләр белән эшләгәндә, алда күрсәтелгән һәм башка, шуларга охшаган, күнегүләр укучыларның сүз запасын арттырырга һәм баетырга, сөйләм һәм язу телен үстерергә ярдәм итәләр, укучыларда кызыксыну тудыралар.

**Кулланылган әдәбият**

1. Поварисов С.Ш. Тел – күңелнең көзгесе. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1982. – 158 б.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / ред. Гәниев. – Казан: Матбугат йорты нәшр, 2005. – 807б.

© Касимова Р.А., Каримова З.С., 2024

УДК 811.512.145

**Кашаева А.И., Сагидуллина Л.Р.,**
*Уфа ш., Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «ИЛ» КОНЦЕПТЫ

***Аннотация:*** *мәкалә татар телендәге «ил» концептына багышланган. Репрезентатив тел материалын («ил» сүзенең сүзлек мәгънәсе, дериватлар, «ил» компонентлы фразеологизмнар) анализлау аша концепт үзәгенең һәм аның периферияcенең мәгънәсе өлешчә ачыла.*

***Терәк сүзләр:*** *лингвокультурология, дөнья тел картинасы, концепт, татар теле, «ил» компонентлы фразеологизмнар.*

Дөнья күләмендә социомәдәни процессларның үсү-үзгәрүе, мәдәният феномены һәм тел шәхесе кебек проблемаларга игътибарның артуы фәндә тел – мәдәният мөнәсәбәтләрен өйрәнүче махсус тармак һәм мәктәпләр оешуга этәргеч бирде. Сүз *лингвокультурология* турында бара. Кызганычка каршы, соңгы 20-25 елда бу термин күп кулланылса да, бүгенге көндә әле аның теоретик-методологик базасы бары формалашу хәлендә генә; статусы һәм билгеләмәсе буенча шулай ук әлегә галимнәр арасында бердәм фикер юк, тикшерену алымнары һәм терминологиясе буенча да төгәллек сорала.

Лингвокультурология XX гасырның соңгы чирегендә, тел белемендә антропологик парадигма җимеше буларак барлыкка килә. Аның чишмә башында XIX гасырда ук Вильгельм фон Гумбольдт «О различии строения человеческих языков и его влиянии на духовное развитие человеческого рода» дип исемләнгән хезмәтендә, иң беренче булып, тел холкы һәм халык холкының үзара бәйләнеше турындагы нигезләмәсен тәкъдим иткән. Галимнең тел һәм дөньяны аңлау-төшенүгә бәйле рәвештә әйтелгән, «тел – халык рухы чагылышы, ул кешелек яшәеше тарихы һәм халыкның энергиясе белән турыдан-туры бәйле; тел – тәмамланган эш яки әйбер түгел, ул – эшчәнлек; тел – кешенең барлык төр эшчәнлекләре нигезендә ятучы, аны кеше итүче төп көч; телләр – милләтләрнең үзләренә генә хас фикерләү органнары» кебек фикер-гыйбарәләре, шулай ук ул ясаган фәнни ачышлары арасында төрле тел формаларында фикерләү һәм чынбарлыкны кабул итүдәге аермалыкларны ачыклавы һәм, моннан чыгып, телдә мәдәният төрлелеге чагыла дигән нәтиҗә ясавы аннан соң килгән буын галимнәр тарафыннан, шул исәптән, бүгенге көндә дә аеруча зур кызыксыну белән җентекләп өйрәнелә һәм фән дөньясында искиткеч әһәмияткә ия [4].

В.В.Красныхның «Этнопсихолингвистика и лингвокультурология» (2002) хезмәтендә лингвокультурология турыдан-туры милли дөнья картинасы, лингвистик аңны тикшерүне үз эченә алган мәдәниятнең телдә һәм дискурста чагылышын өйрәнүче дисциплина буларак карала [4].

Татар тел белемендә лингвокультурологиягә нигез салучы, аның проблемаларын өйрәнүче, дөньяның тел картинасын өйрәнү белән шөгыльләнүче дип Җамалетдинов Рәдиф Рифкат улын атыйбыз. Шулай ук, аның «Тел һәм мәдәният. Татар лингвокультурологиясе нигезләре» китабын, галимнең фәнни мәктәбе һәм укучыларын атарга мөмкинбез.

Лингвокультурологиянең төп төшенчәләренә «дөнья күренеше», «дөнья тел күренеше», «концепт» керә.

Концептуаль дөнья күренеше дип знаклар системасына салынган дөнья «образын» атыйлар, ә дөнья тел күренеше исә – телдә чагылган

концептуаль дөнья күренеше [3; 23]. Дөнья тел күренеше – халыкның гасырлар буе җыелган тәҗрибәсен тәшкил иткән, телнең номинатив чаралары аша белдерелгән чынбарлыкның бөтен һәм күпкырлы дөнья булып сурәтләнүе.

«Дөнья күренеше» концепциясен антропологиядә Р.Редфильд күтәреп чыга. Аның билгеләмәсе буенча, дөнья күренеше – теге яки бу халыкка хас булган әйләнә-тирә дөнья, җәмгыять әгъзаларының үзләре, үз гамәлләре, дөньяда үз активлары турындагы күзаллаулары ул [7; 5].

Р.Р. Җамалетдинов буенча дөнья тел күренеше төзеленешен, ягъни структурасын тасвирлау ике баскычтан торырга тиеш була: «беренчесе, тел тамгаларының (билгеләренең) гомумкешелек, универсаль эчтәлеген яки инде дөнья тел күренеше компонентлары буларак, концептларны ачыклаудан, ә икенчесе, билгеле бер этномәдәният гомумилегенең дөньяны танып-белү тәҗрибәсен беркетү ысулы буларак, милли тел үзенчәлеген сыйфатлаудан гыйбарәт» [3; 25]. В. фон Гумбольдтның фикере буенча, «дөнья тел күренеше» төшенчәсе фикерләү һәм чынбарлык арасында «арадашчы дөнья» буларак яши.

Концептлар турындагы дискуссия бик күптәннән килә. Шунысы үзенчәлекле: әлеге термин соңгы вакытта тел белеме өлкәсендә генә түгел, әдәбият белеме, логика, фәлсәфә һәм культурологиядә дә бик еш кулланыла.

Тел белеменә килгәндә, бу сүз турында рус һәм татар телләренең аңлатмалы сүзлекләрендә дә, чагыштырмача күптән түгел нәшер ителгән күләмле лингвистик сүзлекләрдә дә мәгълүмат бирелми.

В.З. Демьяноковның хезмәтенең кайбер нәтиҗәләренә тукталуны урынлы булыр дип уйлыйбыз:

1) фәнни латын телендә *conceptus* сүзе «төшенчә» буларак түгел, бары тик «яралган” мәгънәсендә бик сирәк кенә кулланылган. Италья һәм испан телләрендә бик күптәннән *concetto, concepto* сүзләре матур әдәбият әсәрләрендә һәм фразеологизмнарда урын алган. Француз телендә очрамый диярлек;

2) немец телендә *konzept, koncept* рус телендәге «конспект» мәгънәсендә йөртелү белән билгеле. Инглиз телендә *concept* «төшенчә»не аңлатучы философик термин буларак XIX гасырның икенче яртысыннан, рус телендә – бу мәгънәдә 1920-1970 нче елларда кулланыла.

Безнең илдә концепт табигатен иң беренчеләрдән булып анализлау омтылышын С.А.Аскольдовның «Слово и концепт» мәкаләсендә очратабыз. Монда автор «танып-белү характерындагы» һәм «иҗади концептлар»ны аерып куя. Ул концептка түбәндәге билгеләмәне бирә: «*Концепт* – фикер барлыкка китергән төзелмә, ул фикерләү барышында безнең өчен бер үк төрдәге күп санлы предметларны алыштыра» [1; 269].

Автор концептның алыштыру вазифасын ассызыклап күрсәтә. Тикшеренүче өчен концептның когнитив роле мөһим. Таныл-белү концептларын һәм иҗади концептларны аерып, С.А.Аскольдов аларның гомуми характерына, күп санлы предметлардан торуына һәм соңгыларының индивидуальлегенә игътибар итә. Аныңча, иҗади концептларга төшенчәләр, күзаллаулар, сизү-тоюлар, хис-тойгылар, хәтта ихтыяр чагылышлары, шулай ук ассоциатив характер хас. Концептның тышкы сыйфатламасы дип галим аның потенциальлеген атый.

Концепт термины хәзерге лингвистикада урнашса да, бүгенге вакытта бердәм билгеләмәсе юк, һәрбер галим үзенең билгеләмәсен бирә. Мәсәлән, Е.С. Кубрякова буенча, концепт – менталь лексиконның оператив эчтәлекле берәмлеге [4; 45]. Ә А.Вежбицкая: «Концепт ул үзе «Идеаль» дөньядан. Аның үз исеме бар һәм ул кешенең «Чынбарлык» дөньясы турында культура белән бәйле күзаллавын чагылдыра» дигән [4; 56]. Бер генә билгеләмә булмавы концептның катлаулы, күпъяклы структурасы белән аңлатыла. Концепт үз эченә социаль, мәдәни өлешне дә ала. Бу өлеш ассоциация, милли образ һәм шушы культурага, халыкка хас коннотацияне үз эченә кертә.

Татар тел күренешен өйрәнү максатында аны оештыручы, чагылдыручы концептларны барлау, алар белдергән үзәк һәм периферияләге мәгънә һәм мәгънә төсмерләрен ачыклау, алардагы универсаль, милли, шәхси компонентлары билгеләү бүгенге көндә лингвомәдәният фәнененең төп юнәлешләреннән. Татар лингвокультурологиясе бу юнәлештә актив эшли, «сагыш», «моң», «ут», «гомер» кебек бик күп концептлар тикшерелә, лингвомәдәни сүзлекләр, шулай ук тарихи һәм мәдәни мәгълүматлар белән аңлатмалы сүзлекләр төзелә. Мәсәлән, «2006 елда Р.Р. Җамалетдиновның «Тел һәм мәдәният. Татар лингвокультурологиясе» исемле хезмәте дөнья күрде. Бу китапның кушымтасында татар этномәдәният сүзлеге урнашкан, анда 40 концепт анализланган. Сүзлектәге концептлар төрле дәрәҗәгә ияләр, анда макроконцептлар да (*ана, җан, моң* һ.б.), микроконцептлар да (*катык, капка, тәрәзә* һ.б.) бергә урнаштырылган [4, 247 – 348]. Шул ук вакытта бу хезмәт татар дөнья тел күренешенең барлык мөһим концептларын да колачлый, дип әйтеп булмый: *мәхәббәт, милләт, сүз* һ.б. концептлар, мәсәлән, анда юк» [7; 15]. Алар арасында «ил» концепты да бар.

Концептларны тикшерүнең төп этаплары ачыкланган. Без тикшеренү кысаларында түбәндәге этапларны үттек: а) «ил» концептын атаучы лексик берәмлекнең аңлатмалы сүзлектә теркәлгән мәгънәләрен ачыклау; ә) «ил» сүзенең этимологиясен ачыклау; б) дериватларны ачыклау; в) «ил» компонентлы фразеологик берәмлекләрне туплау һәм аларны анализлау.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» ндә *ил* лексемасының ике компонентлы саф лексик омоним булуы теркәлгән. «Ил» концептын омонимның беренче компоненты ачыклый. Әмма омонимның икенче компонентында да (*Ил – умарта кортларының аерым семьясы)* «ил» концептына хас мәгънә тоемлана. Безнең карашка, бу омонимик пара полисемия таркалу һәм алар арасындагы мәгънә бәйләнеше югалуы нигезендә барлыкка килгән булырга мөмкин. Уртак сема – «җыйналу, күп булып бергә оешу» [8; 377].

Татар теленең этимологик сүзлегендә: *ил* этимологиясе түбәндәгечә билгеләнә:

«**Ил** «страна», диал., фольк. «деревня, село» (ЛТ I: 77; ДС III: 59-60) «мир, мирно, дружно» (Тукмашева 1992: 54) «народ, племя» > мар. *эл* < гом.кыпч., гом.төрки *эл*, аз.*әл*, угыз. *ил*, или «ил; халык».

**Ил** сүзе (нәкъ тат.яңгырашта) б.э кадәрге Үзәк Азия һуннары теленнән үк билгеле. Һәм шул чакта ук «төзек дәүләт, тыныч юл» мәгънәсендә булган. Татар сөйләшләрендәге ил «тынчлык, иминлек» мәгънәсендә (дөнья хәлләре турында «*илме – яумы?*» дип сорау һ.б.) Урхун язуларындагы *ил такы (тагы) ил болды* җөмләсендә чагылыш таба. Татар сөйләшләрендәге *ил-көн, ил-күз, ил-су* сүзләре дә борынгы төрки дәүләтләрдән килә. Болардан тыш, татар һәм башкорт телләрендә *илү «волость урта зурлыктагы административ берәмлек», иләү «бәмәга, община»* һәм монгол теленнән кергән *ил-ат (дөресе илят, илат – монг. «илләр») «илдәге барча халык»* һ.б. дәүләтлеккә даир сүзләр бар. *Ил < эл* сүзе белән эвенк. *илэ* «кеше; кунак» сүзе чагыштырыла. *Ил* – борынгы язмаларда *ил, эл* озын сузык белән килә. Бу хәл ошбу сүзнең әүвәле озынрак бер сүздән кыскартып хасил булганлыгына ишарә итә кебек», – дип яза күренекле галим Р.Г.Әхмәтьянов [2; 297]. «Ил» концептын белдерүче сүз тарихына кыскача этимологик күзәтү нәтиҗәләре концепт атамасының бик борынгы характерда булуын, төрки, монгол, фин-угыр телләрендә киң таралганлыгын дәлилли.

Дериватлар – ул ясалма сүзләр. Алар бер тамырлы сүзләр нигезендә формалашалар. Дериватларның күп булуы, «ил» концептын атаучы сүзнең никадәр татар милли дөнья картинасына «тамырланганын», халык тарафыннан үзләштерелгән булуын күрсәтүче бер дәлил. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә түбәндәге дериватлар табылды: *ил-ана, ил-ат, илбасар, илбасарларча, илбасарлык, илбаскын, илбаш, илгизәр, илгизәрлек, илгәзәк, илгәзәклек, илгәзәкләнү, илгәсәк, иилдәтнә, илдәш, ил-йорт, ил-көн, ил-күз, ил күрше, илсатар, илләрара, илсез-йортсыз, ил-су, илсөяр, ил-күләм һ.б.* Димәк, *ил* сүзенең тамырдаш сүзләре күп, һәм алар халыкның актив лексикасын тәшкил итә[8].

Н. Исәнбәт сүзлегендә «ил» компонентлы 40 фразеологик берәмлек таптык [5]. Мәсәлән: *Ил аралау; Ил аягы шил булгач; Ил йомышы; Илне авызына карату; Илнекеннән ике илле артык.* Татарча-русча идиомалар сүзлегендә 33 ФБ теркәлгән: «*үз илең өрлек, кеше иле гүрлек*», «*ялгыз башы адашып үлгәнче, ил белән камалып яшә*», «*илнең төтене дә тәмле*».

Җыйган материалны без «Кеше» суперконцепты эчендә «кеше – җәмгыять» концептосферасы кысаларында тикшердек. Төркемнәргә исемнәр биргәндә, В.В.Макарованың «Эта страна», или концепт «Россия» в современном российском политическом дискурсе» дип аталган эшенә нигезләндек. Бу хезмәттә түбәндәге тематик-семантик төркемнәр күрсәтелгән: *Ил – гаилә (йорт, әни); Илне якларга, сакларга кирәк; Туган як, ил табигате; Халык, җәмгыять буларак ил; Илгә характеристика; Хакимияткә характеристика һ.б.* [6].

Без туплаган ФБны, нигездә, шундый ук төркемнәргә кертеп була. Кешене, халыкны, хакимиятне, күренешне, процессны характерлаучы фразеологизмнар күпчелекне тәшкил итә *(илдә (илдә-көндә) бер; ил бөлдергеч; ил белән; ил очырган умарта төсле; бабайныкы – илнеке; ил күз алды; ил казасы; ил сүзе – Идел дулкыны һ.б.).* ФБдә теркәлгән мәгънәви катламнар, нигездә, кешене иҗтимагый күренеш буларак характерлый, социумга уңай я кире бәя бирә. Димәк, «ил» концептының аңлатмалы, этимологик сүзлекләрдә теркәлгән үзәк мәгънәләргә яңа коннотация өсти.

«Ил» концептының татар милли дөнья күренешендә тоткан урынын тирәнрәк ачыклау максатында киләчәктә татар паремияләренә, синонимнарына, публицистик һәм әдәби текстларга мөрәҗәгать итү сорала.

**Кулланылган әдәбият**


1. Аскольдов С.А. Концепт и слово // Русская словесность: антология. – М., 1997.

2. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А-Л). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 543б.

3. Василова А.Ш. Лингвокультурный концепт «Сагыш» (тоска) в татарской языковой картине мира / А.Ш. Василова / Автореф. дис. … канд.филол.наук. – Казань, 2006.

4. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре / Р.Р. Замалетдинов. – Казан: Мәгариф,2006.

5. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989.

6. Макарова В.В. «Эта страна», или концепт «Россия» в современном российском политическом дискурсе. (file:///C:/Users/1/Downloads/J-M-17%20(2).pdf)
7. Сагидуллина Л.Р. Текст. Язык. Литература. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2023. – 120 с.
8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: II том: Г-Й. – Казан: ТӘhСИ, 2015. – 712б.
© Кашаева А.И., Сагидуллина Л.Р., 2024

УДК 811.512.145

**Мансурова З.Җ.**,
*Бүздәк районы, Башкортстан Республикасы, Россия*

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КЫСАЛАРЫНДА МУЗЕЙ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ РОЛЕ

***Аннотация:*** *мәкаләдә татар әдәбиятыннан музей дәресен мәктәп укучыларын әхлакый-патриотик тәрбияләүнең бер чарасы буларак оештыру карала. Мәкаләдә музей дәресләренең актуальлеге, максаты һәм бурычлары, эшчәнлек юнәлешләре, үзенчәлекләре ачыклана. Башкарылган эшләр нигезендә укучыларга әхлакый-патриотик тәрбия бирү компонентларының формалашу дәрәҗәсе ачыклана.*
***Терәк сүзләр:*** *әхлакый-патриотик тәрбия, музей дәресе, музей педагогикасы, дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлек.*

Бүгенге көн вәзгыятеннән чыгып, илебезнең бөтен мәктәпләрендә дә яшь буынга патриотик тәрбия бирү һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Ул иң элек укучыларда туган илгә һәм туган җиргә карата мәхәббәт тәрбияләүне, ватанпарвәрлекне күз уңында тота. Яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүдә төп рольне укытучы үти. Укытучы – ул буыннарны тоташтыручы, белем биреп кенә калмыйча, укучыларга өлкән буыннарның рухи байлыгын җиткерүче дә, бүгенге белән үткәнне бәйләп торучы да, тарихи шәхесне тәрбияләүче дә. Нинди шартларда яшәсәк тә, патриотик тәрбия милли тәрбия бирү белән тыгыз элемтәдә кала.

Милли тәрбия бирүнең эчтәлеге, нигездә, өч өлештән тора дип әйтергә була. Беренчесе – укучыларга гомумкешелек кыйммәтләренең асылын аңлату, һәм аларның бу кыйммәтләрне тануына ирешү. Икенчесе – укучыларда гомумкешелек сыйфатларын формалаштыру. Өченчесе – балаларның үз милләтләренең төп сыйфатларына ия булуларына ирешү. Шулай итеп, халкыбызның язмышы, киләчәге бүгенге

яшьләребезнең нинди шәхси сыйфатларга ия булуына бәйле [2; 3].

Соңгы елларда илнең күп кенә мәктәпләрендә патриотик тәрбия чарасына әверелгән музей дәресе кебек эш формасы таралды. Ул яшь буынны патриотик тәрбияләүнең оптималь ысулларын һәм юлларын эзләү белән бәйле. Бу очракта мәктәпләрдә музейлар зур роль уйный башлады. Тарих укытучылары гына түгел, татар теле һәм әдәбияты укытучылары да музей педагогикасы технологиясен үзләштерде.

Иҗади эшләүче һәр укытучы, дәресләренең, сыйныфтан тыш чараларының эчтәлеген баету өчен, үз халкының миллилеген саклаган һәрбер нәрсәдән файдаланырга тырыша. Безнеңчә, үз халкыңның үткәнен бүгенгесе белән чагыштырып өйрәнү өчен мәктәп музейларыннан да кулайрак тәрбия урыны юктыр. Чөнки мәктәп музееның бай материалын уку-укыту процессында һәрдаим кулланырга мөмкин. Каядыр барасы һәм чыгымнар турында уйлыйсы юк, дәресләреңә кирәкле әзер материал кул астыңда. Тагын бер мөһим нәрсә бар: берникадәр укучы мәктәп музейлары эшчәнлегенә тартыла. Алар бу өлкәдә танып-белү даирәсен киңәйтә, үзен компетентлы шәхес итеп тәрбияли. Менә шуңа күрә без әдәбият дәресләренең кайберләрен, бигрәк тә Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләрне үткәндә, мәктәп музейларында үткәрүне күпкә уңышлырак та, файдалырак та дип саныйбыз.

«Музей педагогикасы» төшенчәсе безнең илдә 90 нчы елларда кулланыла башлады, ләкин дәресләр үткәрү формаларының берсе буларак, чагыштырмача күптән түгел генә барлыкка килде. Музей дәресе белем бирү, мәдәни агарту һәм тәрбия юнәлешенә ия. Мондый төр дәресләр интеграцияләнгән характерда һәм берничә этапта оештырыла [4; 102].

Татар әдәбияты дәресләрендә төрле чорларны өйрәнгәндә музей-дәресләр бик зур кыйммәткә ия. Музей предметлары – кешеләр тормышы һәм вакыйгалар турында мәгълүмати чыганак булып торалар, эмоциональ йогынты ясарга, үткәннең рухына, иҗатчы дөньясына үтеп керергә мөмкинлек бирәләр. Шулай итеп, бала йөрәгенә күпер салына, дөрес тормыш ориентирлары формалаша, тормышның мәңгелек кыйммәтләренә тартылу барлыкка килә. Музей педагогикасының асылы шунда: реликвияләр, раритетлар саклау урыны булып кала биреп, музей аралашу, әхлакый ориентирлар формалаштыру, югары культуралы кешене тәрбияләү өчен нигезгә әверелә.

Музей дәресләре – ул музейда яки музей күргәзмәсен, интерактив технологияләр кулланып үткәрелгән дәрес. Ул традицион чараларны алып баруның гадәти формасын үзгәртә, туган як тарихын, күренекле якташлар тормышын өйрәнүне кызыклырак һәм эчтәлекле итә [4; 120].

Музей дәресләрендә уен ситуацияләрен булдыру методлары

кулланыла, интерактив диалог, театральләштерү, мөстәкыйль танып белү эшчәнлеге оештырыла. Укытучы дөрес итеп эшчәнлекне оештыра алса, мондый дәресләрдә балаларга күңелсез булалмый: укучылар парта артында утырмыйлар, тарихи экспонатларны өйрәнәләр, бер-берсе белән зирәклек һәм тапкырлык буенча ярышалар (табышмаклар, ребуслар чишәләр), вакыт эчендә сәяхәткә чыгалар, үзләре дә уйлап чыгарылган хикәяләрнең геройлары була алалар.

Музей дәресләре фәнни-эзләнү эшләрен оештыруда да бик зур роль уйный һәм түбәндәге күнекмәләрне булдыруга юнәлдерелгән:

1. тикшеренү эшенең максатларын һәм бурычларын билгеләү;
2. кирәкле материалны мөстәкыйль эзләү һәм аны конспектлаштыру;
3. мәгълүматны анализлау һәм системалаштыру;
4. гипотеза чыгарырга, аның нигезендә материалны классификацияләү белән практик тикшеренү үткәрү;
5. нәтиҗәләр ясарга һәм гомумиләштерергә.

Музей дәресләрендә укучыларга күзәтү мөмкинлеге бирелә, аларда эзлекле рәвештә тикшеренү, анализ, бәяләү, танып белү күнекмәләре формалаша. Укучылар физиклар, географлар, тарихчылар, биологлар күзлегеннән дә карап фикер йөртәләр, чагыштыралар, нәтиҗә ясыйлар. Болардан тыш мәгълүмати чыганаклар аша рухи байлыгыбызны барлыйлар һәм арттыралар. Шуның нәтиҗәсендә туган як тарихына кызыксынуны көчәя, үз халкың белән горурлану хисе тәрбияләнә.

Үз эш тәҗрибәмнән чыгып, тагын шуны әйтеп үтәсем килә: музей дәресләре эш программасына яраклы рәвештә үткәрелә. Ул күбрәк класстан тыш уку дәресләре белән бәйле. Музейда уздырылган дәресләр зур тәрбияви һәм танып-белү үзенчәлегенә ия. Укучылар уздырылган һәрбер чараны йотлыгып тыңлыйлар, ата-бабаларының кулланган әйберләрен үз кулларына алып, тотып карау мөмкинлегенә ирешәләр. Бүгенге тормышны үткән заман белән чагыштырып, тормышның кадерен белергә дә өйрәнәләр. Чыннан да, Г. Ибраһимов билгеләп үткәнчә, «Күп белүгә караганда да, аз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләнгәнен табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр» [1; 92].

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: туган җиребезгә, халкыбызның үткәненә мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләүдә музей дәресләре зур роль уйный, чөнки милли традицияләргә нигезләнгәндә генә мәктәп үзенең тәрбияви һәм белем бирү бурычларын тулысынча үти ала.

**Әдәбият**

1. Ибраһимов Г.Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933) / Томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр М. Х. Хәсәнов, Р. Р. Гайнанов. – Казан: Татар кит. нәшр., 1978. – 291 б.
2. Мөлекова Ф.Р. Музей – тәрбия учагы // Ачык дәрес. – Сентябрь. – 2010.
3. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогика. – Казан: Мәгариф, 2004.
4. Этнопедагогика в современной школе: Пособие для учителя. – Абакан: Хакасское книжное издательство, 2010. – С. 208.

© Мансурова З.Я., 2024

УДК 811.5

**Мөхәммәтшина А.Ф.,**
*Казан ш., Россия*
*Фәнни җитәкче – **Р.С. Нурмөхәммәтова***

# ТӨРКИ ҺӘМ КЫТАЙ РИЗЫК АТАМАЛАРЫНЫҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ТӨРКЕМНӘРЕ

***Аннотация:*** *мәкалә төрки һәм кытай ризык атамаларының лексик-семантик классификациясен барлауга багышлана. Әлеге эш ике тел гаиләсенә кергән халыкларның ашамлык исемнәрендәге уртак сыйфатларны һәм аерымлыкларны ачыклауга, шулай ук бу атамаларның семантик үзенчәлекләрен билгеләүгә юнәлтелә. Тикшерү барышында төрки һәм Кытай мәдәниятләрендә ризыкларны билгеләү өчен кулланыла торган сүзләргә чагыштырма анализ ясала. Этимология һәм атамаларның стилистик кулланылышы мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә. Хезмәт нәтиҗәләре мәдәниятара хезмәттәшлекне һәм лингвистик типологияне алга таба өйрәнү өчен файдалы булырга мөмкин.*

***Терәк сүзләр:*** *милли ризыклар, төрки халыклар аш-суы, кытай ризыклары.*

Матди мәдәниятнең барлык элементлары (тору урыны, кием, ризык, йорт савытлары һ.б.) арасыннан этник үзенчәлекләр нәкъ менә ризыкта ачык күренә. Туклану, мәдәниятнең иң консерватив элементларының берсе буларак, ерак үткәндә барлыкка килгән үзенчәлекләрне бүгенге көнгә кадәр саклый.

Билгеле булганча, борынгы заманнардан ук кеше үзенең яшәү урыннарында булган азык ресурсларын кулланырга мәҗбүр булган. Кеше һәрвакыт үзе даими яшәгән җирдә ашарга һәм чәчү өчен яраклы кыргый бөртекләрнең үсүен һәм кулга ияләштерү өчен кыргый хайваннарның яшәвен теләгән. Кешеләр башта кыргый формада урып, аннары чәчә башлаган беренче бөртекле ашлык Кече Азия, Фәләстин, Иран һәм Көньяк Төркмәнстан тауларында, шулай ук төньяк Африкада үсә торган арпа булган.

Борынгы төркиләрнең туклану системасы Көньяк Кавказның табигый-климат үзенчәлекләре тәэсирендә барлыкка килгән. Антик авторлар хәбәр иткәнчә, борынгы төркиләр бодай, арпа, тары, суган һәм сарымсак үстергәннәр, ә җыелган уңышны ашлык саклау чокырларына салганнар. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, бүгенге көндә дә азәрбайҗаннарда ашлык саклау чокырлары кулланыла. Дагыстанда яшәүче азәрбайҗаннар (терекеменнар) төзегән бу хуҗалык чокырлары турында танылган Россия этнографы С.Ш. Гаджиев «Дагестанские терекеменцы. XIX – начало XX в.» китабында болай дип яза: «Терекеменнарның хуҗалык корылмалары арасында ашлык өчен махсус чокырларны да искә алырга кирәк. Мондый түгәрәк чокырның тирәнлеге 2-2,5 м. Аның стеналарын камыш белән ныгытканнар, ә төбенә калын салам җәйгәннәр. Ашлыкны чокырларга, гадәттә, сукканнан һәм киптергәннән соң салалар. Чокырны имән такталар белән каплыйлар һәм өстен балчык белән сылыйлар» [3; 13].

Этнографлар билгеләп үткәнчә, һәр милли аш-суның үзенчәлеге бар, бу аларны башка халыклар ризыкларыннан аерып тора. Белгечләр фикеренчә, көнкүрештә киң таралган көндәлек продуктлар гына милли булып санала. Борынгы төркиләр өчен мондый милли продуктлар булып сарык ите, бодай, арпа, тары, борыч, суган, сарымсак, йөзем, алма, тәмле һәм хуш исле кыргый яшелчәләр, сөт, эремчек, каймак, катык, кымыз, май саналган. Танылган төрки телләр белгече К.М. Мусаев бу хакта болай билгеләп үтә: «Конкрет телне тикшерүнең иң дөрес ысулы – лексиканы тематик төркемнәр буенча өйрәнү» [6; 12]. Лексиканы һәм аерым лексик-семантик төркемнәрне өйрәнүнең бу универсаль ысулы, аерым алганда, төрки тел белемендә дә киң таралган. Мәсәлән, Б. Огел төрки телләрдә ризык атамаларын *итле, сөтле* һәм *онлы* һ.б. дип бүлә [7; 42]. Азәрбайҗан теленең туклану лексикасын тикшерүче А.Г. Алиев аларны дүрт лексик-семантик төркемгә бүлә: *итле, сөтле, онлы, икмәк атамалары* [1; 28]. Бу эштә беренче тапкыр паремиологик структура, концептларда туклану лексикасы, шулай ук аучылык һәм балык тоту, дини ышанулар һәм тыюлар белән бәйле азык-төлек бирелгән.

Югарыда аталган классификацияләрдә лингвомәдәни (когнитив, этнолингвистик, антропологик), шулай ук туклану лексикасының гендер, символик, концептуаль, социаль, иерархик аспектлары чагылыш тапмаган.

Алда әйтелгәннәр безне дә төрки телләрдә туклану лексикасын өйрәнгәндә тематик принцип анализ кулланырга этәрә. Инде эшләнгән классификацияләрне исәпкә алып һәм анализлана торган материалның конкрет мәгълүматларыннан чыгып, без төрки телләрдә туклану лексикасын тематик төркемчәләргә бүләбез.

Этнографик әдәбиятта Үзәк Азия халыкларына хас булган ике төр туклану системасы билгеле. Беренчесе *ит һәм сөт* продуктлары балансына нигезләнә. Ул кешегә организм өчен кирәкле майлар, углеводлар, аксымнар бирә, алар белән бергә крахмал һәм үсемлек витаминнары кирә. Икенчесе *хайван майлары балансына һәм диңгез продуктларын* куллануга нигезләнгән. Алар аксым, сөт продуктлары белән баетылган. Ике туклану системасы да яшәүгә сәләтле булулары белән аерылып тора һәм организмны кирәкле элементлар белән тәэмин итә [9; 139]. Бу фикерләрне тулысынча төрки телләрнең туклану системасына карата кулланырга мөмкин. Төрки халыкларның туклану системасы нигездә сөт-ит продуктларына нигезләнгән.

Һәрбер җәмгыятьтә туклану системасының әһәмияте һәм мәдәни эчтәлеге тикшерүчеләрнең игътибарыннан читтә калмаган. Бу аңлашыла, чөнки әлеге лексик-семантик төркемнең атамалары, ризык куллану һәм аның белән бәйле йолалар һәм традицияләр, ризыклар әзерләү технологиясе, аларның продуктлар составы, һичшиксез, кызыклы. «Туклану системасы хуҗалыкның өч төре белән тыгыз бәйләнгән: ярым күчмә, күчмә һәм утрак. Һәм бу өч хуҗалык төре төп продуктлар җыелмасын, аларны эшкәртү, ризык әзерләү ысулларын, азык-төлек чикләүләрен һәм өстенлекләрен, кешеләрнең ашаганда үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен билгели» [8; 163].

Галимнәр арасында төрки халыкларның ризык рационында үсемлек продуктларын куллану мәсьәләсе турында бердәм фикер юк. Кайбер галимнәр (мисал өчен, В.А. Левшин) төрки халыкларның туклану системасы *ит һәм сөт ризыклары балансына* нигезләнгән дип саный. Башкалар (әйтик, П.В. Голубовский) күчмә халык борынгыдан ук *бөртекле культуралар* ашаган дип саный. Тикшерүче М.О. Косвен, әлеге ризыкларның кыйммәте турында сөйләгәндә, болай дип яза: «күрәсең, бөртекле ашлыкларны башта кыздырылган килеш ашаганнар һәм соңрак яфракларны онга мана башлаганнар» [5; 92]. Татар халкының туклану системасын өйрәнгән Этнограф А. Вамбери болай билгеләп үтә: «...татарларның ризыгы башлыча иттән тора; әгәр кайбер урыннарда

икмәк бөтенләй билгеле булмаса да, сирәк очрый торган тансык ризыкны тәшкил итә» [2; 37].

Төрки халыклар элек-электән үсемлек продуктларын кулланганнар. Борынгы төрки сүзлекләрдә һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә тары, арпа, бодай, қонақ (кыргый борыч) һ.б. искә алынган булуы моңа дәлил. Этнограф А. Диваев эшендә шулай ук: «...көтүчеләрнең гади ризыгы булып тары, көже (тары яки арпа бөртекләреннән әзерләнгән сөтле сыек эчемлек) санала» дип күрсәтелә [4; 137].

Кытай гастрономия мәдәниятенең бай традицияләре һәм борынгы тарихы бар. Аның концепциясе борынгы кытай фәлсәфәсе белән тыгыз бәйләнгән. Безнең эрага кадәр II меңьеллыкта ук кытай хакиме И Инь «туклануны гармонияләштерү" теориясен булдыра алган. Үз чиратында, Конфуций безнең эрага кадәр VI-V гасырларда кулинар сәнгатьнең нечкәлекләрен өйрәнү белән шөгыльләнгән. Хәзерге вакытта аның күп кенә рецептлары Шаньдун провинциясендә конфуциан аш-суының нигезен тәшкил итә.

Кытайда бик киң таралган мәкаль бар “民以食为天” (Азык – халык күге), ул халык тормышында ризыкның бик мөһим урын алып торуын аңлата [10; 52]. Кытайда төрле тәмдәге ризыклар бар һәм бу Кытайның бай гастрономик культурасын күрсәтә. Һәр Кытай ризыгының үзенчәлекле тәме генә түгел, ә аерым мәгънәле атамасы да бар.

Кытай кухнясының аерым үзенчәлеге – продуктларның (яшелчә, тәмләткечләр) балансланган булуы. Шуңа күрә ризыкларның кабатланмас исе, тәме һәм төсе бар. Яшелчә, тәмләткечләр һәм аларның гармонияле бердәмлеге борынгыдан Кытай ризык әзерләү сәнгатенең нигезе булып саналган.

Традицион ризыкның тәме генә түгел, файдасы һәм хәтта шифалы булуы да бик мөһим. Шуңа күрә Кытай аш-суында тәмләткеч үләннәр киң таралган. Борынгы Кытай аш-суында инь һәм ян төшенчәләренә зур игътибар бирелгән. Барлык ризыклар энергия бирә һәм тынычландыра торганнарга бүленгән. Мәсәлән, ит – чиста ян-продукт; су үзендә инь энергиясен йөртә. Сәламәтлекне һәм озын гомерне саклап калу, инь белән янны гармониядә тоту өчен, үз рационыңны шулай төзергә кирәк дигән ышану яшәп килгән [10; 42].

Кытай табынының бик мөһим элементы – аның тышкы кыяфәте, ризыкларның урнашу тәртибе һәм аларда төсләр комбинациясе. Өстәл сервировкасы гадәттә ак-зәңгәр төсләрдә саклана, ачык төсләр яки контрастлы комбинацияләр кулланылмый. Ашлар хризантема чәчәкләре, бодай башаклары яки сәер хайваннар рәвешенә китерелгән яшелчә, җиләк-җимеш белән бизәлә. Кытай кухнясының күпчелек ризыклары бик күп компонентлы. Һәрбер ризык күп санлы өлешләрдән тора, аларның

һәрберсе аерым әзерләнә, һәм ахырдан гына барысы бергә кушыла. Төрле ризыкларның бик күп, бер-берсенә туры килми кебек тоелган исләре һәм тәмнәре Кытай кухнясында бербөтен булып, органик рәвештә кушыла. Кытайларның аш-су сәнгатенең максаты – кунак ризыкның нинди компонентлардан торганын аңламасын өчен, башлангыч продуктның чын исен яшерү. Әзер ризыкның бизәлеше һәм тышкы кыяфәте шул ук максатка хезмәт итә [10; 59].

Ризык атамалары Кытай мәдәниятенең мөһим өлеше булып тора, анда Кытай халкының зирәклеге чагыла. Аш-су атамалары халыкара коммуникацияләрдә Кытай мәдәниятен таратуда мөһим роль уйный. Һәм алар тел билгеләре генә түгел, ә икътисад, сәясәт һәм җәмгыять үсешен чагылдырган Кытай мәдәниятен ачыклаучы да. Кытай мәдәниятендә ризыкларны ничек әзерләү генә түгел, ә аларны ничек атау да мөһим, чөнки исемнәрдә ризыкларның эчтәлеге дә, аларның мәдәни кыйммәте дә чагыла. Гадәттә Кытай ризыкларының атамалары 2-8 иероглифтан ясала [12; 23], иң кыска ризык исемнәре ике иероглифтан гыйбарәт, мәсәлән, 凉粉, 豆花, 扣肉һ.б. Күпчелек тикшерүчеләр Кытайда ризыклар исемнәре номинациясенең алты төп тибын билгелиләр: 1) төп продукт буенча; 2) әзерләү ысуллары буенча; 3) формасы буенча; 4) тәме буенча; 5) ризыкның кайда барлыкка килүе турында; 6) мәдәни факт, милли бәйрәм, вакыйга, персонаж һ. б. белән бәйле. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, күпчелек ризыкларның номинациясе бер модель буенча гына түгел, ә берничә модель нигезендә ясалган. Мәсәлән, Кытайның билгеле ризыгы **地三鲜** *(пьинин – dìsānxiān)*, аның исеме турыдан-туры «өч җир сафлыгы» дигәнне аңлата. Бу ашамлык төп продукт моделе һәм урын моделе буенча аталган. Бу ризык Кытайның төньяк-көнчыгышыннан килә һәм кыздырылган баклажан, татлы борыч һәм бәрәңге катнашмасыннан тора. Нәкъ менә бу өч яшелчә кыш көне Төньяк Кытайда яшелчә рационының нигезен тәшкил итә, чөнки кыш көне бу төбәктә башка яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр киң таралмаган. Тарихи факторлар моделе буенча гына аталган ризык бар. Мәсәлән, «кырмыскалар агачка менә» дигәнне аңлаткан **蚂蚁上树** *(пьинин – mǎyǐshàngshù)* ризыгы. Бу ризыкның төп продукты – фунчоза һәм дуңгыз ите, ләкин аларны бу ризыкның атамасында күрсәтмәгәннәр, чөнки Кытайда яшәүче һәр кеше ризыкның нәрсәдән торганын аңлый.

Шул ук вакытта**蚂蚁上树** *(пьинин – mǎyǐshàngshù, «кырмыскалар агачка менә»)* исеме бик ярлы гаилә турында риваять белән бәйле. Бу гаилә шулкадәр ярлы булган ки, итне күпләп сатып ала алмаган, бары тик бик кечкенә генә кисәкләп кенә кулланган. Итне гаиләнең барлык әгъзалары ашасын өчен, бүләргә кирәк булган, шулай итеп, вак ит

кисәкләрен камыр ризыклары белән бергә кыздырганнар. Бу ризыктагы токмач – агач белән, ит кырмыскалар белән чагыштырыла, ә күтәрелергә (йөрергә, сөйрәлергә) фигыле пешерелгән фунчозаның ябышучанлыгын чагылдыра [13; 7-8].

Формасын исәпкә алып уйлап чыгарылган ризыклар исемнәре дә бар. Иң таралган ризыклар – **松鼠**鱼*(пьинин – sōng shǔ yú, «тиен сыман балык»)* һәм **孔雀开屏**鸡 *(пьинин – kǒngquè kāipíng, «павлин сыман тавык»)*. Метафораны еш кына ризыкларны атаганда, аларның матурлык дәрәҗәсен арттыру максатыннан кулланалар. Мәсәлән, кайвакыт ризыкның ялтырап торган төрен аңлатканда水 (су) сүзен кулланалар. **蟹黄**水饺 *(пьинин – xièhuángshuǐjiǎo «бәллүр пилмәннәр»)* монда 水 (су) сүзе парда пешерелгәннән соң пилмәннең үтә күренмәле һәм ялтырап торган рәвешен тасвирлый. Баоцы / пилмән – камырдан һәм фарштан әзерләнгән ризык, формасы буенча россиялеләргә таныш мантыйларны хәтерләтә.

Заимствованные слова в русском языке представляют собой значительную часть лексикона и происходят из различных языков. Некоторые из самых распространенных и известных заимствованных слов в русском языке включают:

1. Французские заимствования: ресторан, буфет, депо, костюм, бульвар.

2. Английские заимствования: компьютер, интернет, маркетинг, бизнес, кофе.

3. Немецкие заимствования: барон, картофель, бургомистр, штурмовик, фольклор.

4. Итальянские заимствования: аперитив, операция, концерт, армада, джентльмен.

5. Испанские заимствования: алкоголь, томат, армада, инквизиция, манифест.

Это лишь небольшая часть заимствованных слов в русском языке. Они приносят разнообразие и глубину в лексикон, отражая культурные и исторические связи России с другими странами.

Узбекский язык, подобно многим другим языкам, также содержит заимствованные слова из различных языков. Некоторые из заимствованных слов в узбекском языке включают:

1. Арабские заимствования: китоб (книга), мактаб (школа), дуо (молитва), саҳро (заря), роҳмат (милость).

2. Персидские заимствования: бозор (рынок), китобат (письменность), дастур (правило), шахар (город), дуст (друг).

3. Русские заимствования: автомобил (автомобиль), телефон (телефон), кафе (кафе), университет (университет), футбол (футбол).

4. Турецкие заимствования: кечкин (спасибо), тўп (пуля), кечирмоқ (прощать), тўқуш (борьба), чайхана (чайхана).

Это лишь небольшая часть заимствованных слов в узбекском языке. Они отражают исторические, культурные и языковые контакты Узбекистана с другими народами и странами.

Заимствованные слова в русском и узбекском языках имеют свои сходства и различия. Вот некоторые из них:

**Сходства:**

1. Источники заимствований: Оба языка заимствовали слова из различных языков, таких как арабский, персидский, тюркский, французский и др.

2. Семантические переносы: Некоторые заимствованные слова в обоих языках могут иметь схожие значения или использоваться в схожих контекстах.

**Различия:**

1. Исторические источники: Русский язык заимствовал много слов из европейских языков (французский, немецкий), тогда как узбекский язык имеет большее количество заимствований из арабского и персидского.

2. Фонетические особенности: Заимствованные слова в русском и узбекском языках могут претерпевать различные фонетические изменения в соответствии с фонологическими правилами каждого языка.

3. Грамматические особенности: Заимствованные слова в русском и узбекском языках могут подвергаться различным грамматическим изменениям, так как грамматика и структура обоих языков отличаются.

Это лишь общие сведения о сходствах и различиях между заимствованными словами в русском и узбекском языках. Если у вас есть конкретные слова или примеры, которые вы хотели бы рассмотреть, пожалуйста, уточните, и я могу предоставить более детальную информацию.

Исследование сходств и различий между заимствованными словами в русском и узбекском языках позволяет выявить интересные аспекты взаимодействия языков и культур.

В процессе изучения заимствованных слов в русском и узбекском языках были обнаружены как сходства, так и различия. Оба языка имеют богатое наследие заимствований из различных языков, что свидетельствует о культурном обогащении и исторических связях между этими регионами.

© Нурмухамедова М.У., Камалов Ш.Р., 2024

УДК 891.706:502

**Нурмухамедова М.У., Бахронова Ш.Ж.,**
*г. Самарканд, Узбекистан*

## ПРИНЦИПЫ ИЗУЧЕНИЯ БИОГРАФИИ А.П. ЧЕХОВА В СРЕДНИХ И СТАРШИХ КЛАССАХ

***Аннотация:*** *изучение биографии Антона Павловича Чехова в школе имеет важное значение для формирования у учащихся глубокого*

*понимания его творчества и влияния на русскую литературу. Применение различных методических подходов позволяет сделать процесс обучения более увлекательным и эффективным.*

***Ключевые слова:*** *произведения, рассказ, повесть, пьеса, интегративный подход, социальная и философская проблема, творческий путь.*

Антон Павлович Чехов (1860-1904) – один из самых значительных русских писателей, драматург, прозаик, чье творчество оказало огромное влияние на мировую литературу. Его жизнь и судьба тесно переплетены с его произведениями, отражая эпоху перемен и социальных потрясений конца XIX – начала XX века. Его жизненный и творческий путь является примером самоотверженного служения искусству и стремления к истине.

Чехов родился в Таганроге в семье купца. Детство и юность прошли в атмосфере, отмеченной как бедностью, так и духовной насыщенностью. С ранних лет он проявлял литературные способности, помогая семье финансово, публикуя юмористические рассказы под псевдонимами в различных изданиях. Получив образование в Таганрогской гимназии, он продолжил обучение в Московском университете на медицинском факультете, где получил диплом врача. Медицина оставалась для него важной частью жизни, влияя на его мировоззрение и отражаясь в его произведениях.

Литературная карьера Чехова началась с юмористических рассказов, опубликованных в юмористических журналах. Постепенно его творчество стало более серьезным, обращаясь к глубоким социальным и философским проблемам. Он создал множество рассказов, повестей и пьес, затрагивающих различные аспекты русской жизни: быт мещанства, жизнь интеллигенции, трагедии и радости обычных людей, проблемы медицины и социальной несправедливости.

Среди наиболее известных произведений Чехова:

Рассказы: «Хамелеон», «Тоска», «Палата № 6», «Человек в футляре», «Ионыч», «Крыжовник», «Душечка», «Скучная история».

Повести: «Степь», «Дуэль», «Палата №6», «Остров Сахалин».

Пьесы: «Чайка», «Дядя Ваня», «Три сестры», «Вишневый сад».

Его произведения отличаются тонким психологизмом, мастерским владением языком, глубоким пониманием человеческой природы и острым социальным видением. Чехов мастерски изображал мелочи повседневной жизни, которые при его умелом изложении обретали философское звучание.

Изучение биографии Антона Павловича Чехова в школе – это не просто перечисление дат и фактов из жизни писателя. Это сложная и многогранная задача, требующая грамотного подхода, позволяющего

раскрыть перед учениками образ яркой личности, влияние её жизни на творчество и понимание глубины его произведений. Эффективное изучение биографии Чехова в средних и старших классах основано на нескольких важных принципах [1; 200].

Принцип интегративного подхода к изучению биографии А.П. Чехова подчёркивает неразрывную связь между его жизнью и литературным творчеством. Он отвергает изучение биографии в отрыве от произведений и наоборот, предлагая синергетический подход, где каждое дополняет и обогащает другое.

Произведения как иллюстрация биографических аспектов: Произведения Чехова служат первичным источником для понимания его личности, убеждений и ценностей. Его письма, дневники и рассказы раскрывают его мысли, чувства и наблюдения над окружающим миром. Анализ этих источников позволяет глубже и тоньше понять человека, стоящего за литературой. Например, часто сдержанный юмор в его рассказах отражает его собственную личность, в то время как повторяющиеся темы разочарования и смертности в его поздних произведениях могут отражать его личные переживания болезни и ограниченности человеческого существования.

Взаимное обогащение: Интегративный подход не просто использует биографию для объяснения произведений или наоборот. Скорее, он способствует динамическому взаимодействию между ними. Анализ рассказа может пролить свет на аспекты жизни Чехова, в то время как понимание конкретного периода его жизни может углубить интерпретацию его работы из того времени. Этот циклический процесс приводит к более богатому и всестороннему пониманию как его жизни, так и его художественного мастерства.

Важно представить Чехова не как абстрактную личность, а как реального человека со своими сильными и слабыми сторонами, своими увлечениями и мечтами. Изучение писем, дневников, воспоминаний современников позволяет создать более полный и объёмный образ писателя, раскрыть его характер, ценностные ориентации и отношение к окружающему миру. Это поможет ученикам лучше понять его произведения и почувствовать эмоциональную насыщенность его творчества.

Вот несколько примеров активных методов обучения, которые можно эффективно применять:

Проектная деятельность: Учащиеся могут самостоятельно выбрать тему, связанную с жизнью и творчеством Чехова, и разработать проект. Например:

Создание мультимедийной презентации: Презентация может быть посвящена конкретному периоду жизни Чехова (детство в Таганроге, поездка на Сахалин, отношения с О.Л. Книппер), анализу одного из его произведений или сравнению его творчества с творчеством других писателей.

Разработка интерактивной карты путешествий Чехова: На карте будут отмечены места, где он жил и работал, с привязкой к его произведениям [2; 390].

Создание видеоролика по мотивам рассказа или пьесы: Ученики могут инсценировать отрывок из произведения, добавляя музыку, спецэффекты и др.

Дискуссии и дебаты: Организация дискуссий по проблемным вопросам биографии и творчества Чехова. Например: «Чехов – художник реалист или символист?», «Влияние медицинской практики на творчество Чехова», «Актуальность проблем, поднятых в произведениях Чехова, в современном мире».

Ролевые игры: Учащиеся могут взять на себя роли Чехова, его близких, героев его произведений и разработать диалоги, сюжетные линии, исходя из знания фактов его биографии и сюжетов его произведений.

Презентации: Подготовка и защита учебных презентаций, в которых учащиеся излагают результаты своей исследовательской работы по конкретной теме.

Творческие задания: Написание эссе, стихов, рисунков, музыкальных композиций, вдохновленных жизнью и творчеством Чехова.

Применение активных методов обучения делает процесс изучения биографии А.П. Чехова более увлекательным, способствует глубокому пониманию его личности и творчества, развивает критическое мышление, творческие и коммуникативные навыки учащихся. Главное – предоставить им возможность для самовыражения и активного участия в учебном процессе.

В заключение следует отметить, что успешное изучение биографии А.П. Чехова в школе невозможно без комплексного подхода, сочетающего в себе хронологический анализ с тематическим акцентированием, интеграцию биографических фактов с художественным творчеством писателя, использование разнообразных источников информации и активных методов обучения [3; 165]. Только такой подход позволит не просто перечислить даты и факты, но и раскрыть перед учениками многогранную личность Чехова, показать влияние его жизни на его творчество и, в конечном итоге, способствовать более глубокому

пониманию и осмыслению его произведений. Применение изложенных принципов сделает изучение биографии Чехова увлекательным и познавательным процессом, приближающим школьников к пониманию великого русского писателя и его эпохи.

**Список литературы**


1. Маранцман В.Г., Чирковская Т.В. Проблемное изучение литературного произведения в школе. – М.: Просвещение, 1987. – 200 с.
2. Методика преподавания литературы / под ред.О.Ю. Богданова. – М.: изд. Центр «Академия», 1999. – 390 с.
3. Семанова М. Чехов в школе. – С.-Пб: Педагогические науки, 1994. – 165 с.


© Нурмухамедова М.У., Бахронова Ш.Ж., 2024

УДК 811.512.145

**Рахимова Г.И., Каримова З.С.,**
*Уфа ш., Россия*

# ЛИЛИЯ САГИДУЛЛИНА ИҖАТЫНДА СИНОНИМНАР СТИЛИСТИКАСЫ

***Аннотация:*** *мәкаләдә Л.Сәгыйдуллина шигъриятендә синонимнарның кулланылышы һәм аларның стилистик үзенчәлекләре анализлана.*

***Терәк сүзләр:*** *синонимнар, лексема, стилистика, семантика, идеографик синонимнар, стилистик синонимнар, диалектизмнар, эмоциональ-экспрессив төсмер.*

Татар телендә, бер үк төшенчәне белдереп, мәгънә ягыннан бер-берсенә якын булган, ә семантик-стилистик төсмерләре ягыннан аерылып торган бик күп сүзләр бар. Синоним дип йөртелгән мондый сүзләр, төрле язылышта булсалар да, төп мәгънәләре белән бер-берсенә тәңгәл киләләр. «Синоним яки мәгънәдәш сүз (бор. грек. synonymos – бердәй исемле) – мәгънәләре ягыннан тәңгәл килгән яки якын тора торган сүзләр. Лексик синонимнар бер үк сүз төркеменә карыйлар, бер төшенчәне төрле яклап атыйлар, әмма бер-берсеннән мәгънә төсмерләре яки стилистик бизәкләре белән белән аерылып торалар: искиткеч, шаккаткыч, гаҗәп, хәйран калырлык, таң калмалы, уш китмәле. Синоним сүзләрнең мәгънәләре бер-берсе белән төгәл тәңгәл килми, аларның һәрберсе аерым мәгънә төсмере белдерү өчен хезмәт итәләр: аяусыз, рәхимсез, шәфкатьсез, мәрхәмәтсез,

миһербансыз, кешелексез, кансыз синонимик оясында иң көчле миһербансызлыкны белдерә торган сүз – кансыз» [3; 5].

Фәнни югарылыкта язылган хезмәтләрдән күренгәнчә, синонимия күренешен төрле яклап өйрәнергә мөмкин:

а) мәгънә төсмерләрнең төрле булуы;

б) кулланылыш сферасы;

в) эмоциональ-экспрессив бизәкләре

г) грамматик төзелеше ягыннан (тамыр, ясалма, тезмә) һ.б.

Синонимнар фикерне төгәл, анык, җыйнак итеп формалаштырырга мөмкинлек бирәләр, сөйләмне матур яңгырашлы, аһәңле ясыйлар, күренеш һәм төшенчәләрне, аларның билгеләрен төрле-төрле мәгънә төсмерләре һәм стилистик бизәкләр белән аңлатып, тасвирлап бирергә ярдәм итәләр. [3; 31].

Синонимнарның тууында түбәндәге сәбәпләрне күрсәтергә мөмкин:

1. Предметларның (күренешләрнең) яңа ачылган сыйфатларын тулырак итеп бирергә омтылу.

2. Башка телләрдән сүзләр керү: библиотека – китапханә, семья – гаилә, ящик – тартма, гыйлем – белем һ.б.

3. Диалектизмнарның кулланылуы: җиралма – картуф, авыру – чир, чиләк – бидрә һ.б.

Мәгънә төсмере – сүзнең семантик үзенчәлеге, мәгънәне, төшенчәне барлыкка китерүче билгеләр бердәмлеге ул. Сүзнең мәгънәсендә төп һәм өстәмә билгеләр була. Сүз мәгънәсендәге өстәмә билгеләр – синоним сүзләрне бер-берсеннән аера торган мәгънә төсмерләре алар [3; 11]. Телнең үсеш тенденциясе, беренчедән, конкретлыкка, төшенчәне анык һәм төгәл бирүгә омтылу булса, икенчедән, – кыскалыкка омтылу, кабатлаулардан, артык сүз һәм формалардан котылырга тырышу. Шул нигездә яңа синонимнар барлыкка килә, тел дә байый, камиллеккә, төгәллеккә ирешә [3; 12].

Л. Сәгыйдуллина үзенең шигъриятендә синонимнарны бик киң куллана. Мисалларга игътибар итик:

*Чүп-чарлы һәм кап-кара кар...*
*Бозлавык, тайгак юллар...*
*Үлемечле буран, салкын...*
*Котып төнедәй уйлар...*
**(«Авыру кыш»)** [1; 31].

Шигырьдә кулланылган синонимнар күренешне күпьяклап характерлауга, сурәтне көчәйтә баруга хезмәт итә. Әйтерсең лә, күз алдында кинодагы кебек тере сурәт туа. Һәм укучы һәрбер кимчелекне,

һәрбер нюансны сизеп, тоемлап ала, ә бу исә шигырьнең мәгънәсен, төп идеясен яхшы аңларга ярдәм итә.

Киңәш бирә дуслар, танышлар:
*Тынычлан* син, диләр, *сабырлан*!
*Ябыш* диләр, җиргә! *Тамырлан*!
***(«Өлешем»)*** [1; 15].

Тынычлан һәм сабырлан синонимнары шигырьнең яңгырашын, эмоциональлеген арттыруда зур өлеш кертә. Шулай ук рифмалашкан «тынычлан – сабырлан – тамырлан» сүзләре дә шигырьнең эчтәлегенә катгый төс өсти. Бу билгеләр барысы да шигъри әсәрне экспрессияле, тәэсирле, дулкынландыргыч итәләр.

Түбәндәге мисалда берничә синонимик пар сандык ачу вакытын сурәтләү өчен оста, урынлы бирелгән. Кулланылган синонимнар безне бераз йомшартып, күңелне тынычландырып, уй-хисләргә бирелдереп, булган хәтирәләрне барларга әзерли кебек:

Аяз көндә генә йомшак, талгын җилдә
Бау, коймага элеп, *таза* һәм *пакь* җирдә
Үткән белән киләчәкне тибрәтәләр...
***(«Сандык»)*** [1; 10].

Сыйфатлар, синоним булып кулланганда, предмет һәм күренешләрне тулырак ачарга мөмкинлек бирсәләр, фигыльләр синонимлашып, эш-хәрәкәтне сурәтләүдә поэтик образлылыкка ирешүдә ярдәм итәләр. Фигыль синонимнарны күбрәк лирик шигырьләрдә очратабыз:

Тик тормыштан туймаганмын.
*Моңланганмын.*
*Җырлаганмын.*
Җиһан моңын *тыңлаганмын.*
Гомер чапкан – тоймаганмын.
Вакыт атын кыйнаганмын,
Чабышын да тыймаганмын,
Авызлыклап куймаганмын –
Карышырга кыймаганмын.
Дәрья көткән – тоймаганмын.
***(«Рондо»)*** [1; 15].

Бу өзектәге синонимнар шигырьгә эчке динамика, эмоциональлек өсти. Укучы шушы тезелеп киткән сүзләр аша лирик геройның халәтен, хисләрен, борчуларын яхшы аңлый, бу тойгыларны аның белән бергә кичерә. Өзектәге кыска юллар да шигырь тукымасына нәзәкатьлелек, сөйкемлелек өсти. Шигырьдәге бер мәгънәле сүзләр әсәрнең аңламына тагы да горурлык һәм күтәренке кәеф өсти кебек.

Алдагы өзектә без тагын фигыль синонимнарын очратабыз:

Чалгылар янап чабалар!
Кыралар! – Кыргый үлән.
*Чапсалар* да, *кырсалар* да
Яңарып тора гелән,
Әйтерсең, сихри келәм.
***(«Татарник»)*** [1; 32].

Синоним сайлауның асылы һәр очракта да теге яки бу төшенчә яисә образлы фикер өчен иң нык туры килгән сүзне, «шул сүзнең нәкъ үзен» эзләп табуга кайтып кала. Бу максат, бер үк сүзне кабатлаудан котылу өчен, икенче сүз сайларга кирәк булганда да, читтә калмый. Шунсыз әйбәт стиль юк. [2; 156].

Аермалы билгеләргә карап, тел белемендә синонимнарның түбәндәге төрләрен аералар:

1. Идеографик синонимнар – мәгънә төсмерләре белән аерылып торган синонимнар. Идеографик синонимнар телдә зур күпчелекне тәшкил итәләр. Фикерне төгәл, анык итеп җиткерүдә бу төр синонимнар зур роль уйныйлар:

*Ап-акларга, пакь, сафларга*
Кыен шул яшәүләре.
Чамасыз кизә сынаулар –
Кемдә соң үлчәүләре?
**(«Каеннар»)** [1; 16].

Түгелмичә, яшьнәмичә генә
Хушлашабыз – шулай кирәктер.
*Елмаябыз*, хәтта *көлешәбез* –
Дөнья безне шулай өйрәтте.
***(«Агыйделнең аръягында»).*** [1; 212].

Идеографик типтагы синонимнар берсе урынына икенчесе килә алмый, чөнки мәгънә төсмерләрен аермыйча куллану фикерне төгәл биреп бетермәү генә түгел, бөтенләй башкача аңлауга да юл калдыра.

2. Стилистик синонимнар дип төрле стильләрдә кулланыла торган синонимнарны атыйлар. Мәсәлән:

*Таптый, изә, чүп-чар итә* –
Анын азыгы түгел.
Дуңгыз «сыйлап» гомер үтә...
*Басыл,* моң! Күңел, *сүрел!*
***(«Яз үткәч»)*** [1; 24].

Ә калганнар, баш киткәнче,
Мактанышыйк – мактыйкмы?
*Эчтән генә, мыштым гына*

Сүгеп – күңел ачыйкмы? –
Үзебезне таптыйкмы?
***(«Сайлау»).*** [1; 186].

1. Эмоциональ-экспрессив синонимнар – чынбарлыкка төрле мөнәсәбәт белдерү ягыннан аерылып тора торган синонимнар:

*Туган, кардәш, «өлкән брат» теле...*
Шулай тизләтәбез «соңгы көнне»:
Әверелешләр конвейеры «суга»
*Телсез* генә түгел, *әпә* җанны.
***(«Әверелү»)*** [1; 58].

Иртән – *ялкау*, кичен – *иренчәк,*
Көне үтә терсәген тешләп...
Син дә шундый булсаң иде дим:
Зыян салмас идең «эш» эшләп.
*(***)* [1; 37].

2. Абсолют синоним – бер төшенчә бирү өчен кулланылган, мәгънәләре буенча тулысынча тәңгәл килә торган синонимнар. Мәсәлән:

Без котлы булып туганбыз:
Кот-җан бит иңдерелгән.
*Кот*-бәхет тә, *җан*-орлык күк,
Һәр кешегә бирелгән.
***(«Кот»)*** [1; 122].

Яркәй урамнары – серле дөнья.
Топографы үзем булмагач,
Бу картаны үзем сызмагач,
Шартлы килеш кала билгеләре
Җан өрмәгәч – җансыз өлгеләре.
Ябык тәрәзәле – *йорт-өйләре.*
Кемсә генә – *бәндә, кешеләре...*
***(«Илеш тәэссоратлары»)*** [1; 203].

Синоним сүзләр янәшә тезелеп килеп сүрәт- тасвирның тәэсирлеген көчәйтүче градация дигән стилистик фигура да ясыйлар [2; 162]. Һәр сүз үзеннән алдагысының эчтәлеген, эмоциональ-экспрессивлыгын тирәнәйтү нәтиҗәсендә градация алымы уй-фикерне, тойгы-кичерешләрне үтемлерәк, тулырак, калкурак итеп бирә.

*Таптый, изә, чүп-чар итә –*
Аның азыгы түгел.
Дуңгыз «сыйлап» гомер үтә.
*Басыл,* моң! Күңел, *сүрел!*
***(«Яз үткәч»)*** [1; 39].

«Көзге блюз» дә градация алымнарына күпләп мисаллар китерергә була:

Яшеллеген кырау алгач
*Сүнә, кибә, корыша*
Хәсрәтеннән яшьләр коя,
*Сарыларга сабыша...*
Җан җылысын җуя-җуя,
Сарыларга сабыша...
*–Көрәшергә!*
*–Тешләшергә!*
Этләрдән дә узып *этләшергә!*
Үз-үзеңнән хәтта *читләшергә!*
***(«Полилог»)*** *[*1; 65].

Лилия Сәгыйдуллина, синоним сүзләрне бер-бер артлы тезеп, фикер, хис өермәсен тагып да күпертә, шигырьне тәэсирле итә, шуның белән бу сүзләр бер-берсен тулыландыралар, көчәйтәләр һәм нәтиҗәдә авторның фикерен ассызыклыйлар. Димәк, синонимнар стилистик яктан күз салганда, бик отышлы кулланылганнар.

Шагыйрь иҗат итү барышында синоним, антоним, омоним кулланыйм әле дип уйламый, әлбәттә, ул күңелендәгесен түкми-чәчми ак кәгазьгә төшерә. Лилия Сагыйдуллина да нәкъ шулай эш итә, ләкин аның кайбер шигырьләре гел синонимнардан гына тора дип тә уйлап була, чөнки язучы, бу сурәтләү чараларын кулланып, әйтергә теләгән фикерен укучыга төгәл итеп җиткерә ала.

**Әдәбият**

1. Сәгыйдуллина Л.Р. Күпердә: шигырьләр. – Уфа: Китап, 2018. – 224 б.
2. Сафиуллина Ф.С. Татар шигъриятендә яңа сурәтләр. – Казан // Казан утлары, 2004. – № 3. – С. 155-164.
3. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Татар теленең синонимнар сүзлеге. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. – 263 б.

© Рахимова Г.И., Каримова З.С., 2024

УДК 811.512.145

**Сагидуллина Л.Р.,**
*Уфа ш., Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮДӘ ЛИНГВИСТИК УЕННАР

***Аннотация:*** *мәкаләдә лингвистик уеннар укучыларның иҗади потенциалын үстерү, татар теленә өйрәтү процессында дивергент фикерләү өчен нәтиҗәле дидактик материал буларак карала.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теленә өйрәтү, дидактик материал, дивергент фикерләү, иҗат, лингвистик уеннар.*

Кайсы гына өлкәне алсак та, һәр җирдә теге яки бу мәсьәләне чишүнең креатив юлларын табучы, иҗади фикерләү сәләтенә ия кешеләргә зур ихтыяҗ барлыгы күренә. Бүген заман таләпләренә җавап бирердәй шәхес формалаштыру укыту системасы проблемасы гына түгел, ә илнең, җәмгыятьнең яшәү перспективасын билгеләүче төп критерий буларак кабул ителергә тиеш.

Бүген традицион конвергент фикерләүгә алмашка дивергент фикерләүне үстерү – аерым «хыялый»ларның теләге генә түгел, ә цивилизацион алгарышның котылгысыз таләбе. Дивергент һәм конвергент фикерләү үзенчәлекләрен һәм үсеш факторларын өйрәнү өстендә озак еллар күп чит ил (Дж. Гилфорд, Г. Груббер, Д. Роджерс, К. Тейлор, К.Робинсон һ.б.) һәм Россия (А.М. Матюшкин, С. Татищев, А.Б. Шнейдер, И.В. Блауберг, М.А.Холодная һ.б.) педагоглары һәм психологлары эшләсә дә, аларның идеяләре методик система булып оешкан һәм мәктәп системасына үтеп кергән дип әйтә алмыйбыз. Яңа укыту стандартларының нигезе итеп күп кенә алдынгы педагогик, психологик идеяләр алынса да, әлегә алар арсында дивергентлык идеясе өстенлек итми.

Дивергент фикерләүнең иҗади, коммуникатив, шәхси компетенцияләрне формалаштырудагы ролен ассызыклау кирәк. Балаларның иҗади эшчәнлеге, күзаллавы, сәләте, фикерләве психология, педагогика өлкәсендә Л.С. Выготский, Дж. Родари, В.А. Сухомлинский, Е.П. Ильин һ.б. хезмәтләрендә карала. Бүгенге шартларда иҗади эшләр куллану иң нәтиҗәле юлларның берсе, чөнки иҗади эшләр уку эшчәнлеген камилләштерүдә иң көчле стимул. Иҗади фикерләү балаларны хыялланырга, логик фикер йөртергә, йомгаклар ясарга, дәлилләр китерергә генә өйрәтеп калмый, ә төрле өлкәдә туган мәсьәләләрне чишүче булып үсәргә ярдәм итә, эшчәнлекне мотивлаштыра.

Дивергент фикерләү кешенең шәхес буларак формалашуында да зур роль уйный. Һәм бу фикерләү толерантлык, кызыксынучанлык һәм креативлык кебек сыйфатларны да үстерә. Дивергент фикерләү формалаштыру юнәлешен киң кулланылышка кергән тәнкыйди фикерләү, иҗади эшләр, проектлар методы кебек иске-яңа технологияләр белән бәйләп карау мәктәпнең киләчәге өчен актуаль. Шуны да әйтергә кирәк, тел – дивергент фикерләү үстерү өчен яхшы инструмент була ала, чөнки ул, бер үк , укыту-үсеш-тәрбия максаты да, укыту-үсеш-тәрбия чарасы да.

Бүгенге социолингвистик шартларда балаларның «телле» аралаша белү осталыгы мөһим роль уйный. Ә телгә өйрәтү – фикерләүгә өйрәтү дигән сүз. «Тел, знаклар системасы буларак, кешенең фикерләү процессын формалаштыручы һәм камилләштерүче корал рәвешендә кабул ителә. Знак (билге) бер үк вакытта үзен дә, башка бер күренешне дә атау мөмкинлегенә ия» [1; 23]. Сүз – безгә таныш типик знакларның берсе. Ул, бер яктан, дөньяның бер өлешен атый, икенче яктан, үзе үк шул дөньяның бер өлешен тәшкил итә. Шуңа күрә дә телгә өйрәтү процессын фикерләүнең иҗади алымнары белән бәйләп алып барырга кирәк.

Иҗади фикерләүгә карата тел бер көчәйткеч – катализатор булып тора, дип әйтергә мөмкин. Шулай ук тел дә яңа сыйфатлар өстәп, фикерләүне оештыра. Икенче яктан, күренекле галим Л. Рубинштейнча әйтсәк, үз фикеребезне тел чаралары ярдәмендә тәгъбир иткәндә (формалаштырганда), без аны тудырабыз һәм камилләштерәбез дә. Телдән башка бер генә чара да мондый киң уен мөмкинлекләре бирми. Нәрсә соң ул уен? «Уен – һәрвакытта да мәгънәле практик эшчәнлек моделе; телгә төрле уеннар уйлап чыгару мөмкинлеге салынган» [1; 9]. Бу нәтиҗәгә нинди дә булса уенны күзәте ярдәмендә дә ианнып була: һәрвакыт диярлек уен сөйләм белән үрелеп бара.

Лингвистик уеннарны бик еш кына «тел уены» яки «сүзләр белән уйнау» диеп атыйлар, чөнки сүз – телнең иң мөһим һәм табигый берәмлеге. «Лингвистик уеннар» укучыларда, уенчыларда уенның эчтәлеге турында уйланучы, тел закончалыкларын ачуга сәләтле экспериментчы ролендә чыгыш ясау теләген уята. Укучы лингвистик уенда сүзне тарката, җыя, үзгәрешләр кертә, үзгәрешне күзәтә, нәтиҗәләр ясый ала [2; 176].

Татар телен туган тел һәм чит тел буларак укыту методикасында шулай ук уен методы телгә өйрәтү системасына керә. Бу хактагы фикерләрне Ф.С. Вәлиева, Ф.С. Сафиуллина, Н.В. Максимов һ.б. хезмәтләрендә очратабыз. Ф.Ф. Харисов, мәсәлән, татар телен чит тел буларак өйрәтүдә рольле уеннарның әһәмиятен ассызыклый [3; 158].

Лингвистик уеннар, безнең карашка, дивергент фикерләүне формалаштыру юлында методик релевант метод-алымнар арасында мөһим урынны били, чөнки аларның асылы, нигездә, куелган проблемага күп төрле вариатив чишелешләр тәкъдим итү мөмкинлеге белән характерлана [2; 179].

Сүзгә хас билгеләр арасында иң мөһимнәренә аның формага (авазлар тышчасына), лексик мәгънәгә ия булуы керә. Бу ике сыйфаттан тыш, мөстәкыйль сүз үз вазыйфасын башкара алмый. Шуңа күрә лигвистик уеннарны без ике төркемгә бүлеп тәкъдим итәбез: I – формага

өстенлек бирүче уеннар; II – сүзнең лексик мәгънәсенә нигезләнүче уеннар. Лингвистик уеннарны без Д.В. Любичның «Лингвистик уеннар» [32] китабында тәкъдим ителгән уен үрнәкләре нигезендә, татар теле материалында төзедек. Мәкалә кысаларында формага өстенлек бирүче уеннарны тәкъдим итәбез.

1. «Авазны тот» уены

Укучыларга радио, телевизор, магнитофон һәм башка аудиочаралар я булмаса, укучы // укытучы укуында сүзләр // текст тәкъдим ителә. Алдан ук нинди аваз // авазларны тоту хакында килешелә. Мәсәлән, [ә, ө, ү] авазларын; [ж, һ, ң] авазларын һ.б. Бу авазлар кергән сүзне ишетүче аны беренче булып тотып ала һәм кабатлый икән, аңа очко (балл) бирелә. Беренче булып 5 (10) балл җыючы җиңә. Шундый ук эшне авазлар тезмәсе белән дә тәкъдим итеп була: [й+а, й+ә, й+у, й+ү, й+ы, й+е, й+о, й+ө].

2. Ясалма акцент

Уенда катнашучыларга я әйтелеш нормалары бозылган әзер текст тәкъдим ителә (аудиоматериал), я нинди дә булса орфоэпик кагыйдәне бозып әйтү төркемдә (сыйныфта) килешү буенча башкарыла. Мәсәлән, басым семантик функция башкарган сүзләрнең җөмләдә басымын үзгәртү: Мин я'ңа күлмәк алдым. Яңа' гына яңгыр явып үтте; [k],[ғ]авазлары урынына [к],[г], [a°] урынына[а]әйтү һ.б. Уен табигый диалог, сөйләшү рәвешендә алып барылырга, хаталы әйтелеш сөйләм эчендә яңгырарга һәм тыңлаучылар аны тотып алырга, төзәтергә тиеш. Баллар күбрәк хаталы әйтелешне махсус сөйләмгә кертүчеләргә дә, аларны төзәтүчеләргә дә бирелә ала. Шундый эшне фигыль формалары белән эшләргә мөмкин (үткән, киләчәк, хәзерге заман, 1-2-3 затка куярга һ.б.).

3. Сүзләр җыю

Бер вакыт эчендә (3-10 минут) нинди дә булса бер формаль билге буенча күбрәк сүз җыярга кирәк: а) сүз башындагы 1 (2-3) хәрефтән башланган сүзләр (5-6-7-8 хәрефле дип күрсәтергә мөмкин); ә) 1 яки берничә соңгы хәрефләр; б) рифма; в) беренче һәм соңгы хәрефләр; г) үтәли хәрефләр: а сүзнең беренче, икенче, өченче урынында килә; д) бер тәртиптә бирелгән сүздәге тартык авазлар җыелмасы – «Каркас» уены (йлдз, вл, клмк, дфтр...); е) бер тәртиптә бирелгән сүздәге сузыклар җыелмасы (е-е-е, а-а-а, у-а...).

4. «Сүзлек байлыгыңны тикшер» уены

Түбәндәге аваз тезмәләреннән башланган татар сүзләрен әйтегез // язагыз (вакытны чикләмәскә дә мөмкин): ад... (10), аз... (40), ай... (38), ал... (153), ах... (23), аң...(42) һ.б. Җәя эчендә бу аваздан башланган сүзләрнең «Татар теленең орфографик сүзлеге»ндәге күләмен күрсәтергә

мөмкин. Үз мисалларының санын һәм җәя эчендәге саннарның пропорциясен табып, актив сүзлек коэффицентын табып була.

5. «Җавап бир» уены

Уенда катнашучылар капма-каршы ике рәткә тезелеп баса. Уенны алып баручы (укытучы) туп куллана: сүзнең беренче иҗеген атый да бер укучыга тупны бирә, укучы иҗеккә тагы иҗек (иҗекләр) өстәп, килеп чыккан сүзне туп белән бергә укытучыга бирә. Сүз төзи алмаучы, я озак уйлаучы уеннан чыга, азакка кадәр калучы – җиңә. Уен өчен актив авазларны алырга һәм аларга сузыклар өстәргә кирәк: [к, k, т, б, с, ч] һ.б. Шушы ук уенны сүз белән уйнарга да була: укучы әйтелгән сүзгә рифма атарга тиеш (ул – юл, кала – бала, атлар – картлар, җыен – кыен һ.б.).

6. Анаграммалар төзү

Укучы бер сүз уйлый. Сүздәге хәрефләрне төрле тәртиптә өтерләр аша яза: ч, а, л, а, р, у, м, а; т, ә, п, к, ә, м; ү, л, ш, ә, р, е һ.б. Кем хәрефләрнең дөрес тәртибен таба, шуңа балл. Бу эшне парларда да оештырып була.

7. Метаграммалар төзү

Бу уенның авторы дип Л. Кэролл – «Алиса в стране чудес» әсәренең авторы исәпләнә. Бер үк төрле авазлар // хәрефләр санына ия сүз алына. Һәр адым саен бер хәрефне генә үзгәртеп бер сүздән икенчесенә күчәргә кирәк. Кем тизрәк һәм азрак адымнар санын һәм арадаш сүзләрне таба, шул җиңүче була. Мәсәлән, кыш-тыш-тый-җый-җәй, сыер-куян, сөт-бал, матур-батыр, салам-курай һ.б. Бу уенның варианты да бар: бу очракта һәр адым саен берәр хәреф өстәргә, я алырга мөмкин, ләкин өстәү нигезендә мәгънәле сүз барлыкка килергә тиеш.

8. Чайнворд

Бу очракта да, метаграммадагы кебек, сүзләр тезмәсе төзергә кирәк: беренче сүзнең соңгы ике//бер хәрефе икенче сүзнең беренче ике// бер хәрефе белән туры килергә тиеш: алма-матур-урман-андыз-ызгыш...; нарат-тарак-аклан-анчар-чара...

9. Наборщик

Бу уен «Колбаса», «Навуходоносор» дигән исемнәр белән аталырга мөмкин. Бер сүз алына, шул сүздә очраган хәрефләр белән сүзләр төзү. Мәсәлән, матур: ат, ут, урам, тур, урт, утар һ.б. Алфавиттагы хәрефләрнең барысын да берәр тапкыр гына кулланып сүзләр төзергә мөмкин.

10. Тавтограмма

Татар телендә кайбер авазлар (хәрефләр) куллану ешлыгы ягыннан бик актив. Мәсәлән, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «к» хәрефенә, димәк [к], [k] авазларына башланган сүзләрнең саны – 4894, “т” хәрефенә – 3947, «с» – 1930, «б» – 1876, «п» – 1749, «а» – 1650, «м» – 1630, «ч» – 1483, «и» – 1304 сүз теркәлгән. Бу үзенчәлекне исәпкә алып,

укучыларга бер хәрефтән башланган сүзләрдән текст төзергә тәкъдим ителә (дәрестән тыш вакытта). Җөмләләр төзүдән башларга да мөмкин (дәрестә). Уенны «хикәя-бикәя» дип тә атыйлар; аны шигырь формасында тәкъдим итәргә мөмкин: Көтмәсәк тә, караланып, көз килә. / Көзгедә дә, кайтавазлап, көз көлә. / Киләсе көн кичәгедән көнләшә. / Канатлары каерылмаса көзгәчә, / Кара көздә күңел генә көрәшә. (Л.С.)

Уенның варианты да бар: алфавиттагы һәр авазлы хәрефкә, мөмкин кадәр бер тема кысаларына кертеп, берәр тавтограмма-җөмлә төзергә. Алсу алма алды. Әнисенә әйтте. Бүген бабайларына барачак...

11. Нотарикон

4 – 8 хәрефтән торган сүз атала. 3 минут эчендә мөмкин кадәр күбрәк фразалар уйлап табу. Фразадагы сүзләрнең беренче хәрефләре бирелгән сүз хәрефләреннән башланырга тиеш. Мәсәлән, «урак» сүзе бирелә. Җөмләләр: Урамда Роза апа күренде. Уйларым рәхәтлек алып килде. һ.б. Бер үк сүзне кабатларга ярамый. Кем күбрәк җөмлә төзи, шул җиңә. Башта уенда катнашучының, я билгеле берәр шәхеснең исемен (Тукай, Сәйдәш) алырга мөмкин. «Укытучы» – ул кешелекле, ышанычлы тылсымчы, уйлы, чыдам ымсындыручы. Уенны катлауландыру өчен сүз урынына җөмлә тәкъдим итәргә дә була. Нотариконны мнемотехника алымы буларак файдаланалар. Мәсәлән, төсләр спектрын истә калдыру өчен бирелә торган «Каждый охотник желает знать, где сидит фазан» фразасы таныш. «Бәләкәй Илдарны юрганга төреп чанага утырттылар» – татар телендә килеш исемнәрен һәм тәртибен, «Рамайның авылы» – сонор тартыкларны истә калдыру өчен кулланыла. Кире нотарикон формасында апюнсено – 30 көннән торган ай исемнәренең шифровкасын искә төшерергә мөмкин.

12. Липограмма

Беренче вариантта еш очрый торган бер яки берничә хәреф атала: «ә» («җ», «с» һ.б). Бирелгән вакыт эчендә (3-5 минут) бу хәреф кермәгән сүзләрдән грамматик планда дөрес текст төзергә кирәк. Күләмле һәм хатасыз текст авторы җиңә. Шул ук уенның икенче вариантын телдән эшләп була. Сөйләмдә күпмедер вакыт эчендә нинди дә булса тартык авазны, мәсәлән, [р] авазын кулланмаска килешелә. Бу алым «Әйе», я «юк» димәскә, «ак» – «кара»га тимәскә...» дигән балачак уенын хәтерләтә. Бу очракта «[р] авазына тимәскә», дигән шарт куела. Диалог, сөйләшү оештырыла. Кем авазны әйтә, шул уеннан чыга.

13. Кар йомарламы

Бу уенны парлар белән дә, төркемнәрдә дә үткәреп була. Мәсәлән, беренче уенчы ике хәрефтән торган сүз яза, икенчесе – өч хәрефтән торган, аннан – дүрт хәрефтән... Ул бик яхшы укучы булган. Эш – Аяз өчен мөһим шөгыль булачак. һ.б. Грамматик планда дөрес җөмлә я аның

өлеше барлыкка килергә тиеш. Вакыт – чикләнгән. Кирәкле сүз таба алмаучы җиңелә. Төркемдә эшләгәндә һәр уенчыга бер тема кысаларында һәр сүзе бер хәрефкә арта барган җөмлә төзергә тәкъдим ителә. «Ропалик юл» варианты кулланылырга мөмкин: бу очракта беренче сүз – бер иҗекле, икенче сүз – ике, өченче – өч иҗекле һ.б.

14. Монорим

Әдәби төрләр арасында сүз формасы белән актив эшләүче төр һәм аның жанрлары – поэзия. Монорим – шигырь техникасы (рифмалаштыру) белән бәйле уен. Иҗек калыбы саны (мәсәлән, 8-7) һәм рифмалаштыру мөмкинлеге киң бер сүз бирелә: ат (хат, ят, чат, шат, бат, ...); яфрак (туфрак, пычрак, ерак, дурак...) һ.б. Һәр юл рифмалашырга тиеш, бәйләнешле текст барлыкка килергә // килмәскә мөмкин. Бу алым поэзиядә сирәк булса да кулланыла.

15. Акрошигырь

Бу уен «Нотарикон» ны хәтерләтә. Шигырьнең һәр юлы бер хәрефтән башлана. Акрошигырьне кеше исеме – фамилиясе нигезендә төзү киң таралган. Үрнәк рәвешендә Фәнил Гыйләҗевнең тавтограмма алымын кулланып язган шигырен китерәбез. Чатырларда чиркәү чаңы чыңлый. / Зилзиләсе зыңлый заманның. / Калтыранып каны күперсә дә, / Телен тешләп түзә татарым. / Саллы салларыбыз сибелгәнгә / Күмелдекме комлы күбеккә? / Бүректәге бүре балаларын / Ирек исе икән исертә...

Тагын бер мисал: «Татар, таркал, тар кал!» – тапкырлана тарихта: / Хәтерсезлек, хокуксызлык хөкем итә халыкта, / Караланган кичәгесе киләчәген кыршаулый, / Сатылучы-сатучылар садәлекне сагалый. (Л.С.)

16. «Качкын сүзләр» уены

Текстның я җөмләнең грамматик формасы сүзләр ярдәмендә оеша. Һәр сүзнең фразадагы ролен ачыклау максатында «Сүзләр алу» («Качкын сүзләр») уенын оештырып була. Мәсәлән, уенда катнашучы: Тормышында күпме киртәләрне / Күргән бөек Тукай, күнеккән (С.Хәким) мисалында мөһим сүзләрне, җөмләне саклаучы сүзләрне ачыклап кына калмый, ә текстның мәгънәсен тирәнрәк аңлауга ирешә. Моның өчен ул җөмләдән берәр сүзне алырга һәм фразаның грамматик һәм мәгънәви бөтенлеген күзәтергә тиеш. Шул ук мисал нигезендә «Сүз кушу» алымын да кулланып була: (кайгылы, авыр...) тормышында, (катлаулы, иксез-чиксез...) киртәләрне һ.б.

17. Мариенбад уены

Кәгазьдә, я тактада һәрберсе, шигырь кебек, аерым юлга 4 (берничә) җөмлә языла. Уенчылар, чиратлап, җөмләнең грамматик бөтенлеге сакланырдай итеп, җөмләдәге бер сүзне (сүзтезмәне) сызалар (сөртәләр). Кемнән соң җөмлә бозыла, я калган уенчыларга вариант калмый, шул җиңелә. Мәсәлән: Безнең гомер – су өстендә күбек кенә. /

Дәрья өчен ул бары тик куык кына. / Җилләр аны уйнаталар көлеп кенә... / Ә аннан соң хушлашалар үбеп кенә... / Күбек исә тора һаман туып кына (Л.С.).

18. «Чиксез җөмлә» уены

Уен әйтмә һәм язма формада оештырылырга мөмкин. Беренче уенчы ия+хәбәрдән торган гади җөмлә әйтә. Икенче уенчы җөмләнең грамматик һәм семантик бөтенлеге сакланырдай итеп бер сүз өсти һәм җөмләне кабатлый (телдән булса) я яза, өченче кеше тагы бер сүз өсти һәм уен шулай дәвам итә: Эт өрә – Усал эт өрә – Усал эт ярсып өрә – Күршедә усал эт ярсып өрә... Яңа сүз өстәүче җөмләне тулысынча кабатларга тиеш. Җөмлә ни кадәр озынрак, хатасыз кабатлау шул кадәр авыррак. Уен укучыдан, игътибар да, хәтер дә, лексик байлык та, грамматик законнарны белүне дә, вариатив фикерләү сәләтен дә таләп итә. Бу уенның язма формасында җөмлә структурасының моделен төзергә мөмкин. Татар җөмләсенең моделен, сүзләр бәйләнеше законнарын белгән кешенең җиңүче булу мөмкинлеге зуррак.

Шулай итеп, лингвистик уеннар дивергент фикерләүне формалаштыру юлында методик релевант метод-алымнар рәвешендә, татар телен туган һәм икенче тел буларак өйрәнү – өйрәтү барышында актив, системалы кулланылырга тиеш. Тәкдим ителгән лингвистик уен үрнәкләре куелган проблемага күп төрле вариатив чишелешләр тәкъдим итү мөмкинлеге белән характерлана, ягъни дивергент фикерләүче шәхес формалаштыруга өлеш кертә.

**Кулланылган әдәбият**


1. Любич Д.В. Лингвистические игры. – СПб.: «Издательство Буковского», 1998. – 272 с.

2. Сагидуллина Л.Р. Лингвистик уеннар нигезендә дивергент һәм иҗади фикерләү камилләштерү мөмкинлекләре / Актуальные проблемы современной татарской филологии. Сб. статей VIII Всероссийской научно-практической конференции. – Уфа, РИЦ БашГУ, 2020. – С. 175-179.

3. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 302 б.


© Сагидуллина Л.Р., 2024

УДК 811.512.145

**Сагидуллина Л.Р.,**
*Уфа ш., Россия*

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «ГОМЕР» КОНЦЕПТЫНЫҢ РЕПРЕЗЕНТАЦИЯЛӘНҮЕ

***Аннотация:*** *мәкалә татар телендә «гомер» концептын репрезентацияләүгә багышланган. Тел материалын анализлау аша («гомер» сүзенең сүзлек мәгънәсе, этимологик анализ нәтиҗәләре, синонимнар, «гомер» компоненты белән фразеологизмнар) концепт үзәгенең һәм аның периферијасенең әһәмияте өлешчә ачыла.*

***Терәк сүзләр:*** *лингвокультурология, дөнья тел картинасы, татар теле, «гомер» концепты, «гомер» компонентлы фразеологизмнар һәм паремияләр.*

Кешенең тирә-якны танып белү процессы үзенең материаль һәм рухи дөньясы белән кызыксынудан аерылгысыз. Кеше вербаль аң белән характерлана. Икенче төрле әйткәндә, без киләчәк эш-хәрәкәтләрне тел һәм сөйләм ярдәмендә күз алдына китерәбез, атыйбыз, саклыйбыз, тапшырабыз. Халык яки аерым шәхеснең рухи-мәдәни тормышын сүзләр аша тикшерү белән лингвокультурология фәне шөгыльләнә. Галимнәр лингвокультурологиянең тикшерү предметлары күптөрле, дип билгели. Мәсәлән, В.А. Маслова: 1) эквивалентсыз лексика һәм лакуналар; 2) телдә теркәлгән мифлашкан тел берәмлекләре: архетип һәм мифологемалар, йола һәм ышанулар, гореф-гадәтләр; 3) телнең паремиологик фонды; 4) телнең фразеологик фонды; 5) эталон, стереотип, символлар; 6) телнең метафора һәм образлары; 7) телләрнең стилистик тәртибе; 8) сөйләм тәртибе; 9) сөйләм этикеты өлкәсен атый [4; 30].

Лингвокультурология фәненең төп аңламнары арасында «дөньяның тел картинасы», «концепт» төшенчәләре бар. «Дөнья күренеше» термины XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында физика фәнендә барлыкка килә. Тел гыйлеменә ул Л. Вайсбергер тарафыннан кертелә.

Хәзерге вакытта телче галимнәр «дөнья картинасы» терминын киң кулланалар. Дөнья күренешендә тел һәм фикерләү бәйләнешен галимнәр төрлечә аңлата. Дөнья күренешенә метафора кебек тә карыйлар, термин үзе дөньяда төрле терминнар тудыра, төрле контекстларда кулланыла. Мәсәлән, конкрет милләтнең дөньяны ничек күзаллавын – милли дөнья күренешен, дөньяның поэтик күренешләрен тикшерүгә багышланган хезмәтләр барлыкка килә.

Төрле дөнья күренешләрен өйрәнү универсаль, милли концептларны барлау-тикшерүгә нигезләнә. Концептларны анализлауның төп методы – концептуаль анализ. Ләкин «концептуаль анализ» сүзтезмәсе үзе дә күпмәгънәле: мәсәлән, ул конкрет концептларны өйрәнүне дә, художестволы текстны концептлар ярдәмендә анализлауны да аңлатырга мөмкин.

Концептларны билгеле бер милли дөнья тел күренеше кысаларында тикшерү бу милли тел күренешендә аның тоткан урынын, аңа нинди мәгънәләр салынуын ачыкларга ярдәм итә. Һәр милли дөнья тел картинасында шул халык менталитетына гына хас концептлар бар. Татар дөнья тел картинасының бер өлешен тәшкил итүче мәдәни кыйммәтле, мөһим концептларның берсе – «гомер» концепты, чөнки ул яшәү асылын чагылдыручы концептлардан.

«Кеше» суперконцептының үзәген тәшкил итүче концепт – «гомер»нең татар телендә репрезентацияләнү дәрәҗәсен күзәтү халыкның яшәешкә бәйле фәлсәфи карашлар системасын ачыкларга мөмкинлек бирә.

«Гомер», гарәп теленнән алынган сүз булуга карамастан, татар теле тарафыннан тирән үзләштерелгән. Моңа дәлил рәвешендә сүзнең мәгънәләрен ачыклыйк. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «гомер»нең 5 мәгънәсе теркәлгән: «1) Барлык тереклек иясенең туу моментыннан алып үлгәнгә кадәр булган физиологик хәле, яшәү вакыты; 2) Кешенең гомерендә була торган билгеле бер чор; 3) Вакыт, вакытның бер өлеше; 4) рәв. мәг. күч. юклык формасында фигыль янында: беркайчан да, бервакытта да; 5) рәв. мәгъ. күч. гомергә: мәңге, мәңгегә, гомер буена, бик озак вакытта” [6; 130]. Гомумиләштереп әйткәндә, татар халкында *гомер* – кеше, вакыт, мәңгелек төшенчәләре белән тыгыз бәйле, туганнан алып үлгәнгә кадәрге чор буларак аңлана.

«Гомер» концептын тел берәмлекләре нигезендә билгеләнүен этимологик күзәтүләр белән ныгыту үзен аклый. Р.Ә. Әхмәтьянов *гомер* лексемасының гарәп теленнән «*яшәү, яшәп тору*» мәгънәсе белән алынганлыгын; татар диалектларында, төрки, фин-угыр телләрендә киң кулланылышка ия сүз икәнлеген; иске әдәби телдә *гыймарәт, мигъмар* («төзүче, архитектор») сүзләренең *гомер* белән тамырдашлыгын, Дәрдемәнд иҗатында гомернең «гасыр» мәгънәсендә кулланылуын билгели [1; 233].

Заманча когнитив лингвистика яктылыгында синонимнар дөньяны тел категорияләштерү һәм концептуализацияләүнең иң мөһим чараларының берсе буларак карала. Без «гомер» концептының татар телендә тормышка ашыруның синонимик парадигмасын ачыкладык. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» нигезендә «гомер»не атаучы

синонимик рәт төзелде: *тормыш, яшәеш, яшәү, тереклек, хәят-тормыш, дөнья, язмыш.* Синонимик рәткә кергән лексик берәмлекләр идеографик синонимнар; аларда «гомер» мәгънәсе белән тулы тәңгәллек күзәтелми. Әмма синонимнарны барлау безгә концептны вербальләштерү ысулларының төрлелеген контекстлы-синонимик кыр, контекстуаль синонимнар җыелмасы рәвешендә күзалларга мөмкинлек бирә.

Фразеология үзенең мәгънәсе, төзелеше һәм функциональ үзенчәлекләре ягыннан аерым сүзләрдән һәм гади сүз тезмәләрдән аерылып тора. Фразеологик берәмлекләр, халыкның мәдәни үсешен яктыртып, бер буыннан икенче буынга барлык стереотиплар, эталоннар, архетипларны тапшыралар. «Фразеология тел дөнья күренешенең бер фрагменты. Фразеологик берәмлекләр һәрвакыт субъектка карый. Ачыклап әйткәндә, фразеологик берәмлекләрнең барлыкка килүе дә дөньяны тасвирлау түгел, ә аны интерпретацияләү, билгеләү һәм субъектив мөнәсәбәтләрне белдерүдән барлыкка килә» (4; 82).

«Гомер» концепты күп мәдәниятләр өчен уртак булуына карамастан, һәр мәдәният аңа үз коннотацион төсмерен сала. Шул билгеләрне ачу «культураны тирәнтен өйрәнү» принцибына таяна һәм дөнья тел картинасын өйрәнүдә зур роль уйный. Бүгенге фәндә мәдәни мәгълүмат телнең номинатив берәмлекләрендә мәдәният семалары, аның җирлеге, концепты һәм мәдәни коннотацияләр аша тәкъдим ителә. Фразеологизмнар мәдәни яктан әһәмиятле мәгълүматны туплыйлар, бик күп мәгънәләрне белдерергә ярдәм итәләр, өстәвенә, тел чараларын кимрәк куллану мөмкинлеге дә саклана.

Нәкый Исәнбәтнең «Татар теленең фразеологик сүзлеге» [3] һәм Ф.С. Сафиуллинаның «Татарча-русча фразеологик сүзлеге»ндә «гомер» компонентлы 65 тотрыклы сүзтезмә күрсәтелә: *гомер итү, гомер сөрү, гомер кичерү, гомер өзелү һ.б.* Тупланган материалны 5 семантик төркемгә бүлү мөмкин: 1) Үлем мәгънәсендә: *гомере киселде, гомере төгәнү, гомере өзелү, гомере төкәнү; 2)* Тереклек итү мәгънәсендә: *гомер сөрү, гомер итү, гомер буе, гомер бакый, гомер буена; 3)* Чор мәгънәсендә: *гомернең көзе, гомер таңы, гомер язы; 4)* Файдалы-файдасыз яшәү мәгънәсендә: *гомерен уздырып, чабата туздырып; гомерен черетү; гомер бушка үтү; 5)* Теләк мәгънәсендә: *гомере озын булсын; гомере озын булсын, бала-чагалары мул булсын.*

Мисаллардан күренүенчә, татар теленең фразеологик берәмлекләрендә «гомер» концептының өстәмә коннотацияләр алуы күзәтелә. «Гомер» еш кына «үлем» белән параллель рәвештә бирелә, «гомер» һәм «чор» бәйләнеше дә актив, «гомер» һәм «яшәү» мәгънәсе дә очрый, «гомер»гә «теләк» мәгънәсе дә салынган. «Халык аңламында, гомер – гамьле, мәгънәле, файдалы, озын булырга тиеш. «Гомер»

компонентлы фразеологик берәмлекләр халыкның акыл-хикмәт байлыгын, рухи сафлыгын һәм югары әхлагын гәүдәләндереп, бүгенге көндә дә үзләренең зур идея художество кыйммәтләрен саклап киләләр» [5; 38].

Телнең паремиологик берәмлекләр фонды лингвокультурология һәм концептлар теориясе өчен, һичшиксез, әһәмиятле, чөнки әлеге фонд массакүләм милли акылның аеруча мөһим стереотипларын үзгәртеп торырга мөмкинлек бирә. Паремияләр кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр, социаль-тарихи контекст, көнкүреш, гореф-гадәтләр һәм традицияләр үзенчелекләрен чагылдыралар. Кеше аңының үзенә генә түгел, «үзенеке булган башка нәрсәгә» дә юнәлдерелгән ике яклы сөйләшү табигатен тану, теге яки бу лингвомәдәни бергәлеккә игътибар арту паремияларне телара чагыштыру мөмкинлегенең мөһимлеген актуальләштерә, ул халык мәкальләренең универсаль һәм милли үзенчелекләрен ныграк ачуга булышлык итә.

Паремияләрне өйрәнү, беренчедән, мәдәният белән билгеләнгән телдәге мәгънәләрне ачыкларга, икенчедән, аеруча мөһим мәдәни стереотипларны формалаштыруның когнитив алымнарын карарга мөмкинлек бирә (2; 124).

«Гомер» концептының татар мәкаль-әйтемнәрендә чагылышы милли дөнья картаинасының бер өлешен тәшкил итә. «Татар халык мәкальләре»ндә «гомер» компонентлы 78 берәмлек бирелә [7].

«Гомер» концептының мәкаль-әйтемнәрдәге мәгънә төсмерләре ачыкланды, аларга лексик-семантик классификация үткәрелде. «Гомер» – ул: 1) мәңгелектә вакыт чагылышы (*Гомернең узганы юк, күлмәгенең тузганы юк; Сәгать-сәгать газиз гомер үтеп бара, вакыт үтсә, бу гомергә юктыр чара; Гомер озын да, сәгать кыска.);* 2) Яшәү чорлары: (*Гомер таңнары атып тора; Гомер көзекөннәр коя);* 3) Гомер сыйфатлары: (*Озак гомер итәр өчен акрын гомер итәргә кирәк; Үткән гомер – аккан су, яки искән җил; Үткән гомер – калган салават; Эшсез гомер – утсыз гомер; Эш булсын дигән кеше юк, Гомер үтсен дигән кеше күп.);* 4) Мирас: *(Аталардан мирас – баһасыз гомер, Яндырмыйча агач булмас күмер.);* 5) Кешегә хас сыйфатлар: (*Кеше дөньяда ничаклы гомер итсә дә туймый; Кеше гомере – су өстендәге ак күбек.);* 6) Яшәү мәгънәләре: (*Гомер юлы такыр булмый; Күп уйлаган – гомерен бушка уздырган; Күңеле киңнең гомере рәхәт үтә.).*

Әлеге төркемнәрне аңлатмалы сүзлектә бирелгән мәгънәләр белән чагыштырсак, монда «гомер» концептының мәгънә төсмерләре баерак булуы күренә: мәсәлән, *гомер-мирас, гомер-яшәү, гомер-мәңгелек* кебек аңламнар мәкаль-әйтемнәрдә күзәтелә. Бу факт, беренчедән, «гомер» сүзенең, алынма булуына карамастан, татар халкы тарафыннан семантик

планда күптән һәм тирән үзләштерелгәнлеге хакында сөйли, икенчедән, дөнья тел картинасында татар халкының яшәү фәлсәфәсен чагылдыручы төп берәмлекләрнең берсе буларак кабул ителә. Бу концепт «яшәү мәгънәсе, яшәү сыйфаты, кеше сыйфаты» кебек аңламнарны да үз эченә сыйдырган. Татар мәкаль-әйтемнәрендә гомернең буыннардан тапшырылган мирас булуы, аңа сакчыл караштa яшәү идеясе дә еш чагыла. «Гомер» «үлем» белән параллель рәвештә дә бирелә, «гомер» – «Алла» бәйләнеше дә күзәтелә, «гомер»гә «яктылык» мәгънәсе дә салынган. Димәк, татар телендә «гомер» сүзе өстәмә коннотацияләр белән баетылган, мәкаль-әйтемгә әверелерлек дәрәҗәдә семантик планда халык тарафыннан күптән үзләштерелгән.

Шулай итеп, «гомер» концепты милли концепт критерийләренә җавап бирә. Беренчедән, концептны атаучы *гомер* сүзе югары ешлыкка, күпмәгънәлелеккә ия; актив лексика; актив җитештерүче нигезле сүз (*гомер – гомергә, гомерлек, гомерле һ.б.*). Гомер лексемасының синтагматик бәйләнешләре дә киң: *гомер – үтә, ага, бетә, уйландыра, сүнә...; гомер – бәхетле, бәхетсез, озын, кыска, үкенечле, моңлы, кайгылы...; гомер – халык (гомере), кеше, иҗат, җыр, яшьлек..., гомер – язы, көзе, кышы, таңы, иртәсе, киче.* Фразеологик берәмлекләр, паремияләргә ясалган лексик-семантик, идеографик күзәтүләр дә «гомер» концептының татар дөнья тел күренешендә гаять мөһим урын алып торуын раслый.

**Кулланылган әдәбият**


1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А-Л). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 543б.

2. Җамалтдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.

3. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1989.

4. Маслова В.А. Лингвокультурология. – М.: Издательский центр «Академия», 2001. – 208 с.

5. Сагидуллина Л.Р. Текст. Язык. Литература. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2023. – 120 с.

7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: ТӘһСИ, 2005. – 848 б.

8. Татар халык иҗаты. Мәкаль һәм әйтемнәр. – Казан: Тат. кит. нәшрияты, 1987. – 591 б.


© Сагидуллина Л.Р., 2024

УДК 821.512.145(075.8)

**Самитова С.Г., Хуснетдинов Р.М.,**
*Казан ш., Россия*

# УРТА ДИНИ УКУ ЙОРТЛАРЫ ӨЧЕН ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ДӘРЕСЛЕК-ХРЕСТОМАТИЯ ТӨЗҮ ТӘҖРИБӘСЕ

***Аннотация:*** *мәкаләдә хәзерге әдәби белем бирүнең төп максатлары һәм бурычлары формалаштырыла, белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы таләпләре исәпкә алына, авторлар укучыларны татар матур әдәбиятының югары ноктaлары белән таныштыра. Дәреслек-хрестоматия укучыны әсәрләрнең сәнгати кыйммәтен аңларга, тарихи-әдәби процесста аларның урынын билгеләргә сәләтле белемле һәм фикерле укучы итеп тәрбияләүгә юнәлдерелгән. Әдәби мирасны шәкертләрнең дини мәгърифәте күзлегеннән өйрәнергә омтылышлар ясала.*

***Терәк сүзләр:*** *татар әдәбияты тарихы, мәдәният, таләп, халык авыз иҗаты, кыйммәт, милли традиция.*

Татарстан Республикасында татар һәм рус телләренең тигез хокукка ия булуы, белем һәм тәрбия бирү системасында – гомуми, һөнәри, югары белем бирү баскычларында – ике телне дә укыту мөмкинлеген тудыра. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә шәкертләрнең әдәплелек хисен үстерү, татар мәдәнияте һәм әдәбиятының байлыгын аңлау, шулай ук катарсис хисе тудыру – барысы да яшь буынның рухи һәм эстетик үсешенә зур өлеш кертә. Татар әсәрләрен өйрәнү, аларның матрицасын тою, шәкертләрне үз милләтенең мәдәни мирасын хөрмәт итәргә һәм аңларга өйрәтү өчен мөһим. Бу процесс, үз чиратында, татар теленең һәм мәдәниятенең киләчәген саклап калу өчен дә әһәмиятле.

Гыйлем һәм тәрбия бирү системасындагы үзгәрешләрнең актуальлеге һәм XX гасырның соңгы чирегендә дөнья күргән дәреслеклекләрнең заманча укыту стандартларына җавап бирмәве – татар әдәбиятын укыту өчен яңа уку әсбапларына мохтаҗлыкка дәлил булып тора һәм актуаль материаллар булдыруны таләп итә.

ТӘҺСИ һәм КФУ галимнәре тарафыннан гомуми белем бирү учреждениеләре өчен программа һәм дәреслекләрнең чыга торуы белем бирүнең сыйфатын арттыру өчен мөһим адым. Ләкин татар әдәбиятын профильле булмаган һөнәри урта белем бирү уку йортларында укыту өчен яраклаштырылган уку-укыту әсбапларының җитмәве билгеле. Әлеге мәсьәлә бу өлкәдә чишеләсе проблемаларның берсе булып кала, мондый

әсбапларга ихтыяҗны тагын да арттыра. Шуңа күрә, татар әдәбиятын укыту өчен яңа әсбаплар булдыру, шәкертләрнең әдәби белемнәрен һәм фәнни яссылыкта аңлауларын үстерү өчен бик мөһим. Бу, үз чиратында, татар теле, мәдәниятенең киләчәген саклап калу һәм үстерү өчен кирәкле шартлар тудыра.

Бүгенге көнгәчә бу төр уку йортларында әдәбият дәресләре югары сыйныф укучылары өчен махсус бастырылган «Әдәби уку» һәм «Татар әдәбияты» мәктәп дәреслекләре нигезендә алып барылды. Аларның күбесе татар әдәбиятын укытуда яңа методикалар һәм ресурслар булдыруның әһәмиятен күрсәтә. Р.М. Хөснетдинов һәм С.Г. Сәмитова тарафыннан әзерләнгән «Туган як (татар) әдәбияты» дәреслек-хрестоманиясе профильле булмаган вузларда әдәбият фәнен укыту өчен актуаль һәм кирәкле ресурс булып тора. Бу дәреслек, татар әдәбиятының асылын һәм үзенчәлекләрен аңларга теләүче шәкертләргә ярдәмлек булачак. Төрки телләр гаиләсенә керүче төрекмән, казах һәм үзбәк студентлары, дини юнәлештә гыйлем алучы мөселман шәкертләре өчен татар әдәбиятының байлыгын һәм матурлыгын өйрәнү мөмкинлеге тудыру, чын мәгънәсендә, мәдәни, әдәби алмашу һәм аңлашу өчен мөһим адым.

Дәреслекнең максаты – гыйлем алучылар тарафыннан татар халык авыз иҗатын һәм әдәби әсәрләрен өйрәнү, шулай ук уку процессында коммуникатив компетенцияләр формалаштыру һәм үстерү. Бу, гыйлем алучыларның әдәби белемнәрен арттыру гына түгел, ә алар тарафыннан укылган әсәрләрнең эчке композициясен киңәйтү өчен әһәмиятле. Мондый юнәлештәге хезмәтләр, татар әдәбиятын һәм мәдәниятен популярлаштыруда, шулай ук яшь буынның рухи, әхлакый һәм эстетик үсешендә зур роль уйный.

Гомумән, әдәбият гыйлеменә битараф булмаган һәрбер кеше, әдәби әсәрләрне укып, укыган материалга индивидуаль яки күмәк анализ ясап, үз-үзенә сораулар биреп һәм шуларга җавап эзләп, шигъри ядкәрләрне күңеленә салып, үзенең рухи байлыгын үстерергә сәләтле. Ышанабыз: хезмәттә яктыртылган барлык материалны калеб аша үткәргән һәр шәхеснең коммуникатив компетенциясе һәм рух байлыгы берничә баскычка югарыга күтәреләчәк.

Татар әдәбияты кысаларында шәкертләрнең билгеле бер чорга, авторларга һәм әсәрләргә карата аңлы рәвештә белем алуын тәэмин итү мөһим. Гыйлем һәм тәрбия алучыларның әсәрләрне хатасыз укый белүе, укыган материалны аңлау күнекмәләрен формалаштыру процессы әдәби белемнәрен һәм фикерләү сәләтләрен үстерү өчен кирәк. Әлеге юнәлештәге әсбапларны өйрәнү дәверендә, әдәбият дәресе буенча белем

алучыда татарча аралашу, фикерләү, диалог төзү, сорауларга дөрес җавап бирү кебек күнекмәләр үстерлә.

Нәтиҗәдә, татар әдәбияты фәне аудиториянең шәхси һәм һөнәри үсешен, шулай ук татар мәдәниятенә мөнәсәбәтен билгели.

Дәреслек 36 дәрескә исәпләнгән. Шул структураны күз алдында тотып, шартлы рәвештә дәресләр ике блокка бүленеп эшләнелде. Әсбапның беренче бүлеге хаклы рәвештә әдәбиятыбызның чишмә башы булган халык авыз иҗатын, татар халык ашларын һәм татар әдәбиятының чорларга бүленешен, икенче бүлек исә, конкрет авторларның тормыш юлын, иҗатын яктыртуга багышланган темаларны үз эченә ала.

Фольклорга багышланган бүлектә традицион әсәрләргә тәфсилле анализ ясала. Аларның төрләре, жанрлары ачыклана һәм халык арасында киң таралган җәүһәрләрдән үрнәкләр китерелә. Хезмәттә халык авыз иҗаты әсәрләрен куллану, татар халык ашларының һәм халкыбызның күркәм гадәтләреннән саналган кунакчыллыгына басым ясау – барысы да телгә, әдәбиятка, гомумән, татар милләтенә карата кызыксыну уяту, дөрес аралашырга өйрәнү, укырга, язарга һәм үз фикерләрен туплап әйтә белүгә ярдәм булып тора [1, 47].

Икенче блокка караган барлык дәресләрнең структурасы уртак. Алар түбәндәгечә:

- автор иҗат иткән чор хакында, шул дәвер әдәбияты белән бәйле кызыклы мәгълүмат (чорларны яктырткан аерым дәрестә кулланылышта булмаган өстәмә материал);
- автор турында кыскача белешмә;
- әсәрләрнең тулы варианты яки фрагменты;
- бирелгән әсәрләрнең тема, идея, конфликт үсешенә бәйле сораулар;
- татарча-русча сүзлекчә.

Хезмәткә һәр дәрестән соң татарча-русча сүзлекчә кертүне мөһим дип саныйбыз, чөнки шәкертләрнең татарча белүе төрле дәрәҗәдә булу сәбәпле, дәрес дәвамында кулланылган авыр сүзләрнең мәгънәләренә аңлатма бирү – әсбапның дәрәҗәсен күтәрә һәм белем алучыларда кызыксыну уята.

Һәр дәресне теманың атамасы, куелган максатлар, мөһим сүзләр һәм сүзтезмәләрдән башлау, шулай ук уңышлы алым. Чорга яки язучының тәрҗемәи хәле һәм иҗатына караган кызыклы мәгълүматларга урын бирү – дәреслекнең кызыксыну кыйммәтен күтәрә. Мәсәлән, Болгар дәүләтенең барлыкка килүе, бу чорның иҗтимагый-сәяси тормышы һәм беренче татар язма үрнәген биргән Кол Галинең тормыш юлы һәм

«Кыйссаи Йосыф» әсәренә багышланган темага түбәндәге кызыклы мәгълүматлар китерелә.

1. Бөек Болгар дәүләте – Азов буендагы төрки телле кабиләләрнең зур һәм көчле берлеге.

2. Дәүләт VII гасырның беренче яртысында барлыкка килә, Донның түбәнге агымын һәм Таман ярымутравы территорияләрен биләп тора. Аның башкаласы – Фанагория шәһәре (Тамандагы элекке антик шәһәр). Икенче зур шәһәр – Таматарха, соңыннан ул Тмутаракан исеме белән таныла.

3. Болгарларны беренче булып кабиләләр берлегенә оештырган кеше – нәселе белән Атилла ыруыннан килүче Органа санала.

4. Болгар дәүләте күп еллар хәзәр каганаты һәм Киев русе белән низагта торган.

5. Болгар иленең рәсми рәвештә ислам динен кабул итүе зур бер тарихи баскыч була.

6. Татарстан Республикасында Идел буе Болгары дәүләтенең Ислам динен кабул итүе көне 922 нче елның 21 нче мае дип исәпләнә. 2022 нче елның 21 нче маенда Болгар дәүләтенең (безнең әби-бабайларыбызның) ислам динен кабул итүенә 1100 ел булды.

7. Болгар дәүләтенә ислам динен Сусан ар-Раси җитәкчелегендә Аббасид хәлифәте илчелеге алып килә. Гарәп сәяхәтчесе, язучы, әлеге илчелекнең сәркәтибе Әхмәд ибн Фадлан язмаларыннан илчелекнең Болгар дәүләтенә сәяхәте, ислам динен кабул итү фактлары билгеле.

8. Бу дәүләт «Бөек» дип аталса да, берничә дистә ел гына яшәгән һәм Кубрат хан үлгәч таркалган.

9. Бары тик, берничә талпыныштан соң гына, 1236 нчы елда Монгол кабиләсенең Субәдәй җитәкчелегендәге хәрби командасы Болгар дәүләтен тар-мар итә һәм ул Алтын Урда (Улус Джучи) дәүләте составына кертелә. Шунысын да искәртеп үтик: Алтын Урда дәүләтенең беренче башкаласы Болгар шәһәре була.

10. Болгар чоры әдәбияты бары тик Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы белән генә билгеле дияргә була [4; 55–56].

Югарыда атап үтелгән мәгълүматлар барысы да гыйлем алучыларның игътибарын җәлеп итүгә һәм бу чорны күзаллау максатына да хезмәт итә.

Дәреслектә бирелгән сорау һәм биремнәр өйрәнелгән материалны үзләштерү дәрәҗәсен тикшерергә мөмкинлек бирә, шәкертләргә татарча үз фикерен ялгышмый җиткерә белергә, төрле ситуациядә югалып калмаска өйрәтә.

Шулай ук, дәрес барышында шәкертләр тарафыннан хикәягә план төзелә, шуңа нигезләнеп, әсәрнең идеясе ачыла, кайбер материаллар яттан

сөйләнелә, рольләргә бүлеп укыла h.б. Вакытка уку мәктәп чорында актив кулланылса да, кайбер темаларда шушы алымны куллану, шәкертләрнең фикерләвен, иҗади сәләтен арттыру максатыннан кирәк дип табылды.

Хезмәттә XIX йөз ахыры, XX гасыр башында иҗат иткән кайбер автор әсәрләренең иске татар телендә язылган вариантларыннан өзекләр хәзерге әдәби телгә тәрҗемә итү өчен тәкъдим ителә. Шәкертләр тарафыннан бу төр биремнәрне башкару гарәп һәм фарсы теленнән алган белемнәрне дә камилләштерә, ныгыта.

Язылганнарга нәтиҗә итеп шуны билгелик:

- дини уку йортлары өчен татар әдәбиятыннан мондый форматтагы дәреслекләр булмавы – хезмәтнең вакытлы һәм урынлы булуын ассызыклый;

- дәреслек, халык иҗаты һәм әдәбиятының ун гасырлык тарихын үз эченә алып, халык фикеренең үсешен чагылдыра;

- хезмәттәге материаллар шәкертләрнең милли үзаңын үстерә һәм горурлык хисләре уята.

**Әдәбият**


1. Әхмәтҗанов Ю.Ә. Чәй ашлары: татар халык ашлары / Ю.Ә. Әхмәтҗанов. – Казан : Раннур, 2010. – 47 б.

2. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: теория. Тарих / Д.Ф. Загидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2004. – 148 б.

3. Закирова И.Г. Болгар чоры халык иҗаты / И.Г. Закирова; Татарстан Республикасы фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. – Казан: Фикер, 2003 (ООО Печ. двор). – Б. 42–43.

4. Самитова С.Г., Хуснетдинов Р.М., Әдәбият: уку-укыту әсбабы / РИЦ «Школа». 2023, 404 с.

5. Татар әдәбияты тарихы сигез томда [Текст] = История татарской литературы в восьми томах / Татарстан Республикасы фәннәр акад., Г.Ибраһимов исем. Тел әдәбият һәм сәнгать институты; [төз. Р.Ф. Рахмани]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014–2021.


© Самитова С.Г., Хуснетдинов Р.М., 2024

УДК 811.512.145

**Сафина Э.Х., Сагидуллина Л.Р.,**
*Уфа ш., Россия*

# ТАТАР СӨЙЛӘМЕНДӘ СҮЗ БАСЫМЫ ХАТАЛАРЫ ҺӘМ ҖИТЕШСЕЗЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация:*** *мәкаләдә просодиянең басым кебек компонентларына бәйле хаталар һәм җитешсезлекләр барлыкка килүгә китерә торган кагыйдәләрдән кайбер искәрмәләр анализланды.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, просодия, сүз басымы, пауза, сүз басымындагы хаталар.*

Бүгенге көндә әдәби тел нормалары сөйләм теле һәм чит телләр басымын тоя. Соңгы вакытта телдә һәм сөйләмдәге тискәре үзгәрешләрнең тел киләчәгенә куркыныч янарлык дәрәҗәдә артуы күзәтелә. Татар теле аянчлы үзгәрешләр кичергән чорда сөйләм оештыру, аның әдәби норма таләпләренә яраштлы яңгыравына ирешү проблемасы аеруча актуальләшә. Бу яссылыкта просодия, аның компонентларын өйрәнү җитди тикшеренүләргә этәргеч бирә. Сөйләм просодиясенең компонентларын белү, аларны дөрес һәм урынлы куллану коммуникациянең нәтиҗәлелеген арттыра. Просодиядә басым һәм интонация мөһим роль уйный.

Татар телендә сүз басымы функциясе (сүзне оештыру һәм сүзнең мәгнәсен аеру функциясе) бик катлаулы түгел, дип танылса да, сөйләм барышында тел вәкилләре, аеруча татар телен икенче тел буларак өйрәнүчеләр төрле кыенлыкларга очрый [1; 77-78]. Сүз басымының соңгы иҗеккә төшүе абсолют характерда түгеллеге, басымны беренче, уртадагы иҗеккә кую очракларының шактый күләмле булуы әйтмә сөйләм тудыручылар, сөйләмгә өйрәтүчеләр игътибарыннан читтә кала килә.

Интонация кешенең уй-фикерләрен, омтылышларын, эчке халәтен ачык чагылдыра. Сөйләүченең тавышыннан, сөйләм тизлегеннән, интонацион бизәкләрдән сөйләүченең темпераменты, холык-фигылен дә белергә мөмкин [1; 18].

Кешенең тавышы бик күп сәбәпләр аркасында үзгәрә. Сөйләм просодиясенең компонентларын белү, аларны дөрес һәм урынлы куллану коммуникациянең нәтиҗәлелеген арттыра. Сөйләмнең интонацион планда дөрес төзелүе кешенең гомуми культурасын күрсәтүче билге дә. Сәнгатьле укырга әзерләнү өчен дә интонация күренешен һәр яктан, тирәнтен өйрәнү сорала. Укучыларның сәнгатьле уку һәм сөйләм

культурасы – функциональ грамоталылык дәрәҗәсен күрсәтүче төп критерийләрнең берсе, дип исәпләнә. [2]

Интонация – сөйләмнең ритмик-мелодик компонентларын атап китик:

*көй* (төп тон хәрәкәте) – җөмләдә тавыш күтәрүне яисә киметүне гамәлгә ашыручы интонациянең төп компоненты (сорау яки хикәяләү тәкъдиме); аны синтагма һәм ритмик төркемнәргә бүлгәләп, фразаны оештыра.

*сөйләм ритмы* – әдәби текстның эстетик оешмасы нигезенә хезмәт итүче басымлы һәм басымсыз, озын һәм кыска иҗекләрне даими кабатлау

*сөйләм темпы* (аның элементларын – авазларны, иҗекләрне, сүзләрне әйтү тизлеге) – сөйләм узу тизлеге һәм яңгырауның вакыт эчендә озынлыгы: әйтелеш ахырына сөйләм темпы акрыная, ул мәгълүмат әһәмиятенә караганда тизрәк әйтелә.

*интенсивлык* – әйтелгәннәрне әйтү дәрәҗәсе, көче яки йомшаклыгы

*тембр* – сөйләмнең аваз төсе, ул аның эмоциональ-экспрессив төсмерләрен бирә.

*пауза* – сөйләм агымын өзә торган вакыт яңгырашын туктату [4].

*басым* – сөйләмдәге бер элементның (иҗек, сүз, сүзләр тезмәсе) башкаларыннан аерылып торуы. Шуна бәйле рәвештә, сүз басымы (иҗек басымы), логик басым, синтагма басым дигән төшенчәләр барлыкка килгән. Басым – сүзнең төп фонетик билгесе һәм «*җаны ул*» [3; 209].

Татар сөйдәмендә басымга бәйле хаталар еш күзәтелә.

Без беләбез, сүзләрдә дөрес басым ясау, җөмләләрне дөрес төзү, шулай ук сүзләрне дөрес куллану һәм әйтү – кешенең мәдәният дәрәҗәсен, аның телне белүен күрсәтә. Тагы да мөстәкыйл сүэ төркемнәрендә кайбер хата тудыручы очракларны күрсәтик.

Билгеле булуынча, татар телендә сүз *басымы,* гадәттә, соңгы иҗеккә төшә: *китап (китАп), кеше (кешЕ*). Яңа кушымчалар өстәлгәндә, басым соңгы иҗеккә күчә: *китаплАр, кешелӘр.* Бу – универсаль кагыйдә. Әмма нәкъ бу кагыйдәгә буйсынмаган очраклар басымга бәйле сөйләм хаталарына алып килә дә инде.

Сүз басымы куюның кыен очраклары төрле сүз төркемнәрендә төрле сәбәпләр белән аңлатыла. Барлык сүз төркемнәре өчен уртак сәбәпләрнең кайберләре: төп телдәге басымны саклаган алынма сүзләр (*симфо΄ния, вакци΄на*), парлы сүзләр (*и΄р-ат, арлы΄-бирле*), кушма сүзләр (*кү΄пиҗекле, ише΄калды),* төрле кушымчаларның басым алмаулары (*бара'сыңмы, эшлә'миләр)* һәм басымны үткәрмәүләре (*ба'рмыйлар),* сүз басымы белән тойгылы басым мөнәсәбәте аркасында вариатив басымнар барлыкка килүе, төп һәм өстәмә басымнар алу очраклары һ.б.

Исем, сыйфат, сан сүз төркемнәрендә сүзне оештыручы иҗек басымы азаккы иҗеккә төшә. Ләкин бу сүз төркемнәрендә дә кайбер үзенчәлекләр бар. 1) Мәсәлән, исемдә яки сыйфатта 1 һәм 2 затка караган хәбәрлек кушымчасы басымны кабул итми, басым хәбәрлек кушымчасы алдындагы иҗеккә төшә: *укытучы'мын, укытучы'сың, мату'рсың, эшчә'нсез* һ. б. 2) Сыйфатта артыклык дәрәҗәсен белдерүче көчәйткеч кисәкчәләр ялганганда, басым беренче иҗеккә төшә: *я'мь-яшел, ка'п-кара* һ. б. Бу очракта еш кына (кисәкчә бер иҗекле булганда) беренче иҗек басым белән әйтелеп, сыйфат шул басым астында кисәкчәгә кушылып әйтелә. 3) Рус теле аша кереп, әдәби сөйләмнән таралган алынма исемнәр басымны рус телендәгечә кабул итәләр. 4) Саннар басымны азаккы иҗеккә кабул итәләр. «*Йөз*» һәм «*мең*» саннары үзләрен ачыклап килгән саннарга кушылып әйтеләләр һәм энклитика күренешенә дучар булалар.

Алмашлык сүз төркеменең басым кабул итү күренеше катлаулы. 1) Зат, тартым, кайтым алмашлыклары басымны азаккы иҗеккә алалар: *мине'м, синнә'н, аларда'; аларныкында'; үзе'м, үзе'ң, үзебе'з.* Үз функциясен һәм урынын үзгәрткән бер иҗекле зат алмашлыгы басымны кабул итми, алдагы сүзгә кушылып әйтелә. Хәзерге татар әдәби телендә дә «ул» алмашлыгы хәбәрлек кушымчасы функциясендә файдаланыла ала. Бу очракта ул хәбәр булып килгән сүзнең артында тора һәм, аерым басым алмыйча, шул сүзгә кушылып әйтелә. 2) Сорау, билгеләү, юклык алмашлыклары басымны беренче иҗеккә кабул итәләр: *ке'мгә? ке'мнәр? ке'мнәргә? нә'рсәсеннән? ни'чек? һә'ммә, бө'тен, бе'рничек, бе'ркая.* 3) Күрсәтү алмашлыкларының кайберләре басымны – беренче иҗеккә, икенчеләре азаккы ижеккә кабул итәләр*: теге', тегендә'; ә'нә, ме'нә* һ. б. -*лай* кушымчасы катнашкан күрсәтү алмашлыклары басымны – азаккы иҗеккә (*бола'й, ала'й, шула'й, тегелә'й*), *-дый (>-дай)* кушымчасы катнашканнары басымны шушы кушымча алдындагы иҗеккә кабул итәләр (*а'ндый, мо'ндый, шу'ндый*). 4) Билгесезлек алмашлыкларының -*дыр* кушымчасы ялганып ясалганнары басымны – беренче ижеккә *(ке'мдер).*

Рәвеш сүз төркемендә кайбер сүз ясагыч кушымчалар (*-дай/-дәй,* -*тай/-тәй,* -*ча/-чә*) басым алмыйлар. Басымны ике төрле кабул итү очраклары да күзәтелә: *ка'рдай, я'шьләй* һәм *карда'й, яшьлә'й.* Сүзне оештыручы иҗек басымын кабул итмәсә дә, микъдари озын тойгылы иҗек басымын рәвештә -*ча/-чә* кушымчасы да кабул итә. «*Үз*»*,* «*һич*»*,* «*һәр*» алмашлыклары белән башланган кушма рәвешләр еш кына басымны беренче иҗеккә алалар: *ү'зара, һи'чкайда.*

Фигыль күрсәткечләре сүзне оештыручы иҗек басымын кабул итү урыны ягыннан бер төрле генә түгел: хикәя фигыльнең уңай төрдәге синтетик заманнары сүзне оештыручы иҗек басымын заман күрсәткеченә

кабул итәләр (*бара'быз, килде'гез*). Үткән заман һәм киләчәк заман хикәя фигыльләр 3-зат күплек санда сүзне оештыручы иҗек басымын зат-сан кушымчасына алалар (*укыдыла'р, өйрәнгәннә'р*). Хәзерге заман хикәя фигыль 3-зат күплек санда да басымны заман кушымчасына кабул итә (*бара'лар, укы'йлар*). II зат боерык фигыльләрдә басым беренче иҗектә була: *э'шлә, у'тырыгыз*. Фигыльдә I – II зат-сан кушымчалары басымны алмый: *язга'нсың, киле'рмен.* Хәл фигыльнең өченче төре сүзне оештыручы иҗек басымын шушы хәл фигыль күрсәткече *(-ганчы)* алдындагы иҗеккә кабул итә (*кайгы'рганчы*). Киләчәк заман хикәя фигыльнең ике төрендә дә басым заман кушымчасына төшә: *сөйлә'рмен, сөйлә'рсең.* Фигыльдә юклык кушымчасы үзенә басым алмый һәм үзеннән үткәрми: *барга´нсың – ба´рмагансың, килде´ – ки´лмәде.* Фигыльгә сорау кисәкчәсе (*-мы/-ме*) өстәлсә, басым кисәкчә алдындагы туктап кала: *килә'ме, укыды'ңмы.*

Сүзләрне иҗекләргә бүлеп, без сөйләм вакытында паузалар да куябыз. Сүзләрдәге сузык авазларны әйткән вакытта тын бүленеп чыга. Шул вакытта иҗек барлыкка килә. Иҗекләр арасында кечкенә тынышлар (паузалар) ясала. Сөйләгәндә яки тыңлаганда, без ул кечкенә тынышларга игътибар итмибез, әмма стилистик максатларда – аерым сүзләр белдергән мәгънәләргә тыңлаучының игътибарын аеруча җәлеп итәр өчен, иҗек араларындагы шул кечкенә тынышларны беркадәр зурайтырга була [1; 26].

Дөрес пауза кую белән – сез тыңлаучыларыгызның игътибарын аеруча мөһим мизгелләргә җәлеп итү, яки аларга әйтелгәннәрне уйларга вакыт бирү өчен куллана аласыз. Моннан тыш, сезнең сүзегезгә ышандырырлык бирә ала, чөнки тыңлаучылар үз сүзләрегезне җентекләп уйлап сөйләгәнегезне сизәчәкләр.

**Кулланылган әдәбият**

1. Абдуллина Р.С. Риторика һәм интонация. Монография. – Яр Чаллы, 1999 – 400б.

2. Иванова-Лукьянова Г.Н. Культура устной речи: интонация, паузирование, логическое ударение, темп, ритм: Учеб. Пособие. – 2-е изд., – М.: Флинта, Наука, 2000. – 200 с.

3. Сафиуллина Ф.С. Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен д-лексик. Тулыл. 2нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 407 б.

4. https://studfile.net/preview/1843180/page:14/

© Сафина Э.Х., Сагидуллина Л.Р., 2024

УДК 811.512.141

**Сахаутдинова Л.Р., Султанбаева Х.В.,**
*г. Уфа, Россия*

# КОНЦЕПТ «ДОБРО И ЗЛО» («ИЗГЕЛЕК ҺӘМ ЯУЫЗЛЫҠ») В КОГНИТИВНОЙ ЛИНГВИСТИКЕ

***Аннотация:*** *статья посвящена концепту «добро и зло». В когнитивной лингвистике концепт «добро и зло» рассматривается как противоположность, то есть два противоположных полюса, которые определяют наше восприятие и оценку событий и действий.*

***Ключевые слова:*** *когнитивная лингвистика, концепт «добро и зло», семантика, ассоциация.*

Концепт «Добро и зло» («Яҡшылыҡ һәм яманлыҡ») в когнитивной лингвистике представляет собой сложный многогранный механизм, который не только отражает моральные оценки, но и формирует мировосприятие индивида. Эти концепты не статичны; они эволюционируют вместе с культурой, языком и историческим контекстом.

В языке добро зачастую ассоциируется с позитивными эмоциями, такими как радость, любовь и справедливость, в то время как зло проявляется через негативные аспекты: ненависть, страдания и несправедливость. Эти ассоциации становятся основой для создания образов и метафор, которые помогают людям осмысливать свои внутренние конфликты и социальные явления.

К примеру, в поэзии Марины Цветаевой часто встречается антитеза философско-поэтического типа: «добро» – «зло», «действие» – «рефлексия», «красота» – «уродство», «вера» – «рассудок», «дух (душа)» – «тело», «юность» – «старость», «мгновение» – «вечность»:

«–Добро любила ль, всем сердцем страстно?
Зло – возмущало ль тебя оно?.
– «О Боже правый, со всем согласна!
Я так устала. Мне всё равно!» [4]

Как видим, автор проявляет любовь к образам, ненависть, разное эмоциональное состояние.

Также следует учитыватт, что  концепты добра и зла становятся не просто абстрактными идеями, а реальными инструментами, формирующими социальное взаимодействие и личностное развитие.

К примеру, центральное место в произведениях Рината Камала занимают размышления героев о духовно-нравственных проблемах, о

счастье и несчастье, милосердии и жестокости, о ценности человека и равнодушии к его судьбе, верности и предательстве, долге и ответственности, добре и зле. Сила жизнерадостности, жизнелюбия, мужественной борьбы с несправедливостью, стремления к духовной свободе героев, с которыми писатель солидарен, сопереживает за них и видит в них себя самого, поразительна» [5]. К примеру, в романах «Оҙонтал», «Сабыр йән», «Ағай-энеләр», «Вариҫ», «Талаҡ», «Һөйкөмлө һөйәк», «Мәғҙән магазины» герои – представители не одного поколения, а разных поколений. Через эти семьи, родные, всегда стремящиеся к правде и справедливости, через этих смелых, прямолинейных и в то же время жизнерадостных, обреченных на печальные судьбы людей мы видим судьбу всей страны, проблемы общества и времени. Так, в романе Оҙонтал» основной конфликт происходит между двумя семьями. Вот уже несколько поколений: первые возвышаются над богатствами, должностями, престолами, вторые – борются за установление справедливости в стране [1].

Согласно когнитивной лингвистике, концепт «Добро и зло» («Яҡшылыҡ һәм яманлыҡ») является частью нашего когнитивного аппарата, то есть системы знаний и представлений, которые мы используем для восприятия и понимания мира. Он включает в себя не только понятия «добро» и «зло», но и связанные с ними значения, ассоциации, эмоции и сценарии [3].

В стихотворении Ларисы Абдуллиной «Ҡомартҡы» концепт «добро» («яҡшылыҡ») описывает положительные качества и действия человека. Это концепт, который присутствует во многих культурах и религиях, и имеет различные трактовки и интерпретации. Однако, в целом, добро можно определить как состояние души, которое проявляется в добрых поступках, желании помогать другим и стремлении к благополучию окружающих.

*Дәүерҙәрҙе дәүерҙәргә бәйләп,*
*Пәйғәмбәрҙең һаҡлап ҡеүәтен,*
*Яҡшылыҡ булһын атығыҙ тип,*
*Кеше булһын затығыҙ тип,*
*Боронғонан килә был әйтеү![2]*

Итак, одной из основных проблем этого направления являются вопросы смысла жизни, добра и зла. Действительность быстро меняется, поэтому писатели стремятся отразить новые реалии современности, исследуют человека и общество, их взаимоотношения. Авторы пытаются осмыслить сложные перипетии современности с помощью традиционных и нетрадиционных средств и методов. Взаимодействие различных и

стилевых начал в реалистических произведениях выражается не только в содержании, но и в изменении приемов поэтики.

Таким образом, в когнитивной лингвистике концепт «добро и зло» рассматривается как противоположность, то есть два противоположных полюса, которые определяют наше восприятие и оценку событий и действий. Добро обычно ассоциируется с позитивными качествами, такими как моральность, справедливость, доброта, а зло – с отрицательными, например, жестокость, эгоизм, несправедливость.

**Список литературы**

1. Камал Ринат Оҙонтал: Романдар. – Өфө: Китап, 2004. – 518 бит.

2. Килмөхәмәтов Т. А. Әҙәбиәттең сағыу биҙәктәре. Ижади портреттар. – Өфө: Китап, 2005. – 188 бит.

3. Лотря Л.В. Концептуальная оппозиция «добро – зло» в этноязыковой картине мира: дис... канд. филол. наук. – Чебоксары, 2004. – 237 с.

4. Цветаева М.И. Полное собрание стихотворений // Электронное издание http://library.lgaki.info:404/2017/Цветаева%20М_Стихотворения.pdf.

© Сахаутдинова Л.Р., Султанбаева Х.В., 2024

УДК 811.512.145

**Субаева З.Р., Каримова З.С.,**
*Уфа ш., Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕЛМӘЛӘРНЕ ӨЙРӘНГӘНДӘ МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ИҖАТЫННАН ФАЙДАЛАНУ

***Аннотация:*** *мәкалә татар теле дәресләрендә фразеологик берәмлекләрне татар язучысы М.Мәһдиев әсәрләре материалында өйрәнүгә багышлана.*

***Терәк сүзләр:*** *фразеологизмнар, сурәтләү чаралары, стиль, стилистика, лексикология, антоним, синоним, омоним.*

Соңгы вакытта язучыларның образлы телен, индивидуаль стилен өйрәнүгә дә әһәмият ителә. Ләкин турыдан-туры мәктәп программасына яраклаштырылып язылган хезмәтләр юк дәрәҗәсендә. Әдәби әсәрнең телен тикшерү үзе бер кыен эш булса, аны укучыларга методик алымнар белән җиткерү тагын да кыенрак. Әлбәттә программада каралган барлык

әдәби әсәрләрнең, язучыларның да тел-стиль үзенчәлеген тикшерү максат итеп куелмый. Анализ өчен образлы тел осталарының тел-сурәтләү чараларына бай булган әсәрләрне алырга кирәк. Шуның үрнәгендә теләсә нинди әсәрнең телен өйрәнергә була. Бу мәсьәләгә һәр укытучының үз иҗади карашы булырга тиеш.

Танылган татар язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең әсәрләренең теле искиткеч бай. Бу мәкаләдә без язучының «Кеше китә – җыры кала» әсәрләрендәге сурәтләү чараларыннан фразеологик әйтелмәләрне тикшерәбез. Язучының фразеологик әйтелмәләрен мәктәптә татар теле дәресләрендә анализлау аша, аларда фразеологик әйтелмәләрне дөрес итеп аңлау, үзләренең сөйләмнәрендә куллану үзенчәлекләрен тәрбияләргә мөмкин.

Татар телендә урта (тулы) гомум белем бирү мәктәпләре өчен Р.Р.Галиуллина, Д.Ф.Заһидуллина төзегән татар теле һәм әдәбияты программасында лексикология буенча сигез сәгать дәрес каралган. Программа гамәлдәге дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелгән. Программага яраклы рәвештә Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләре җиденче, сигезенче, унберенче сыйныфларда өйрәнелә. Җиденче сыйныфта язучының «Без – кырык беренче ел балалары» (бер сәгать), сигезенче сыйныфта «Кеше китә – җыры кала» (бер сәгать), унберенче сыйныфта язучының тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә бер сәгать, «Бәхилләшү» әсәрен өйрәнүгә ике сәгать вакыт каралган.

Бала кечкенә чакта ук туган тел аша объектив чынбарлыктагы предмет, күренеш, вакыйгаларның эчтәлеген танып-белә. «Әдәбиятны өйрәнү – ул киң мәгънәдә иҗтимагый аң, культура, сәнгать үсешен, этик-эстетик карашларның эволюциясен күзәтү һәм тикшерү дигән сүз. Әдәбият шушы юнәлештә билгеле бер белем бирү белән бергә фикер, хис-тойгыларга изге юнәлеш бирү чараларының берсе һәм бик әһәмиятлесе булып санала» [3;5]. Шуңа күрә мәктәп программасына эчтәлекле һәм сәнгатьчә эшләнеше югары дәрәҗәдә булган әсәрләр сайлап алына.

Тел, М.Горький әйткәнчә, әдәбиятның беренче элементы. Әдәби әсәрнең сәнгатьчә эшләнешен, тел-стиль чараларын өйрәнү укучыларның эстетик зәвыклары формалашуына, матурлыкны тоюларына, туган телнең эчке серләрен, потенциаль мөмкинлекләрен тирәнрәк үзләштерүгә сөйләмен үстерү һәм дөньяга карашын киңәйтүгә, әсәрне аңлауга, язучының осталыгын билгеләүгә зур ярдәм итә [2;14].

М. Мәһдиевнең сигезенче сыйныф өчен «Кеше китә – җыры кала» әсәреннән бирелгән кыска гына өзек тел чараларының бер төре булган, фразеологик әйтелмәләргә гаҗәп бай, барлыгы кырык бер фразеологик әйтелмә кулланылган. Укучылар аларның стилистик функциясен, образ

тудырудагы үзенчәлеген белергә тиешләр. Бу исә сүзләрнең, фразаларның эчке мәгънәләрен тирәнрәк аңлауга ярдәм итәчәк.

Тикшерүне мәгънәдәш сүзләрдән башлыйк. Фразеологик әйтелмәләр аерым лексик берәмлекнең синонимы булып торалар. Мәсәлән, язучы «аралашмыйлар» – дигән сүз урынына «алыш-биреш бетте», «исәп-хисап өзелде» сүзләрен куллана: «Гомер буе ипи, он, тоз, керәчин алышып яшәгән күршеләр белән Васфикамал бер ел эчендә исәп-хисапны өзде» [1;384]. «Матур» сүзенең мәгънәсен «күз явын алырлык», «исең китәрлек» дигән фразеологик әйтелмәләр дә кулланыла: «ачы тел», «телләренә шайтан төкергән», «ачуы чыгу», «чыгырыннан чыгарды» һ.б.

Әсәрне өйрәнү барышында фразеологик әйтелмәләр сүзлеккә яздырыла һәм аларның ясалыш, стилистик үзенчәлекләре тикшерелә.

Фразеологик әйтелмәләрнең мәгънәсен, стилистик үзенчәлеген төшендерү өчен кыскача әңгәмә уздырырга мөмкин.

*«Иллә мәгәр, ни бригадир, ни башкалар Ташлытау килененең теленнән куркып аңа сүз катмыйлар иде»* [1;370]. «Теленнән куркып», «сүз катмыйлар иде» – фразеологик әйтелмәләре нинди сүз төркеменнән ясалган? Исем + фигыль. «Васфикамал вәгъдәсендә торды, колхоз эшен сытып эшләде» [2;377] җөмләсен ничек аңлыйсыз? Эшне сытып булмый. Бу күчерелмә мәгънәдә. Бу Васфикамалның үтә тырыш, уңган икәнлеген күрсәтә.

Мөхәммәт Мәһдиев бу әсәрендә халык телендәге бай лексик-фразеологик берәмлекләр белән эш итә: кайгы басты, исәп-хисапны өзү, сүз катмый, җәфа чиктем, аяк-кулын бәйләү һ.б. Алар халык телендә, язма әдәби әсәрләрдә күптән кулланыла. Мәсәлән, халыкта «бәгырьләрен телгәләде», «кайгы басты» фразеологик әйтелмәләре бар, М.Мәһдиев мәгънәне көчәйтергә теләп, аны ачыклап килүче сүзләр белән тулыландыра.

Укучылар аларны табып, дәфтәргә язалар:

| Халыкта | М.Мәһдиевтә |
|---|---|
| теленә эләгү | ачы теленә эләгү |
| кулын бәйләү | аяк-кулын бәйләү |
| йөрәген телгәләде | йөрәк бәгырьләрен телгәләде |
| телсез калды | телсез-авызсыз калды. |

Укучыларга аларның халыкта ничек, язучыда ничек бирелүен төшендереп китәргә кирәк. Кайбер фразеологик әйтелмәләрнең эчтәлеге М.Мәһдиевтә хәтта бөтенләй башка сүзләр белән бирелә. Халыктагы фразеологик әйтелмәләрне укучыларның үзләреннән таптырырга кирәк.

М.Мәһдиев үзе дә яңадан-яңа фразеологик әйтелмәләр тудыра. «*Дөньяда ике явыз булса, шуның берсе Васфикамалдыр... Ни әйтсә –*

*зәһәр чыга, ни сөйләсә – ярага нашатырь сибә. Колхоз эшен сытып эшләде» [1;382]*

Язучы мәгънәдәш фразеологик әйтелмәләр белән эш итүнең матур үрнәкләрен күрсәтә. Мәсәлән: *иманын суырган, җәфа чигү, биетәм мин сезне, чыгырыннан чыгаруы* һ.б. Бер үк төрле фразеологик әйтелмәләрнең стилистик-семантик үзенчәлеге контекстка, вакыйгаларга, шартларга карап билгеләнә.

М.Мәһдиев фразеологик антонимнарны да күп куллана: гаиләдә җылы тынлык урнашты – гаиләдә рәт китте, тәмле телле – ачы тел һ.б. «*Шул минутта, чыннан да, өйдә җылы тынлык урнашты. Шул уңай белән гаиләдә рәт китте. Шәйхи хәлфә дә, Васфикамалның ачы теленә бер эләгеп карагач, капкасыннан чыкмас булды. Шәяхмәт тәмле тел белән тынычлык урнаштырмакчы булды»* [1;375].

Язучының бу әсәре фразеологик әйтелмәләргә искиткеч бай. Аларның төзелешен, составын, стилистик үзенчәлеген, образлылык куәтен өйрәнү, алфавит буенча сүзлеген төзү әсәрнең идеясен тулырак аңлауга ярдәм итәчәк. Әлбәттә, барлык фразеологик әйтелмәне дә укучыга җиткерү мөмкин түгел, шулай да әдипнең фразеология белән эш итү новаторлылыгын укучыга аңлатмый калырга мөмкин түгел.

Шулай ук фразеологик әйтелмәләрне өйрәнү барышында укучыларга тагы да түбәндәге биремнәрне тәкъдим итәргә мөмкин:

1. Фразеологик берәмлекләрне укыгыз, аларның рус телендәге эквивалентларын табыгыз.

Күз карасы кебек саклау, тел теш артында тоту, бармак аша карау, койрыгына басу, чебеннән фил ясау, теш кайрау, койрык болгау, сүз эзләп кесәгә кермәү.

2. Бирелгән фразеологизмнарның мәгънәләрен синонимнары ярдәмендә аңлатыгыз.

Ут йоту, борын чөю, төп башына утырту, ындыр артында гына, авызга су кабу, кулына күз иярми, лашман тарту, кот алыну.

3. Бирелгән фразеологизмнарның мәгънәләрен аңлатыгыз һәм антонимнарын языгыз. Алар белән җөмләләр төзегез.

Күңел күтәрелү – күңел төшү

Кесәсе калып –

Телне тыю –

Сүзне үлчәп сөйләү –

Сабак бирү –

4.Төзелешләре ягыннан фразеологик әйтелмәләрнең төркемнәрен күрсәтегез.

Эт ялкавы, ике яклы пычак, өмет йолдызы, киң күңелле, әлиф йоткан, әйтеп бетергесез, чыгырыннан чыгу, дөнья көтү, эш килмәгән, ми кайнау, яшен ташы кебек, әллә нидә бер, эчендәге тышында һ.б.

Татар теле дәресләрендә фразеологик әйтелмәләрне өйрәнгәндә алда карап үтелгән чаралардан файдалану бик яхшы нәтиҗәләргә китерә ала.

**Кулланылган әдәбият**


1. Мәһдиев М.С. Әсәрләр: ун томда, т. 2. – Казан: Тат. кит.нәшр., 2019. – 538 б.
2. Поварисов С.Ш. Тел - күңелнең көзгесе. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. – 158 б.
3. Хаков В.Х. Татар әдәби теле. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1999. – 296 б.


© Субаева З.Р., Каримова З.С., 2024

УДК 811.512.141

***Султанбаева Х.В., Гимашева Г.М.,***
*г. Уфа, Россия*

# КОНЦЕПТОСФЕРА «ҒАИЛӘ» («СЕМЬЯ») С ГЕНДЕРНОЙ ХАРАКТЕРИСТИКОЙ «ЖЕНЩИНА»

***Аннотация:*** *статья посвящается концептосфере «семья» в современной башкирской литературе.*

***Ключевые слова:*** *концепт, семья, женщина, невеста, вдова, Мустай Карим.*

Современная лингвистика характеризуется повышенным интересом к проблемам исследования языка и культуры, языка и менталитета, а также реконструкции языковых национальных картин мира как отражения мировоззренческих и ментальных установок носителей языка. Следовательно, в данном исследовании отмечается важность выявления семантического потенциала концептов «кәләш» («невеста») и «килен» («невестка») в творчестве Мустая Карима в аспекте башкирских национально-культурных особенностей.

Концепт «Кәләш» («Невеста») часто ассоциируется с женщиной, обладающей красотой, нежностью и утонченностью. Она выступает в роли символа любви, женственности и духовной чистоты. В произведениях писателя «Кәләш» («Невеста») часто встречается как муза, вдохновляющая героя на поэтическое творчество или на поиск истины и смысла жизни.

Концепт «Килен» («Невестка») олицетворяет собой силу, мужество и целеустремленность. Концепт в творчестве Мустая Карима играет важную роль в раскрытии глубоких философских и жизненных тем.

В нижеследующем примере такие ценностные компоненты, как «тол кәләш» («овдовевшая невеста»), «етем ҡалған» («осиротела»), «ҡатын булмау» («не успеть стать женой») указывают на семейное положение, душевное состояние и характер женщины в обществе. Глаголы «ышанманым» («не верила») и «ышанмайым» («не верю») в качестве повтора усиливают эмотивность женщины, ее «ҡайғы» («печаль») и «бәлә» («беду»). Образ овдовевшей женщины является собирательным и олицетворяет состояние башкирских женщин, чьи мужья не вернулись с войны:

Мин тол кәләш.

Ҡатын булмай етем ҡалғанмын.

Ун йыл буйы шуға ышанманым,

Ышанмайым. Булмаç... ялғандыр! [4; 406].

Под ценностным компонентом «йәрәшкән кәләш» («суженая невеста») раскрывается свадебный обычай, при котором проводят «колыбельное сватовство» («туй никахы») между детьми. Синонимичные слова и повторы «йәрәшкән» («суженая»), «башҡортта иртә йәрәштерәләр» («у башкир очень рано сватают») раскрывают цель данного обычая и его порядок:

– Йәрәшкән кәләшем. Исеме Тамара. – Исемен әйткеһе бик килгәйне.

– Бында бигерәк йәшһегеҙ бит...

– Беҙҙә – башҡортта шулай иртә йәрәштерәләр, хатта сәңгелдәктә саҡта уҡ. («Йәләлетдин атай») [4; 413].

Ценностные компоненты «кәләш» (невеста») и «жена» («ҡатын») характеризуют «тоғролоҡ» («верность»), «көтөү» (ожидание») и семейное положение «кәләш булыу» («быть невестой»). Например:

– Мин Мария Тереза!

– Ниндәй Тереза?

– Любомир Зухтың кәләше. Ҡатыны... («Ярлыҡау») [5; 129].

Следующий пример показывает, что с детства в сердце ребенка старшее поколение вкладывает уважение, почитание семейных ценностей:

Ильястан: Ололар шаяртып: «Нисә кәләш алаһың?» – тиһәләр, «Икене!»– тип яуаплай ине ул. («Тормош сәхифәләренән») [4; 443].

Ценностный компонент «ҡалым» («калым») выражает один из обрядов сватовства башкир. Нижеследующий пример ярко показывает связь концепта «Кәләш» («Невеста») с термином родства «кәйнә»

(«свекровь»). В честь уплаты калыма за невестку, «ҡәйнә» («свекровь») собирает гостей. Данный обычай также является радостным событием для семьи:

Тәңкәбикә: Яҡшы ҡунаҡ үҙ ризығы менән йөрөр, ти. Бик уңайлы мәлгә тап булдың. Уртансы улымдың кәләше өсөн бөгөн генә ҡалым түләп бөтөрҙөм. Аҡ тирмәлә кисен мәжлес булыр. Түр башыма рәхим итерһең. («Ай тотолған төндө») [4; 17].

Концепт «Килен» («Невестка») также связан с лексико-семантическим полем «бәхет» («счастье»). В приведенных двух примерах ценностный компонент «бәхет килене» («невестка счастья») олицетворяет невесту как «байрам сәбәпсеһе» («виновница праздника»), «шатлыҡ килтереүсе» («приносящая радость»), «мөхәббәт» («любовь»). Значит, ценностные компоненты «бәхет килене» («невестка счатья») и «яҙ килене» («невестка весны») характеризуют синонимичную цепь таких понятий, как «яңырыу» («обновление»), «сәскә атыу» («расцвет»), «яҙ һылыуы» («красавица-весна»), «матурлыҡ» («красота»). Выражения «ҡартлыҡты ҡаршы алыу» («встреча старости») и «матурлыҡ менән хушлашыу» («прощание с красотой») характеризует ценностный компонент «шатлыҡ» («радость») в лексико-семантической группе «туй» («свадьба»). Понятие «яҙ» («весна») служит также приложением к слову «туй» («свадьба»). Примеры:

Байрамы был Урал иленең

Тәбрикләйек бәхет киленен («Табын йыры») [4; 57].

Был ҡартлыҡты ҡаршы алыу түгел,

Примечательно, что концепт «Килен» («Невестка») многогранен: одновременно раскрывает и быт, и ремесло, и характер, и эпоху героев. К примеру, архаизмы «тирмә» («юрта»), «ҡор» («собрание»), «мосафир» («путник»), «ҡымыҙ бешеү» («взбивание кумыса»), «һыйлау» («угощение») отражают языковую картину мира башкирского народа.

Ценностный компонент «килене килен генә түгел» («невестка не только невестка») характеризуется выражениями «күҙҙәргә тамаша» («отрада глазам»), «һиҙгер күңелгә бер мөғжизә» («чудо для чуткой души»). Повтор слова «килен» характеризует эмотивность восхваления и удивления. Синонимы «тамаша» («отрада») и «мөғжизә» («чудо») также являются ценностыми компонентами. Пример:

Килене килен генә түгел, күрер күҙҙәргә тамаша, һиҙгер күңелгә бер мөғжизә ине.

Да ведь невестка не только невестка – глазам отрада, чуткой душе чудом кажется* («Оҙон-оҙаҡ бала саҡ») [5; 359].

Таким образом, в данном исследовании концепт «Кәләш» («Невеста») и «Килен» («Невестка») выражаются такими ценностными

компонентами, как «тол кәләш» («овдовевшая невеста»), «етем ҡалған» («осиротела»), «ҡатын булмау» («не успеть стать женой»), «йәрәшкән кәләш» («суженая невеста»), «кәләш» (невеста»), «жена» («ҡатын»), «ҡалым» («калым»), «ҡыҙ урлау» («похищение девушки»), «бәрәкәт» («благополучие»), «ҡот» («благополучие»), «кеселәргә кесе булыу» («уважение к младшим»), «ололарға оло булыу» («уважение к старшим»), «усаҡ» («огонь»), «тупраҡ» («земля»), «бәхет килене» («невестка счастья»), «яҙ килене» («невестка весны»), «ҡот» («уют»), «йәм» («уют»), «фатиха» («благословение»), «ҡунаҡсыл» («гостеприимная»), «килене килен генә түгел» («невестка не только невестка»), «хазина» («клад»), «изге мөғәләмә» («доброе отношение»), «әсә» («мать»), в которых раскрываются взаимоотношения родственников, в том числе с «ҡәйнә» («свекровь»), «ҡайны» («свёкор») и др. Лексические средства, фразеологизмы, архаизмы, неологизмы, пословицы и поговорки, описание свадебных обрядов, обычаев и традиций отражают языковую картину мира башкирского народа. Необходимо подчеркнуть, что ценностные компоненты характеризуют: 1) статус невестки; 2) душевное и физическое состояние; 3) возраст невестки; 4) характер; 5) взаимоотношения с родственниками; 6) быт, 7) эпоху и др.

## Список литературы

1. Султанбаева Х.В., Гимашева Г.М. Концепт как лингвокультурная единица в когнитивной лингвистике // Языковые единицы в свете современных научных парадигм. Материалы V Всероссийской научно-практической конференции с международным участием / Отв. редактор Р.А. Газизов. – Уфа, 2020. – С. 299-301.

2. Гимашева Г.М. Концептуальный анализ в башкирском языкознании (на материале концептосферы «Ғаилә» («Семья») // Актуальные проблемы национальных литератур и отечественного литературоведения. Сборник материалов Всероссийской (с международным участием) научно-практической конференции, посвященной 125-летию со дня рождения видного башкирского поэта, общественного и государственного деятеля Шайхзады Бабича / Отв. редактор Г.С. Кунафин. –Уфа, 2020. – С. 44-45.

3. Карим М. Сочинения в 4 томах. Том 4. Повести, воспоминания, статьи, беседы. – Уфа: Башкирское книжное издательство, 1988. – 600 с. (на башк. яз.).

4. Карим М. Сборник «Времена». – Уфа: Башкирское издательство «Китап», 1992. – 360 с. (на башк. яз.).

5. Карим М. Сочинения в 5 томах. Том 3: пьесы, повести, рассказы. – Уфа: Башкирское издательство «Китап», 1997. – 480 с. (на башк. яз.).

© Султанбаева Х.В., Гимашева Г.М., 2024

УДК 811.512.141

**Үҙәнбаева Н.С. , Иҫәнғолова Г.А.,**
*Өфө к., Рәсәй Федерацияһы*

# БАШҠОРТ ТЕЛЕНДӘ ДАРЫУ ҮЛӘНДӘРЕНЕҢ АТАМАЛАРЫ ҺӘМ УЛАРҘЫҢ ХАЛЫҠ МЕДИЦИНАҺЫНДА ҠУЛЛАНЫЛЫШЫ

***Аннотация***: *мәкәләлә башҡорт телендә дарыу үләндәренең атамалары һәм уларҙың халыҡ медицинаһында ҡулланылышы тураһында һүҙ бара, сөнки үләндәр менән дауаланыуҙың тарихи дәүере кешелек тарихына бәрәбәр булып, быуаттар төпкөлөнә барып тоташа.*

***Асҡыс һүҙҙәр***: *башҡорт теле, халыҡ медицинаһы, дарыу үләндәре.*

Башҡорт халҡы борон-борондан тәбиғәткә яҡын булған. Шифалы үләндәрҙе яттан белеп, һәр ҡайһыһының файҙаһын күреп йәшәгән, шуға күрә рухи яҡтан да, физик йәһәттән дә ныҡлы булған.

Дарыу үләндәре төрлө культураларҙа һәм традицион медицинала меңәр йылдар дауамында төрлө ауырыуҙарҙы дауалау һәм иҫкәртеү өсөн файҙаланылған. Дарыу үләндәрен төп ҡулланыу юлдары: ауырыуҙарҙы дауалау, ауыртыуҙы баҫыу, йоҡоно яҡшыртыу, антисептик урынына ҡулланыу һ.б.

Халыҡ медицинаһында төрлө үҫемлектәр актив ҡулланылған. Һәр үҫемлектең үҙ функцияһы булған, һәм һәр үҫемлек тәғәйенләнеше буйынса файҙаланылған. Мәҫәлән, Рим Әхмәтов үҙенең «Одолень-трава» китабында үҫемлектәрҙе түбәндәгесә бүлгән: яман шешкә ҡаршы үҫемлектәр, үпкә ауырыуҙарына ҡаршы ҡуллана торған үҫемлектәр, йөрәк өсөн үҫемлектәр, нервылар өсөн үҫемлектәр, ашҡаҙан-эсәк ауырыуҙарына ҡаршы үҫемлектәр, бауыр өсөн үҫемлектәр, бөйөр һәм бәүел ҡыуығы өсөн үҫемлектәр, быуындарҙы дауалау өсөн үҫемлектәр, тире ауырыуҙарына ҡаршы үҫемлектәр, аллергиянан үҫемлектәр, эндокрин һәм ҡайһы бер башҡа ауырыуҙарға ҡаршы ҡуллана торған үҫемлектәр, әсә һәм уның балаһы өсөн үҫемлектәр, ирҙәр һәм ҡатын-ҡыҙҙар өсөн үҫемлектәр.

Бер нисә киң билдәле дарыу үләндәренә туҡталып китәйек.

Ябай мәтрүшкә (рус. душица обыкновенная, лат. Origanum vulgare) – 50-70 см бейеклегендәге, күп һанлы ваҡ сәскәле, тамыр һабағы

тармаҡлы күп йыллыҡ үҫемлек; иренлеләр (баллыбабайҙар) (рус. Яснотковые (губоцветные), лат. Lamiaceae) ғаиләһенә ҡарай. Грек теленән тәржемә иткәндә «тау яҡтылығы» тигәнде аңлата. Башҡорт телендәге атамаһы рус телендәге үҫемлектең икенсе бер атамаһынан – «матрёшка» һүҙенән килеп сыҡҡан.

Һабағы дүрт ҡырлы, төҙ, йомшаҡ төклө, өҫкө өлөшөндә тармаҡлы. Июнь-июль айҙарында, икенсе йылынан сәскә ата. Ябай мәтрүшкә Европала һәм Урта Диңгеҙҙә таралған. Рәсәйҙә бөтә ерҙә лә (Алыҫ Төньяҡтан тыш) үҫә: аҡландарҙа, ҡыуаҡтар араһында, ҡоро асыҡ үләнле урындарҙа, уба битләүҙәрендә.

Халыҡ медицинаһында мәтрүшкәне ревматизм, паралич, эпилепсия, гипертония, атеросклероз, ашҡаҙан-эсәк эшмәкәрлеге боҙолғанда ҡулланалар. Һыуыҡ тейгәндә тирләү, һыуыҡты ҡыуыу өсөн ҡулланыла, шулай уҡ нервы системаһын тынысландырырға, йоҡоһоҙлоҡ менән яфаланғанда ярҙам итә.

Аҡбаш *син.* ябай ергәүек, ялан ергәүеге, ураҙ уты, ерегүлән, ҡура (рус. лабазник обыкновенный, йәки лабазник шестилепестный, таволга, таволожник, лат. Filipéndula vulgaris) – тарбаҡай һабаҡлы, ҡауырһын һымаҡ япраҡлы, 6 тажлы аҡ сәскәле, хуш еҫле күп йыллыҡ үҫемлек; розалылар (рус. Розовые, лат. Rosáceae) ғаиләһенә ҡарай. Ап-аҡ сәскәле икәнен башҡорт телендәге атамаһы үҙе үк әйтеп тора. Европа һәм Көнбайыш Азия илдәренең дымлы болондарында үҫә.

Салицилаттарҙың күп булыуы арҡаһында, артрит һәм ревматизм ваҡытында быуындарҙың шешеүен һәм ауыртыуын тиҙ баҫа. Антибактериаль һәм антивирус үҙенсәлектәренә эйә булғанға, һалҡын тейеү һәм грипп ваҡытында бик файҙалы. Ергәүекте төрлө характерҙағы баш ауыртыуында, ашҡаҙан ауыртыуында, шулай уҡ тынысландырыусы һәм тартышыуға ҡаршы сара булараҡ, атеросклерозды һәм тромб барлыҡҡа килеүҙе иҫкәртеү сараһы булараҡ ҡулланалар. Аҡбаш төнәтмәһен тире зарарланғанда (шул иҫәптән янғанда), сәс үҫеүен нығытыу өсөн ҡулланалар.

Ябай еҙтөймә *син.* төймәкәй (рус. пижма обыкновенная, лат. Tanacetum vulgare) – 50 см бейеклегендәге, һары сәскәле күп йыллыҡ ҡырағай үҫемлек, ҡый үләне; астралылар (рус. Астровые, лат. Asteraceae) ғаиләһенә ҡарай. Сәскәләре һары төҫтә булғанға һәм формаһы менән төймәгә оҡшағанға күрә башҡорт телендә шундай атама алған. Болондарҙа, баҫыуҙарҙа, урмандарҙа осратырға була Япраҡтарҙы ышҡығанда камфора еҫе сыға, шуның өсөн үҫемлекте «рус мускусы» тип тә атайҙар. Еҙтөймә июндән сентябргә тиклем сәскә ата, үҫемлекте июнь-июль айҙарында, ә өлгөргән емештәрен көҙөн әҙерләйҙәр.

Еҙтөймә төнәтмәһен түбәндәге осраҡтарҙа ҡулланалар:

– кислоталылығы түбән булған гастрит, холецистит, үт юлы дискинезияһы ваҡытында;

– нервы системаһы ауырыуҙарын дауалау өсөн;

– төрлө инфекцион ауырыуҙарҙы дауалау өсөн.

Әсе әрем (рус. полынь горькая, лат. Artemisia absinthium) – бейеклеге 50-200 см булған күп йыллыҡ ярымҡыуаҡ; астралылар (рус. астровые, лат. Asteraceae) ғаиләһенә ҡарай. Һабағы төҙ, аҙ ҡырлы, өҫкө өлөшөндә тармаҡлы, төбөндә йыш ҡына ҡыҫҡаҡ емешһеҙ үренделәр барлыҡҡа килтерә. Сәскәләре бөтәһе лә көпшәле, һары төҫтә, июнь-июль айҙарында сәскә ата. Емеше 1 мм оҙонлоҡтағы көрән төҫтә, оҙонса-клин формаһында, нәҙек-бураҙналы, түбәһендә түңәрәк, бер аҙ ҡабарынҡы майҙансыҡ бар. Емеше август-сентябрь айҙарында өлгөрә.

Дауаланыу маҡсатында сәскә атҡанға тиклем йә яңы ғына сәскә атҡан һабағын йыялар. Һуң йыйһаң, файҙалы матдәләр әҙерәк була. Һуңыраҡ йыйылған сәскәләрҙә һары төҫ юҡҡа сыға, улар көрән төҫкә инә. Әремде асыҡ һауала, ышыҡ аҫтында йәки киптереү ҡоролмаларында 40-50° температурала киптерәләр. Ҡоро һабаҡтар тиҙ һыныусан булырға тейеш. Сеймалды тығыҙ тоҡсайҙарҙа йәки ағас һауытта 2 йыл һаҡларға мөмкин.

Әремде төнәтмә йә шыйыҡ экстракт рәүешендә ашҡаҙан-эсәк юлы, бауыр, үт ҡыуыығы ауырыуҙары, йоҡоһоҙлоҡ, малярия, грипп ваҡытында ҡулланалар.

Халыҡ медицинаһында әремде ҡулланыу ысулдары:

– диспепсия һәм ашҡаҙан һутының кислоталылығы түбәнәйгәндә;

– бауырҙы таҙартыу өсөн.

Ғөмүмән, әремде йырҙарҙа, төрлө әҫәрҙәрҙә, легендаларҙа осратырға була. Ул дарыу үләне генә түгел, тыуған яҡ, тыуған тупраҡтың символы, айырыуса уның әсе еҫе.

Бәпембә (рус. одуванчик, лат. Taraxacum) – ҡыуыш һабаҡлы, һары сәскәле туҙғаҡ орлоҡло үҫемлектәр заты; астралылар (рус. Астровые, лат. Asteraceae) ғаиләһенә ҡарай. Дауалау өсөн, нигеҙҙә, тамыры ҡулланыла. Япрағын да файҙаланып була. Бәпембә тамыры составында инулин, гликозид, алма кислотаһы, минераль тоҙҙар һ.б. биологик актив матдәләр бар. Бәпембә тамыры август-сентябрҙә йә апрель-май айҙарында ҡаҙып алына. Һалҡын һыуҙа йыуғандан һуң ҡоро урында һәм күләгәлә киптерелә. Бәпембә тамырынан әҙерләнгән төнәтмәне аппетит юғалғанда, бауыр һәм үт ҡыуыығы шешкәндә, нервылар ҡаҡшағанда ҡулланалар.

Аҡ баллыбабай *син.* һаңғырау кесерткән, һуҡыр кесерткән (рус. яснотка белая, йәки глухая крапива, лат. Lamium album) – 30-70 см бейеклектәге, дүрт ҡырлы төҙ һабаҡлы, бысҡы ситле япраҡлы, аҡһыл

һары сәскәле, йөнтәҫ күп йыллыҡ үҫемлек; иренлеләр (баллыбабайлылар) (рус. яснотковые (губоцветные), лат. Lamiaceae) ғаиләһенә ҡарай.

Һуҡыр кесерткән сәскәһенән әҙерләнгән төнәтмәне халыҡ медицинаһында тын алыу юлдары шешкәндә (бронхит, трахеит һ.б.), берәй эске ағзанан (ашҡаҙан, үпкә, аналыҡтан һ.б.) ҡан килгәндә, бауыр, бөйөр, бәүел ҡыуығы сирләгәндә, ҡайһы бер гинекологик ауырыуҙарҙан, нервылар ҡаҡшағанда, йоҡоһоҙлоҡ йонсотҡанда, ҡан аҙайғанда ҡулланырға кәңәш ителә. Экзема, экссудатив диатез, сиҡан кеүек тире сирҙәре йонсотҡанда ла был төнәтмәне эсеү файҙалы.

Һары мәтрүшкә (рус. зверобой обыкновенный, йәки зверобой продырявленный, лат. Hypericum) – һары, пурпур, ал сәскәле күп йыллыҡ, һирәгерәк бер йыллыҡ үләндәр йәки ярым ҡыуаҡтар заты, бейеклеге 30-100 см, һары мәтрүшкәлеләр (рус. зверобойные, лат. Hypericaceae) ғаиләһенә ҡарай. Июндән алып августа тиклем һары сәскә ата, июнь-сентябрҙә орлоғо өлгөрә. Европала Атлантик океандан алып Себер, Монголия, Ҡытайға тиклем таралған, Төньяҡ Африкала осрай. Башҡортостанда киң таралған, бигерәк тә Көньяҡ Уралда күпләп үҫә.

Төнәтмәһен, настойкаһын ашҡаҙан-эсәк ауырыуҙарын, бауыр һәм үт ҡыуығын дауалағанда ҡулланлар, тамаҡ шешкәндә һарҡынтыһы менән сайҡаталар. Бөйөр, артрит, радикулит булғанда ла ҡулланалар. Ҡатын-ҡыҙ ауырыуҙары, балаларҙа диатез булғанда файҙаһы тейә. Үпкә туберкулезы булғанда ыңғай йоғонтоһо күҙәтелә. Халыҡ медицинаһында башҡа бик күп сирҙәргә ҡаршы ла файҙаланалар.

Боланут *син.* ҡырлыҡ, ҡыҙылхан, ҡырлыхан (рус. кипрей узколистный, йәки иван-чай, лат. Chamaenerion) – оҙон һабаҡлы, ҡыҙыл йәки ал төҫтәге, тамағы асыҡ, зигоморф сәскәле күп йыллыҡ үләндәр заты; ҡыҙылханлылар (рус. кипрейные, лат. Onagraceae) ғаиләһенә ҡарай.

Болануттан әҙерләнгән сәй һаулыҡҡа файҙалы, ҡан яңырыуына, тамырҙары нығыныуына, тәндән ағыуҙы, радиацияны сығарыуға булышлыҡ итә, көс бирә. Ул яраларҙың бөтәшеүенә ярҙам итә, эндокрин системаһы ауырыуҙарына ҡаршы тора, хатта яман шештең барлыҡҡа килеүен тотҡарлай. С витамины, каротин күп, тимер, никель, баҡыр, марганец һәм башҡа матдәләр ҡанға ыңғай тәьҫир яһай.

Бысала *син.* меңъяпраҡ (рус. тысячелистник, лат. Achillea) – тетмәкәй япраҡлы, ваҡ кәрзиндәргә йыйылған аҡ һәм алһыу сәскәле үләндәр заты, бейеклеге 30-50 см, астралылар (рус. астровые, лат. Asteraceae) ғаиләһенә ҡарай. Июнь-октябрь айҙарында сәскә ата, август-октябрҙә емеше өлгөрә. Үҫемлек бик әрһеҙ, туғайҙарҙа, тау биттәрендә, юл буйҙарында үҫә.

Халыҡ медицинаһында меңъяпраҡ үләне ҡанды туҡтатыу, яраларҙың бөтәшеүен тиҙләтеү, аш эшкәртеүҙе яҡшыртыу өсөн ҡуллланыла.

Шулай итеп, күп быуаттар буйы формалашҡан башҡорт халыҡ медицинаһында үҫемлектәр бик актив ҡулланылған һәм һәр үләндең үҙенең тәғәйенләнеше, функцияһы булған. Халыҡ уларҙы йыйып киптергән, ҡайтатма йәки төнәтмә әҙерләгән.

**Ҡулланылған әҙәбиәт**

1. Ахмедов Р.Б. Одолень-трава. – Уфа: Башкирское издательство «Китап», 2001. – 432 с.

2. Ғүмәров В. З. Тыуған яҡтың шифалы үҫәмлектәре. – Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1996. − 160 бит.

3. Усманова М.Г., Исянгулова Г.А., Хайретдинов С.С. Идеографический толковый башкирско-русско-латинский словарь народных названий растений в башкирском языке. Синонимы. – Уфа: Издательство БГПУ, 2015. – 263 с.

4. Усманова М.Г., Исянгулова Г.А., Хайретдинов С.С., Еникеева Л.А. Алфавитный толковый башкирско-русско-латинский словарь народных названий растений в башкирском языке. Синонимы. – Уфа: Издательство БГПУ, 2015. – 370 с.

5. Хайретдинов С.С. Русско-башкирский, башкирско-русский словарь видовых названий растений Башкортостана / Башҡортостан үҫемлектәренең русса-башҡортса, башҡортса-русса төр исемдәре һүҙлеге. – Уфа: РИО БашГУ, 2002. – 117 с.

© Үҙәнбаева Н.С., Иҫәнғолова Г.А., 2024

УДК 398

**Фазлутдинов И.К.,**
*г. Уфа, Россия*

## ТАТАРСКИЕ БАИТЫ: СОВРЕМЕННОЕ СОСТОЯНИЕ И ПЕРСПЕКТИВЫ ИЗУЧЕНИЯ ЖАНРА

***Аннотация:*** *статья посвящена проблеме жанрово-тематической классификации исторических и военно-исторических баитов, составляющих обширный пласт татарского лиро-эпического фольклора. Основываясь на материалах IX тома «Баиты» 15-томного свода «Татарское народное творчество», изданном на русском языке, автор определяет принципы жанрово-тематической классификации данных произведений, подразделяет их на две группы и семь подгрупп. В*

*диахронном аспекте анализируется историческая основа произведений, их художественные особенности, связь с этнографией народа. Предлагаемая классификация помогает более полному и системному видению генезиса произведений исследуемого жанра.*

***Ключевые слова***: *татарский фольклор, военно-исторические баиты, классификация, жанр, мотив, война, личные трагедии, народ, поэтика жанра.*

Многие жанры фольклора – сказки, песни, пословицы и поговорки являются интернациональными. Они имеются в творчестве всех или целого ряда народов. В то же время в устной поэзии имеются жанры национальные, присущие творчеству только одного или лишь нескольких народов. Таковыми являются исландские саги, башкирские кубаиры, украинские думы и др. Татарские народные баиты тоже являются самобытным, в известном смысле национальным жанром фольклора. В творчестве других народов, за исключением башкир, нет произведений, которые были бы тождественны татарским баитам [1; 3].

Издание в 2022 году IX тома «Баиты» 25-томного свода «Татарское народное творчество» на русском языке в полной мере является отражением межкультурных коммуникационных процессов в постсоветском пространстве. Русскоязычный читатель впервые получил возможность ознакомиться с наиболее содержательными произведениями данного фольклорного жанра, отражающего духовную культуру татарского народа, его историю и этнографию. На нас была возложена ответственность выступить в качестве научного редактора данного тома, а также одного из авторов вступительной статьи и научных комментариев. Публикация данной работы была осуществлена под грифом Института Языка, литературы и искусства Академии наук Республики Татарстан [2].

Во вступительной статье нами были предложены новые принципы научной классификации баитов, мотивированные отказом от вульгарно-социологического и идеологического подходов, бытовавших в татарской фольклористике советского периода.

По характеру описываемых событий и идейно-художественным особенностям, материалы данного тома мы подразделили на четыре основные группы. Это:

1. Баиты, основанные на мифологических и религиозных сюжетах;
2. Исторические и военно-исторические баиты;
3. Социально-исторические баиты;
4. Социально-бытовые баиты [3; 13].

Данные группы, в свою очередь, подразделяются на более мелкие подгруппы. На наш взгляд, предлагаемая классификация позволяет более полно и обоснованно систематизировать произведения исследуемого жанра, облегчает их восприятие читателями.

**Исторические и военно-исторические баиты** являются наиболее многочисленными и широко распространёнными в народе. Раскрытие всей глубины и трагизма описываемых исторических событий, затронувших практически весь татарский народ, в них осуществляется через судьбы конкретных людей. По тематике произведения данной группы довольно разнородны – посвящены как отдельным личностям, сыгравшим особую роль в жизни народа, так и великим историческим событиям – катастрофам, войнам, определившим развитие общества на многие годы и десятилетия. Поэтому данные произведения можно назвать своеобразной поэтической летописью народа.

Исходя из вышесказанного, исторические и военно-исторические баиты в этом томе подразделены на следующие подгруппы:

**1. Об исторических событиях и личностях;**

**2. Военно-исторические баиты;**

2.1. О русско-французской войне 1812 года;
2.2. О русско-турецкой войнах;
2.3. О Кавказской войне 1817 – 1864 годов;
2.4. О русско-японской войне 1904 – 1905 годов;
2.5. О Первой мировой войне 1914 – 1918 годов:
2.5.1. О пленных солдатах;
2.5.2. О запасных солдатах, рекрутах и призывниках;
2.6. О гражданской войне 1918 – 1920 годов и классовой борьбе;
2.7. О Великой Отечественной войне 1941 – 1945 годов:
2.7.1. Фронтовые баиты;
2.7.2. Тыловые баиты [3; 16].

Большинство баитов, **посвящённых историческим событиям и личностям**, созданы в недавнем прошлом и теснейшим образом связаны с рукописной литературой. Ещё полвека тому назад Г. Газиз и Г. Рахим считали, что фонд исторических баитов составляют три произведения: «Взятие Казани», «Колченогий Тимур» и «Шахгали» [4; 138]. В то же время, баит «Колченогий Тимур» [2; 54] не имеет исторической взаимосвязи с реальным пришествием Тимура в Булгар. Историческая ценность произведения заключается в том, что оно пытается зафиксировать тесную связь татарского фольклора с рукописной литературой, предлагая некую объективную оценку этой личности.

Баиты «Взятие Казани» [2; 48-49] и «Сююмбике» [2; 54-60] посвящены завоеванию Казани. Они изобилуют присущими фольклору

проявлениями анахронизма, искажениями исторических фактов. Например, во «Взятии Казани» сказано:

*Исторический факт: в семисотом году вторгся в Булгар Тимур,*

*Чтоб из рук Габдуллы, хана прежнего, город себе отобрать* [2; 48].

«Семисотый год» по хиджре в современном календаре соответствует 1300 году. Но, по историческим данным, Тимур достиг границ Булгар только в 1391 году [5; 68]. Даже в баите «Сююмбике», подверженному явному влиянию труда неизвестного историка «Казанская история» и статей Ризы Фахретдина, опубликованных в журнале «Шура», дата смерти сына ханши Утямешгирея указана с ошибкой на 14 лет.

У некоторых баитов, основанных на реальных событиях, отсутствует традиционный зачин – привязка к дате происшествия. К таковым относятся «Наводнение в селении Ор» [2; 51-52], повествующий о событиях 1808 года, или «Пожар в Казани» [2; 49-51], рассказывающий о трагических событиях начала XX века. Хотя в баите, описывающем землетрясение на далёком острове Сицилия, и указана конкретная дата (*«начался двадцатый век, восемь лет прошло»* [2; 52]), на наш взгляд, это сделал не народный сказитель, а скорее всего, «писатель или редактор». Желая подробнее описать данные события и впечатлить читателей, он стилизовал их в жанровых традициях баита. Несмотря на то, что это произведение было опубликовано, оно не получило широкого народного признания.

Зато баит «Землетрясение в Ашхабаде» [2; 358-360], посвящённый трагедии 1948 года, раскрывает перед читателем всю скорбь и неизгладимые, глубокие раны в душе непосредственного свидетеля. Мать, потерявшая в этом землетрясении детей, создаёт волнующее эпическое произведение в традициях баитов, посвященных личным трагедиям. Данный баит, относящийся к середине XX столетия, имеет общие жанрово-художественные черты с более ранними произведениями данного типа: их объединяет повествование от первого лица; мотивы безвозвратного расставания, неотвратимости судьбы; страдания-переживания, наставления, взывание о помощи к Аллаху, потеря всяких надежд. Если в «Землетрясении на Сицилии» [2; 52-54] глазами стороннего наблюдателя в большинстве своем даются картины буйства стихии, то в «Землетрясении в Ашхабаде» [2; 358-360] они коротки и третьестепенны – основу баита составляют выверенные, точные слова и фразы, раскрывающие всю глубину и суть материнской трагедии:

*Что происходит, мир кипит, дрожат земля и море?*

*Стененья всюду, стоны, крики, погибают люди* [2; 358].

Посвящённые историческим личностям баиты «Об Акмулле» [2; 62-63] и «О Тукае» [2; 65-66] также созданы в традициях баитов о личных трагедиях. Неслучайно эти два произведения так любимы народом: один из поэтов был жестоко убит, а второй умер своей смертью, но в совсем молодом возрасте.

**Военно-исторические баиты** («Баиты о русско-французской войне», «О русско-турецкой», «О русско-японской», «О Первой мировой» и др.) в народе называют «военными». Они составляют примерно половину баитов, хранящихся в фондах Института Языка, литературы и искусства Академии наук Республики Татарстан. Этому есть несколько объяснений. Во-первых, развернувшиеся в начале XIX-XX веков войны мирового масштаба, стали общей для всех жителей России трагедией, и баит, будучи эпическим жанром, является отражением данных событий. В военных баитах большее внимание уделяется раскрытию душевного состояния воина – вчерашнего крестьянина, чем изображению батальных сцен. Во-вторых, в начале XIX-XX веков жанр баита переживает бурный, количественный и качественный рост, эволюционные изменения начинаются именно с военно-исторических произведений. Мотивы прощания с этим миром, до этого бытовавшие в баитах о личных трагедиях, переносятся на поля сражений. Военные баиты рассказывают о жестокой трагедии разлуки с родиной, о вынужденном оставлении мирного труда, о неведомой мачехе-чужбине, о беспощадном пекле сражений, сквозь которые предстоит пройти. Лейтмотивами этих произведений служат тоска по родине, желание вернуться домой, проклятие войне.

Ещё одной причиной широкого распространения военных и солдатских баитов является крепкая связь аудитории и автора. Этот тип произведений создаётся вырванными из мирной жизни, перенёсшими огромные потрясения татарскими крестьянами. С полей сражений баиты вместе с солдатскими письмами отправляются домой, где их читают родные и близкие солдата, передавая из рук в руки. Письменный характер произведений оказывает неоценимую помощь в развитии данного жанра. Его отдельные образцы – например, седьмой баит цикла о русско-японской войне [2; 101-112] – можно назвать хрониками, напрямую опирающимися классическим принципам поэтики баитов. Упор на раскрытие «силы и высокого боевого духа солдат» в баитах об Отечественной войне 1812 года, объясняется общим патриотическим настроем и сплочённостью народов России, хотя численность участвовавших в этой войне татар была в разы меньше, чем в последующих войнах. Например, Казанское ополчение состояло из 5000 человек [5; 165]. В «Русско-французских баитах» храбрость воинов более

тридцати башкирских и тептярских полков раскрывается с применением своеобразных гипербол («Но разбила это войско дюжина лихих тептярей», «ходуном земля ходила, когда били мы француза») [2; 66-67].

В остальных военно-исторических баитах и подобных им произведениях о плене, о нелегкой солдатской доле не отмечается ни излишнего оптимизма, ни героики. Основу их составляют мотивы, связанные с тоской простого человека по родине, идеи противостояния войне и др.

В томе «Бәетләр», изданном в 1983 году на татарском языке [6], баиты, созданные в советскую эпоху, составляли отдельный раздел и подразделялись на две большие группы. В первую вошли произведения, имеющие ярко выраженный исторический характер (баиты о гражданской войне, о борьбе с кулачеством; фронтовые баиты периода Великой Отечественной войны; о тяготах жизни в тылу). Вторую группу составили баиты личных трагедиях. На наш взгляд, выделение баитов советского периода в отдельный раздел с научной точки зрения было неоправданно, так как они не имели принципиальных типологических различий от классических произведений жанра, развивались по традиционным канонам, имели общую образно-поэтическую основу, что, впрочем, подчеркивалось и создателями искомого тома во вступительной статье [6; 14].

Именно поэтому мы решили отказаться от подобного разделения фонда баитов и, объединили исторические баиты советского периода с дореволюционными произведениями, выделив их в отдельные тематические группы, исходя из событийно-тематической направленности. Баиты, посвященные личным трагедиям советской эпохи, также пополнили группу традиционных произведений жанра [2; 344-358].

Баитов о гражданской войне и классовой борьбе с кулачеством немного, всего лишь десять. Главные герои данных произведений – сильные и смелые защитники революционных завоеваний – верой и правдой служат народу. Среди них есть и красный командир, и неуловимый партизан, и погибший от рук крестьян-мятежников сельский коммунист, и молодая учительница, и убитый остатками кулацкой банды комсомолец. Событийную основу этих баитов составляют социально-классовые трагедии. Но, в отличие от традиционных баитов, данные произведения пропитаны духом большевистской идеологии, верой в победу новой жизни, чувством ненависти к классовым врагам и стремлением окончательно их уничтожить. Пафосные призывы к борьбе определяют внутреннюю интонацию и эмоциональное напряжение баита. Это положение является определяющим и в баитах, где главным героем

является коллектив единомышленников («О переправе через Яик» [2; 178-179], «Баит о красных партизанах» [2; 175-178]), и в произведениях, посвященных конкретной личности («Баит о Гарифулле» [2; 179], «Красавица Тазкия» [2; 182-183], «Баит о Мирсаите» [2; 183-184]).

Как уже было сказано, традиционным баитам, особенно баитам на военную тематику, характерно описание реальных событий и переживаний от лица непосредственного участника или свидетеля. Кроме того, в произведениях с ярко выраженной эпической составляющей, таких как «Баит о гражданской войне» [2; 172-175], «Баит о красных партизанах» [2; 175-178], сильно авторское начало. Поэтому с уверенностью можно утверждать о том, что данные баиты созданы самобытными талантами, хорошо знающими традиции не только народного творчества, но и письменной поэзии. Как пишет Ф. Урманчеев, «…баиты о гражданской войне очень близки к агитационно-публицистической поэзии, испытавшей в советский период стремительный рост» [7; 104].

В баитах, повествующих о трагической гибели участников гражданской войны, положительными героями выступают красные бойцы, погибшие за построение нового социалистического общества, что, на наш взгляд объясняется, и коммунистической идеологией, господствовавшей в течение 70 лет, и реальным отношением современников на происходящие события. Рассмотрим «Баит о Гарифулле» [2; 179]. Гарифулла с товарищем был послан на разведку в деревню Татарское Текашево, но их схватили белые и расстреляли, узнав, что они – красные партизаны. Позже в родном селе в память о них был написан вышеназванный баит. Произведение построено на традиционной поэтике баитов, посвященных личным трагедиям, но, в то же время, несёт в себе новую идею – герои погибли, сражаясь за светлое будущее. Народ сочувствует им, выражает свою солидарность и уверенность в том, что их светлые мечты претворятся в жизнь. Эта уверенность из уст героев звучит с искренней грустью:

*Изгородь из свежих прутьев нам не суждено сплести,*
*Расцветёт страна родная, жаль, что мы не доживём* [2; 179].

Организованное кулаками в начале двадцатых годов XX века движение вилочников являлось отражением непримиримого противоборства двух антагонистических социальных сил, двух противоположных классов. Баиты «В начале двадцатого года…» [2; 180-181] и «Красавица Тазкия» [2; 182-183] раскрывают всю жестокость этих событий, потрясших простой народ. В этих произведениях кровавые деяния вилочников раскрыты в эпическом плане. Народ обвиняет кулаков, проливающих безвинную кровь, и их приспешников –

представителей сельского духовенства. Баит заканчивается разгромом внутренних врагов.

Часть баитов, созданных на рубеже двадцатых-тридцатых годов XX века, отражает этапы борьбы за коллективизацию на селе и уничтожение кулачества как класса, провозглашённое большевистским руководством. Герои этих произведений – погибшие от рук кулаков отважные парни. Ради победы новой жизни на селе жертвуют собой и Мирсаит, и Габдельнур, и Рахи. При художественном раскрытии этих образов народ особое внимание уделяет их общественной деятельности, а причину трагической гибели связывает с борьбой за считавшиеся священными для той эпохи идеалами:

*Ту одежду, что осталась от меня, носи, родня,*
*Помните, что за Советы, за колхоз я жизнь отдал.*
*(«Баит о комсомольце Рахи»)* [2; 186-188].

Неслучайно эти строки повторяются и в других баитах, становясь «общим местом», элементом поэтики для всех произведений данной тематической группы.

Баиты, посвящённые Великой Отечественной войне, нами были распределены по двум подгруппам – «Фронтовые баиты» и «Тыловые баиты». Данная классификация произведена на основе не только поэтической географии описываемых событий и военной «биографии» фольклорного героя, но и жанровых принципов художественного отображения действительности. Для фронтовых баитов, как правило, свойственны эпические и лиро-эпические художественные приёмы, а в тыловых преобладают лирические.

Подробнее остановимся на двух баитах, в эпическом плане раскрывающих боевой дух татарских фронтовиков – «Баит об обороне Москвы» [2; 190] и «Берлин мы тоже взяли» [2; 210-211]. Эти баиты были записаны из уст очевидцев событий – вчерашних солдат. Главным героем здесь выступает коллектив – советские солдаты, прошедшие победный боевой путь от Москвы до Берлина, баиты раскрывает всю полноту их чувств и переживаний:

*Каменный город, столица, матерь для всех городов*
*Шею свернул здесь германец, будет урок для других.*
*(«Баит об обороне Москвы»)* [2; 190].

Своим патриотическим пафосом и оптимистическим духом эти баиты повторяют «Баиты о русско-французской войне». Причина данного сходства очевидна: и Отечественная война 1812 года, и Великая Отечественная война 1941-1945 годов народом воспринималась как справедливая борьба за свободу и независимость Отчизны.

По способу раскрытия событийной линии часть фронтовых баитов относятся к лиро-эпическим произведениям. В них отсутствуют грандиозные батальные сцены, зато детально и реалистично раскрываются моменты проводов простого сельского паренька на фронт, чувства и переживания солдата. Тесная связь, частая смена эпических и лирических картин усиливает поэтическо-эмоциональное звучание баитов. Одни главные герои, одолев врага, возвращаются домой, и создают баиты о пережитом («Баит о красном бойце» [2; 196-202], «Наша армия – мощная армия» [2; 203-205]), другие смертью храбрых погибают в бою. Односельчане, основываясь на воспоминания друзей-однополчан погибших героев, дошедших до дома писем, увековечивают их имена в баитах («Разведчик Нурияздан» [2; 193-196], «Баит о Файзулле-агай» [2; 202-203]). Независимо от того, кем и когда были написаны эти произведения, их объединяет общая идея: главные герои одержимы духом патриотизма и готовы преодолеть все препятствия, чтобы исполнить свой священный долг.

*Сутками гнали проклятых, сон и еду позабыв,*
*Только добившись Победы, в душах наступит покой.*
*(«Разведчик Нурияздан»)* [2; 195].

Герои лиро-эпических баитов получили советское воспитание и продолжают дело своих отцов – героев произведений, посвящённых гражданской войне. Этим и объясняется общая идейно-художественная основа двух событийно-тематических групп жанра.

К подгруппе «Тыловые баиты» в большинстве своём относятся лирические произведения, созданные народом в годы войны. Они раскрывают переживания народа вследствие военных трагедий, гибели отцов и сыновей на полях сражений, голода и холода. Основными образами этих баитов являются геройски погибшие или пропавшие без вести солдаты.

По содержанию произведения данной подгруппы близки к баитам о личных бытовых трагедиях. Отличие в идейном наполнении: в баитах о личных трагедиях смерть человека наступает в результате непредвиденных жизненных обстоятельств, как несчастный случай; а в тыловых баитах речь идёт об осознанном выборе главного героя, своей гибелью на поле битвы приблизившего долгожданную Победу. Такие произведения можно считать народным памятником, поэтической эпитафией павшим и пропавшим без вести защитникам Родины.

Основными авторами тыловых баитов являются татарские женщины. Тяжелейшие душевные переживания вследствие получения похоронки на сына, на любимого мужа, или включения их в списки

пропавших без вести, сами по себе получали форму баита. Процесс возникновения тыловых баитов шёл именно таким образом.

Баит «Сын мой Салих» [2; 217-218] записан со слов матери погибшего фронтовика – Шамсераван апа Тимерхановой. Баит раскрывает всю полноту горячей материнской любви и невыносимой горечи потери. Получив скорбную весть, мать не теряет самообладания, она понимает, что гибель её сына не напрасна:

*Прошу у ветра и у птиц хоть что-нибудь поведать;*
*Похоже, голову сложил ты, за страну сражаясь* [2; 218].

Понимание того, что своей смертью Салих приблизил великую Победу, придаёт баиту оптимистическое звучание, подчёркивает его основную идею.

Своим тонким психологизмом и художественным исполнением тыловые баиты близки к жанру лирических песен. По древним канонам жанра, многие из них обретают мелодию, становятся примером синтеза устного и музыкального народного творчества.

В заключение нужно отметить, что баит, как лиро-эпический жанр татарского народного творчества, преодолел долгий исторический путь в своём генезисе. Выражая отношение народа к важнейшим историческим событиям, он и сегодня не потерял своё художественно-эстетическое и общественно-воспитательное значение. Это по-прежнему любимый и востребованный жанр татарского фольклора, который широко распространён в народе и находится в развитии.

**Литература**

1. Урманче Ф.И. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья: основные проблемы изучения баитов. – Казань: Татарское книжное издательство, 2002. – 256 с.

2. Татарское народное творчество: в 15 томах. Т. 9: Баиты / сост.: Ф.В. Ахметова, И.Н. Надиров, К. Б. Замалетдинова; отв. ред. И.К. Фазлутдинов. – Казань: Татарское книжное издательство, 2022. – 479 с.

3. Ахметова Ф.В., Надиров И.Н., Урманчеев Ф.И., Фазлутдинов И.К. Татарские баиты // Татарское народное творчество: в 15 томах. Т. 9: Баиты / сост.: Ф.В. Ахметова, И.Н. Надиров, К.Б. Замалетдинова; отв. ред. И.К. Фазлутдинов. – Казань: Татарское книжное издательство, 2022. – С. 5-34.

4. Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. Икенче басма. – Казан: Тат. мат. нәшр. комб-ты, 1925. – 316 с. *(на татарском языке)*

5. Татарстан АССР тарихы. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1970. – 744 с. *(на татарском языке)*

6. Татар халык иҗаты. Бәетләр / томны төзүчеләр Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1983. – 352 с. *(на татарском языке)*

7. Урманчеев Ф.И. Халык авазы: татар халык бәетләре тарихыннан очерклар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1974. – 128 с. *(на татарском языке)*

© Фазлутдинов И.К., 2024

УДК 821.512.145

**Фатыхова А.Л.,**
*Казан ш., Россия*
*Фәнни җитәкче: доцент* ***А.Ф.Юсупов***

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНДӘ КОММУНИКАТИВ МЕТОДКА НИГЕЗЛӘНЕП УКЫТУНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

***Аннотация:*** *укучыларны аралашырга өйрәтү – татар теле дәресләрендә үтәлергә тиешле төп бурычларның берсе. Заманча дәреслекләрдә укучыларның коммуникатив үсеше өстендә эш төрле төр биремнәр аша тормышка ашырыла.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, дәреслек, коммуникатив метод, укыту технологияләре.*

Коммуникатив компетенция формалаштыруда тел дәресләренең әһәмиятен аңлап эш итеп, заманча дәреслек авторлары фикерне туган телдә белдерү, мәгълүмат белән эшләү һәм аудиторияне эш нәтиҗәләре белән таныштыру, дискуссия, проект методына караган эш алымнарын тәкъдим итәргә тырышалар. Эш дәвамында заманча дәреслекләрне анализлау нәтиҗәсендә түбәндәге эш алымнарының еш очравы билгеләнде.

Татар теле дәресләрендә, башка дәресләрдәге кебек үк, проект технологиясен куллану мәҗбүри. Шуңа күрә биремнәр арасында проект эшчәнеген тәкъдим итә торганнары бар. Мәсәлән, сигезенче сыйныф укучыларына мондый кызыклы эш тәкъдим ителә. Укучыларга авыл урамы, авыл елгаларын сурәтләгән рәсем күрсәтелә. Рәсем янындагы проект биремен теркәп китик:

- «Рәсемне кара. Сыйныфташларыгыз белән бергә үзегезнең туган җирегезнең ойоконимнары, гидронимнарын һәм оронимнарын барлап, проект эше эшләгез» [2; 54].

Проект эше бүгенге көндә формалашу әһәмиятле булган күнекмәләрнең бик күбесен үстерүгә ярдәм итә, шул исәптән коммуникатив күнекмәләр үсеше дә комплекслы рәвештә үстерелә: төркемнәрдә эшләгәндә, мәгълүматны аудитория мөмкинлекләрен күздә тотып эшкәрткәндә, социологик метод кулланып эшләү вакытында (опрос, анкета оештыру күздә тотылганда), аудитория алдында чыгыш ясаганда, рефлексия этабында эш буенча нәтиҗәләр ясаганда.

Коммуникатив компентенция формалашу язма сөйләм үсеше өстендә эшне дә күздә тота. Сигезенче сыйныфлар өчен тәкъдим ителгән мондый биремне карыйк:

- Чәчәкләрнең безнең тормышыбыздагы роле турында кечкенә генә инша яз [2; 70].

Соңгы елларда эссе жанры актуальләшә, ул матур әдәбиятка да, публицистикага тартым булып тора. Дәреслекләрдә дә бу үзгәрешкә бәйле рәвештә эссе язу тибындагы биремнәргә урын бирелә. Мәсәлән, сигезенче сыйныфта укучыларга Фәнис Яруллинның «Сорау һәм җавап» шигырен укырга тәкъдим ителә. Биредә лирик герой «Кеше булып яшәргә нәрсә кирәк кешегә?» дигән сорауга җавап эзли. Лирик геройга таулар, чәчәкләр, диңгезләр җавап бирәләр. Җаваплар арасында төрле шартлар әйтелә: тирәнлек, бердәмлек, горурлык, гүзәллек һ.б. Лирик герой мондый нәтиҗә ясый:

Һәм шушылар өстенә<br>
Кирәк тагын иң элек<br>
Кешене кеше иткән<br>
Бер нәрсә – кешелеклелек [2; 65].

Дәреслек авторлары мондый биремне теркиләр:

- Кеше булып яшәргә нәрсә кирәк кешегә? темасына эссе яз [2; 65].

Әмма биремне уңышлы башкару өчен эссе турында төшенчә бирергә дә кирәк. Укучылар шигырьдә ясалган нәтиҗәгә генә түгел, үз позицияләренә дә таянырга тиешләр: эссеның үзәгендә автор позициясе торырга тиеш. Мәсәлән, мондый варианттагы фикерләр урын алырга мөмкин:

- мәхәббәт кирәк. Илен, үзен башкаларны яраткан кеше генә кеше булып яши ала.

- эмпатия кирәк. Башкаларның хәлен, кичерешләрен үз кичереше кебек кабул итә алган кеше генә кеше булып кала бирә, хайваннарда исә эмпатия юк һ.б.

Коммуникатив компетенция интонация белән дөрес идарә итү, саф татарча матур итеп уку, сөйләү күнекмәләрен үстерү өстендә дә эш алып баруны таләп итә. Бу яктан дәреслекләрдә аудио язмалар белән даими эш алып баруны уңай күренеш дип бәяләргә була. Бигрәк тә шигырь

текстларын дәреслек авторлары артистлар, нәфис сүз осталары башкаруында тыңларга еш тәкъдим итәләр. Электрон дәреслекләр моңа бөтен мөмкинлекләр бирә. Бары шуннан соң укучыларга иң элек лингвистик тема буенча, ә аннан тексттагы тема буенча сораулар бирелә. Мәсәлән, сигезенче сыйныфта «Кабатлау» бүлеге кысаларында Мәҗит Гафуриның «И чәчәкләр» шигыре бирелә. Аудиоязма тыңланып, текст укылганнан соң мондыйрак сораулар бирелә:

- кайсы сүзләрнең антонимнарын беләсең?
- алмашлыкларның төркемчәләрен әйт.
- Кисәкчәне тап, мәгънәсен әйт.
- Хикәя фигыльләрнең заманын аңлат.
- Син кайсы очракта һәм кемгә чәчәкләр бирергә яратасың?
- Яңа ел бәйрәменә чәчәкләр сайларга туры килсә, анди нинди чәчәкләр булыр иде? [2; 121].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: заманча дәреслекләрдә укучыларның коммуникатив үсеше өстендә эш төрле төр биремнәр аша тормышка ашырыла: аудиотекст белән эш, проект эшен башкару, инша, эссе язу һ.б.

**Кулланылган әдәбият**

1. Сәгъдиева Р.К., Фәйзрахманова К.Ф. Туган тел (татар теле). 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2022. – 152 б.

2. Сәгъдиева Р.К., Фәйзрахманова К.Ф. Туган тел (татар теле). 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2024. – 128 б.

© Фатыхова А.Л., 2024

УДК 821.512.145

**Фахртдинова А.А.,**
*Уфа ш., Россия*
*Фәнни җитәкче – ф.ф.к., доцент* ***М.С. Шәрипов***

## ДӘРДЕМӘНД ИҖАТЫНДА ФӘЛСӘФИ МОТИВЛАР ЧАГЫЛЫШЫ

***Аннотация:*** *әлеге мәкаләдә шагыйрьнең «Кораб», «Бүзләрем маналмадым», «Видагъ», «Без» программа әсәрләре һәм башка шигырьләре анализлана, алардагы төп мотивлар ачыклана: яшьлекне сагыну, тормышка ашмаган өметләр, язмыш, милләт, тормыш.*

***Терәк сүзләр:*** *мотив, шагыйрь, символ, мәдәният, жанр.*

«Хәзерге татар әдәбият белеме XX гасыр башындагы милли әдәбиятны өйрәнүнең теоретик һәм тарихи-мәдәни мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Галимнәр язучыларның иҗатын өйрәнү принципларын үзгәртергә, бүгенге көн позициясеннән әсәрләрне аңлатырга, сәнгать текстларын заманча һәм традицион анализ ысуллары белән тикшерергә, XX гасыр башындагы иҗтимагый-фәлсәфи фикер нәтиҗәсе булган әсәрләрне ачыкларга омтылалар. Тирән һәм системалы карашны таләп итә торган өйрәнү объектларының берсе – шагыйрь Дәрдемәнд иҗат мирасы» [4; 328].

2024 елда татар әдәбиятының классик шагыйре, меценат, миллионер-алтынчы, нашир, I Дәүләт Думасы депутаты (1906) Дәрдемәнднең (Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев) тууына 165 ел тулды. Дәрдемәнд – даһи шәхес, XX гасыр башы татар әдәбиятты феномены. Үз милләтен кайгыртып, аның өчен реаль матди ярдәм күрсәтеп яшәгән. Миллионер затлар арасында мондый кешеләрне очрату мөмкин эш түгел, диярлек. Икенчедән, аның иҗаты да үзенчәлекле: үз стиле, алымы булган лирик шагыйрь, шигыренең һәр сүзе зур мәгънәгә ия, фәлсәфи фикерне үтемле һәм кыска итеп әйтеп бирүе белән аерылып тора. Аның иҗаты үзәгендә «яшәү һәм үлем, тәкъдир, язмыш, гомер агышы, вакыт, кеше, яшәүнең фанилыгы («Без», 1908; «Бүзләрем маналмадым», 1908; «Хәят”, 1908; һ.б.), туган якны, Ватанны сагыну, туган телне олылау, изгеләштерү («Видагъ», «Әгәр барсаң, саба җил», «Туган-үскән җир» һ.б.) кебек мотивлар урын алган [5; 86]. Мәгълүм ки, мотив – тексттагы мөстәкыйль һәм тотрыклы эчтәлек-форма компоненты. Ул бер әсәр чикләрендә дә, әдип иҗатында да аерып чыгарылырга мөмкин [1; 123]. «Үткән еллар» авторның басылып чыккан беренче шигыре. Биредә без Дәрдемәнднең гомер турында уйлануларын күзәтәбез: *Һай, гомерләр... үтте китте... / Кая китте ул заман! / Кайда ул шәп һае-һулар! /Гофтегүләр бар иде...* [2; 72].

«Монда үткәнең матурлыгын сагынып, аны бүгенгә куеп үкенү шикелле элегик мотивлар өстенлек итә» [6; 258]. Дәрдемәнд иҗатында вакыт – үткән, хәзерге һәм киләчәк формаларында карала.

«Бүзләрем маналмадым» шигырендә дә Дәрдемәнд кешегә гомер өчен бирелгән вакытның бик тиз узуын бәян итә. Шигырьдә Дәрдемәнд үзенең язмышы, тормышы, милләт хакында уйлана. Тирән фикере – милләтенең үз ватаны юк. Киләчәк томанлы. Лирик герой якты дөньяга зур өметләр баглап яшәгән, сөю хисе белән янган, милләт коесыннан зәмзәм суы эчәсе килгән, инде күмелеп кабергә керер вакыты җиткәч, ни күрсен – бер өмете дә акланмаган. Бар саналса да, ил эчендәге кеше

булып саналмаган, аның гыйшкына сокланучылар юк, ил эчендә искән җилләр аңа ләззәт бирә алмаган, шуңа аяныч, ди ул: *Исте җилләр ил эченнән,/ Иртә-кич салдым колак./ Җил-җилкәсләрнең моңыннан/ Зәукы әлхан алмадым./ Кайда бер тау, кайда мәэмул/ Чишмәи әбелхәят!/ Тез йөгендем, яшь тамыздым, – /Дәрткә дәрман алмадым./ Дәрткә дәрман алмадым* [2; 85].

Шигырьдәге *искән җилләр* символы – ил тормышындагы әһәмиятле иҗтимагый-тарихи һәм сәяси вакыйгаларны характерлый. Аларны инкыйлаб белән бәйләнештә аңларга кирәк. Дәрдемәнд яңача сәясәтне аңларга тырышып караса да, аны кабул итә алмавын ассызыклый.

«Кораб» шигыренә күз салыйк. Илнең, милләтенең, барыр юлын, киләчәген тәгаен күзаллый алмау шигырь юлларына моңсулык, чарасызлык, өметсезлек кебек хисләр иңдерсә дә, кораб әле исән, авырлык белән булса да йөзүен дәвам итә: *Чыкты җилләр,/ Купты тулкын –/ Ил корабын җил сөрә!../ Кайсы юллар,/ Нинди упкын/ Тарта безне җан сорап?!* [2; 28].

Биредә кораб – милләт, ил, Ватан мәгънәләрен аңлатса, җил – илдәге тарихи вакыйгаларга ишарә ясый. Күрүебезчә, Дәрдемәнд әлеге әсәрендә милләт язмышы мәсьәләләрен тасвирлау максаты белән символларга, катлаулы метафораларга мөрәҗәгать итә. Дәрдемәнднең «Кораб» шигыре шагыйрьнең милләт язмышы өчен борчылуын чагылдыра.

«Видагъ» шигырендә Дәрдемәнд киң мәгънә салынган Туган иленнән аерылуны тасвирлый. *Тәгәрәп – уйнап/ Буй үскән/ Туган илем, исән бул!/ Чәч кузгатып, җәй искән/ Таңгы җилем, исән бул!/ Йөгереп – йөгереп туктаган.../ Яулык болгап сыктаган/ Нәзкәй билем, исән бул!* [2; 31].

Шагыйрь барысы белән дә аерым-аерым саубуллаша. Лирик геройга үз иленнән аерылу җиңел түгел. Монда аның балачагы үткән, егет булган, мәхәббәтен тапкан. «Нәзкәй биле» белән бергә таңны каршылаган. Хәзер шуларның барысын да калдырып китәргә кирәк.

Әлеге юлларда туган илдән аерылуның авырлыгы, газабы ассызыклана. Билгеле ки, шагыйрь эммиграция юлын сайламаса да, бу хакта уйланган, хисләрен кәгазьгә күчергән дип фаразларга мөмкин.

«Без» шигырендә Дәрдемәнд тарихтан күп нәбиләр, падишаһларның, күп халыкларның һәм илләрнең килеп китүе турында сөйләп килә дә «без дә бетәбез», ди. Кем ул «без»? Шигырь болай тәмамлана: *Өеп чергән өметне... төртте утны/ Йотып утларны... китте...яна... яна...* [2; 21].

Дәрдемәнднең әлеге шигыре яшәү / үлем төшенчәләрен үткән / бүгенге / киләчәк вакытлы чикләренә тигезләп куя. Лирик герой, үз-үзе белән сөйләшеп, тормышның тиз агышын, вакытлыбулуын яшәеш кануны кебек билгели: *Исә җилләр, күчә комнар... бетә эз! Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!* [2; 21].

Ягъни яшәү һәрвакыт үлем белән тәгәлләнә, гомер чикле. Бу очракта җил һәм ком символлары яшәешнең агышын, вакытның туктаусыз хәрәкәтен ачалар. А.М. Саяпова җилнең бу шигырьдә мәңгелек символы булуын күрсәтә [3; 156].

Дәрдемәнд – татар шигъриятендә генә түгел, ә гомум төрки әдәбиятта аерым бер дәвер булып тора. Ул бик үзенчәлекле, һәм аны, әйтергә кирәк, форма өлкәсендә генә яңалык алып килүче буларак бәяләү дөрес түгел.

Дәрдемәнднең иҗаты «саф» символизм кысаларына кереп бетми, ләкин татар шигъриятендә ул XX йөз башы чорында символизм элементларын кулланучыларның берсе һәм иң киң кулланычы.

Дәрдемәнд символизмына аерым үзенчәлекләр хас. Алары белән ул хәтта рус символистларыннан да аерылып тора. Беренче үзенчәлеге булып аның үзенә генә хас фәлсәфи системасы булуы тора. Кайбер рус символистлары кебек үк, Дәрдемәнд мифологик элементларны аеруча еш куллана. Бу мифологик образлар шулай ук Дәрдемәнд иҗатында символлар дәрәҗәсенә күтәреләләр.

Өченче үзенчәлеге итеп, Дәрдемәнднең кыскалыгын китереп була. Аның шигырьләре кыска гына түгел, хәтта шагыйрьнең әйтмичә калуы белән бәйле. Кайчак нинди дә булса фикерне әйтмәве, укучы өчен бернинди сүз белән дә әйтеп булмый торган хис тудыручы пауза барлыкка килә.

Дәрдемәнднең символизм мәктәбенә керү бәхәссез, ләкин шагыйрьнең күп кенә үзенчәлекләре шулай ук башка әдәби агымнарга да карый. Дәрдемәнд иҗатында романтизм элементлары да шактый, һәм хәтта реализмга һәм аерым очракта импрессионизмга караган шигырьләре дә бар. Моңардан тыш, Дәрдемәнд иҗатында Шәрыкъ әдәбияты йогынтысы да ачык сизелә. Менә шушы агымнарның синтезына замана каршылыкларын өстәсәк, нәтиҗәдә бер генә фикергә киләбез: Дәрдемәнднең иҗаты катлаулы, һәм аны бер генә әдәби агым эченә тулысынча кертеп булмый, дип саныйбыз.

Дәрдемәнд үз шигырьләрен Шәрыкъ әдәбиятыннан кергән мәдхия, газәл, робагый кебек жанрларда иҗат итә. Күңелендәге уй-кичерешләрне ул кыска, ләкин бик үтемле итеп әйтеп бирә алган. Юмористик, сатирик рухлы шигырьләре дә бар, ләкин иҗатына моңсулык, җитдилек хас. Дәрдемәнд тәхәллүсе исемен бик тә белеп сайлаган, чөнки ул аның рухын

чагылдыра, язганнарының мәгънәсенә дә туры килеп тора. Дәрдемәд «кайгылы», «моңсу» дигәнне аңлата. Шагыйрь милләте, Ватаны, кешенең яшәве, гомер итүе турында уйлана. Ул, чын мәгънәсендә, философ шагыйрь.

Гомуми йомгак ясап, шуны искәртергә мөмкин: Дәрдемәнд – милләт өчен яшәгән. Ул үзенең иҗатында төп, магистраль мотивны – милләт мотивын халык язмышы, ил язмышы, кавем, тарих барышы, гомер агышы белән бәйләп сурәтли.

**Әдәбият**


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

2. Дәрдемәнд. Шигырьләр. Фотоальбом / текст авторы Л.Хәмидуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 239 б.

3. Саяпова А.М. Поэзия Дардменда и символизм. – Казань: Каз. гос. пед. ун-т, 1997. – 210 с.

4. Шарипов М.С. Дәрдемәнд иҗатын өйрәнүдә герменевтика методы. //Актуальные проблемы современной татарской филологии: сборник статей X Всероссийской научно-практической конференции (9 декабря 2022 г.) / отв. ред. И.Ф. Зарипова; И.К. Фазлутдинов. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2022. – С.328-332.

5. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

6. Халит Г. Шагыйрь иҗатында дөнья һәм тарих концепциясе // Бертуган Рәмиевләр: Фәнни-библиографик җыентык. – Казан: Рухият, 2002. – Б. 242-264.


© Фахртдинова А.А., 2023

УДК 821.512.145

**Харисова Д.Р.,**
*Михайловка, Уфа районы,*
*Башкортстан Республикасы, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУДА ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ КУЛЛАНЫП УКУЧЫЛАРНЫҢ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ

***Аннотация:*** *әлеге мәкаләнең максаты – укучыларның коммуникатив культурасын үстерү мәсьәләләрен өйрәнү һәм татар*

*телен укытуда заманча технологияләр нигезендә телне өйрәнү өчен уңай шартлар тудыру.*

***Терәк сүзләр:*** *коммуникацион технология, инновацион технология, «тел мохитенә чуму», мотивация, татар теле.*

Күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри башка телләрне өйрәнгәнче кешеләрнең үз туган телен яхшы белүенә зур игътибар биргән, чөнки бала рухи байлыкны һәм туган тел төшенчәсен гаиләдә ала. Кызганычка каршы, күпчелек балалар өчен бу эш бары тик мәктәптә генә башлана. Шуңа күрә дә туган телне өйрәтү өчен укытучыларга, иң башта балаларда телгә кызыксыну уятырга кирәк, ә кызыксыну уятыр өчен дәресләрне эчтәлекле, заман технологияләрын урынлы кулланып, дәресләрдә психологик уңай атмосфера, уңыш ситуациясы тудырып кына өйрәтеп һәм яхшы нәтиҗәләргә ирешеп була. Хәзерге заманда күп кенә татар методистлары татар телен укытканда коммуникатив технологиягә нигезләнүне өстен күрә (Р.З. Хәйдәрова, Ф.Ф. Харисов, К.С. Фатхуллова һ.б.). Белгечләр фикеренчә, әлеге система сүзлек запасын, сөйләм күнекмәләрен, укучыларның белемнәрен арттыру өчен шартлар тудыра, тел тирәлеге булдыруга, шулай ук татар телен өйрәнүгә уңай мотивация булдыруга ярдәм итә.

«Кешегә балык бир, ул бер көн тук була, син аны балык тотарга өйрәт – ул көн дә тук була», – дигән халык. Бу сүзләр белән килешми мөмкин түгел. Фән һәм техника казанышлары зур тизлек белән үсә барган заманда мәгариф тә яңара, камилләшә бара.Чыннан да, без укучыларга белем биреп кенә калмыйбыз, ә киләчәктә шул белемнәрне кулланып, сәләтле шәхес тәрбияләү бурычын да үтәргә тиешбез. Сыйфатлы белем бирү өчен без дәрес¬ләребездә инновацион технологияләр кулланып эшләргә тиешбез. Педагогик инновация – ул белем бирүнең нәтиҗәлелеген үстерү өчен кулланыла торган яңа педагогик алымнар, ысуллар һәм технологияләр.

Татар телен укытуда уңышка ирешер өчен укытучы кеше бертуктаусыз эзләнергә, дәресләрне методик алымнарны төрләндерергә, заман белән бергә атларга кирәк. Бу уңайдан, мәсәлән, кроссенс алымы да әдәбият һәм татар теле дәресләрен җанландырып җибәрә. Бу алымның өстенлеге дә шунда, ул укучыларны мөстәкыйль рәвештә эзләнергә өчен шартлар тудыра, иҗади фикерләргә өйрәтә, укучыларның да материалны ни дәрәҗәдә үзләштергәнен аңларга ярдәм итә.

Рус телле мәктәптә балаларга татар телен үзләштер өчен төп 3 шартның

үтәлүе мөһим:

1) татар телендә аңлашырга, сөйләшергә өйрәтү,

2) үзләренең фикерләрен татар телендә аңлата белү,

3) башкаларның фикерләрен аңлап, язма һәм сөйләм формасында күрсәтә белү.

Башлангыч сыйныф укучылары өчен дәресләрдә уен технологиясен куллану, уйный-уйный татар телен өйрәнү уңышлы алымнарның Чөнки уеннар бала тормышында әһәмиятле урын алып торалар. Уен технологиясе тәрбия чарасы буларак, ул балаларның шәхес буларак формалашуына да этәргеч булып тора. Балага белем һәм тәрбия уен аркылы яхшырак бирелә. Ул уйнаган вакытта бик күп нәрсәләрне таный, үзенә күнекмәләр ала. Уен формасында оештырылган дәресләр фән белән кызыксынуны көчәйтә, баланың мөстәкыйльлеген, шулай ук балаларның иҗади сәләтен үстерә, фикерләү дәрәҗәсен арттыра, дәресне җанландыра, кызыклы итә. Уйный-уйный белем алганда, телдән үзләштерә торган материал җиңел ныгытыла һәм мавыктыргыч була, балаларның күзәтүчәнлеге арта. Тик әлеге эш төрен оештырганда, укучыларның яшь үзенчәлеген истә тотып, аны дәрестә урынлы куллану кирәклеген дә истән чыгармаса кирәк.

Татар теленнән дәрестән уйнала торган уеннарны берничә төркемгә бүлеп була:

а) әле өйрәнелмәгән татар лексикасын үзләштерергә ярдәм итүче уеннар;

б) өйрәнгән лексиканы ныгытырга ярдәм итүче уеннар;

в) грамматик формаларны, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен ныгытырга ярдәм итүче уеннар.

Дәрестә уенның төрле вариантларын кулланырга мөмкин. Мәсәлән, «Лото» уены. Өйрәнелмәгән татар лексикасын үзләштерергә ярдәм итүче уеннарның берсе буларак иң кулае дип исәпләнергә хаклы, минечмә. Сүзләр һәм аерым шакмакларда предметлар бирелгән, шул сүзләрне предметлар белән туры китерергә кирәк. Укучы укый, сүзгә баса һәм ул сүз предметны таба. Шулай ук аудиоязма кулланылу, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен ныгытырга ярдәм итүче чараларның берсе. Җөмләләр укыла һәм предметларның сыйфатлары атала, сыйфат сүз төркеменең грамматик формаларын үзләштергәндә бу уен төре ярдәмгә килә. Хәрәкәтне чагылдыручы рәсемнәрне куллану яисә презентация ярдәмендә хәрәкәттәге видеоязмаларны күрсәтү мөмкин. Һәр рәсемгә (видеоязмага) карата сорау бирелә: «Бу кем, ул нишли?». Бу рәсемнәргә (видеоязмага) карап фигыльләрнең грамматик формаларын өйрәнә алалар, укучылар җавапларны укый ала, күреп истә калдыра. Бу уенны рольләрдә уйнап була, шулай ук парлы эш итеп уздырырга мөмкин.

Күрүегезчә, уеннар бик күп төрле һәм аларны төрлечә уйнатып була, ә максат бер – укучыларның сүзлек байлыгын арттыру, аралашырга һәм фикер йөртергә өйрәтү.

Мультимедиа интерактив кушымталарны алганда башлангыч сыйныф укучылары өчен «БАЛА» мультимедия интерактив китапханәсен файдалану уңышлы. Укучылар мультфильмнарны аеруча көтеп ала. Бу китапханә, миңа калса, әгәр дә аны тиешенчә һәм урынлы куллансаң, башлангыч сыйныф укучыларда аеруча сөйләм телен үстерү һәм сүзлек байлыгын арттыру өчен иң яхшы сайтларның берсе. Беренчедән, бу мультфильмнар күренекле татар язучыларының һәм шагыйрьләренең, татар халык авыз иҗатына караган әсәрләренә нигезләнеп презентация кебек слайдлардан торган мультфильмнар. Бу презентациядәге слайдларны туктатып та карап була, укучылар рәсемнәрне карап, сүзләрне истә калдыра. Башта слайдтагы җөмләне татарча укып, шуннан русчага тәрҗемә куеп тыңлап, тыңлаганда сүзләрне экранда күрсәтеп һәм һәр сүз өстендә эш алып барып була. Мультфильмны карап беткәч, тест биремнәрен үтәп, текст буенча бирелгән сораулар буенча фикер алышырга да мөмкин. Бирелгән сораулар текст белән генә чикләнеп калмый, шулай ук әсәрнең эчтәлегеннән чыгып, тормыш белән, гаилә, татар халкы горефгадәтләре белән дә бәйле сораулар бар.

Миңа калса Learningapps сайты да бик кызыклы һәм үзенчәлекле. Бу сервиста онлайн-уеннарны бик җиңел үзләштереп, аларны да төзеп була. LearningApps.org сервисы Швейцария, Германия университетлары белгечләренең гыйльми – тикшеренү проекты буларак барлыкка килә. Балаларның белемнәрен актуальләштергәндә, яңа тема өйрәнгәндә һәм ныгытканда, LearningApps.org сервисын кулланып төзегән дидактик биремнәр (уеннар) тәкъдим итәм. Шундыйлардан пазллар җыю, парын табу, сүзләрне (рәсемнәрне) төркемнәргә урнаштыру, төшеп калган сүзләрне урнаштыру һәм башка уеннарны санап китәргә була. Татар теленнән «**Минем күнегүләр**» дигән веб-бит ачып, әзер конструктор буенча кирәкле уеннар, биремнәр төзеп була. Бу сайттагы биремнәр белән укучыларның үткән материалны кабатлап һәм укучыларның белемнәрен тикшереп була (мисаллар – Әйтү максаты ягыннан җөмлә, гаилә – охшаган мисалларны үз веб-биттә саклап була, сыйныфның уку дәрәҗәсенә карап, биремнәрне җайлаштырып үз биремеңне дә булдырырга мөмкин). Шулай ук бу сервистан укучыларга биремнең QC-coдын телефоннарына фотога төшереп, кушымталар аша биремнәрне үз телефоннарында эшли алалар.

Дистанцион уку да укытучыларны эзләнергә, укучы белән дистанцион укытуның отышлы технологиярен кулланып эшләргә өйрәтте. Шул ук Learningapps сайтында виртуаль класслар белән эшләп

була. Класслар булдырыла һәм укучыларга биремнәрнең ссылкасы җибәрелә. Укучылар шул ссылкадан кереп, биремнәрне үтиләр, ә укытучы статистика дигән вкладкага кереп, укучыларның биремне ничек үтәгәнен тикшерә ала.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кроссвордлар чишү, төзү дә дәресләрне җанландыра. Кроссвордлар төзү өчен уңайлы сайт бар, ул – biouroki.ru. Бу сайт шул ягы белән уңайлы, егермедән дә артмаган сүз язып, берничә төр кроссворд төзергә була. Охшаган төр кроссвордны сайлап алып, аңа бары тик сораулар гына уйлап язасы кала, һәм бу сайт укытучының эшен күпкә җиңеләйтә. Мисал – Камал, Казан, театр, драматург, артистлар, афиша, Банкрот).

Шулай ук belem.ru сайтыннан да дәрескә һәм дәрестән соң чараларга кызыклы материаллар табарга мөмкин. Анда күренекле татар язучыларының биографиясе турында да мәгълумат бар, дәрес һәм класстан тыш эшкәртмәләр дә, онлайн-тестлар, рәсемле сүзлек тә урын алган.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: дәресләрдә инновацион технологияләрне урынлы кулланып кына нәтиҗәләргә ирешеп була.

**Технологияләр ярдәмендә:**

– укучыда телне өйрәнүгә кызыксыну барлыкка килә;

– укыту сыйфатын күтәрергә ярдәм итә;

– укучыларның сөйләм теле яхшыра, сүз байлыгы арта;

– дәрес укыту формаларын һәм ысулларын төрләндереп була;

– укучының шәхси сыйфатын ачыкларга мөмкинлек барлыкка килә.

Нәтиҗәдә ясап, шуны әйтеп була: татар теле дәресләрендә инновацион технологияне куллану уку-укыту процессын яңача, заманча оештыру дигәнне аңлата. Заманча технологияләрне кулланып уздырылган дәресләр нәтиҗәсендә укучылар татар сәнгате, халык тормышы белән тирәнрәк танышуга ирешә; аларның иҗади сәләтләре активлаша, белем алуга кызыксынулары арта, сөйләм телләре яхшыра.

Күрүебезчә, укыту процессында кулланырлык технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуда иң уңышлы вариантын табу. Шулай итеп, компьютер технологияләрен үзләштерү уку процессын индивидуальләштерергә, укытуның уңай мотивациясен көчәйтергә, танып белү эшчәнлеген активлаштырырга ярдәм итә.

## Әдәбият

1. Гильманов Д.Ш. Дидактические условия формирования устойчивого интереса к изучению татарского языка русскоязычными

младшими школьниками: автореф. дис. …канд. пед. наук. – Казань, 2002. – 24 с.

2. Зиннатуллин Р.К. Күпмәдәниятле белем оешмаларында татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту // Поликультурное образовательное пространство Поволжья: интеграция регионального и международного опыта. – Казань: 2014. – С. 216 – 220.

3. Фатхуллова К.С. Татарский язык как средство межкультурного общения в образовательном процессе // Филология и культура. Philology and culture. 2013. – № 1 (31). – С. 264-267.

4. Хайдарова Р.З. Реализация принципов коммуникативного обучения в учебнике татарского языка для русскоязычных учащихся: Дис. канд. пед. наук. – Казань, 1999. – 185 с.

5. Харисов Ф.Ф. Научные основы начального обучения татарскому языку как неродному. – Казань: Изд-во ТАРИХ, 2000. – 479 с.

6. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Русчадан Н.К. Нотфуллина тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2002. – 367 б.

© Харисова Д.Р., 2024

УДК 821.512.145

**Хәмәтҗанова Ф.С.,**
*Сарман районы, Татарстан Республикасы, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА ФӘННИ ТИКШЕРЕНҮ ЭШЛӘРЕНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ

***Аннотация:*** *тәкъдим ителгән язмада татар телен һәм әдәбиятын укытуда балаларда татар теленә кызыксынуны үстерү максатыннан эзләнү-тикшеренү эшләренең әһәмиятен төшендерү төп урын алып тора.Укучыларның эзләнү-тикшеренү белән шөгыльләндерә алу ул бик зур мөмкинлекләр ача, укучыларның сөйләм телен, иҗади сәләтен үстерү белән беррәттән, яшь буында әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итә, укучы шәхесенең үсешенә зур йогынты ясый, иҗади активлыкка этәргеч бирә. Аның төрле сүзлек, тәнкыйди материаллар белән эшләү күнекмәсе арта.Бу исә үз чиратында татар телен өйрәнүнең дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәби, мәдәни хәзинәләребезне башка халыклар арасында таратуга юл ачачак һәм балаларны рухи яктан баетуга ярдәм итәчәк.*

***Терәк сүзләр:*** *алым, электив, мотивация, проект ысулы, тәрбияви максат, югары технология, логик фикер йөртү,уку, укыту алымы, укыту ысуллары, яңа технологияләр.*

Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәреш сорый. Укытучыларыбыз алдында бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, телебезне саклап калу бурычы булса, икенчедән, балаларда телне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, бу кызыксынуны үстерү бурычы. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын сорый. Бүгенге көн укытучыдан иҗади эшли белүне таләп итә. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык – бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу. Балаларның акыл үсеше, фикерләү дәрәҗәсе, рухи дөньясы төрле-төрле, шуңа күрә һәр балага шәхси якын килеп эшләгәндә генә, аның үзенә генә хас булган үсеш дәрәҗәсе үзенчәлекләрен, табигый мөмкинлекләрен билгеләргә һәм сәләтен ачарга мөмкин.

Мәктәптә эшләү дәверендә мин шуңа инандым: һәр сыйныфта да сәләтле, кызыксынучан балалар була, бары тик аларны вакытында барлап, сәләтләрен тиешле юнәлештә үстерүне оештыра белергә генә кирәк. Бигрәк тә зур сыйныф укучыларына кирәк мондый ярдәм. Мине укучыларны фән дөньясына халыкның тарихы, мәдәнияте, үзләре яши торган авыл, район, республика, аның кешеләре аша тикшеренү эшләренә җәлеп итү проблемасы уйландыра. Ә укучыларны эзләнү-тикшеренү белән шөгыльләндерә алу ул бик зур мөмкинлекләр ача, укучыларның сөйләм телен, иҗади сәләтен үстерү белән беррәттән, яшь буында әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итә, укучы шәхесенең үсешенә зур йогынты ясый, иҗади активлыкка этәргеч бирә. Мондый укучылар китапларны күпләп укый башлыйлар, чөнки әдәби әсәр аның эзләнү эшендә төп чыганак булып хезмәт итә. Укучы китап авторының башка әсәрләрен алып укый, чагыштыра, бу темага язылган башка авторларның да хезмәтләрен, әсәрләрен эзли, иҗади фикерли.Аның төрле сүзлек, тәнкыйди материаллар белән эшләү күнекмәсе арта.Бу исә үз чиратында татар телен өйрәнүнең дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәби, мәдәни хәзинәләребезне башка халыклар арасында таратуга юл ачачак һәм балаларны рухи яктан баетуга ярдәм итәчәк.

Фәнни-тикшеренү эшен башкару дәвамында укучыда туган якка, халкыбызның рухи мирасына, фәнгә кызыксыну уяна.Укучының логик фикер йөртү сәләте арта, фәнни әдәбият белән кызыксына, эзләнә. Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген оештыруга, әлбәттә, мотивация булдыру мөһим.Эшне укучы кызыксынып, теләп башкарырга тиеш. Фәнни-

практик конференцияләрдә катнашу, чыгыш ясау укучыда максатчанлык, төгәллек, җаваплылык һәм ихтыяр көче тәрбияли. Фәнгә беренче адымнар ясауга, әлбәттә, мәктәптә үткәрелә торган конференцияләр ярдәм итә.Бу чарада укучылар ораторлык осталыгы, үз фикерен дәлилли белү, дискуссия алып бару күнекмәләре алалар.Мәктәбебездә һәр ел рәттән традиция буенча укучылар өчен конференцияләр үтә.Башлангыч сыйныфлар өчен ул «Беренче адымнар» дип аталса, югары сыйныф укучылары өчен төрле темаларга уздырыла.

Эзләнү өстендә эш түбәндәге этаплар аша уза: 1) Әзерлек этабы, 2) Проект өстендә эш. 3) Фәнни эшне тәкъдим итү – проектны яклау. 4) Эшне бәяләү (берничә дәрәҗәдә бәяләү). Мин үз эшемдә тикшеренү һәм проектлар методын 2016 нчы елдан куллана башладым. Беренче эш тәҗрибәсе «Г.Тукайның иҗатында «Шүрәле образы» темасына булды. Мондый эзләнүдә балалар үзләре шигырьләр сайлыйлар, шагыйрьнең иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнәләр.

Бүгенге көндә сәләтле балалар белән «Без яшь, без сәләтле...» электив программасы нигезендә эшлим. Республика, регион, Бөтенрәсәйкүләм уңышларыбыз бик күп. Мин моңа чиксез шатмын. Укучылар, мәктәпне бетереп, югары уку йортларында укый башлагач, фәнни хезмәтләр – докладлар, курс эшләре, төрле пректлар, рефератлар яза башлыйлар. Бу өлкәдә аларга күп төрле чыганаклар белән эш итәргә туры киләчәк, ә мәктәптә укыганда ук бу эшкә өйрәтелгән укучы чыганакларны ничек эзләп табасын, алардан кирәкле мәгълүматларны ничек туплыйсын, аннан соң ничек гомумиләштереп, нәтиҗәләрне ни рәвешле ясыйсын белә һәм, әлбәттә, аңа күпкә җиңелрәк булачак.

Гомумән, фәнни хезмәт язарга алынган укучы белән эшләгәндә укытучыдан тактлылык, осталык таләп ителә. Укучыга вакытында ярдәм итеп, аны эшкә өйрәтсәк кенә, без татар халкының белемле укучыларын үстерүгә өлеш кертә алачакбыз.

**Кулланылган әдәбият**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: «Мәгариф», 2007.

2. Исмәгыйлова С.Г. Укытучының фәнни эшчәнлеге // «Мәгариф» журналы, 2011. – № 12. – 96 б.

3. Рахимов А.З. Научно-исследовательская и внедренческая деятельность. Лаборатории творческого развития. – Уфа, 2004.

4. Хайдарова Р.З. Научно-педагогические аспекты билингвального образования в Республике Татарстан. – Набережные Челны, 2006.

5. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан:Татарстан китап нәшрияты, 2015.

6. Шаймарданова ФДББС шартларында татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик компетентлыгын камилләштерү // Мәгариф. – 2015.

© Хәмәтҗанова Ф.С., 2024

УДК 37.013

***Хәсәнова А.Н.,***
*Казан ш., Россия*

## ГАБДЕЛБАРИ БАТТАЛ – ЖУРНАЛИСТ

***Аннотация:*** *мәкаләдә Габделбари Батталның журналистика өлкәсендәге эшчәнлеге яктыртыла. Әлеге мәкалә кысаларында Г.Батталның 1917 елга кадәр татар вакытлы матбугатында язган мәкаләләре кыскача карала. Аның мәкаләләренең төп тематик төркемнәре аерып күрсәтелә.*
***Терәк сүзләр:*** *Габделбари Баттал, вакытлы матбугат, редактор, журналист, «Йолдыз» газетасы*

Габделбари Габдулла улы Баттал тарих, әдәбият өлкәсендә генә түгел, вакытлы матбугатта да тирән мәгънәле әсәрләре белән эз калдырган, татар журналистикасының тууына, үсүенә һәм алга китүенә зур йогынты ясаган олы галим.

Г.Батталның журналистик эшчәнлеге туган иленнән читтә башланып китә. 1904 елда белемгә омтылыш аны Мисырдагы Әл-Әзһар университетына алып килә. Ләкин әлеге уку йортына керә алмау сәбәпле, үзлегеннән белем ала, гарәп, рус телләрен өйрәнә башлый. Матди хәле начар булу сәбәпле, ул төрле газеталарда эшләргә мәҗбүр була. Каһирәдә чыга торган «Әл-Мөнар» журналы, «Әл-Мөэид» һәм «Әл-Мокатим» газеталарында аның беренче мәкаләләре басыла, соңрак «Әл-Җәридә» газетасында мөхәррирлек вазыйфасын башкара [1; 49]. Ләкин, кызганычка каршы, аның бу чор эшчәнлеген яктырткан мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә. Бары тик Казанга кайткач та, әлеге газеталар белән элемтәсен өзмәве билгеле [17].

1908 елда Г.Баттал Россиягә кайта һәм бераз вакыт Оренбургтагы «Вакыт» газетасында эшләп ала. Бу газета аның туган илендә журналистик эшчәнлегенең башлангычы булып тора. Шуннан башлап ул вакытлы матбугатта даими катнаша башлый. 1908 елдан башлап «Шура» журналында да аның мәкаләләре бастырыла. Мисырдан күп нәрсәләр төшенеп кайткан Г.Баттал төрле мәсьәләләргә карата үз фикерен белдерә торган журналист булып таныла.

1913 елның август башларында «Йолдыз» газетасы нашире Һади Максуди чакыруы буенча, Г.Баттал Казанга килә һәм «Йолдыз» газетасында җаваплы сәркатип булып эшли башлый. 1913-1917 еллар аралыгында газетаның һәр санында аның татар халкы тормышына караган күп санлы мәкаләләре дөнья күрә. Г.Баттал «Йолдыз» да дүрт ел дәвамында эшли. Күрәсең, бу дәвердә аның газетага йогынтысы булмый калмый. Г.Ибраһимов Сухумидан 1917 елның 13 маенда дусты Х.Искәндәревкә язган хатында: «Йолдыз»ның хәле яхшырды, газетаның йөзе күпкә үзгәрде, мин аның (Г.Батталның) «Йолдыз» да калуын телим», – дигән сүзләр яза [15; 87].

Ләкин 1917 елда Г.Баттал «Йолдыз» газетасыннан китә. Сәбәпләренә килгәндә, Г.Баттал бу турыда язган мәкаләсендә «Һади әфәнде белән сәяси нәзарда килешә алмаудан», – дип яза [5].

Шул ук елны Г.Баттал Мөселман комитеты һәйәтенең әгъзасы буларак Төркестанга җибәрелә [9]. Анда ул Исмәгыйль Габди белән берлектә «Шураи Ислам» газетасын оештыра. Ләкин «Шураи Ислам» буржуаз газета була икән дип, газета нәшер ителәчәк матбага хезмәткәрләре каршы чыгалар [13]. Шуңа да карамастан, бик зур кыенлыклар белән булса да, алар газетаның ике санын бастыруга ирешәләр.

Казанга кайткач, Г.Баттал 1917 елның 2 июленнән татар эсерларының лидерларыннан булган Ф.Туктаров белән «Корылтай» газетасын оештыра. Шул ук елның ноябрендә Уфада ачылган Эчке Россия һәм Сибирия төрек-татарлар Милли Мәҗлес эшендә актив катнашучыларның берсе була. Г.Баттал бу эшчәнлекне «Корылтай» газетасы битләрендә даими яктыртып бара. Ләкин әлеге газетаның да гомере озын булмый: 1918 елның мартында «контрреволюцион» эше өчен «Корылтай» ябыла. Аның бары тик 67 генә саны чыгып кала. Шул ук елның 8 апреленнән исә, «Корылтай» урынына «Алтай» газетасы чыга башлый. Бу эш Г.Баттал җаваплылыгы белән башкарыла. 23 майда 13 саны дөнья күргән газета эшчәнлеге Казан Советы тарафыннан туктатыла. Советка каршы пропаганда алып баруы өчен газетаның мөхәррире Г.Баттал кулга алына. Аны «моннан соң бернинди газета-фәлән чыгармаска вәгъдә бирәм», – дигән шарт белән имза алып, төрмәдән чыгаралар.

Уфаны кызыллар алгач, куылган Милли Мәҗлес әгъзалары белән бергә Г.Баттал да – Себергә Кызылъяр (Петропавел) шәһәренә юнәлә һәм анда Милли Мәҗлес «Кече Милли Мәҗлес» исеме астында эшен дәвам итә. Кызылъяр шәһәрендә ул Г.Исхакый белән берлектә «Маяк» исемендә сәяси, әдәби, милли газета [14; 125] чыгаруга катнаша. Ләкин бу газета

турында мәгълүматлар аз, аның «Кече Милли Мәҗлес» органы булуы да мөмкин [18: 9].

Себердә совет хакимияте урнашкач, Г.Баттал Казанга кайтырга карар кыла. Монда ул гаиләсе белән күрешә, ләкин берничә көннән соң аны кулга алалар һәм төрмәгә утырталар. Гражданнар сугышы беткәнче, мәҗбүри хезмәт лагеренда була. Үзенең киләчәге өчен куркып, Г.Баттал чит илгә качарга карар кыла. Ялган таныклык ярдәмендә Финляндиягә китә.

Баттал шул дәрәҗәдә журналистикага гашыйк кеше була ки, хәтта чит илдә дә язуыннан туктамый. Истанбулдагы «Рәсүлзадә» нәшриятына «Казанлы» имзасы белән мәкаләләр җибәреп тора.

1925 елның ноябрендә ул Төркиягә күченә. Монда да публицистик эшчәнлеген дәвам итә. «Төрек мәдәнияте» журналында бер-бер артлы яңа хезмәтләрен бастыра. Аның мәкаләләре башка телләрдә дә дөнья күрә. Мәсәлән, Казан татарлары әдәбиятына багышланган мәкаләсе немец телендә Голландиянең «Handbuch Orientalistik» журналында бастырыла. Казан һәм Кырым татарлары әдәбиятына багышланган башка ике мәкаләсе «Philologicae Turcicae Fundamenta»ның икенче томында француз телендә нәшер ителә [16; 10-11].

Г.Батталның журналистик эшчәнлеге үзенең тематикасының киңлеге белән аерылып тора. Моннан чыгып, аның мәкаләләренең эчтәлеген берничә тематик төркемгә бүләргә мөмкин:

- иҗтимагый-сәяси;
- мәгариф өлкәсенә караган;
- хатын-кыз мәсьәләсе;
- тарихи.

Г.Баттал күпчелек мәкаләләре иҗмагый-сәяси темага багышланган. Ул үзе дә җәмәгать эшләрендә актив катнашкан: «Шәрекъ клубы»нда һәм «Эчке Россия һәм Сибирия татарларының Милли Идарә»се әгъзасы булган шәхес. Шуңа бәйле рәвештә бу эшчәнлекне вакытлы матбугат битләрендә дә яктырта [11]. Иң беренче чиратта Г.Баттал газета-журнал битләрендә милләт хадиме буларак чыгыш ясый.

1905–1906 еллардагы Беренче Россия революциясе татар халкы тормышына шактый үзгәрешләр алып килә. Санкт-Петербург, Түбән Новгород кебек Россиянең төрле шәһәрләрендә съездлар үткәрелә, оешмалар төзелә, планнар корыла. Ләкин бу кыска вакытлы кабыну гына булып ала. Иң элек университетлар, ир-ат укытучылар әзерли торган (дәрелмөгаллимин) һәм хатын-кыз укытучылар әзерли торган (дәрелмөгаллимәт) училищалар, гимназия, семинарлар ачарга карар кылынса да, төрле сәбәпләр аркасында, һичбер нәтиҗәгә киленми. Бу сүлпәнлеккә, гамьсезлеккә каршы Г.Баттал 1914 елда «Мәктәп»

журналында «Киңәш мәҗлесенең карарлары» исемле мәкаләсен бастыра. Уфада уздырылган киңәш мәҗлесендә чыгыш ясаган дин әһелләрен тәнкыйтьләп, «һәрбер фикере чыпчык борыныннан да кыска булган җаһил мулланың «шәригать белән дөнья фәннәре бергә җыелмый!» [6] дигән лафына игътибар итмәскә чакыра. Мәктәп-мәдрәсәләрдә үзгәрешләр ясау, дөньяви фәннәр укытуны яклаган Г.Баттал, бу хосуста бер җыелыш ясалуына өмет итә.

Г.Баттал милләтнең алга китүендә аң-белемнең әһәмиятен тирәнтен аңлаган журналист. Шуңа күрә дә бу проблема турында даими язып торган. Аның 1914 елда «Йолдыз» газетасында бер-бер артлы басылып чыккан «Иҗтимагый эшләрдә косурымыз» [18;154], «Бәхетсезлегемез» [3] мәкаләләре шул ук теманы яктырталар.

«Татар карагруһлары» мәкаләсендә Г.Баттал татарның үткәненә мөрәҗәгать итеп, татарда мәдәният, мәгариф үсешенә киртә булып торган факторларны атап үтә. Хәзерге көндә дә мондый каршылыкларның булуына басым ясап, болай дип яза: «...Күптән түгел үз арамыздан «татарлар панисламизм белән угърамалар» дигән бер груһ адәмнәр чыгып, мәктәп вә мәдрәсәләремездә тентүләр ясалуга берничә галим вә мәдәният хадимнәренең тузылуга сәбәп булынган иде. Инде хәзер әллә нинди карагруһ партияләренең уставларыннан копия алып, «Сыйрател мөстәкыйм» исемле союз ясап, шуңа «Бөтен Русиядәге мөселман халкының иттифакы» исеме биргән адәмнәр дә үз арамыздан табылды...» [Йолдыз,1914: 11 февраль].

Г.Баттал әлеге союзга нигез салырга омтылучы Петербург мулласы Сафа Баязитовның «Мәдрәсәләрдә фән укылырга ярамый» дигән фикере белән килешмичә, үзенең союзга һәм Баязитовка булган мөнәсәбәтен белдереп, аны «Атналык гәзитәсен идарә итә алмаган бер гаҗиз бәндә, карагруһ русларның модадан чыгып, тынчып беткән уставларын татарчага әйләндереп, шуңа тигезләп ясаган союз» [18; 162] дип атый. Әлеге җөмләдән Г.Батталның «Сыйрател мөстәкыйм»гә булган карашы ачык чагыла. Биредә аның үткен тел остасы булуын да билгеләп үтәргә кирәк. Гомумән, Г.Баттал иҗтимагый-сәяси тормышның күп яклары белән тирәнтен кызыксынган һәм караңгы күренешләрне, буржуаз милләтчеләрне, карагруһ динчеләрне фаш иткән мәкаләләрен вакытлы матбугат битләрендә даими бастырып килгән.

Г. Баттал аеруча әһәмият биргән, матбугатта даими алып барган темаларның берсе – мәктәп-мәгариф системасы. Әлбәттә, аны татар халкының авыр тормышы, аң-белем, мәдәни дәрәҗәсе түбән булуы ачындыра. Ул мәктәп-мәдрәсәләрдә белем бирүче муллаларның «мәдрәсәләрне теләгәнчә идарә итү»ләренә каршы чыгып, тиз арада бу хәлне үзгәртергә чакыра. «Черек нигез белән озак яшәргә мөмкин

түгел...Вакыт уза бара, һәрбер көн, сәгать вә минут санаулы вә кадерле. Без телибез ки, олугъларыбыз тарафыннан бу тугърыда матбугатта гарыз кылынган фикерләр, сахрада кычкырылган тавыш кеби югалып китмәсен иде...» [2] дип яза үзенең мәкаләсендә Г.Баттал.

Ул халыкның белем-культурасы түбән булуына, аның караңгылыкта яшәвенә ачына, уку-укыту эшләрен хәл итү зарурлыгын кискен куеп, мәгарифне тәртипкә салу өчен матур сүзләрдән эзлекле чараларга күчү кирәклеген күрсәтә.

Г.Баттал публицистикасында зур урын алып торган тагын бер тема – хатын-кыз мәсьәләсе. Ул хатын-кызларның хокуксызлыгы белән килешмичә, аның азатлыгын, мөстәкыйльлеген яклаучы буларак чыгыш ясый. Әлеге күренешкә сәбәп булып килгән дини тәртипләргә каршы чыга [18;144].

Шул ук вакытта Г.Баттал бу өлкәдә күзәтелгән хәрәкәтләргә сөенеп, аларны хуплап күтәреп ала. Бу мәсьәләнең нинди мөһим булуын күрсәтү өчен, Европа һәм Америка хатын-кызларын мисалга китерә [18; 26]. Мөгаллимәләр курсы, хатын-кызлар өчен махсус нәшрият ачылу вакыйгаларына карата чиксез сөенечен белдерә [8]. Татар хатын-кызлары өчен үрнәк булырлык Фәхрелбанат Сөләймания, Фатыйма Фәридә ханымнар турында мәкаләләр бастыра [18; 157]. Соңгысы турында «гүзәл кале вә тугъры фикерләре илә матбугатта мескен татар хатын-кызларының якты дөньяга чыгулары өчен хезмәт итүче», дип яза [12]. Күргәнебезчә, Г.Баттал милләтнең үсешендә хатын-кызларның роле зур булуын яхшы аңлаган.

Г.Баттал тарихчы буларак, халыкның үткәненә бәйләнешле публицистик мәкаләләр дә язган. Шундыйларның берсе – «ничәмә-ничә йөз еллардан бирле татар йөрәгендә бер урын тотып килгән» [10; 52] Сөембикә манарасы хакында. 1917 елның 16 сентябрендә манара башындагы «бөркет» сурәте алына. Шул җәһәттән бу манараның татар әсәре булмавы хакында сүзләр йөри башлый. Моңа мөнәсәбәтле Г.Баттал үзенең мәкаләсен язып чыга. Бу турыда татар тарихчыларыннан Ш.Мәрҗани, Г.Әхмәрев, Һ.Атласый фикерләрен генә китереп калмыйча, рус галимнәре П.Заринский, П.Невзоров, Н.Загоскин, П.Дульский, М.Рыбушкин, С.Шпилевский, Н.Бажманов карашларын, хәтта голландияле Витзен манзараларын да тәкъдим итә. Әлеге мәкаләдән Г.Батталның, беренчедән, киң карашлы тарихчы булуы расланса, икенчедән, публицистик мәкаләләр остасы булуы тагын бер кат ачыклана.

Аның 1913 елда чыккан «Милләтне билгеләү» мәкаләсе дә тарихи характерда. Ул чорның актуаль темасы-татарларның үзбилгеләнүе турындагы мәсьәләне яктырта. Күпчелек өчен «Без нинди милләт соң?» дигән сорау актуаль була. Бу өлкәдә дә фикер төрлелеге күзәтелә.

Кемнәрдер үзләрен болгар, нугай, мөселман яки төрек дип атый. Г.Баттал мәкаләсендә халыкның тарихи үткәненә күзәтү ясый. Бу мөнәсәбәттә Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Тукай фикерләренә таянып, публицист татар милләте булуыбызны исбат итә. «Без – татарбыз, русның «славян» булуы, рус булуына манигъ булмаган кебек, безнең төрек булуыбыз «татар» булуыбызга монафи түгел» [7], – дип яза.

Г.Баттал татар халкы тарихы белән генә чикләнеп калмый, Мисыр тарихына караган мәкаләләрен дә бастыра. Әлбәттә, бу факт аның киң эрудицияле журналист булуы турында сөйли.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк, Г.Баттал гомерен татар журналистикасына багышлаган, аның үсүенә, алга китүенә зур өлеш керткән, күләмле публицистик мирас калдырган шәхес. Аның исеме татар тарихында үзенең мактаулы урынын алырга лаеклы.

**Әдәбият**


1. Баттал Габдулбари Абдуллович. Ислам на Урале: энциклопедический словарь / Коллект. автор. сост. А.Н. Старостин. – М., 2009. – С. 49.
2. Баттал Г. Ашыгырга кирәк // Йолдыз. – 1913. – 7 ноябрь.
3. Баттал Г. Бәхетсезлегемез // Йолдыз. – 1914. – 19 февраль. – № 1128.
4. Баттал Г. Ике мәҗлес // Йолдыз. – 1914. – 24 апрель. – № 1174.
5. Баттал Г. «Йолдыз»дан нигә киттем? // Кояш. – 1917. – 28 март.
6. Баттал Г. Киңәш мәҗлесе карарлары // Мәктәп. – 1914. – № 1. – Б. 11-13.
7. Баттал Г. Милләтне билгеләү // Мәктәп. – 1913. – № 6. – Б. 149-153.
8. Баттал Г. Мөгаллимәләр курсы // Йолдыз. – 1914. – 8 апрель.
9. Баттал Г. Мөселман комитетының гомуми җыелышы // Йолдыз. – 1917. – 16 июнь.
10. Баттал Г. Сөембикә манарасы хакында // Сөембикә. – 1917. – № 24.
11. Баттал Г. Укучылар файдасына «Шәрекъ» кичәсе // Йолдыз. – 1915. – 16 декабрь. – № 1571.
12. Баттал Г. Фатыйма-Фәридә ханымның вафаты // Йолдыз. 1914. 18 февраль.
13. Баттал Г. «Шураи ислам» гәзитәсе (идарәгә мәктүб) // Ил. – 1917. 16 июнь.
14. Гайнанов Р., Мәрданов Р., Шәкүров Ф. Татар вакытлы матбугаты. – Казан: Рухият, 1999. – 125 б.

15. Ибраһимов Г. Хатлар һәм документлар. – Казан: Фикер, 2000. – Б. 87.

16. Кәримуллин Ә. «Ике бертуган Максудилар» авторы Г.Баттал Таймас турында. – Казан, 1999. – Б. 10-11.

17. Кәримуллин Ә. Тарихыбыз сәхифәләреннән // Мирас. – 1995. – № 9. – Б. 127.

18. Хәсәнова А.Н. Милләт гомере дөнья гомере кадәр озын булсын. – Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Габделбари Баттал. Сайланма әсәрләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Габдулбари Баттал. Избранные сочинения / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, А.Н. Хәсәнова, Г.М. Ханнанова; кереш сүз авторы А.Н. Хәсәнова. Т. 1. – Казан: ТӘһСИ, 2023. – 20 нче чыг. – 256 б.

© Хәсәнов А.Н., 2024

УДК 821.512.145

**Шайхалиева Г.М.,**
*г. Уфа, Россия*
*Научный руководитель – к.ф.н. доцент* ***Н.У. Халиуллина***

## СПЕЦИФИКА СТИЛИСТИКИ СОВРЕМЕННЫХ МЕДИАТЕКСТОВ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

***Аннотация:*** *в статье рассматриваются проблемы определения стилистической принадлежности медиатестов и их связи с культурой речи. Основное внимание уделяется влиянию языка массовых коммуникаций на формирование новой языковой политики. Анализируются стилистические особенности медиатекстов, их связь с типологией норм и влияние на языковую жизнь общества.*

***Ключевые слова:*** *медиатекст, речь, модусная ориентированность, модализация.*

Ряд ученых рассматривают речь как систему культурно обусловленного поведения, поскольку убеждения и ценности представляют собой некие точки отсчета и определяют поведение человека [1; 7]. В сознании говорящего такое видение представляется как некая форма интерпретации действительности, которая основана не столько на соотношении базовых модальных сущностей Действительного, Возможного и Необходимого, сколько на учете аксиологических аспектов модальности [6]. В этом смысле медиатекст – это сконструированное речевое поведение, соответствующее

интенциональному состоянию (~ментальности говорящего) и культурным моделям описывающего или предписывающего характера.

В функциональной стилистике, исследующей речемыслительную деятельность, где смысловая структура как воплощение замысла текста рассматривается в совокупности экстралингвистических факторов, выступающих основой текстопорождения в определенной сфере общения. Замысел текста многослоен: «Главное отличие смысловой структуры целого текста – в возможности объективации в ней, отражении не только собственно фрагмента действительности (денотата в узком смысле – вещи, факта), но и процессов коммуникативно-познавательной (когнитивной) деятельности субъекта, как и структуры самого знания, а также – шире – социокультурного контекста» [7]. Исходя из этого, можно утверждать, чтосмысловая структура текста имеет определенную иерархию, которая, в свою очередь, отражает фрагмент действительности (денотат) и целенаправленную активность сознания познающего субъекта, связывающую коммуникативную деятельность с достижением определенного результата.

Психолог Н.Д.Павлова писала: «Интенциональная структура текстов представляет собой иерархически организованную систему. Направленность на действительность образует нижний уровень иерархии. Интенции второго уровня – апологизация и критика – модифицируют анализ действительности и в свою очередь испытывают влияние направленности говорящего на аудиторию. Направленность на адресата, воздействие, агитацию составляет верхний уровень системы. Под влиянием этой направленности интенции нижних уровней иерархии приобретают конкретно соотнесенное с адресатом выражение, обеспечивающее адекватное восприятие и пропагандистское воздействие выступления» [5].

Речь (текст) рассматривается как многослойное иерархическое образование. Оно содержит в себе дескриптивную составляющую (тот или иной фрагмент действительности) и модусную составляющую, которая включает, в свою очередь, валюативную, определяющую общественную ценность дескриптивного содержания медиатекстов, и нормативно-побудительную, формируемую на основе определения ценности дескриптивного.

Важно подчеркнуть при этом, что модусная ориентированность, которая фокусирует взгляд на мир, оказывается важнейшей в смысловой организации медиатекста, поскольку определяет смысл информирования, формируя специфическое ценностное содержание медиатекста. Экстралингвистические факторы ориентированности в медиатексте, согласно Г.Я. Солганику, это «общественные интересы», а также

«представления субъекта речи о пользе, выгоде, политических целях» [8: 15]. Отбираемая для публикации фактуальная сторона сообщения определяется модусом установочного целеполагания (тем, что необходимо, возможно или желательно показать). Следовательно, в смысловой структуре медиатекста отражается не просто тот или иной фрагмент мира, но опыт его восприятия и осмысления, что позволяет «установить, с каким видением мира мы столкнулись в данном тексте, что и по какой причине привлекло внимание человека, какие именно фрагменты знания и оценок в нем закреплены и т.д.» [7].

Специфика идеологической работы в сфере публицистики состоит в том, что это пропагандистская деятельность ярко выраженной ценочной (прагматической) направленности. Особенное внимание уделяется семантике, связанной с вектором «автор – адресат». Согласно А.Г. Баранову [2], содержание и объем модальности определяется через разнообразные отношения между участниками текстовой деятельности.

Оценка является интенциональной основой механизмов модализации, служащих задачам идеологии, поскольку выполняет функцию связующего звена между ментальной сферой говорящего и социально-культурным контекстом. Именно оценке принадлежит ведущая роль в изменении значений, в переоценке слова и его перемещению из одного ценностного контекста в другой. Направление соответствия между пропозицией и действительностью оформляется модальностью: либо мир выступает в качестве «точки отправления» и заданного критерия истинности слов (онтологическая модальность, de re), либо же слова рассматриваются как своего рода проект, в соответствии с которым строится новое положение дел в мире (деонтическая модальность, de dicto).

Основная задача модальности – управление процессом интерпретации высказываний адресатом. При этом в речи фактор модальности связан с разными аспектами оценочности и выбором предоставляемых языком способов выражения значений говорящим. Отметим здесь идеологически обеспеченный культурой характер модализации в медиатексте: она служит процессу эффективного внедрения риторической формы идеологии в общественное сознание.

Для изучения особенностей отображения «картины мира» необходимо прежде всего понимание важности процессов номинации как основных для порождения речи в определенном контексте. Референция и оценка связаны в ментальном поле медиатекста. Референция создается не только референцией предметных наименований, но и референцией компонентов с пропозициональным значением, которые соотносятся с

фактами, событиями, ситуациями, вызывающими приятие или неприятие идеологического субъекта.

Например, статья из газеты «Кызыл таң».

«*Өч дронны бәреп төшергәннәр*.

Башкортстаннан алгы сызыкта алышучы Салават Юлаев исемендәге оператив билгеләнештәге икенче батальон сугышчылары дошманның «Баба-Яга» тибындагы өч дронын бәреп төшергән.

Бу турыда батальонның телеграмм-каналы хәбәр итә.

Алар моны даими алып барылучы атышларга һәм дошман һөҗүменә карамастан эшли алган. Сугышчылар дроннарга *Белгород өлкәсендә очарга* һәм кешеләргә *зыян китерүгә* ирек бирмәячәкләрен белдерә.

Автор:Резеда Галикәева».

В данном примере использованы предикаты диктума, выражающие объективную информацию. Это глаголы акционального подкласса с его семантическими разрядами физического действия, перемещения, речевого действия и социальных интерсубъектных действий. Перед обозначенными «фактами» в речь вводится отрицательный смысл (Өч дронны бәреп төшергәннәр), и возникает целенаправленное высказывание, к которому может быть применен критерий идеологической оценки с концептом «неприятие».

Предикаты соответствуют не «вещам», а «отношениям». Предикаты выступают в роли особых семантических сущностей языка, которые типизируются не в форме словарных единиц, глаголов, а в форме пропозициональных функций и соответствующих им схем предложений.

Модализация существует в определенной мере как процесс передачи интенционального состояния. Этот процесс сводится к репрезентации своих убеждений, мотивов, оценок и к стремлению «заразить» ими адресата, т.е. повлиять на состояние собеседника так, чтобы оно соответствовало желаниям говорящего.

Таким образом, к инструментарию модализации, помимо лексических наименований, относится схемная семантика, актанты, характер предикации (агенс, пациенс, производимое действие), – иначе говоря, концептуальное объединение, интерпретация.

Ю.С. Степанов отмечал, что в междисциплинарных исследованиях, связавших в процессе разработки «теории речевых актов» лингвистическую философию и психологию, интенциональность относят к свойству многих ментальных состояний субъекта речи. Один и тот же объект может становиться разными предметами в зависимости от типа сознания: воспринимают этот предмет или судят о нем, ненавидят его или любят и т.п. В этом смысле говорят об «интенциональном существовании

предмета внутри душевного акта» [9; 204]. Отношение сознания к предмету может принимать различные модификации, зависящие уже не от предмета – от состояния сознания.

Следовательно, само значение слова (высказывания) определяется тем, что в «переживании» заключено отношение к предмету [9; 204]. Ю.С. Степанов считает, что восприятие предмета как значения вообще есть один из главных семиотических законов [9; 27]). Такое значение связывается с целью говорящего, так как является результатом его действий. Следует добавить: на уровне дискурс-анализа важен не столько даже фактор значения слова, сколько его иллокутивная сила – эффект значимости, выделенности образованного смысла.

**Список литературы**

1. Арутюнова Н.Д. Язык и мир человека. – М.: Языки русской культуры, 1999.

2. Баранов А.Г. Функционально-прагматическая концепция текста. – Ростов н/Д: Изд-во Ростов. ун-та, 1993.

3. Вежбицкая А. Язык. Культура. Познание: пер. с англ. / отв. ред. М.А. Кронгауз. – М.: Рус. словари, 1996.

4. Гаспаров Б.М. Язык. Память. Образ: лингвистика языкового существования. – М.: Нов. лит. обозр. 1996.

5. Дускаева Л.Р. Интенциональность речевой деятельности журналиста // Вестн. СПбГУ.Сер.

6. Колесов В.В. Русская ментальность в языке и тексте. – СПб.: Петербургское востоковедение, 2006.

7. Оптимизация речевого воздействия / Н.А. Безменова, В.П. Белянин, Н.Н. Богомолова и др.; отв. ред. Р.Г. Котов. – М.: Наука, 1990.

8. Солганик Г.Я. Современная публицистическая картина мира // Публицистика и информация в современном обществе. – М., 2000. – С. 5-17.

9. Степанов Ю.С. В трехмерном пространстве языка: семиотические проблемы лингвистики, философии, искусства / отв. ред. В.П. Нерознак. 2-е изд. – М. : Либроком, 2010.

10. «Өч дронны бәреп төшергәннәр» [Электронный ресурс]: Новости // Кызыл таң. – 2024. – Режим доступа: https://kiziltan.ru/articles/batyrlar-d-vere/2024-10-22/ch-dronny-b-rep-t-sherg-nn-r-3979437. – Дата обращения: 13.11.2024.

© Шайхалиева Г.М., Халиуллина Н.У., 2024

УДК 811.512.145

**Шайхалиева Г.М.,**
*г. Уфа, Россия*
*Научный руководитель – к.ф.н, доцент* ***Н.У. Халиуллина***

# РЕПРЕЗЕНТАЦИЯ ЭМОТИВА «УЛЫБАТЬСЯ» В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ: ИСТОРИЧЕСКИЙ АСПЕКТ

***Аннотация:*** *в данной статье характеризуется эмотив елмаю «улыбаться» в сравнительно-историческом плане. Рассматривается семантическая характеристика данного предиката и репрезентация в современном татарском языке и памятниках древнетюркской письменности.*

***Ключевые слова:*** *сравнительно-историческое языкознание, татарский язык, этимология, эмотивная лексика, предикат, семантика.*

Улыбка – самое универсальное средство невербального общения, способ проявления внимания к собеседнику. Данный феномен является объектом рассмотрения психологов, социологов, литературоведов, лингвистов и специалистов других научных отраслей. По утверждению психологов, «мы улыбаемся не только потому, что чему-то, кому-то рады», а по причине того, что «улыбка помогает нам чувствовать себя счастливее и увереннее». Ссылка

За многие тысячелетия эволюции человек довел искусство улыбки до совершенства. Улыбка – это мимическое движение, в котором могут принимать участие до 53 мышц лица. Если иметҗ в виду, что лицевых мимических мышц вообще насчитывается 57, то понимаем, насколько сложное это движение и как разнообразна бывает улыбка. Кроме того, в этой мимической реакции участвуют глаза – их выражение очень важно для понимания сути улыбки.

Традиционно считается, что она выражает положительные эмоции: радость, удовольствие, счастье. В процессе длительной эволюции улыбка приобрела множество видов и значений и у современного человека выражает довольно противоречивые эмоции. Например, сложно описать в нескольких словах, какие чувства передает грустная, издевательская, злобная или трагическая улыбка. Способность человека передавать с помощью улыбки разнообразные чувства, с трудом поддающиеся описанию, – одна из загадок этой сложной мимической реакции.

В лингвистическом аспекте эмотивный глагол «улыбаться» имеет сложную характеристику. Предикат елмаю «улыбаться» в татарском

языке выражает – радость, удовлетворение, согласие и другие чувства, выражение лица, усмешку.

Как видно из определения, «улыбка» соответствует беззвучному смеху. В этом плане елмаю является гомогенным в семантическом плане с лексемами көлемсерәү, авыз еру: Бар күзләрдә елмаю һәм җылы күрәм – Авылымны хәтеремә ныграк үрәм (С.Гәрәева).

2) Глагол елмаю «улыбаться» употребляется по отношению к небесным телам: луна, солнце, звезда и т.д., яркая, искрящаяся. Көмеш ай елмайган кичләр тупыллар түбәсендә (Г.Афзал).

3) В переносном значении елмаю «улыбаться» означает сверкание, мерцание. Бары тик ак клавишлары гына, ап-ак тешләргә охшап, елмаеп, балкып тора (Р. Вәлиев). [5]

2. Мимика лица, похожая на смех и выражающая чувства, отношения к кому-то или чему-то. Например, Һәр авазга җавап биргәндәй, башын селкеп, «ыһы, ыһы, ыһы» дияргә кереште, саргылт мыегы астыннан, ялтырап, ак тешләре күренде, битенә канәгать елмаю чыкты (Ф. Латыйфи). Кояш елмаюын тойган урам рәхәтләнеп ята» (Ә. Баянов). Елмаюы күңелгә рәхәтлек биреп тора (Н. Хәсәнов).

Как указывает Р.Г. Ахметьянов, елмай-у [йы̆лмай-у] ~ диал. җылмай-у «улыбаться» активно используется только в Волго-Уральском регионе. Диалектальный йылма – «улыбчивый» от имени прилагательного «приветливый». Эта форма, в свою очередь, получила свое развитие от огузского йылма, казахского, каракалпакского җылмаң «весёлый (шат күңелле)» монгольского җилмагай «блестящий (ялтырап торган), гладкий (шома)». Возможно, есть фонетическая и семантическая связь между лексемами җылы «теплый», җылымса «тепленький»). [1; 279]

В других тюркских языках йылмай (нугай), каз., к.-калп., үзб. җылмай, җылмаю, җилмой- употребляются в значении «остыть, слегка расслабляться после злости», а в чувашском языке – йӑл кӳл – «улыбаться» ~ йӑл «блеск (ялт)» Э.В. Севортян основу йылмай рассматривает во взаимосвязи с йылым-ай ~ җылымлану «становиться теплым» [1; 279].

В лексической системе татарского языка представлены несколько видов улыбок, которые имеют положительную коннотацию. Матур елмаю «красивая улыбка»:

Яз матур елмая,
Карашы җылы, назлы.
Таштай каткан боз да
Түзмәде, эреп акты. (Гузель Идрисова «Яз елмаю»).

Серле елмаю «загадочная улыбка»:

Шагыйрь абый серле елмайды да,
Барлап чыкты шигырь киштәсен.
(Лилия Нурлы «Шагыйрь абый»).

Бәхетле елмаю «счастливая улыбка»: Табиб арбада изрәп йоклап яткан сабыйга таба иелде һәм бәхетле елмайды. [2]

Киң елмаю «широкая улыбка»: – Шатландым инде мин... – Илнур чынлап та шат икәнен исбатларга теләгәндәй, киң елмайды (Марат Кәбиров «Тик син генә»).

Сөйкемле елмаю «обаятельная улыбка»: Егетләргә кызлардагы зифа буй– сын һәм матур күзләр генә түгел, ә сөйкемле елмаю да ошый икән. [ТатМедиа: https://chelny– rt.ru/news/kyzlar– kolagyna/teshlr– slamt– bulsyn.]

Мөлаем елмаю «ласковая улыбка»: – Сезнең белән танышырга мөмкинме? – дип мөлаем гына елмайды Алия (Гөлшат Фаткуллина «Гашыйклар көне»).

Чатур елмаю «блестящая улыбка»: Зәрия, гадәтенчә, сүзен көттереп кенә әйтте, тансыкка гына елмайды – чатур иде елмаюы! [Казан утлары, №8, 1985] Нурия Измайлова «Яшьлек шаярулары».

Куанып елмаю «радостная улыбка»: Яхшылыкны Ходай Тәгалә үзе күрә, белә ул! – дип куанып, бәхетле елмайды Әсхәт абый, берни булмагандай (Зөлфәт Хәйруллиның «Әсхәт ага шәфкатьлелекнең чын үрнәге иде»).

Мул елмаю «щедрая улыбка»: Кояш мул елмайды бүген безгә... [4]

Ак тешләрен күрсәтеп елмаю «улыбаться, обнажив белые зубы».: Ул тигез ак тешләрен күрсәтеп елмайды (Таңчулпан Гарипова «Исле гөл»).

На этих примерах положительные эмоции были актуализированы следующими словами: красивая, добрая, загадочная, счастливая, ласковая, блестящая, радостная, щедрая.

Отрицательный спектр эмоций и эмоций тоже очень широк. Подтверждением данного высказывания может служить словосочетание качества с «улыбкой» и отрицательной коннотацией.

Мут елмаю «фальшивая/натянутая улыбка»: Малай оялчан гына елмайды (Роза Хәбибуллина «Җылы оя»).

Моңсу елмаю «мрачная/грустная улыбка»: Әнкәсе моңсу гына елмайды (Әхмәт Дусайлы «Гөлфая»).

Уңайсызланыбрак елмаю «смущенная улыбка»: Ул килеп җитте, минем онытылгандай һаман карап торуымнан, ахрысы, уңайсызланыбрак елмайды, миңа туры карамаска тырышып (Әмирхан Еники «Матурлык»).

Саран елмаю «жадная улыбка»: – Китмисең, – диде хатын, саран гына елмайды. (Нәбирә Гыйматдинова «Пәри утарында»).

Уйчан елмаю «Задумчивая улыбка»: Ул уйчан гына елмайды, бертын дәшмичә торды (Әмирхан Еники «Матурлык»).

Гаепле елмаю «виноватая улыбка»: Үзең күрдең инде, – дип гаепле елмайды Люда. (Марат Кәбиров «Бердәнбер һәм кабатланмас»).

Усал елмаю «злобная улыбка»: Саумысыз!? ... – дип усал гына елмайды хатын (Мөнир Вафин «Ахир. Галлюцинация»).

Кыюсыз елмаю «неловкая улыбка»: Егет бер мәлгә әлеге хәлнең чынлыгына ышанмыйча торды, аннан соң кыюсыз гына елмайды... (Марат Кәбиров «Мин яратам сине...»).

Сүрән генә елмайды «небрежно, слабо улыбнулся»: Әле генә кояштай балкыган малай сүрән генә елмайды, йөзенә өлкәннәргә хас җитдилек кайтты. (Флүс Латыйфи «Аякла каза»).

Ахмакларча елмаю «глупо улыбаться»: – Сәер, әйеме? – дип ахмакларча елмайды Тео. (Зәринә Бикмуллина «Диплом эше»).

Слово «улыбаться» сочетается не только с прилагательными, но и именами существительными, глаголами и наречиями.

Танып елмаю «знакомая улыбка / узнав, улыбнулся»: Ул мине танып елмайды. [7]

Карап елмайды «улыбнулся, посмотрев»: Завод директоры Әлфиягә карап елмайды да.... (Гөлчирә Галимова «Шиңгән чәчәкләр»).

Елмайды сагыш катыш «улыбнулся грустно и тоскливо»: Тормыш сукмагында очрап, елмайды сагыш катыш... (Рифат Җамал «Сагынуларымны белде»).

Болыт елмайды «облако улыбнулась»: Рәхмәт, Ходаем! дип әйтергә җыенганда, болытлар кеше сурәтенә кереп, аңа елмаялар иде (Вәсилә Фәйзетдинова «Аңа болытлар елмайды»).

Яз елмайды «весна улыбнулась»: Яз елмайды елгага,
Елга күңеле тулышты.
(Гузель Идрисова «Яз елмаю»).

Уңыш елмайды «успех улыбнулся»: Иске Балтач авылыннан Рәлиф Рамазанов, Түбән Иванай авылыннан А.Туктамышева, Яңа Балтач авылыннан Фрид Миңнеәхмәтоваларга уңыш елмайды (Рима Валиева «Гәзиткә язылып бүләк оттылар»).

Кояш елмайды «солнце улыбнулось»: ...кояш елмайды.... [http://aznakaevo–rt.ru/photo/tymytykta–chagyda–ilderdelr–muncha–kerdelr]

Бәхет елмайды «улыбнулась удача»: [6]

Улыбка разнообразна и важна в процессе общения. Улыбка показывает, что она описывает не только положительные, но и негативные эмоции.

Авыз еру «смеяться, улыбаться». «Җырлагыз, кызлар, җырлагыз, Муеныгызда – сыргагыз; Яшь чагында җырлап калыйк, Үскәч авыз ермабыз» (Җыр).

Авыз ерып карау «двусмысленное отношение, непонимание серьезности вопроса». «Сезнең фидакярлеккә авыз ерыбрак карарга өйрәндекме?» (Т.Миңнуллин).

Авыз эченнән көлү «беззвучно смеяться, улыбаться». «Солдат авыз эченнән генә көлеп куйды» (Г.Бәширов).

В древнетюркском языке лексема елмай-у не представлена, понятия «смеяться» и «улыбаться» выражаются лексической единицей kül, что соответствует татарскому көл-ү.

В памятниках древнетюркской письменности kül употребляется в значении «смеяться”: külsä kök tägri külä turur «если она смеется, голубое небо смеется» [3].

В «Древнетюркском словаре” данная лексема представлена в примерах из уйгурского памятника «Алтын ярук»: külčirmäk qil – «улыбаться»: külčirmäk qilu jarliqap «соблаговолив улыбнуться», в словаре Махмуда Кашгари «Диване лугат-ит турк»: er küldi «мужчина засмеялся» [3].

От корневого слова kül образованы следующие формы: kulčirmäk, küldür, kulgusüz, külsir «посмеиваться», külmä, külsä, kulgu «смех», kültür «смешить», külün, külünc «объект смеха, насмешки, забавный, смешной», külüs, külüt, kün jaru «светится».

Küldür – побуд. от kül-: dušmanlarni jilɣlayurdumni dosṭlarumni külgürdüm «я заставлял плакать моих врагов и давал повод смеяться моим друзьям».

Kulgusüz «без смеха»: tiyla sözüm külgüsüz «слушай мои слова без смеха».

Külsir «посмеиваться»: er külsirdi «мужчина посмеивался».

Bu körgän esitgän senä külmä- sün «видевший и слышавший это пусть не смеется над тобой».

Külsä kök tägri külä turur «если она смеется, голубое небо смеется».

Лексему kül можно встретить в составе фразелогизмов: külcir: ažun külčirär «мир улыбается»; bu savaɣ, [esit]ip külčirä jüzin Zormuzta tänri... inča tep tedi «услышав эти слова, бог Индра, улыбаясь... сказал так». kül-qatɣur «смеяться, заливаться смехом»: ünün atti keklik külä qatɣura «куропатка кричала, [словно] заливалась смехом»; kün jaru «перен, светиться, улыбаться (о счастье)»: bobun inčkä tegdi jarudi küni «народ достиг покоя, ему улыбнулось счастье (букв, засветило его солнце)».

Таким образом, эмотив елмаю «улыбаться» имеет сложную фонетическую и семантическую характеристику и является объектом системного, концептуального, психолингвистического анализа.

**Литература**

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: [Этимологический словарь татарского языка]: Ике томда / Р.Г. Әхмәтьянов. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 1 т. (А–Л). – 2015. – 543 б.; 2 т. (М-Я). – 2015. – 567 б.

2. «Безгә аерылышырга кирәк...» [Электронный ресурс]: Новости // ИнтерТат. – 2013. – Режим доступа: https://intertat.tatar/news/bezga–aerylysyrga– kirak– 5858684. – Дата обращения: 13.11.2023.

3. Древнетюркский словарь [Электронный ресурс]: Ленинград – Наука – 1969. – Режим доступа: https://archive.org/details/dtslovar/page/n363/mode/2up?view=theater. – Дата обращения: 20.11.2023.

4. Кояш мул елмайды бүген безгә... [Электронный ресурс]: Стихи // Вконтакте. – 2023. – Режим доступа: https://vk.com/wall–45765060_36392. – Дата обращения: 13.11.2023.

5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: т.1-6 (А-Я). – Казан: ТӘhСИ, 2015-2021.

6. Тәмле шоколадтан ясалган букет иясенә барып иреште [Электронный ресурс]: Новости // ТатМедиа Шәһри Чаллы. – 2022. – Режим доступа: https://shahrichalli.ru/news/kich– bgen– irtg/tmle–shokoladtan– yasalgan– buket– iyasen– baryp– ireshte– video. – Дата обращения: 13.11.2023.

7. «Ул мине танып елмайды” – урманда югалган өч яшьлек кызны тәүлек буе эзләгәннәр [Электронный ресурс]: Новости // ИнтерТат. – 2017. – Режим доступа: https://intertat.tatar/news/ul– mine– tanyp– elmaydy–urmanda– yugalgan– ch– yashlek– kyzny– t– lek– bue– ezl– g– nn– r–4844258. – Дата обращения: 13.11.2023.

© Шайхалиева Г.М., Халиуллина Н.У., 2024

УДК 811.512.145

**Шарафутдинова Л.Б., Гайнуллина Г.У.,**
*Уфа ш., Россия*

# ИЛСӨЯР ИКСАНОВА ШИГЪРИЯТЕНДӘ СИНТАКСИК ФИГУРАЛАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

***Аннотация:*** *мәкаләдә И.Иксанова шигъриятенең синтаксик*

*үзенчәлекләре, шулай ук шигырьләрдәге синтаксик фигураларның стилистик функциясе тикшерелә.*

***Терәк сүзләр:*** *стилистика, синтаксис, синтаксик фигуралар, җөмлә сүзләр тәртибе, поэтика.*

Лингвистик стилистикасының максаты төрле яклы: ул билгеле бер телдә нинди сөйләм стильләре һәм чаралары булуын, аларның бер-берсенә бәйле һәм бер-берсеннән аерып тора торган үзенчәлекләрен, сөйләм төрен һәм стильне барлыкка китерүдә телнең лексик, грамматик һәм фонетик чаралары ни рәвешле кулланыла икәнен ачыклау; телнең үзенең билгеле бер мәгънә яки тойгы белдерүдә, кешенең аңына, уй-кичерешләренә тәэсир итүдәге көч-куәте һәм мөмкинлекләре нинди-моны өйрәнү шулай ук лингвистик стилистика эше.

Татар тел белемендә бүгенге көндә стилистика аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе булып кала. Татар язучылары һәм шагыйрьләренең телен өйрәнүгә багышланган хезмәтләр булуга карамастан, поэтик синтаксиска багышланган мәкаләләр, монографиялар юк диярлек. Шул ук вакытта Татарстанда туып иҗат итүче талантлы шагыйрә Илсөяр Иксанова теленең синтаксик үзенчәлекләре моңа кадәр галимнәр тарафыннан тикшерелмәде.

Мәкаләбездә И. Иксанованың 1999 елда басылып чыккан «Кышкы канәферләр», 2008 елда басылган «Кырык кыл» шигырьләр җыентыкларының синтаксик үзенчәлекләрен барларга омтылдык. Аның әсәрләрендә без гади, кушма җөмләләрнең нинди стилистик функция үтәүләрен тикшерү белән бергә, әсәрләрдә сүз тәртибен карадык һәм шагыйрь кулланган синтаксик фигураларның стилистик кулланылышын билгеләдек.

Шигъриятtә сүзләрнең кире тәртибе күп очракта рифма, ритм барлыкка китерү өчен кулланылса, кайбер вакытта Илсөяр Иксанова нинди дә булса сүзгә игътибарны арттырыр өчен аны юл башына куя.

Сорау җөмләгә һәр вакыт сорау интонациясе хас. Сорау интонациясе җөмләдә сорау кушымчалары, сорау сүзләре булганда да бик ачык сиземләнә. Ә сорау кушымчалары һәм сорау сүзләре булмаганда, сорау интонациясе сорау җөмләне формалаштыручы бердәнбер булып кала. Илсөяр Иксанова шигъриятендә бирелгән сорауларның күбесенә җавап табып булмый, чөнки лирик герой бу сорауларны язмышына төбәп бирә, Аллаһы Тәгаләдән җавап көтә. Тойгылы җөмләләрдә лирик геройның хис-кичерешләре тагын да кискенрәк, ачыграк билгеләнә.

Илсөяр Иксанова иҗатында бер составлы җөмләләр аерым урын алып торалар. Күбесенчә билгеле үтәүчеле фигыль җөмләләрдә баш кисәк I затның уй-кичерешләрен, эш башкаруын күрсәтеп тора, чөнки үзәктә –

лирик герой, һәм ул үзе турында сөйли, фикерләре белән бүлешә һәм хистойгыларын белдерә, шуңа күрә билгеле үтәүчеле фигыль җөмләләр билгесез үтәүчелегә караганда Илсөяр Иксанова шигъриятендә күбрәк очрый.

Билгесез үтәүчеле җөмләләрдә субъектның кем икәнлеге мөһим түгел, чөнки ул – типик образ, беренче чиратта – шагыйрь өчен аның исеме кирәк түгел, шагыйрьне аның эше, хис-кичереше, уй-фикерләре, һәм бигрәк тә аның лирик геройга булган мөнәсәбәте кызыксындыра.

Рәссамнан аермалы буларак, шагыйрь сүз белән сүрәт ясый. Һәм күз алдына теге яки бу ситуацияне китереп бастырыр өчен шагыйрь бик уңышлы атау җөмләләрне куллана.

Сүз җөмләләр башка бер составлы җөмләләрдән аермалы буларак, ким җөмләләргә якын торалар. Кайбер вакытта аларны бары тик контексттан гына аңлап була, шуңа күрә алар диалогларда гына кулланылалар, бу төр җөмләләр Илсөяр Иксанованың без тикшергән җыентыкларында бары тик тугыз тапкыр гына күзәтелде.

Илсөяр Иксанова шигъриятендә тезмә кушма, каршы куючы теркәгечле тезмә кушма, күп тезмәле катнаш кушма, күп иярченле катнаш кушма җөмләләрне бик уңышлы куллана.

Илсөяр Иксанованың без тикшергән җыентыкларында 14 төр иярчен җөмләләрнең бары 8 төре генә күзәтелде. Иярчен шарт, вакыт җөмләләрне бик еш һәм уңышлы кулланыла.

Илсөяр Иксанова шигырьләрендә гади җәенке, эмоциональ яктан бай җөмләләр күбрәк очрый, әмма катлаулы кушма җөмләләрне дә ул бик уңышлы куллана.

Бер үк юлны шигырьдә берничә тапкыр кабатлау ярдәмендә, Илсөяр Иксанова үзенең фикеренең дөреслегенә шик-шөбһәсез каравын һәм укучыга да шушы уйның ничек кенә парадоксаль яңгыраса да, төптән уйлаганда, хакыйкатькә туры килгәнлеген күрсәтә:

***Озаклады, озаклады*** *йолдыз,*
*Офыкларда тагын алсу таң.*
***Ак кар ява****,*
*Ап-**ак** сагыш **ява**.*
*Йөрәгемә кунып **кар ява**.*
*Тәүге хисләр хатирәсе төсле*
***Беренче кар ява, беренче...***

Илсөяр Иксановада кайбер вакытта беренче строфа шигырь азагында тагын бер тапкыр кабатлана. Шушы алым белән шагыйрь үзенең әсәрен бербөтен буларак формалаштыра.

Илсөяр Иксанова антитеза күренешен иң оста файдаланган шагыйрьләрнең берсе дип әйтсәк ялган булмас:

***Бәхетем, бәхетсезлегем,***
***Шатлыгым, сагышым*** *син.*
***Ай*** *күреп* ***кояш*** *алганда*
***Югалткан табышым*** *син.*
*Бүген бәйрәм.*
*Халкым* ***көлә-көлә,***
***Елый-елый бәйрәм иткәндә...***

Ул күп очракта яшерен антитеза күренешен куллана. Бу очракта антонимнар түгел, ә шагыйрь тудырган сүрәтләр бер-берсенә каршы куела.

Телдә бер-берсенең капма-каршысы булып торган шатлык һәм хәсрәт, уң һәм сул сүзләре бу шигырьдә көчле сурәтләү чарасы булып кулланыла. Илсөяр Иксанова иҗатында яшьлек һәм картлык сүзләре белән ясалган антитезалар аеруча күбрәк булуы күзгә ташлана.

Илсөяр Иксанова үзенең шигырьләрендә сүзләрне, фразаларны кабатлау белән укучының игътибарын җәлеп итә, шул ук вакытта бу шагыйрь хис-тойгыларның градациясен, үсүен күрсәтү өчен дә куллана. Шагыйрә шигырьләрендә искиткеч матур, халыкчан образ тудыра.

*Мин – җәйләрдә,*
*Сагышларны әле*
*Оныттырыр дигән җәйләрдә.*
*Сагышланмам дигән җәйләремдә*
*Төшкә керми торсаң,*
*Төшкә керми торсаң ни була?!*

Авторның иҗат җимешенең һәр юлын сагыш биләп алган. Ул шул күңел сарылыгын әзгә булса да онып торырга дип табигать кочагына юнәлә. Урманнарнарны урый, җиләк әзли, печән җыя, су керә, ләкин сагыш басылмый. Җитешкән уңыш – басу киңлекләрен саргайган төсен күреп, үзенең сагышын моңарда гәепле саный. Тынгы табалмый лирик герой. Сагышы аны җәйге төннәрне төшләренә кереп йөдәтә.

*Кырык кыллы язмыш,*
*Чиртә күрмә ялгыш.*
*Бер кылында – шатлык,*
*Бер кылында – сагыш.*

Автор күңеленең кырык кылын тартып туган бу шигырьләрен, укучысының да күңел кылларына кагыла алса иде дигән ният белән иҗат иткән төсле.

Шагыйрьләр төрле була. Ә шагыйрьлек, минемчә, Ходай тарафыннан бирелгән бер миссия, олуг вазифа ул. Шигырь – ул күңел халәтене, күңел ихтыяҗы. Ул тула тора, борчып тора, бәби көткән шикелле җитлегә бара. Тула, тула да туа. Син аны ни өчен һәм нилектән

шушы вакытта язганыңны белмисең дә, аңлата да алмыйсың. Шагыйрь ул күрәзәчедәй алдан күрә төсле. Ирем белән яшәгән чакта, аны югалтудан куркып язылган шигырьләрем бик хисап.

*Тагын бер кат гомер бирсә Ходай,*
*Сиңа бирсә гомер тагын берне, –*
*Кай ярларга язмыш ташласа да,*
*Эзләр идем сине, бары сине!*
*Тагын бер кат гомер бирсә Ходай,*
*Тагын бер кат бу дөньяга килсәк,*
*Киек казлар,*
*Безгә юл сабыгыз,*
*Табышалмый адашыплар йөрсәк.*

«Ялгыз калудан куркып язылган иҗат җимешләрем алар. Ул бит аек акыл белән язылмый... Соңыннан гына уйлыйсың... Шагыйрьлелек шул Ходай хикмәте инде ул.

Кызым Алсу янында улым Наил дә бар иде, ләкин ул гомерсез булды.  Хатын-кыз өчен иң зур бәхет бала табу булса, иң зур фаҗигә – баласын югалту.

***Ап-ак ташың,***
***Ап-ак кабер ташың.***
*Яшәлмичә калган гомеркәең,*
*Синең белән минем җанымның да*
*Бер кисәге китте, бәгырькәем...*

Сүземне тәмамлап, берне генә ассызыклыйм, бар иҗатым, тормыш юлдашым Илдарның, улым Наилнең  яшәлмәгән гомерләрен шигырьләремә ялгап озайту», – дип яза Илсөяр Вазыйх кызы. Аның моңа хакы бар. Кәтелмәгән бәхет-шатлыклар көтсен аны алдагы тормышында.

**Әдәбият**


1 . Иксанова И. Кышкы канәферләр: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 95 б.

2 . Иксанова И. Кырык кыл: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 239 б.

3 . Курбатов Х.Р. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан; Мәгариф, 2002. – 199 б.

4 . Поварисов С.Ш. Сүз һәм сәнгатьле сөйләм. – Уфа: Китап, 1997. – 166 б.


© Шарафутдинова Л.Б., Гайнуллина Г.У., 2024

УДК 94

**Шарипов А.А.,**
*г. Брно, Чехия*

# ОБЩЕСТВЕННО-ИСТОРИЧЕСКИЕ ПРОЦЕССЫ НА БАЛКАНСКОМ ПОЛУОСТРОВЕ С НАЧАЛА XIX ВЕКА ДО 1918 ГОДА

***Аннотация:*** *в данной статье анализируются межнациональные и межгосударственные взаимотношения народов и стран Балканского полуострова, развитие Боснии и Гереговины и Черногории в период с начала XIX века до 1918 года.*

***Ключевые слова:*** *этногенез, договор, мир, Балканский полуостров.*

После сербских восстаний в 1804 и 1815 годах Сербия присоединила Новопазарский и Зворницкий санджаки, ранее входившие в состав Боснийского пашалыка. Административным центром пашалыка был Травник до 1850 года, затем – Сараево. По турецкой переписи населения 1851-1852 годов в Пашалыке проживало 1 077 956 человек, в основном сербы и хорваты; 44,9% из них были православными, 37,3% мусульмане и 16,5% католики. В ходе турецких реформ в 1820 и 1830 годах боснийско-герцеговинские феодалы потеряли свои источники дохода, что привело к увеличению трудовых и естественных обязанностей крестьян. Леса, принадлежавшие ранее феодалам, были признаны государственной собственностью с правом свободного пользования. В страну начал поступать иностранный капитал в 1820-1840 годах. В 1860 году была построена железная дорога из Баня Луки в австрийский город Нови, телеграфная линия между Сараево и Баня Лукой.

**Беспокойства и австро-венгерская оккупация.** Феодалы страны встали против реформ, проводимых Турцией. В 1821 году вспыхнуло восстание в Сребренице, Мостаре и других городах Боснии, что привело к казни 300 феодальных мятежников. В 1826 году султан Махмуд II использовал восстание военных джанничаров в Стамбуле для распущения их подразделений. Через год после этого он приказал расформировать янычарские полки в Боснии. Ответом стало возмущение и фактическое игнорирование решений турецкого правительства. Новым ударом стало распоряжение султана 1829 года о возврате заново заселенных районов в Подринье сербам, как требовалось Турцией по Дринопольскому миру после поражения в войне с Россией. В последующие годы неповиновение продолжалось: во время восстания 1831 года под предводительством

Хусейна Градашчевича боснийская армия разбила турок на Косовом поле. Чтобы ослабить боснийскую оппозицию, турецкое правительство отделило Герцеговину от Босни в 1833 году. Власть Турции укрепилась только к 1851 году. В первой половине XIX века в стране сформировалось национально-освободительное движение, возникшее среди католического духовенства. Результатом стало восстание в Боснии и Герцеговине в 1875-1878 годах. В 1878 году на основании Сан-Стефанского мирного договора Босния и Герцеговина получили автономию. Однако в соответствии с Берлинским соглашением того же года Австро-Венгерская империя между июлем и октябрем 1878 года оккупировала Боснию и Герцеговину.

**Австро-Венгрия.** После австро-венгерской оккупации Боснии и Герцеговины, оставшейся законно под властью Османской империи, в страну стали поступать иностранные инвестиции, заинтересованные в дешевой рабочей силе и сырье. Государство и Габсбурги владели железными дорогами, лесопильными заводами, угольными шахтами, табачной и текстильной промышленностью. Промышленные товары массово импортировались из Австро-Венгрии. Следуя военно-стратегическим и экономическим целям, государство быстро строило железные дороги и шоссе. Произошло увеличение товарооборота и 262 городского населения, а феодальная структура сохранялась в сельских районах. Крестьянские беспорядки начались в Герцеговине с 1878 года; крупное восстание произошло в 1882 году. В 1880 году австро-венгерские власти получили право назначать митрополита и выплачивать ему зарплату от Константинопольского патриархата, который подчинялся Боснии и Герцеговине. В 1881 году была основана высшая организация боснийских и герцеговинских мусульман, Улема Меджлису, члены которой назначались государством. Активности католической церкви, которой правительство предоставляло привилегии, достигли точки подстрекательства к национально-религиозной ненависти к сербам и мусульманам.

Аннексия Боснии и Герцеговины Австро-Венгрией была провозглашена 7 октября 1908 года. Часть общества Боснии и Герцеговины надеялась на освобождение страны от власти Австро-Венгрии и создание государства под руководством Сербии. В 1913-1914 годах возникла сербская националистическая организация «Млада Босна». Среди ее участников был Гаврило Принцип, который 28 июня 1914 года в Сараево совершил убийство Франца Фердинанда и его жены Софии, что привело к началу Первой мировой войны. 29 октября 1918 года, во время распада Австро-Венгрии, хорватский съезд в Загребе провозгласил государство Словенцев, Хорватов и Сербов, чьи власти

немедленно объявили об окончании участия в войне. 1 декабря того же года это государство объединилось с Королевством Сербии и Черногории в Королевство Сербов, Хорватов и Словенцев.

**Развитие Черногории с начала 19 века до 1918 года.**

**Пётр I и борьба за прибрежную территорию (1800-1830).** Черногорцы пытались захватить Которский залив после падения Венецианской республики, но затем залив перешел под контроль Австрии по мирному договору в Кампо-Формио. После битвы при Славкове (1805) Австрия должна была передать Которский залив Франции, но Россия была решительно настроена помешать этому и решила открыть новый фронт русско-французской войны в южной части Адриатического моря. Французское управление над Котором и Далмацией принесло значительный прогресс, особенно в области инфраструктуры. Французы предложили построить качественную дорогу из Котора в Цетине за свой счет и открыть консульство. Однако владыка отклонил эти предложения, опасаясь, что дорогу может использовать враг для потенциального вторжения. Холодное соседство завершилось в 1813 году, когда французская армия, столкнувшись с поражениями Наполеоновой армии, была вынуждена отступить. Черногорцы под руководством владыки на собрании в Доброте объединили обе области и также согласились на создание общего правления. В середине 1814 года черногорцы были вынуждены покинуть прибрежные земли.

В 1830 году скончался владыка Пётр I. С уменьшением помощи со стороны России после окончания наполеоновских войн в стране периодически возникал голод, и ее лидеры серьезно рассматривали массовое выселение черногорцев в Россию. Вклад в развитие черногорского государства со стороны владыки Петра I был очевидным. Он был искусным политиком и успешным военачальником и владел несколькими языками. Четыре года после его смерти он был провозглашен святым.

**Пётр II Негош.** Последователем Петра I был владыка Петр II Петрович Негош (1830–1851). 17 ноября 1830 года собрание лишило Вуко Радонича звания губернатора, после чего он был изгнан из Черногории. В 1831 году в страну вернулись Матей Вучичевич и Иван Вукотич, привезшие деньги из России и принимавшие участие в устранении должности губернатора. Вместо правления суда в 1831 году был учрежден правительственный сенат. Также была создана гвардия, наделенная полицейскими полномочиями и функцией защиты государственной границы. В результате трансформаций, проведенных в первой половине XIX века, черногорские митрополиты превратились в автократических правителей.

В 1833 году была основана первая начальная школа в Черногории, а в 1834 году – типография. В 1833 году Пётр II посетил Петербург, где получил титул владыки. Россия продолжала выплачивать ежегодные субсидии Черногории, сумма которых была увеличена в девять раз после второго визита Петра II в Россию в 1837 году.

**Вторая половина XIX века.** В 1850 году турецкое правительство считало Черногорию частью Османской империи. В 1852 году Данило провозгласил себя князем и также объявил себя «воеводой Сербии». Государство начало поддерживать сербов из Герцеговины в борьбе за освобождение от турок. Турция враждебно восприняла объявление новой формы правления в Черногории. В декабре 1852 года турецкая армия напала на внутренность Черногории. Дипломатическое вмешательство Австрии и России привело к концу войны. В 1855 году был принят новый набор законов, установивший равенство граждан перед законом. 1 мая 1858 года состоялась битва на Граховце между черногорцами и турками. После отправки русских и французских кораблей к берегам Адриатики, Турция заключила мир и передала некоторые другие территории Черногории. После этой битвы, с участием Франции и России, в апреле 1859 года была установлена граница между Черногорией и Турцией. Некоторые албанские и герцеговинские земли, включая Никшичскую жупу, перешли в Черногорию. В 1861 году в стране начался жестокий голод.

В 1862 году Черногория поддерживала восстание сербов из Герцеговины, после чего турки атаковали Черногорию. Черногория была спасена от полного поражения дипломатическим вмешательством Франции и России. В результате мирного соглашения были разрушены укрепления, и османские войска были размещены на территории Черногории. После убийства Данило новым князем стал Никола, который верил, что его династия должна осуществить миссию объединения сербских земель. В новой войне с турками в 1862 году Черногория была разбита. В соответствии с сербско-черногорским соглашением от 23 сентября 1866 года князь Никола, во имя объединения Сербии и Черногории, согласился отречься от власти в пользу династии Обреновичей. После убийства сербского князя Михаила в 1868 году союз между государствами распался. В 1871 году для борьбы за освобождение и объединение сербов в Цетине были созданы «Дружины», члены которых начали готовить восстание в южнославянских странах, включая Боснию и Герцеговину, а также восстание сербов внутри них.

В июне 1876 года вместе с Сербией Черногория объявила войну Турции. 16 июля в Герцеговине в битве черногорско-герцеговинские силы победили турецкие силы. 2 августа на албанском фронте 5 000

черногорских войск одолели 40 000 турецкую армию в битве при Фундине. Сан-Стефанско-Берлинский мирный договор (1878 год) провозгласил независимость Черногории. Решением Берлинского конгресса (1878 год) территория Черногории увеличилась с 4405 км² до 7 тысяч км². Черногория получила города Подгорица, Колашин, Никшич, Забляк, Улцинь и Бар с морским побережьем длиной 70 км. Черногорцы поселились в городах Колашин и Никшич, откуда было выселено турецкое население. В конце 1870-х годов начались первые спонтанные демонстрации рабочих. В 1879 году Сенат был заменен Государственным советом и Верховным судом. Территория страны была разделена на десять нахий. В 1880 году было создано тайное оппозиционное политическое общество, стремившееся изменить правительство и принять конституцию. Власти начали преследовать оппозицию, многих из которых вынудили эмигрировать. Данило Шчепчевич Негош основал наследственную церковную и политическую власть династии Петровичей (Негошей), передаваемую от дяди к племяннику. Под его руководством был принят первый писаный закон Черногории – Стега.

**Начало XX века.** Под влиянием России были проведены реформы, сделавшие страну современным государством. В 1901 году был принят закон о государственном бюджете. В 1902 году Никола I Петрович официально объявил начало государственных реформ. Была введена новая административно-территориальная система, заменяющая клановое деление страны: территория была разделена на регионы и округа. В 1905 году была принята конституция, скопированная с сербской конституции 1869 года. Вся власть оставалась в руках князя. Парламент был консультативным органом власти. В 1906 году в Подгорице была построена табачная фабрика итальянской компанией. В 1906 году началось чеканка черногорской монеты – перперу, эквивалентной австрийской короне. С 1901 по 1912 год появилось пять банков. Крупнейшие финансовые операции проходили через Черногорский банк и Народный банк Черногорского княжества. В 1909 году была открыта узкоколейная железная дорога Бар-Вирпазар. Черногория стала зависимой от столицы Италии и Австро-Венгрии. Значительным доходом для бюджета страны были годовые субсидии, выделяемые российским правительством.

После парламентских выборов в октябре 1907 года Сербия прервала дипломатические отношения с Черногорией. Во время боснийского кризиса отношения между обеими странами были восстановлены. В начале XX века Черногория была небольшим сельскохозяйственным государством, где в 1909 году проживало около 222 тысяч человек, из которых только 15,57% жило в городах. Сельское

хозяйство было примитивным, неурожаи и голод были частыми. В 1909 году был раскрыт заговор, участники которого стремились свергнуть князя Николу. В этом же году под руководством русского инженера Болотова были осушены болота у Скадарского озера. Скоро был обнаружен еще один заговор, участники которого планировали свергнуть Николу и посадить на трон его старшего сына Данила, освободив политических заключенных.


**Список литературы**

1. Ladislav Hladký. Bosna a Hercegovina. – Historie nešťastné země, 1. vyd., Brno, nakladatelství Doplněk, 1996, 216 s.
2. František Šístek. Černá Hora. Libri, 2007. 126 s.
3. Чиркович Сима. История сербов. – М.: Весь мир, 2009. – 448 с.
4. Королюк В.Д. Формирование раннефеодальных славянских народностей. – Москва: Наука, 1981. – С. 289.


© Шарипов А.А., 2024

УДК 821.512.145

**Шарипов М.С.,**
*Уфа ш., Россия*

## ДӘРДЕМӘНД ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮДӘ ЯҢА АЛЫМНАР

***Аннотация:*** *мәкаләдә автор Дәрдемәнднең иҗади мирасын өйрәнүне анализлау ысулларының традицион, идея-тематик планыннан читләшергә киңәш итә, әдәбият белеме герменевтикасының комплексы методын тәкъдим итә.*

*Мәкалә авторы Дәрдемәнд әсәрләрен өйрәнү өчен түбәндәге парадигманы тәкъдим итә: 1. тирәнтен уку һәм образлы кабул итү; 2. билгеләрне, метафораларны, яшерен кодларны беренчел системалы анализ-расшифровкалау; 3. образлар синтезы нигезендә интерпретация; 4. авторның дөнья моделен торгызу.*

***Терәк сүзләр:*** *поэзия, Дәрдемәнд, герменевтика, анализ, метод, символ, код, парадигма, биография.*

XXI гасыр башы татар әдәбият белеме милли әдәбиятның «алтын чорын» өйрәнүнең теоретик һәм тарихи-мәдәни мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Галимнәр язучыларның иҗатын өйрәнү принципларын үзгәртергә, бүгенге көн позициясеннән әсәрләрне аңлатырга, сәнгать текстларын заманча һәм традицион анализ ысуллары белән тикшерергә,

XX гасыр башындагы иҗтимагый-фәлсәфи фикер нәтиҗәсе булган әсәрләрне ачыкларга омтылалар. Тирән һәм системалы карашны таләп итә торган өйрәнү объектларының берсе – шагыйрь Дәрдемәнд иҗат мирасы.

Татар әдәбияты классигы, меценат, миллионер-алтынчы, нашир, җәмәгать эшлеклесе, I Дәүләт Думасы депутаты (1906) Дәрдемәнднең (Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев) әдәби мирасы – татар әдәбиятының гына түгел, ә XX гасыр башындагы бөтен төрки дөньясының уникаль күренеше ул. Әлеге көндә дә аның тормышы һәм иҗаты тирән серләр белән капланган. Һәм ул заман укучысын үзенә тарта. Бөек шагыйрьнең афористик, фәлсәфи әсәрләрен шәрехләү бүген аеруча актуаль мәсьәлә булып тора.

2022 елда 16 сентябрендә Уфа шәһәренең «Нур» татар дәүләт театры бинасында Дәрдемәнд тормышына һәм иҗатына багышланган «Аһ, туган каумем газиз» әдәби-музыкаль кичәсе, «Милләтнең даһи улы» музей экспозициясе оештырылуы киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты. Дәрдменд иҗатына багышланган чарада чыгыш ясаганда, танылган язучы Фәүзия Бәйрәмова Дәрдемәнд шигъриятенең өйрәнелмәвенең сәбәбен кискен чагылдырып аңлатты: «Дәрдемәнд шигырьләрен аңлатырга безнең әдәбиятчыларыбызның, кызганычка каршы, тешләре үтми!». Чыннан да, Дәрдемәнд хакындагы фәнни хезмәтләрнең аз булуы XX гасыр дәвамында галимнәр бөек шагыйрьнең иҗатын өйрәнүгә бик теләп кермәгән дигән фикер тудыра. Әлбәттә, монда XX гасырның 20-50 нче елларын исәпкә алырга кирәк, буржуаз шагыйрь буларак игълан ителгән Дәредмәнд тыелган язучылар исемлегендә иде, һәм бу елларда аның иҗатына тикшерүчеләрнең берсе дә мөрәҗәгать итмәде, итсәләр дә, шагыйрь бары тик сыйнфый позициядән торып бәяләнде. 50-нче еллар ахырыннан барлык чикләүләр бетерелгән кебек иде, дистә еллар эчендә барлыкка килгән бушлыкны тутырырга вакыт иде кебек. Ләкин, әйтергә кирәк, бу юнәлештә тикшерену эше әкрен хәрәкәтләнде.

Бер яктан, Дәрдмәнд мирасы зур түгел: мең шигъри юл, балалар өчен сигез хикәя, берничә хатирәл-хикәяләр, «Бала» новелласы. Ләкин, икенче яктан, аның һәр шигыре диярлек – «каты төш», шигъри табышмак. Афористлык, яшерен фәлсәфи мәгънә «Кораб», «Бүзләрем маналмадым», «Хәят» һ.б. шигырьләр нигезендә ята.

Сәнгать фәнендә «creativchacking» (иҗади кодларны сүтү) төшенчәсе бар. Хәзерге әдәбият турындагы фәндә текстның тулы эчтәлеген ачуга, комплекслы, системалы анализга нигезләнгән әдәби әсәрләрне өйрәнүгә яңа алымнар актив кулланыла. Илебез һәм чит ил әдәбият белемендә барлыкка килгән әдәбиятны өйрәнүнең классик

ысулларына нигезләнеп, әсәрне, аның эчке структурасын объектив анализларга омтылып, хәзерге әдәбият турындагы фән структур, мәдәни-тарихи, чагыштырма-тарихи, чагыштырма, чагыштырма, семиотик анализ, концепт анализы кебек методларны актив куллана.

XX гасыр ахырында барлыкка килгән, хәзер әйдәп баручы алымнарның берсе – когнитология. Ул филологиядә комплекслы анализ белән шөгыльләнә. Бу яңа юнәлеш тулаем текстны һәм, аерым алганда, образ-детальләрне тикшерүгә хезмәт итә. Г. Тукай энциклопедиясен төзү әдәбиятны комплекслы өйрәнүнең бер ачык мисалы булып тора. Бу юнәлештә беренче тәҗрибә 2012 елда Казанда З.Рәмиев җитәкчелегендә чыгарылган Г. Тукай әсәрләре белешмәлек–сүзлек чыгарылышы булды, анда һәр әсәр монографик планда анализлана. 2016 елда чыккан «Тукай энциклопелиясе» комлекслы анализ ысулының югары үрнәге булып тора. Шагыйрьнең иҗатын өстән-өстән генә түгел, ә җентекләп тикшерү нәтиҗәсендә, мәсәлән, XX гасыр башында шактый билгеле, чорның атаклы шигаре ролен үтәгән «Сөй гомерне, сөй халыкны» шигыренең авторлыгы төгәлләнә.

Дәрдмәнд шигриятен комплекслы өйрәнү өчен, тикшерүчегә Урта Азиядә яшәүче төрки халыкларының мәдәнияте, гарәп, төрек, фарсы телләре белән хәбәрдар, Көнчыгыш һәм Көнбатышның мифологиясен, әдәбиятын, тарихын һәм фәлсәфәсен белергә кирәк. Шагыйрьнең биографиясен дә тирәнтен белү зарур, чөнки «чынбарлык – автор – әсәр» чылбырында Дәрдемәнд шәхесе аның иҗатын аңлау өчен мөһим шарт булып тора. Ирендек таулары арасында үткәрелгән балачак, мәдрәсәдә уку, Төркиягә сәфәре, Оренбургта яшәү, алтын табу, меценат, җәмәгать эшлеклесе, нәшер итүче булу, милләт турында кайгыртуы белән бәйле эшчәнлеге – болар барысы да аның шигъриятендә эз калдыра. Дәрдмәнд һәм аның абыйсы Шакир Рәмиев тарафыннан бастырылган «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы укучыларда милли үзаң, эстетик зәвык формалаштыруга бәяләп бетергесез өлеш керттеләр, профессиональ әдәби тәнкыйтьнең барлыкка килүенә ярдәм иттеләр, басма битләрендә мөхәррирләр яңа татар әдәбиятына туры кыйбла күрсәттеләр.

Дәрдемәнд иҗатын шәрехләүгә алынган кешегә шуны да онытмаска кирәк: Шагыйрь үз заманының югары белемле кешесе, бай китапханәгә ия кеше булган. Шагыйрьнең замандашлары язганча, ул Көнчыгышның күренекле шәхесләренең, шулай ук Көнбатыш һәм Русия вәкилләренең әсәләрен укыган булган. Мондый көчле рухи мирас аның иҗтына этәргеч бирә.

«Гуманитар фәннәр методологиясенә карата» хезмәтендә М.М. Бахтин билгеләп үткәнчә, «...текст бары тик башка текст (контекст) белән бәйләнештә генә яши. Текстларның бу контакт ноктасында гына

диалогка якынлаша торган яктылык барлыкка килә» [1; 78]. Билгеле, мәдәни диалог-сөйләшү өчен әдәби күперләр кирәк. Шул максатны аңлап, XIX гасырның икенче яртысында Кырымда чыккан «Тәрҗемән» газетасының төп иганәчесе булырга Рәмиевләр теләк белдерәләр. Күпсанлы татар телендә чыккан басмалар арасында бертуган Рәмиевләр чыгарган «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы, һичшиксез, энциклопедик эчтәлеге, югары сыйфатлы бизәлеше ягыннан аерылып торалар.

Фатих Кәрими һәм Риза Фәхреддин мөхәррирлегендә чыккан бу басмалар, хәзерге Башкортстан җирендә яшәгән төрки халыкларга гына түгел, ә бөтен Россиядә яшәүче, чит илдә яшәүче төрки-мөселман халыклары киләчәгенә җитди тәэсир ясадылар. Татарлар тупланган төбәкләрдән, шулай ук Кавказ, Кырым һәм Урта Азия, Шәркый Төркестан, Төркия, Сүрия, Мисыр тарафларыннан каләм ияләре «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы, «Вакыт» нәшрияты белән иҗади элемтәдә торалар. Борһан Шәрәф, Габделбари Баттал, Шәриф Камал, Җамал Вәлиди, Кәбир Бәкер, Ярулла Вәли кебек гасыр башында канат җәйгән сүз осталары Рәмиевләр оештырган редакцияләрдә армый-талмый хезмәт кылалар. Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Риза Фәхреддин, Фатих Кәрими, Йосыф Акчура, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Ярулла Биги, Зәки Вәлиди, Һади Атласи, Чыгътай кебек билгеле язучылар, галимнәр үзләренең иҗат җимешләрен Оренбургта даими бастырып торалар.

1906 елда аваз биргән «Вакыт» газетасы яңа хакимият тарафыннан 1918 елның 26 гыйнвар көнендә ябыла. Барлыгы 2309 саны гына чыгып өлгерә. Рәмиевләр 1907 елның декабрендә «Шура» журналын бастыруга рәсми документ алалар. Журнал айга ике мәртәбә даими чыгып тора. 1908 – 1918 еллар арасында 240 саны дөнья күрә.

Шулай итеп, Рәмиевләр тырышлыгы белән озак еллар буена яшәп килгән бу басмалар татар язучыларына «рухи бәйләнешләр» һәм «мәдәни диалоглар» өчен мәйданчык булып хезмәт иткәнннәр.

XX гасыр башында күп кенә татар газеталары һәм журналлары басылып чыга, милли нәшриятлар актив эшли, аларда вакыт-вакыт яңа әсәрләр басыла. Алар барысы да татар язучыларына «контактлар» һәм «диалоглар» өчен мәйданчык булып хезмәт иткән.

Совет чорыннан калган догматик әдәбият белеменә каршы көрәштә, хәзерге заман тикшеренүчеләре киңлек-вакыт категорияләре белән бәйле рәвештә язучының дөнья сурәтен актив рәвештә өйрәнә, оппозицияләр бүлеп чыгара, вак детальләрне ачырга ярдәм итүче халыкның «мәдәният архетибы» һ.б. мәсьәләләргә туктала. Бу яссылыкта 2009 елда Казан шәһәрендә Дәрдемәнд юбилеена багышланган

«Дәрдеменд мирасы һәм хәзерге заман» Бөтенрусия фәнни-гамәли конференциясе узды, бөек шагыйрь иҗаты белән бәйле күп проблемалар күтәрелде.

Бүгенге көндә Дәрдемәнд әсәрләре, мәсәлән, бары тик традицион анализ кысаларында, идея-тематик планда гына тишерелергә тиеш түгел, мондый ысул чор таләпләренә туры килми. Филология фәннәре докторы, профессор Нурмөхәммәт Хисамов язганча, «Дәрдемәнднең күләме ягыннан зур булмаган, әмма фәлсәфи-әхлакый эчтәлеге һәм шигъри осталыгының үзенчәлеге белән гаять зур әһәмияткә ия мирасы совет әдәбиятының бөтен тарихы дәвамында татар шигъриятен тикшерүчеләрдән берәүне дә битараф калдырмады. Берәүләр аңа кискен рәвештә кире бәя генә биреп, икенчеләре бары шигъри осталык җәһәтеннән генә аның әһәмиятен таныса, өченчеләре исә лирикасының җәлеп итү серләрен тулырак төшенергә тырышты. Әмма вульгар социологизм йөге барлык очракта да диярлек мәгълүм стереотиплар чигеннән чыгарга ирек бирмәде. Шунлыктан аның шигърияте әдәбият белеме өчен асылда һаман чишелеп бетмәгән мәсьәлә булып кала. Аны тулырак аңлыйм дисәң, узган унъеллыкларда урнашып калган схемалардан тәвәккәл рәвештә баш тартырга һәм әсәрләрнең текстын җентекләп өйрәнергә кирәк» [2; 154].

Алга таба Дәрдмәнд әсәрләре буенча системалы рәвештә мәгълүмат җыю, өйрәнү, автор әйтергә теләгән фикерне комплекслы схема аша ачыклау булырга тиеш: 1. әсәрне тирәнтен уку-кабул итү; 2. метафораларны, символларны, гыйбарәләрне аңлату-анализ; 3. әсәр-образны шәрехләү; 4. автор тудырган дөнья сурәтен күзаллау.

Узган гасырның 80 нче елларында Гали Халит, Дардменд поэзиясен өйрәнеп, аның күп шигырьләре әлегә кадәр өйрәнелмәгән булып кала, аның шигъриятенең «серләре» тулысынча ачылмаган, җентекләп анализлау нигезендә аның поэзиясенең катгый системасы булдырылмаган, шагыйрь әсәрләрен яңа тикшерүчеләр көтә дип белдерде [3; 207]. Танылган галимнең сүзләре бүгенге көндә кадәр актуаль булып кала. Көн тәртибендә 2016 елда чыгарылган «Тукай энциклопедиясе» үрнәге буенча фундаменталь хезмәт – Дәрдеменд энциклопедиясен төзү эше тора.

Башкортстан җире татар әдәбиятына биниһая өлеш керткән шәхесләрне күп бирде. Бу исемлек башында, һичшиксез, даһи шагыйрь Дәрдемәнд намы балкып тора. Дәрдемәнднең уникальлеге барыннан да элек аның универсаль даһи булуында. Дәрдемәнднең универсальлеге, үз чиратында, шунда ки, аның күз алдында поэзия генә түгел, ә тарих, фәлсәфә, сәясәт, иктыйсад, наширлык эшчәнлеге, алтын приискларын оештыру, милләт турында гамь кебек өлкәләр дә булган. Киң колачлы

мондый универсаль даһиның, универсаль генийның әле татар тарихында булганы юк.

**Кулланылган әдәбият**


1. Бахтин М. «Эстетика словесного творчества». 2-е изд. – М., 1979. – 384 с.

2. Хисамов Н. Галим, шагыйрь, шәхес. – Казан: Алма-Лит, 2007. – 304 б.

3. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1986. 3 том. – 508 б.


© Шарипов М.С., 2024

УДК 821.512.145

**Шарипов М.С.,**
*Уфа ш., Россия*

## ДӘРДЕМӘНД ҺӘМ БАШКОРТСТАН

***Аннотация:*** *мәкаләдә бертуган Рәмиевләрнең Башкортстан тарихындагы урыны, Дәрдемәнднең иҗади мирасын өйрәнү, саклау һәм пропагандалау буенча республика татар җәмәгатьчелегенең эшчәнлеге ачыклана.*

***Терәк сүзләр:*** *Дәрдемәнд, поэзия, Башкортстан, шагыйрь, анализ, һәйкәл, шигырьләр.*

2024 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты татар халкының даһи шагыйре, меценат, миллионер-алтынчы, нашир, I Дәүләт Думасы депутаты (1906) Дәрдемәнднең (Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев) тууына 165 ел тулуга багышланган «Дәрдемәнд: шәхес, шагыйрь, фикер иясе» дип аталган фәнни-гамәли түгәрәк өстәл оештырды. Мәҗлеснең пленар утырышында һәм алга таба фикер алышуларда чыгыш ясаучылар Дәрдемәнд иҗатын һәм тормыш юлын Башкортстанда пропагандалау буенча эшләр хакында кызыксыну белдерделәр.

Һичшиксез, теге яисә бу әдипне хәтердә тоту эше концептуаль шәкелдә туган ягыннан башланырга тиеш. Бу яктан караганда, Дәрдемәнд иҗатын, тормыш юлын өйрәнү буенча эшләр шагыйрьнең туган ягында – Башкортстанда даими алып барыла. Дәрдемәнд иҗатын тикшерү, аның мирасын халыкка җиткерү эше буенча нинди уңышлар белән килде Башкортстан татарлары чираттагы юбилейга?

2024 елның 27 августында Башкортстанның Мәләвез районы Җиргән авылында Дәрдемәнд истәлеген мәңгеләштерү буенча зур эш башкарылды: авылның мәдәният йорты алдында шагыйрьнең һәйкәле ачылды. Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы вәкиллеге тарафыннан Дәрдемәнднең туган авылында оештырылган бу гамәл шагыйрьнең тууына 165 ел тулуга багышланды. Башкортстанда Дәрдемәндкә һәйкәл-обелиск ачылу вакыйгасы татар әдәбиятының гаять зур бәйрәменә әйләнде. Бу һәйкәл ачылу – татар сүз сәнгатенең тантанасы иде, концептуаль символга ия тантана иде Төп сенсация шунда иде ки, дөньяда беренче тапкыр татар шагыйре Дәрдемәндкә һәйкәл ачык һавада куелды. Заманында бөек рәссам, сынчы Бакый Урманче Дәрдемәнднең зур һәйкәлен һәм кечкенә бюстын иҗат итә. Бүгенге көндә алар Казанның Бакый Урманче иҗатына багышланган музейда саклананалар. XX гасырның икенче яртысында Бакый Урманче башлаган традиция дәвам итсен иде. Киләчәктә Казанда да, Оренбургта да һәм башка шәһәрләрдә дә мондый һәйкәлләр ачылуына өмет итәбез. Искә төшә шагыйрь юллары: «гәрчә мин дә бар саналдым, ил катар сан алмадым...»

Соңгы елларда Башкортстанда Рәмиевләр мирасына игътибар артканнан арта. Уфа шәһәренең «Рамазан» төрки милли-агарту үзәге белән Уфа фән һәм технологияләр университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы да Дәрдемәнд иҗатына багышланган гыйльми конференцияләр, күргәзмәләр, әдәби-музыкаль кичәләрне даими оештыралар. 2022 елның 16 сентябрендә Уфа шәһәренең «Нур» татар дәүләт театры бинасында «Рамазан» төрки милли-агарту үзәге тарафыннан оештырылган «Дәрдемәнд: аһ, туган каумем газиз» әдәби-музыкаль кичәсе, «Ватанга һәм милләткә хезмәт итү юлында» музей экспозициясе киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты. Музей экспозициясен туплауда ярдәм иткәне өчен зур рәхмәтләрне инде бакыйлыкка күчкән Галия апа һәм Равил абый Рәмиевләргә белдерәбез. Башкортстандагы данлыклы Рәмиевләр нәселенә нигез салган ата-бабалары хөрмәтенә Стәрлебаш районында яшәүче Нил Рәмиев һәм аның дуслары район үзәгендә – Стәрлебаш авылында махсус Рәмиевләр мәчетен төзүләре дә билгеле булды бәйрәмдә. Стәрлебашта яшәүче туган якны өйрәнүчеләр фикеренчә, Дәрдемәнд шәҗәрәсе Муса Җәлил шәҗәрәсенә барып тоташа. Мондый фикерләр җитди тикшерүне сорыйлар. Яшь галимә Ләйсән Ваһапова-Галимова Дәрдемәнднең ике шигыре табылуы хакында белдерде. Бу факт игътибарга лаек.

Бу шигырьләр кайдан табылган соң? Ләйсәннең әтисе Ваһапов Нигъмәтулла 1970 елның июлендә Оренбург янындагы Каргалы авылында фәнни экспедициядә була. Казан дәүләт университетының филология факультетында укыган бу студентка авылның Мостафа исемле

карты Дәрдемәнд мирасына кагылышлы ядкярьләр саклаучы Таһир Исаевның Оренбургтагы өй адресын бирә. Т.Исаев заманында бертуган Кәримовлар типографиясендә эшләгән, Дәрдемәнд белән аралашып йөргән икән. Шагыйрь яңа шигырьләрен аңа беренчеләрдән булып укыта торган булган, кайберләрен хәтта бүләк иткән. Исаев төп нөсхәләрен үзендә калдыра, әмма ике шигырен күчереп алырга рөхсәт итә. Ләйсән Ваһапова әтисе язып алган шигырьләргә эчтәлеге һәм формасы ягыннан комплекслы анализ ясый. Аның фикеренчә, бу шигырьләр Дәрдемәнднеке. Дәрдемәнднеке булуы ихтимал бу шигырьләр тирән эчтәлекле, серле, матур яңгырашлы язылганнар.

Беренчесе:

*Тугды...*
*Үрмәләде...*
*Җилдәй йелде...баг атты.*
*Сулды!*
*Вәйла дәрйг...*
*Җиһандин үтте* (1920)

Икенчесе:

*Җазибмен...*
*Җамнар тотдым.*
*Вакты сәхәр*
*Милләте җәддия чыктым.* (Язылу елы билгеләнмәгән)

Рәмиевләр кая гына килеп утырмасыннар, кайда гына алтын приисклары ачмасыннар, андагы яшәүче халыкның тормышы, яшәвеше, авылының йөзе үзгәрә. Халык гыйлемле, тәрбияле, мул тормышта яши башлый. Эшләре алга киткән саен, авылга ярдәмнәрен дә арттыра баралар. Башкортстанның беренче Президенты М.Рәхимов фикеренчә, «Закир һәм Шакир Рәмиевләр – Ватаныбызның чын патриотлары. Алар төбәкнең икътисадына, рухи һәм социаль тормышына зур өлеш кerттеләр. Баймак, Учалы, Зилаир, Хәйбулла, Әбҗәлил, Зианчура районарындагы башкорт авылларында меңләгән кеше эш белән тәэмин ителгән. Рәмиевләр хастаханәләр, мәктәпләр, мәчетләр төзегәннәр. Башкорт һәм татар балаларын үз исәбенә укытканнар, Россиядә китап чыгару эшен оештыралар» [1;14].

Дәрдемәнд һәм аның абыйсы Шакир Рәмиев – XX гасыр башындагы милләтебезнең пассионар шәхесләре. Мондый шәхесләр исәбенә 2018 елда тууына 100 ел туган Закир Рәмиевнең оныгы – электрон хисаплау машиналары конструкторы, атаклы шахматчы Бәшир Рәмиевне дә кертәбез.

Дәрдемәнд юбилее алдыннан Башкортстанда чыккан бихисап гәзит-журналларда, шул исәптән «Уфа» журналы рус телендә, «Ихлас» журналы татар телендә Дәрдемәнд иҗаты һәм тормышына багышланган кызыклы мәкаләләр бастырдылар. Бер мәкаләдә Дәрдемәнд тәхәллүсе хакында фикер алып барыла: «XX гасыр башында Закир Рәмиев үзенең кем икәнлеген Дәрдемәнд атамасы артына яшергән. Тәхәллүс куллану – Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбиятыннан, Шәрык әдәбиятыннан килгән эстетик традициянең бер чагылышы һәм ул тамырлары белән ислам фәлсәфәсенә барып тоташкан тыйнаклык күренеше-сыйфаты белән бәйле. Шагыйрьнең исеме озак еллар Дәрдмәнд вариантында язылып килде. Галим-әдәбиятчы Нурмөхәммәт Хисамов исә, аргументлар китереп, шагыйрь Дәрдемәнд формасында аталырга тиешлеген белдерде. Бу атама фәндә кабул ителде. Тәхәллүс ике өлештән тора: «дәрд» һәм «мәнд». «Мәнд» – нәрсәгәдер ия мәгънәсен аңлата. Ә менә «дәрд» сүзен озак еллар буе «кайгылы», «хасталы», «сагышлы», «моңсулы» эчтәлекләре белән генә аңлатып килделәр. Тик бер мәгънә төсмере читтә кала бирде: «бәхетсез». Бу яктан караганда, Дәрдемәнд тәхәллүсе «бәхетсез кеше»не дә аңлата. Димәк, Дәрдемәнд – гадәти тәхәллүс түгел, бу – әдипнең гаять тирән эчтәлекле шигъри коды. Дәрдемәнд кайчандыр дәүләтчелеген югалткан халкы өчен, аның киләчәге өчен тирән борчылулар кичергән шагыйрь. Бу яктан, шагыйрьнең тәхәллүсе җисеменә туры килә, әсәрләренең рухын ача» [1;16]. Дәрдемәнд – татар әдәбиятының гына түгел, ә XX гасыр башындагы бөтен төрки дөньясының уникаль күренеше ул. Әлеге көндә дә аның тормышы һәм иҗаты тирән серләр белән капланган. Һәм ул елдан-ел заман укучысын үзенә тарта бара. Бөек шагыйрьнең афористик, фәлсәфи әсәрләрен шәрехләү, хәлбуки, бүген аеруча актуаль мәсьәлә булып тора.

Без, нигездә, Дәрдемәнд турында фикер йөртәбез. Ә менә бу шәхесне тәрбияләгән этисе – кыю йөрәкле Мөхәммәтсадыйк турында (ата кеше балаларына мирас итеп егермеләп прииск калдыра), миһербанлы әнисе Хәнифә, миллипәрвәр абыйсы Шакир хакында аз сөйлибез. 1869-1917 елларда аталы-уллы Рәмиевләр 5 тонна алтын чыгаралар. Бертуган Рәмиевләр алтын приискларының санын ике тапкыр арттыралар. Табылган байлыкның күп өлеше хәйрия эшенә юнәлтелә. Әле XIX гасырда ук Закирның бабасы Габделкәрим киләчәк турында төптән уйлаган. Ул малайларына хатын булырдай кызларны да үзе сайлый. Мөхәммәтсадыйгына, мәсәлән, 1850 елда хәзерге Башкортстанның Явыш авылындагы морзалар нәселеннән килгән Әлмөхәммәт бине Ибраһим Дашковның кызы Хәнифәне димли. Ибраһим Дашков яшь кияүгә фантастик киләчәкле проект-киңәш тәкъдим итә: алтын приискларын оештырырга! XIX гасырның икенче яртысында

хәзерге Башкортстан җирендә Америкадагы кебек алтын кизүе башлана. Ирәндек, Урал таулары битләрендә алтын приискалары ачыла, кыйммәтле металга юлыккан сәүдәгәрләр бик тиз баеп китә. Бу фундаменталь киңәш Рәмиевләр язмышын яңа ясыллыкка куя. Һәм, әйтергә кирәк, татарның рухи үсешенә дә, милләтнең киләчәк язмышына да зур этәргеч ясала.

Шакирга 5 яшь, Закирга 3 яшь булганда, Рәмиевләр гаиләсе Җиргәннән хәзерге Башкортстанның Баймак районы Юлык исемле татар авылына күченә. Бу авыл аша кәрван юллары үтә, монда ямщиклар хезмәте көйгә салынган, зур базар даими эшли. Садыйк авылда кечкенә сабын заводын ача. Лирон Хәмидуллин язуынча, 1869 елда, Җиргәннән Юлыкка күчеп килүләренә җиде ел тулганда, Мөхәммәтсадыйк Орск өязендә бөлгенлеккә төшкән бер рус кешесеннән алтын приискын сатып ала.

Тырышкан ташка кадак каккан: тәүге прииста ук Рәмиевләр алтын эзенә юлыгалар. Аннары икенче прииск ачалар, аннан өченче... Аларның саны озакламый ике дистәгә барып җитә. Яңа приисклар ачар өчен яңа җирләр сатып алалар. Жиргәндә кызыл мал белән генә сатулык иткән Рәмиевләр гаиләсе кинәт баеп китә.

Башкортстанда 2024-2025 еллар арасында Дәрдемәнд юбилеена багышланган «Аһ, туган кавемем газиз!» дип аталган мәдәни фестиваль оештыру каралган. Бу фестиваль кысаларында дистәләгән милли-мәдәни чаралар оештырылачак. 2024 елның 19 ноябрендә М.Гафури мемориаль йорт-музеенда Дәрдемәнд юбилеена багышланган «Аның шигырьләре гүзәл иде...» дип аталган искә алу чарасы башкорт һәм татар телләрендә узды. «Шура» журналының 1908 елдагы 1 нче санында үзенең атаклы «Кораб» шигыре белән аваз биргән Дәрдемәнд менә инде бер гасырдан артык үзенә карата кызыксынуны туктатмый, татар дөньясында шагыйрь исеме елдан-ел популярлаша бара. Аның тормышта кылган изге гамәлләре, шигырьләренең эчке аһәңе һәм тышкы яңгырашы яңа заман кешеләрен берчә сокландыра, берчә тирән уйларга мәҗбүр итә. Без, Башкортстан кешеләре, туган ягыбыз тарихында якты эз калдырган Дәрдемәнд белән, һичшиксез, ихлас горурланабыз.

**Әдәбият исемлеге**

1. Шәрипов М. Аһ, туган каумем газиз... // Ихлас. – 2024. – № 10. – 14–18 б.

© Шарипов М.С., 2024

УДК 821.512.145

**Шарипов М.С.,**
*Уфа ш., Россия*

# ХӘЗЕРГЕ МИЛЛИ СӘХНӘ ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ҮСЕШ-ҮЗГӘРЕШЕ

***Аннотация:*** *әлеге мәкаләдә хәзерге татар драматургиясенең үсеш үзенчәлекләре карала, аны шартлы рәвештә ике чорга бүлеп була: үзгәртеп кору чоры драматургиясе (1985-2000); үзгәртеп корудан соңгы чор драматургиясе (2000-2024). Бу чор сәхнә әдәбиятында үзләрен өч төп юнәлеш – реалистик, романтик, шартлы стильләр ачык күрсәтте. Жанрларның һәм стильләрнең төрлелеге чынбарлыкның яңа материалларын кыю үзләштерүгә, яңа коллизияләрнең чагылышына һәм аларда кызыклы характерлар тудыруга китерде.*

***Терәк сүзләр:*** *театр, милләт, чор, татар сәхнә әдәбияты, мәдәният, жанр формасы, драма, комедия.*

Татар драматургиясе татарлар тупланып яшәгән җирләрдәге үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнештә үсеш кичерә. Һәр чорда татар пьесасының үзенә генә хас тема-проблемалары, жанр һәм жанр формалары төрлелеге, әдәби-эстетик сыйфатлары булды. Үзенчәлекле тормыш сурәте булган сәхнә әдәбияты җәмгыять үсеше, андагы үзгәреш-яңалыклар белән тыгыз бәйләнештә яши. Совет чорының тәүге елларыннан ук әдәби иҗатның бу төренә яңа идеологиягә хезмәт кылучы функция көчләп йөкләтелсә дә, дистә еллар буе ул үзенең борынгы чорлардан килгән табигый миссиясен үтәргә омтылды. 1985 елдан соңгы милли драматургия «Хәзерге татар сәхнә әдәбияты» дип аталган яңа дәвергә аяк басты. Хәзерге татар сәхнә әдәбиятын шартлы рәвештә ике чорга бүләргә мөмкин: үзгәртеп кору чоры драматургиясе (1985-2000); үзгәртеп корудан соңгы чор драматургиясе (2000-2024). Бу бүленештә иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-эстетик факторлар нигез булып торалар.

Яңа чор татар драматургиясе хәрәкәтендә 1985-2000 еллар аерым урын тота. Ул вакытта ил системасында, социаль-сәяси үзаңда фундаменталь үзгәрешләр күзәтелә: җәмгыять озак еллар буе хакимлек иткән идеологик стереотиплардан баш тарта, әдәби иҗатта яңа эстетик принциплар булдырыла. Татар драматургларының бу еллардагы иҗади омтылышлары XX гасырның икенче яртысындагы әдәби-драматик тенденцияләр юнәлешенең дәвамы иде. «Хрущёв җепшеклеге» дип аталган чордан соң, билгеле булганча, яңа җәмгыять төзүче, үзен дә шәхес буларак белдерүче кеше татар драматургиясенең сурәтләү предметына әверелә.

Татар драматургиясе классиклары Г.Камал, Г.Коләхмәтов, Ф.Әмирхан, М.Фәйзи, Ф.Бурнаш, К.Тинчурин, Т.Гыйззәт, Н.Исәнбәт, Р.Ишморат һәм башка сүз осталарының бай традицияләрен дәвам итеп, яңа дәвер драматурглары кыю рәвештә актуаль проблемалар күтәрәләр, замандаш типларын билгелиләр, гыйбрәтле характерлар гәүдәләндерәләр. Яңа дәвердә әдәбият мәйданына аяк баскан Т.Миңнуллин, Х.Вахитов, Ш.Хөсәенов, А.Гыйләҗев, Д.Вәлиев, И.Юзеев, Ә.Баянов, Р.Хәмит, Ф.Яруллин, Р.Мингалимов кебек татар язучылары милли драматургия офыгын киңәйттеләр: үз пьесаларында ата-бабалары васыять иткән тормыш рәвешен кыю чагылдырдылар, драматургиянең яңа мөмкинлекләрен һәм иҗади чараларын эзләү һәм аларны куллану өстендә актив эшләделәр. Туфан Миңнуллинның 1985 елга кадәр үк популяр булган пьесаларының берсе – «Үзебез сайлаган язмыш» драмасы – ул чордагы мөһим шигарь белән башлана. Мәктәпнең яшь укытучысы педагогик утырышта укыту һәм тәрбия системасындагы тәртипләрне «Ялган!» дип атый. Мондый тәнкыйди ясыллык торгынлык чоры драмаларын характерлаучы бер сыйфат булып тора иде. Бу исә сәхнә әдәбиятына җәмгыйтьтә җитешсезлекләр белән риза булмаучы, аны үзәртеп коруга әзер булган яңа типтагы геройны алып килде.

Герой проблемасы – әдәбиятның һәм, аерым алганда, драманың мәңгелек проблемасы. Ләкин XX гасырның икенче яртысында, татар драматургиясендә генә түгел, ә илнең күпмилләтле драматургиясе контекстында да, җәмгыятьтә барган революцион социаль-икътисади үзгәрешләр белән бәйле заманда, герой мәсьәләсе аеруча актуальләште. Һәм бу табигый иде, чөнки драма һәрвакыт җәмгыятьнең эчке хәрәкәтенең барометры, илнең пульс тибеше, аның каршылыкларының көзгесе булган. Сәхнә әдәбиятының тәрбияви миссиясе, аның яңа кешене формалаштыруда роле аеруча җәмгыять алдында рухи-әхлакый проблемалар, кешеләрне хакыйкать идеяләре буенча тәрбияләү кирәклеге, кешеләрне дөрес сүз һәм реаль эш белән тәрбияләү кирәклеге барлыкка килгән вакытта арта.

XX гасыр ахырында вакытны, чынбарлыкны тирән аңлау өчен җәмәгатьчелектә сораулар туа: без кемнәр, ник болай яшибез, безгә ничек үзгәрергә? Бу чорның иҗтимагый-сәяси вакыйгалары дөреслекне яклау – вөҗдан эше, эчке ихтыяҗ дип уйлаган кешеләрне мәйданга алып чыга. Торгынлык чорында тамыр җибәргән кимчелекләрне алып ташлау өчен көрәшергә әзер мондый кешеләр тормышта бар иде. Мондый кешеләр – илнең әхлакый потенциалын саклау эшендә аңлы, намуслы, эшлекле, батыр кешеләр – яңа типтагы каһарманнар иде. Алар яңа, тәраккый кешеләр иде, алар яңа буын өчен кирәк иде.

Драматургия мондый типларны сәхнәдә бөтен тулылыгында гәүдәләндерде. Шунысы мөһим, тормыш һәм вакыт үзе сәхнә әдәбиятын, аның табигате, жанр һәм идея-эстетик асылы аркасында, җәмгыятьне яңарту, кешеләрне рухи кыйммәтләр белән баету өчен көрәшнең беренче сызыгында булырга мәҗбүр итә. Илдә иҗтимагый фикернең кысылган халәте вакытында драматургиянең сизгер булмавын, җәмгыятьтәге чын хәлне аңламавын, безнең әхлакка ят күренешләрне ачып салмавын, үзгәрешләр, үзгәртеп кору өчен көрәшмәвен белдерү гаделсезлек булыр иде. Һәрхәлдә, драматургия чын тормышны һәм чын конфликтларны чагылдыруда аеруча активлык күрсәтте.

Драматургия кайвакыт артта калмаган гына түгел, ә мөһим иҗтимагый процессларны чагылдыруда алгы рәттә булды [1]. Бөтенроссия әдәби-театраль киңлегендә популяр булган А.Вампиловның «Үрдәккә ау», Г.Бокаревның «Металлл эретүчеләр», И.Дворецкийның «Чит як кешесе», А.Гельманның «Бер җыелыш протоколы», А.Абдуллинның «Унөченче рәис», М. Шатровның «Вөҗдан диктатурасы» һәм башка күп кенә пьесалар 1970-1980 елларда тормышны дөрес чагылдыруга омтылу белән аерылып тордылар һәм милли драматургияләргә, милли театрларга үрнәк булдылар. Бу әсәрләрдәге сюжетларда кешенең барлыгын һәм аның аңын деформацияләгән тискәре тенденцияләр, социаль үсешкә зыян китергән күренешләр кискен рәвештә фаш ителде.

Татар сәхнә әдәбияты да торгынлык вакытындагы сынауны лаеклы үтте. XX гасырның икенче яртысындагы күпчелек танылган татар драматурглары әдәбиятка 60 елларда, 70 еллар башында килә. Бу – аларның жанрларны төрләндерү өлкәсендәге актив иҗат эшчәнлеге чоры. Яңа сәхнә әдәбиятында, нәтиҗәдә, онытыла барган традицион һәм яңа жанрлар һәм жанр формалары урын алды: тарихи трагедия, халык драмасы, көнкүреш драмасы, тарихи-биографик драма, монодрама, интеллектуаль драма, иҗтимагый драма, бәхәс-драма, социаль-психологик драма, мелодрама, водевиль сатирик комедия, музыкаль комедия, моңсу комедия. Бу дәвердәге сәхнә әдәбиятында өч төп юнәлеш – реалистик, романтик, шартлы стильләр үзләрен ачык сиздерделәр. Жанр һәм стильләрнең төрләнүе чынбарлыкның яңа материалларын кыю үзләштерүгә, яңа коллизияләр чагылдыруга һәм аларда кызыклы характерлар тудыруга китерде.

Иҗади шәхес үсеше өчен уңайсыз шартлар хөкем сөрүгә карамастан, драматург Т. Миңнуллин һәм аның чордашлары драмаларда актуаль, көнүзәк темаларны чагылдырып кына калмыйлар, ә еш кына, вакыт үзгәрешен һәм вакыйгаларны алдарак сиземләп, иртәгәсе көндә җәмгыятьне нәрсә көтәчәге турында фараз итәләр, кинаяләр белдерәләр.

Алар өчен иҗат батырлыгы үрнәге булып өлкән буын вәкилләренең әсәрләре хезмәт итте. Горбачев-Ельцин «җепшеклеге» чорында, демократия иреге һәм хәбәрдарлык шартларында, тамашачы хөкеменә кайчандыр тыелган пьесаларның кайтуы, аларның киң укучы-тамашачыга яңадан тәкъдим ителүе шатлыклы күренеш иде. Н.Исәнбәтнең «Портфельле кияү» комедиясе, А.Гыйләҗевнең «Өч аршин җир» драмасы, Г.Исхакый драмалары татар театр репертуарларын шактый баетты, үзләре артыннан яңа чор язучыларын ияртте. Хәзер бу чорга, сынаулар елларында чыныккан әдәби-театраль хәрәкәткә, күз салып, без ышаныч белән әйтә алабыз: узган гасырның 70-80 елларындагы, 80-90 елларындагы татар драматургиясе дә көрәшнең авангардында иде, бу буын җәмыятьтәге җитди үзгәреш процессларын әзерләүдә актив катнашты.

Вахитов-Миңнуллин буыны сәхнә язучыларының иң яхшы традицияләренә таянып, XX гасыр ахырында татар әдәбиятына талантлы драматурглар когортасы килә: З.Хәким, Г.Каюмов, Ф.Бәйрәмова, Д.Салихов, М.Гыйләҗев, Р.Сәгъди, Аманулла, Р.Зәйдулла һәм башкалар. Яшь авторларының иҗат кыбласы, сурәтләү алымнары, герой гәүдәләндерү принциплары ягыннан, үзгә иде. Алар үзләренең игътибарын «позитив характер», «идеаль герой», «реалистик сурәтләү» кебек төшенчәләргә түгел, ә милли тематикага, заманның хәл ителүен көткән актуаль проблемаларга, гадәти булмаган образларга (халык характеры, сәер кеше, ялгышучы кеше, «кечкенә кеше», эзләнүчән кеше) юнәлттеләр. Бу драматурглар стилендә модернист алымнарны куллану, архетипларны, мифологеммаларны әсәр тукымасына кертеп җибәрү, ике дөнья хәлләрен фантастик алымнар ярдәмендә гәүдәләндерү гадәти хәлгә әйләнде. Тормышның үз формасыннан, барлык детальләрне натуралистик хәлгә җитәрлек сурәтләрдән, реалистик алымнардан туйган укучы-тамашачы уйлап чыгарылган ярым хыялый, ярым тормышчан реальлеккә чума иде. Тормыштагы логик аңламга сыймаган хәл-вакыйгалар «абсурд театры» күренешенең барлыкка китеүенә этәргеч ясады. З.Хәкимнең «Кишер басуы», М.Гыйләҗевнең «Баскетболчы», Ф.Бәйрәмованың «Вакыйга юләрләр йортында бара», Д. Салиховның «Алла каргаган йорт», Аманулланың «Әлепле артистлары» пьесалары метафорик хәл-вакыйгаларны, символик күренешләрне актив куллану, сюжетның шартлы образларга һәм хәл-ситуацияләргә корылуы белән аерылып торалар. 2022-2023 еллардагы күп кенә татар театрлары репетуарында модернистик алымнарга нигезләнгән Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясенең урын алуын феноменаль күренеш дип карарга кирәк. Димәк, тамашачы Әлмәндәр тибындагы тирә-як белән гармониядә яшәгән, шәхес иреге өчен якалашкан ил агасын, халыкчан

характерны сагынган. Чын ил агалары, аксакаллар белән аралашуга рухи ихтыяҗны театрлар дөрес сизеп алганнар һәм бу әсәрне сәхнәдә тамашачыларга тәкъдим иткәннәр.

Шулай итеп, XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында милли сәхнә әдәбияты үзенчәлекле чорга аяк баса. Йөз ел элек Аурупа тибындагы милли сәхнә сәнгатенә һәм әдәбиятына орлык салган классикларның тормыш һәм сәнгать хакыйкате принципларына нигезләнгән юнәлеше татар драматургларының хәзерге буыны иҗатында тарафыннан уңышлы үсеш ала. Иҗтимагый тормышның объектив күренешләре, чынбарлыкның тискәре күренешләре аларның әсәрләренең психологик, фәлсәфи катламын, социаль-тәнкыйди юнәлешен, публицистик аһәңен, шулай ук геройларның билгеле типларын билгели.

**Кулланылган әдәбият**

1. Ахмадуллин А.Г. Татарская драматургия: история и проблемы. – Казань: Татар. кн. изд-во; 2012. – 192 с.

© Шарипов М.С., 2024

УДК 81'362

**Шарипова Л.М.,**
*г. Самарканд, Узбекистан*

## СУЩНОСТЬ, ПЕДАГОГИЧЕСКИЕ И ПСИХОЛОГИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ РАЗВИТИЯ ИНТЕРЕСА К ИЗУЧЕНИЮ ЯЗЫКА ПОСРЕДСТВОМ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ ИНТЕГРИРОВАННЫХ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ТЕХНОЛОГИЙ

***Аннотация:*** *в статье раскрываются эффективные инновационные и интегративные методы, позволяющие интересно организовать процессы изучения языка студентами, способы развития интереса учащихся к обучению посредством игр, игровые методы изучения иностранного языка и их роль в формировании социального и личностного компетенции, коммуникативные навыки, навыки работы в команде и многое другое.*

***Ключевые слова:*** *инновационные и интегративные методы, игровые методы изучения иностранного языка, социальные и личностные компетенции.*

Сегодня очень необходимы опытные молодые кадры, умеющие владеть собой во всех сферах, которые принесут пользу развитию

общества. Высшие учебные заведения должны готовить творческих творцов, молодежь и новаторов, которые будут способствовать изменению текущей жизни общества. Для этого высшие учебные заведения должны всегда им помогать, уважая личность специалиста.

Внедрение педагогических инноваций в учебный процесс системы иноязычного образования является актуальной потребностью современности. Проблема интеграции образования и обучения в высшей школе важна и актуальна как для теории, так и для практики, и определено, что в последнее время принято несколько подходов: урок проводится двумя специалистами-предметниками или путем объединения двух предметов в один урок. оно ведет от одного специалиста к организации интегрированных курсов, к радикальному изменению содержания иноязычного образования. Стало понятно, что и вузы, и дидактика, и методология пока к этому не готовы. В настоящее время проблемой создания интегрированной информации, составляющей основу этих вопросов, является знание иностранного языка.

- нечто странное, необычное: *Бу ниткән **әкәмәт** – алтмыш яшен тутырып узган, кырык ел буена колхозны җилкәсендә тарткан фронтовик Айтугановны таларга җыенабызмы?* (Г.Ахунов) → ср.: оценка какой-либо ситуации, чьих-либо действий как вызывающих удивление, недоумение: *Ни сәбәптер, ни өметтер, картларның да кызларга матур күренәсе килә бит, **әкәмәт***. (Ш.Галиев);

- вооруженная охрана, стража: *Моңарчы басудан келт-мелт каз куып йөргән Шәйхи хәлфә янгын сараена **каравылга** килде.* (М.Мәһдиев) → ср.: призыв на помощь в случае опасности: *Болдырга чыгу белән Сәкинә ачы чырылдау һәм елау тавышы белән сөрән салды: «**Каравыл**! Күршеләрем, җан туганнарым, коткарыгыз, ирем үтерә бит мине. **Каравыл, каравыл!..**»* (Л.-Х.Таналин);

2) глаголы:

- глагол прошедшего времени изъявительного наклонения со значением «иметь в большом количестве»: *Дөрес, Галия Гафаровна – уңган һәм кешелекле врач, югалып калмады, абруй казанды, Республиканың баш акушер-гинекологы дәрәҗәсенә **җитте**.* (М.Маликова) → ср.: требование прекратить какое-либо действие: *[Хәсән:] **Җитте**, узынма. Бар, кереп, чәй эч*. (Т.Миңнуллин);

- глагол в повелительном наклонении со значением «устремлять, направлять взгляд куда-либо»: *Алдыңа **кара**!* → ср.: выражает предупреждение, изумление: ***Кара, кара,** моның да теле бар икән!* (М.Фәйзи);

- глагол в повелительном наклонении со значением «покинуть какое-либо место, чье-либо общество»: *Юл читеннән ераккарак **кит**!* → ср.: употребляется при выражении требования прекратить какое-либо действие либо при выражении чувства сомнения, возмущения: *Гариф Хәмидәнең елаганын күреп: – Әллә елап йөри инде?.. **Кит**, юкка елама!.. Тапкан елар нәрсә! – диде.* (М.Гафури).

Таким образом, конверсия – один способов словообразования, при котором слово одной части речи переходит в разряд другой, в результате чего происходит изменение грамматической категории слова без добавления аффиксов или каких-либо изменений в его форме. Модализация и интеръективация как виды конверсии занимают особое

место в словообразовательной системе языка, позволяя не только создавать новые слова, но и обогащать их значение.

**Список литературы**

1. Ахтямов М.Х. Современный башкирский язык. – М., 1994. – 186 с.

2. Зарипова И.Ф. Инкорпорация глаголов с актантами в словообразовании в современном татарском языке // Сохранение и развитие родных многонационального государства: проблемы и перспективы: мат-лы X Междунар. научно-практ. конф. – Казань: Отечество, 2019. – С. 99-102.

3. Смирницкий А.И. Лексикология английского языка. – М.: Издательство литературы на иностранных языках, 1956 – 260 с.

4. Степанов Ю.С. Французская стилистика: в сравнении с русской / Ю.С. Степанов. – М.: URSS, 2006. – 360 с.

5. Юсупова Л.Р. Место конверсии в системе словообразования современного татарского языка // Актуальные проблемы современной татарской филологии: Сборник статей XI Международной научно-практической конференции, посвященной 90-летию со дня рождения известного языковеда, тюрколога, переводчика, доктора филологических наук, профессора Р.Г. Ахметьянова (1933-2018) и 65-летию кафедры татарской филологии и культуры, Уфа, 24 ноября 2023 года. – Уфа: Уфимский университет науки и технологий, 2023. – С. 283-286.

© Юсупова Л.Р., 2024

УДК 811.512.145

**Яхина Д.Р.,**
*Уфа ш., Россия*
*Фәнни җитәкче – ф.ф.к., доцент* ***И.Ф. Зарипова***

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ

***Аннотация:*** *мәкаләдә мәктәп дәреслекләрендә бирелгән фразеологик берәмлекләр анализланды. Укучыларның лексик күнекмәләрен үстерү өчен, сүзләрнең әйтелешен, язылышын, мәгънәсен, ясалышын, башка сүзләр белән бәйләнешен, сөйләмдә кулланылышын үзләштерү мөһим. Моның белән беррәттән, татар һәм рус телләрендәге сүзләрнең мәгънә ягыннан аермаларын күрсәтеп бару, рус телендә эквивалентлары булмаган сүзләрне аңлатып бирү дә сорала. Татар телендә полисемия күренеше киң таралган. Шуңа күрә укытучы сүзнең*

*тиешле мәгънәсен контексттан чыгып сайлап алу күнекмәләрен камилләштерүгә дә аерым игътибар бирергә тиеш.*

***Терәк сүзләр:*** *тел, сөйләм, тел байлыгы, мәктәп.*

Туган тел – халыкның рухы, җаны, иң әһәмиятле билгесе. Телдә һәм тел аша халыкның милли психологиясе, характеры, фикерләү һәм иҗат үзенчәлекләре ачыла, шулай ук аның тарихы, культурасы чагылыш таба. Шуңа күрә туган телне өйрәнү һәм саклау иң зарур эшләрдән санала.

Тел – кешеләрнең бер-берсе белән аралаша торган иң әһәмиятле чарасы. Фикерләү һәм культурага ирешү коралы. Укучыларның телдән һәм язма сөйләмнең югары культурасына ия булуы, туган телнең барлык чараларыннан, стилистик байлыгыннан тулы һәм дөрес файдалана белүе – һәркайсы тел укытучысының изге бурычы.

Мәктәптә укучының гомуми үсеше, барлык уку предметлары буенча өлгереше, грамоталылыгы аның үз фикерләрен ни дәрәҗәдә эчтәлекле, логик эзлекле, ачык һәм дөрес итеп белдерә алу сәләтенә бәйле. Укучы үзләштерә торган тел нормаларына фонетик, лексик, морфологик, орфографик, синтаксик һәм пунктуацион законнар һәм кагыйдәләр керә; бәйләнешле/контекстлы/сөйләмнән файдалану алымнары һәм стилистик нормалар да шуларга өстәлә. Укучы һәр сүзгә карата «Мин аны дөрес әйтәмме? Дөрес язаммы? Дөрес аңлыйммы?» дигән сорау куя белергә тиеш.

Язма сөйләм телен үстерүнең әһәмиятле бүлеге – укучыны җөмлә төзи белергә өйрәтү. Укучылар хикәя, сорау, боерык, ияле, иясез, җыйнак һәм җәенке җөмләләр һәм ике-өч гади җөмләдән торган кушма җөмләләр төзи белергә тиешләр. Язма сөйләм үстерүдә бәйләнешле яки контестлы сөйләм төзи белү аеруча әһәмиятле. Бәйләнешле сөйләмнең үз алымнары, нормалары бар. Иң элек бәйләнешле текстка кергән аерым җөмләләр үзара бәйле булырга тиеш. Алар билгеле бер тәртипкә куела, бербөтен барлыкка килерлек итеп, бер эчтәлек астына берләштерелә.

К.Насыйри грамматиканы өйрәнү максатын билгеләгәндә үк («Сөйләшкәндә вә язганда телне хатадан сакламактыр») телдән һәм язма сөйләм үстерүне күз алдында тота. Ана телендә сөйләгәндә, язганда сүз сайлый белүгә, сүзләрне дөрес әйтүгә, куллану принципларына, стилистик алымнарга игътибар итә («Нәмунә», «Кавагыйде китабәт»).

Г.Ибраһимов «Татар телен ничек укытырга?» исемле китабында ана теле дәресләрендә телдән һәм язма сөйләм үстерүгә аеруча зур игътибар юнәлтә. «Сөйләм яшәүдә нинди зур урын тотса, язып аңлату да хәзерге мәдәни хәятта аннан аз ким әһәмиятле», – ди ул [1; 15]. Баланың

сөйләргә өйрәнүен ул язарга өйрәнү өчен хәзерлек итеп аңлый һәм аның юлларын да күрсәтә:

а) эчтәлекле логик эзлекле итеп сөйләтү,

б) сюжетлы рәсемнәр буенча сөйләтү,

в) укучылар белән әңгәмә сәгатьләре үткәрү.

Хәзерге программаларда, методика китапларында һәм мәкаләләрдә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә язма сөйләм телен үстерү сүзләрне әдәби дөрес әйтү өстендә, сүз, җөмлә, бәйләнешле сөйләм өстендә эшләү, телдән һәм язма сөйләм өстендә эшләү дип, киң мәгънәдә аңлатыла. Язма сөйләм үстерү логик фикерләү сәләтен үстерү белән дә тыгыз бәйләнгән. Грамматик, пунктуацион, орфографик яктан дөрес булган, тирән эчтәлекле итеп логик дөрес төзелгән сөйләм генә камилләшкән язма сөйләм булып санала. Фикерләү сәләте һәм сөйләм осталыгы үсү әдәбият һәм тел дәресләре белән табигый үрелеп бара һәм сөйләм өстендә эшләү элементлары һәр дәрестә була.

Тел байлыгы җитмәү аркасында, укучылар башка фәннәр буенча да материалны эзлекле итеп сөйләп бирә алмыйлар. Аларда тел күнекмәләре җитәрлек булмау мәктәптә уку-укыту эшләрен тиешле югарылыкта алып барырга комачаулый. Шунлыктан татар теле укытучылары тел курсының бөтен тармаклары (фонетика, орфография, морфология, синтаксис һәм пунктуация) буенча үткәрелгән барлык тип дәресләрдә һәм әдәбият дәресләрендә дә, төрле күләмдә һәм төрле метод-алымнар кулланып, укучыларга сөйләү һәм язу күнекмәләре бирү эшенә зур урын бирәләр. Хәтта тел байлыгын үстерү буенча аерым дәресләр оештыралар. Шулай эшләгәндә генә, укучыларның гомуми культурасы үсә һәм алар барлык яктан да грамоталы шәхес булып тәрбияләнәләр. Укучылар мәктәптән дөрес сөйләргә өйрәнеп, оста сөйләшерлек дәрәҗәдә әзерләнеп, үз фикерләрен язма рәвештә төпле билгеләп чыгарга тиешләр.

Сөйләм һәм язу телен үстерү укытучыдан туктаусыз хезмәт таләп итә. Тел дәресләрендә сөйләмгә һәм язуга тигез урын бирү, укучыларда җитәрлек күнекмәләр булдыру – укытучының төп максаты. Моның өчен дәреслекләрдә бирелгән төрле күнегүләр, мөстәкыйль эшләр үткәрү, төрле диктантлар яздыру кебек эшләр өстенә, тагын түбәндәге эшләрне дә, төрледән-төрле метод һәм алымнар да куллану уңышлы нәтиҗәләр бирәчәк һәм язма сөйләм телен үстерүнең әһәмиятен дә билгели алачак.

1) картина, сюжетлы рәсемнәр яки видеоязмалар күрсәтеп, шуларның эчтәлеген сөйләтү һәм соңыннан сочинение итеп яздыру яисә, изложение өчен алынган текстны укып, аның эчтәлеген сөйләтү, соңыннан аны яздыру;

2) чыгыш ясарга өйрәтү һәм чыгыш язу;

3) сыйныфтагы чыгышларына яки җавапларына бәя бирү яисә рецензия язу, аның уңышлы һәм кимчелекле якларын күрсәтү;

4) төрле төрдәге иҗади биремнәрне үтәү;

5) сүз, эпиграфлар белән эшләү, фразеологик эш, план төзү, докладлар, рефератлар язу, конспектлар, тезислар төзү.

Әлеге алымнар укучыларны иҗади эшләргә, игътибарлы булырга, үз фикереңне язма рәвештә оештырырга, иҗади уйларга, хәтерләрен үстерергә, фикерләргә, эзләнергә, дәлилләргә, нәтиҗә ясарга, грамоталы язарга өйрәтә.

Язма сөйләм телен үстерү эшләре грамматика, орфография, пунктуация һәм әдәбият дәресләре белән дә тыгыз бәйләнештә үткәрелә. Билгеле, башка фән укытучылары да укучыларны дөрес, грамоталы язарга өйрәтүгә игътибар итәргә тиешләр. Бу яктан да, фән укытучылары белән берлектә, бәйләнешле сөйләм үстерү буенча төрле эшләр оештырырга мөмкин. Әлеге темага караган киңәшмәләр («Фәннәрнең бәйләнеше»), «Математика бездә кунакта», «Пушкин һәм Тукай» кебек интеграль язма эшләр оештыру уңай нәтиҗәләр бирәчәк.

Татар теле һәм әдәбият дәресләре укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстереп кенә калмый, тәрбия дә бирә.

Укучыларның язма телен үстерү, әлбәттә, бу хатасыз язу, орфографик яктан белемле булуны да таләп итә. Хатасыз язарга өйрәтү өчен кирәкле орфографик күнегүләр сайлаганда, иң элек орфографиянең принципларына мөрәҗәгать итәләр. Һәр тел өчен иң җайлы, уңайлы ысул – сүзне ишетелгәнчә язу, фонетик принцип. Татар теленең үз сүзләре, нигездә, фонетик принцип буенча, ничек әйтелсә – шулай языла. Академик грамматикада: «Татар әдәби телендә сүзләр ничек, нинди авазлар белән әйтелсә, шулай языла, – бу безнең орфография өчен төп кагыйдә», – дип күрсәтелә.

Бу тәгъбир баланың хатасыз яза алуы аның уку осталыгына бәйле икәнлеген аңлата. Әгәр бала беренче сыйныфта ук сүздәге хәрефләрне дөрес авазлаштырып, төшереп калдырмыйча, урыннарын алмаштырмыйча, артык хәрефләр өстәмичә, сыйфатлы укуга ирешсә, аның уку осталыгы һәм грамоталы язу сәләте дә камил булачак. Иң элек укучыда сүзнең дөрес график образын формалаштырырга кирәк. Төрле илләрнең психологлары, методистлары баланың аңына хаталы язылган сүзне беркетеп, теркәп куярга ярамаганлыгы турында кисәтә. Нигездә, бу хәлнең килеп чыгуына язма эшләрдәге хаталар өстендә эшләү сәбәпче була. Бу эш, гадәттә, хаталы язылган сүзне ун яисә тагын да күбрәк тапкыр дөрес итеп яздырудан гыйбарәт. Ләкин укучы, шул сүзне соңгы тапкыр язганда, барыбер үзенчә, хаталы итеп яза. «Язгач укып төзәтү гадәте булган балада дөрес язу күнекмәсе озак формалаша», – дип

искәртә күренекле методист С.Г.Вәгыйзов [2; 272]. «Народное образование» журналының баш мөхәррире А.М.Кушнир, шулай ук, «Хаталар өстендә эшләү дөрес язу күнегүләренә бирелгән вакытны ун тапкыр артык исраф итә» дигән фикердә тора һәм, сүзнең дөрес график образын тудыру өчен, орфографик күнегүләрне күчереп язудан башларга тәкъдим итә. Ләкин бу аң эшчәнлегенә бәйсез, автоматик рәвештә күчереп язу булмый. Укучыга алдан ук максат куела: текстны бер хатасыз күчереп язарга кирәк, чөнки эшнең беренче хатага хәтле булган өлеше генә исәпкә алыначак. Шулай итеп, күчереп язу бала өчен максатчан эшчәнлеккә әверелә, ул акылын эшкә җигеп, игътибарын көчәйтеп, туплап эшләргә тиеш була [14; 37].

Башкарылган эштә хаталар төзәтелми, хатасыз язылган өлеш хаталы өлештән горизонталь сызык белән генә аерып куела, һәр дөрес язылган юл өчен бер балл бирелә. Укучы үзе сызыктан соң булган юл ни өчен исәпкә алынмаганын үзлегеннән тикшереп карый, хатасын таба һәм укытучының хаклы икәнлегенә ышана. Бу инде балада Федераль дәүләт белем бирү стандарты (ФДББС) таләп иткән үзтикшерү компетенциясе формалаша башлауны аңлата. С.Г.Вәгыйзов күчереп язуның өч төрен аерып күрсәтә [2; 207].

Шулай итеп, мәктәптә укучыларның сөйләм телен үстерү – тел укытучыларының алдында торган бурычы. Бүгенге заман укучылары үз фикерләрен начар формалаштыралар. Ләкин шуңа карамастан төрле метод һәм алымнар, эш төрләре белән укучыларның логик эчтәлекле, аһәңле, грамоталы, тирән фикерле язма сөйләм телен булдыруы аерым ачык. Үз тәҗрибәсеннән, теоретик белемнәреннән һәм үзенең әзер булуыннан чыгып, һәр татар теле укытучысы бу проблема өстендә эшли һәм үз методын, алымнар системасын булдыра.

**Әдәбият**

1. Вәгыйзов С.Г., Вәлитова Р.Г. Башланыч мәктәптә татар теле методикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.

2. Вәгыйзов С. Г. Кызыклы грамматика: Укытучылар өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2002.

3. Селевко Г.Н. Современные образовательные технологии. – Москва: Народное образование, 1998.

© Яхина Д.Р., 2024

УДК 821.512.145

**Яхина Д.Р.,**
*Уфа ш., Россия*
*Фәнни җитәкче – к.ф.н., доцент* ***М.С. Шәрипов***

# ШӘРИФ КАМАЛ ПРОЗАСЫНДА БИНАР ОППОЗИЦИЯ ЧАГЫЛЫШЫ

***Аннотация:*** *Шәриф Камал иҗатында бинар оппозицияләр — бер-берсенә каршы төшүче парлы төшенчәләр, образлар, темалар — әһәмиятле роль уйный. Аның әсәрләрендә социаль, культуралы һәм эзотерик темалар арасындагы бәйләнешләр, конфликтлар, һәм контрастлар ярдәмендә геройлар арасында драматик алыш-бирешләр күзәтелә. Бинар оппозицияләр аша автор геройларның җәмгыятьтәге урыннарын, милли һәм мәдәни аерымлыкларын, һәм психологик көрәшләрен чагылдыра. Бу темаларның аудиториядә дөньяга караш формалаштыруда әһәмиятле роль уйнавы язучының иҗатының тирәнлеген һәм катлаулылыгын күрсәтә.*

***Терәк сүзләр:*** *Әдәбият, автор, оппозиция, проза, антитеза, контрастлык, хикәя.*

XX гасыр башы татар матур әдәбият әсәрләрендә кулланылган контраст, художестволы антитеза чаралары гади алымнар түгел иде. Бу янәшәлек, капма-каршы төшенчәләрнең мәгънәләре чорның социаль тигезсезлеген дә ачык күрсәтә иде. Оппозитив фикерләүне без Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан әсәрләрендә еш очратабыз. Мондый художестволы-фәлсәфи фикерләү аеруча Ш.Камал иҗатына хас булды.

Шәриф Камала үзенең оппозитив фикерләвендә кеше тормышы, эшчәнлеге белән бәйле капма-каршы төшенчәләр белән актив эш итә. «Акчарлаклар» әсәрендә, мәсәлән, Ш.Камал иҗтимагый гаделсезлекне художестволы антитеза, ягъни бинар оппозиция ярдәмендә сурәтли: балык эзләүче акчарлаклар / бәхет эзләүче эшчеләр; акчарлаклар елый / акчарлаклар көлә; кырык мең табыш турында хыялланучы промысел хуҗалары / кырык сумлык хезмәт хакына өмет итүче эшчеләр; байлар йортындагы йомшкак түшәк / эшчеләрнең салам җәелгән ятагы һ.б.

Шәриф Камал татар сүз сәнгатендә XX йөз башы мәдәни яңарышын башлап җибәргән, психологик прозага нигез салган язучыларның берсе буларак билгеле. Бер яктан, үз чоры татар җәмгыятендәге төрле катлау, бигрәк тә хезмәт кешеләренең (сезонлы эшчеләр, балыкчылар, шахтерлар), интеллигенция вәкилләренең яшәешен тормышчан картиналарда һәм образларда тасвирлап, язучы милли

әдәбиятка өр-яңа темалар алып килә: матди хәлләре чиктән тыш авыр булган татарларның читтә бәхет эзләве, сукбайлык, матди-иҗтимагый шартларның кеше язмышларын җимерүе шундыйлардан. Икенче яктан, форма өлкәсендә татар прозасында башланган үзгәрешләр дә Ш. Камалның 1909–1910 елларда иҗат ителгән кыска хикәяләренә барып тоташа. Ул XX йөз башы татар әдәбиятына сәнгатьнең гади кешеләр күңелендәге матурлыкны, рухи байлыкның танып белеп бетерү мөмкин булмаган тирәнлеген, кешенең тормыштагы һәр мизгелгә җылы мөнәсәбәт белдерә, ягъни бәхет кичерә алуын сурәтләргә тиешлеге хакындагы карашны алып килә, кешеләрнең катлаулы психологиясен, эчке дөньясын, рухи үзгәрешләрне, хәтта аң төпкелендә барган процессларны сурәтләү объектына әйләндерә. Эмоциональ-лирик моң, аз сүз белән бирелгән тирән мәгънә, композицион җыйнаклык һәм тыгызлык – әдипнең хикәяләренә әнә шул сыйфатлар хас.

Бинар оппозиция – структуралистик теориядә кулланыла торган концепция, ул ике каршылыклы төшенчәне (мисал өчен, кара-каршы, яхшы-җиңел) анализлау өчен кулланыла. Әдәбиятта ул геройлар, конфликтлар, сюжет һәм тематика арасында катлаулы мөнәсәбәтләрне аңлату өчен файдалы инструмент булып тора.

Шәриф Камал прозасында бинар оппозиция төрле дәрәҗәдә күзәтелә. Аның әсәрләрендә ярылып күренгән төп каршылыклар – традиция һәм яңалык, авыл һәм шәһәр, күрсәтелгән образларның мораль һәм этик аспектлары.

Камалның әсәрләрендә традицион татар мәдәнияте һәм яңалыкка омтылу арасындагы каршылыклар бик ачык итеп чагылыш таба. Әсәрләрендә автор авылның традицион кыйммәтләрен саклап калырга тырыша, ләкин шәһәр данын, яшәү рәвешен һәм заманча үзгәрешләрне дә кабул итәргә мәҗбүр була. Шәһәр шартларында аылга хас традицияләрнең шулай ук юкка чыгуы демонстрацияләнә, автор укучыны боларның бер-берсенә тәэсирен аңларга этәрә. Хәлбуки автор өчен ук авыл һәм шәһәр арасындагы каршылыклар да мөһим роль уйный. Авыл – тынычлык, бердәмлек һәм традиция символы, ә шәһәр – динамика, конкуренция һәм индивидуализм символы. Шәһәргә килүче герой авылның көне-көненә үтәгән иҗтимагый тормышының каршылыгын чагылдыра. Шәһәр тормышының катлаулылыгы һәм авыл кешеләренең физик һәм психологик авырлыклары арасында тудырылган конфликт Ш. Камал иҗат иткән образларның характер формалашуында мөһим урын алып тора.

Шәриф Камал иҗатында кешеләрнең мораль үзенчәлекләре һәм аның җәмгыятьтәге роле арасында да даими бинар оппозиция бар. Автор геройлары еш кына үз принциплары, кыйммәтләре белән көрәшә, бу

процесс дәвамында аларның шәхси һәм иҗтимагый охшашлыгы формалаша. Төп геройлар үзләренең профессиональ һәм кешелек кыйммәтләре арасында сайларга мәҗбүр була, бу исә аның мораль статусына зур йогынты ясый.

Аерым бер хикәяләрдә тормыш сынаулары кешенең аларны кабул итүенә бәйләп куелмый. Язучы, яшәешнең кешеләргә зур авырлыклар китерүен күрсәтеп, татар җәмгыятендәге бәхетсезлекләрне милли проблема буларак аңлата. «Сулган гөл»дә (1909) 19 яшьлек Камәрнең ялгызлыгы – көндәш өстенә карт ирләргә кияүгә бирелгән татар кызлары фаҗигасе кебек шәрехләнә. «Кычкырыш»та (1910) киленнәрнең – хатын-кызларның татар гаиләсендәге хокуксызлыгы игътибар үзәгенә куела. Фаҗигале күренеш белән янәшә геройлар күзаллаган, хыялланган бәхет тә кечкенә детальләрдә сиземләнә. Әйтик, «Сулган гөл»дә Камәрнең рухи ялгызлыгына 13 яшькә кадәрге балачагы һәм шул вакыттагы өмет-хыяллары каршы куела, бәхеткә омтылыш, рухи яктан үзенә якын кеше белән аралашу ихтыяҗы кичерешләр агышы кебек сурәтләнеп, Г. Халит бик дөрес билгеләгәнчә, «бу кичерешләрдә үзен бәхеткә хаклы санаган олы җанлы герой дөньясының якты бер чите, тәрәзәчеге ачылып киткән кебек» [1]. Гади бер татар кызының рухи дөньясы, аның табигать, күкләр белән аралашу гүзәллеге язучы сурәтләгән фаҗигане тагын да көчәйтергә ярдәм итә. Шундый ук алым башка хикәяләрдә дә урын ала. «Ата» (1910) хикәясендәге картаеп кына эти булган, ашлык абзарында эшләүче Корбангалинең улы туу белән бәйле хыяллары гади кешеләр яшәгән тормышның авырлыгын тасвирлауда катнаша, бер үк вакытта кешеләрнең, нинди генә кыенлыклар килүгә карамастан, бәхет кичерә алу мөмкинлеге турында сөйли.

1914 елны Ш. Камал күләмле әсәр – «Акчарлаклар» повестен төгәлли. Ул язучы хикәяләрендә очраган күп кенә мотивларны мөстәкыйль сюжет сызыклары дәрәҗәсенә үстереп язылган. Вакыт ягыннан, Каспий диңгезенә эшкә килгән кешеләрнең бер сезон – җәй башыннан көзгә кадәр – тормышларын колачлап алган повесть күп язмышлар, ялланып эшкә килергә мәҗбүр иткән сәбәпләр хакында җентекләп сөйләп, татарларның читкә эшкә йөрү хәрәкәтен тулы яктырта. Автор сурәтләгән геройлар – ярлылыкка түзә алмыйча, акча эшләргә килүчеләр. Ләкин алар арасында солдаттан кайтыр җире булмаганнар да (Хөснетдин), эчү аркасында гаиләсен җимергән мулланың балалары да (Гариф), бөлгән бай малайлары да (Федор Лашкарев) бар. Җир, азлык акча эшләргә читкә куа диюче автор бу кешеләрнең асылда бераз мая туплап, яңадан туган якларына кайтып дөнья көтәргә хыялланнуын ачыклый. Ләкин повестьта сурәтләнгән сезон да, эшчеләрнең искә төшереп-ретроспекция ясап тәкъдим ителгән алдагы еллар вакыйгалары

да бу хыялның тормышка ашарлык түгеллеген күрсәтә. Шул ук вакытта язучы читтә йөрүнең татар гореф-гадәтенә, әхлагына тискәре йогынты ясавы турында да сөйли: аракы эчү, карта уйнау, сугышу-талашу. Гариф белән Газизә мәхәббәте турындагы сюжет сызыгы да ялланып эшләүчеләрнең кабат татар авылларына кайта алмаячагына, шушы алдавыч тормыш белән яшәү дәвам итәчәгенә мисал булып килә. Газизәгә карата күңелендә җылы хисләр уянган Гариф, шулар иркенә буйсынып, кызга вәгъдә бирсә дә, бу вәгъдәнең тормышка ашмаячагы табигать сурәте аша сиздерелә. Бер тапкыр бу юлга бастыңмы – моннан котылу юк. Язучы читтә ялланып эшләүчеләрнең йортсыз-җирсез, өметсез, киләчәксез булуын ачынып сөйли. Бүгенге табыш хакында уйлау ераккарак күз ташларга мөмкинлек бирми. Газизәнең авылга кайтып эшләргә, дөнья көтәргә теләге булса да, Гариф гаилә корырга әзер түгел. Ш. Камал читтә бәхет эзләүнең милләтне инкыйразга китерә торган хәрәкәт булуын идея итеп күтәрә. Шушы фикерне ассызыклау өчен кертелгән канатсыз акчарлаклар метафорасы, аларның «тонык һәм эчпошыргыч тавыш белән елаганга да, көлгәнгә дә охшашлы гыйгылдап-гыйгылдап» кычкырынулары автор сызлануы, экзистенциясе төсен ала.

Хикәяләрендә кешеләрнең фаҗигасе яки күңел матурлыгы, рухи байлыгы яки бушлыгы хакында сөйләп, Ш. Камал һәр әсәрендә яшәешнең бер ягын ача. Аның геройлары – гади кешеләр, ләкин характер бирелеше ягыннан автор аларга бер төркемгә, сыйныф-катлау вәкилләренә хас сыйфатларны туплый, тормыш сынауларының иң авырларын үткәргән геройлар хәлиткеч мизгелдә – тагын да җаваплырак сынауны (кешелеклелек сынавын!) кичкән мәлдә сурәтләнәләр. Әйтик, «Уяну» (1909) хикәясе тегермәндә эшләүче Муса һәм аның хатыны Гафифә образлары, аларның язмышы аша тормыш китергән авырлыкларны күтәрә алмауның ике моделен тергезә. Элек бай баласы булган Муса хәзер «шәһәрнең читендә иң сәләмә, иң ярлы мәхәлләдә» яши. Язучы аның ни сәбәпләр белән бу хәлгә төшүен күрсәтми. Ләкин әлеге сынау Мусаны үзгәртә: ул эчүгә бирелә, язмышка үчен сөеп өйләнгән хатыныннан ала башлый, нишләгәнен белмәс дәрәҗәгә җиткән ерткычка әверелә. Иң соңгы сынау – үзе өчен бердәнбер кадерле кеше булган хатынын кыйнап үтергәнен белү – Мусаны акылдан яздыра. Гафифә исә сынауларны сабырлык белән кабул итә. Ире кыйнаганнан соң елгага ташланырга җыенуы да аның хакына булып чыга («Ах, үләм инде, тынычланырсың...»). Язучы бу вакыйганы Мусаның да, Гафифәнең дә фаҗигасе итеп сурәтли. Хикәяләү әле Муса хисләрен, әле Гафифә кичерешләрен тергезә һәм тормышның башкача булу мөмкинлеген искәртә. Хикәянең исеме – «Уяну» – Мусаның үзе кылган хаталарны аңлавы, мәхәббәтен югалтканлыгына төшенүе турында сөйли. «Уянган»

Муса ерткычлыгы, вәхшилеге нәтиҗәләрен күтәрә алмыйча акылдан яза. Г. Халит мондый финалны «гади кеше намусының явызлыктан, кыргыйлыктан өстенлегенә, аның вөҗдан уты сүнмәвенә, рухи матурлыгына ышаныч» уятучы дип бәяли. Ретроспекция ясап, язучы Муса һәм Гафифәнең яшь вакытларын, мәхәббәтләрен искә төшерә. Хикәядә әһәмиятле символ буларак бирелгән, Гафифәнең якасыннан өзелгән төймә мәхәббәтнең дә өзелгән булуын күрсәтеп килә. Яшьле күзгә охшап, төймә Мусага гаебен искәртә, иң якын кешесен, бәхетен, киләчәген югалтуы хакында сөйли. Шулай мәхәббәт категориясе хикәяне аерым кеше тормышы тарихыннан гомумән яшәеш кануны хакындагы фәлсәфи тарихка әйләндерә. Кеше өчен иң кадерле хиснең – мәхәббәтнең бик нәфис һәм нәзберек икәнлеген, тормыш авырлыкларын күтәрә алмыйча, аны югалтуның фаҗигагә әверелүен сөйли. Бер ясалган ялгышның, хатаның төзәтелә алмаганын укучы сызлануы объектына әйләндерә.

Халык күңелендә үз урынын алган Ш.Камал иҗаты мирасы яшәвен дәвам итә, анда күтәрелгән мәсьәләләләрне яңа алымнар белән өйрәнү, шул исәптән әсәрләрдә чагылыш тапкан бинар оппозицияләрнең функциясен тикшерү бүгенге әдәбият белеме өчен актуаль булып кала. «Хәзерге татар әдәбият белеме XX гасыр башындагы милли әдәбиятны өйрәнүнең теоретик һәм тарихи-мәдәни мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Галимнәр язучыларның иҗатын өйрәнү принципларын үзгәртергә, бүгенге көн позициясеннән әсәрләрне аңлатырга, сәнгать текстларын заманча һәм традицион анализ ысуллары белән тикшерергә, XX гасыр башындагы иҗтимагый-фәлсәфи фикер нәтиҗәсе булган әсәрләрне ачыкларга омтылалар» [2, 328].

Шәриф Камал прозасында бинар оппозиция уңышлы чагылыш таба, ул укыучыны татар җәмгыятендә һәм әдәбиятта үзгәрешләрне, конфликтларны һәм шәхесләрнең яшәү юлларын анализларга күчерә. Аның әсәрләре, традиция һәм яңалык, авыл һәм шәһәр, мораль һәм этика каршылыгы аша, укучыга дөньяны аңлауда катлаулы, әмма кирәкле көрәш күрсәтә. Шул рәвешле, Шәриф Камалның иҗаты татар прозасындагы бинар оппозициянең уникаль һәм тирән мөмкинлекләрен ача.

**Кулланылган әдәбият**

1. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

2. Шариф Камал: научно-популярный сборник. – Казан: Татмедиа, 2023. – 201 б.

3. Шарипов М.С. Дәрдемәнд иҗатын өйрәнүдә герменевтика методы // Актуальные проблемы современной татарской филологии: сборник статей X Всероссийской научно-практической конференции (9 декабря 2022 г.) / отв. ред. И.Ф. Зарипова; И.К. Фазлутдинов. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2022. – С. 328-332.

© Яхина Д.Р., 2024

## ИНФОРМАЦИЯ ОБ АВТОРАХ

**Абдиева А.Ф.,** магистрант Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Алдырханова-Каримова А.Р.,** учитель башкирского языка и литературы 3-ей многопрофильной полилингвальной гимназии-интерната «Сибай», г. Сибай, РБ.

**Афзалова Г.А.,** учитель татарского языка и литературы МБОУ «СОШ №8», г. Октябрьский, РБ.

**Ахмадулина А.А.,** студент факультета башкирской филологии, востоковедения и журналистики УУНиТ.

**Ахунова А.Р.,** преподаватель татарского языка и литературы МАОУ «Татарская гимназия № 84», г. Уфа, РБ.

**Бахронова Ш.Ж**., студентка курса Узбекско-Финского педагогического института, г. Самарканд, Узбекистан.

**Бекмирзаева Л.Р.,** ассистент Узбекско-финского педагогического университета, г. Самарканд, Узбекистан.

**Белянина Р.А.,** магистрант Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Бобокулов И.Т.,** доктор филологических наук, профессор Ургутского филиала Самаркандского государственного университета им. Ш. Рашидова, Узбекистан.

**Валиефф София,** основатель и педагог Татарской этнической школы, г. Аделаида, Австралийский Союз.

**Гайнуллина Г.У.,** кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ, г. Уфа, РБ

**Гамбарова А.Х.,** студентка факультета башкирской филологии, востоковедения и журналистики УУНиТ.

**Гареева Р.Р.,** студентка 2 курса Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Гарипова-Хасаншина В.М.,** кандидат филологических наук, заведующий кафедрой татарского языка и национальной культуры Российского исламского института, г.Уфа, РБ.

**Гарифуллин В.З.**, доктор филологических наук, профессор, заведующий кафедрой национальных и глобальных медиа Института социально-философских наук и массовых коммуникаций ФГАОУ ВО «Казанский федеральный университет», г. Казань, РТ.

**Гафарова Г.Ф.,** учитель татарского языка и литературы МБОУ СОШ с.Куяново Краснокамского района РБ.

**Гимашева Г.М.,** кандидат филологических наук, УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Губайдуллина Р.В.,** студентка факультета башкирской филологии, востоковедения и журналистики УУНиТ.

**Еникеева Д.Д.,** студентка 2 курса Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Закирова И.Г.,** доктор филологических наук, главный научный сотрудник отдела народного творчества ИЯЛИ АН РТ, г. Казань, РТ.

**Зарафутдинова Э.Т.,** учитель татарского языка и литературы МОАУ СОШ №6 городского округа город Нефтекамск, РБ.

**Зарипова И.Ф.**, кандидат филологических наук, доцент, заведующий кафедрой татарской филологии и культуры УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Зарипова К.Р.,** студентка 1 курса Восточного института Дальневосточного федерального университета, г. Владивосток, о. Русский, Приморский край.

**Ибрагимова А.Н.,** учитель английского языка академии подготовки «Harvest Academy» г. Гунсан, Южная Корея.

**Исмагилова А.В.,** студентка 3 курса Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Исянгулова Г.А.,** доктор филологических наук, профессор кафедры востоковедения и башкирского языкознания УУНиТ, г. Уфа.

**Калкаманова Г.Ф.,** учитель татарского языка и литературы МБОУ СОШ с. Субханкулово, Туймазинский район РБ.

**Камаева И.И.,** студентка 5 курса Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Камалова А.Р.,** студентка Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Камалова З.Х.,** учитель татарского языка и литературы МБОУ СОШ № 4 г. Дюртюли РБ.

**Камолов Ш.Р.,** студент Узбекско-финского педагогического университета, г. Самарканд, Узбекистан.

**Каримова З.С.,** кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ, г. Уфа, РБ

**Касимова Р.А.,** студентка 5 курса Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Кашаева А.И.,** студентка 2 курса Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Маматова Ш.Н.,** ассистент Ургутского филиала Самаркандского государственного университета им. Ш. Рашидова, Узбекистан.

**Мансурова З.Я.,** учитель татарского языка и литературы МОБУ Каранская СОШ МР Буздякский район РБ.

**Муратова М.И.,** магистрант Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Мухаметшина А.Ф.,** аспирант Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета.

**Наджмиддинова Г.Н.,** докторант Навоийского государственного университета, Узбекистан.

**Наджмиддинова М.Н.,** преподаватель Навоийского государственного университета, Узбекистан.

**Насибуллина Н.Ш.,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН Республики Татарстан, г. Казань.

**Нуралиев Г.К.,** ассистент Ургутского филиала Самаркандского государственного университета им. Ш. Рашидова, Узбекистан.

**Нурмухамедова Мафтуна У.**, преподаватель Узбекско-финского педагогического университета, г. Самарканд, Узбекистан.

**Нурмухамедова Мохира У.**, ассистент Узбекско-финского педагогического университета, г. Самарканд, Узбекистан.

**Рахимова Г.И.,** магистрант Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Рузикулова А.,** студентка Узбекско-финского педагогического университета, г. Самарканд, Узбекистан.

**Сагидуллина Л.Р.,** кандидат педагогических наук, доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Самитова С.Г.,** кандидат филологических наук, доцент кафедры ОДО Казанского национального исследовательского технологического университета (КНИТУ), г. Казань, РТ.

**Сафина Э.Х.,** магистрант Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Сахаутдинова Л.Р.,** магистрант 1-го года обучения факультета башкирской филологии, востоковедения и журналистики УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Субаева З.Р.,** студентка 5 курса Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Сулейманова Д.Д.,** кандидат филологических наук, редактор отдела журнала «Тулпар», член Союза писателей РБ и РФ.

**Султанбаева Х.В.,** доктор филологических наук, профессор кафедры востоковедения и башкирского языкознания УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Узянбаева Н.С.,** студент факультета башкирской филологии, востоковедения и журналистики УУНиТ.

**Фазлутдинов И.К.,** кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ, г. Уфа, РБ.

**Фатыхова А.Л.**, магистрант Института социально-философских наук и массовых коммуникаций ФГАОУ ВО «Казанский федеральный университет», г. Казань, РТ.

**Фахртдинова А.А.,** студентка 5 курса Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.
**Халиуллина А.Г.,** кандидат филологических наук, доцент кафедры татарского языка и литературы БГПУ им. М. Акмуллы, г. Уфа, РБ.
**Халиуллина Н.У.,** кандидат филологических наук, доцент, заведующий кафедрой татарского языка и литературы БГПУ им. М. Акмуллы, г. Уфа, РБ.
**Хаматзянова Ф.С.,** учитель татарского языка и литературы МБОУ «Сармановская СОШ» Сармановского района РТ.
**Хамидова У.О.**, ассистент Ургутского филиала Самаркандского государственного университета им. Ш. Рашидова, Узбекистан.
**Харисова Д.Р.,** учитель татарского языка и литературы МОБУ СОШ им. Алымова А.М. с. Михайловка, Уфимский район, РБ.
**Хасанова А.Н.,** кандидат филологических наук, г. Казань, РТ.
**Хуснетдинов Р.М.,** кандидат филологических наук, и.о. заведующего кафедрой ОДО Казанского национального исследовательского технологического университета (КНИТУ), г. Казань, РТ.
**Шайхалиева Г.М.,** студентка БГПУ им. М. Акмуллы, г. Уфа, РБ.
**Шарафутдинова Л.Б.,** магистрант Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.
**Шарипов А.А.,** магистрант, г. Брно, Чехия.
**Шарипов М.С.,** кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ, г. Уфа, РБ.
**Шарипова Л.М.,** ассистент Ургутского филиала Самаркандского государственного университета им. Ш. Рашидова, Узбекистан.
**Шафикова Э.М.,** магистрант Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.
**Эшчанова Г.А.,** кандидат филологических наук, доцент Ургенчского государственного педагогического института, Узбекистан.
**Юсупов Н.О.,** преподаватель Ургутского филиала Самаркандского государственного университета им. Ш. Рашидова, Узбекистан
**Юсупова Л.Р.,** магистрант Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.
**Яхина Д.Р.,** студентка 5 курса Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ, г. Уфа, РБ.

## ЭЧТӘЛЕК


| | |
|---|---|
| *Гайнуллина Г.У.* Гали улы – гали зат (профессор Р.Г. Сибәгатов турында) | 3 |
| *Зарипова И.Ф.* Гали галим, зыялы зат | 6 |
| *Насибуллина Н.Ш., Эшчанова Г.О.* Суфиян Поварисов иҗатына, фәнни эшчәнлегенә күзәтү | 10 |
| *Сулейманова Д.Д.* Парные слова как лингвопоэтическое средство в прозе С.Ш. Поварисова | 15 |
| *Фазлетдинов И.К.* Риф Мөхәммәтҗанов – Башкортстанда татар фольклористикасына нигез салучы | 20 |
| *Халиуллина А.Г.* Суфиян Поварисов: журналист, мөгаллим, галим | 28 |
| *Шарипов М.С.* Р.Г. Сибәгатовның этнолингвистика и политология өлкәсендәге эшчәнлеге | 34 |
| *Абдиева А.Ф.* Лексико-семантический анализ фразеологизмов с колористическим компонентом «черный» (на материале русского, английского и татарского языков) | 39 |
| *Алдырханова-Кәримова А.Р.* Башланғыс кластарҙа фольклор жанрҙарын өйрәнеү | 43 |
| *Афзалова Г.А.* Татар халкының теле һәм культурасында төрки элементлар | 49 |
| *Ахмадулина А.А., Исянгулова Г.А.* Соматические фразеологизмы с компонентом аяҡ «нога» в башкирском языке | 52 |
| *Ахунова А.Р.* Татар телен өйрәнүче балаларның эти-әниләре белән эшләү юллары | 55 |
| *Бабакулов И.Т., Маматова Ш.Н., Хамидова У.О.* Сематические и словообразовательные особенности собирательных существительных русского и узбекского языков | 58 |
| *Бабакулов И.Т., Рузикулова А.Ф.* Классификация морфем русского и узбекского языков | 60 |
| *Бекмирзаева Л.Р.* Ученый энциклопедического склада… | 63 |
| *Белянина Р.А., Сагидуллина Л.Р.* Татар теле дәресләрендә һәм дәрестән тыш чараларда рустелле балаларның үзаллы эшчәнлеген активлаштыруда музыкаль технологияләрнең роле | 66 |
| *Белянина Р.А., Сагидуллина Л.Р.* Татар телен өйрәнүдә Илья Франкның уку методы | 71 |
| | |

| | |
|---|---|
| *Валиефф София* Австралиядәге татар милли-мәдәни оешмалары: кичә, бүген һәм иртәгә. | 74 |
| *Гайнуллина Г.У.* Татар телендә кешенең эчке дөньясын характерлаучы фразеологик берәмлекләрне семантик яктан төркемләү | 81 |
| *Гамбарова А.Х.* Компаратив конструкцияларҙың морфологик юл менән яһалышы | 88 |
| *Гареева Р.Р., Зарипова И.Ф.* Татар телендә лингвистика өлкәсенә караган фразеологик терминнар | 92 |
| *Гарипова-Хасаншина В.М.* Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романында антропонимик система | 96 |
| *Гарифуллин В.З.* Татар балалар матбугатының традицион кыйммәтләрне саклаудагы роле | 101 |
| *Гафарова Г.Ф.* Краснокама районы татарларының фольклор үрнәкләре | 106 |
| *Ғөбәйҙуллина Р.В.* Хәҙерге башҡорт телендә парцелляцияның өйрәнелеше | 111 |
| *Еникеева Д.Д., Зарипова И.Ф.* Татар телендә гендер компонентлы фразеологизмнарның лексик-семантик үзенчәлекләре | 114 |
| *Закирова И.Г.* Ай һәм ел фасыллары белән бәйле атамалар (мәкаль-әйтемнәр мисалында) | 121 |
| *Закирова И.Г.* «Түләк» дастанының тамырлары кая тоташа? | 126 |
| *Зарафутдинова Э.Т.* Тюркизмы в произведениях С.Т. Аксакова | 129 |
| *Зарипова К.Р., Зарипова И.Ф.* Фразеологизмы с зооним-компонентом, характеризующие человека, в русском языке | 135 |
| *Зарипова И.Ф.* Лексикографик чыганакларда «бала» концептының чагылышы | 142 |
| *Ибрагимова А.Н.* Сравнительный анализ татарского и корейского языков: сходства и различия в лексике, грамматике, фонетике и синтаксисе | 149 |
| *Иҫәнголова Г.А.* Сабир Шәрипов әҫәрҙәрендә сағыштырыуҙарҙың ҡулланылыу үҙенсәлектәре | 153 |
| *Исмагилова А.В., Сагидуллина Л.Р.* «Сүз» концептының әдәби текстта чагылышы | 157 |
| *Калкаманова Г.Ф.* Әйтем – сүзнең бизәге, ә мәкаль – сүзнең җиләге | 163 |
| *Камаева И.И.* Татар әдәбиятында «кечкенә кеше» темасының барлыкка килүе | 166 |

| | |
|---|---|
| *Камалова А.Р.* Татар телендә модаль сүзләр белән белдерелгән сүз җөмләләр | 171 |
| *Камалова А.А., Халиуллина Н.У.* Татар телендә «бәхет» концепты | 176 |
| *Камалова З.Х. Полилингваль шартларда татар һәм рус телләрен чагыштырып укыту* | 180 |
| *Каримова З.С.* Татар халык җырларында туганлык атамаларының лексик-семантик һәм стилистик үзенчәлекләре | 182 |
| *Касимова Р.А., Каримова З.С.* Татар теле дәресләрендә фразеологик әйтелмәләргә өйрәтүче чаралар | 186 |
| *Кашаева А.И., Сагидуллина Л.Р.* Татар телендә «ил» концепты | 190 |
| *Мансурова З.Җ.* Татар әдәбияты кысаларында музей дәресләренең роле | 195 |
| *Мөхәммәтшина А.Ф.* Төрки һәм кытай ризык атамаларының лексик-семантик төркемнәре | 198 |
| *Муратова М.И.* Н. Исәнбәт драматургиясендә конфликт чагылышы | 205 |
| *Муратова М.И.* Н.Исәнбәт драматургиясен мәктәптә өйрәнүнең кайбер аспектлары | 208 |
| *Najmiddinova G.N. Sun'iy intellekt texnologiyalari va ularni ta'limda qanday qilib to'g'ri ishlatish kerak* | 212 |
| *Nuraliyev G'olibjon Qurbonboyevich* Tog'ay Murodning «Otamdan qolgan dalalar» asarida qo'llanilgan ayrim harakat-holatga taqlid so'zlar talqini | 215 |
| *Нурмухамедова М.У.* Описание природы в творчестве А.Чехова, Л. Толстого и других русских писателей | 219 |
| *Нурмухамедова М.У.* Развитие эпического жанра в литературе алтайских и славянских народов | 221 |
| *Нурмухамедова М.У., Камолов Ш.Р.* Заимствованные слова в русском и узбекском языках | 224 |
| *Нурмухамедова М.У., Бахронова Ш.Ж.* Принципы изучения биографии А.П. Чехова в средних и старших классах | 227 |
| *Рахимова Г.И., Каримова З.С.* Лилия Сагидуллина иҗатында синонимнар стилистикасы | 231 |
| *Сагидуллина Л.Р.* Татар теленә өйрәтүдә лингвистик уеннар | 236 |
| *Сагидуллина Л.Р.* Татар телендә «гомер» концептының репрезентациясләнүе | 243 |
| | |

| | |
|---|---|
| *Самитова С.Г., Хуснетдинов Р.М.* Урта дини уку йортлары өчен татар әдәбиятыннан дәреслек-хрестоматия төзү тәҗрибәсе | 248 |
| *Сафина Э.Х., Сагидуллина Л.Р.* Татар сөйләмендә сүз басымы хаталары һәм җитешсезлекләре | 253 |
| *Сахаутдинова Л.Р., Султанбаева Х.В.* Концепт «добро и зло» («изгелек һәм яуызлыҡ») в когнитивной лингвистике | 257 |
| *Субаева З.Р., Каримова З.С.* Татар теле дәресләрендә фразеологик әйтелмәләрне өйрәнгәндә мөхәммәт мәһдиев иҗатыннан файдалану | 260 |
| *Султанбаева Х.В., Гимашева Г.М.* Концептосфера «ғаилә» («семья») с гендерной характеристикой «женщина» | 264 |
| *Үҙәнбаева Н.С., Иҫәнғолова Г.А.* Башҡорт телендә дарыу үләндәренең атамалары һәм уларҙың халыҡ медицинаһында ҡулланылышы | 267 |
| *Фазлутдинов И.К.* Татарские баиты: современное состояние и перспективы изучения жанра | 272 |
| *Фатыхова А.Л.* Татар теле дәреслекләрендә коммуникатив методка нигезләнеп укытуның чагылышы | 282 |
| *Фахртдинова А.А.* Дәрдемәнд  иҗатында фәлсәфи мотивлар чагылышы | 284 |
| *Харисова Д.Р.* Татар теле һәм әдәбияты укытуда инновацион технологияләрне кулланып укучыларның сөйләм телен үстерү | 288 |
| *Хәмәтҗанова Ф.С.* Татар телен һәм әдәбиятын укытуда фәнни тикшеренү эшләренең әһәмияте | 293 |
| *Хәсәнова А.Н.* Габделбари Баттал – журналист | 296 |
| *Шайхалиева Г.М.* Специфика стилистики современных медиатекстов на татарском языке | 302 |
| *Шайхалиева Г.М.* Репрезентация эмотива «улыбаться» в татарском языке: исторический аспект | 307 |
| *Шарафутдинова Л.Б., Гайнуллина Г.У. И*лсөяр Иксанова шигъриятендә синтаксик фигураларның кулланылышы | 313 |
| *Шарипов А.А.* Общественно-исторические процессы на Балканском полуострове  с начала XIX века до 1918 года | 317 |
| *Шарипов М.С.* Дәрдемәнд иҗатын өйрәнүдә яңа алымнар | 322 |
| *Шарипов М.С.* Дәрдемәнд һәм Башкортстан | 327 |
| *Шарипов М.С. Х*әзерге милли сәхнә әдәбиятының үсеш-үзгәреше | 332 |
| | |

| | |
|---|---|
| *Шарипова Л.М.* Сущность, педагогические и психологические особенности развития интереса к изучению языка посредством использования интегрированных образовательных технологий | 336 |
| *Шафикова Э.М., Гайнуллина Г.У.* Татар телен укыту чарасы буларак дистанцион ресурсларның методик үзенчәлекләре | 340 |
| *Юсупов Н.О.* Переводы «Илиады» Гомера на языки мира | 344 |
| *Юсупова Л.Р.* Образование служебных частей речи путем конверсии | 349 |
| *Юсупова Л.Р.* Модализация как конверсионный способ словообразования в современном татарском языке | 354 |
| *Яхина Д.Р.* Татар теле дәресләрендә сөйләм телен үстерүнең әһәмияте | 360 |
| *Яхина Д.Р.* Шәриф Камал прозасында бинар оппозиция чагылышы | 364 |

При подготовке электронного издания использовались следующие программные средства:

- Adobe Acrobat – текстовый редактор;
- Microsoft Word – текстовый редактор.

Все права защищены. Книга или любая ее часть не может быть скопирована, воспроизведена в электронной или механической форме, в виде фотокопии, записи в память ЭВМ, репродукции или каким-либо иным способом, а также использована в любой информационной системе без получения разрешения от издателя. Копирование, воспроизведение и иное использование книги или ее части без согласия издателя является незаконным и влечет уголовную, административную и гражданскую ответственность.

*Научное издание*

**АКТУАЛЬНЫЕ ПРОБЛЕМЫ**
**СОВРЕМЕННОЙ ТАТАРСКОЙ ФИЛОЛОГИИ**
***Сборник статей***
***XII Международной очно-заочной научно-практической конференции, посвященной юбилеям ветеранов кафедры:***
***100-летию со дня рождения***
***Народного писателя Республики Башкортостан,***
***доктора филологических наук,***
***профессора С.Ш. Поварисова,***
***90-летию со дня рождения доктора филологических наук,***
***профессора Р.Г. Сибагатова,***
***85-летию со дня рождения кандидата филологических наук,***
***доцента Р.М. Мухаметзянова***
***(г. Уфа, 22 ноября 2024 г.)***

*Электронное издание сетевого доступа*

*За достоверность информации, изложенной в статьях,*
*ответственность несут авторы.*
*Статьи публикуются в авторской редакции*

Подписано к использованию 27.12.2024 г.
Гарнитура «Times New Roman». Объем 6,92 Мб.
Заказ 254.
*ФГБОУ ВО «Уфимский университет науки и технологий»*
*450008, Башкортостан, г. Уфа, ул. Карла Маркса, 12.*

Тел.: +7-908-35-05-007
e-mail: ric-bdu@yandex.ru